ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ


4.2001



# Tatarstan Respublikası Prezidentı

## UKAZI

### «Tatarstan Respublikasının xalıq şağire» digən maqtawlı isem birü turında



Tatar ədəbiatın üsterüdəge olı qazanışları eçen şağir **Yarullin Fəniz Ğataulla ulına** «Tatarstan Respublikasının xalıq şağire» digən maqtawlı isem birelde.

Tatarstan Respublikası Prezidentı **M. Ş. ŞƏYMİEV**

Qazan, Kreml', 2001 yıl
13 fevral', № UP-112

# Казан утлары
# Qazan utları

*2001*

**4**

**(942)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Факил Сафин,**
**Ренат Харис,**
**Зиннур Хөснияр,**
**Розалина Шаһиева.**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Фәнис ЯРУЛЛИН. Җир башы. *Шигырь* ........ 5
Фоат САДРИЕВ. Бәхетсезләр бәхете. *Роман* ........ 6
Рашат НИЗАМИ. Кем шакый замана ишеген? *Шигырьләр* ........ 73
Якуб ЗӘНКИЕВ. Өтелгән мәхәббәт. *Роман* ........ 77
Әхмәт РӘШИТ. Уртак булсын гамьнәр, борчулар. *Шигырьләр* ........ 96
Зиннур ХӨСНИЯР. Кышлаган үгез. *Хикәя* ........ 101
Рәшит ӘХМӘТҖАН. «Ачлык мәйданы» китабыннан шигырьләр *(Р. Фәйзуллинның кереш сүзе белән)* ........ 111

### ПУБЛИЦИСТИКА

Миргазиян ЮНЫС. «Кәрәзле телефон» кәрәзлеме? ........ 121

### ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Тукайны янадан укыйбыз ........ 131

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Гөлчәчәк ГАЛИЕВА. Милләт каһарманы ........ 138
Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Алмагачлар чәчәктә *(Яшь прозаиклар иҗаты турында уйлану)* ........ 145

### КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

8—Әнфал (Табыш малы) сүрәсе ........ 154

### ФӘН

Зәрия ХӘБИПОВА. «Идегәй» дастанында ил тоту һәм тәрбия мәсьәләләре ........ 161
Вил ГАНИЕВ. XX йөз татар әдәбияты *(Тарихи-библиографик күзәтү)* ........ 174

### ЮБИЛЕЙЛАР

Мөдәррис ВӘЛИЕВ. «Мин чигенә алмыйм...» *(Хисам Камаловка 75 яшь)* ........ 180
Ləbibə İXSANOVA. Ğasır yəştəşe *(Sərwər Ədhəmovanıŋ tuuına 100 yıl)* ........ 183
Әхмәт РӘШИТ. Матурлыгын мактап таңнарның... *(Рәшит Гәрәйнең тууына 70 ел)* ........ 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ........ 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Ф. САДРИЕВА «Счастье несчастных» *(начало)*, окончание романа Я. ЗАНКИЕВА «Опаленная любовь», рассказ З. ХУСНИЯРА; стихи Р. НИЗАМИ, А. РАШИТОВА, Р. АХМЕТЗЯНОВА *(с предисловием Р. Файзуллина)*.
«Публицистика»: статья М. ЮНУСА посвящена насущным проблемам современного татарского языка и перевода.
«Литературная критика»: статьи Т. ГАЛИУЛЛИНА «Перечитывая Тукая», Г. ГАЛИЕВОЙ «Подвиг», М. ВАЛИЕВА «Яблони в цвету».
Коран на татарском языке.
«Наука»: статьи З. ХАБИПОВОЙ «Проблемы государственности и воспитания в семье в дастане «Идегей»; историко-библиографическое обозрение В. ГАНИЕВА «Татарская литература XX столетия».
В номере отмечаются юбилеи Х. Камалова, С. Адгамовой, Р. Гарая.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Весна»—фотоэтюд; известный ученый, литературовед Виль Ганиев.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": F. SADRIEV'S novel «The happiness of unhappy» (begining), Y. ZANKIEV'S novel «The burnt love» (ending), Z. KHUSNIAR'S story; the verses of R. NIZAMI, A. RASHITOV, R. AKHMETZIANOV (with R. Faizullin's preface).
"Journalism": M. UNUSOV'S article devoted to problems of Tatar language and translation.
"Literary criticism": T. GALIULLINS'S article «Reading again G. Tukai», G. GALIEVA'S article «The flowering apple-trees».
"Koran in Tatar language".
"Science": Z. KHABIPOVA'S article; V. GANIEV'S history and bibliography review «Tatar literatura of XX century».
In this issue is noted jubilees of H. Kamalov, S. Adgamova, R. Garai.
The diary of social and cultural life.
In our covers: «The spring» - photo-etude, the famous scientist and specialist in literature Vil Ganiev.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.03.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8619 Заказ А-119
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.

## Fənis Yarullin

### Cır başı

Yəşel qara belən
Şiğer yazdı şağir,
Hər süzendə anıņ naz ide.
Yotılıp uqıdı bu şiğerne hərkem,
Ə şağirneņ iseme — Yaz ide.

Ber kəy yazdı yəşen bu şiğergə
Ə yafraqlar anı cırladı.
Dərtle cillər dirijorlıq itte,
Başın iep dənya tıņladı.

Küņellərdə, yarsu yılğa bulıp,
Əllə nindi yaqtı nur aqtı.
Qoşlar qawrıyınnan moņnar tamdı,
Aq bolıtlar bulıp cır aqtı.

Şuşı cırda, ğadi genə cırda
Küpme kəç bar, küpme aşqınu!
Qırda igen bulıp şawlayaçaq
Cəyge simfoniənen başı bu.



## Фоат Садриев

# БӘХЕТСЕЗЛӘР БӘХЕТЕ

РОМАН

### 1

Алар әле кичә бергә түгел иде.
Алар әле бер атна элек сәлам дә бирешмиләр, хәтта бер-берсен күрмәмешкә салыша иделәр.
Аралары мәңгегә өзелгән кебек иде...
—Яңадан йөз ел буе ачуланышмаска ант итешәбезме, Зәнфирә?
—Ә йөз елдан соң?
—Аннан соң бер мәртәбә ачуланышабыз. Ни төсле икәнен белү өчен.
—Кызык була икән, әйеме?
Аларның сүзләрен бүлеп, әтәч кычкырды.
—Ирек, ишетәсеңме, «Кайтырга!» дип кычкыра.
—Ялгышасың. «Зәнфирә-ү-ү, кер-мәү-ү-ү!» дип кычкыра ул.
Алар рәхәтләнеп көлделәр. Бу караңгы, айсыз, йолдызлы төн алар өчен кояш белән яктыртылгандай нурлы иде. Юк-юк, төннең айлы булуы кирәкми. Ай яктысында Зәнфирәнең матур гәүдәсен болай ачык күрә алмас иде Ирек. Аһ, аның ак күлмәге! Бу ефәк күлмәкне Зәнфирә инде атнадан артык кия. Бу күлмәк аның инбашларын, күкрәкләрен, билләрен, гәүдәсенең һәрбер сыгылмасын, борылышын төнге караңгылыкта Ирекнең йөрәген өттереп алыр дәрәҗәдә аермачык, якын, кайнар итеп күрсәтте. Инбашыннан күкрәк өсләп сузылган юан чәч толымы тезенә житәр-житмәс тора. Күлмәкнең итәге дә шунда туктый. Таң якынлашканын белдереп, тагын берничә әтәч аваз салды.
—Ирек, ник әтәчләр генә кычкыра, тавыклар кычкырмый икән?

---

Фоат САДРИЕВ (1941)—*язучы, «Таң җиле» романы, «Шаһзаманов эше», «Авыш басу икмәге» кебек повесть, хикәяләр, «Их сез, егетләр!..» «Ач тәрәзәң...», «Кондырлы кодачасы» һ. б. пьесалар авторы. Мөслимдә яши.*

—Шуны да белмисенме?—ди Ирек, анын соравына тапкыррак җавап эзләп.—Тавыклар ялкау, әтәчкә аларны уяту өчен ярты төннән «Торыгыз, торыгыз!» дип тамак ертырга кирәк. Тавыклар ялындыра, ялкауланып кунакчаларында месли бирәләр. Хатын-кыз затына хас сыйфат инде ул.

—Әтәч ни кыра соң? Анын бар белгәне шул кычкыру. Тавык ичмасам күкәй сала.

—Бер күкәй салса, дөнья кубара. Ә әтәч миһербанлы, кайгыртучан. Бер ярма тапса, шуны үзе капмый, кыт-кыт-кыт килеп, тавыкларын чакыра.

Зәнфирә юри үпкәләгән булып читкә атлады, Ирек анын беләгеннән тотты.

—Җибәр, авырттырасын, беркөн дә күгәреп калган.

—Сон, ярый алайса...

Ирек тиз генә аны кочып алды, сул кулы белән биленнән, уны белән тез астыннан эләктерде дә югары күтәрде һәм иреннәреннән үпте. Зәнфирә юри чәбәләнә, ләкин башын читкә алмый, ана каракучкыл шомырт агачы да, Ирек тә, йолдызлар да, ул үзе дә салмак кына әйләнә кебек. Юк, анын башы гына әйләнә, ул айнып китә, йөзен читкә бора, аякларын селки, Ирекнең кабырга турын чеметеп ала.

—Төшер, оятсыз!

Бер кулында анын кайнар билен, икенче беләгендә кайнар тез асларын тойган Ирек кызны җиргә бастырырга мәҗбүр була. Бөтен бите, тәне ут янган хәлдә, Зәнфирә читкә атлый. Ирек нишләптер чүгәли һәм башын кыйгайтып астан аңа карый. Зәнфирә ап-ак күлмәге белән йолдызлар уртасыннан йөзеп бара. Тау өстендә дә йолдызлар, шомыртнын ботаксыз буш җирләрендә дә йолдызлар. Өй түбәләрен, морҗаларын, бөтен дөньяны йолдызлар чорнап алган. Җем-җем иткән йолдызлар эчендә ап-ак күлмәкле Зәнфирә йөзә һәм капкаларыннан кереп югала...

—Иртәгә чыгарсың бит?

—Чыкмыйм!—дигән тавышы ишетелеп кала Зәнфирәнен.

Ирек кайтырга кузгалды. Юри акрын атлады, кабат борылып килеп, капка төпләреннән сызгырып узды һәм тавышсыз гына көлә-көлә үзләренең очына юнәлде. Юк, үпкәләмәде Зәнфирә, юри генә кылана.

Ә менә үткән атнаның үткәнендә... Каһәр төшкән сишәмбе көнне... шул сишәмбедә Зәнфирә тәүге мәртәбә әлеге ак күлмәген киеп чыккан иде. Ирек күлмәкне мактады да мактады һәм шаярып кына кулын кызнын күкрәгенә салды.

—Күлмәгеннең бу төше кабарыбрак тора икән, әйеме?

Шул сүзне әйтүгә Зәнфирә чалт итеп анын янагына чапты.

—Шиндеме?

Чалт иткән тавыш тынуга Зәнфирә капкаларыннан кереп юк та булды. Ирек, күзен челт-челт йомып, авызын ачты да калды. Шул төннән соң Зәнфирә өч көн сөйләшмәде, Ирек анын янынннан кәҗә бәтие кебек теркелдәп кайтты, гафу үтенде, ялынды-ялварды, янадан кабатламам, диде. Әмма Зәнфирә бер сүз дәшмәде, өйләренә керде дә китте. Дүртенче кичтә авыз ачып нибары өч сүз әйтте:

—Оятсыз икәнсең син!

Шул сүзләрдән соң алар талашып аерылыштылар. Ирекнен җене котырып ачуы чыкты. Харап булган икән, каян килгән хан кызы. Әйтерсен, инде алар мона кадәр кочаклашмаганнар да, үбешмәгәннәр дә, гел бер-берсеннән читтә генә йөргәннәр. Борынынны бик күтәрсән, шулай кәпрәя бир, авылда кызлар бетмәгән, инде мона кадәр ялындырганнарын да җитәрлек булды, янадан әйләнеп тә карамыйм дип ант итте Ирек. Шушылай уйлагач, анын күнеле гел тынычланып калды. Кара әле ничек рәхәт бит: бүген кич белән чыгам диясе юк, кинога йә вечерга керергә аны көтеп аласы юк, озатып куясы юк. Теләсән, өендә китап укып утыр, теләсән, ятып йокла, теләсән, жанына ошаган кызны кинога алып

кер. Иң мөһиме болар да түгел. Ирек бит әле университетта читтән торып укый, төннәр буе Зәнфирә белән ырдык-шырдык сүз сөйләшеп, кирәкле-кирәкмәскә тарткалашып, һәркөн ярты төнгә кадәр гомер уздырганчы, программа буенча каралган тау-тау китапларын укыса, курс эшләрен эшләсә, меӊ мәртәбә файдалырак түгелмени? Күптән шулай кирәк иде ләбаса. Аннары Ирекнең күнелендә яна әсәрләр өлгереп килә. Зәнфирә жилбәзәк белән бушка гомер уздырганчы, шуларны ижат итәргә тотынса, әйбәтрәк булмасмыни? Көндезләрен бит боларның берсенә дә вакыты юк, ә кичләрен, әбисе әйткәндәй, урамда мачамайланып гомер үткәргәч, кайчан укыр да кайчан язар соң ул? Ирек шулай уйлады һәм шулай эшләде дә. Клубка чыкмады. Бөек акыл ияләре томнарына, философия, политэкономия, тел гыйлеме чытырманлыкларына чумды. Әмма өч көн үтү белән, аның зиһене чуала башлады, укыганы миенә сеңмәде, уйлары Зәнфирә янына йөгерде. Аның өч тиенгә ярамаслык буш сүзләре бөек акыл ияләренең тирән фәлсәфи фикер белән сугарылган дистәләрчә битләреннән кирәгрәк һәм тирәнрәк булып колагында яңгырадылар. Ул, бөтенесен онытырга теләп, теше-тырнагы белән КПСС тарихына ябышты. Бер бит, ике бит, өч бит укыды һәм кинәт үзенең эчтән генә Зәнифә турында уйлавын, күнеленнән аның белән сөйләшеп утыруын гажәпсенеп тә, оялып та фаш итте. Ул теге битләрне кабат актарды һәм, коты очып, бер нәрсәне ачты: укыганнарының бер генә сүзе дә, андагы фикерләрнең кәррәсе дә башында юк иде. Уттай ком сахрасында әллә ничә көннәр бәргәләнеп, сусыз тилмергән кеше судан бүтән берни турында да хыяллана алмаган кебек, ул да Зәнфирәдән башка бер нәрсә турында да уйлый алмады. Дүртенче көнне, акылы белән күпме генә карышса да, кемнендер житәкләп тартуына буйсынгандай, нәрсәгәдер өметләнеп, йөгерә-атлый клубка ашыкты. Аңардагы горурлык әле һаман да тыштан битарафлык күрсәтергә тырыша, эчендәгесен тирә-юньдәгеләргә сиздерми иде. Ләкин йөрәге бары тик аны уйлап, аның исеме белән генә типте. Ирек бер генә нәрсәне—аның клубка чыгуын теләде. Зәнфирә нәкъ шул ак күлмәктән, күрше кызы Роза белән иде. Алар елмаешып иң элек китапханәгә килеп керделәр, юри газета укыган булып утырган Ирек, шатлыгыннан кычкырыр дәрәҗәгә житеп, астан гына аның йөзенә күз төшереп алды да юри башын аска иде, газетага чекрәйгән булып кыланды. Ә үзенең йөрәге дөп-дөп типте, әйтерсең лә ком чүлендә суга тилмереп соңгы өметен өзгән кеше ургылып бәргән салкын чишмә янына килеп чыккан иде. Аның бөтен битенә, барлык тәненә дөртләп ут капты, йөрәгенең дөпелдәвен китапханәдәге барлык халык ишетәдер, әлеге утның кайнарлыгын һәммәсе дә ачык сизәдер һәм мона Зәнфирә сәбәпче икәнен аңлыйдыр кебек тоелды. Зәнфирә белән Роза нидәндер көлештеләр, чырык-чырык килеп кем беләндер үртәштеләр, әмма Ирек ягына күз дә атмады алар. Ул моны газетага иелгән хәлдә күзенең чите белән аермачык күреп торды. Зәнфирәнең рәхәтләнеп көлеп, берни булмагандай болай кылануы, Ireккә күз дә ташламавы коточкыч иде. Димәк, аның өчен барыбер, димәк, ул болай гына йөргән, димәк, ул Ирек кичергәннәрне кичермәгән, димәк, Ирек аны бөтенләй белмәгән. Зәнфирә, Роза белән ничек көлешә-көлешә кергән булса, шулай ук чыгып та китте. Аның жинсез ак күлмәге, кояшта каралган беләкләре һәм балтырлары, аркасыннан салынып төшкән кара чәч толымы—һәммәсе дә ишектә югалды. Ирекнең китапханәдән чыгып йөгерәсе, авылны ташлап әллә кайларга китәсе килде. Ләкин алар артыннан ук кузгалырга ярамый иде. Ул әле бер газетага үрелде, әле икенчесен актарып, күзләрен йөртеп укыгандай итте, әмма бер генә сүзнең дә мәгънәсенә төшенә алмады. Зәнфирәнең чыгып китүенә ышанмагандай, Ирекнең күз карашы тагын ишеккә тартылды. Аның теләген аңлагандай, ишек ачылып китте һәм мәктәп директоры Заһит Фәхруллинның базык гәүдәсе күренде. Ул ап-ак күлмәктән, кара галстуктан иде. Ирекнең күнеленнән ул Зәнфирәгә ошарга теләп шулай пөхтә

киенгәндер дигән көнләшүле уй йөгереп үтте. Ирек директор белән ашык-пошык исәнләште дә клубка керде. Яшьләр танцы итәләр иде. Ул беркемгә карамады, башын горур күтәргән хәлдә, урамга чыгып китте һәм кызу-кызу өйләренә таба атлады. Ләкин күпме генә борсаланып ятса да, йоклый алмады. Уйлары һаман бер тирәдә бөтерелделәр. Зәнфирәне күпме генә каралтырга, иң начар сүзләр белән тиргәргә теләсә дә, ул һаман яп-якты булып, ап-ак көлмәге белән, көмештәй чылтерәп көлүче тавышы белән күз алдына килде дә басты, килде дә басты... Бу хәл ничә мәртәбә кабатлангандыр—Ирек әйтә алмый. Зәнфирә күз алдында гәүдәләнгән саен ана чиксез рәхәт тә, кыен да, йөрәге татлы сыктау һәм сызлану белән еш-еш тибә иде...

Шушындый уйлар, кайнар кичерешләр уртасында ятканда, ул әле урамның тын иңәнлеген, әле танцының бетмәгәнлеген, яшьләрнең клубтан таралышмаганлыгын уйлады да сикереп торды. Ашыга-кабалана киенде, ишекне тавыш-тынсыз гына ачты да урамга чыкты. Әмма ләкин бераз баргач, ул, адымнарын акрынайтып, бөтенләй туктап калды. Хәзер ул клубка барып керде ди, Зәнфирәне танцыга чакырды ди. Ә Зәнфирә чыкмаса? Оятыңнан жир тишегенә ташланыргамы? Ләкин жир тишеге юк бит. Ул, шәбәргән тавык чебеше кебек, урынына барып утырачак, барлык яшьләр анардан астыртын көләчәкләр, Ирекнең Зәнфирәгә ялынып йөрүе икенче көнне үк бөтен авылга таралачак... Юк, юк, һич тә клубка барырга ярамый. Ул шулай уйлады, ә аяклары, аның уйларын ялгыш аңлагандай, Ирекне һаман шул якка әйдәделәр... «Танцыга чакырмаска, ишек төбендә көтеп торып, озата гына барырга», дип уйлады ул, аякларына сүзсез буйсынып. Ләкин аның икеле-микеле уйлары, борчылулары, бәргәләнүләре юкка булып чыкты: Зәнфирә белән Роза кайтып киткәннәр иде инде. Ул атылып-бәрелеп Зәнфирәләргә юл тотты. Тик аларның да, Розаларның да өйләрендә ут юк иде. Ирек очып диярлек шул тирәдәге урам-тыкрыкларны, Ык буйларын, үзләре йөри торган сукмакларны әйләнде, тик кызларны очрата алмады. Икенче кичне ул, алдан ук клуб каршына килеп басты, егетләр белән гәп сата-сата Зәнфирәне көтте. Роза белән ул күренгәч, алар ишектән кереп киткәндә Ирек: «Ай-яй, эреләнгән берәүләр, борылып та карамыйлар»,—диде. «А как же!»—диде Зәнфирә, күзләреннән шаян очкыннар сибеп.—Гөрбияннарга гөрбиян, көләчләргә көләч без». Ирекнең күңеле әллә нишләп китте. Ничек сагындырган, ничек кадерле, ничек якын иде бу караш, ничек ягымлы иде бу тавыш! Шушы тавыштан, ягымлы күз карашыннан Зәнфирәнең үзен гафу иткәнлеген, магнит белән тарткандай үзенә чакыруын, сагынуын аңлады. Шул кичне Ирек аны озата барды, алар аңлаштылар, татуланыштылар һәм сызылып таңнар атканчы серләштеләр...

Ирек елмая-елмая шушыларны уйлап кайтты, капка төбендә бераз туктап торды. Жәйге төннең жылы кочагыннан һич тә аерыласы килмәде. Йолдызлар бер-берсен уздыра-уздыра аңа күз кыстылар. Бөтен дөньяны йолдызлы гөмбәз биләп алган һәм ул ниндидер серләр сөйли иде кебек. Их, беләсе иде, ни бар икән шушы гөмбәз артында? Нинди тормыш кайный икән анда? Иләк күзе кебек вак-вак тишекләрдән көмеш яктылык сикергәли. Ул тишекләрнең теге ягында ни икән соң? Ирекка бу гөмбәз артында ап-ак дөньядыр, анда көмеш жан ияләре яшидер, анда гел шатлык-бәхет, елмаю-көлү генә тантана итәдер кебек тоелды...

## 2

—Бигрәкләр дә корыга китте бит әле бу!—диде Гөлжамал, тәлинкәсенә сөтле чәй өстәп.—Сабан туена кадәр дә яумаса, дөньясын көйдереп бетермәгәе.

Ана жавап бирәсе урында карты Хәйри кетердәтеп шикәр ватты да шопырдатып чәен йотты. Аның йөзе ачулы иде.

—Нәрсә булды соң сина, бүген иртәдән бирле бер сүз дәшмисең?

Карты әйтерсен лә аны ишетмәде. Чәен эчеп бетерде дә чынаягын шылтыратып каплап куйды.

—Бәй соң, карт, башка эчмисеңмени? Бер чынаяк чәй белән...

—Тирне сөртергә сөлге бир әле,—диде Хәйри, төксе генә.

Аның болай дәшүе, әлбәттә, Гөлҗамалга ошамады, ул урындыгын шыгырдатып артка этәрде дә сөлгегә китте, аны үрелеп кенә картының тезенә таба аткач, чәенә үрелде. Берсе бер сүз дәшмәде, борынгы җиз самоварның чыжылдавы гына өйгә ниндидер җанлылык бирә сыман. Хәйри тирен сөртте дә, караватка барып, әле күптән түгел генә торган урынына сузылды. Гөлҗамал, сөлгене китереп бирмәвенә үкенеп, карты янына килде.

Хәйринең авыр итеп тырышып сулыш алганлыгы ишетелеп тора иде. Гөлҗамал аның көрәктәй зур, сөякчел, тамырлары бүртеп торган кулын ике кулы белән тотты да:

—И карткаем, йөрәгең тагын бик нык кысамы әллә?—диде.

Хәйри, ана күз генә төшереп алгач, карашын түшәмгә төбәде. Кулын акрын гына карчыгының кулларыннан ычкындырып, баш астына салды.

—Малайны нишләп уятмыйсың?—аның тавышы кырыс һәм коры иде.—Иркәлисең-иркәлисең дә...—Ул сүзен әйтеп бетерә алмады, ишектә Ирек күренде.

—Әти, хәлең ничек?—диде ул, беләгенә сәгатен тага-тага.

—Менә синеке ничек?—диде Хәйри, ана яратмыйча карап.

Ирек аптырап китте, аның кашлары дереләп куйдылар.

—Нигә, әти?

—Кая барасыңны беләсең, ул сиңа колхоз җыелышы түгел, райком бюросы.

—Соң, мин бит инде, әти, әзерләндем.

—Әзерләнсәң дә... Төне буе йөрмәскә кирәк иде. Әле син бюроның ни икәнен белмисең.

—Ай Алла, карт,—диде Гөлҗамал, чебен кугандай ана таба кулын селти-селти.—Нәрсәгә кәефең юк дисәм, шушыңа булган икән. Үтәр әле, сират күпере түгел.

Хәйри житез генә торып утырды.

—Хак әйтәсең: син уйлаган сират күпере түгел, аннан хәтәррәк!

Гөлҗамал, «синең белән сүз куертып вакыт әрәм иткәнче» дигәндәй, сул кулын селтәде дә казанга кайнарланырга салган сөтен болгатырга китте. Хәйри исә кулларын артка куйган килеш бераз уйланып торды да малае каршына килде.

—Сиңа сабак итеп шуны әйтим: мин күптән беткән идем.—Ирек, ашавыннан туктап, әтисенә сораулы карашын төбәде.—Әйе, әйе! Тик бер нәрсә коткарды. Мин яшь чакта бик дуамал идем. О-о-о!

Гөлҗамал казан капкачын шапылдатып япты да йөзен аларга борды.

—Тапкансың мактаныр нәрсә! Шахтада эшләгәндә эчеп-сугышып йөрүләреңне дә әйт инде бер башлагач...

—Ник әйтмәскә? Бандага ияреп яздым хәтта. Коммунист итүләре генә коткарып калды.—Хәйри Ирекнең нәкъ каршына килеп утырды һәм, ярым пышылдауга охшаш ят тавышка күчеп, һәр сүзе саен имән бармагы белән өстәл шакылдатты:—Кешегә партия иң югары таләп куя! Бу—бөек нәрсә, улым! Үтә шуларны—син әүлия буласың!

Әлеге сүзләр тәмам барып житсен дипме, үзенең тормыш сукмакларын хәтерләпме, Хәйри тынып калды. Әтисен болай ук житди итеп беркайчан да күргәне юк иде әле Ирекнең. Шул чак әнисе, үз-үзенә сөйләнгәндәй, йомшак кына әйтеп куйды:

—Ә картаймыш көнендә үзенне нишләттеләр?

—Нишләттеләр?

—Кыерсыттылар бит...

—Һаман аңламыйсың...—Хәйри, ыңгырашуын тыеп, өзек-өзек сулыш алды.—Кыерсыттылар... Әмма партия түгел! Ул мине аягыма бастырды,

кеше итте. Мин ана гомергә рәхмәтле!..—Хәйринен күзләре дымланды, керфекләре чыланды, әмма бер генә бөртек яше дә тәгәрәп төшмәде. Карлыккан тавышы тагын сүзләрен киртләп-киртләп кискәндәй тезде:—Белеп тор: бер-бер хәл булса, син минем малаем түгел!

Ирек дертләп китте, урыныннан ничек сикереп торганын да сизми калды.

—Нинди хәл ул, әти?!

—Ана тап төшерден ни, мина ни—икесе бер...

Гөлжамал да кабынып китте:

—Бер әйбер юкка баланын жанын талкып, йөрәгенә шом салып утырмачәли, карт!..

—Тик тор! Булгач, сон була!

Урамда машина кычкырткан тавыш ишетелде. Ирек ялт итеп тәрәзәгә карады һәм партком секретаре Фидаил Ганиевнын яшел «Москвич»ын күрде. Шундук сикереп торып костюмын киде дә урамга чыгып йөгерде. Аны әтисенен кырыс карашы озатып калды.

Райкомда аларны көтеп тормаганнар иде. Коридор тулы борчулы халык, кемнәрдер каядыр ашыга, кемнәрдер папкаларын, кәгазьләрен актарып, ниләрдер тикшерә. Бюро утырышы бара торган бүлмә ишеге каршына өелешкән кешеләрнен кайсылары басып торалар, кайсылары утырган, кайсыларыдыр кычкырып сөйләшәләр, кайсыларыдыр бер урынга сыенып, пышы-пышы киләләр. Кара дермантин белән тышланган ишектән кемнәрдер кызарынып, кемнәрдер агарынып килеп чыга, алар урынына икенчеләре кереп китә. Мона кадәр тыныч, бернидән курыкмыйча килгән Ирек үзеннән күп яшькә олы кешеләрнен бу ишек каршында дер калтырап, куркып торуларын, каушап килеп чыгуларын күргәч, нининдер пошамантга төште. Әйтерсен лә ул хәтәр бер агымга эләкте, ул агым барысын да һәлакәткә сөйри һәм һәркем ярга таба йөзәргә, котылырга тели иде. Житмәсә, анын кырындагы партком секретаре Ганиев калтыранган бармаклары белән әле бер блокнотын актарып нидер эзли, әле кесәсеннән тау кадәр кәгазь өемнәре алып, бармагын теленә тигереп чылата-чылата, шуннан ниндидер саннар чүпли, әле куркулы карашы белән Иреккә төбәлеп, Устав йә программа буенча сораулар биреп куя. «Каушама, нык бул, дәшми калма, беләсенме-белмисенме, жавап бирергә тырыш», ди. Әнә шулай пошаманда сәгатьтән артык вакыт узды. Ахырда кабул итү бүлмәсендәге кыз:

—Ганиев, керегез,—дип дәште.

Партком секретаре борынын тартты, чәчен тарап куйды, битләрен кульяулыгы белән сөртте, галстугын рәтләде, костюм жиннәрен сыпыра-сыпыра, дермантин ишек төбенә килеп басты, тирән итеп сулыш алды да Ирекнен колагына:

—Минем арттан калма,—дип пышылдады.

Ике катлы ишекне үткәннән сон, алар гаять зур бүлмәгә килеп керделәр. Башта ул Иреккә мәктәпнен спорт залы кадәр тоелды. Күзенә шартлап бәрелгәне—түр стенадагы Ленин портреты, нәкъ портрет турындагы өстәл артында утыручы беренче секретарь Арсланов, сул як почмактагы өч-дүрт ал байрак булды. Аннары Ирекне стеналарнын шифоньер төсле елкылдап торучы такталар белән төреп алынган булуы гажәпсендерде. Бу ничектер карангы, күнелсез һәм һаваны кыса кебек иде. Беренче секретарьнын каршыннан сузылган озын өстәл тирәсенә ике яклап бюро членнары утырган. Өстәлнен бу башында сул бите янган, хәтта колагы эреп янагына ябышкан ябык кына кешегә Ирек куркып карады. Әллә сиземләве, әллә кайдадыр күрүе буенча, ул бу кешенен район халык контроле комитеты председателе Вафин икәнлеген чамалады. Вафинга каршы утыручы Әхнәф Шәрифуллин, башын ишеккә таба борып, Иреккә жинелчә генә күз сирпеп алды, дустанә елмайды. Райкомолнын беренче секретаре үзенен колхоз комсомол оешмасы секретарен әнә шулай сәламләде һәм бу Иреккә элеккеге хәленә кайтырга,

тынычланырга ярдәм итте. Димәк, анын биредә таянычы, үз кешесе бар. Арырак ул райкомнын идеология секретаре Шәвәлиевне, өченче секретарь Әхмәтҗановны таныды. Өстәлдән читтә—стена буйлап тезелгән урындыкларда тагын әллә кемнәр күзгә чалынды. Шул чак алар әле генә кергән ишек дөпелдәп ачылып китте, Ирек, үзе дә сизмәстән, артына борылып карады. Аннан базык гәүдәле, гаҗәп зур башлы, саргылт чырайлы, ап-ак чәчле бер кеше күренде. Ул, сизелер-сизелмәс аксап, Арсланов өстәленә таба китте. Анын белән кул биреп күреште дә:

—Сонаруым өчен гафу итегез,—диде.

Беренче секретарь дәшмәде, «ярар» дигәндәй, баш кына кагып куйды. Әлеге кеше, сул яктагы буш урындыкның берсен тартып, өстәл янына утырды һәм, алдындагы кызыл папканы ачып, андагы кәгазьләргә үрелде. Арсланов башын бераз арткарак ташлады да:

—Ганиев, башла,—диде.

Партком секретаре, кулындагы делоны ачып, Ирекнен партиягә алуны сорап язган гаризасын укыгач, анын анкетасы белән таныштырды, кемнәр рекомендация биргәнлеген, партия җыелышында бертавыштан КПСС сафларына кабул ителгәнлеген укыды. Ганиев, вакыт-вакыт һава житмәгәндәй тотлыгып, туктап алды, авыр итеп сулады, мангаена тир бәреп чыкты. Аннары ул делоны үрелеп кемгәдер бирде һәм ул, кулданкулга күчә-күчә, Арслановка барып житте.

—Тә-ә-әк,—диде Арсланов, делонын берничә битен ашыкмыйча гына ачып.—Сабитов Ирек Хәйриевич. Тә-ә-әк.—Ул, башын делодан күтәреп, шактый вакыт Ирекка туп-туры карап торды.—Укытучы, комсомол оешмасы секретаре, стена газетасы редакторы, агитатор, драмтүгәрәк житәкчесе...

Бу калын иренле, чәчләре тырпайган малайнын егерме яшьтә булуына, балалар укытуына, әллә ничә төрле җәмәгать эше алып баруына Арслановнын ышанасы килмәде шикелле. Әмма Ирекнен очкынлы күз карашынын бимазалы бәргәләнүеннән анарда нindидер зур көч яшеренгәнлеген чамалап була иде.

Ирек бит алмаларынын кызыша башлавын тойды, ят кешеләр каршында шәрә килеш калгандай, кыенсыну кичерде һәм күз керфекләрен аска төшерде.

—Кемнәрдә нинди сораулар бар?

Бер генә мизгелгә тынлык урнашты. Ирек, нindидер биеклекне сикереп үтәргә әзерләнгәндәй, үзенен бөтен барлыгын гайре табигый киеренкелек биләвен тойды. Бу менә хәзер биреләчәк сорауларны көтүдән иде. Уртада кысылыбрак утырган кечкенә гәүдәле кешенен үтә кин мангайлы пеләш башы өстәл уртасынарак авышты да Ирекка таба борылды.

—Әйтегез әле, сез партиягә ни өчен керәсез?—диде ул һәм авызын йомып та бетермичә җавап көтеп ана төбәлде.

Ирек үзе ясаган адымнын асылын бөтен житдилеге белән анлый иде. Шуна күрә каушамыйча, тыныч кына җавап бирде:

—Коммунизм төзүчеләрнен алгы сафында атлау өчен керәм.

Теге кешенен авызы ябылды, йөзе яктырып китте һәм ул «молодец» дигән мәгънәдә баш селкеп куйды. Бая, теге кеше сорау биргән мәлдә Арсланов үзенен өстәлендәге газеталар өемен актара башлаган иде. Ул район газетасын тартып чыгарды да анын дүртенче битен тулысынча биләгән «Кая барабыз?» дигән мәкаләне күтәреп күрсәтте:

—Бу сезнен мәкаләме?—диде ул Ирекка.

—Әйе,—дип җавап бирде Ирек.

—Мина мәкаләгез ошады. Фикерләрегез кызык, ләкин бер урыны белән килешмәдем.—Арсланов, шул урынны эзләп, газета битеннән күз карашы белән берничә мәртәбә йөгереп үтте.—Менә таптым. Сез кешене белмибез, дип язасыз. Ничек инде белмибез? Безнен илдә кешене ин алдынгы фән тикшерә. Әйтик, психология, социология, антропология

диик. Шуңа әдәбият, сәнгать өстәлә, кеше турында күпме хезмәтләр язылган. Сез шуларның барысын да кире кагарга телисезме?

Ирек мондый сорауны көтмәгән иде. Ул бераз каушап китте, бәлки бөтенләй дәшмәскәдер дип уйлады. Ләкин бу үз фикерләреннән чигенү булыр иде. Шуңа күрә, бераз куркып булса да, чигенмәскә булды.

—Мин кире кагарга җыенмыйм. Кешене бик аз беләбез, дим.

—Дәлилләрегез?—диде Арсланов.

Ирекнең моңа дәлилләре җитәрлек иде. Ләкин ул дәлилләрне китерә башласаң, ике сәгать вакыт та җитмәс иде. Шуңа күрә ул ин гади дәлилне китерде:

—Сез минем ни өчен партиягә кергәнемне беләсезме соң?

Бүлмә буйлап «аһ» иткәндәй ниндидер күренмәс дулкын үтте, барысы да, команда биргәндәй, башларын Ирекка таба бордылар. Ә Вафин ничектер авыз эченнән ике мәртәбә пырхылдап көлеп тә куйды. Теге кин маңгай өстәл уртасына ук сузылып аңа борылган, авызы ачылган иде. Арсланов, әллә көлүеннән тыелып, әллә көчәнеп елмаерга теләп, «менә сиңа: мә» дигәндәй, башын җинелчә генә як-якка чайкый иде.

—Ләкин партиягә ник кергәнегезне әле генә әйтеп бирдегез, ләбаса.

—Тәҗрибә күрсәткәнчә, кешенең сүзе белән эше күп чакта тәңгәл килми,—диде Ирек, бәхәсләшү кайнарлыгыннан тәм таба башлап.

Икенче секретарь Шәвәлиевнең кәгазьдәй ак чырае селкенеп куйды һәм ул:

—Сезнеке?—диде.

—Минеке тәңгәл килә. Чыннан да алгы сафта атларга телим.

Идеология секретаре аны ычкындырырга теләмәде, һөҗүмне дәвам итте:

—Ни соң ул алгы саф?

—Башкаларны үз артыңнан ияртү.

—Ничек ияртү?

—Үрнәк күрсәтеп. Әдәби әсәрләр язып, мәсәлән.

Шунда барысы да тынып калдылар. Ничектер астан, ирен читләре белән генә елмаеп утыручы кешеләрнең йөзеннән анык кына берни дә укырлык түгел иде. Әллә бу тынлыкны бозу нияте белән, әллә үзен күрсәтмәкче булып, райкомол секретаре Әхнәф Шәрифуллин беренчегә таба борылып:

—Бер генә сорау мөмкинме, Минзаһит Усманович?—диде.

Беренче, күз керфекләрен генә сирпеп, аңа рөхсәт биргәч, ялт итеп Ирекка борылды да:

—Терлекчелектә комсомол-яшьләр күп эшлиме?—диде.

—Барлык терлекчеләрнең сиксән процентка якыны комсомоллар,—дип җавап бирде Ирек, теләмичә генә.

Ул райкомол секретаренын бу сорауны ник бирүен аңламады. Чөнки беркөн комсомол активын җыйгач, Әхнәф Шәрифуллин трибунадан торып үзе: «Баллы Төбәктә фермаларда эшләүчеләрнең күпчелеге комсомоллар, Сабитовтан үрнәк алыгыз»,—дигән иде. Әхнәф Шәрифуллинның бу соравы аңа кыйммәткә төште. Шуны гына көткәндәй, Шәвәлиев комсомолның иң нечкә, иң авырткан сөяленә басты:

—Ә взнослар белән эш ничек тора?

—Түләргә теләмиләр.

—Нишләп?—диде идеология секретаре.

Ирек бер сүз дә дәшмәде.

—Нишләп түләмиләр?

—Комсомол берни дә эшли алмый,—диләр.

—Барысы дамы?

—Барысы да ук түгел.

—Сез ни дисез андыйларга?

—Комсомолның ролен аңлатам.

—Аңлату гына аз, ролен күрсәтергә дә кирәк, үзегезнең көчегез

белән. Тырышып караганыгыз бармы?

—Спорт эшен тикшергән идек. Яшьләр штангы, гер, көрәшү өчен маты, волейбол һәм шахмат кебек спорт кирәк-яраклары алуны сорадылар.

—Алдыгызмы соң?

—Юк...—Ирекнең тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты.

Партком секретаре шактый каты итеп аңа терсәге белән кагылып алды.

—Ә син төртмә аңа, Ганиев,—диде беренче секретарь, кинәт тавышын күтәреп.—Җыелышыгызда җитәкчеләр катнаштымы соң?

—Әйе, Ганиев абый да, авыл Советы секретаре дә катнашты.

—Ә колхоз рәисегез?

—Ул кирпеч юлларга чыгып киткән иде.

—Сиңа замечание, Ганиев,—диде Арсланов, бармагы белән янап.—Җил куып йөрүдән туктарга вакыт. Яшьләрнең теләген канәгатьләндерергә кирәк.

Ганиев әллә ни арада торып баскан иде инде.

—Булыр, Миңзаһит Усманович, булыр,—диде ул, башын селкә-селкә.

—Булырның чите тузмый, Ганиев. Ничәнче замечание бу сиңа? Мин берсен дә онытмыйм. Утыр.

—Сабитовны партиягә алу мәсьәләсендә нинди тәкъдимнәр бар?

Вафин, янган яңагын кулы белән каплаган хәлдә, беркемгә дә карамыйча, башын иеп:

—Фикерле егет, алырга кирәк,—диде.

—Кем дә кем Сабитовны партия сафларына алырга ди, шул бюро членнарының тавыш бирүләрен сорыйм.

Барысы да кул күтәрделәр.

—Төшерегез,—диде Арсланов.—Ну, Сабитов, сезне партиягә кабул ителүегез белән чын күңелдән котлыйбыз, коммунист исемен югары тотыгыз.

—Рәхмәт, ышанычыгызны акларммын!—диде Ирек, чын күңеленнән.

Партком секретаре торып басты, алар ишеккә юнәлделәр.

—Сабитов!

Ирек артына борылды.

—Әтиегезнең сәламәтлеге ничек?—диде Арсланов, ниндидер ягымлы, кайгыртучан тавыш белән.

—Авырып тора,—диде Ирек, аның мондый сорау бирүенә гаҗәпләнеп.

—Больницадамы ул, өйдәме?

—Өйдә...

—Ярый алайса. Сау булыгыз.

Алар, кабул итү бүлмәсендәге халыкны ерып, ашыга-кабалана беренче катка төшеп киттеләр. Район үзәгеннән чыкканчы берни дә сөйләшмәделәр, тешләренең кысылуыннан, яңакларының тартышып-тартышып куюыннан Ирек секретарьның ачулы икәнен күрде. Машина дүртенче тизлектә алга таба элдерә башлагач, ул Иреккә ташланды:

—Ни пычагыма иде инде сиңа спорт кирәк-яраклары?—диде ул, ачулы күзләрен түгәрәкләндереп.—Юк, имеш...

—Ни диярго иде соң, Ганиев абый? Алдашыргамыни?

—Дәшмәскә. Кузгатмаска. Башка сүз беткәнме?

—Ай-яй, оста син, Ганиев абый,—диде Ирек тә ачуы чыгып.—Сезгә керә торгач, аяк табаннарым калмады. Кайтарыйк, үзем юллыйм, үзем табып алып кайтам дидем.

—Миннән генә тормаганын ничә мәртәбә аңлатырга кирәк сиңа?!

—Яшьләргә вәгъдә бирмәскә идегез.

Партком секретаре кинәт:

—Кара әле, артык күп беләсең икән бит син?!—дип кычкырып җибәрде.—Яшь кенә килеш телең ай-яй озынайган!

Ул аны юл буе тиргәп кайтты. Ирек башкача бер сүз дә дәшмәде, чөнки дәшүнен файдасы юклыгын анлый иде. Ул машинадан төшеп калганда, әтисе капка төбендә басып тора иде.

—Йә, улым, ничек?—диде ул, Ирек анын янына килеп житәр-житмәстән.

—Алдылар, әти, барысы да әйбәт булды.

Әтисе саллы кулы белән анын аркасыннан какты:

—Молодец, улым, менә хәзер инде син зур кеше.

Тыштан сиздермәсә дә, Хәйринен башы күккә тиде. Менә хәзер малаена ул аеруча сокланып һәм яратып, ләкин ана сиздермичә генә караш ташлаштырды. Нәкъ үзем инде, дип уйлады ул, горурлык белән. Тимерчыбыктай конгырт чәчләр, текә ак мангай, килешле куе кашлар, эчкерсез карауччы конгырт күзләр, үрдәк баскан борыны—гел үзеннән, суйган да каплаган инде. Калын иреннәренен өскесе, әнисенекенә охшап, чәк кенә алга чыгып, бөтен йөзенә сөйкемлелек биреп тора. Гәүдәсе юка, яшь талчыбык шикелле сыгылмалы, ә куллары көрәктәй. Хәйри яшь чакта үзе дә нәкъ шундый иде, тимердәй ныклыгы белән кешеләрне шаккаттыра иде. Хәйри сиздермичә генә, жайлап кына Ирекне күзәтә, сыный. Жир казыймы, печән чабамы, утын ярамы—ару-талуны, ял итүне, тирләүне белми малае. Бу инде анын тырышлыгын күрсәтә.

Хәйри сүзсез генә тагын бер мәртәбә, яратып, малаенын инбашыннан какты.

—Әйдә, улым, төшкелекне ашап алыйк.

—Икенче ярты бит инде, әти. Әле ашамадыгызмыни?

—Сине көттек, улым, сине!—диде Хәйри, тантаналы төстә.

Ләкин аларга бу сонарган әбәтне тынычлап ашарга насыйп итмәгән икән. Әнисе савытларга аш бүлергә тотынуга, капка шыгырдаган тавыш ишетелде. Ул да булмады, ишектә киленнәре Нәфисәнен чәче-башы тузган, елаудан шешенеп беткән йөзе пәйда булды. Ул үзе әлегә еламый иде, әмма баласынын акырганы аны төргән чүпрәкләр эченнән дә йөрәкне ярырлык булып ишетелә иде. Абыйсынын хатыны исәнлек-саулык сорашмады, баланы караватка атты да:

—Булмый, түзәрлегем калмады, мин китәм!—дип еларга кереште.

Әнисенә ияреп килгән өч яшьлек Алмаз керү белән бабасына таба йөгерде.

—Бабай, мин сезне сагындым,—диде ул, йомшак ябык беләге белән бабасынын муеныннан кочаклап.

Гөлжамал, аш бүлә торган чүмечен ташлап, караватта ятучы баланын одеалын чишәргә кереште.

—Тагынниләр булды инде, килен?—диде ул өзгәләнеп.

—Бер әйбер дә юк, бер нәрсә дә булмады!—Нәфисә, йөзен куллары белән каплап, аралыкка кереп китте.—Яшәсен, эшләсен, сез дә яшәгез, ә мин китәм!..

—Кая китәсен, килен, кая?!—диде Хәйри, кисәтүле тавыш белән.

—Чистайга, әтиләргә китәм!

Киленнәренен болай тузынуы беренче генә мәртәбә түгел иде. Алар өйләнешкәннән бирле ни малайлары Мэлс, ни киленнәре бер-берсенә баш бирмәделәр. Әгәр Хәйри белән Гөлжамалнын башларындагы чал чәчләре тагын да арта төшкән икән, менә малайлары белән киленнәре сәбәпче. Гөлжамал акырып елаучы баланы күтәреп алып килде дә Нәфисәгә бирде:

—Килен, әйдә имез әле, бала ярсып беткән бит...

Алар, кече якка күчеп, чыбылдыкны тарттылар.

Алмаз да, күрәсен, тук түгел иде. Ул, бабасына куелган кашыкны алып, кабалана-кабалана ашарга тотынды. Ирек бу хәлләргә, йөрәген учы белән кыскандай, аптырап карап утырды. Бераздан әнисе белән Нәфисә керделәр, баланы караватка салдылар.

—Әйдә, ашыйк әле, килен,—диде әнисе.—Улым, кил, син дә утыр.

Ирек кечкенә Әлфиянең нәни алсу битенә, кояшка чагылудан бер ачылып, бер йомылып торучы зәңгәрсу күзләренә карап торды, аның алсу нечкә бармакларына сары шылтыравыгын тоттырды. Әлфия, әллә белеп, әллә белмичә, кулын кызу-кызу селтәде, шылтыравык шылтыр-шылтыр килде. Бу вакытта инде Алмаз ашап туйган иде, ул йөгереп Ирек абыйсы янына килде.

—Ирек абый, Ирек абый, мине матайда йөрет әле!

Ирек аны күтәреп алды, җилкәсенә утыртты, быжылдаган тавыш чыгарып, өйне бер-ике урады, аннары төшереп идәнгә бастырды.

—Бар, Әлфияне карый тор, аннары тагын йөртермен.

Өстәл янында сүзсез генә ашадылар. Барысының да күңелләре урыныннан купкан, ашның тәме киткән, ата-ана да, килен дә, Ирек тә гаҗиз иде. Хәйри тамак кырып куйды:

—Килен, син кискен сындырырга ашыкма әле.

Ул сүзен әйтеп бетерергә дә өлгермәде, Нәфисә кашыгын шартлатып куйды да сикереп торды, аның күзләре яшьләнделәр, калтыранган куллары, нәрсәгә тотынырга белмичә, әрле-бирле йөрделәр.

—Әти, мин синең ни әйтәсеңне беләм.—Ул тагын кычкырып еларга тотынды.—Кирәкми, интектермәгез... Барыбер яши алмыйбыз без... Аның миннән башка кешесе бар...—Нәфисә, караватка барып, өстәлдәгеләргә сырты белән утырды.

Бу сүзләрдән Хәйри сикереп торды.

—Әстәгъфирулла тәүбә!—диде Гөлҗамал, авызына китергән ашын кабалмыйча туктап калды. Ул бер Хәйригә, бер Ирекка, бер оныкларына аптырап карады.—Ни дигән сүз була инде бу?

—Ни әйтсәм, шул була,—диде Нәфисә, аларга борылып карамыйча.

Хәйри килене янына килеп житкән иде инде. Ул аның йөзенә таба иелде. Күңелендәге күрергә теләгәндәй, туп-туры күзләренә карарга тырышты. Әмма килене карашын яшерде.

—Әйт, килен, кеме бар аның?—Хәйринең тавышы чәчләрне үрә торгызырлык усал иде.

Нәфисә сискәнеп куйды, сикереп торып чыкты да китте. Хәйри килене урынына утырды. Алмаз тагын бабасының тезләренә үрмәләде.

—Улым, Ирек,—диде ул, оныгының чәчләрен сыпырып.—Бар, хәзер үк абыеңа шалтырат, җир тишегеннән булса да тапсыннар, җә матаең белән үзең әйләнеп кайт, ыштубы хәзер үк минем каршыма килеп бассын!

—Ярый, әти,—диде Ирек, һәм, өйдәге бу кыен халәттән котылуына сөенеп, ишек алдына чыгып китте.

Ләкин телефоннан күпме генә шылтыратса да, абыйсын тота алмады. «Сугарулы көтүлектә», диде ана орлыкчылык буенча агроном. «Хәзер үк барып табыгыз, әтиегез бик ашыгыч авылга чакыра, диегез»,—диде Ирек.

Әйтүләре соң булгандырмы, эшеннән бушый алмагандырмы, Мэлс бик соң кайтты. Ирек ишек алдында Алмазны арбага утыртып тартып йөри, Хәйри өй буендагы эскәмиядә аны көтә иде. Мэлсның мотоциклы тавышын ишетү белән Алмаз капкага таба йөгерде, әтисе белән Ирек тә шунда атладылар. Көне-төне басуда чабып, җилдә каралган, чуен төсенә кергән Мэлсның йөзе кырыс иде. Каршысына йөгереп килгән малаен күргәч, бөтенләй аптырашта калды, имәнеп китте.

—Улым, нишләп йөрисең монда?!—диде ул, гаҗәпләнгән тавыш белән.

Алмаз горурлык белән ярып салды:

—Бабайларга килдек!

—Кем белән?

—Әни белән.

Мэлс башын күтәрде, әтисенә килеп кул бирде.

—Исәнме, әти. Әллә бер-бер хәл булдымы?

—Әлегә юк бугай,—диде Хәйри кырыс кына.—Әйдә керик әле.

Өйдә Нәфисә белән Гөлҗамал өстәл әзерләп йөриләр иде.

—Син нишләп монда?—диде Мэлс, бусаганы атлап керү белән.

Аның ачулы тавыш белән әйткән бу сүзләренә Нәфисә борылып та карамады. Гөлҗамал ике кулын шапылдатып тезләренә сукты:

—И, улыкаем, әнкәй, ни хәлләрегез бар дип ник сорамыйсың? Ник исәнләшмисең? Килен кайтты—исәнләшмәде, кычкырырга тотынды. Инде син кайтып керден—исәнлек сорамыйсын. Нинди кешеләр сез? Мин бит сезне көненә ничә мәртәбә уйлап, ничә мәртәбәләр тәрәзәләрдән карап көтәм!—Гөлҗамал алъяпкыч итәген күтәреп күзләрен каплады, ул тавышсыз гына елый иде.

Мэлска чиксез кыен булып китте.

—Хак әйтәсең, әни. Чыннан да әллә нишләп беттек бугай инде без,—диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.—Рәнҗемә, зинһар.

Хәйри карчыгының инбашыннан какты.

—Ярар, карчык, тынычлан әле.

Әлфия караватта мeслэп йоклап киткән иде. Хәйри әле килененә, әле малаена берничә мәртәбә карап алганнан соң, тамак кырып болай диде:

—Мин гомер буе кешеләр алдында булдым. Әниең белән безнең тормышны алар үзләренеке кебек күреп тордылар. Беркайчан да нәселебезгә тап төшермәдек. Инде хәзер картайган көнебездә сез безне адәм хуры итәргә җыендыгызмы?

Ишек катында утырган Мэлс ике атлауда әтисе янына килеп житте:

—Әти, син ни сөйлисең?! Анлатып бир, ни булды?!

Хәйри, башын бераз артка ташлап, улының күзләренә туп-туры карады:

—Син хатының аерылып китәргә җыенганны белмисеңмени?

Мэлс кинәт турайды, аның йөзенә ачу галәмәтләре чыкты, ирennәре юкарып ачылдылар, өске тешләренең уртасындагы шырпы сыярлык аралык күренде.

—Ә-ә-ә!—диде ул сузып.—Менә хәзер аңладым! Менә ни өчен бозаулар ачтан акырып яталар, кош-кортлар урамга, күршеләрнең бакчаларына чәчелгән.—Ул Нәфисәнең каршына килеп басты.—Нәрсә, Чистайга кайтып, остабикә кебек мендәр өстендә киерелеп кенә утырасың килдемени? Бар, юлына ак җәймә!

Нәфисә дә, ана очып кунарга теләгәндәй, кулларын йодрыклады, күзеннән зәһәр очкыннар сипте:

—Син көне-төне гүләйт ит тә, мин тәүлек буе өйдә мал карыйммы?!

—Нәфисә, мин сиңа элеккесендә әйттем, соңгы мәртәбә кисәтәм дидем. Мин иген үстерергә тиеш, синең итәгеңне генә саклап ята алмыйм!

—Кем итәген саклаганыңны ачыклыйсы бар әле!—диде Нәфисә ярсып.

—Син сөйләсәң дә, чамалап сөйлә! Әти белән әни алдында икәнеңне онытма!

—Мин дөресен әйтәм. Син бит кайтып миңа бер жылы сүз дә катканың юк. Көн саен кайдадыр өстерәләсең, авызыңнан көн саен аракы исе килә.

—Аңла, зинһар: мин нидер юлларга, табарга тиеш! Мин өйдә генә утыра алмыйм. Барыбер синенчә түгел, минемчә булачак! Баланы үстер, өйдә эшлә, шуның өчен сиңа декрет ялы бирелгән. Риза булсаң, тор, риза булмасаң...

Нәфисә баласын төрә башлады:

—Китәрмен! Сөйрәлчекләрең белән яшәрсең!

—Житте сезгә!—диде Хәйри, йодрыгы белән өстәл дөпелдәтеп.

Өй тып-тын булды. Гөлҗамал килене тирәсендә бөтерелде.

—И, килен, түзәргә кирәк. Безнең нәселнең мангаена язылгандыр инде,—диде ул, бертуктаусыз киленен үгетләп.—Менә биатаң да гомере буе өйнең нәрсә икәнен белмәде, гомере буе житәкче эштә, гомере буе

кайтып кермәде. Гомерем буе үзем бөтен хуҗалыкны алып бардым.

—Тукта сайравыңнан!—Хәйринең йодрыгы тагын дөпелдәде. Аннары ничектер тыныч тавыш белән акрын гына сөйләп китте:—Менә мин сезгә карап-карап торам да аптырап куям. Инде яшегез дә бар, укыгансыз, белемегез дә җитәрлек. Тик һәркайсыгыз үзе турында гына уйлый. Ничек алай гомер итеп була соң ул? Ник алайса уртак тормыш кордыгыз?

Хәйри, алардан җавап көткәндәй, тынып калды. Мэлс та, Нәфисә дә башларын аска игәннәр иде. Мэлс нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачуга, Хәйри аңа таба кул селтәде дә сүзен дәвам итте:

—Ярар, сезнең буын шулай яши торгандыр. Ә оныклар? Аларны ник тудырдыгыз? Менә син, килен, газиз сабыйларыбызны алып китмәкче буласың. Балакайларыгызның ярты йөрәге монда өзелеп калганын беләсенме соң син? Ярты йөрәкле баладан юньле кеше чыгармы? Сезгә рәхмәт әйтерләрме алар?

—Әти, миннән түгел бит, миннән түгел!—диде Мэлс, өзгәләнеп.

—Кара әле син фәрештәне, ә!—Хәйри Мэлска таба кул селтәп алды.—Әниең бая юкка еламады. Син безне дә оныттың. Икебез дә авыру, күпме гомеребез калгандыр. Кайтып бер хәл-әхвәл сорашуың, «әти-әни» дип эндәшүең безнең өчен ни икәнен беләсенме?

—Беләм, әти,—диде Мэлс, карлыккан коры тавыш белән.

—Ә-ә-ә!—Хәйри нәрсәнедер аңлагандай тавышын сузып торды.—Син әле белгән килеш кайтмыйсың икән. Безнең янда соңгы мәртәбә кайчан булганыңны хәтерлисеңме?

Авыр тынлык урнашты. Гөлҗамал тагын тавышсыз гына елый башлады. Алъяпкыч итәге белән күз яшьләрен сөртте. Акрын гына картына ялварды:

—Ярар инде, әтисе, ярар. Балаларга каты бәрелмә.

—Менә, менә, синең гомер буе әйтә торган сүзләреңнең җимешләрен хәзер татыйбыз. Тәмлеме?

—Әти...

Мэлс сүзен әйтә алмады, тәрәзәдән күрделәр: капкадан райкомның беренче секретаре Арсланов кереп килә иде. Барысы да аптырап киттеләр.

—Әти,—диде Мэлс, ярдәм сорагандай тавыш белән.—Минзаһит Усманович үзе...

Алар икесе дә кабаланып ишеккә таба атладылар, әмма чыгып өлгерә алмадылар, Арсланов ишекне теге яктан ачып:

—Мөмкинме?—диде.

Өйдәгеләр бердәм җавап бирделәр:

—Әйдәгез, рәхим итегез!

Тупсадан иң элек, яшен ташыдай «ялт» кына итеп, Алмаз сикерде. Арсланов озын аксыл плащтан, култык астына ниндидер кәгазь төргәге кыстырган иде. Бөдрә чәчле башын иеп сәлам биргәннән соң, түргә узды, иң элек Хәйригә, аннары Мэлска кул бирде. Аны озата кереп, хәзер әкрен генә чыгып китмәкче булып ишеккә таба атлаучы Ирекне, озын кулы белән иңбашыннан эләктереп, үзенә тартты.

—Тукта, тукта, кая качмакчы буласың?!

Ирек, якыннан карагач, аның шактый өлкән булуын, күз төпләренең вак җыерчыклар белән капланганлыгын күрде.

—Менә, Хәйри Зәйниевич, бүген төпчегегез дә безнең сафка басты. Сезне шушы шатлыгыгыз белән котларга килдем.

—Рәхмәт, Минзаһит Усманович,—диде Хәйри елмаеп.—Әйдәгез, утырыгыз.

—Килгәч, утырмый булмас.—Арсланов плащын салып Ireккә бирде дә, төргәкне сүтеп, өстәлгә бер тартма конфет, лимон һәм грушалар куйды. Аннары конфет тартмасын ачып, Алмаз каршына чүгәләде:

—Ах, без бит исәнләшергә онытканбыз,—диде ул елмаеп һәм Алмазга үзенең кулын сузды.

Малай ятсынудан аптырабрак калды һәм нишлим дигән мәгънәдә,

күзләрен мөлдерәтеп, әле бабасына, әле әтисенә карады.

—Әйдә инде, улым, исәнләш егетләрчә итеп,—диде Мэлс.

Алмаз, кулын чәпелдәтеп, Арслановның учына салды, тегесе аны кыскандай итенде.

—Үскән егет икәнсен, хәзер менә бу конфетлардан авыз ит инде.

Алмаз кыюсыз гына үрелеп, бер конфет алды.

—Исемен ничек була инде синен?

—Алмаз...

—О-о-о, Алмаз! Бигрәк матур икән исемен.

Ул арада Гөлҗамал белән Нәфисә чәй ясаганнар, утырырга урындыклар куйганнар, өстәлгә суыткычтан тәм-том ташыйлар иде.

—Зинһар мәшәкатьләнмәгез, мин озакка түгел,—диде Арсланов.

—Өйгә кергәч, бер чынаяк чәй эчми китмәссең инде,—диде Хәйри.

—Рәхмәт, рәхмәт,—диде Арсланов.

Ирләр өстәл янына утырдылар. Мэлс кыяр-кыймас кына кунакка дәште:

—Бәлки бераз гына теге, «Чистай малаен» да тотып куербыз, ә?

—Тәкъдимегез өчен рәхмәт, анысын ук булдырып булмас. Менә быел игеннәр унса, әйбәт кенә җыйнап ала алсак, бәлкем әле, Мэлс Хәйриевич, сезнең белән «тегесен» дә чемердәтә-чемердәтә гәпләшеп булыр.

—Мин сезнең бу сүзләрегезне урып-җыюдан соң хәтерегезгә төшерергә тырышырмын,—диде Мэлс елмаеп.

—Ләкин бит моның өчен шактый тирләргә туры киләчәк. Мин бая гына сезнең теге урман артындагы басуыгыз яныннан үттем, Мэлс Хәйриевич. Андагы бодайның куелыгы бер дә ошамый миңа. Яз көне чәчү нормасы турында кисәткәч, сез кабул итмәдегез.

Мэлс чынаягын чыкылдатып тәлинкәсенә куйды, торып басты, кабат утырды.

—Минзаһит Усманович!—диде ул, үпкәләгән тавыш белән.—Өстәл янында да бюро оештырмыйк инде.

—Мэлс!—Хәйри улына борчылып, ачу белән карады.

Үтә дә кыен, күңелсез тынлык урнашты. Арсланов иреннәрен кыскан хәлдә чынаяктагы чәен калагы белән челтер-челтер болгатты, әйтерсен лә ул аннан нидер эзли иде.

—Мэлс Хәйриевич...—Ул, әйтимме-юкмы дигәндәй, сүзләрен берәм-берәм көттереп кенә чыгарды.—Мин сездә беренче мәртәбә, ни әйтсәгез дә, мин кунак.

—Мин дә кунак, Минзаһит Усманович,—Мэлс та аның кебек үк акрын гына сүзләрен үлчәп кенә әйтте.—Әле менә кайтып кына кердем...

—Сез бит әле яшь кеше,—диде Арсланов, тавышына бернинди кисәтү билгеләре чыгармыйча.—Тынычрак булырга, тыелырга кирәк.

—Сез дә артык карт түгел, Минзаһит Усманович.—Мэлс, бераз дәшми торгач, сүзен дәвам итте:—Ә кешегә акыл бирүе шулкадәр җайлы...

—Мэлс, улым!

Ләкин Мэлс әтисенең кисәтүле эндәшүенә игътибар итмәде. Арсланов башын күтәрде. Бер генә секунд эчендә аның күзләрендә ниндидер усал очкыннар уйнап алды.

—Җайлы дисезме? Миңа да акыл бирегез әле.

—Ачуланмассызмы соң?

—Юк.

—Сезгә хуҗалык органнарын алыштырмаска, үз эшегез белән шөгыльләнергә киңәш итәр идем мин.

—Туктый беләсеңме син, малай актыгы, юкмы?!

—Чү, чү! Тыймагыз, туры килгәндә сөйләшеп калыйк әле... Сезнең беттеме, Мэлс Хәйриевич?

—Бетүен бетмәде, шулай да берлеккә җитеп торыр.

—Әгәр ул хуҗалык органнары үз эшләрен башкармасалар?

—Ник башкармасыннар икән? Менә мин агроном, сездән килгән фәрман буенча фәлән көндә фәлән культураны фәлән җиргә чәчәргә тиеш. Йә, әйтегез әле, каян беләсез сез моны? Турысын гына әйткәндә, аны әле мин дә белеп бетермим, шундагы халык кына белә.

—Рәхмәт киңәшегез өчен, искә алырмын.

—Ай-һай, ай-һай...

Мэлс «ай-һаен» бетерергә өлгермәде, әтисе, кискен генә борылып, аның янагына чабып та җибәрде.

—Сез нишлисез, Хәйри Зәйниевич?!—диде Арсланов, бу көтелмәгән хәлдән аптырап калып.

Мэлс исә янагын кулы белән тотты да бер сүз дә дәшә алмады.

—Кем белән сөйләшкәнеңне әз генә чамалап сөйләш, малай актыгы!—диде Хәйри, аңа йодрыгын селкеп.—Ул сиңа урам малае түгел, райком секретаре!

—Их, әти!—Мэлсның ачудан тыны кысылды.—Гомерең буе райкомнан куркып яшәдең инде. Хәзер дә куркасың.

—Юк, курыкмадым, хөрмәт иттем,—диде әтисе, горур тавыш белән.—Әле мин хәзер дә райком члены.

Мэлс кулын селтәде дә чыгып китте.

—Үз малаеңа суксаң да ярый ул,—диде Хәйри, Арслановның каршында акланырга теләгәндәй.—Әзрәк файдага булмасмы.

Алар бераз тын гына утырдылар. Аннары Арсланов торып плащын алды һәм кабат Хәйри янына килде. Аның дулкынланганы йөзенә чыккан иде.

—Беләсезме, Хәйри абый...—Аның беркайчан да Хәйригә исеме белән эндәшкәне юк иде.—Беләсезме... Мин бит сезнең янга бүген махсус килдем... Әллә ничә мәртәбә райкомда очраганда бүлмәмә чакырмакчы булдым, кыюлыгым җитмәде. Дөресрәге, рәсми итеп сөйләшергә теләмәдем.—Ул бераз тынып торды.—Хәйри абый... булдыра алсаң, кичер син мине... Мин бик зур гаепле синең каршыда.

—Ә нәрсә өчен кичерергә тиеш мин сине?!—диде Хәйри, аңламамышка салынып.

—Нәрсә өчен икәнен син бик яхшы аңлыйсың. Ашыктым мин, кабаландым һәм шуның аркасында ялгыштым да. Сине терелеп җиткәнгә кадәр председательлектән аласы булмаган икән...

—Юкка борчыласыз,—диде Хәйри, үткәндәге рәнҗүләре кузгала башлавын сизеп. Шуны туктату өчен сүзне ул Арсланов ягыннан дәвам итте:—Хирурглар чирне кисеп атканны артык күрә. Әгәр сезнең урында булсам, мин дә шулай эшләгән булыр идем.

Хәйри хак әйтәме, әллә болай гына, сүз өчен генә әйтәме икәнен белү өчен Арсланов аңа шактый вакыт текәлеп карап торды, карт коммунистның арыган күзләреннән, тирән җыерчыклар сызылган маңгаеннан шуңа җавап эзләде һәм сүзен дәвам итте:

—Әгәр миңа карата сез шуны эшләгән булсагыз, мин бик нык рәнҗер идем. Ә бәлкем, кем белә, сез минем мәңгелек дошманыма әверелер идегез. Аклый торган нәрсә түгел бу...

Арсланов ишеккә атлады:

—Сыегыз өчен рәхмәт, сау булыгыз,—диде. Хәйринең озатырга чыгарга җыенуын күргәч:—Юк, юк, озатып йөрмәгез, мин чаптым,—диде дә, эре-эре атлап, өйдән чыгып китте, тәрәзә турыннан чагылып кына алды һәм шапылдап капка ябылганы ишетелде...

Хәйринең йөрәге чәнчеп куйды һәм ул, хәлсезләнеп, караватка утырды. Аннары акрын гына ятты, күзләрен йомды. Беренче секретарьның гафу үтенүе йөрәктәге яраны төзәтмәсә дә, ул аның сызлавын киметә торган май сөрткәндәй, җиңеллек бирде. Әйе, рәнҗеттеләр аны. Утыз елдан артык колхоз рәисе йөген сөйрәде, нинди генә чорларны үткәрмәде, нинди генә җитәкчеләрнең кул астында эшләмәде, нинди генә әр-хур сүзләре ишетмәде, нинди генә кыен көннәр кичермәде, адәм башы

житмәс нинди генә хәлләрдән исән чыкты, берни белән дә, гаилә бәхете белән дә, саулыгы белән дә исәпләшмәде. Ә менә узган ел урак өстендә идарә утырышыннан соң, кешеләр инде бүлмәсеннән чыгып бетеп барганда, аның күз аллары караңгыланып китте, гәүдәсен тоймас булды, ләкин зиһене эшли иде. Ике кулы белән өстәл читен чытырдатып кыскан килеш: «Егетләр, туктагыз!»—дип кычкырды. Бүлмәдән чыгып баручы өч-дүрт кеше аптырап ана борылып карадылар. «Туктагыз, әз генә сабыр итегез, миңа хәзер нидер булачак»,—диде. Сүзләрен әйтеп тә бетерде, урындыгы белән бергә авып та китте... Калганын ул хәтерләми.

Больницада ул бер тәүлектән соң гына аңына килде. Гөлҗамалы, Мэлс, Нәфисә аны чиратлап унбиш көн буе сакладылар. Тәүлеге-тәүлеге белән ул бөтенләй аңсыз ятты. Чиреннән бераз айныгач, район житәкчеләре дә, үзе белән бергә эшләүче колхоз рәисләре дә, совхоз директорлары да өзлексез аның хәлен белергә килделәр, тынычландырдылар, савыгуын теләделәр, әле син безгә бик тә кирәк, диделәр. Аннары Хәйрине санаторийга жибәрделәр, ул дәваланып кайтты, инде авыл урамнарында кешеләр белән сөйләшә-сөйләшә йөри башлады, әмма врачлар аны эшли башлаудан катгый рәвештә тыйдылар. Ә Хәйринең йөрәге, ике кулын артка куеп, бернинди максатсыз, ашыкмыйча-кабаланмыйча, күккә карап йөрүгә түзә торган түгел иде. Күнелен басар өчен агач бакчасына чыкты, әле яна гына яуган жепшек карны алма төпләренә ыргытты, тыгызлап таптады. Ишек алдын көненә өч-дүрт мәртәбә себерде. Әз генә кар яуса да, капка төпләрен көрәде, тик барыбер күнеле басылмады. Җәйдән ярылмыйча калган биш-алты каен түмәре бар иде. Жинел балта белән чөй кагып, ул аларны ярырга керешге. Гөлҗамалы чыгып, аның кулыннан балтасын тартып алмакчы булды, тик Хәйри аны этеп-төртеп дигәндәй, өйгә кертеп жибәрде. Курыкма, диде, мин бит бернинди авырлык китермичә, чөй белән генә ярам, диде. Утынны ул мона кадәр күрелмәгән шатлык-куаныч тоеп ярды, үзенен тәненә көч-куәт кайтуын сизде.

Ләкин бу йөрәкнең инде күп мәртәбәләр сыналган алдавы булып чыкты. Төнлә аны ашыгыч ярдәм машинасы белән больницага алып киттеләр. Менә шул чакта аны эштән алу буенча беренче хәрәкәт башланган да инде...

Арсланов капканы ябуга, «Волга»сы янында әрле-бирле йөрүче Мэлсны күрде. Ул кызу адымнар белән аның каршына килде.

—Мин бераз арттырыбрак жибәрдем, зинһар кичерегез, Минзаһит Усманович,—диде ул.

Секретарь аның жилкәсеннән какты:

—Ярый, ярый, булгалый андый хәл.

—Хатын тәмам бәгырьгә төште. Эштән соң кайтсан да, командировкага китсән дә, райкомга бару белән куркыта. Ул бит теге бүлмәдә баласын имезгән булып, безнен сөйләшкәнне тынлап утырды. Мин, дурак, үземнең курыкмаганымны күрсәтергә теләдем.

Арсланов шаркылдап көлеп жибәрде.

—Карагыз әле, сез миңа элек тә ошый идегез, хәзер бигрәк тә нык якын булып киттегез бит әле, Сабитов. Мин туры кешеләрне яратам. Әллә берәр хуҗалыкны житәкләп карыйсызмы?

—Һе, уйларга кирәк, принципта мин каршы түгел.

—Килештек алайса?

—Килештек.

Алар кул бирештеләр дә Арсланов, руль артына утырып, кара «Волга»сын әкрен генә кузгатып алып китте һәм йөрәге әрнүдән йөзен чытып куйды. Секретарь үзе жибәргән хаталарның тагын берсен күрде. «Менә бит,—дип уйлады ул,—өлкән Сабитовны эшеннән алганбыз икән, аның урынына ник малаен куймаска иде? Хәйри Зәйниевич тә рәнжемәс, район халкы да бу ялгышны мең мәртәбә күпертә-күпертә гайбәт сатмас иде.»

Хәйрине эштән алуга ул үзе генә тәвәккәлләмәгән иде. Ничектер бервакыт «Авангард» колхозы рәисе, бюро члены Гайсә Батталов янына барып чыккач, аның бүлмәсендә кофе эчә-эчә алар шактый сөйләшеп утырдылар.

—Минзаһит Усманович, «Үрнәк» колхозы таралып бара бит, сез шуны сизәсезме?—диде Батталов.

—Ничек тарала?

—Сөт белән тәгәрәделәр, ит планы өзелү алдында, төзелешләре тукталды. Тагын нәрсә кала соң инде?—диде Батталов, ике кулын ике якка җәеп.—Хәйри абзыйның каты кулы юклыгы берничә ай эчендә үзен сиздерде. Нәрсәдер эшләргә кирәктер бит.

Аның бу сүзләре Арслановны уйга салды. Беренчедән, Батталовның «Үрнәк» өчен кайгыруын берничек тә аңлап булмый иде. Ник дисәң, үрнәклеләр һәрвакыт аның колхозының борынына чиертеп килделәр. Батталовның Сабитовтан яшерен көнләшүе районда гына түгел, хәтта республиканың кайбер җитәкчеләренә дә мәгълүм иде. Ни өчен соң әле ул алайса «Үрнәк» турында кайгырта? Ярышта «Үрнәк» җиңгән саен, Батталовның кара коелулары, «Үрнәк»нең уңышларын шик астына алып, чыгыш ясаулары юкка булды микәнни? Монда аңлашылмый торганниндидер сер ятадыр сыман тоелды. Шулай да сорыйсы итте:

—Соң син, Гайсә Батталович, нәрсә әйтмәкче буласың?—диде Арсланов, аның кысык күзләренә карап.

—Мин нәрсә әйтим? Таралып беткәнче, җыеп алырга кирәк хуҗалыкны. Сабитов инде ул барыбер эшли алмаячак. Әле кичә генә баш врач белән сөйләшеп тордык. Ул да шул ук фикердә.

Секретарь бер сүз дә дәшмәде. Кофесын эчеп бетерде дә хушлашып чыгып китте. Әмма шул көннән башлап, «Үрнәк» колхозыннан алынган һәр тискәре хәбәр, бу хуҗалыктагы һәр кимчелек аңа, аның хәтеренә Батталов белән булган әлеге сөйләшүне искә төшерде. Батталов сүзләре аңа уннан да, сулдан да, район җитәкчеләреннән дә, «Үрнәк» колхозы кешеләреннән дә ишеттерелә башлады. Соңгы тамчыны идеология секретаре Шәвәлиев тамызды.

—Колхозчылар канәгать түгел, беркем беркемгә буйсынмый, председатель мәсьәләсен ашыгыч хәл итәргә кирәк,—диде ул.

Арсланов бусында да кистереп кенә бер сүз дә әйтмәде. Бер атнадан колхоз партком секретаре райкомга чылтыратты, иртәгә колхозчыларның гомуми җыелышы, председатель мәсьәләсен кузгатсалар, нишләрбез икән, диде. Җыелышка, үзе теләп, Шәвәлиев китте.

—Җыелыш бик әйбәт үтте,—диде ул, икенче көнне иртүк Арсланов янына кереп.

Тикшерелгән мәсьәләләрне санап күрсәтте. Колхозчыларның айга-вайга карамыйча көн тәртибенә председатель сайлауны да кертүләрен һәм бертавыштан Өлфәт Җәлиловны сайлауларын җентекләп сөйләде. Җәлиловның сайлануы Арслановны гаҗәпләндермәде, ул резервта тора иде.

Бераз вакытлар үткәч, Арсланов «Үрнәк»кә сайланган яңа председательнең Шәвәлиевкә туган тиешлеген белде.

## 3

Бер айдан артык барган җәйге сессия Ирек өчен бер көн кебек тә тоелмады. Хәер, үзенең борчу-шатлыклары, сөйләп бетерә алмаслык кичерешләре белән ул бәлки унике айга да тиң булгандыр. Менә хәзер «кукурузник»та айкала-чайкала очып кайта ул. Өстә—зәңгәр күк, аста—ямь-яшел болыннар, басу-кырлар, авыллар, елга-күлләр, юлларда хәрәкәтләнүче машиналар, сыер-сарык көтүләре... Нинди сагындырган алар! Казан тормышыннан соң йөрәккә шундый якын алар! Казанда Ирек берни дә күрмәде дисән дә дөрес булыр. Китаплар, конспектлар,

уку заллары Ирекне тәмам йоттылар, әйтерсең, ул шулар эчендә эреп юкка чыкты. Төненә өч-дүрт сәгать йоклаган чаклары да аз булмады. Ул утырып та укыды, чалкан ятып та, капланып та, кырын ятып та, тезләнеп тә укыды, йоклый торган караваты, одеал-мендәрләре чүбеккә әйләнеп, җыерылып, бау кебек ишелеп бетте. Әйткән сүзне аңламас булды, кайчан ашаганын-эчкәнен онытты, дәшсәләр—борылып карамады, һаман шул укыганнары белән җенләнеп яшәде. Башкача булмый иде. Мескен читтән торып укучы бер имтиханын тапшырмаса, ана, сессиядән кайткач, эшендә акчасын түләмиләр, моны көнендә-сәгатендә хезмәттәшләре белә, аннары аның имтиханын бирә алмаганлыгы бөтен авылга тарала, ул инде җуелмаслык кара тап булып маңгаена языла. Мондый тап белән кайтып керү үлемгә тиң. Шуңа күрә мескен читтән торып укучы акылын җуяр дәрәҗәгә җитеп тырыша-тырмаша, Ходайга ялвара, нормаль кеше бер елда үзләштерә алмастай белемнәрне өч-дүрт көндә миенә сеңдерә һәм күп вакыт җинеп тә чыга. Арыган-талчыккан, ябыккан булса да, бу минутларда самолетта очып кайтканда Ирек чиксез бәхетле иде. Артында койрыгы калмау куаныч булса, аны бит әле әйтеп бетергесез тагын зур шатлык көтә. Ул—Зәнфирә. Ирек бүген иртән ана аэропорт киоскысыннан бик матур медальон алды.

Ирек әти-әнисе белән күрешеп, ашап-эчеп, бераз ял итеп алды да мәктәптән урап кайтырга булды. Исәбе—шуннан медпунктка чылтыратып, Зәнфирә белән сөйләшү иде. Ләкин мәктәп бикле булып чыкты. Ул идарәгә сугылды, почтага керде, анда кешеләр бар иде—телефоннан сөйләшергә кыенсынды. Кибеткә сугылды һәм, бераз уйлап торганнан соң, медпунктка юнәлде. Әгәр Зәнфирә каядыр чыккан, кемгәдер укол-мазар кадарга киткән булса? Ул чакта бетте баш, медпункт мөдире Хәлимә Ирекне үртәп оялтып бетерә, төрлечә сөйләндерә, чыгып та китә алмыйсың, утлы күмердә таптанган кебек иза чигәсең. Шуңа күрә ул Зәнфирә булмаган суратта тиз генә чыгып китәргә сәбәп эзли-эзли атлады.

Медпункт мөдире Хәлимә ялгызы гына иде. Ирек, хәл-әхвәл сорашканнан соң, үртәүдән котылу нияте белән, үзенчә үгезне мөгезеннән алды:

—Хәлимә апа, салкын тигергәнгә бирәр даруыгыз юкмы?

Шулчакта үзенең алдашуыннан аның чырае бурлаттай кызарып чыкты һәм, әлбәттә, моны Хәлимә күрми калмады.

—Кемегезгә салкын тиде?—диде ул, серле елмаеп.

—Үзем бераз авырып киттем...

—Ә-ә-ә, алай икән. Имтиханнарыңны бирә алдыңмы соң?

—Әйе, барысын да тапшырдым.

—Котлыйм. Алайса дүртенче курс студенты булгансың инде,—диде Хәлимә, шкафтан дарулар актара-актара.—Температураң юкмы?

—Юк, юк...

—Алайса Зәнфирәң бер үпсә—бер чирең дә калмас!—Хәлимә авызын ерды.—Ана берәр нәрсә тапшырыргамы соң?

Аның исемен ишетүгә, Ирекнең йөрәге урыныннан купты, каушавы юкка чыгып, кыюлык килде, елмаюдан калын иреннәре җәелеп китте.

—Син ана, Хәлимә апа, бер казан сәлам тапшыр.

Хәлимә кеткелдәп көлеп җибәрде:

—Казанский сәлам була инде алайса?

—Әйе, Казаннан алып кайттым...

Ирек саубуллашып чыгып китмәкче булган иде дә, Хәлимә аның беләгеннән тотып туктатты.

—Ә мина ул сәламнән өлеш чыгамы соң?—диде ул, мут елмаеп.

—Ун килограммы сина,—диде Ирек һәм чыгып китте.

Хәлимә аны тәрәзәдән күзе белән озатып калды һәм авыр итеп көрсенеп куйды... Аның Ирек өчен ничек җан атканын бу җир йөзендә беркем дә белми, бу аның гаҗәеп татлы, кешегә түгел, үзенә әйтергә дә ояла торган бер сере иде. Аны кайда гына очратса да, Хәлимәгә дөнья

яктырып киткән кебек була. Ул Иречне Зәнфирәгә кадәр үк ярата иде. Шуны сиздермәү өчен һәр хәрәкәтен, күз карашын тыйды, яшерде, бөтенесен эченә йотты. Әгәр аңа булган хисләрен кемдер сизсә, ул, ике дә уйламыйча, авылдан чыгып качар, гыйшык тотучы карт кыз дигән исемне күтәрә алмас иде. Нәкъ менә сөюен яшерүе аркасында ул аны күреп, аның белән сөйләшеп, татлы мизгелләр кичерә дә бит. Аның уйлавынча, Ирек бу җир кешесе түгел, ниндидер илаһи зат иде. Шулай булмаса, ялкындай кайнар күзләр аңа каян килсен? Аның һәр күзәнәгеннән яшәү көче ташып тора, ул сөйләгәндә, күнелендәге тирбәлешләрне нәкышьләп, иреннәре генә түгел, каш-керфекләре дә, борын, ияк, бит, янак сызыклары да хәрәкәтләнә, бер рәвештән икенче рәвешкә күчә. Дулкынланган чакларында ул бигрәк тә күркәм, күнел күгендә талпынучы тере җанның үзенә әверелә, сине сокландырып әсир итә. Иречнең инбашларыннан биленә таба нечкәреп килгән гәүдәсен кысып кочасы, бәхетсез башкаенны аның күкрәгенә куясы килә...

Ирәктән сигез яшькә өлкән Хәлимә аның белән бергә булуны, яратышуны уена да китереп карамады, бу нәрсә аның тарафыннан баштук кисеп ташланган, юк иде. Шуңа күрә ул Ирек белән Зәнфирәнең мәхәббәтеннән әз генә дә көнләшмәде. Алай гына да түгел, ике яшь йөрәкнең бер-берсен сөюе аңа шатлык-куаныч, чын ләззәт бирә иде, үз балалары бәхетенә сокланучы ана гына шулай була аладыр. Элегрәк аңа шундый мәхәббәт турында сөйләсәләр, ул ана берничек тә ышанмас, көлеп кенә куяр иде. Нихәл итмәк кирәк, тормыш дигән могҗиза күз күрмәгән, колак ишетмәгән хәлләрне һәрдаим тудырып тора шул.

* * *

Кичен көтү кайткач та Ирек үзенә урын таба алмады. Медальонын, кадерләп кәгазьгә төреп, кесәсенә салды да урамга чыкты. Кояш инде баеган, әмма караңгы төшәргә әле вакыт күп иде. Ул элек тауга менеп китте. Аның түбәсенә басып, алсу шәфәкъ нурлары астында изрәп яткан иген басуларына күз салды. Авыл өстеннән карашы белән әле унга, әле сулга үтте, һәр йортны, һәр агачны барлады. Бормаланып килүче Ыктан күзен ала алмыйча торды. Авыл сагындырган иде. Үзенең унынчы классны бетергәч, шәһәргә китү уе белән йөргән чакларын хәтеренә төшерде дә «мин нинди юләр булганмын икән», дип уйлап алды. Кала белән чагыштырып буламы соң аларның Баллы Төбәк авылын! Биредә бәхетле иде Ирек. Янында әти-әнисе, яраткан мәктәбе, укытучылары һәм укучылары, көн саен очраша торган Зәнфирәсе—һәммәсе дә биредә.

Клубка бик барасы килсә дә, Ирек бармады. Ык буена төште, яшел бәпкә үләне баскан сөзәк ярга утырды. Зәнфирәнең өе моннан ерак түгел, ул инде аның кайтканын белә. Әз генә башын эшләтсә, ул да бирегә килергә тиеш. Су өсте тып-тын, ара-тирә уйнап балыклар чумып ала, әле һаман кайтасылары килмичә йөргән казлар, яр буендагы сай урынга җыелышып, акрын гына каңгылдашалар, кайбер туймас тамаклары, башларын суга тыгып, артларын күтәреп, ләмнән азык эзлиләр. «Әллә су коенып чыгарга микән?» дип уйлады Ирек, сикереп торып. Кеше-кара күренми, читтәрәк үлән ашап йөрүче ике-өч сыердан башка бер җан иясе дә юк иде. Ул тиз-тиз чишенде дә шопырдап суга кереп китте. Су салкынча да, җылы да, йомшак та иде. Биленнән үткәнче ерып кергәннән соң, ул колач салып йөзеп китте, арыган, талчыккан тәннәренә хәл керде, сулышы кинәйде. Ирек аръякка чыгып комга утырды, комның әле көндезге кызуы бетмәгән иде. Рәхәтләнеп, тирән итеп сулыш алды, кечкә һава белән бөтен тәненә шифалы ширбәт суырылып керде. Аннары ул, кабат йөзеп, Ыкның уртасына кадәр керде, аның комлы төбенә басты, су нәкъ муеннан иде. Бала чактагы кебек чумып, комны капшый-капшый, бик озак барды. Аннары, тыны тәмам беткәч, пух итеп өскә

калыкты һәм, суны ерып, киемнәре янына китте. Яшел чирәмгә басып, сикергәли-сикергәли, әле бер колагыннан, әле икенчесеннән су чыгарды, беләкләрен, тәннәрен сыпырып, су тамчыларын коеп төшерде. Тәненең бераз кипшенгәнен көтте дә киенеп куйды. Ул чәчен тараганда, тыкрык башыннан болайга төшеп килүче Зәнфирә күренде. Инде карангылык белән болганып баручы шәфәкъ яктысында аның баш шәүләсе, түгәрәк иңбашлары, нечкә биле, ал күлмәк итәге астыннан чыккан тез башлары һәм балтырлары, яр астыннан караганда, әкияти матур булып күренәләр иде. Ирек, шашып кочардай булып, ана таба атлады.

—Исәнме, Зәнфирә!

Алар кул биреп күрештеләр. Зәнфирә кызык итеп иреннәрен бөрде дә:

—Үзе авыру, ә үзе салкын суда коенып йөри!—диде.

—Һи-и, әллә ышандың? Соң, мин бит медпунктыгызга сине күрим дип кергән идем,—диде Ирек, аны кочакламакчы булып.

Зәнфирә жинел генә читкә тайпылды.

—Нишлисең, тәрбиясез тәрбияче! Әнә казлар, бозаулар карап тора.

—«Зәнфирәне кочакла» дип алар әйтте дә инде миңа.

—Казанга сәламне дә шулар тутырып жибәрмәде микән әле.

—Шулар, шулар!—Ирекнең авызы ерылды.—Нигә иртәрәк килмәдең?

—Ничек килим ди? Синең сәламнәреңне кышлыкка тозлап куйдым.—Зәнфирә рәхәтләнеп көлеп жибәрде.

—Ярар, андый һөнәрең булгач, мин сиңа Казаннан тагын берәр казан сәлам алып кайтырмын.

—Рәхмәт, булган кадәресе дә житте,—диде Зәнфирә һәм яр буйлап китеп барды.

Ирек аны култыклады, иреннәрен аның колагына якын ук китереп:

—Нигә минем хәлне сорашмыйсың?—диде.

—Нәрсә сорашыйм? Хәлеңнең мөшкеллеген Хәлимә апага әйтеп чыккансың бит инде.

—Шулай да усал син, Зәнфирә,—диде Ирек аны туктатып.—Алар инде бу вакытта өянкенең ябалдашы астында иделәр.—Белсәң ничек сагынганымны!

—Бер кинәш әйтимме, Ирек?—диде Зәнфирә, шыпырт кына.

—Әйт, әйдә!

—Сагынсаң,—диде Зәнфирә тагын да ныграк пышылдап,—аягыңны суга тык, Ирек...

—Аягымны гына түгел, инде башымнан ук суга кереп карадым... Файдасыз...

Ирек аны үзенә таба тартты, иреннәреннән үбеп алмакчы булды, ләкин Зәнфирә башын борды һәм аның кайнар иреннәре кызның колагына гына тиделәр.

—Алкамны төшерәсең!

—Зәнфирә, мин бит сиңа сәлам генә алып кайтмадым.—Ирек кесәсеннән медальонын чыгарды.

Көндез ул Зәнфирәнең комсомол билетына төшкәннән артып калган бер фоторәсемен, түгәрәкләп кисеп, медальон эченә тыгып куйган иде.

—Ай, нинди матур!—Зәнфирә медальонны кулына алды.—Бик кыйммәт тора торгандыр бу.

—Ун мең сум гына.

—Шулайдыр дип уйлаган идем аны үзем дә. Мин бу кадәр кыйммәтле әйберне ала алмыйм.

Зәнфирә шулай диде дә медальонны житез генә Ирекнең муенына кигереп куйды.

—Ә мин аны сиңа бушка бирәм.

—Ә мин аны түләмичә алмыйм.

—Түлә алайса.

—Минем ун мең сум акчам юк.

—Кирәкми миңа ун мең сум! Бер үптерүең ун медальонга тора.

Ул Зәнфирәне, муенынннан кочып, үзенә тартты һәм аның иреннәреннән үбәргә кереште. Зәнфирә читкә тартылмады, хәтта ике калак сөяге турында Ирек аның кайнар кулларын тойды. Шуннан файдаланып, ул медальонын үзенең башыннан чыгарды да Зәнфирәнең муенына төшерде. Аннары ул аның билен ике кулы белән үзенә таба кысты. Кызның күкрәкләре, бөтен гәүдәсе, тез-аяклары аңа сыланды. Инде күптән көтелгән, күптән йөрәкне ярсыткан, әллә ничә йөз километрлар аерылып торганнан соң булган бу кавышу минуты, әллә татлы булганга, әллә шулай озак көтеп алганга, тәүге үбешү ят та, яңа да, шул ук вакытта үтә таныш та иде.

—Әллә ябыккансың инде?—диде Зәнфирә, аның колагына пышылдап.

—Сине уйлап киптем,—диде Ирек, аның битенә иреннәрен тигереп.—Ә син мине сагындыңмы?

Зәнфирә дәшмәде, тик Ирек аның үзенең аркасына салган кулларының ныграк кысылып куюын тойды.

Ирекнең моңа кадәр булган шик-шөбһәләре сыпырып алгандай юкка чыкты, аларның урынын шатлык биләде...

## 4

Шәвәлиев, кичә кич сәгать дүртләрдән соң Арсланов янына кереп, машинкада басылган зур гына мәкалә биреп чыккан иде. Мәкалә республика журналының махсус заказы буенча язылды. Ул районда мәгариф, медицина, мәдәният эшләренең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында иде. Аңа материалны райкомның бөтен идеология бүлеге туплады, ә язуын район гәзите мөхәррире Абдуллинга йөкләделәр. Егерме биш битлек бу мәкаләгә район күрсәткечләренең бер генә саны да керми калмаган иде. Аны укып чыкканчы, Шәвәлиевнең күзләре күгәрде. Мәкаләне кабат эшләтерлек кеше юк иде.

Селектордан беренче секретарьның үзенә кереп чыгуын үтенгәч, Шәвәлиев чакыруның әлеге мәкалә буенча икәнлеген шундук сизенде.

—Сез моны үзегез укыган идегезме?—дип каршылады аны Арсланов, баскан килеш мәкаләгә кулы белән шап-шоп суккалап.

—Укыдым,—диде Шәвәлиев.

—Да-а-а,—дип сузды беренче секретарь.—Нишлибез соң, җибәрәбезме?

Шәвәлиев Беренченең мәкаләдән канәгать түгеллеген ишекне ачу белән сизде, шуна күрә һәр сүзен чамалап чыгарды.

—Соң, барысын да эченә ала инде ул үзе болай. Тулы картинаны бирә.

—Анысына сүзем юк. Тик моны кем укыр икән? Мине шул сорау борчый.

Арсланов өч мәртәбә мәкаләгә каты-каты итеп чиертеп алды. Әйтерсең лә ул мәкаләгә түгел, Шәвәлиевнең маңгаена чиертте.

—Минемчә, бераз кыскартып, сан боткасын киметеп, нииндидер җанлырак, кеше күңеленә тәэсир итәрдәй әйберләр кертергә иде бит, Зөфәр Шәрипович.

—Үзем тырышып карасам инде,—диде Шәвәлиев.

Зөфәр Шәрипович көндез аның белән шөгыльләнә алмады, кич, махсус килеп, бүлмәсендә ярты төнгә кадәр утырды. Тик күпме генә тырышса да, мәкаләгә җан кертерлек бер генә җөмлә дә өсти алмады. Ахырда кулдан язган биш-алты бит хезмәтен вак кисәкләргә ерткалап, үзенең булдыксызлыгына нервысы котырып, бүлмәсендә әрле-бирле йөренде.

Күпме кеше материал җыйды. Ничә төннәр Абдуллин тирләп-пешеп утырды. Инде менә хәзер Беренчегә мәкалә ошамый. Мәкалә аныкы, тик Арслановның анда бер генә фикере дә, бер генә сүзе дә

кермәгән. Аның өчен шушы кадәр зур эшне башкарган өчен Зөфәр Шәриповичны төксе караш, төртмә сүз генә көтә. Ул үзенең райкомга килгәнче, секретарь булып сайланганчы район больницасында хирург булып эшләгән чакларын сагынып хәтеренә төшерде. Ул анда үзе патша, ул үзе боера иде. Аның өчен беркем дә тырышмады. Әгәр операция ясала икән, аны үз куллары белән ясады һәм үзе җавап та тотты. Менә хәзер ул—үлеп баручы күпме авыруны терелткән кеше—егерме биш битле мескен бер мәкаләгә җан өрә алмыйча җәфалана. Әйтерсең лә ун елга якын вакыт эчендә аның баш миен алып, анда кызыл балчык тутырып куйганнар иде. Ул хәлсезләнеп, кәнәфиенә чумды, башын артка ташлап, күзләрен йомды. Аның тавык йомыркасы төсле шома ияк асты бер кабарды, бер шинде, авызы чатнап кипте. Бу минутларда ул үзен дөньядагы иң бәхетсез кеше итеп тойды. Урамнан үтүчеләр Шәвәлиев зур эш белән кайнашып, һаман райкомда утыра дип хәйран калып китәләрдер. Әйе, зур эш эшләнде. Ул инде хәзер беркайчан да хирург та була алмый, элекке күнекмәләр бетте, куллар калтырый, нервылар, бер кечкенә ботак черт иткәнгә дерт иткән куян кебек, калтырап кына торалар. Зөфәр Шәрипович, гәүдәсен турайтып, өстәлендә яткан газеталарны бер максатсыз алып-алып карады, тигезләп урыннарына куйды һәм нишләптер район газетасына игътибар итте. Аның дүртенче битендә әдәби сәхифә бирелгән, шунда Ирек Сабитовның «Укытучы йөрәге» дигән шигыре дә басылган иде. Ул шигырьне Шәвәлиев кабат укып чыкты. Матур язылган иде шигырь. Шулчак аның зиһенене яктырып киткәндәй булды. Туктале, диде ул үз-үзенә, әгәр Сабитовны чакырсаң? Бәлкем ни дә булса эшли алыр. Бу секретарьлек дәрәҗәсенә суга торган нәрсә булса да, соңгы чара иде. Икенче көнне иртән сәгать тугызда Ирек аның каршында басып тора иде инде.

—Утырыгыз,—диде секретарь.

Ирек ишек янындагы урындыкка утырды.

—Юк, юк, менә монда килегез әле.

Шәвәлиев үзенең зур өстәленә аркылы куелган кечкенә өстәлнең ике ягындагы яшел кәнәфинең берсенә күрсәтте. Ирек йомшак һәм артык иркен шул кәнәфигә сакланып кына чүгәләде. Ничектер, ике кешелек тарантаска берүзең утырган шикеллерәк иде бу.

—Мәктәбегездә әзерлек ничек бара?

—Әзерләнәбез инде, Зөфәр Шәрипович,—диде Ирек.—Өлгерербез дип уйлыйм.

—Сезгә райкомның ашыгыч поручениесе бар, Сабитов,—Шәвәлиев мәкаләнең икенче данәсен үрелеп Ирек алдына салды.—Менә шушыны шагыйрьләрчә матуррак тел белән төзәтеп чыгарга иде. Бу хәлендә ул гади отчетны хәтерләтә. Ә безгә җанлы, кешеләр дулкынланып укырлык мәкалә кирәк. Һәм белеп торыгыз,—Шәвәлиев тавышын акрынайтты,—ул бер журналда Арсланов имзасы белән басылачак.

Ирек бөтен тәненең кызышып китүен тойды, чигәсенә кан бәрде. Бу бик зур нәрсә ич. Беренче исемennән мәкалә язу, аның биеклегеннән торып күрү һәм фикерләү дигән сүз.

—Булдыра алырсызмы?

Ирек дәшмәде. Әкрен генә кәгазь битләрен актарды, ул инде аның ни турында икәнен чамалый башлаган иде, шулай да кистереп җавап бирергә батырчылык итмәде.

—Сезгә өч көн вакыт, Сабитов.

Ирек бусына да дәшмәде, секретарьга карап кына куйды.

—Җитәр бит шул вакыт?—Шәвәлиев җавап көтеп карап торса да, анардан тагын бер сүз дә ала алмады.—Директорына әйтеп куярбыз, бүгеннән син өеңдә шушы эш белән шөгыльләнәсең һәм беркемгә дә ләм-мим. Килештекме?

Ирек мәкаләне дипломатына салды да торып басты һәм акрын гына:

—Ярар,—диде.

Ул очып кайткан кебек кайтты. Аңа әле шигырь язганда да бу кадәр көчле дәрт-илһам килгәне юк иде. Чөнки бу коточкыч зур йөкләмә, моны райком тикле райком аңа ышанып тапшыра икән, бу инде нәрсәдер аңлата иде. Ул үзенә күрелмәгән көч килүен, зиһененең үткенләнүен, фикерләренең кайнавын сизде. Кайту белән верандадагы өстәле янына утырды, мәкаләне җентекләп укып чыкканнан соң, ярты сәгать уйланып утырды да дәртләнеп эшкә кереште. Шактый урыннарын сызып атты, шактый урыннарга лирик чигенешләр, фәлсәфи фикерләүләр өстәде. Ниһаять, көн ярымда эшен төгәлләде, Шәвәлиевкә илтеп тә бирде. Секретарь аны райкомның утырышлар залына алып керде, Ирек мәкаләсен кычкырып укырга кереште, дәртләнеп укудан шыбыр тиргә батты, бит алмалары кызарып чыкты, соңгы җөмләне тәмамлагач, Шәвәлиев, ике кулын чалбар кесәсенә тыгып, залны урап килде. Ул Ирекне кочып алыр хәлдә иде. Секретарь, шул әйберне эшләмәс өчен, кулларын кесәсенә тыкты да инде.Артык мактау сүзе ычкындырмас өчен фикерен әйтүдән дә тоелды. Ике мәртәбә урап-урап килгәннән соң, ул Ирек каршында туктады:

—Ярый, ярый, намус белән эшләгәнегез күренеп тора,—диде.—Мин уйлыйм, беренче секретарь канәгать булыр. Партия йөкләмәсен сез намус белән үтәдегез, маладис.

Ирек, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, торып басты һәм, саубуллашып, ишеккә юнәлде. Шәвәлиев тә аның артыннан атлады һәм җинелчә калтыранган кулларын Ирекнең иңбашына салып:

—Әле мондый йөкләмәләрнең киләчәктә дә булуы ихтимал, Сабитов,—диде.

Арсланов мәкаләне ошатты. Ул аны укып чыгу белән кулына тоткан килеш, үзе Шәвәлиев бүлмәсенә килеп керде.

—Молодец, Зөфәр Шәрипович! Мин болай үк булыр дип көтмәгән идем.

Шәвәлиевкә кыен булып китте. Ул кульъязманы машинкага биргәндә үк Сабитов эшләгәнне әйтергәме-юкмы дип баш ватты. Әйтмәгән сурәттә беренче секретарь каршында аның дәрәҗәсе бер баш күтәреләчәк, ә әйткән сурәттә, әлбәттә, күпмедер түбән төшәчәк иде. Ләкин беренче очракның ике куркыныч ягы бар: кайчан да булса мәкаләне Сабитов эшләгәнлеге билгеле булырга мөмкин. Бусы—бер. Икенчедән, Беренченең Шәвәлиевкә, син бит булдырасың дип, тагын шундый эшләр кушуы бар иде. Болар икесе дә аны куркытты. Күп уйлый торгач, ул дөреслекне яшермәскә булды һәм шуңа күрә Арслановның күзләренә туп-туры карап:

—Мин мәкаләне Сабитовтан эшләттем,—диде.

—Нинди Сабитов?

—Моннан ике-өч ай элек партиягә кабул иткән идек бит.

—Ә-ә-ә, хәтерлим ул егетне. Мондый кадрларны югалтмаска кирәк безгә, Зөфәр Шәрипович,—диде Арсланов.

## 5

Уку елы әйбәт кенә башланып китте. Сентябрь быел гаҗәеп матур, коры торды. Балалар колхозга бәрәңге алуда атнадан артык эшләделәр. Шактый көннәр чөгендер кисәргә һәм төяргә йөрделәр. Инде менә сентябрь азагында бөтен классларда гөрләп укулар башланды. Берничә көн яңгыр явып маташты да, кинәт яктырып кояш чыкты, әбиләр чуагы килде. Очсыз-кырыйсыз зәңгәр, җилсез күктә ак тожымнар йөзә, алар кайвакытларда синең битләреңә, муеныңа килеп уралалар, шулчакта җәйнең үтүе, көзнең җитүе күңелгә аеруча сагышлы булып сизелә. Агачлардан дөп-дөп алмалар коела, аяк астында сары яфраклар кыштырдый, миләшләр, баланнар кызарышып утыралар. Ирек эре-эре адымнар белән, тыкрыкта калын булып түшәлгән яфракларны кыштырдата-

кыштырдата атлап килде дә мәктәп ишек алдына керде, йөгереп диярлек баскычтан күтәрелде. Бүген ике укытучы авырып киту сәбәпле, аның кайбер дәресләргә үзгәреш кертәсе бар иде. Шуна күрә ишектән кергәндә үк портфелен ача-ача керде. Укытучылар бүлмәсендә әле беркем дә юк, Заһит Фәхруллин ялгызы гына иде. Алар кул биреп күрештеләр. Ирек шундук, расписание өстенә иелеп, юк укытучыларның дәресләрен алыштыру әмәлен эзли башлаган иде дә, директор эндәшүгә башын күтәрде.

—Син расписаниеләреңне ташла әле,—диде ул, кул селтәп.—Райкомга чакыралар. Ашыгыч!

—Кемне?

—Кемне, кемне!—диде директор, аның аңламавына ачуы килгәндәй.—Сине!

—Кем чакыра?

Ул өйдән бөтенләй башка хыяллар белән чыккан иде, шуна күрә директорның әйткәннәре аның башына тулылыгы белән барып житә алмады.

—Шәвәлиев.

—Ник?—диде Ирек, һаман аның ачуын китерергә теләгәндәй.

—Ник икәнен белсәм, үзем генә әйтер идем!—директор тавышын шактый нык күтәрде.—Вакыт уздырма инде, тизрәк бул, бар!

Турысын әйтергә кирәк, бу хәбәр пошамангa салды Ирекне.

Райкомның кабул иту бүлмәсендә кеше шактый иде. Ирекне күрү белән, секретарь кыз: «Сез Сабитов бит, әйеме?»—диде. «Әйе»,—дип жавап бирде Ирек, үзенә төбәлгән дистәләрчә күзләрнең карашыннан кызарып. Секретарь кыз, керт-керт басып, Шәвәлиев бүлмәсенә кереп китте. Бераздан ул сүзсез генә чыкты да урынына утырды. Шактый вакыт узды. Менә Шәвәлиев бүлмәсенең ишеге ачылып китте һәм аннан кулларына блокнотлар тоткан биш-алты кеше чыкты. Алар ишекне ябуга, өлкән яшьтәге чал чәчле, мәһабәт гәүдәле бер ир кермәкче булып ишеккә үрелде. Ләкин секретарь кыз, кисәтүле эндәшеп, аны урынына утыртты.

—Сабитов, керегез!—диде ул.

Ирек галстугын, костюмын рәтләгән кебек итте дә ишектән эчкә атлады. Шәвәлиев кем беләндер телефоннан сөйләшә иде, ул, кул изәп, Ирекне үзенә таба чакырды һәм өстәл аша күрешергә сузылды. Ирек аның симез-йомшак кулын куркып кына кысты да бер адым артка чигенеп куйды. Шәвәлиев телефоннан сөйләшүен дәвам иткән хәлдә, бармагы белән төртеп, теге яшел кәнәфигә күрсәтте. Ирек, кыяр-кыймас кына, барып утырды.

—Йә, ни хәлләр?—диде Шәвәлиев, сөйләшеп бетергәч.

—Рәхмәт, Зөфәр Шәрипович, әлегә ярыйсы.

Шәвәлиев, кәнәфиенә киерелеп, Ирекккә сынаулы караш ташлады. Ирек керфек астыннан гына Шәвәлиевне үз гомерендә беренче мәртәбә жентекләп карап чыкты. Аны иң хәйран калдырганы шул булды: секретарьның йөзе түгәрәк, бит очлары алмадай кызарып тора, күз төпләрендә дә, маңгаенда да бер генә жыерчык та юк иде. Чәчләре куе, чем-кара, бер генә чал чәч тә күренми. Зөфәр Шәриповичның түгәрәк гәүдәсе, үзенә килешле тегелгән кара костюм-чалбары, ак күлмәге, кызыл галстугы белән түгәрәк кәнәфигә, күкәй салырга утырган каз кебек, тап-таман кереп кенә утырган иде.

—Менә нәрсә, Сабитов,—Шәвәлиев, күкрәге белән терәлә язып, аңа таба иелде.—Мин читләтеп-чатлатып озын-озак сөйләүне яратмыйм. Партиянең район комитеты сезгә зур ышаныч күрсәтергә жыена: идеология бүлегенә инструктор итеп эшкә чакырабыз.

Ул, бу тәкъдимне Ирекнең ничек кабул итүен аңларга теләп, аңа төбәлде. Чынында секретарьның сүзләре Ирекккә кайнар су сипкән кебек тәэсир итте. Беренче секундларда ул ни уйларга да белмәде, чөнки зиһене эшкәртеп, моның нәрсә икәнлеген аңлап житкерә алмады.

—Мин сезнең җавабыгызны көтәм,—диде Шәвәлиев.

Ирек урыныннан торып басты, аның бармаклары җинелчә калтырый иде. Шуңа күрә ул кулларын артына яшерде.

—Бу бит...—Ирек ни әйтергә дә белмәде. Әле ул хәзергә әти-әнисе турында да, Зәнфирә һәм мәктәп турында да уйларлык хәлдә түгел иде.—Миңа вакыт бирегез.

Секретарьга аның шундук ризалык бирмәве ошады. Димәк, мәсьәләне төптән, төрле ягын уйлап хәл итәргә ярата, күрү белән барып капланмый, кабаланмый.

—Ярый,—диде ул, ничектер сәер генә сузып.—Күпме вакыт кирәк соң сезгә? Бер атнамы, ун көнме, бер аймы?

—Минем бит әле әти-әнием бар, йортта мин—төпчек малай,—диде Ирек, гаепле кеше кебегрәк итеп.—Мин сезгә иртәгә җавап бирермен. Телефоннан гына әйтсәм, ярармы?

Шәвәлиев аңа карап елмайды:

—Җавабыгыз уңай булса, телефоннан да ярый.

Ирек авылга кайтып җиткәнче үк нәратлыкта төшеп калды. Аңа башында бөтерелгән уйларны, күңелендәге давылны тәртипкә китерергә, булганын-булмаганын барларга, урынына куярга һәм иң элек үзе бер анык карарга килергә кирәк иде. Унбиш-егерме метр киңлектәге нәратлыкны үтеп, ул авыл ягына чыкты. Авыл моннан тулысынча күренеп бетми, аның яртысын тау каплап тора. Әмма бу төштән күрше авылларга кадәр җәйрәп ята. Көзнең чатнап торган һавасы шулкадәр чиста, саф, җылы һәм коры иде. Кояш нәкъ аңа карап үзенең алтын нурларын коя, яшел хәтфә уҗымнар, алар янында сузылган сап-сары агач полосалары, уң як болын буендагы әрәмәдә алсуланып, йә шәмәхә-кызгылт төскә кереп, йә сап-сары булып утыручы агачлар—һәммәсе, бер сагышлы моң булып, күзләр аша күңелгә тулалар иде. Табигатьтә көз булса да, инде җир өстенә тиздән кар ятачак көннәр килсә дә, Ирекнең күңелендә яз җинеп килә иде. Уйлый, һәр ягын да бизмәнгә сала торгач, ул үзенә әйтелгән бүгенге тәкъдимнең очраклы түгеллеген аңлады. Барлык кешеләрне таң калдырырлык, аларның язмышларында борылыш ясарлык әсәр язу хыялы аның күңелендә көчәйгәннән-көчәя бара иде. «Менә укуымны гына бетерим дә бөтен вакытымны, бөтен сәләтемне шуңа багышлыйм» дигән чаклары аның иң кадерле, берни белән алыштыргысыз илаһи мизгелләре була иде. Ләкин бит моңа ирешү өчен зур омтылышлар белән яшәргә, зур вакыйгаларның уртасында кайнарга кирәк. Мәктәп стеналары, сүз дә юк, аны мондый вакыйгалардан аералар иде. Ул бер нәрсәне яхшы белә: андый әсәр тудыру өчен яңа фикерләр, кайнар тойгылар, зур рухи омтылышлар кирәк. Әсәргә аларны зур эшләр белән шөгыльләнгән шәхес кенә кертә ала. Әгәр райкомга килсә, Ирек дөньяның агышында, тормыш пульсында торачак, бүгенге киеренке тормыш вакыйгалары эчендә кайнаячак. Шул чакта гына халыкны, кешеләрне ничек яшәргә өйрәтерлек әсәр туачак. Ул әсәрнең исемен Ирек «Яңа Коръән» дип куячак. Ул Коръән һәркемнең өстәл китабына әвереләчәк. Аны язу өчен ул югарыдан торып та, гади кешеләр арасында кайнап та тормышны өйрәнәчәк. Райком нәкъ әнә шундый урын. Анда хәят елгасына юнәлеш бирелә, аның агышы тизләтелә, төрле чүп-чарлар, киртәләр алып атыла. Тормышның төбендә кайнап, ун ел буе аңлый алмаган нәрсәләрне син монда бер елда, бәлкем тизрәк тә аңлаячаксың. Ирек, кулларын баш астына куеп, чирәмгә ятты. Зәп-зәңгәр күк шулкадәр дә төпсез, очсыз-кырыйсыз. Әнә бер ак тоҗым очып китте. Бәлкем ул мәңге төшмәс, шушы галәмгә, шушы зәңгәр биеклекнең иң ерактагы чоңгылына очып китәр. Төнлә йолдызлар барында күк тәбәнәгрәк күренә икән. Ә менә хәзер Ирек аның очсыз-кырыйсыз икәненә хәйран калды. Үзе күтәрелеп очасы тормыш күге дә шушылай ук очсыз-кырыйсыз зәңгәр һәм саф булып тоелды аңа. Шундый биеклеккә күтәрелгәндә генә кешеләргә пәйгамбәр сүзенә тиң сүз әйтеп буладыр. Аннары кинәт ул сискәнеп

киткән кебек булды. Әбиләр чуагы бит мәңгелек түгел, ул бик кыска гомерле, үтеп тә китәр, менә бу зәңгәр күкне кургашындай авыр кара болытлар каплар, карлы-бозлы яңгыр сибәләр, шыксыз көз, һәркөн җаннарны өшетеп, көйсез кияү кебек, үзенең төрле якларын күрсәтер. Тормышта да шулай булмасмы? Ирек бу уйларыннан көлемсерәп куйды. Символлар, чагыштырулар, фараз кылулар... Яза торган кешенең хыялы эшләргә тиеш. Наратлык буенда уздырган сәгатьтән артык вакыт эчендә ул гүяки икенче кешегә әверелде. Хәзер инде аның карары катгый, үзе өчен анык иде: берминди икеләнүсез китәргә. Хәтта әти-әниләре каршы килсә дә, аларны инандырып булса да, бу адымны ясарга кирәк. Әгәр ул үзенең иң изге хыялын, илаһи биеклектә күп еллардан бирле саклап йөрткән өметләрен тормышка ашырыйм дисә, ана шушыннан да дөресрәк юлны табу мөмкин түгел иде.

Ул өйләренә канатланып кайтып керде. Әтисе белән әнисе аның район үзәгенә барганлыгы хакында әле берни дә белмиләр, аны мәктәптән кайтты дип уйлыйлар иде.

—Улым, ачыктыңмы?—диде әнисе.

—Юк, әни, әлегә ашыйсым килми,—диде Ирек һәм, сүзне нәрсәдән башларга белмичә, бераз уйланып торды.—Мин бүген Болынкырда булдым,—диде ул, мич янында мәшәләнгән әнисенә һәм караватта утырган әтисенә карап.—Райкомга эшкә чакыралар.

Әнисенең йөзенә курку галәмәтләре чыкты, аның күзләре түгәрәкләнде, ни әйтә бу малай дигәндәй, аптырап картына төбәлде. Хәйринең исә йөзеннән сизелер-сизелмәс якты шәүлә йөгереп үтте. Улына ягымлы карашын төбәде:

—Кем итеп чакыралар?

—Инструктор... Идеология бүлегенә.

Әтисе, житез генә торып, нәрсәдер эзләгәндәй, мич янынннан урап килде дә кулын Ирекнең башына куйды, кытыклагандай чәчләрен аралады.

—Ничек уйлыйсың соң, улым, башкара алырсыңмы?

—И, атасы,—диде Гөлҗамал, аның янына килеп.—Соң төпчегебезне районга җибәреп... Ничек яшәрбез?

—Бар әле, ашыңны кара,—диде Хәйри, кырыс кына. Аннары ана борылып, тавышын күтәреп әйтте:—Ничек яшәрбез, имеш!.. Әнә авылда күпме карт-коры. Баласы да, чурты да юк. Яшиләр бит.

—Соң, аларның юк, безнеке бит янибызда,—диде Гөлҗамал, бирешергә теләмичә.

—Ә аларныкы булмаганмыни?! Һе... Безнең малайны райком тикле райкомга эшкә чакыралар! Горурланырга кирәк моның белән! Ә син... Тьфү!

—Туктале, ә синең мәктәбең?

Хәйри бу юлы карчыгына чын-чынлап рәнҗеп карады.

—Соң, әнисе, райкомга эшкә алгач... нинди мәктәп кайгысы ди монда!—Ул карчыгына таба, бөтенләй өметсез бу дигәндәй, кулын селтәде дә кабат урынына барып утырды. Аның күзе гел Ирекдә генә иде.—Кайчаннан соң, улым?—диде ул түземсезләнеп.

—Иртәгә җавап бирергә куштылар: ризамы-түгелме.

—Риза диген, риза! Шундук әйтеп кайтасың калган.

—Соң, әти, ничек инде...—Сездән башка...

Шулай итеп мәсьәлә хәл ителде. Кичен Мэлс абыйсы кайткан иде. Ул, бу хәбәрне ишеткәч, бер сүз дә әйтмәде. Китеп барганда гына капка төбендә Ирекка болай диде:

—Энекәш, синең кирпеч заводында булганың бармы?

—Юк.

—Син анда барып кара әле.

—Нигә?

—Кирпеч заводында эш коточкыч авыр, теләсә кем түзә дә алмый. Тагын шунысы бар, кая карасаң да кирпеч... чие, яндырырга кертелгәне,

мичтән яндырып чыгарганнары. Бөтенесе бер зурлыкта, бер формада. Аяк асты тулы кирпеч ватыгы... Кайсылары урталай сынган, кайсылары буйга, кайберләре гел чәрдәкләнеп беткән...

—Абый, сүзең булса, туп-туры гына әйт әле,—диде Ирек түземсезләнеп.

—Туп-турысы шул: сине эшкә чакыра торган җир дә кирпеч заводы инде ул. Тик анда...—абыйсы сүз таба алмыйча тукталып торды.—Тик анда калыпка кызыл балчык урынына икенче әйбер салалар.

—Абый, миңа тормышның уртасында кайнап, анлап, язарга иң кулай урын түгелмени ул?

—Белмим... Мин «барма!» диярмен, ә син, «юлыма абый гына аркылы төште» дип, гомерең буе миңа рәнҗерсең.

Абыйсы, олы перчаткаларын киеп, мотоциклы янына килгәч, тагын туктап калды.

—Мин инде аңладым: сез хәл иткәнсез. Әтинең дә башы күккә тигән. Син шулай да шушы капка төбен, шушы кичне, әнә теге кызарып чыгып килүче айны, минем әйткән сүзләрне хәтереңә ешрак төшер әле. Яме?

—Ярар,—диде Ирек, ихлас күңелдән.

Абыйсы мотоциклын кабызды да китеп барды. Ул һәрвакыт нәрсәгә дә булса каршы. Гомере буе шулай. Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Авылга кайтырга, төп ихатада тегенди-мондый эш эшләргә абыйсы һич тә вакыт таба алмый иде. Ирек тә район үзәгенә китеп барса, абыйсына үзенең моңа кадәрге булган яшәешенә шактый гына төзәтмәләр кертергә туры киләчәк. Шушыларны уйлагач, Ирек елмаеп куйды. Ул әйткәнчә, шушы кич, капка төбе, кызыл ай белән ант итте: кайда гына, нинди генә эштә эшләсә дә, һичберкайчан әти-әниләрен, төп нигезне Ирек ташламас, пәйгамбәр булып күкләргә ашса да, аларга барлык эшләрендә ярдәм итәр, бары тик рәхмәтләрен генә алыр!..

Кич мәдәният йортында көзге бал оештырганнар, яшьләр күп иде. Фойе белән сәхнә сары, ал, кызгылт яфраклар белән бизәлгән. Күңелле музыка, җыр, бию, уен-көлке белән кичәнең үткәне сизелмәде дә. Ирек белән Зәнфирә фойедан ук җитәкләшеп чыктылар, тирләгән муеннарына, битләренә салкынча көзге һаваның сарылуыннан рәхәтлек кичерделәр, бернинди сәбәпсез шаркылдап көлделәр. Ай бөтен урамны, күк йөзен, өй түбәләрен ялт итеп балкыткан, җирдән әнә табарлык иде. Алар, бер әкияти дөньядан чыгып, тагын икенчесенә чумдылар.

—Минем сиңа әйтәсе бер серем бар.

—О-о-о,—диде Зәнфирә, басынкы гына көлеп.—Кайсы төштән таптың син аны?

—Беләсеңме... Мине райкомга эшкә кодалыйлар.

—Кодалар килдемени?

—Бүген Шәвәлиев чакыртты.

Шулчак Зәнфирәнең елмайган иреннәре җыела алмыйча катып калды. Аның күзләре киерелеп ачылдылар, сулышы ишетелмәс булды. Гәүдәсе, ничектер коелып төшкәндәй, кечерәеп калды, бөтен йөзе житди кыяфәткә керде. Ирек аңа райкомда эшләүнең өстенлекләре, аның ижатына күрелмәгән этәргеч бирәчәге турында дәртләнеп сөйләде, Зәнфирә аны сүзсез генә тыңлады. Аның йөзе ай яктысында усак көле төсле аксыл булып күренә иде. Ирек, аны үзенә таба борып, иреннәре белән Зәнфирәнең битләренә, күзләренә, иягенә кагылды.

—Зәнфирә, китимме соң?

Зәнфирә, башын сулга борып, күз карашын еракка төбәгән хәлдә:

—Син бит инде күптән анда, Ирек,—диде.

—Зәнфирә! Ник алай дисең?!—Ирек аны үзенә тартып, кысып-кысып кочаклады. Зәнфирәнең нәфис кечкенә колагына кайнар сүзләрен пышылдады:—Синең бер сүзең җитә... Менә хәзер китмә дисәң, китмим...

Аның бу сүзләре, ничек кенә кайнар әйтелмәсеннәр, Зәнфирәгә

рашкы бөртекләре кебек килеп бәрелделәр.

—Юк, Ирек,—диде ул.—Мин сина беркайчан да андый сүз әйтмәячәкмен...

Зәнфирә арыган, талчыккан күзләре белән Ирекккә мөлдерәп карады. Бу караш, ай яктысында булгангамы, нәрсә беләндер хушлашу, аерылышу һәм үкенү төсмерен анлата иде. Ирек анын яраланган күнелен төзәтмәкче булып:

—Киләчәктә фатир да бирәчәкбез, диләр. Болынкырга күчәрбез,—диде.

Әйтүен әйтте, шундук тагын дөрес әйтмәгәнлеген анлады. Зәнфирәнең әнисе ике ел инде икенче группа инвалид, үз хажәтенә дә көч-хәл белән генә йөри иде. Бер-берсенә әйтмәсәләр дә, аларнын фикерләре нәкъ шул бер тирәдә бөтерелгән булып чыкты.

—Рәхмәт, Ирек,—диде Зәнфирә, зәгыйфь тавыш белән.—Синен ниятләрең изге... Алар барып та чыгар. Минем бит әле әнием дә бар.

—Тәзкирә апа да...—Ирек ни дип әйтергә белми аптырап калды.—Ул да безнең белән яшәр...

Алар күптән инде Зәнфирәләр турында басып торалар икән. Кызнын йөзе ачылмады, тавышы югалды, күзләре ничектер зураеп, дымланып киттеләр.

Алар шактый вакыт сүзсез тордылар. Хәзер үртәшеп тә, юк-бар сөйләшеп тә, чеметешеп тә, шаярышып та, көлешеп тә булмый иде. Ул нәрсәләр, таш стена белән аергандай, каядыр еракта калган иде. Ә төн, бәлкем көзнен соңгы төне, бөтен дөньяны нурлаган, матурлаган, алар икесе күнел ачсыннар, куансыннар өчен әзерләнгән иде. Әлек мондый айлы төн алар өчен бәйрәм генә түгел, ожмахта үткәрелгән бер ләззәтле көнгә тин була иде.

Зәнфирә ничектер шәүләдәй, тавышсыз-тынсыз гына өенә керде дә китте. Ирек, йөрәгенә салкын таш бастыргандай, башын аска иеп, акрын гына үзләренә таба атлады. Әйтерсең лә алар мәңгегә аерылдылар, Зәнфирә караңгыда ялгызы басып калды, ә Ирек ана хыянәт итеп китеп барды сыман. Ләкин бу бит дөрес түгел! Сон, алай булгач, нигә сон ул Иреккне гаепләгән кебек сөйли һәм Ирек чыннан да үзен гаепле итеп тоя?..

### 6

Яна коллективта эшли башлау Ирек өчен әллә ни кыен булмады. Аны Әминә исемле инструктор белән бер бүлмәгә утырттылар. Аларнын өстәлләре кара-каршы, тик Әминәнеке тәрәзәгә якын, түрдәрәк, Ирекнеке ишеккә табарак иде. Икесенә ике телефон, уртак ыгы-зыгылар, киңәш-табыш итүләр. Ут борчасыдай житез Әминә Ирекдән ике-өч яшькә өлкәнрәк булса да, аны берничек тә андый яшьтә дип уйларлык түгел. Ару-талчыгулар Әминәгә бөтенләй ят. Ул күбесенчә костюм-чалбар, водолазка кия, чәчләрен егетләрчә кыска итеп йөртә. Үзенен «Иж» мотоциклына утыртып, атна-ун көн эчендә Иреккне районнын барлык авыллары, идеология эшенең торышы белән таныштырып чыкты.

Ирек хыялланганына ирешTе. Өерменен ул нәкъ уртасына килеп эләкте, һәм ул аны шундый итеп бөтерә башлады, артына борылып карарга да вакыты калмады.

Менә ул чын тормыш! Менә ул яну! Ирек очынып, илһамланып эшләде. Партия һәм комсомол бюросы утырышлары, жыелышлар, пленумнар, партактивлар әзерләшеп уздырышу, йөзләрчә кешеләр белән аралашу, бәхәсләшү, кушу һәм мәжбүр итү... Боларнын һәммәсен дә йөрәгенә сеңдереп, зиһенең белән эшкәртеп кенә өлгер! Инде аны бөтен районда беләләр. Әгәр шулай кушылса, ул теләсә кайсы житәкчене көннен йә төннен теләсә кайсы вакытында хәтта жир читеннән дә эзләтеп таптыра, кирәк булса теләсә нинди хәлендә зырылдатып райкомга китереп житкерә. Шуна күрә сина әллә каян елмаеп сәлам бирәләр, баш

иялəр, хəл-əхвəл сорашалар, килеп чыгыгыз, дилəр, кирəк əйберлəрегез юкмы, дилəр.

Ирек ябыкты, суырылды, күз төплəре күгəрде. Төннəрен, əгəр фатирына кайтып элгəшергə туры килсə, конспектларына тотынды, əмма кагаеп-кагаеп китеп, башы йə стенага, йə өстəлгə бəрелде. Ул елны Ирек кышкы сессиягə бара алмады. Аны иң нык борчыганы—авылга кайта алмау иде. Зəнфирə белəн очрашулар сирəгəйде, салкынайды. Əтисе белəн əнисенең хəллəрен дə ул күп вакытта кеше аркылы гына белеште. Мэлс абыйсы райкомда, йə урамда аны очратса, «нихəл, райком күсесе» дип күреште. Йөзенең житди булуы бу сүзлəрне шаярып түгел, чынлап əйтүе турында сөйли иде.

## *Ирекнең көндəлегеннəн*

*«Мин нинди көчле икəнмен! Əгəр үзеңə иң югары талəплəр куйсаң, əлбəттə. Ə биредə башкача мөмкин дə түгел. Ныклы тəртип! Кушылган—үтə! Куш һəм үтəт! Өлгерə алмадым, булдыра алмадым дигəн акланулар беркем тарафыннан да кабул ителми. Лəкин бүген язасы нəрсəм ул турыда түгел.*

*Мин бер хакыйкатьне теркəп куярга телим. Ул түбəндəгедəн гыйбарəт. Партия работнигының эш урыны бар җирдə—урамда, һəрбер өйдə, басуда, фермада, урманда, суда, күктə икəн! Кешелəрнең тормышы матур булырга тиеш. Моның шулай булуы өчен мин һəркайда һəм һəркайчан җаваплы. Шуңа күрə эш сəгатьлəре, ял һəм эш көннəре дигəн бүленеш юк дəрəҗəсендə.*

*Бүген минем шатлыклы көнем. Сəгать теллəре инде төнге уникегə якынлашып килсə дə, язмыйча кала алмыйм. Иртəнге якта «Җиңүче» колхозының ике бригадасында терлекчелəр җыелышлары уздырдык, йөклəмəлəрнең үтəлешен тикшердек. Район үзəгенə кайткач, ашханə каршындагы кибеткə сугылмакчы булдым. Керсəм—гауга, тавыш! Очсызлы балык консервлары саталар икəн. Кемдер карыйсы иткəн—срогы күптəн чыккан. Бер хатын биредə алган тары ярмасын, күрше кибеттə үлчəтеп, кабат китергəн. Ике йөз граммга өткəннəр, гомергə шушы хəл, үлчəү белəн бер, сдача биргəндə икенче алдыйлар ди. Кибеттəн үк санэпидстанциянең баш врачына чылтыраттым. Халык контроле комитетында беркем дə туры килмəде. Эчке эшлəр бүлегеннəн сəүдə мəсьəлəлəре белəн шөгыльлəнүче сотрудникны чакырттым, нəтиҗəсен хəбəр итəргə куштым. Райкомга кайту белəн хəлне Шəвəлиевкə сөйлəдем. Зөфəр Шəрипович Беренчегə чылтыратты да алдагы айда сəүдə хезмəте күрсəтү мəсьəлəсен бюрога куярга булдык. Аны хəзерлəүне миңа йөклəделəр. Унбер кешелек комиссия төзедек. Барлык авыллардагы сəүдə нокталарын тикшереп чыгачакбыз.*

*Хəзер теге шатлыгыма күчəм. Яз көне Əминə белəн партҗыелышта катнашып кайтканда мотоциклыбыз ватылып юлда калдык. XX партсъезд исемендəге колхоз үзəге Имəнгə җитəргə əле өч чакрым ара бар. Җəяүлəп авылга киттем. Соң иде инде. Клубта ут бар, керəм. Фойеның уртасына озын өстəл куйганнар да шуның тирəсенə яшьлəр тезелеп утырган. Авызларында тəмəке, рəхəтлəнеп кəрт сугып яталар. Почмакта буш аракы шешəсе ауный. Стена буенда биш-алты кыз көнбагыш ярып утыра. Мин кызлардан клуб мөдиренең кайда икəнен сорыйм. «Таифə апа ул клубны ачып кына бирə, үзебез биклибез»,—дилəр. Егетлəр янына барам, исəнлəшəм. Кемдер сынап карый, кемдер игътибар да итми. Хəлне аңлатам, мотоциклны сөйрəп алып кайтырга иде дим. «Рəтең булса—момент!» ди берсе. Калганнары күтəрелеп көлəлəр. Шул чак бөдрə чəчле бер егет «əйдəгез» дип, мине үз артыннан ияртте. Бу егет «Запорожец»ы белəн безне Болынкырга кадəр илтеп куйды. Клубта бер ватык хромкадан башка берни дə юк икəн. Икенче көнне үк райкомолдан Əхнəф, мəдəният бүлеге мөдире Азат белəн колхозга юл тоттык. Мəсьəлə райком каршындагы идеология комиссиясендə тикшерелде. Хуҗалык җитəкчелəренə дə, үзебезгə дə ару элəкте. Андагы авылларны күз уңыннан ычкындырмадык. Бүген кич Əминə белəн шунда бардык. Йа Хода! Күпме үзгəреш! Дүрт авылында да мəдəният учаклары гөрлəп эшли. Шахмат-шашка, бильярд уйныйлар. Колхоз үзəге Имəндə штанга, гер*

*күтәрү, көрәш буенча ярыш үткәреп яталар. Кызлар-егетләр безне төреп алдылар, рәхмәт укыйлар, китапханәгә алып кереп, кыстый-кыстый чәй эчерделәр. Шул яшьләрнең якты йөзләрен күрү, рәхмәт сүзләрен ишетү ничек рәхәт! Ә бит мондый халәт кичергән көннәрем шактый җыйналды минем. Димәк, мин кешеләргә кирәк! Димәк, мин башкаларның тормышын ямьләү өчен әз генә булса да үз өлешемне кертә алам...»*

Шатлыклы көннәре дә, уңышсызлары да булгандыр инде. Әмма Ирек бер нәрсәне төгәл әйтә ала—гамьсез көннәре берәү дә булмады. Аптырашта калдырганнары да җыела торды...

Районда халыклар дуслыгына багышланган республика семинары үтәчәге билгеле булгач, шунда катнашучыларга күрсәтү өчен театральләштерелгән сценарий язуны Ирекка йөкләделәр. Бу эш аның төн йокыларын качырды. Нигаять, сценарий Шәвәлиевкә тапшырылды. Икенче көнне ул Ирекне үз бүлмәсенә чакырып:

—Искиткеч әйбәт булган,—диде.—Синең бу сценариеңны бастырып тарату өчен Республика Халык иҗат йортына тәкъдим итәчәкбез.—Ул бераз гына уйланып торды да, кәнәфиен калдырып чыгып, Ирекнең каршына килеп утырды.—Тик син анда өч урында «Сарман» көен яңгыратасың. Алып атыйк без аны...

Ирек, әллә ялгыш аңладыммы дигәндәй, секретарьга аптыраулы караш ташлады.

—Ничек инде, Зөфәр Шәрипович?!—диде ул кулларын як-якка җәеп.—Ул көй бит бөтен сценарийны кояш нуры кебек җылытып, яктыртып тора, бүгенге тормышка, Татарстан җиренә дан җырлый, милли хисләребезне уята.

Шәвәлиевнең йөзе караңгыланды.

—Син мин кушканны үтә әле, Сабитов,—диде ул, шыпырт кына.

—Соң, аңлатыгыз, аңлатыгыз!—диде Ирек кызып.

—Аңлатам, тик үзең генә бел. Арсланов «Сарман» көен яратмый.

—Соң... ни...—Ирек сүзен әйтә алмыйча ык-мык килде. Аның гаҗәпләнүенең чиге юк иде.—Сценарий бит... аның ни катышы бар...

—А-алып ат! Аңлыйсыңмы: алып ат! Минзаһит Усманович аларның бездән алда баруларына, макталып торуларына котыра. Мин бит беләм: барыбер алдырып ташлатачак! Яңадан андый нәрсәләр язганда, Актанышка бәйле җырларны да кертә күрмә.

—Анысы ни белән бәйле инде?—дип сорады Ирек, тавышына юри кызыксыну билгеләре чыгарып.

—Ни булсын—шул ук сәбәп...

Бу хәл Ирекнең күңелендә берничек тә аңлата алмастай авыр юшкын калдырды...

* * *

—Ирек Хәйриевич, тиз генә кереп чыгыгыз әле.

Килеп керүгә, Шәвәлиев аның кулына бер кочак кәгазь тоттырды.

—Бирегә партиянең комсомолга җитәкчелеге буенча әйберләр. Элеккеге пленум, бюро материаллары, өлкә комитетына җибәрелгән информацияләр.

—Нәрсәгә соң болар?

—Бер атнадан өлкә комитеты пленумы булачак. Яшьләрне коммунистик тәрбияләү мәсьәләсе каралачак. Безнең Беренче шунда чыгыш ясарга тиеш. Без аның белән киңәштек тә (Шәвәлиев бусын алдады, әле Арсланов белән бу хакта берничи сөйләшү булмаган иде), аны язуны сиңа йөкләргә булдык.

Ирек кәгазьләрне чаштыр-чоштыр актарды да бер сүз дә әйтмәде.

—Күп түгел инде ул, машинкада дүрт-биш бит әйбер,—диде Шәвәлиев, сүзен дәвам итеп.—Син элекке комсомол оешмасы секретаре, яшьләр белән эшләүдә безгә нәрсә җитми, нинди яңа алымнар кулланырга

кирәк—курыкмыйча үз фикерләреңне яз. Райкомның эшләгән эшен дә күрсәтергә онытма, бик шапырынма да, проблемаларга күбрәк басым яса. ВЛКСМ үзәк Комитетының беренче секретаре белән ҮК аппаратыннан зур гына кеше килә, диләр. Шулай булгач, чыгышның нинди дәрәҗәдә булырга тиешлеген син яхшы аңлыйсың. Күп дигәндә өч көн вакыт. Ерып чыгарсың бит?

Ирек, кәгазьләрдән башын күтәреп, Шәвәлиевкә карады. Аның өчен бу баш бетәрлек нәрсә түгел иде, үзенең дә күптән күңелен сызлаткан, их шушыларны әйтергә, дип йөргән фикерләре күп иде.

—Зөфәр Шәрипович, еруын ерып чыгып булыр, тик мин бит әле бу көннәрдә сөт буенча Карамалы фермасына вәкил итеп беркетелгән. Анысыннан азат итәрсез инде.

Шәвәлиев утырган урынында боргаланып куйды.

—Ирек, фермага кем беркеткәнен яхшы беләсең бит. Беренченең кушуыннан башка синең өстеннән беркем дә, хәтта Алла да, ул вазифаны төшерә алмый.

—Соң бит, Зөфәр Шәрипович...—Ирек гаҗизлектән берни әйтә алмады, тотлыгып, әйтәсе сүзләре тамагына тыгылып калды. Бераздан гына тын алып, ул, якасыннан әҗәл алган кеше кебек, көч-хәл белән телен әйләндерде:—Мин бит көне буе фермада булырга тиеш, һәркөн иртәнге биштә Минзаһит Усмановичның үзенә нинди чаралар күргәнлегебез турында хәбәр итәргә тиеш. Мин кайчан языйм? Ул чакта аның белән мин үзем сөйләшәм.

—Тссс!—диде Шәвәлиев, имән бармагын тырпайтып.—Син, Сабитов, бер әйберне онытма: бездә бу эш кушылды дип, тегесен җилкәдән төшерү юк. Әгәр андый тәртип булса, райком бик начар житәкчелек итәр иде. Әнә кара Әминәгә, Нуриевка, Гомәровка, миңа... Һәрберебезнең иңенә мең төрле вазифа йөкләнгән. Шуңа күрә киңәшем шул сиңа: көндез яз, фатирыңда утырсаң, бигрәк тә әйбәт булыр. Беренченең күзенә күренмәскә тырыш. Ә иртән дүрттән йөрүчеләр бар бит, шуларга утырып китәсең дә тиз генә чылтыратып кайтасың. Башкача булмый.

Ирек икенче секретарь бүлмәсеннән күңеле айкалып чыкты. Алай алдашуны, төлкеләнүне яратмый да, булдыра да алмый иде ул. Ә менә хәзер хәйләләргә, алдарга кирәк. Әле бит оештыру бүлеге инструкторлары көннең теләсә кайсы вакытында, фермадамы син, юкмы, тикшереп торалар, бармаганнардан аңлатма алалар. Беренче кушканнан авыл хуҗалыгы идарәсе начальнигы да, район Советы башкарма комитеты председателе дә, хәтта аның кул астындагы ике секретарь да баш тарта алмый. Шәвәлиев әйткәнчә йөреп, Ирек чыгышны фатирында язды. Ләкин өч көндә бетерә алмады. Дүртенче көнне иртүк, алдан сөйләшеп куйганча, район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары Галиев машинасында (ул Карамалы фермасыннан арырак хуҗалыкка вәкил булып йөри) фермага барып житеп, андагы хәлләрне ачыклады. Фуражы да арттырылган, силосы, яшел массасы да мул бирелә, әмма ферма буенча сөт йөз килограммга кимегән иде. Моның сәбәбен беркем дә әйтә алмады: баш зоотехник та, ферма мөдире дә аптырап җилкәләрен генә сикерттеләр. Ә бит сөтне киметү түгел, ике атна эчендә һәр сыер башына йөз иллешәр грамм арттыру бурычы куелды. Ирек иртәнге биш тулганчы ук телефоннан номер җыйды. Трубкадан ишетелгән кыска сигналлар беренченең кем беләндер инде элемтәгә кергәнлеге турында сөйли иде. Ярты минут үткәннән соң, ул кабат номер җыйды. Шул ук хәл кабатланды. Чылтырата торгач, сәгать алты тула язды. Ахырда беренченең «да» дигән калын тавышы ишетелде.

—Карамалы фермасыннан Сабитов әле бу,—диде Ирек, саннар язылган кәгазен алдына куеп.

—Вообще-то, Сабитов, бу вакытта чылтыратмаска да була иде,—диде беренче кырыс кына.—Әллә сез безнең ничәдә сөйләшергә тиешлекне онытгыгызмы?

—Мин сезгә биш тулганчы ук чылтырата башлаган идем инде, Минзаһит Усманович,—диде Ирек, тирләп чыккан мангаен кул аркасы белән сыпырып.

—Ну что ж... Мин сезгә ышанам. Ничек анда хәл?

—Менә ике көн инде фуражны арттырдык, сыер башына җитмешәр килограмм яшел масса бирелә...

—Сабитов, слушай!—Беренченең шулай кинәт бүлдерүе Ирекне әллә нишләтеп җибәрде.—Син мина сөтнең күпмегә артканын гына әйт.

Ирек бераз тынсыз-өнсез калып эндәшә алмый торды.

—Сөтме... Сөт артмады, Минзаһит Усманович...

—Мин сезне анда ни өчен җибәрдем?!—Беренче секретарь аның җавап бирүен көтеп торды.—Әллә ишетмисез?

—Ишетәм, Минзаһит Усманович. Сөт арттырырга...

—Йә, күпмегә артты?

—Артмады, кимеде шул...

—Кимеде?!—Арслановның тавышы ачулы төс алды.—Күпмегә?

Ничек кенә тырышса да, «йөз килограмм» дигән сүзне әйтергә аның теле әйләнмәде һәм ул ничек алдашканын сизми дә калды:

—Җитмеш килограмм чамасы...

Бу санны әйткәндә, аның теле ут янды. Әйтерсең, ул авызыннан утлы күмер төкерде, күз аллары әлҗе-мөлҗе килде.

—Нәрсә, сез анда сөт киметер өчен бардыгызмыни?!—Арсланов әшәке итеп сүгенеп куйды. Аның сүгенүе Ирекнең мангаена күсәк белән китереп орган кебек тәэсир итте.—Ну, отвечай же! Куда пропало молоко?!

Ирек коелды да төште. Әйтерсең лә ул җинаять өстендә тотылган иде.

—Ну?!—секретарь тагын сүгенде.—Син әллә телеңне йоттыңмы?!

—Хәлне төзәтербез, Минзаһит Усманович,—диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

—Кайчан?

—Шушы бер-ике көндә,—диде Ирек, сөтнең артасы-кимүе турында уйлаудан бигрәк, бу авыр сөйләшүдән котылу өчен.

—Хорошо, доложишь,—беренче трубкасын куйды.

Ирек җидегә бөкләнеп сөйләшкән җиреннән, телефон трубкасын да куярга онытып, урындыкка утырды. Ул эченнән колхоз председателен, партком секретарен, баш белгечләрне, ферма мөдирен, ялкау савымчыларны, эчкече скотникларны эт итеп сүкте. Хәзер үк бөтенесен җыеп, эссе табага бастырырга ниятләде, чөнки аңа беренче тарафыннан барлык хокуклар бирелгән, ул аларны сөт арттырмаган өчен иң начар сүзләр белән сүгә ала, мыскыллый ала, кирәк булса, җинаять эше ачтыра, җитәкчеләрен өерләре белән райком бюросына сөйрәп китерә, эштән алдыра. Хәзер аның өчен бердәнбер юл булып шушыларны куллану калды. Ләкин, уйланып утыра торгач, бераз суына төшкәч, Ирек үзенең бу уйлаган гамәлләренең берсен дә кыла алмаганлыгын аңлады. Аның күңеле моңа каршы килә, ничек кенә үзен мәҗбүр итәргә теләсә дә, ул боларның берсен генә дә эшли алмый иде. Ирек авыр сулады һәм, кәгазьләрен кесәсенә тыгып, ферма йортыннан чыгып китәргә әзерләнде. Шулчак телефон чылтырады. Трубкада Шәвәлиев иде.

—Сабитов, синме?—диде ул, исәнләшеп-нитеп тормыйча.

—Әйе.

—Мин сине көтеп утырам.

—Безнең монда эш хана бит әле, Зөфәр Шәрипович. Сөт кимегән.

Аның сүзләрен, әйтерсең, Шәвәлиев бөтенләй ишетмәде.

—Син чыгышны язып бетердеңме?—аның тавышы кисәтүле яңгырады.

—Бетерә алмадым шул...

—Ничек бетерә алмадың?!

—Нигездә төгәлләдем инде мин аны.

Шәвәлиев аны кискен бүлде:

—Давай, слушай, без нигездә дигән сүзне ташлыйк әле. Чыгыш әзерме?

—Төгәлләп бетерәсе бар.

—Күпме ул төгәлләп бетерәсе дигәне?

—Ну...—Ирек бераз уйланып торды.—Бит ярым, күп дигәндә ике биттер.

—Хәзер аны беренчегә алып керергә кирәк. Давай, немедленно кайтып жит.

—Юк, Зөфәр Шәрипович, мин кайта алмыйм. Минзаһит Усмановичка фермада хәлне төзәтергә вәгъдә бирдем. Ике көн эчендә. Хәзер бөтенесен җыеп алам...

—Хәзер син берни дә эшли алмыйсың, синең урынга икенче кеше җибәрербез. Чыгышны шушы минутта машинкага бирергә кирәк. Кайда анын язылган өлеше?

—Минем фатирда.

—Гәрдиева барса, табып кайта аламы аны?

Ирек язуларының кайда, ничек ятканын күз алдына китерде дә:

—Өстәлдә инде алар, табар,—диде.

—Болай итәбез,—диде Шәвәлиев.—Син беркая да чыкма. Кәгазь алып, чыгышынны уйлый тор. Сине алып кайтырга мин үземнең машинаны җибәрәм.

—Миңзаһит Усмановичтан сүз булмасмы соң?

—Әллә син чыгыш синең сөтеңнән әһәмиятсезрәк дип уйлыйсыңмы?

Ирекнең башында мең төрле уй бөтерелде. Төптән уйлап караганда, беренче белән икенченең сүзләре мантыйкка сыймый. Әйтерсең лә алар, зур бер кайчының ике чаты кебек, Ирекнең гәүдәсен, йөрәкләрен-миләрен дә кертеп, урталай кисәләр иде. Әгәр алар чыннан да бу чыгышны язуны Ирекка тапшыру турында килешенгән булсалар, ни өчен соң Минзаһит Усманович аңа шул дәрәҗәдә каты бәрелде? Дөрес, аның бюроларда, пленумнарда, башка зур җыелышларда «хатын-кызлар, сез ишетми торыгыз» дип, сүгенгәләп ала торган гадәте бар иде. Ләкин аның бүген Ирекка юллаган сүгенү сүзләре тел белән дә әйтерлек, язарлык та түгел иде.

Ярты сәгать үтүгә, ферма тәрәзәсеннән Шәвәлиевнең сары «УАЗигы» күренде. Ул шундый кызу килә иде, ферма тирәсендәге катканакларда әллә тагы яртышар метр сикерде, ава язып, әле бер якка, әле икенче якка түнтәйде, ферма йортын буфеты белән этеп аударырлык булып килеп туктады. Ирек ашыгып чыкты, аның урынына сөт арттырырга килгән Әминә төшеп калды.

Чыгышны көндезге унберләргә басып бетерделәр. Хәреф хаталарын төзәткәләгәч, Шәвәлиев аны беренчегә алып кереп китте. Ирекка бүлмәсеннән беркая да чыкмаска кушты. Иртән чәй дә эчмәгән килеш, ул көндезге уникегә кадәр утырды.

Арсланов кәефсез иде, чыгышка ул күз дә төшермәде, өстәленең бер ягына алып куйды да телефоннан сөйләшергә кереште. Аннары өлкә комитеты секретаре белән тоташтырдылар, Шәвәлиев чыгып китәргә мәҗбүр булды. Шул килеш алар, Беренченең хөкемен көтеп, төшке ашка кадәр утырдылар.

—Булмаса мин төштән соң фермага китим әле, Зөфәр Шәрипович,—диде Ирек, аңа ялварып.

—Син нәрсә, слушай! Ә хәзер чыгышыңны браковать итсә? Юк инде, хәзер моннан котылмыйча, безгә беркая да китү юк. Аяк та, кул да богаулы. Тик шулай да Минзаһит Усмановичның күзенә чалынырга тырышма әле. Беренче киткәч, тиз генә аша да, ул эшкә килгәнче, бүлмәнә кереп биклән.

Ирек, ашханәгә барып, каптыр-коптыр капкалады да тизрәк райкомга йөгерде. Бүлмәсенә кереп, өстәл артына утырды һәм беренче мәртәбә,

нишләптер, үз-үзенә нәфрәтләнеп карады. Аның яшәгән тормышы дөрес түгел иде бугай. Ул дәртләнгән хыяллар һаман да чынга ашмыйлар иде. Тормыш казаны кайнавын туктаусыз кайный, әмма ләкин тын алырга, уйланырга, вакыйгаларга бәя бирергә вакыт юк иде...

Шәвәлиев белән Ирек төштән соң бер сәгать тә, ике сәгать тә, өч сәгать тә көттеләр. Ирек бер эш тә эшли алмады. Йөрәге урынында түгел, нервылары соңгы чиккәчә киерелгән иде. «Әгәр чыгыш ошамаса?» дип, коты очып уйлады ул. Инде аны төзәтергә анын көче дә, мөмкинлеге дә калмаган иде. Ул аңа барлык тормыш тәҗрибәсен, өч ел университетта укып алган белем хәзинәсен—һәммәсен дә салган иде. Ә Беренче һаман дәшмәде. Сәгать кичке биш тулгач, Шәвәлиев түзмәде, Беренчегә үзе чылтыратты. «Ярый, бара»,—диде Арсланов бик канәгать булмаган кебек кенә. Шәвәлиевкә шушы җавап житкән иде инде. Анын кем язды дип сорамавы да икенче секретарь файдасына иде.

Арсланов секретарь кызга беркемне дә кертмәскә, беркем белән дә телефоннан тоташтырмаска кушып, чыгышны укырга кереште. Чыгыш беренче юлларыннан ук кыю фикерләре, фәлсәфи тирәнлек белән чын тормыш проблемаларын оста куюы белән Арслановны тан калдырды. Аны ул бер йотым су эчкәндәй укып чыкты. Шактый вакыт айный алмый утырды. Эченнән бу чыгышны язучыдан көнләште һәм ул, әлбәттә, беренче юлларыннан ук монын Сабитов кулы икәнлеген ачык тойды. Чыгыш үзенең фикерләү ягыннан бик югары торуы белән бергә чамасыз биеклекләргә дә очмаган, райком эшчәнлегенең жанлы фактларына таянган иде. Ул шундук катгый карарга килде: әле пленумга кадәр өч көнгә якын вакыт бар, чыгышын сүзен сүзгә ятларга. Әгәр кәгазьдән укыса, һичшиксез, пленумда катнашучылар моны кем язып бирде микән дип утырачаклар иде. Чөнки ул да, башкалар да пленумнарда, партия активларында беркемнең дә, бигрәк тә райком, өлкә комитеты секретарьларынын чыгыш язып мәшәкатьләнмәгәннәрен, аны яза да алмаганнарын беләләр иде.

Минзаһит Усманович өч көн буе бүлмәсенә юньләп кеше керттермәде, телефоннан сөйләшүләрне киметте, фермалардагы вәкилләр иртәнге биштә Шәвәлиев белән телефоннан элемтәгә керделәр. Күп тырыша торгач, чыгышны ул ятлап бетерде. Партия мәктәбендә өйрәткәнчә, ул аны ин элек үз куллары белән күчереп язып чыкты, шул язганын зәнгәр, кызыл карандашлар белән төрле кисәкләргә бүлгәләде, блоклап хәтерендә калдырды. Инде ничә еллар буе анын ручка тотып шушы кадәр әйбер язганы юк иде. Чыгышны күчергәндә, ул тирләп-пешеп чыкты, авызларын ачып, иреннәре, иякләре белән хәрәкәтләнә-хәрәкәтләнә, ручкасын йөртүче кулына ярдәм итте. Бармаклары арыгач, ял итү бүлмәсенә чыгып, ятып торды. Аны күчереп бетергән көнне, телевизор да карамыйча, түшәгенә ауды һәм бер мәртәбә дә кыймшанмыйча, иртәнгә кадәр йоклады. Ятлавы да жинел булмады. Минзаһит Усманович үзен моңа гомуми эш өчен, кирәк булганга гына мәжбүр итте. Ике көн ярым эчендә ул шул чыгыштан башка берни турында да уйламады. Эшкә барып кайтканда да тексттагы сүзләр анын баш миендә бөтерелделәр.

Пленумда ана тәнәфестән соң сүз бирделәр. Ул трибунага бик нык дулкынланып, онытмагаем, ялгышмагаем дип курка-курка күтәрелде. Шулай да кесәсеннән кәгазен чыгармады, әкрен генә башлап китте. Тора-бара ул үзенең ашыгуын аңлады һәм нинди дер көйләү тоны белән сөйләвен сизде. Аннары ул туктап калды, җөмләләрен уйлап төзегән кебек, өзек-өзек сөйли башлады. Зал аны авызын ачып тынлады, чыгышы берничә мәртәбә көчле алкышларга күмелде. Трибунадан төшеп, урынына барганда, ул үз артыннан хуплау сүзләре ишетеп калды. Утыргач, янәшәсендәге кешеләр үрелеп кулын кыстылар, котладылар. Ләкин болары әле чүп кенә иде. Өлкә комитетының беренче секретаре үзенең йомгаклау сүзен нәкъ менә Минзаһит Усманович чыгышыннан башлап китте. Ул житәкләгән партия райкомын яшьләрне коммунистик тәрбияләүдә барысына да үрнәк итеп куйды, райкомнын эш тәжрибәсен жентекләп

өйрәнү кирәклегенә басым ясады. Киләчәктә безгә, диде ул, бу район җирлегендә республика семинары да үткәрергә туры килер. Миңзаһит Усмановичның башы шатлыктан күккә тиде. Пленумга килгәндә, ул үзенең чыгышының яхшылар рәтендә буласын белсә дә, мондый ук резонанс алыр дип көтмәгән иде. Ләкин әле бу да, кем әйтмешли, чәчәкләре генә иде. Пленум бетеп, инде киенергә чыккач, аның янына үзләренең районына курьерлык итүче өлкә комитеты инструкторы килеп, Миңзаһит Усмановичны читкә алып китте.

—Сезне беренче үзенә чакыра, хәзер үк,—диде.

Арслановның бөтен тәненнән ток үткәндәй булды. «Нәрсәгә булыр? Сөт белән районның хәле авыр, шуңадыр».

Беренче аны аягүрә басып каршылады. «Яхшы чыгышыгыз белән котлыйм!»—диде ул аның кулын кысып.

—Вообще-то сез мине, Миңзаһит Усманович, сегодня приятно удивили,—диде ул елмаеп.—Выступлениегыз отлично, я бы даже сказал великолепно!

—Сездән мондый сүзне ишетү минем өчен зур бәхет,—диде Арсланов, бераз каушап.

—Между прочим, сез фикерле белүегезне күрсәттегез. Как һомо сапиенус думающий,—ул кеткелдәп көлеп җибәрде, аннары кинәт җитди кыяфәткә керде.—ЦК инструкторы берәр журналга тәкъдим итү өчен алып та китәм, диде. Мин сезгә, беләсезме, ни әйтер идем. Бу нәрсәгә сез инде вникли, давайте бер капитально нәрсә язып карагыз. Пусть будет брошюра. Или китап. А я обещаю, бик тиз вакыт эчендә без аны чыгартырбыз. А то без яшьләр белән эшләү мәсьәләсендә соңгы вакытта ЦКдан замечание арты замечание алабыз. Пора, наверно, на это поставить точку.

Секретарь сөт турында да, башкасын да сорашмады, сүз шуның белән тәмамланды. Моннан Миңзаһит Усманович бер нәрсәне ачык аңлады: әгәр секретарь, аны махсус чакырып кертеп, брошюра йә китап язарга агитацияләп утыра икән, бу инде аның вакыты күплектән яисә эше беткәнлектән түгел иде. Димәк, аның әйткәннәре Арслановка бирелгән олы йөкләмә һәм ул һичшиксез тиешле югарылыкта үтәлергә тиеш иде. Самолетта очканда, ул•моны ничек эшләү турында уйланып кайтты. Сүз дә юк, моны үтәрдәй кеше районда бар, ул—Сабитов иде. Шул ук вакытта Сабитовның аңа китап язганын беркем дә белмәскә тиеш. «Ләкин моны Шәвәлиевкә әйтмичә башкарып чыгып булырмы соң?»—дип уйлады ул. Сабитов турыдан-туры аның кулы астында, көн саен идеология секретареннан да берничә эш ала. Шушыларны уйлап кайтканда, беркөн Сабитовка каты бәрелүе өчен үкенеп куйды ул. Чөнки сөт бөтен район буенча кимегән иде. Егет аның бик кәефсез чагына туры килде. Әле ул шул көннәрдә аның өчен чыгыш та язып йөргән икән. Хәзер менә китап язарга кушарга кирәк. Әлбәттә, үзе яза алса, Миңзаһит аны беркемгә дә кушып маташмас, язар да ыргытыр иде...

Бөгелмә аэропортыннан аны каршыларга килгән кара «Волга»сында, ияген костюм якасы эченә яшереп, күзләрен йомган хәлдә, йокымсыраган кыяфәт чыгарып кайтса да, зиһене һаман шул китап тирәсендә яшен кебек эшләде. Ничек кенә итсәң дә, Шәвәлиевкә әйтмичә булмый иде. Ул бусын ачыклап бетерде. Чөнки китап өчен бик күп материал да тупларга кирәк. Боларның барысын да Сабитов берүзе башкара алмаячак. Башкарган сурәттә, өлкә комитеты секретаре кушкан эш соңарачак иде. Ә мондый ышанычны алай итеп ямьсезлисе килмәде Арслановның. Ул, Казаннан чылтыратканда ук, чыгышның әйбәт бәяләнүе турында Шәвәлиевкә әйткән иде. Хәтта аның кем язганын сиздерүен дә көткән иде. Ләкин икенче ул хакта ләм-мим. Миңзаһит эченнән генә елмаеп куйды. Үзен күрсәтәсе килә, дәрәҗәне нык тотасы килә, дип уйлады ул шул чакта. Кайткач, чыгышны кем язды дип тә сорамады, Шәвәлиевкә чылтыратты да:

—Сабитов белән минем янга керегез әле,—диде.

Ике минуттан Шәвәлиев белән Ирек беренче каршында утыралар иде инде.

—Ну, Сабитов, фермада хәлләр ничек?—диде ул елмаеп.

Ирек секретарьның үзенә ягымлы тавыш белән болай дустанә дәшүен көтмәгән иде. Кергән чакта ул тагын сүгеп ташлар, ниләр дип акланырмын, сөтнен һаман да артмавын ничекләр анлатырмын дип, коты алынып кергән иде. Шуна күрә ничек җавап бирергә дә белмәде, житәкчеләр мондый очракларда әйтә торган таныш фразадан башка әйбер таба алмады.

—Кулдан килгәннең барысын да эшлибез, Минзаһит Усманович.

Ул нәрсәләр эшләвен санамакчы булган иде, беренче, жиңелчә кул селтәп, ана туктарга кушты.

—Син беркөн анда под горячую руку попал мина... Бераз катырак та эләкте үзенә. Ну, ярый, түзәргә кирәк. Ничек диләр әле: әти суккан урын тәмугта янмый, ди.—Ул көлеп жибәрүгә, кеткелдәп Шәвәлиев кушылды. «Ну, әйттегез дә, Минзаһит Усманович!»—дип баш селкеде. Аннары беренче житди кыяфәткә керде һәм сүзен дәвам итте:—Менә монда безнең өчен яна эш туды әле,—диде ул, юл буе уйлап кайткан планын тормышка ашыра башлап.—Партия өлкә комитеты яшьләрне коммунистик тәрбияләү буенча безнең эшебезне гомумиләштерүне сорый. Аерым брошюра, йә китап дәрәжәсендә.

—Төрле кешеләрнең чыгышлары рәвешендәмени?—диде Шәвәлиев.

Арслановның йөзе чытылды, икенченең бу сүзе ана һич тә ошамады.

—Түгел!—диде ул ачулангандай кискен рәвештә.—Райкомның эш тәжрибәсе турында сүз бара. Бары тик райкомның! Бәлкем ул безнең пропаганда һәм агитация бүлеге исеменнән чыгар,—дип алдашты ул.—Ә бәлкем беренче секретарь исеменнән.

Ирек белән Шәвәлиев, бер сүз дә әйтмичә, ана карап утыра бирделәр.

—Яшьләр тормышын, яшь кеше буларак, безнен Сабитовтан да яхшырак белүче юк дип уйлыйм мин.

—Точно, дөрес, хак әйтәсез, Минзаһит Усманович,—диде Шәвәлиев, кабалана-кабалана беренченең тел төбенең кая таба баруын сиземләп.—Аның өчен инде бу.

—Йә, Сабитов, алынырсын бит?—диде Арсланов, анын күзләренә туп-туры карап.

Хәзер бу күзләрдә боеру да, усаллык та юк, ниндидер ягымлылык, хәтта ялваруга охшаш нәрсә сизелә иде. Ирек, үзе дә сизмәстән, командиры каршында үрә баскан солдат кебек, урындыгыннан күтәрелде.

—Утыр, утыр, Сабитов,—диде беренче, без бит синен белән бертигез дигәндәй...

Ирек урынына утырды һәм:

—Кушасыз икән, тырышырмын,—диде.

—Вот молодец! Иначе не может быть. Район өчен, республика өчен кирәк. Ну инде сез, Зөфәр Шәрипович, ана бу зур эшне башкарырга мөмкинлек бирегез. Материаллар белән тәэмин итегез.

—Итәрбез, Минзаһит Усманович, итәрбез,—диде Шәвәлиев, шулай ук урындыгыннан бераз күтәрелеп.—Барысын да үзем табып бирермен.

—И надеюсь, пока моны өчебездән башка беркем дә белмәскә тиеш. Ни одна живая душа!

Шәвәлиев белән Ирек анын сүзен хуплап баш селкеделәр.

Бу кадәр эшнең Сабитовка йөкләнүенә, үзенең котылуына Шәвәлиев шатланып туймады. Әгәр хәзер беренче Сабитов язган чакта син анын табан астын кашып торырсын дисә, ул, ике дә уйламыйча, ризалашачак иде.

—Сабитов, анда кыенлыклар килеп чыкса, давай, туры үземә кер. Бергәләп поможем. Шулай бит?

—Шулай, Минзаһит Усманович, шулай. Бик дөрес әйтәсез,—диде

Шәвәлиев, автоматтан аткандай.—Тик инде ул сезне борчып йөрергә тырышмас.

—Эчтәлегенә килгәндә... ул инде билгеле,—диде Арсланов.—Төшен минем чыгыш тәшкил итәчәк. Ничегрәк үстерергә—үзегез карагыз.—Ул шулай диде дә торып басты.—Ну, добро!

Беренче элгәре Сабитовның, аннары Шәвәлиевнең кулын кысты да, алар бүлмәдән чыгып киттеләр. Шулай итеп, Ирек өстенә бөтенләй уйланмаган тау кадәр эш йөкләнде...

Берничә көннән Арсланов Ирекка чылтыратты.

—Ну, ничек, Сабитов?—диде ул.

—Менә материаллар туплыйм,—диде Ирек.

—Син, Сабитов, имей в виду, и үзең генә бел. Наверня-ка, под этим делом будет стоять подпись первого секретаря.

Ирек барысын да аңлады.

## 7

«Ярыш» колхозында идеология эшенең торышын тикшерү райкомның перспектив планында бар иде. Ә колхоздагы эшләр ташка үлчим. Зөфәр Шәрипович моңа бик нык сызланды. Караны ак итеп күрсәтү ансат түгел, ләкин моны эшләргә кирәк иде. Чөнки аларны бу хуҗалыкның партком секретаре Кәбиров белән беркем дә белми торган һәм белмәскә тиеш күренмәс җепләр бәйли иде. Ул җепләрнең кайчан барлыкка килгәнен Зөфәр Шәрипович инде онытып та бара бугай. Кайсыдыр елны күрше районнан кайтканда, аның машинасының арткы күчәре кырылып чыкты. Кара буран эчендә шофер белән икәү алар аптыраушта калдылар. Җитмәсә, ягулык та бетеп килә. Шул чак бер ат күренде, ул аларның машинасы турына тукталды, хәл-әхвәлләрен сорашты. Атның хуҗасы районның иң читтәге авыл Советы председателе Кәбиров булып чыкты. Ул чакта аны Шәвәлиев юньләп белми дә иде.

—Моннан беркем дә үтмәячәк хәзер, вакыт унынчы ярты, әйдәгез авылга төшеп куныйк,—диде ул аларга.

Шофер машинаның суларын агызды да, Кәбиров чанасына утырып, авылга юл тоттылар. Шәвәлиевнең беркайчан да мондый хәлгә төшкәне булмаганга, калын киенеп йөргәне юк иде. Юка гына кышкы пальто, көзге носки белән ботинка, юка күн перчатка, ул хәтта шарф та бәйләмәгән иде. Кәбиров аны толыпка төреп утыртты. Шулай да бер сәгатьләп кайткан арада ул теше тешкә тимәслек булып туңды. Шоферны колхоз автомеханигының өенә кертеп калдырдылар. Ул шунда кунарга, иртәнгә машинаны сөйрәтеп кайтарту хәстәрен күрергә тиеш иде. Шәвәлиевне Кәбиров кунак йортына алып кайтты. Каян ачкычы булгандыр, үзе ачып керде, утларны яндырды, нәрсәдер жылытырга куйды һәм, телефоннан номер җыеп, кемнедер чакырды. Шуннан соң бер ярты чыгарды, стаканны тутырып аракы салды.

—Әйдәгез, Зөфәр Шәрипович, сез бик туңгансыз, коткарса, шушы гына коткара,—дип, мөлдерәп торган стаканны аның кулына тоттырды.

Чәкештерделәр дә эчеп куйдылар. Тозлы кыяр кабып, шытыр-шытыр чәйнәгәннән соң гына, Шәвәлиев Кәбировның йөзенә ныклап карады. Кечкенә гәүдәле, түм-түгәрәк йөзле, чем-кара күзле, керпедәй тырпаеп торган чәчле кеше иде ул. Яше белән дә Шәвәлиевтән биш-алты яшькә кечерәктер. Менә ул кайнарланган ит чыгарды, шулпа куйды һәм тагын бер стакан тутырып салды. Инде баягы аракы Зөфәр Шәриповичның туңган табаннарын ут итеп кызыштыра башлаган иде. Бусын да эчеп куйдылар. Кара борыч сибеп, шулпа, ит ашагач, алар икесе дә кып-кызыл булдылар. Тәндә кан уйный башлады. Ул арада тышта аяк тавышлары ишетелде һәм бер яшь кенә кыз килеп керде.

—Соня, безгә әзрәк капкаларга китерерсең әле,—диде Кәбиров.

Кыз кухня ягына кереп китте. Кәбиров, оста фокусчы кебек,

урыныннан да кузгалып тормастан, каяндыр тагын бер ярты тартып чыгарды. Шәвәлиев инде, үзенең шактый изрәвен сизсә дә, каршы бер сүз дә әйтә алмады. Менә кыз чыжылдап торган табада кайнар бәлеш чыгарды. Кәбиров, шешәне ачып, тагын стаканнарга аракы койды. Инде чәкештерергә генә үрелгәч, кире куйды да артындагы шкафтан бер хрусталь рюмка алды.

—Соня, чык әле монда,—диде ул.

Ап-ак халат кигән кыз аларның каршына чыгып басты. Аның битләре алсуланып яна, зур зәңгәр күзләре, озын керфекләре сине суырып алырга теләгән кебек карыйлар иде. Кәбиров рюмкага аракы салып, ана да тоттырды.

—Син бу абыенны таныйсыңмы?—диде Кәбиров, күзе белән Шәвәлиевкә күрсәтеп.

—Танымаска,—диде Соня, керфекләрен аска төшереп.

—Танысаң, бик әйбәт. Ул бүген безнең кунак, бу якларга бик сирәк килеп чыга. Шуңа күрә тәмле теленне, якты йөзенне кызганма,—диде.—Әйдә әле, кадерле кунагыбыз хөрмәтенә берне тотып җибәрик.

Соня алар белән чәкештерде, чәкештергән вакытта зур зәңгәр күзләре белән Шәвәлиевкә туп-туры карады һәм рюмкасындагы аракысын тамчысын да калдырмыйча эчеп бетерде. Ниләрдер сөйләшә-сөйләшә, алар икенче яртыны да төпләп куйдылар, өченчесен дә башладылар, Соняны җырлатып та алдылар. Ул, калган рюмкаларын бетереп эчмәсә дә, барыбер алар белән бергә кабып-кабып куйды. Шәвәлиев белән Кәбиров тартырга чыктылар.

—Ярый, Зөфәр Шәрипович, гаеп итмәгез, мина инде китәргә туры килә. Сез биредә кунарсыз. Ишекне эчтән элеп керегез.

—Сон, әле бит анда...—Шәвәлиев башка сүз әйтә алмады.

—Ныгытып элеп керегез,—диде Кәбиров һәм саубуллашып китеп барды.

Шәвәлиев ишекнең ике келәсен дә элде, оялдындагы утны сүндерде һәм эчкә керде. Өстәл инде җыештырылган. Соня кухняда савыт-саба юып маташа иде. Шәвәлиев аның янына керде. Йөрәге ярсып типте. Бер яктан ул тавыш чыгудан курка, икенче яктан бөтен җаны-тәне белән кызга тартыла, инде бу тартылуны йөгәнләрлек көч юк иде. Ул аның инбашына кулын салды. Кыз елмаеп ана борылды.

—Нәрсә, Зөфәр Шәрипович?—диде ул.

Аның ачуланмавын, читкә тартылмавын сизгән Шәвәлиев кулын кызның биленә шудырып төшерде, аны үзенә табарак тартты.

—Рәхмәт,—диде Соня, тагын да ягымлырак елмаеп.—Савытларны юып бетерим инде.

—Юк, Соня, юып бетермә син аларны,—диде Шәвәлиев һәм аның кулындагы савытны читкә алып куйды.

Ул кызны кочаклап диярлек кухнядан алып чыкты, сервантган ике рюмка һәм башланган яртыны алып, өстәлдәге итле савытны якынрак тартып китерде. Рюмкаларга тутырып салды да Соняны урындыкка утыртты, үзе дә аның янына елышты. Рюмкаларны чәкештергәч, аның күзләренә карады.

—Соня, син бик кунакчыл кыз икәнсең, йөзең якты, телең тәмле,—диде.—Мин сина һәрвакыт рәхмәтле булырмын һәм кулымнан килгән яхшылыкны эшләрмен. Әйдә безнең дуслык өчен! Ләкин бетереп эчеш, килештекме?

—Мина күп була бит, Зөфәр Шәрипович,—диде Соня, ана ялварулы карап.

—Юк, Соня, ташлама ясый алмыйм, үтенмә дә, чөнки бит бу дуслык өчен эчелә.

Ул үзенең рюмкасын ялт итеп бушатып куйды, ә Соняныкын кулы белән күтәрә-күтәрә эчертеп бетерде. Соня бер кисәк ит капты, аны ашыга-ашыга чәйнәп йоткач, икенчесенә үрелде. Ләкин Шәвәлиев аның

чәнечкеле кулын үзенең учы белән каплады. Икенче кулы аның инде әллә кайчан Соняның иңбашында иде.

—Соня,—диде ул пышылдап,—дуслык өчен эчкәч, ит капмыйлар бит.

Соняның маңгаена, мин аңламадым дигәндәй, аптыраулы җыерчыклар чыкты.

—Ә нәрсә кабалар соң?

—Капмыйлар. Дуслыкны менә болай беркетәләр.

Шәвәлиев аның бераз гына күпереп торучы чиядәй иреннәреннән комсызланып үбәргә тотынды. Ахырда кыз башын читкә алды, аягына басып:

—Миңа кайтырга кирәк,—диде.

—Кайтырсың, Соня, кайтырсың...

Ул кызны күкрәгенә кысып алды, тагын шашып иреннәреннән, муеныннан үбәргә тотынды, үрелеп утны да сүндерергә өлгерде.

—Зөфәр Шәрипович... Зөфәр Шәрипович... Кирәкми... Сез нишлисез?..

Шәвәлиев кызны, әллә сөйрәп, әллә күтәреп, киң тахтага алып барды һәм алар йомшак урын өстенә аудылар. Ул, аның өстенә ятып, авызын үзенең авызы белән томалады. Кулы белән халатын ычкындырырга, өстендә нәрсәсе бар, сыдырырга, салдырырга, төшерергә керешә. Соня артык карышмады, ничектер ыңгырашуга охшаш авазлар гына чыгарды. Берничә минуттан алар анадан тума хәлдә бер-берсенең кайнар кочагында, тышта җир җимертеп буран улаганын онытып, әллә кайда очалар иде инде...

Кәбиров белән Шәвәлиевнең дуслыгы әнә шулай башланды. Аның карамагындагы авыл Советында биш-алты авыл, кызлар күп иде. Шәвәлиевкә яңадан Сонялар да, Санияләр дә, Хәлимәләр дә, Кәримәләр дә кадер-хөрмәт күрсәттеләр.

Кәбиров, карап торуга бернинди игътибарны җәлеп итми торган юк кына кеше булып күренсә дә, барлык авыллардагы хатын-кызларга житешә торган, бик елгыр кеше булып чыкты. Ул Шәвәлиевне урман эчендәге шалашларда да, умарталык йортларында да, елга буендагы палаткаларда да хур кызлары белән йоклатты. Һәм шунысы гаҗәп, Шәвәлиев, вакыт-вакыт берәр нәрсә ишетелсә, башым бетәчәк, дип, котлары очып уйлап куйса да, аның маҗараларын шул кызлардан һәм Кәбировтан башка беркем дә белмәде. Ләкин бит хатын-кызның авызында сүз тормый. Кайсыдыр кемгәдер серен чишәргә мөмкин. Күрәсең, Кәбиров башта ук кемнең кем икәнен күреп, кем белән эш итәргә мөмкин икәнлеген аңлап тотына һәм чыннан да ялгышмый иде. Әлбәттә, Шәвәлиев тә хайван түгел, кайсын Кәбиров ярдәме белән, кайсын үзе төрле урыннарга урнаштыра, кайберсен укырга җибәрә барды. Укып кайтканнарына тагын әйбәт кенә хезмәт хаклы эш урыны табылды. Әлбәттә, ул боларның берсен дә үз кулы белән башкармады, ләкин теге кызлар моның кем кулы белән эшләнгән изгелек икәнлеген бик яхшы аңладылар. Шәвәлиев Кәбировны да онытмады. Ул аны иң элек, төрле юлларын табып,—Кәбировның белем ягы ифрат та сай иде—югары партия мәктәбенә читтән торып укырга кертте. Аннары, бер ел укыр-укымаган килеш, «Ярыш»ка партком секретаре итеп билгеләделәр. Менә хәзер ничә еллар шунда эшләп ята Кәбиров. Халык белән дә, кызлар белән дә уртак тел тапты. Берәү дә эшләми дип тә зарланмый, яхшы эшли дип тә мактамыйлар. Кәбировның «Ярыш»ка куелуының Шәвәлиев үзе генә белгән тагын бер сере бар. Бу колхозның өченче бригадасында аның әти-әнисе яши. Яшьләре инде житмешнен өстендә, ә районга килергә ниятләре юк. Сарык, кош-корт асрыйлар, бәрәнге утырталар. Хуҗалыкта эш күп, ә Зөфәрнең кайтырга вакыты юк. Хәер, турысын гына әйткәндә, вакытын да табар иде, ул анда кайтып, койма коеп, утын ярып йөрми инде. Райком секретаре башы белән алай йөрсә, аңардан көләрләр иде.

Шуна күрә анын телефоннан бер сездерүе җитә. Нәрсә кирәк, Кәбиров барысын да ялт итеп эшләп куя. Дөресрәге, йә өлкән класс укучыларыннан, йә шунда авыл Советы активыннан эшләтә. Печән-салам, фураж, утын кебек нәрсәләрне дә ул кайтарта, ул тиешле урынына урнаштыра. Шул ук вакытта алар элекке шалашларны, елга буйларын, умарталык йортларын да онытмыйлар. Бу райком дигән тәмугтан ычкынып, оҗмахтагы кебек бәхетле мизгелләр кичерә икән, Зөфәр Шәрипович алар өчен Кәбировка бурычлы. Шул ук вакытта югары партия мәктәбе бетергән дигән диплом алуы, бүген, партком секретаре булып, машинада җилдереп йөрүе өчен Кәбиров ана рәхмәтле иде.

Менә ни өчен бу бюрода «Ярыш» колхозынын партия комитеты, анын секретаре эшчәнлегенә югары бәя куелырга тиеш. Гөнаһ шомлыгына каршы, соңгы көннәрдә анын бүлегендә Сабитовтан башка беркем дә калмады. Миннуллинны бер айга укырга җибәрделәр, анын урынбасары авырып больницага керде. Башкалар сөт буенча фермаларга беркетелгән. Үзе бер-ике мәртәбә «Ярыш»та булганнан соң, Шәвәлиев анда Сабитовны да җибәрде. Бюро карарын язуны Сабитовка кушарга курыкты, чөнки колхозда идеология эше мактанырлык түгел иде. Кәбировны ул икәүдән-икәү генә чакта, хәтта салып утырганда, күп мәртәбәләр кисәтте. Син әзрәк идеология эше белән дә шөгыльлән әле, диде, үзенне генә түгел, мине дә яндырасын бит, диде. Кәбиров, ярар, диде. Тик икенче көнне үк онытты. Күрәсен, анын уе башка өлкәдә иде. Ул өлкәдә Кәбиров чип-чиста унга бәрә, әллә ничә Шерлок Холмс килеп эзләсә дә, бер генә эз дә калдырмый.

Шәвәлиев бюро карарын үзе язды. Кайсы гына тармагын алса да, мактарлык нәрсә юк иде. Шулай да сүзен тапты, җаен китерде. Парткомнын эшен шактый зурайтып күрсәтте. Сонынннан, әлбәттә, кайбер вак-төяк кимчелекләрен дә атады. Гомумән алганда, идеология эшчәнлеген «канәгатьләнерлек дип табарга» дигән пунктны язды.

Бюро утырышына Кәбиров белән агитколлектив җитәкчесе чакырылды. Алар белән бергә Ирек тә керде. Арсланов көн тәртибен укып чыкты да:

—Кем әзерләде?—дип сорады.

—Безнен бүлектә Сабитов белән без икәү инде хәзер,—диде Шәвәлиев, ирен чите белән елмайгандай итеп.

—Давай, Кәбиров, доложи,—диде Арсланов.—Биш минут сина.

Кәбиров төгәл биш минутка сыешты. Аннары агитколлектив җитәкчесен бастырдылар. Ана берничә сорау бирделәр, утырырга куштылар.

—Кемнәр сөйләргә тели?—диде Арсланов.

—Мин берничә сүз әйтим әле,—диде Шәвәлиев һәм блокнотын тотып торып басты.—Мин бу хуҗалыкта еш булам,—дип башлап китте ул.—Элекке еллар белән чагыштырганда, идеология эшенә игътибар сизелерлек артты. Кәбировнын унай бәяләнергә тиешле сыйфатларыннан берсе—анын халык белән тыгыз элемтәдә эшләвендә. Кешеләр аны яраталар, ул кемнен нәрсә белән сулаганын белеп тора. Гомумән, партия комитеты анын җитәкчелегендә кешеләр белән индивидуаль эшләүгә юнәлеш тота. Бу бик яхшы. Барлык төр тәрбия чаралары парткомда расланган план нигезендә алып барыла. Күргәзмә материалларнын янартылуын унай яктан бәяләп үтми мөмкин түгел. Кайда гына карама, партия сүзе, партия чакыруын гәүдәләндерүче лозунглар, өндәмәләр. Стена газеталары вакытында чыга, редколлегияләр яхшы кадрлар белән ныгытылган.

Шәвәлиев тагын шактый гына унай якларны күрсәтеп үтте һәм сүзен:

—Мин барысын да әйтеп бетермим, үз алдыма андый максат та куймадым, бюро утырышы барышында алар әле әйтелер,—диде. Шуннан сон шактый кимчелекләрне дә санап үтте.

—Тагын кем сөйли?

Сүз сораучы булмады.

—Сабитов! Сезнең нәрсә дә булса өстисегез бармы?

Ирек кулындагы кәгазьләрен тоткан килеш торып басты.

—Зөфәр Шәриповичның әйткәннәренә мин түбәндәгеләрне өсти алам. Дөрес, эш планнары бар. Мин ике елныкын карап чыктым. Планнарның үтәлеше бик начар. Аларның дүрттән бере дә үтәлми.

Шәвәлиев, кызарып, башын аска иде. Кайбер бюро члennарының йөзендә елмаю билгеләре чалынды. Моны Ирек тә күрми калмады. Шушында ул туктамакчы да булган иде, ләкин бит Шәвәлиев: «Мин барысын да әйтеп бетермим»,—диде. Бәлкем ул аны сыныйдыр? Идеология өлкәсендәге кимчелекләрне күрә аламы дип, мәсьәләне шулай бер яклы гына яктырткандыр? Шуңа күрә Ирек күңелендәге фикерләрен әйтми булдыра алмады:

—Әйе, йөз алтмыш лекция укылган. Бу бик күп кебек. Әмма тикшерә башлагач, хәйран каласың. Әйтик, укытучы Сәлимова ата-аналар алдында интернациональ тәрбия темасына чыгыш ясаган. Мин тикшердем, ул бернинди дә лекция түгел, гади әңгәмә. Шуны лекторлар группасы җитәкчесе, бер лекция укылды дип, исәпкә ала. Ата-аналар җыелышы культура йортында үткән булган. Аның директоры үзенең көндәлегенә шулай ук бер лекция укылды дип билге ясаса, китапханәче дә шуны иҗтимагый-политик темага бер лекция дип теркәп куя.

Бюро члennарыннан кемдер тыелып кына көлеп куйды. Шәвәлиев күзе белән Сабитовка төбәлде, аның авызын йөгереп барып учы белән томалардай булды. Ләкин Ирек аңа карамады. Әгәр караса, Шәвәлиев, һичшиксез, күз кысып булса да, аңа туктарга кирәклеген сиздерер иде.

—Мин ике бригаданың политукуында катнаштым. Алар колхоз җыелышыннан бик аз аерылалар. Шул ук хуҗалык мәсьәләләре, бернинди теоретик фикерләү юк. Мәдәният йортларында халыкны җәлеп итәрлек, кешеләр күңеленә йогынты ясарлык тематик кичәләр, конференцияләр уздырылмый...—Ирек шунда Шәвәлиевнең шартлардай булып утыруын күрде дә:

—Минем бетте...—дип урынына утырды.

Башка чыгыш ясаучы булмады.

—Карарга карата кемдә нинди фикерләр бар?—диде Арсланов.

Бюро члennарының һәркайсы үз алдына куелган карар проектын укырга кереште.

—Монда барысы да дөрес констатацияләнгән,—Арсланов проекттан карашын алмыйча гына сүзен дәвам итте.—Минемчә, Сабитов сөйләгәннәрне кертергә кирәк.—Ул бераз туктап торды һәм башын күтәрде дә, елмаеп, Шәвәлиевкә карады.—Яшьләр үсә бит, Зөфәр Шәрипович.

Шәвәлиев «ә» дә димәде, «җә» дә димәде, башын игән хәлдә кызарып утыра бирде. Беренченең: «Синең урынга да кадрлар үсеп килә, син үз эшенә болай өстән-өстән генә карама әле»,—дияе иде бу. Арсланов, тикшерелгән мәсьәлә буенча йомгак ясаганнан соң, райкомның идеология бүлеге алдына бурычлар куйды. «Ярыш»тагы кимчелекләрнең башка хуҗалыкларда да күзәтелүен, моның Шәвәлиев командасының йомшак эшләве нәтиҗәсе икәнлеген әйтте. Тикшерү күрсәткәнчә, диде ул, парткомның идеология өлкәсендәге эшчәнлеге берничек тә канәгатьләнерлек дип бәяләнә алмый. Карарны үзгәртеп язарга кирәк булачак.

—Кем шушы төзәтмәләре белән карар проектын кабул итәргә ди, шуларның кул күтәрүен сорыйм.

Барысы да бердәм кул күтәрделәр.

—Утырыш тәмам,—диде Арсланов.

Кәбиров белән агитколлектив җитәкчесе инде чыгып китәбез дип кузгалгач, беренченең кискен тавышы яңгырады:

—Кәбиров! Бер генә минутка туктап тор әле. Син аңладыңмы безнең нинди карар кабул иткәнне?

—Аңладым, Минзаһит Усманович,—диде Кәбиров.

—Анласан, үзгәр. Мин сине күптән күзәтеп йөрим. Не тем ты занимаешься. Бу сина житди кисәтү. Хужалыкта бернинди үзгәреш тә юк бит. Хәзер ничә еллар. Пора за ум взяться. Барыгыз, кайтыгыз, эшләгез.

Бюродан сон Шәвәлиев Ирекне үз бүлмәсенә чакырып кертте. Анын чырае кара коелган иде.

—Мә, кабат эшлә!—ул Ирекнен алдына карар проектын ыргытты.—Син, Сабитов, чама дигән нәрсәне оныттып жибәрәсен. Әллә син мине «Ярыш»тагы кимчелекләрне күрмәскә сукыр дип белденме? Ә син беренче каршында мине камчылап утырасын.

—Нишләп инде алай булсын, Зөфәр Шәрипович! Сез бит үзегез: «Барысын да әйтеп бетермим»,—дидегез.

—Давай, син башынны юләргә салма әле! Мин дә юләр түгел. Син инде мин барлык кимчелекләрне яшереп ята икән дип уйлыйсын. Ә без нишли алабыз? Күпме семинар, күпме жыелыш, күпме бюро—барысында да партоешма секретарьларына, агитколлектив житәкчеләренә, мәдәният, мәгариф хезмәткәрләренә тәрбия эшен көчәйтү буенча күрсәтмәләр бирәбез, барып кабат-кабат тикшерәбез, партия жәзасына тартабыз, эшеннән алабыз. Ә берәр үзгәреш бармы сон? Ну, нишләргә тиеш без? Бәлкем жавабын син табарсын?

Шушы бюродан сон кешеләр ана икенче күз белән карый башладылар. Бюро утырышы бетү белән, Әхнәф телефоннан чылтыратып, аны үз бүлмәсенә чакырды, кирә-керешкә кулын кысты, шапылдатып инбашына сукты.

—Шәвәлиевне сыртына салуын белән!—диде ул, шаркылдап көлә-көлә.

—Мин нишләгән сон ул кадәр?

—Күпме эшләп, бюро карарынын шулай кискен үзгәртелгәнлегеен мин белмим. Шәвәли өчен үтергеч кисәтү бу!

Мондый нәрсә бик тиз тарала бит. Һич уйламаган кешеләр Ирекнен кулын кыстылар, котладылар. Беркөнне анын бүлмәсенә абыйсы килеп керде дә шул ук әйберне кузгатты:

—Ну, молодец, Шәвәлиевне яндыргансын бит.

Ирек анын болай кылануын ошатмады.

—Нәрсәгә сон сез барыгыз да Зөфәр Шәриповичны күрә алмый-сыз?—диде ул, ачуы килеп.—Анын сезгә нинди зарар салганы бар?

Мэлс кычкырып көлде.

—Әле син берни дә белмисен, энекәш. Ул сина тыштан берни дә сиздермәс, елмаер-көлер, тик син ана ышанма. Бик сак бул, һәр адымынны үлчәп атла...

Абыйсынын сүзләренә Ирекнен ышанасы килмәсә дә, күнеленә шом төште...

## 8

Ирек эш бүлмәсендә бал-маскарадка сценарий язып утыра иде. Кинәт райкомолнын икенче секретаре Гөлнара белән китапханәче Сөембикә күренде. Гөлнара озын төз гәүдәле, түгәрәк йөзле, дулкынланып торучы кара чәчләре инбашларына ук төшеп торган бер кыз иде. Ирекка ул артык житди күренә, сөйләшкәндә дә бик сирәк елмая, күп чакта шаяртканны да анламый. Ана Сөембикә күбрәк ошый. Ул житендәй сары чәчле, зәп-зәнгәр түгәрәк күзле, бит очлары алсуланып тора, ә үзе, алсу иреннәре арасыннан ак тешләрен күрсәтеп, гел елмаер, гел көләр. Сөембикәнен Ирекка тагын шунысы ошый, анын тавышы ничектер балаларныкы кебек нәфис, саф һәм нечкә. Шуна күрә Сөембикә үзеннән бер-ике яшькә зур булса да, Ирек ана үскәнем дип дәшә иде. Кызлар ашыга-кабалана килеп керделәр дә, икесе берьюлы анын каршына утырдылар. Ирек, аларнын керүенә чын күнелдән шатланып, каләмен

өстәлгә куйды. Ул кызларга карап елмайды, кызлар аңа карап елмайдылар. Сөембикә пырхылдап көлеп үк җибәрде.

—Кызлар, сезнең нindидер шатлыгыгыз бар бугай. Болай гына белә алмыйм. Каяле, уч төпләрегезне күрсәтегез.

Ул шулай дип Гөлнарага үрелде, ләкин тегесе кулларын артка яшерде. Сөембикә ике кулын да, учларын югары каратып, аңа сузды. Ирек, чәнчә бармагы белән аның уч төбен кытыклап, юри нидер укыган булып кыланды:

—Бу төштә тормыш сызыгы, шатлык күренә, көлү күренә, байлык күренә. Монда бөтенләй аңлаешсыз... Ә менә бу сызыкта бер егет «Сөембикә» дип дәшә.

Сөембикә көлеп җибәрде һәм аның имән бармагын учына кысып алды. Ирек юри аны тартып ала алмаган булып кыланды, Сөембикә бармакны һаман ныграк кысты.

—Тавышланмагыз, кеше килеп керсә,—диде Гөлнара, ишеккә таба атлап.

Турысын гына әйткәндә, ул аларның шаяруларыннан көнләште.

—Ә барыбер белә алмадың,—диде Сөембикә, аның бармагын җибәреп.

—Белмәгәннең беләге авыртмый.

—Син Яңа елны кайда каршыларга җыенасың?—дип сорады Гөлнара.

Егет дәшмәде.

—Ирек абый,—Сөембикә ялварулы күзләре белән аңа карады.—Әйдә бергәләп каршылыйк, ә?

—Безнең әниләр кунакка китә,—диде Гөлнара.—Унлап кеше җыела. Әхнәф, Әминә...

—Ярар, мин каршы түгел,—диде Ирек.

Кызлар ишеккә юнәлделәр. Чыгып киткәндә, Сөембикә борылып, Ирекка телен күрсәтте. Ирек аңа әйбер аткан төсле кизәнде... Хәзер авылга кайтып, Зәнфирәне бал-маскарадка чакыру һәм Яңа елны бергә каршыларга күндерү калды. Сценарий белән, башка мәшәкатьләр белән вакыт үтте дә китте, авылга кайта алмады Ирек. Ахырда ул медпунктка чылтыратты. Трубканы Хәлимә алды, Зәнфирәнең аптекага даруга киткәнлеген әйтте. Ирек тиз генә аптекага йөгерде һәм урамда ашыга-кабалана кайтып баручы Зәнфирәне куып җитте. Зәнфирә нишләптер кәефсез иде. Артык кычкырып та көлмәде, шаяртмады да. Ирек аны юлга кадәр әйберләрен күтәрешеп озата чыкты, авыл хәлләрен сорашты. Аннары сүзне Яңа ел каршылау мәсьәләсенә борды.

—Юк, мин килә алмам,—диде Зәнфирә, район үзәгендәге бал-маскарадны бик күрәсе килсә дә. Ирек беренче гыйнварда ук сессиягә китеп барачагын әйтте. Комиссиядә булганлыктан, авылга кайту түгел, мәдәният йортыннан бер минут та китә алмаячагын аңлатты. Ахырда Зәнфирәдән «Ярар, карарбыз әле», дигән өметле сүзне алуга ирешге.

## 9

Бүген иске елның соңгы көне. Бернichә сәгатьтән яңа ел. Нәрсәләр алып килә ул безгә? Юк, әле ул турыда уйлыйсы килми, әле аңа кадәр бик күп шатлыклар, куанычлар белән тулы сәгатьләр бар. Ирек белән Зәнфирә инде икенче мәртәбә район үзәге урамнарын әйләнәләр. Мамык карлар ява, бөтен җиһан шушы өстән иңүче ак бөрчекле чуар пәрдә артында калган. Мәдәният йорты каршындагы мен төрле бизәкләре белән балкучы биек чыршы да, аның янәшәсенә өелгән озын кар тавын сырып алып чана шуучы бала-чагалар да, төрле-төрле ниг ъмәтләр, тәмле кәрчә-мәрчә тулы өстәлләрдә ялтырап утыручы самавырлардан, табаларда чыжылдап пешүче кайнар коймаклардан күтәрелүче булар да, шашлык асларында пыскыган күмер төтеннәре дә, кар кунган бүрекләр, шәлләр, шарфлар эченнән елмаючы йөзләр дә,

борыннарыннан пар бөркүче, ялларын туздырган пар атларда гармун уйнап, җырлар җырлап әйләнүче егет-кызлар да—бөтенесе, бөтенесе сихри төстә бер-берсенә якынайган, үзара кушылып куерган, бөтенесе бергә буталып бөтерелә. Әмма шушы мәхшәр эчендә һәрбер кар бөртегенен һавадан ак моң булып төшкәне, ак моң булып җиргә кунганы ишетелә, шау-шу эчендәге мондый сәер тынлык Яңа ел кичендә—үткән еллар офыгына бәрелеп, киләчәккә кайтаваз булып яңгырый торган Яңа ел төнендә генә була: болар бөтенесе, күңелгә тулып, сине әллә кайларга күтәрәләр, очсыз-кырыйсыз буш кинлекләргә чөяләр, син шушы тылсымлы әкият эчендә эреп юкка чыгасың, бары тик соклану, шатлык тойгысы гына сине үзең итеп тота, ак моңнан исерәсең, әмма исергән саен дәртең, гайрәтең арта бара. Бөтенесе изрәтә, бөтенесе айныта! Бөтенесе серле! Бөтенесе хыялый! Сәгатьләрне-минутларны саный торган, әмма чиксез вакыт бусагасы төбенә килеп җитүенә куанган чак. Бусага аша атла һәм ул—синеке, ул әле башланмаган, ул, ак кояш, көмеш нурлар белән өретелеп, синең алдыңда тора, сиңа бары тик шатлык-бәхетләр генә вәгъдә итә...

Ирек, кулларын сузып, кар бөртекләрен тота, ылыс ботагыннан кар алып авызына каба.

—Салкын тигерәсең, юләр!—дип Зәнфирә аны тиргәгәндәй итә.

—Кем белә, бәлкем мин иске елның соңгы кар бөртекләрен беренче булып үбүче кешедер?!—ди Ирек елмаеп.—Син дә миңа кушыласыңмы?

—Юк!

—Ул чакта мин сине карлы авызым белән үзем үбәм!

Һәм ул тиз генә аның бит очыннан үбеп ала.

—Кеше алдында... Әллә эчтеңме син?!

—Эчмичә исердем, син китергән шатлыктан, Зәнфирә!

Сәгать җидедә мәдәният йортында маскарад башланды. Гөлнара белән Сөембикә, Әхнәф, мәдәният бүлеге мөдире Азат Ирекне әле бер якка, әле икенче якка тарткаладылар. Зәнфирә зәңгәр күлмәк киеп, зәңгәр шәл бәйләп килгән иде. Ирекне алар алып киткәндә, ул берүзе утырып калды, йөзе җитдиләнде. Ләкин бал-маскарад Иректән башка бармый иде, сценарийга шунда ук төзәтмәләр кертергә, нәрсәдер өстәргә, нәрсәнедер кыскартырга туры килде. Менә беренче вальс башланды. Ирек Зәнфирәне биергә чакырды, алар әллә ничә төрле утлар белән балкып торган чыршы тирәсендә әйләнә башладылар.

—Әллә син килгәнеңә үкенеп утырасаң инде?—диде Ирек, Зәнфирәнең колагына пышылдап.

—Юк, миңа бик күңелле...

Алар яңадан сүзләрен дәвам итә алмадылар, Сөембикә килеп: «Сине комиссия председателе чакыра»,—диде. Ирек, гафу үтенеп, Зәнфирәне урынына утыртты да сәхнәгә менеп китте. Шулчак кара костюм-чалбар кигән, кара галстук таккан, чегәннекедәй бөдрә чәчле бер егет Зәнфирәне танцыга чакырды. Зәнфирә чакыруны кабул итте, ләкин егетнең каршына басу белән ул укшып җибәрә язды. Аңардан аракы исе бөркелә иде.

—Мин сезне беренче мәртәбә күрәм, чибәркәй,—диде егет, исерек телен көч-хәл белән әйләндереп.

—Мин үземнең чибәркәй икәнемне сездән башка да беләм, бөдрәкәй,—диде Зәнфирә, аңардан тизрәк котылу теләге белән.

Ләкин егет үпкәләргә уйламады да, авызын күтәреп хихылдап көлеп җибәрде.

—Кыю икәнсез үзегез.

—Әйдәгез минем турыда сөйләшмик әле.

—Ә минем сөйләшәсем килә,—диде егет.

—Ләкин тормыш бит сезнең теләкләрегез белән генә бармый.

—О-о-о, аңладым. Сез ни турында сөйләшер идегез соң?

—Минем кем белән танцы иткәнемне беләсем килә.

—Рәхим итегез,—диде егет, башын иеп һәм Зәнфирәнең борынына

аракы исе бөркеп.—Мин беренче секретарьның яраткан улы булам.

Шушы сүзне әйтүе белән егет «Минем белән биегәнгә горурлан», дигәндәй тоелды. Зәнфирә аның мактанчыклыгын ошатмады.

—Мин сезнең атагыз кем дип сорамыйм бит әле,—диде ул.

—Алайса рәхим итегез: буем бер дә житмеш, авырлыгым житмеш биш килограмм, бер елдан аттестат алам, Мәскәү инженерлык институтына керергә жыенам. Тагын нинди мәгълүматлар кирәк?

—Рәхмәт,—диде Зәнфирә.—Сез мине башка кызыксындырмыйсыз.

Ул егетнең кулларыннан ычкынды да «гафу итегез» дип урынына барып утырды. Ирек һаман юк иде. Менә уртада уеннар башланды. Алып баручы чыршы янына бер кыз белән бер егетне чакырды. Баягы егет йөгереп килде дә Зәнфирәне кулыннан сөйри башлады. Ул карышты, урындыгына ябышып, егеткә:

—Мин уйнамыйм, зинһар кыстамагыз,—диде.

Шулчак алар янына Ирек килеп житте. Теге егет белән кул биреп күреште дә:

—Зәнфирә, нигә чыкмыйсың, Рашат чакырганда карышмыйлар,—диде.

Зәнфирә аңа бер сүз дә дәшмәде, ачулы карашын төбәп алды да кулларын артына яшерде, егет китеп барды. Ирек аларның тарткалашканын Арсланов белән хатыны карап утыруын күрде.

Уеннардан соң тагын танцы башланды. Ирек инде Зәнфирәне танцыга алып чыгыйм гына дигәндә, Сөембикә килде дә:

—Ирек абый, бу Яңа елда без бер мәртәбә дә синең белән биемәбез микәнни?—диде һәм, кулыннан эләктереп, уртага сөйрәде. Ирек, Зәнфирәгә борылып карый-карый, аңа ияреп атларга мәжбүр булды.

Шуны гына көткәндәй, Рашат тагын килеп Зәнфирәне биергә чакырды. Ләкин ул «юк» дигән мәгънәдә баш чайкады. Беренче секретарь малае өчен болай борылып китү зур оят иде, ул, ачуына түзә алмыйча, залдан бөтенләй үк чыгып китте. Зәнфирә исә менә елап жибәрәм, менә елап жибәрәм дип утыра иде. Сөембикәнең кызыл иреннәрен уйната-уйната, Ирекнең авызына керә язып нидер сөйләве, аларның бер-берсенә сыланып бетеп танцы итүләре аның женен котыртты. «Ичмасам килмәгән булсам, күрмәс идем, хәзер авылда рәхәтләнеп яшьләр белән бергә чыршы тирәсендә күнел ачар идем», дип уйлады. Ирекнең инде монда яңа дуслары бар, ул аны юри генә, күңелен сындырмас өчен, кыенсынганнан гына чакыргандыр кебек тоелды. Әгәр хәзер берәр машина булса, ул, ике дә уйламыйча, авылга кайтып китәр иде. Яңадан Ирек үзен танцыга алып чыккач, ул бер сүз сөйләшмәде, минем ачуланганымны, рәнжегәнемне белсен дип, бер генә мәртәбә дә елмаймады. Яңа ел кичәсе үзенең ахырына якынлашты. Бер-бер артлы маскалар керде, аларны күргәч, Зәнфирәнең күңеле кабат ачылып китте. Иң кызыгы эт белән мәче маскасы иде. Алар житәкләшеп йөриләр, мәчесе сап-сары, эте кап-кара, үзе күзлектән, туктаусыз мәчесен сыпырып тора, иркәли, тегесе аның иркәләвенә мияулап жавап бирә. Менә маскалар биюе башланды. Ирек Зәнфирәне уртага чакырды һәм алар рәхәтләнеп, дөньяларын онытып танцы итә башладылар. Ирек аның кәефе күтәрелгәнгә шатланып туя алмады, ләкин бу шатлык озакка булмаган икән. Эт белән мәче, икесе ике яктан килеп, аларны аердылар. Мәче Ирек белән, эт Зәнфирә белән бии башлады. Зәнфирәгә әле башта кызык иде, зур гәүдәле кара эт белән бию бу залда беренче аңа тәтеде, бөтен кешенең күзе аларда иде. Кызып-кызып биегәндә, алар вальс моңнарына әйләнеп киттеләр һәм шул чакта эт бик каты итеп аның аягына басты. Зәнфирә чак кычкырып жибәрмәде, авыртудан иреннәрен тешләде, ләкин берни сиздермәде, әйләнүен дәвам итте. Алар тагын кемгәдер килеп бәрелделәр, эт аның икенче аягына китереп басты, бусында аның күзләреннән атылып яшь чыкты. Әйтерсең, аның аягына бетоннан коелган күсәк белән китереп суктылар. Ул, эттән ычкынып, урынына барып утырды, сызланудан

аякларын селкеп алды. Ә Ирек мәче белән рәхәтләнеп бии, хәтта аның озын койрык очын үзенең костюм кесәсенә дә кыстырып куйган иде. Соныннан маскаларны бүләкләү башланды. Жюри беренче урынны эт белән мәчегә бирде. Аларга бүләк тапшыргач, маскалар салынды, һәм Зәнфирә чак кычкырып җибәрмәде: песи булып киенгәне Сөембикә, ә аның аягын шештереп чыгарганы беренче секретарь малае иде. Шулчак ул үзенең аягына Рашатның юри ачу белән басканын аңлады. Анысы тагын ник кирәк булгандыр, халык алкышлаган вакытта, инде хәзер тиресен салган эт аның алдына килеп баш иеп китте.

Уеннар әле дәвам итә иде. Жюри комиссиясе председателе Миннуллин лотерея уенында катнашучыларга отышларны атый башлады. Бал-маскарадның иң югары бүләге, билетлардагы иң югары отыш Арсланов хатынына чыкты. Ул бер шешә шампанский иде. Халык гөрләтеп кул чапты. Бал-маскарад беткәннән соң, Гөлнара, Сөембикә, Әхнәф һәм тагын берничә егет Яңа ел каршыларга киттеләр. Ирек белән Зәнфирә алардан арттарак калып атладылар. Адым саен Зәнфирә аягының авыртуыннан кычкырып җибәрердәй булды. Бигрәк тә уң аягының баш бармагы сызлауга түзәрлек түгел иде. Әйбәт кенә кайтканда, кинәт аларның каршына тагын Рашат килеп чыкты.

—Ирек, может быть, уступишь?—диде ул, боларның каршында аякларын аерып баскан килеш.

—Син башта татарча сөйләшергә өйрән!—диде Зәнфирә, ачуын тыя алмыйча.—Ә русча сүзләреңне Мәскәү маржаларына калдыр.

Зәнфирә Ирекне култыклады да, читтән урап, аны сөйрәп диярлек алып китеп барды. Егет, аягын аерып баскан килеш, урынында калды. Ә бераздан башын алар ягына борып:

—Колхоз!—дип кычкырды.

Алар шактый вакыт сөйләшмичә бардылар.

—Сез беренче секретарь малаен муеныгызга атландыргансыз икән,— диде Зәнфирә, Ирекнең күзенә туры карарга тырышып.—Үзеннән аракы исе килә, үзе сагыз кебек сылана. Кара, нинди сүз әйтеп калды.

—Зәнфирә, әйдә бүген күңелсез нәрсәләр хакында сөйләшмик әле. Яңа елның соңгы минутлары. Бу мизгелләр сагынып сөйләргә калсын.

Менә алар Гөлнараларга кайтып җиттеләр. Алты почмаклы зур агач өйнең түр ягында, аллы-гөлле нурлар чәчеп, чыршы балкый, ике өстәл бергә терәп, табын әзерләнгән иде. Чишенеп, төзәтенеп өстәл янына утыруга, телевизорда совет халкына Яңа ел котлавы яңгырады. Барысы да басып, шампан шәрабе авыз иттеләр. Аннары Әхнәф Ирекккә тост әйтергә кушты.

—Мин сезне Яңа ел белән котлап, тормышта өчәү бергә атлау өчен тост тәкъдим итәм.

Табындагылар канәгатьсезлек билгесе белдереп шаулашып алдылар:

—Өчәү?!

—Кемнәр соң ул?

—Сер булмаса, әйт әле!

—Сер түгел,—дип дәвам итте Ирек.—Берсе—үзем, икенчесе—хыялым, өченчесе... күңел бакчасында һәркөн сайраучы былбылым...

Соңгы сүзләрне әйткәндә, ул Зәнфирәгә карап куйды, ул исә керфекләрен аска төшерде.

—Аныкы шагыйрьләрчә булыр инде!

—Бүлдермәгез зинһар!

—Кызганыч, тормышта шушы изге нияткә аяк чалучы бик хәтәр көтүче бар. Аның чыбыркысын күрсәгез! Ул көтүче үзе генә булса, бер хәл иде әле. Аның кырыкмаса кырык баласы, бабасы, оныклары, туганнары сине сырып ала да, хыялың бер якка, үзең икенче якка салулыйсың, былбылың еракта ук торып кала...—Ирек сүзен юри бераз бүлеп торды.

Табын тагын шаулады:

—Ул нинди мәрхәмәтсез көтүче икән?

—Без аны куып җибәрербез!

—Сез аны куа алмыйсыз шул,—диде Ирек һәм имән бармагын югары күтәрде.—Ул көтүченең исеме—Эш.

Әлеге сүзне ишетүгә һәммәсе көлеп җибәрде.

—Касмагын кырып бир инде тизрәк!

—Касмагы шул: безнең бүгенге бәйрәмне каршылавыбыз яшьлек елларыбызның иң гүзәл бер сәхифәсе булып калсын иде. Өчебезнең гомергә аерылмавыбыз өчен!

Бөтенесе дә гөрләтеп кул чаптылар, шампан шәрабе салынган бокаллар, чеңгел-чеңгел килеп, бер-берсенә чәкелде...

Мәҗлес бик озак дәвам итте. Алар рәхәтләнеп җырладылар, биеделәр, күңел ачтылар. Иртәнге өч тулганда Сөембикә:

—Егетләр, кызлар! Әйдәгез бакчага тау шуарга барабыз!—диде.

Аның сүзен барысы да дәррәү хупладылар. Бакчада халык шактый иде. Кайберләре тау шуа, кайберләре гармун белән җырлап йөри, кайберләре тамаша кыла. Ирекләр, Зәнфирәләр кар тавының иң биегенә менделәр, пальтоларына утырып, чажлап аска шуып төшеп киттеләр. Тагын йөгереп менделәр, тагын шудылар, баш-аякларыннан ап-ак карга батып беттеләр. Аларга күңелле, рәхәт, дөнья иркен, берни дә кирәкми иде. Сөембикә әллә ничә мәртәбә Ирекне кочаклап алды да аның белән бергә таудан тәгәрәп төште. Зәнфирәнең тагын кәефе кырыла башлады. Әминә дә, Гөлнара да гел Ирек тирәсендә чуалалар иде. Бервакыт ул тау башында ялгызы гына басып калды. Еш-еш сулап, Ирек аның янына менде һәм, Зәнфирәне кочаклап, тәгәри-шуа бергә төшеп китте. Тау итәгенә җитүгә, Зәнфирәнең болай да авырткан уң аягы, җайсыз килеп, тубыгыннан каерылды. Ул ыңгырашып җибәрде, авыртудан шактый вакыт тора алмыйча ятты. Яшьләр чыр-чу киләләр иде, беркем берни сизмәде. Ирек аны култыгыннан тотып торгызды, тагын тау башына алып менмәкче булды. Зәнфирә аягым авырта, булмый димәде, әле генә үзләре белән күңел ачып утырган бу кызлар, егетләр каршында аның кәефсез дә, рәнҗетелгән булып та күренәсе килмәде. Шуңа күрә ул Ирекка пышылдап кына:

—Әйдә кайтыйк,—диде.

Ирек аңа каршы килмәде, саубуллаштылар да култыклашып китеп бардылар. Зәнфирә үкчәсенәрәк басып атласа да, аягының авыртуы нык сиздерә иде.

—Син ныклап аксыйсың бит,—диде Ирек, аңа карап.

—Бая синең белән шуып төшкәч, аягым каерылды.

—Соң, аны ник шундук әйтмәдең? Их син! Кайсысы?

—Уңы.

Ирек аның уң ягына чыкты, иелеп, бармаклары белән аягына баскалап карады.

—Сынган-тайган булырга тиеш түгел. Безнең фатирга кадәр кайтып җитәрбездер бит?

—Җитәрмен,—диде Зәнфирә, кәефсез генә.

Ирекнең фатир хуҗасы аларның икесенә ике караватка түр якка урын җәеп куйган иде инде, үзе ул кече якта йоклый. Хуҗа хатын аларны ачып кертте дә, утны да яндырып тормыйча, урынына ауды. Ирек белән Зәнфирә, тавыш-тынсыз гына чишенеп, түр якка үттеләр. Өйдә шактый якты иде.

—Мин чишенгәнче чыгып тор әле,—диде Зәнфирә.

Ирек аның караватына аркасын куеп басты.

—Әйдә, мин карамыйча гына торам.

Ул аның чишенгәнен тыңлап торды, кием кыштырдавыннан кайсын салганын, кайда куйганына кадәр аермачык сизде.

—Булды,—диде Зәнфирә, караватына менеп одеал астына чумгач.

Ирек күлмәген салды, чалбарын элеп куйды, юка кара трикодан, майкадан калды. Аны үзе дә теләмәгән ниндидер көч өзлексез Зәнфирәгә

таба тарта иде. Ул бөтен барлыгы белән карышты, ул якка хәтта борылып карамаска тырышты, ләкин карышкан саен, күзләре шунда төбәлделәр, аяклары Зәнфирә ягына таба атладылар. Менә ул караватт янында. Зәнфирәнең кап-кара чәчләре ак мендәр өстенә таралган, кара кашы, матур булып күпереп торучы иреннәре аермачык күренә. Ирек аның иреннәренә үрелде, Зәнфирә карышмады. Ирек, одеалын күтәреп, аның янына менмәкче булды, ләкин Зәнфирә кинәт иреннәрен читкә алды да:

—Ирек, кирәкми...—диде.

—Без бит барыбер бергә булачакбыз...

Ирек, шашып, аның муеннарыннан үбә башлады. Зәнфирә үзенең бармаклары белән аның чәчләрен аралады, битләрен, колакларын иркәләде. Ирек кабат гәүдәсен караватка менгермәкче булды. Инде сул аягы Зәнфирәнең аяклары янында иде. Ләкин Зәнфирә аны йомшак кына этеп җибәрде. Ирек аның йөзенә игътибар белән карады. Урамнан төшкән яктылыкта аның күзләренең яшьләнгәнен күрде. Ул арада Зәнфирә әкрен генә сулкылдый да башлады.

—Зәнфирә, ни булды сина?

—Юк, берни дә юк...

Ирек мәче тизлеге белән одеал астына керде дә аны биленнән кысып алды һәм кайнар тәнен үзенә тартып китерде.

—Ирек, кит!—диде Зәнфирә сулкылдап.

Ирек, еш-еш сулаган хәлдә, аның кайнар гәүдәсен үзенә кысты, колагына баягы сүзләрен пышылдады:

—Без бит барыбер бергә булачакбыз, Зәнфирә...

Зәнфирә аны ике кулы белән күкрәгеннән этте, һәм Ирек, караваттан төшеп, идәнгә басарга мәҗбүр булды.

—Юк, Ирек. Без беркайчан да бергә булмаячакбыз...

—Ничек инде, ни сөйлисең син?!

Зәнфирә җавап бирмәде, күз яшьләре аның керфекләреннән, битләреннән тәгәрәп төште. Ул тавышсыз гына сулкылдый иде.

—Ничек без бергә була алмыйбыз?! Ничек инде бергә була алмыйбыз?!

Ирек өзгәләнүдән нишләргә белмәде.

—Шулай, Ирек. Мин сизәм, без беркайчан да бергә була алмаячакбыз. Бар урыныңа ят... Шушы минутта ук кит. Югыйсә, мин синең турыда начар уйлаячакмын.

Ирек, аякларын көч-хәл белән сөйрәп, үзенең караватына барып ауды. Ул яктырганга кадәр керфек тә какмады, Зәнфирә дә нәкъ аның хәлендә иде... Бүгенге көнне, бал-маскарадны, үзләренең Гөлнараларда утыруларын, аннары бакчага чыгуларын—һәммәсен дә хәтереннән үткәрде һәм, хәтерләгән саен, күңел түрендә ниндидер ачу кузгала баруын, ул ачуның башка беркемгә дә түгел, ә бәлки үзенә карата икәнлеген аңлады. Тора-бара ул ачу күрә алмауга әйләнде. Ирек үзен бөтен кешедән дә түбән, җирәнгеч итеп тойды. Аның шулай икәнлеген бүген Зәнфирә күрде, аңлады һәм мәңгегә аның белән булмаска карар бирде. Иң элек, җирәнгеч булып, Шәвәлиев күз алдына килеп басты. Бал-маскарадның буеннан-буена аның беренче секретарьга ярарга тырышып бөтерелүе Ирекне таң калдырды. Шәвәлиев мәдәният йорты директоры булмәсенә эчемлекләр, тәм-том китерткән иде. Әледән-әле ул шунда Арслановны алып кереп чыкты. Бал-маскарад беткәндә, аларның чырайлары бурлат кебек иде инде. Беренче секретарьның хатынына шампанскийны да ул үзе китереп бирде, башын тезләренә тигерә язып иде. Шәвәлиев шулай йөрсен дә ди. Ә соң Ирек үзе? Нәрсә эшләде? Анардан кай ягы белән өстен? Шәвәлиев бармагы белән ана бер ишарә ясауга, Ирек, йөгерә-атлый сәхнәгә менеп житеп, ул әйткән һәрбер сүзне үтәмәдемени? Арслановның малае Рашат Зәнфирәне танцыга тарткалаганда, ана ярдәм итеп, Зәнфирәне кыстап тормадымыни? Урамнан кайткан чакта, Рашатның әйткән сүзләренә Зәнфирә түгел, ул җавап бирергә тиеш түгел идемени?

Нишләп соң мин шул дәрәҗәдә түбән төштем? дип, коты очып уйлады Ирек. Нәрсә булды? Ярый, Шәвәлиевкә кәнәфиен сакларга кирәк. Ул ялагайлансын да, алдашсын да, этләшсен дә. Ә соң Ирекkә ни кирәк? Бу урын өчен ул җан атамы? Һич тә юк. Әйе, ул тормышны күрде. Әйе, ул зур эшләрнең уртасында кайный. Ләкин, халыкка әйтер сүзе булса да, язуны ташлады, университеттагы курсташларыннан ел ярымга артта калды. Соң алай булгач, нигә ул Шәвәлиев кырында аның хезмәтчесе кебек бөтерелә? Кол үзенең хуҗасына караган кебек, түбәнчелек белән баш ия?

Ирек шунда, кара еланга китереп баскандай, бер коточкыч фикергә тап булды. Аны беркем дә мәҗбүр итми, ул бу хурлыклы эшне үз теләге белән башкара икән. Хыялыннан читләшеп, мәңгелек өчен кыласы бөек һәм илаһи гамәленнән качып, Арслановлар каршына үзе барып тезләнә икән ул. Бу—акылга сыя торган хәл түгел, әмма ни аяныч!—бу шулай иде. Аның уйлавынча, әлеге изге эшкә болай гына тотынып булмый, аңа пакьланып, үзенне тормыш вак-төякләреннән арындырып, тулаем багышларга кирәк. Ә башкалар? Юлларындагы барлык киртәләрне җимереп, үз хыяллары артыннан мәңгелеккә омтылучылар аз түгел лабаса! Димәк, мөмкин. Димәк, хикмәт Ирекнең үзендә. Әлеге олы илаһи гамәл япа-ялгызын зур җаваплылык алу, карарлар кабул итү, барысын да берүзең күтәрү дигән сүз. Монда өстән кушучы юк. Бөтенесе үз йөрәгендә, үз зиһененә, үз ихтыяр көченә бәйле. Ирек шушылардан курка булып чыга түгелме соң? Шуңа күрә кем куша—шуңа елыша. Арслановлар җаваплылык алудан курыкмый, Ирекләр кебек әзер көчне ничек телиләр, шулай файдаланалар. Син, җаныңны шайтанга саткан кебек, көн саен, аз-азлап үзенне аларга бүлгәләп бирәсең. Хыялыңа барасы юлында үскән шайтан таякларын йолкып атасы урында, син аларга су сибеп йөрисең, аларның тамырларына ашлама буласың... Бу—коточкыч иде. Моннан һичшиксез котылырга кирәк иде...

Алар, яктырылу белән торып, берни ашамыйча, берәр чынаяк чәй эчтеләр дә өйдән чыгып киттеләр. Зәнфирәнең аягының авыртуы бетеп җитмәгән, ул җинелчә генә аксый иде әле. Икесе дә кәефсез, йокысызлыктан һәм авыр уйлардан икесенең дә күз төпләре күгәргән, йөзләрендә элеккеге нур юк. Хуҗа хатын моны үзенчә шомланып, үзенчә юрап калды, гөнаһлы булдым шай дип, эченнән генә уфтанды...

Ирек белән Зәнфирә, авыл башына кадәр баргач, икесе ике якка аерылдылар. Ирекнең алдагы көнне тутырып куелган чемоданы кулында иде, ул аэропортка юл тотты. Ә Зәнфирә авылга кайтып китте.

—Исән йөр,—диде ул, сагышлы тавыш белән.—Имтиханнарыңны яхшы тапшыр.—Аннары ничектер саран гына елмаеп куйды:—Ә мин сиңа көн саен теләк теләрмен,—диде.

—Рәхмәт, Зәнфирә. Мин сине Казаннан кайту белән күрермен.

Алар кул бирешмәделәр, ике якка китеп бардылар. Ирек аэропорт бинасына җитеп кенә килгәндә, каршысына аэропорт начальнигы Минһаҗев чыгып кул изәде:

—Сезне икенче секретарь телефонга чакыра.

Ирек, аның бүлмәсенә кереп, трубканы алды.

—Нихәл, Сабитов,—диде Шәвәлиев, аның тавышы бик нык карлыккан, танырлык та түгел иде.

—Әйбәт. Менә китәргә җыенам,—диде Ирек.

—Сиңа борылып кайтырга туры килер.—Шәвәлиевнең ютәлләгәне, шаулатып сулыш алганы ишетелде.—Бүген бюро булды, хәзер бөтен активны җыябыз, отпусктагыларны да чакырабыз.

—Тагын кайсы төш яна, Зөфәр Шәрипович?—диде Ирек, ачуын тыя алмыйча.

—Өлкә комитетының идеология секретаре килә. Һаман синең белән минем башка. Шушы атна эчендә барлык урыннарда йөкләмәләрне кабул иттереп бетерергә кирәк. Ярыш оештыру буенча килә. Давай син срочно кайтып җит әле.

Ирекнең карары катгый иде.

—Минем имтиханнарны сез бирерсезме соң?

—Слушай, Сабитов, сессиягә җибәрү-җибәрмәү ул эштәге мөмкинлектән чыгып хәл ителә. Җәйге сессиягә эштән ун көн алдан бушатырбыз.

—Юк инде, Зөфәр Шәрипович, мин китәм. Болай да курсташларымнан күпкә артта калдым.

—Китмисең!

—Китәм!

Ирек трубканы шапылдатып куйды. Телефон шундук кабат чылтырарга кереште. Минһаҗев, шикләнеп кенә, трубкага үрелде.

—Әйе, Зөфәр Шәрипович... әйе... соң бу бит... сез мине...

Аның әйтергә теләп тә әйтелә алмаган сүзләре эчендә калды.

—Мина Казанга билет бирегез,—диде Ирек.

Минһаҗев ишек катыннан урап килде, урынына утырды һәм күзләрен аска яшереп:

—Билет юк, иптәш Сабитов,—диде.

—Ничек юк? Сез бит әле кергәндә генә райком броне буш дидегез.

—Әйе. Тик мин аны сезгә бирә алмыйм.

—Нишләп?

Минһаҗев Ирекка «мине кызганыгыз, зинһар» дигән төсле итеп карады.

—Төпченмәгез инде. Әгәр сезгә билет бирсәм, иртәгә мин бу урында булмаячакмын. Гафу итегез...

Минһаҗев бүлмәсеннән чыгып ук китте, күрәсең, ул үзенең көчсезлегеннән ояла иде.

Ирек Шәвәлиевнең телефон номерын җыя башлады да туктап калды. Аңа чылтыратып нәрсәне үзгәртә аласың соң? Ул, ачуыннан шартлардай булып, райкомга юнәлде. Эченнән елап-сыкрап җил-җил атлады, хәтта китаплар белән шыплап тутырылган зур чемоданының да авырлыгын сизмәде. Райком бинасына килеп җиткәндә генә ул пальтосының эләктерелмәгәнлеген, шарфының, муеныннан шуып, бер якка асылынып төшкәнлеген абайлады. Кулына перчаткалары да киелмәгән иде.

Ул ашыга-кабалана бүлмәсенә керде.

—Яңа ел белән!—дип каршылады аны Әминә.

—Минем өчен яңа түгел, кара ел әле бу, Әминә...

—Мин аның бүлмәсендә чакта чылтыратты бит ул аэропортка. Ник кайттың соң син? Китәргә дә барырга иден.

—Эштән азат итүләрен сорап гариза бирәм...

—Анысын үзең беләсеңдер, Ирек.—Әминә, аның хәленә кереп, авыр сулап куйды.—Үзем дә берничә мәртәбә китмәкче булып карадым. Котыла алмадым...

Аның соңгы сүзләреннән Ирек әллә нишләп китте.

—Котыла алмадым?!

—Ни әйтим соң? Биредә нипель системасы. Ачуланышып киткән суратта син эшсез каласың. Гадәттә кешене куып чыгарганда шулай була. Ябышып ятудан башка юл калмый...

Ирек райком бюросы исеменә, үзен эштән азат итүләрен сорап, гариза язды да икенче катка менеп китте. Беренче гыйнвар ял көне булуга карамастан, кабул итү бүлмәсендә халык кайнап тора иде. Сәгать унга Арсланов районның барлык җитәкчеләрен җыя икән. Бу аның һәр бәйрәмнән соң эштә эленке-салынкылык китмәсен, салып йөрмәсеннәр, дип җыя торган киңәшмәсе. Бу—аның үзенә йөкләнгән олы җаваплылыкны хәтта шушындый бәйрәм вакытларында да онытмавын барлык җитәкчеләргә күрсәтә торган, махмырлары йөзенә чыкканнарга төрттереп ләззәтләнә торган киңәшмәсе.

Ирекне Шәвәлиев май кояшы кебек елмаеп каршылады.

—Молодец, Сабитов!—диде ул, куануын яшерә алмыйча.

Ирек гаризасын аңа бирде.

—Бу ни?

—Язу таныйсыздыр бит.

Гаризаны укып чыккач, Шәвәлиевнең йөзе сүрелеп китте.

—Ни булды?

—Оялмыйча ничек шундый сорау бирә аласыз?!

—Син чамалап!

—Сессиягә китеп барганда, билет бирдермичә борып кайтару сезненчә гадәти хәл алайса?

—Соң, дөрләп янабыз бит, Сабитов! Ничек син шуны аңламыйсың?!

—Мин монда пожарныйда эшләргә килмәдем. Көн саен янгын! Чиратта өлкә комитеты секретаре дигәне дөртләп кабынган.

—Әйдә, шагыйрьләрчә сөйләшүне ташлыйк әле, Сабитов!

—Яхшы. Гаризамны бюрога кертегез.

Шәвәлиев, узган ел Ирекнең шушындый бер гаризасын алып калып, акрын гына җайлап-майлап, аны оныттырган иде. Бусын ни эшләтергә соң әле дип баш ватты ул һәм бу юлы башка юл сайлады.

—Син партия солдаты икәненне онытасың, Сабитов.

Шулай дип, Шәвәлиев гаризаны ерткалады да чүп савытына ыргытты.

—Аңлашылды. Сез мине эштән җибәрергә теләмисез.

—Бу мәсьәләне мин генә хәл итә алмыйм.

—Алайса ни өчен гаризамны ертып аттыгыз?

—Мин синең турыдан-туры җитәкчең, син иң элек минем боерыкка буйсынырга тиешсең.

—Бюроны да, Миңзаһит Усмановичны да исәпкә алмыйсыз, ә? Мин хәзер үк ана керәм!

Ирек, Беренченең исемен әйтүгә, Шәвәлиевнең кан калтыравын белә иде. Менә хәзер дә ул өстәл артыннан атылып чыкты да, Ирек янына килеп, аны юмаларга кереште:

—Ирек, Ирек Хәйриевич... моңа кадәр килешеп, матур гына эшләдек бит әле. Мин бит...

Ирек аның сүзен кискен бүлде:

—Юк! Без беркайчан да килешеп эшләмәдек. Сез мине таладыгыз.

—Ничек була ул талау?

—Кешенең гомерен талап алу була. Кисәкләп-кисәкләп. Көн саен, сәгать саен.—Ул үзенең йөзен аныкына шулкадәр якын китерде ки, Шәвәлиев куркудан башын хәтта артка ташлады.—Минем гомерем үземә дә кирәк, аңлыйсызмы?

—Ә без нәрсә?—диде Шәвәлиев, чигенә-чигенә барып, кәнәфиенә утыргач.—Без дә үзебезне халыкка бирәбез. Тулаем бирәбез.

Ирек аңа усал елмаеп карады.

—Халык алырга теләр микән соң?

Шәвәлиевнең күзләре түгәрәкләнде, иреннәре калтырап куйды.

—Менә нинди икәнсең син!

—Мин шундый. Авызга бармак тыксалар, шартлатып өзеп тә алам!

Ирек аңардан чыкты да, кабат гариза язып, Арсланов бүлмәсенә кереп тә китте. Секретарь кыз аның артыннан:

—Ирек Хәйриевич, линиядә өлкә комитеты, сабыр итегез!—дип кычкырып калды.

Һәрвакыт урыныннан торып, кул биреп исәнләшә торган беренче секретарь бүген урыныннан купмады, Ирекнен хәерле иртә теләвенә мыгырданып кына җавап бирде.

—Тыңлыйм сезне.

Арслановның өлкә комитеты секретаре белән булган авыр сөйләшүдән ушына килә алмаган чагы иде. Ирекка нидер булды, ул ничек башларга белмичә аптырап калды. Әгәр беренченең кызыксынучан, игътибарлы карашын тойса, ул каушамаган да булыр иде. Теленнән бөтенләй уйламаган сүзләр ычкынды:

—Мин ашалып беткәнмен, ахрысы...

Арсланов йокысыннан уянгандай сискәнеп куйды, кашлары югары күтәрелде, мангаена ике тирән жыерчык чыкты.

—Ни дидегез?

—Сезнең өчен мин бөтенләй юк, ахрысы...

—Гозерегезне әйтегез...

—Мин райкомда бүтән эшли алмыйм.

Ирек гаризасын аның алдына салды. Арсланов, кагылудан курыккандай, гаризаны кулына алмады, иелеп кенә укып чыкты. Аннары, башын күтәреп, сөзәргә жыенган үгезнекедәй кызарган күзләре белән Ирекка төбәлде.

—Сәбәп?

—Минем эш түгел бу. Үземне ваклап-ваклап өләшеп бетердем мин.

—Катлаулы сөйлисез.

—Аңламаслык берни дә юк. Минем шәхси тормышым бетте. Укырга да, язарга да вакытым юк, әтиләр-әниләр янына кайта алмыйм, абыйны күргән юк. Мин кеше буларак нуль. Сезнең өчен, райком өчен генә бар.

Кичә бал-маскарадта Арсланов аның зал белән сәхнәне бер итеп йөрүенә, бөтен тантананы оештыруына сокланып, ә үзенең исерек малаеның буталып йөрүенә нәфрәтләнеп утырган иде. Бүген ул Ирекка коты очып карады. Аның элеккеге якты, ышанычлы күз карашы нишләп сүнгән соң? Сабый баланыкы төсле бернием дә яшерә алмый торган йөзенә, бөтен эчке халәте, сөенеченнән башлап кечкенә борчуына кадәр, чатнап язылып бара торган соклангыч йөзенә ни булган? Күзләрендә ачу-каргыш, әле кичә генә уйнап торучы якты йөз чалымнарын гүя коточкыч авыр, газаплаучы нәрсә баскан, әйтерсең лә алар соңгы мәртәбә бәргәләнәләр, тартышалар. Димәк, аның бәгырен өзәрлек нидер булган. Нәрсә икән соң ул? Шуны ачыклау максаты белән Арсланов:

—Ни өчен бу адымыгызны нәкъ менә бүген ясыйсы иттегез?—дип сорады.

—Минем элегрәк тә гариза биргәнем бар иде. Шәвәлиевкә. Ул сезгә әйтмәдемени?

Арсланов аның соравын җавапсыз калдырды.

—Миңа кергәнче аның белән сөйләштегезме?

—Ул минем бюро исеменә язган гаризамны ертып атты. Ул сездән дә, бюродан да югары куя үзен.

Арсланов йөзен ике учы белән сыпырды, шифалы су эчте, уң кул бармакларын чирттерә-чирттерә өстәл өстендә шыкы-шыкы биетә башлады. Ирекка бик озак вакыт үткән шикелле тоелды. Беренче кинәт торып басты һәм кискен генә сорау бирде:

—Ирек Хәйриевич, сез аның эшен ничек бәяләр идегез? Коммунист буларак, берни яшермичә, үз фикерегезне әйтегез әле.

Ирек, йөзенә берни чыгармыйча, күкрәк тавышы белән генә көлгәндәй итте.

—Ул бер генә уй белән яши: сездән кисәтүле сүз, әрләү ишетмәскә. «Бу нәрсә чыннан да кирәк бит, без моны эшлик әле», дигән уй аның башына да кереп карамый. Ул райкомда, көне-төне эш эчендә кайный, дөрләп яна, жан ата... Ләкин, ышаныгыз, боларның берсе дә юк. Ул беренче чиратта сезнең күз алдыгызда уйный, аннары бүтәннәр каршында кылана. Жир шарының атказанган артисты ул.

Арсланов аны бүлдермичә тыңлады. Ул үзе күптән чамаласа-гөманласа да, шик-шөбһә томаны астында әйле-шәйле торган нәрсәләр, Ирекнең сүзләреннән соң, үтә дә аңлаешлы булып ачылып киттеләр. Шәвәлиевнең кушылганнан тыш энә очы кадәр дә артык эш эшләмәвен, үз өстенә җаваплылык алып, бер генә мәсьәләне дә хәл итмәгәнен, ана йомыш белән килгән кешеләрне әвеш-тәвеш китереп, майлап-җайлап чыгарганын Арсланов белеп бетергән иде инде. Беренченең башыннан кызыктыргыч бер уй йөгереп узды: «Әгәр Шәвәлиев урынына Сабитовны куйсаң?» Фикерле белә, инициативалы, тынгысыз, намуслы. Анысы шулаен

шулай, тик тора-бара Арслановның үзенә генә эш калмавы мөмкин. Ул инде Шәвәлиев кебек «моны болай итикме, тегеләй итикме?» дип сорап тормаячак. Хәер, икенче секретарьның ни өчен алай кыланганын да аңлый Арсланов. Имеш, ул беренчене Алла урынына күрә, һәммәсе дә ул дигәнчә генә булырга тиеш. Арсланов шушыны акылы белән аңлый, әмма Шәвәлиевнең шулай йөрүе аңа ниндидер рәхәтлек бирә, һәм ул үзендә әлеге уенны туктатырлык көч таба алмый. Яшермичә әйткәндә, икенче секретарь, әнә шул ин нечкә кылларына басып, аны биетә икән, кем беренче була соң? Арслановка башын ныграк иgән саен, Шәвәлиев анардан югарырак күтәрелә һәм теге яки бу мәсьәлә еш кына хәлләрдә нәкъ икенче теләгәнчә хәл ителә. Ахырда гажәпләнүдән Арсланов үзе дә тел шартлатып куя. Шайтан белсен, нәрсә бу! Мона бернинди философия китабыннан да җавап таба алмыйсың.

Сабитовны үзенә каршы бүлмәгә утыртуның тагын бер хәтәр ягы бар икән бит әле. Халык Арслановка керәсе урында аңа мөрәҗәгать итә башлаячак. Чөнки ул менә хәзер дә үзенең гөнаһсызлыгы, турылыгы, гаделлеге белән аларның бөтенесеннән дә өстен тора. Ул пычракка кермәячәк. Ә Шәвәлиев—Беренченең ау эте. Берәрсенә өстереп кенә җибәр—ул аның оясын туздыра, бугазын чәйни, эшеннән алырга дисәң—алырлык гөнаһларын таба. Ә Сабитов күпме генә «өс, өс!» дисәң дә, өсмәячәк. Шулай булгач, Арсланов аны, Шәвәлиевтән әллә ничә башка өстен санаса да, берничек тә икенче секретарь итә алмаячак. Шул ук вакытта менә дигән ун кеше инструктор урынына килергә тезелешеп торса да, Сабитовны үз кул астыннан ычкындырырга ярамый иде. Ни өчен дисәң, Арслановның муенында бит өлкә комитетының беренче секретаре элмәк итеп салган хәтәр бурыч—китап асылынып тора. Ул әле язылмаган, һәм моны Сабитовтан башка беркем дә эшли алмый. Ул хәзер һәрнәрсәгә барачак. Бөгелеп төшмәгән икән бит Сабитов. Күзләрендә яшендәй уйнап алучы нәфрәт, тартышып-тартышып куючы янак мускуллары, чабышта томырылган атныкы кебек хәтәр киерелгән борын яфраклары Арслановның баштагы уйларын юкка чыгарды. Ул инде райком белән араны өзгән, алдын-артын абайламыйча, алга ыргыла... Аның коточкыч көче дә хәзер шушы беркатлы турылыкта, бернине дә яшерә белмәвендә иде. Ничек кенә булса да, туктатырга кирәк иде аны. Куркулы карашы белән егетне капшый-капшый, Арсланов шушыларны уйлады. Баядан бирле борчыган соравын ул тагын кабатларга мәҗбүр булды:

—Шулай да әйтегез әле, ни өчен сез нәкъ менә бүген бирергә уйладыгыз гаризагызны?

—Мин кышкы сессиягә китәргә тиеш идем. Өлкә комитеты секретаре килә дип, Шәвәлиев җибәрмәде.

—Әйе, без отпусктагыларны да чакырдык. Ну что ж... Мин сезгә рөхсәт итәм. Икенче рейс белән китегез. Сез ризамы?

Ирек үз колакларына үзе ышанмады.

—Ничек кенә риза!

Арсланов телефоннан номер җыйды.

—Исәнме, Минһаҗев. Икенче рейска урыннар белән ничек анда синең? Ә безнең бронь? Әхмәтов иртәгә китәр. Мин кушты диегез. Аның урынына Сабитовны җибәрегез.

—Рәхмәт, Минзаһит Усманович.

Ирек, чыгарга ниятләп, урыныннан торды.

—Бер генә минут сабыр итегез әле. Мин сезнең теләгегезне истә тотармын. Быел райком работниклары өчен төзелә торган йортны бетерергә ниятлибез. Ике бүлмәле бер фатир сезгә булыр. Өйләнеп тә җибәрерсез. Иҗат өчен дә вакыт калдырырга тырышырбыз. Ә гаризагызны алып торыгыз, Ирек Хәйриевич. Эшләп карыйк әле. Аны бирергә беркайчан да соң түгел.—Арсланов, аның янына килеп, гаризаны кулына тоттырды.—Сезнең өчен тагын бер яңалык бар. Үзегез генә белеп торыгыз. Абыегызны «Биектау»га директор итәргә җыенабыз. Берсекөнгә җыелыш.

Шулчак кәгазьләр тоткан Шәвәлиев килеп керде.

—Зөфәр Шәрипович, Сабитовны укырга җибәрәбез,—диде Арсланов, аның алдында исәп-хисап тоткандай.

Шәвәлиев дәшмәде, чөнки тамак төбенә кайнар төер килеп утырды.

—Барыгыз, Ирек Хәйриевич. Зачет-имтиханнарыгызны уңышлы тапшырыгыз.

Ирек исерек кеше төсле чыгып китте. Шәвәлиев күз яше арасыннан сыгылып чыккан тавыш белән:

—Инструкторым каршында мине шундый хәлгә куйгач, рәхмәт инде, Минзаһит Усманович,—диде ул.—Аны авызлыклап торсаң да, таманга туры килә иде. Хәзер инде, тиле-тиле дигән саен, тигәнәк буе сикерер...

—Ярый алайса, эштән азат итәрбез. Кемегез бар соң аны алыштырырга?—диде Арсланов, юри генә.

—Ни өчен без аның кубызына биергә тиеш? Устав барыбыз өчен дә бер.

—Без сезнең кул астындагы теләсә кемне алыштыра алабыз. Бернинди проблемасыз. Шулаймы?

—Әйе.

—Ә Сабитовны?—Шәвәлиев дәшмәде.—Юк. Чөнки ул егет—талант. Ә талантлар белән сак кыланырга кирәк. Алар эшне генә түгел, илне дә ташлап китә торган халык. Шуңа күрә сезнең миңа үпкәләргә хакыгыз юк.

Беренчедән чыккач, Шәвәлиев секретарь кызга беркемне дә бүлмәсенә кертмәскә кушты. Кәнәфиенә әллә ничек алга таба бөкрәеп утырды да күзләрен йомды, керфекләре арасыннан яшь бөртеге сытылып чыкты... Беренче үзенә карата шушы кадәр гаделсез кыланыр дип, башына да китергәне юк иде аның. Инде бит Сабитов аның кулында, Арсланов каршы килсә, шыкырдап та карамаячак, элеккедән дә ныграк буйсынып, аяк астында бөтереләчәк иде. Хәзер ул Казанда ун көн буе лекцияләр тыңлап, театрлар карап рәхәт чиккәндә, биредә көне-төне үрсәләнеп чабарга, тиреннән чыга язып, өлкә комитеты секретарен каршылау һәм озату хәстәрен күрергә туры киләчәк. Асылда, барлык әзерлек мәшәкатьләре Шәвәлиев җилкәсенә төшә. Их, Арслановның үзен менә шушылай күз яшьләрен йотарлык хәлгә төшерергә! Дөрләтеп яндырырга иде! Мондый әзерлек вакытларында ул элегрәк, тиешле урыннарга яшереп, «миналар» куеп калдыргалады, алар, олы кунак килгәч, берәм-берәм шартлап, Беренченең йөрәген яраладылар. Әйтик, берсендә ул кунак белән бер түшәктә кунарга тиешле кызның үлсә дә бу эшкә бармый торганын әзерләде. Икенчесендә искергән иттән табын әзерләтте, өченчесендә кунакның эче башкалага җитәрлек булып шүредән атты... Түрә кайтып киткәч, Арсланов аңа эт кебек ташлана, үрле-кырлы сикерә, ачуыннан буыла. Тыштан Шәвәлиев үтә дә борчылган кыяфәт чыгарса да, әлеге миналарның шартлавына әллә кемнәрне гаепле итеп күрсәтеп, юри акланып маташса да, эченнән чын мәгънәсендә тантана итә, Беренче ныграк котырган саен, ләйсән яңгырына рәхәтләнеп торган мал сыман, туйганчы ләззәтләнә иде. Ләкин бу юлы андый нәрсәне эшләп булмый, чөнки килүче түрә өлкә комитеты секретаре, тикшерә торганы да идеология эше. Бер генә кимчелек килеп чыксын—Арслановка кадәр ул үзе яначак. Шушы чарасызлык аның йөрәген әрнетте, бөтен ихтыяр көчен паралич-лады.

Монда аның йөрәген сызлаткан тагын бер нечкә нәрсә бар иде. Шәвәлиев кемнеңдер үзенә буйсынмавын бик авырлык белән булса да гафу итәргә мөмкин. Әйтик, бүген Сабитов, аның тыюына карамастан, Казанга китеп барса, ул аны бәлкем кичерер дә иде. Әмма инде кемдер аны буйсындырырга, үзе боерганны Шәвәлиев теләгенә каршы килеп үтәргә куша икән—бусын ул берничек тә гафу итә алмый. Кушканны үтәү, кемнеңдер әйдәкләвенә буйсыну—балачактан ук аның өчен үлем белән бер иде. Шуңа күрә өйдә дә, мәктәптә дә, урамда да аның кушаматы

«Тискәре кәҗә» булды. Гомере буе беркемгә дә «ярар» димәгән Шәвәлиев, райкомга эшкә күчкәч, әлеге сүзне Арслановка көн саен, сәгать саен кабатларга тиеш булып чыкты. Төптән уйлап караганда, аның өчен бу әҗәл белән бер иде. Бүген исә беренче секретарь аны иң хурлыклы үлем белән үтерде...

Бүгенге күз яшьләре аңа балачактагы бер сәер хәлне исенә төшерде. Ул вакытта Зөфәргә ничә яшь булды икән? Үзен яңа гына белә башлаган чагы иде бугай. Барысы да—әти-әнисе, абыйлары, апалары, Зөфәр өстәл янында җыелып утыралар. Олы абыйсы нидер сөйли, бөтенесе шуннан егылып көләләр. Зөфәргә дә кызык, ул да шырык-шырык көлә. Шулай әйбәт кенә утырганда, ул кинәт елый башлый. Мона бөтенесе хәйран кала, ул үзе дә аптырашта, ә менә елавыннан туктый алмый, чөнки аларның көлүләренә ачуы килә. Мондый хәл өйләрендә генә түгел, бүтән урыннарда да күп мәртәбәләр кабатланды. Башлап көлсәләр, Зөфәр аларга иярмәскә, баш бирмәскә тырыша, кызыкка түзә алмыйча иярсә, үзенең шушы йомшаклыгын күтәрә алмыйча елый башлый иде. Үсә төшкәч, ул житдиләнде, тыелырга өйрәнде, юкка-барга авыз ерып яшәүчеләрне өнәмәде. Аның рәхәтләнеп, дөньясын онытып чын көлүе бик сирәк була, ләкин андый чакта ул кычкырып көлми, ә берүзе, эченнән генә көлеп ләззәтләнә. Дөрес, ул хәзер кеше белән бергә көлә, тик бу теш күрсәтү, бүтәннәрдән аерылып тормас өчен ясалган мускул хәрәкәте генә...

## 10

Зәнфирәгә төштән соң бик ашыгыч район үзәгенә барып кайтырга кирәк булды. Тукталышта машиналар көтеп торганда, партком секретаре Ганиев, пакет тотып, аның янына килде.

—Әллә район үзәгенәме?—диде ул, исәнлек-саулык сорашкач.

—Әйе, тиз генә урап кайтасым бар иде.

—Ай, әйбәт тә булды!—диде Ганиев куанып.—Шушы пакетны райкомга кертеп чыгарсың әле.

—И, Ганиев абый, өлгерә алмыйм, аптекадан дарулар да аласым, больница бухгалтериясенә дә сугыласым бар. Ремонтчыларны йөртүче вахта машинасына өлгермәсәм, мин бит төнгә калам!

Ганиев аның терсәгенә кагылып алды да пышылдауга күчте:

—Син кырт кисәргә ашыкма әле. Иреген, бүлмәсеннән дә чыкмыйча, шушы йөкләмәләрне көтеп утыра.

Ганиев күз кысты да конвертны Зәнфирәнең сумкасына төшереп җибәрде. Шундук машина килеп чыгып, ул утырып та китте. Кайчан кайтты икән Ирек? Чылтыратмады да. Ә бит бересе көнне аерылышканда, кайту белән очрашабыз дигән иде.

Ирек бүлмәсенең калын пыялалы ишеге каршысына килеп баскач, ул туктап калды. Бүлмәдә ут яна, кычкырып көлгән хатын-кыз тавышы ишетелә иде. Зәнфирә ике шәүләнең кара-каршы торуын шәйләде. Менә ул шәүләләр бергә кушылдылар, эчтә Ирек тавышы ишетелде, тагын хатын-кыз көлүе яңгырады, нәрсәдер шапылдады. Зәнфирә шакып-нитеп тормады, ишекне ачты да җибәрде. Ирек кемнедер почмакка кыскан, Зәнфирәгә кара калын дәфтәр тоткан бер кул гына күренә иде. Өстәл янында урындык авып ята. Ишек тавышына Ирек ялт итеп карады. Ул, күзләрен киереп ачкан хәлдә, тураеп туктап калды. Почмакта урындыкка утырган, кулына дәфтәр тотканы—Сөембикә иде. Ул ничектер каш астыннан Зәнфирәгә мыскыллап көлеп караган сыман тоелды. Аның иреннәренә җәелгән елмаюы: «Нәрсә, безне тоттыңмыни, канәгатьләнденме?»—ди кебек иде. Ул аягүрә басты да дәфтәрне Ирекнең өстәленә ыргытты:

—Мә, Ирек абый, көндәлегенне эш өстәлендә тотма,—диде дә Зәнфирә яныннан ишеккә таба атлады. Аннары борылып килеп:

—Ах, гафу итегез, исәнмесез һәм сау булыгыз!—диде.

Болар һәммәсе дә бер мизгел эчендә булдылар. Ирек, ни әйтергә белмичә, авызын ачты да катты.

—Сессиядән соң күрешербез дигән иден...

Ирек кинәт ана омтылды.

—Беләсенме, Зәнфирә, мин әле кичә кич кенә кайттым да...

—Менә сиңа пакет. Исән бул.

Зәнфирә кырт борылды да чыгып китте. Ирек аның артыннан ташланды.

—Туктале, бер генә минутка, аңлашыйк, сөйләшик!—дип ялварды.

Яланбаш, яланөс килеш ул аның артыннан урамга чыккач та шактый барды. Ләкин Зәнфирә аңа таба борылмады, сынар сүз дә дәшмәде. Чөнки борылса, Ирек аның яшь тулы күзләрен күрәчәк, эндәшим дип авыз ачса, ул кычкырып елап җибәрәчәк иде. Шуңа күрә ул, аскы иренен канатканчы тешләп, җил-җил больница ягына атлады. Әлеге пакетны биргән Ганиевне, үзенен ник шунда керүен каргады. Ирек артта калгач кына, буасы киткән елга кебек, күз яшьләре бәреп чыктылар. Кешеләргә елаганын күрсәтмәс өчен, ниндидер бер ихатага кереп китте, аның биек капкасы артына ышыкланып, тавыш-тынсыз гына туйганчы елады. Күпмедер вакыттан соң тынычланды һәм, ничек кенә сәер тоелмасын, ул Ирекка ачуланмады, ә бәлки үзен кызганды. Үзен кызгануга, тагын күз яшьләре бәреп чыкты. Ул инде, кулъяулыгы белән сөртә-сөртә, күзләрен генә түгел, битләрен дә кызартып бетергән иде. Кечкенә көзгесен чыгарып, үзенә күз төшерүгә, шаккатты. Мондый хәлдә больницага да, аптекага да кермәскә булды һәм авылга юл тотты. Гадәттәгечә, машина көтә торган чатта туктамады, юлга җәяүләп чыкты. Ул бик юка киенгән иде, каршыдан салкынча җил исә, шуңа да карамастан, Зәнфирә акылсыз бер үҗәтлек белән кызу-кызу авылга таба атлады. Инде ярты юлга җиткәндә, ул үзен куып җитүче машина тавышы ишетте. Зәнфирә артына борылып карамады, утыртсын иде димәде, һаман атлый бирде. Машина бозлавыкта уйнаклый-уйнаклый аның турында туктады. Бу «Нива» машинасы иде. Зәнфирә бер генә мизгелгә шикләнеп куйды, утырыргамы—юкмы дип икеләнеп торды, аннары ниндидер битарафлык белән ишекне ачты. Руль артында Ирекнен абыйсы Мэлс иде.

—Исәнмесез, Мэлс абый,—диде ул, кереп утыргач.

—Исәнме, Зәнфирә сенлем, нишләп җәяү кайтасың?

—Транспорт көтеп тормадым шул. Әллә машина алгансыз инде, Мэлс абый?

Мэлс кычкырып көлеп җибәрде:

—Каян тисен ди ул безгә! Совхозныкы бу.

—Ишеткән идек шул. Котлыйм сезне, Мэлс абый,—диде Зәнфирә.

—Нәрсәсен котлыйсың инде аның? Хуҗалык зур, тәмам таралып беткән, аны аякка бастыру өчен хәзер жененн өзелгәнче чабарга кирәк.—Мэлс, әй, моны нигә сөйләп торам соң әле дигәндәй, кул селтәп куйды.—Үзегезнең хәлләр ничек соң?

—Әйбәт...

—Тәзкирә апа сихәтләнәме?

—Шул бер килеш инде.

Мэлсның, әлбәттә, «Ирек белән араларыгыз ничегрәк соң?» дип сорыйсы килде, ләкин тыелып калды. Ә бәлки бу сорауны бирүнен урынлы түгеллеген сизенгәндер, чөнки ул беренче күз ташлау белән Зәнфирәнең кәефсез икәнен күрде һәм бу хакта сүз кузгатмады. Нәкъ шул турыда сүз кузгатыр дип көткән Зәнфирә аңа эндәшмичә калуы өчен рәхмәт укыды. Ирек турында уйлыйсы да, сөйләшәсе дә килми иде...

Мэлс аны капка төпләренә үк китереп төшерде.

Ике көннән соң Зәнфирәнең Ирекка карата булган мөнәсәбәтен үзгәрткән тагын бер вакыйгага булды. Розаны район үзәгендә очратып, Ирек аның артыннан: «Бүген кайтам, кич клубка чыгыгыз»,—дип әйтеп

җибәргән иде. Роза әле аларның арасына кара мәче кергәнне белми иде, Зәнфирә моны сиздерергә теләмәде. Ул күнеленең кайсыдыр почмагы белән Иреккә рәнҗесә дә, бу кичне бәйрәм көткән кебек көтте. Ирекне, бер караганда, Сөембикәләр, Гөлнаралар белән буталадыр дип шикләнсә дә, икенче караганда, әлеге шикләнүләрен кире кагарга тырыша, аны барыбер элеккечә, саф күңелле, кешелекле, вөҗданлы итеп күрәсе килә иде. Ничек кенә булмасын, ул аңардан башка яшәүне күз алдына китерә алмый, Ирек аңа әнисеннән кала җир йөзендә бердәндер якын кеше иде. Бу якынлык мәктәп елларында бер парта артында утырып укудан ук башланды. Зәнфирә әле барысы да элекке хәленә кайтыр, аларның бәхетле очрашулары, кабатланмас татлы кичләре дәвам итәр, дип өметләнде. Роза белән мәдәният йортына чыкканда, шушы тойгылары Иреккә булган ачу-үпкәләрен, рәнҗешләрен юып та бетерә язган иде. Алар башта китапханәдә утырдылар. Ул көнне танцы булмады, кино башлангач, анда кермичә, фойеда көттеләр. Кино да бетте, ләкин Ирек күренмәде. Алар клубтан чыкканда, Роза борчылып:

—И, малай, синең каршыда ялганчы булып калдым бит,—диде.—Берәр ашыгыч эше килеп чыккандыр. Бүген кайтмаса, иртәгә кайтыр әле.

Зәнфирә бер сүз дә әйтмәде, тамагына тыгылган күз яше сулышын буды.

Ирек икенче көнне иртүк медпунктка чылтыратты, ул гафу үтенде, райкомның икенче секретаре ашыгыч карар язарга кушты, төне буе шуны эшләп утырдым, диде. Зәнфирә аның сүзләрен калтыранып тыңлады.

—Алдама, Ирек, кирәкми, мин бит сиңа тагылмыйм,—диде ул, елый язып.

Телефон трубкасында Ирекнең өзгәләнгән тавышы ишетелде:

—Син мине белмисеңмени, Зәнфирә?!

—Белмәгәнмен, күрәсең, Ирек. Белмәгәнмен...

Ул шулай диде дә трубканы куйды.

Хәлимә аларның сөйләшүен тыңлап утыра иде. Зәнфирә сикереп торды, пальтосын эләктереп, урамга чыгып йөгермәкче булды, әмма соңарды. Җанының үртәлүенә түзә алмаган Хәлимә аны, куллары белән ике җилкәсенә басып, утыртты да каршысына иелде. Зәнфирә, һава җитмәгәндәй, еш-еш сулыш ала, елап җибәрмәс өчен аскы иренен тешләгән иде.

—Матурым, тынычлан...—Хәлимә иркәләп аның чәчләрен сыпырды.—Сөйлә, зинһар, ни булды соң сезгә?

—Бер әйбер дә булмады.—Үзенең бу сүзләреннән оялгандай, Зәнфирә башын читкә борды.—Аның күңелендә миңа урын калмады...

—Ышанмыйм, ялгышасыңдыр!

—Райкомга эшкә китәсен әйткәч тә, сизендем...—Ул дымланган күзләрен кул аркасы белән сыпырып алды.—Йөрәгемә шул чакта әллә ни булган иде... Бер атна авыртып йөрде... Мине кисәткән ул...

Аның газаплы кичерешләре Хәлимәнең бәгырен яшен уты шикелле көйдереп үтте. Алар бергә булсалар—ул да бергә, аерылсалар—ул да аерылачак иде.

Зәнфирә тынычлангач, ул: «Иртәдән бирле башым авырта, өйгә кайтып ятыйм әле»,—дип, чыгып китте. Ләкин өйләренә кайтмады, райкомга барырга карар кылды. Бер сәгать үттеме-юкмы, ул шунда иде инде. Ирекнең бүлмәсендә үзе генә чагы туры килде. Хәлимәне күргәч, ул гаҗәпләнеп калды, нидер сизенүдән йөзенә сагаю билгеләре чыкты.

—Әйдә уз, Хәлимә апа, утыр...

—Утырмыйм,—диде Хәлимә ана, сәер карап.

Бу караш та Ирек әллә кызгану, әллә ярату, әллә рәнҗеш күрде—нәрсә икәнен һич тә аера алмады. Хәлимәнең күзләре яшь белән тулды һәм ул Ирекнең өстәле янына ук килеп басты.

—Ирек...—аның тавышы күкрәгенең иң түреннән пышылдаудан

зәгыйфьрәк булып чыкты.—Ирек үскәнем... Нишлисең син?!.

Ирек бу сорауның ни өчен, кем турында, нинди максат белән бирелүен бик яхшы аңлады һәм моны ишетүе, моңа җавап бирүе чиксез кыен иде.

—Минем бит бер гаебем дә юк, Хәлимә апа...

—Белмим, мин берни дә белмим! Анардан сораганым юк, үзе ләммим берни дә сөйләми. Нишләп соң ул кипте-корыды, сүнде?! Ул бит минем якты кояшым иде. Ник син кайтмый башладың?

Хәлимә ярсып әнә шуларны тезде.

—Их, Хәлимә апа! Сез мондагы хәлне күз алдына да китерә алмыйсыз. Ипи тотып ант итә алам: минем юньле-башлы йокы да күргәнем юк...

—Ялгышмыйсыңмы соң син? Икегезне дә бәхетсез итсәң? Шул хакта уйлап караганың бармы?

—Ныклап торып уйлаган да юк бугай, Хәлимә апа. Мин бөтереп җибәргән бөтергеч шикелле бөтереләм дә бөтереләм. Бередә бер мин генә түгел, барыбыз да шулай...

Хәлимә аның сүзләренә ышанды. Зәнфирәгә ышанмаска да хакы юк иде аның. Ә дөреслек кайсында? Хәер, алар бер үк әйберне әйтәләр ләбаса. Ләкин Зәнфирәнең тел төбен икенчерәк мәгънәдә—Ирекнең күңелен башкалар биләгән, дип аңлаган иде.

«Әллә соң күңелен чибәррәкләргә төштеме?» дип сорыйсы килде аның, әмма кыюлыгы җитмәде. Җитәр дә иде, күңеле моны кире какты, ул аларны бер-берсеннән аерып карый алмый иде.

—Ирек... Күзләре яшьле аның... Зәнфирәне рәнҗетсәң, бәхет таба алмассың син... Үпкәләмә миңа...

—Нишләп үпкәлим...

Хәлимә, ишеккә баргач, туктап аңа борылды һәм кыюсыз адымнар белән аның янына килде.

—Мин бит сине яратам, Ирек... Үскәнем...

Йә, бер Аллам! Бу сүзләрне әйтүе ничек татлы һәм газаплы иде! Үзенең яратуын сөйгән кешесенә ул гомерендә тәүге мәртәбә кычкырып әйтте. Бу вакытта бит алмаларының ничек алсулануын, күзләренең ничек елтыравын, каш-керфекләренең дулкынланудан ничек тибрәнүләрен ул сизмәде, боларны Ирек кенә күрде. Әлеге ачыктан-ачык әйтелгән дөреслек, әлбәттә, бөтенләй икенче мәгънәдә яңгырый, Ireкка бүтән мәгънәдә барып җитә һәм тәэсир итә иде. Ләкин шушы яшерен хакыйкатьне кычкырып әйтә алуы белән, Ирекнең аны аңламавы, анардан көлә һәм йөз чөерә алмавы сәбәпле бәхетле иде Хәлимә!

Ул әйткәнне асыл мәгънәсендә аңлагандай, Ирек сүзсез генә башын аска иде.

—Әйе, яратам! Сине дә, аны да! Яратмасам, болай итеп йөрмәс тә идем...

Ирекнең башы һаман түбәнрәк иелде...

—Хуш, Ирек. Мин әйткәнне онытма!

Ирек аның чыгып киткәнен абайламый да калды. Башын күтәргәндә, бүлмәдә ул үзе генә иде.

## 11

Быел яз бик сәер килде. Мартның беренче көннәре җылытып җибәрде. Кар, кояшның кайнар нурлары астында, табада эрегән май кебек, күзгә күренеп йомшады, шикәрләнде. Урамнарда кар кештерди, чана юлларында, тар сукмакларда ул гөпердәп бата, ялтырап тора башлады. Сигезенче мартта Болынкырның асфальт урамнарында гөрләвекләр акты. Тау битләре, калку басулар каралып, уҗымнар яшелләнеп, кар астыннан чыктылар. Мартның беренче яртысында басулар ачылып бетә язды, аннары кинәт суытып җибәрде, юка гына кар яуды, биш-ун градус салкыннар

килде. Апрель башында кояш тагын мәрхәмәтен күрсәтте, өч-дүрт көн тышта костюм белән йөрерлек җылы булды, шаулап гөрләвекләр акты, су кинәт күтәрелеп, Ыкта боз кузгалды. Инде бераз җилләсә, тырмага чыгарлык була дип торганда, кабат суытты. Апрельнең соңгыункөнлегендә генә чын матур, җылы көннәр башланды. Җиргә ятып искән җылы җил туфракны көне-сәгате белән киптерде, хуҗалар дәррәү тырмага төштеләр.

Колхоз-совхоз җитәкчеләрен җыйгач, Миңзаһит Усманович дым каплауны өч көндә, иртә культуралар чәчүне бер атнада төгәлләү бурычын куйды. Шушы сөйләшүдән соң ике көн үтүгә, аның кәефен җибәргән бер вакыйга булды. Бюро члены Гайсә Батталов бер колхозчыны кыйнаган, дип хәбәр иттеләр район эчке эшләр бүлегеннән. Кыйналучыны ашыгыч ярдәм машинасы белән больницага китергәннәр, төне буе операция ясаганнар, хәле авыр ди. Иң элек Арсланов баш врачка чылтыратты, әлеге кешенең хәле турында сөйләвен үтенде. Чыннан да хәле авыр икән, өч кабыргасы сынган, бавыры ярылган, баш мие селкенгән.

—Зинһар, ничек кенә булса да, исән калдырыгыз,—диде Миңзаһит Усманович, баш врачка ялварып.—Әгәр ул кеше үлсә, сез монын район өчен нинди зур ЧП икәнен аңлыйсыздыр.

—Безнең уйлавыбызча, ул исән калырга тиеш,—диде баш врач.—Ләкин алдан барысын да күреп бетереп булмый, өзлегеп китәргә дә мөмкин. Яшь организм булса, бер хәл иде. Ул абзый алтмышны куып бара бит.

Баш врач белән сөйләшкәннән соң, Арсланов, бөтен эшен ташлап, «Авангард»ка юл тотты. Батталовка аның ачуы килмәде, ул аңа бары тик ярдәм итәргә, бу авыр хәлдән котылу юлын эзләшергә теләде. Чөнки аның өчен Гайсә Батталов председатель генә түгел, иң якын киңәшче дә иде. Болынкырга эшкә килер алдыннан булган әңгәмәдә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Арслановка:

—Мин сездән көнләшәм, Арсланов,—диде.—Чын татар районы, кешеләр бозылмаган, намуслы, эшчән халык. Аннары анда минем якын дустым Батталов эшли. Гомере буе председатель, чын крестьян, акыл иясе. Колхозы республикада гел беренче урында, син аңа таян. Ул барлык кадрларны яхшы белә. Батталов белән киңәшеп эшләсәң, барысы да нормаль булыр.

Аның сүзләрен тотты Миңзаһит Усманович. Тәүге очрашудан ук Батталов белән уртак тел тапты, алар якын дусларга әверелделәр. Атна саен булмаса, унбиш көн саен ул Батталовларга хатыны белән мунчага йөрде. Райондагы бердәнбер якын кешесе итеп, аның белән иң яшерен серләрен уртаклашты.

Өлкә комитетының беренче секретаре районга килсә, кунарга Батталовка барды. Колхозның нарат урманы эчендә югары кунаклар өчен мәһабәт йорты бар. Мунчасы—җәннәтнең үзе. Чабынып чыгасың да Ыкка сикерәсең. Арсланов өлкә комитеты секретаре белән берлектә шунда ике мәртәбә Батталовның сый-хөрмәтен күрде...

Гайсә Батталовның җиде класс белеменнән тыш, үзе әйткәнчә, ит белән бал биреп сатып алган техникум дипломы гына бар. Ләкин анардагы тормыш тәҗрибәсе теләсә нинди дәрәҗәдәге кеше белән тигез торып сөйләшергә мөмкинлек бирә иде. Аны шуның өчен Арсланов аеруча хөрмәт итте.

Ул председатель бүлмәсенә шакып-нитеп тормыйча гына барып керде. Исәнме, димәде, Батталовка кул гына бирде.

—Әйдә, утыр, Миңзаһит Усманович. Чәй йә кофе эчәбезме?

—Юк, берни дә кирәкми, зинһар өчен кеше генә кермәсен.

Батталов кабул итү бүлмәсендәге секретарен беркемне дә кертмәскә кисәтеп куйды.

—Сезнең ник килгәнегезне мин беләм инде,—диде Батталов, калтыранган бармаклары белән алдындагы мәрмәр кара савытын, кәгазьләрне читкә этkәләп.

—Сөйлә, ни булды?—диде Арсланов, аның йөзенең агарып китүенә игътибар итеп.

—Аңлыйсыздыр, Минзаһит Усманович, мин үземнең коба бозау өчен кул күтәрмәдем. Мин председатель булып эшли башлаганнан бирле, ул кешенең күрсәткәннәрен язып барсам, инде шуның кадәр том булыр иде,—ул кулын өстәл йөзлегеннән ярты метр чамасы күтәреп күрсәтте.— Әгәр җир йөзендә ике тискәре, явыз кеше булса, аның берсе, һичшиксез, шушы Шакир булыр. Соңгы вакытта бер атна баш күтәрмичә эчте. Үгезләр ачка көне-төне үкерәләр, әле зоотехник, әле ферма мөдире, әле үзем шуларны ашатабыз. Чакыртып та, өенә барып та, әйбәтләп тә, ачуланып та сөйләшеп карадым. Ярар, дип кала, эшендә юк, исерек. Кичә якасыннан сөйрәп машинага утырттым да фермага алып бардым. Әгәр кайтып китәсе булсаң, малларның атна буе кимегән авырлыгын үз өстеннән түләтәм, судка бирәм, дидем. Кич җаным түзмәде, рульгә үзем утырып, фермага киттем. Бу эшли торган торакка барып кердем. Тып-тын. Эндәшәм, җавап бирүче юк. Түргә таба киттем. Анда лампочка сүнгән, шактый караңгы иде. Шулчак, сәнәк япьләрен миңа төбәп, каршыма Шакир килеп чыкмасынмы! «Эчәгеңне актарам, кабәхәт!»—ди. Инде чәнчедем дигәндә, тайпылып калдым. Ул миңа кабат укталганда, сәнәгең эләктереп алдым, тарткалаша башладык. Башы белән бер мәртәбә ияккә бәреп алды. Тезенә китереп типкән идем, сәнәге кулыннан ычкынды. Шунда, үз-үземне белештермичә, мин аны типкәләп ташладым.—Батталов туктап калды.—Әле дә ярый Ходай саклады, ничек сәнәк белән кадамадым. Ул сикереп торып миңа кизәнә башлады. Шунда ишектән килеп кергән бер терлекче белән ферма мөдире безне аралады.

Алар шактый вакыт, икесе дә карашларын аска төбәгән хәлдә, авыр сулап сүзсез утырдылар.

—Шулай да тыелып калырга кирәк иде сиңа, Гайсә Батталович.

Батталов сикереп торды. Кулын аркасына куеп, бүлмә буйлап йөрергә керешге.

—Әйтүе ансат ул, Минзаһит Усманович. Ничә ел халык белән эшләп, нервы ничек түзсен. Ул бит бер генә көн түгел, һәркөн шушындый хәл.

—Мәсьәлә бик житди, Гайсә Батталович. Ифрат җитди.

—Үзем дә аңлыйм. Ну, терсәкне тешләп булмый...

—Ичмасам якыннары тавыш-тын чыгармасыннар иде, хәзер шул турыда уйларга кирәк.

—Аларны күрдем инде мин...

—Соң?

—Хатыны бер сүз дә дәшми, кызлары ни әйтсәң дә риза, ә олы малае Чаллыда эшли.

—Сиңа аның янына Чаллыга барып кайтырга кирәк,—диде Арсланов.

—Бүген анда партком секретаре җитәкчелегендә дүрт кешелек делегация китте инде, аракысын, башкасын алып.—Монда бит әле аның, болай да талкынган җанны талкып, милициясе килеп җиткән.

Арсланов телефоннан үзенең кабул итү бүлмәсен җыйды.

—Кырык минуттан милиция начальнигы белән прокурорны миңа чакырыгыз,—диде дә ишеккә юнәлде, әйберсен онытkандай туктап, үпкәсен белдерде:—Ну, таптың да соң вакытын!

Батталов аны озата чыкмакчы булды, ләкин Арсланов, ишеккә яны белән баскан килеш, кулларын өскә күтәрде.

—Кирәкми, күрмәүләре әйбәтрәк булыр.

Беренче секретарьның килүе аны тынычландырмады, хәтта борчыйрак та төште бугай. Ул фермаларга сугылды, мастерскойда булды, тагын идарәгә кайтты, әмма җанына урын тапмады. Төш турында хатынына «ашарга кайта алмыйм», дип, телефоннан хәбәр итте дә, Ык борылмасына юл тотты. Елганың комаяклы ин аулак әлеге урынын үлеп ярата иде Гайсә. Бу яклап ямь-яшел болын сөзәкләп кенә елгага кереп китә, кереп киткән җире тип-тигез комлы, чуерташлы. Ә каршыда теп-текә кара яр,

анын өстендә, биек яшел стена булып, наратлык күтәрелә. Борылмага чакрым ярымнар калганда, комырыкта нindидер ят нәрсә чамаланды. Бераз якынайгач, Гайсә аның бик юан бер каен икәнлеген күрде. Бу кыска буйлы, бөкре агач, чатлы-чотлы ботаклары сынып, урыны-урыны белән кабыклары сыдырылып, кызганыч хәлгә төшкән иде. Фаҗигага боз киткәндә тарыган ул, ахрысы. Каен яр читенә эләгеп үскән булырга тиеш. Чөнки тамырлары әллә кайчан кибеп, каралып беткән. Аны аудармыйча тоткан һәм җирдән яшәү сүле суырган ике тере тамыр әле күптән түгел генә шартлап сынган. Терсәкләнеп үскән ботакларына су агымы белән төрле чүп-чар җыелган. Шушы кызганыч хәлдә дә яфрак ярып ята үзе бичаракаем... Гайсә каенның ботаксызрак җиренә барып утырды. Шушы ике тамырда яшәү өчен ничә ел тартышты икән инде бу агач? Ул каенның кәүсәсен сыпырып карады. Картайган, яргаланган кайрысының бүртмәчләнеп каткан кара урыннары уч төбен һәм бармак битләрен, очлы калайга тигәндәй, чәнчештерде, авырттырып сыдырды...

Каршы яктан салкынча җил исә, болганчык су өстен шадралатып дулкыннар йөгерешә, алар күбекләнеп аяк очына кадәр килеп җитә язалар да хәлсезләнеп комга сеңәләр. Гайсәнең чал чәчләрен җил төрле якка йолыккалады, туйганчы туздырды. Тик ул моңа игътибар итмәде, кара костюм-чалбардан гранит сын төсле хәрәкәтсез утыра бирде. Су өстендә акчарлаклар, керәшәләр уйныйлар, атылып төшеп балык эләктерәләр, аратирә гасабиланып чыйкылдаганнары ишетелеп ала. Көчәйгәннән-көчәя баручы җил каршыдагы наратлык артыннан болытларны кузгатып чыгара һәм болайга таба куалый, болытлар белән бергә күләгәләре йөгерә. Менә бер кара болытның күләгәсе, наратлыкка ышкылып, акрын гына елга өстенә килеп керде. «Минем өскә килерме, юкмы?» дип уйлап куйды Гайсә.– Әгәр килсә, барысы да бетәчәк.» Күләгә читләтте. Ул аны, янәшәсеннән ерткыч җанвар үткәргәндәй, курка-курка күзе белән озатып калды. Нәкъ шул чакта колак төбеннән генә фырылдап пар керәшә очып узды, ул хәтта сискәнеп үк куйды.

Арслановның «Ну, таптың да соң вакытын!» дигән сүзләре күнелен кабат кузгатты, кузгатырлык та шул. Юри уйлап чыгарсың да, болай була алмас. Ул ике кулы белән башын учлап, терсәкләре белән тезенә таянды. Аңлый торган түгел бу дөньяны. Әгәр аның барышы гаделлек кануннарына буйсынса, Гайсә бүгенге хәлгә һич тә төшәргә тиеш түгел иде югыйсә. Ник дисән, гомер буе үзе өчен тырышуның ни икәнен дә белмәде ул. Курск сугышында аяклары чәрдәкләнеп, ярты елга якын госпитальдә аунагач, авылына кайтып төште. Күпме генә эшләгәндер, колхоз өчен җан атуын күреп, башта бригадир, аннары председатель иттеләр. Көне-төне титаклап чапты Гайсә, беркемгә дә тынгы бирмәде. Артында аңа «Аксак шайтан» дигән кушамат тагылды, мулла кушкан исемен үз алдында гына әйтәләр иде. Инде хуҗалыкны аякка бастырдым, тынычлабрак эшләрмен, дигән уй туа гына башлаганда, райком аңа урман эчендәге ике урыс авылын берләштерүче «Кызыл юл»ны житәкләүне тапшырды. Ни чәчүен чәчә алмаучы, ни урагын ура алмаучы бер өтәләү хуҗалык иде бу. Гомер-бакый көмешкә эчеп, исерешеп яткан урыслар, бер ел сугышып, Батталовны җинә алмагач, «Безгә кабат татар-монгол игосы килде», дип күнделәр, сөзелеп эшләргә керештеләр. Биредә аңа «Батый» кушаматы ябышты. Инде «Кызыл юл» алдынгы урыннарны дәгъвалый башлаганда, Гайсәне өченче урынга күчерделәр. «Батый»ның тимер кулыннан ычкынуга, урыслар таудан түбән тәгәрәтелгән коргаксу мичкә шикелле, таралдылар да беттеләр. Хәтта ике авылның берсе бөтенләй юкка чыкты. Ниһаять, язмыш «Авангард»ка китереп туктатты. Өч хәерче колхозны берләштереп ясалган, җиде авылны үз эченә алган, сигез мең гектардан артык сөрүлек җире булган бу хуҗалыкны адәм рәтенә кертү өчен Гайсә үз гомеренең күкрәп торган елларын бирде. Салам түбәләр дәвере иде әле ул чаклар. Гайсә вагонлап шифер ташырга тотынды. Аны илнең кайсы почмакларыннан ничекләр итеп табуын, нинди алдау-йолдаулар белән алуын һәм кайтартуын ул үзе белә дә, бер Ходай

гына белә. Анын колхозына керүче авылларда барлык салам түбәләр, районда беренче булып, шиферга алыштырылды. Гайсә халыктан төзелеш материалын, машинасын-тракторын тотмады. Яшьләр өчен йортлар салды, әмма каралтыкура тергезүне юри үзләренә калдырды. Председательнең күзенә карап, буйсынып эшләсеннәр, төзелеш һәм тормыш алып баруның кыенлыгын анласыннар өчен шулай итте. Гайсә колхоздагы эш нормаларын экономистлар белән җентекләп күздән кичерде, кайсын кисте, кайсына өстәде, шәләйвәләй йөреп акча алуларның тамырына балта чапты. Мона күпләр атылып бәрелде, утлы күмергә баскандай бәргәләнде. Ләкин Гайсә нык торып, дәлилләп күрсәтте, үзенең хаклы икәнлеген исбатлады. Мәскәүгә кадәр жалоба яздылар, тикшерделәр, ул хаклы булып чыкты. Гайсә эшләгән кешене күтәрде, әрәмтамакларга, ялкауларга көн күрсәтмәде, адәм мәсхәрәсе итеп сүкте. Авылда хулиганлык, урлашу кебек хәлләр булса, анын рөхсәтеннән башка милициягә хәбәр итү юк. Ә анын хөкеме бик гади: әгәр эш сөючән икән—аклана, әгәр эчкече, хөрәсән ялкавы икән—милициягә. Иген басуыннан терлекләре тотылучылар белән дә шул ук хәл: эшчәннәрнең малы болай гына бирелә, ә тегеләренә закон нигезендә акт төзелеп, штраф салына.

Ә шулай да үзгәрә кешеләр, яхшылыкның кадерен белмиләр. Гайсә торгызган йортларда яшәп ятучылар да артык ватылмыйча, тыныч кына көн күрергә, ә акчаны көрәп алырга ниятлиләр. Бу хәлгә анын эче дөрләпләр яна! Ул йортларның һәркайсы Гайсәнең җанына уеп салынган, һәрберсе йөрәгеннән һаман да кан саркытып, ачытып тора. Чөнки аларны төзегәндә, ниләр генә кыланырга туры килмәде. Әгәр төптән уйлап карасаң, Гайсә Батталовның үз йортлары ул! Шәхси йортыннан да кадерлерәк. Сине өйлеҗирле иткән колхозына хәләл көченне кызгангач, син кем? Шуны йөзләренә бәреп әйткәч, «битәрләргә булгач, салдырмаска иден», дип авызынны томаларга чамалаучылары табыла. Алай гына булса бер хәл иде. Телгә баткан, серкәсе су күтәрми торган андый яшьләр авылдан качып ук китәләр. Менә сиңа океан артыннан кыздырып-куырып кертелгән кеше хокуклары. Ә элек Гайсә рөхсәтеннән башка кош та очып чыга алмый иде колхоздан. Кәҗә койрыгын күтәрә дип, сарык та күтәргән кебек булды да куйды. Качып та пычагым да кыра алмыйлар. «Авангард»тан күпкә начаррак бер ярдәмче хуҗалыкка яисә бүтән җиргә барып урнашалар, эт яшәмәслек шартларда җан асрыйлар, әллә нигә бер авылларына кайтсалар, халыкны котыртып китәләр. Имеш тә, анда хөррият, имеш, ни эшләсәң дә ирек, имеш, бөтенесе ал да гөл.

Качучыларның өчесен Хәйри үзенә тартты. Икесенә тешен кысып түзгән иде Гайсә. Әмма өченче гаилә ана барып урнашкач, ачуыннан шартларга житеп, «үрнәк»кә чылтыратты.

—Хәйри абзый, ник син минем колхозчыларны, тәтәй белән алдап, үзенә аласын?—диде ул, хәл-әхвәл дә сорашып тормастан.

Хәйри акланып-нитеп маташмады, сөйләшүгә бер генә җөмлә белән нокта куйды:

—Ник җибәрәсен соң син аларны?

Гайсә аны элек тә өнәми иде, шуннан сон аралары бөтенләй өзелде. «Исәнме—исән»нән бүтән берни сөйләшмәс, кинәш-табыш итешмәс булдылар...

Җәннәт эзләп, авылдан китүче яшьләр саны арта бара. Пенсионерлар белән генә ерак барып булмый. Житмәсә, элек төзегән ферма тораклары, мастерскойлар да искерделәр, үсмер балага теккән кием курачланган кебек, замана таләпләрен күтәрә алмый башладылар. Алар урынына яңасын салырга Гайсәгә инде соң, ә мона жин сызганып торучы яшьләр юк. Тагын шунысы аңлашылмый, колхоз-совхозларга соңгы елларда куелган житәкчеләр Гайсәләр буыны шикелле чапмыйлар, рәхәтләнеп ялын да итәләр, кинәшмәгә-мазар жыелганда, авызлары ерык, телләрендә уен-көлке, үзара үртәшү һәм эшләре дә гөрләп бара! Нишләп алай икән сон ул?

Гайсә, уйларыннан айныр-айнымас, каенны тагын бер мәртәбә җентекләп карады. Бирелдәге матурлыкны бозып, ямьсезләп тора икән ләбаса

бу. Сөйрәтеп ташларга кирәк булыр. Ә кая? Кеше үлсә, күмәләр. Моны күмеп тә булмый. Яшелләнергә маташып ята бит әле ул, яфракларының тиздән корып, коелып бетәсен белми. Турап алып кайтырга кушар иден—берәү дә якын килмәячәк: шыр ботак, ботаклары кәкре-бөкре, ярып утын ясамалы түгел. Юк, хәзергә торсын әле бу бичара...

Карале нинди зур кара болыт! Күләгәсе туп-туры бирегә якынлаша. Гайсә, сикереп торып, машинасына ташланды, битенә, баягы уйлары өчен ачулангандай, каен ботагы зәһәр сыдырып калды. Машинасын «ә» дигәнче кабызды, «Волга» үрле-кырлы сикерә-сикерә, яр буйлап читкә элдерде. Гайсә, каен сыдырган яңагыннан костюмына кан тамгач кына, машинасын туктатты. Күләгәнең бу юлы да аңа кагылмыйча узып киткәнлеген күргәч, уфылдап тирән сулыш алды...

## 12

Бәхетләре бар икән, кыйналган кеше терелеп аягына басты. Инде бәла үтте, дип шатланганда, өлкә комитетыннан чылтыраттылар. Колхоздан бик зур шикаять язганнар, тикшермәсәгез, Үзәк Комитетка кадәр мөрәҗәгать итәчәкбез, дигәннәр. «Зинһар үзебезгә җибәрегез, барысы да нормаль булыр», дип үтенде Арсланов. Хәзер Батталовның персональ эшен башлангыч партоешмада карарга кирәк. Моны тикшерүне кемгә кушарга икәнен Арсланов шактый озак хәл итә алмады. Ахырда, Шәвәлиевтән дә яхшысы булмас, дигән нәтиҗәгә килде. Мондый катлаулы хәлләрдә ул ни дәрәҗәдә оста эш итүен бер генә мәртәбә расламаган иде. Алар сөзешкәләшеп торалар торуын. Менә хәзер дуслашсыннар. Бүтән чаралары юк.

Зөфәр Шәрипович беренчегә «Ярар, оештырырбыз» дип чыкса да, күңелендә мең төрле уй бөтерелде. Шәвәлиев райкомга килгәннән бирле, Батталов, аны санга сукмады. Хәтта шуңа барып житте ки, бервакыт урак өстендә иртән, Шәвәлиев партком бүлмәсенә колхозның идеология активын җыйгач, Батталов ишекне тибеп килеп керде.

—Бусы тагын нәрсә?!—дип җикерде ул партком секретарена.—Урак бармый, ипи тапшырырга кирәк, ындыр табагында эшләргә кеше юк, ә сез монда аулак өй оештырып ятасыз. Хәзер үк ындыр табагына!

Шул чакта Шәвәлиев кыерсытылган малай хәлендә калды. Аңа бүлмәдәгеләр алдында оят иде. Ул бер сүз әйтмичә чыгып китте дә, машинасына утырып, район үзәгенә элдерде. Батталов үзенә чылтыратыр, кызып киткәнмен дип гафу үтенер, дип көтте ул. Ләкин андый нәрсә булмады. Ул бит, яхшымы-яманмы, икенче секретарь, әлегә районда беркемнең дә аны мондый хурлыклы хәлгә төшергәне юк иде. Берничә көннән Арсланов янына бюро членнары җыелгач, ул торып әлеге хәл турында сөйләде. Батталов, керфеген дә селкетмичә, күзләрен кыса төшеп, аңа туп-туры карап торды.

—Сез нәрсә,—диде ул, Шәвәлиевне сүзен бетерер-бетермәстән бүлдереп.—Кинәшми-нитми безнең кешеләрне җыеп накачка ясап ятасыз? Ындыр табагында ашлык яна, дәүләткә икмәк төяргә кеше юк.

—Мин аларны унбиш минутка җыйдым.

—Сез аларны биш минутка да җыярга тиеш түгел идегез, беләсегез килсә!

Шәвәлиев утырырга мәҗбүр булды. Чөнки ул беренче секретарьның үзен якларга җыенмаганын инде аңлаган иде. Һәм чыннан да Арсланов:

—Әйдәгез, вакланмыйк,—дигән сүз белән аларның бәрелешен туктатты.

Моннан соң да «Авангард» председателе Зөфәр Шәриповичның күп мәртәбәләр канына тоз салды. Ничек, каян, кемнән җыядыр, анарда районның бөтен информациясе бар һәм ул аларның бөтенесен җайлап кына беренче секретарьга житкереп тора иде. Узган ел Арслановның икәү генә сөйләшеп утырган чакта әйткән бер кисәтүен Шәвәлиев мәңге онытмас.

—Сезне «Ярыш» урманнарына җиләккә йөрергә яратасыз, диләр. Хакмы?—диде ул, ярым елмаеп.

Зөфәр Шәрипович эсселе-суыклы булып китте. Шулай да үзен кулга алды, көлгән кебек итте дә:

—Кем әйтә аны, Минзаһит Усманович? Җиләккә йөрү түгел, әтиләр янына кайтып килергә дә вакыт юк әле,—диде.

—Җиләге бар икән, җыярга кирәк, тик халык теленә чыгарлык булмасын,—диде ул, ничектер мәгънәле итеп.

Шәвәлиев шул көнне үк, төнлә кайтып, Кәбировны күрде һәм Беренченең сүзләрен кабатлады. Кәбиров исә, моны көткәндәй:

—Гайсә эше бу,—диде.

—Каян беләсең?

—Аның һәр авылда үз кешесе бар. Лесник күреп калган иде, шул житкергәндер.

—Нинди лесник?

—Лесник Талыйп. Шуның янынннан китми ул.

Алар моннан соң бик сак булырга сүз куештылар. Батталов үзе очрашкан чакларда берни сиздерми, шулкадәр ихлас сөйләшкән булып кылана, хуҗалыгына барсаң, аш-су әзерләтә, көчләп диярлек кунак йортына алып керә. Чәен-мәен куйдыра, мәгәр беркайчан да аның белән утырмый, кырык сәбәп табып, чыгып китә иде. Шәвәлиев, аның хәйләсен бик яхшы белгәнгә күрә, беркайчан да эчемлекләрне ачтырмады, капкаласа ризыгын капкалады, капкаламаса, бер стакан чәй белән чикләнде. Чөнки ул, әгәр шунда бер генә мәртәбә аракы йотса да, киләчәктә моның Батталов авызыннан Арслановка шыр исереп кайтып киткән рәвешендә житкереләсен белә иде. Аннан соң акланып кара син. Кыскасы, тыштан сөйләшкәндә, Шәвәлиев тә Батталовка бик хөрмәт белән караган кебек үтә итагатьле сөйләшсә дә, эченнән бу кешене жен урынына күрә иде.

Ә инде бу персональ эшкә килгәндә, Батталовның кешеләргә кул күтәрүе күптән килә, ул турыда хәбәрләр райкомга да ишетелә. Әмма аны судка бирүче дә юк, милиция дә белми, халык телендә йөри дә шуның белән онытыла. Бусы инде алай калмаска, Батталов, ниһаять, тиешле җәзасын алырга тиеш! Зөфәр Шәрипович ин әүвәле теге кешенең үлүен теләде. Ул чакта Батталовка котылмак юк, Арслановның да түбәсенә ару гына күсәк төшәчәк иде. Әллә инде врачлар артык тырышты, әллә теге әлкәшнең гомере бетмәгән—аның теләге кабул булмады. Вакыйганы элекке эзенә кабат илтеп кертү өчен бер генә юл калды—шикаять язу. Колхозчылар исеменнән, алар теле белән ул шикаятьне Зөфәр Шәрипович үзе язды. Казанга баргач, бер танышыннан күчереп яздырды да почта тартмасына салды. Үч иткәндәй, ул көткәннең киресе чыкты. Беренчедән, өлкә комитетыннан тикшерергә килмәделәр, икенчедән, Арсланов бу персональ эшне, Батталов белән Зөфәр Шәриповичның арасы киеренке икәнлеген белгән килеш, аңа тапшырды да куйды. Шулай итеп, ул үзе корган капкынга шапылдап үзе эләкте. Арсланов «Авангард»ка бүген үк китәргә кушса да, Зөфәр Шәрипович ашыкмады, бу кыен хәлдән котылу юлын эзләде. Батталовны барыбер коткарырлар, әмма ул түгел, бу аның өчен үзен-үзе пычракка салып таптау белән бер иде. Күп уйлый торгач, бердәнбер котылу юлын тапты. Секретарь кызга авырып торам диде дә, үзенең якын дусты, шифаханәнең инфекция бүлеге мөдире Әсәдуллинга барып керде, кыскача гына хәлне аңлатты:

—Нишләтсәң дә, мине тизрәк больницага сал,—диде.

Төштән соң Зөфәр Шәриповичны больницаның йогышлы авырулар бүлегенә салдылар. Әсәдуллин, Беренчегә чылтыратып Шәвәлиевнең бик житди авырып китүе турында әйтте. Рамнарының ак буяулары һәм замазкалары купшаклап коелган бердәнбер тәрәзәгә, почмакта полиэтилен чаршау белән аерып куелган унитазга, сабын исе килеп торган саргылт җәймәтышлыкларга Зөфәр Шәрипович шикләнеп карап торды. Бу урыннарга ятып, койма рәшәткәсе төсле киң сырлы буй-буй бу күлмәк-ыштаннарны, сүсәреп беткән үкчәсез бу чүәкләрне кигән килеш кемнәр генә теге дөньяга ычкынмагандыр! Берничә авылда сары авыруы чыгып, күрше палаталар

шулар белән тулган. Әлеге чирне таратучы A һәм B вирусларының әнә теге биек түшәмдә йөрүче чебеннәрдә дә, дару тотып кергән медсестраларда да, җыештыручыларда да, һавада да булуы ихтимал иде. Шуңа күрә Зөфәр Шәрипович больница исе бәреп торучы бу авыр һаваны бары тик борыны белән, бик кысып-тыелып кына суларга тырышты. Ул, үзе алып кергән спирты белән мамыкны чылатып, авыз-борынын, кулларын сөртте, ишек тоткасын, тумбочка өстен чистартты да, вируслардан качарга теләгәндәй, палатадагы бернигә дә орынмыйча, почмактан-почмакка йөрергә кереште. Кая барсаң да тупыйк, ары китәр юл юк иде...

... Зөфәр медик һөнәрен сайлап ялгышканлыгын институтның өченче курсында ук аңлады. Нишләргә? Кара уйга калдырды аны бу сорау. Ахырда бер ныклы фикергә килде: җәмәгать эшләренә тартылырга, партиягә керергә, диплом алгач, министрлык тирәсенәме баш төртергә. Кызганычка каршы, соңгысы барып чыкмады. Болынкырга килеп эшли башлагач, аның чәчләре үрә торды. Бөтен районына өч хирург, врачлар житми, үзләре гинеколог та, уролог та. Көн-төн кан-үлек, кеше тизәге эчендә актарын, ял да, бәйрәм дә күрмә, шуңа иң кадерле нәрсәңне—гомереңне корбан ит. Син кеше түгел, тән кисүче, тән тегүче машина. Болай яшәп, котылгысыз рәвештә гүргә якынаю ни хаҗәтемә? Ә ничек котылырга? Баш врач булу өчен үзеңне кимендә ун-унбиш ел күрсәтергә кирәк. Аңынчы инде син тәгаен үзең дә гарипләнерсең. Әле беркая шыкырдамыйча өч елынны мәҗбүри эшләү дигән нәрсә дә бар. Димәк, бер юл кала: ничек булса да гомуми житәкчелек эшенә күчү. Шуңа күрә ул Болынкырга килү белән партия җыелышымы, район күләмендәге семинармы, башкасымы—чәчрәп чыгып, ялкынлы нотыклар сөйләүне алдырды. Гомуми эш өчен, халык мәнфәгатьләре өчен ничек яна, ничек үз-үзен аямый дип, кешеләр аңа сокланып туймадылар, житәкчелек тә игътибар итте. Асылда Зөфәр тамчы да борчылмады, ә уйнады гына. Балачактан ук бөтен йөзенә, тавышына мең төрле төсмер чыгара белде, укытучы анардан дәресен сораганда, өй эшен әзерләмәгән булса, яисә ничектер тәртип бозса, кызганыч итеп елаган кыяфәт чыгару һәм нидер уйлап табып аклану, укытучыларны да, классташларын да шуңа ышандыру аңа берни дә тормый иде. Үтә кыен хәлләргә тарыган чакларда, өйдә дә шул юл белән судан коры чыкты. Ә инде күзләрен уйнатып, кулларын селти-селти, тантаналы тавыш белән үзенең итәгенә төшмәгән утлы күмерләрне туздырудан, әллә никадәр кешене үзенең авызына каратып торудан ул бары тик ләззәт кенә алды. Шуның өстенә ул тумыштан ук яңа фикерләр, яңа идеяләр ыргыту остасы иде. Зөфәр Шәрипович кочагы белән газета-журнал алды, анда язылганнарга ияреп, халыкның күптән ачуын китергән күренешләрне шактый кыю тәнкыйтьләде, шуларны төзәтү буенча күптөрле тәкъдимнәр әйтте, саллы дәлилләр китерде. Кармагына никадәр терерәк суалчан сапласаң, балык шулкадәр шәбрәк капкан кебек, аның ул фикерләре шуңа сусаган күңелләрне магниттай үзенә тартты, ул хирург пычагы белән түгел, ә бәлки оста лектор һәм пропагандист буларак, районда бик тиз шөһрәт казанды. Арсланов Татарстан Верховный Советына депутатлыкка сайлау кампаниясендә аны үзенең ышанычлысы итеп алды. Менә шунда ул үзенең апогеена күтәрелде. Аңа нинди тел ачкычлары кайлардан килеп төшкәндер, сайлаучылар белән очрашу җыелышларында ул халыкны бердәм массага әверелдерде, бөтенесен Арсланов өчен җанын бирерлек хәлгә китереп, аның ягына аударды. Беренче үзе дә тәмам исерде, аны кочаклап үбәрдәй хәлгә житте. Элеккеге икенче секретарьның формаль булмаган лидерга әверелә баруына эче пошкан Арсланов аны КПСС Үзәк Комитеты каршындагы иҗтимагый фәннәр академиясенә укырга җибәрде дә, Зөфәр Шәриповичны аның урынына утыртты. Зөфәрнең больницадан котылуына, хыялының тормышка ашуына куанудан башы күккә тигән иде. Әмма бу эш тегесеннән дә хәтәррәк булып чыкты. Беренче көннән үк Арсланов аның өстенә тау кадәр эш өйде. Аларны үтим дип күпме тырышсаң да, очына чыгышлы түгел икәнлегенә төшенгәч, Зөфәр Шәрипович бөтенесен башкаларга йөкләргә тотынды. Менә шунда кешеләрнең күндәмлегенә ул

хәйран калды. Райком сүзен ишетүгә, алар теләсә нинди боерыкны хәрбиләрдәй сүзсез үтәргә күндерелгән булып чыктылар. Шәвәлиев бу механизмның төзелешен бик тиз аңлап алды, туктаусыз янадан-яна эшләр уйлап чыгарды, һәрберсен зур амбар кенәгәсенә көне-сәгате белән теркәде, кемгә кушылганын, кайчан үтәлергә тиешлеген аерып куйды, карышучылары табылса—өркетте һәм, таудай кырмыска оясын туздырып, андагы меннәрчә бөҗәкнең мыжгуын күзәткәндәй ләззәтләнде. Алар барысы да аның тарафыннан жигелгән, аңа буйсынган, аның кодрәтендә иде.

Бүген биредә вакыт чикләнмәгән, барысы турында да уйланырга була, әмма йогышлы сары авыруы вируслары гына аңа тынгылык бирми иде. Ул больницаның бер грамм ризыгын капмады, унитазга аткарып барды, Әсәдуллин яшерен алып килгән ризыкны ашады, савыт-кашыкларын, су белән юганнан соң, спирт белән эшкәртте, авыз-борынына саклангыч марля бәйләде. Кешеләрнең үлеменә битараф булса да, үзенең әҗәлдән коты чыга иде Зөфәр Шәриповичның...

Арсланов әлеге эшне райкомның оештыру бүлеге мөдире Кәрәм Нәҗмиевкә тапшырды. Моның уңай ягы шунда, колхоз үзәге Нәҗмиевнең туган авылы иде. Ул кешеләрне биш бармагы кебек белә, теләсә кем белән уртак тел таба һәм эшне, һичшиксез, тавыш-гаугасыз гына төгәлли алачак иде.

Нәҗмиев инде китәргә җыенганда, Шәвәлиев аңа шифаханәдән чылтыратты:

—Кәрәм Нәҗмиевич, син анда үзең белән безнең Сабитовны да ал әле,—диде ул.—Әзрәк өйрәнсен, үзең теләгән эшләренне эшләтерсең.

Нәҗмиев берсүзсез риза булды.

Батталов аларны урамга ук чыгып каршы алды.

—Ник килгәнегезне беләм, хәбәр иттеләр,—диде ул.—Нәрсәдән башлыйсыз?

—Партком секретаре Фәрдиев бармы?

—Ул үзендә, чакыртыйммы?

—Кирәкми,—диде Нәҗмиев.—Мин аның белән телефоннан сөйләштем инде. Сабитов, син хәзер Фәрдиев белән ферманы әйләнерсең. Кирәкле кешеләрне күреп сөйләш. Кайберләренең аңлатмаларын алсаң да ярар. Үзеннең идеология эшеңне дә онытма. Райком тәртибен беләсең—без бер генә эш белән шөгыльләнә алмыйбыз. Мин бүген кайтып йөрмәм. Килешсәгез, әнә Фәрдиев илтеп куяр, яисә кунак йортында йокларсың.

—Ярый алайса,—диде Ирек һәм партком бүлмәсенә кереп китте.

—Кәрәм Нәҗмиевич, ачкычыгызны бирегез, машинагызны гаражга кертеп куярлар,—диде Батталов.—Безгә иң кулае минем УАЗик булыр.

Ярты сәгатьтән алар теге урман аланындагы өйдә иде инде. Шофер, УАЗны агачлар арасына кертеп, үзе шунда сакта калды. Батталов, таныш йортның ишеген ачкыч белән ачып, эчкә үтте. Биредә бернинди җан иясе юк, әмма өстәл төрле ниг ъмәтләрдән, эчемлекләрдән сыгылып тора иде. Тәшлектә дә юньләп ашамаган Нәҗмиевнең борынын кытыклап кергән тәмле исләрдән авыз сулары килде. Өстәлгә кыздырып куелган эре-эре карп балыклары кайнар иде. Бикле өй эчендә әле генә әзерләнгән мондый ниг ъмәтләрнең тезелеп торуы һәм бер генә җан иясенең дә булмавы Нәҗмиевне хәйран калдырды. Эшли дә, оештыра да, очын да яшерә белә шул Гайсә Батталов.

Председатель зур хрусталь бокалларны тутырып диярлек ак аракы салды. Алар икесе генә чакта беркайчан да рюмка белән эчмиләр иде. Бигрәк тә башлаган чакта. Сүзсез генә чәкештереп, эчеп җибәрделәр һәм карп ашарга керештеләр. Шактый кызышкач, Нәҗмиев:

—Йә, Гайсә, бирәр уйлаган планың бармы?—диде.

—Колхозда нинди план инде? Без бит сез кушканны үтәүчеләр генә.

—Йә-йә, мескенләнмә әле. Вакыты ул түгел. Нәрсә эшләдең?

—Хатынын, туганнарын күреп чыктым, гафу үтендем. Тегесен вәгъдә иттем, бусын вәгъдә иттем.

—Ә үзен күрденме?

—Сөйләшергә дә теләми.

—Менә бусы начар,—диде Нәҗмиев сузып.—Ә аерым коммунистлар, партком членнары?

—Күбесе минем яклы. Каршыларын командировкага-мазар җибәрермен. Әле икәү бергәләп күрәсе кешеләр дә бар. Машинаны мин шуңа тотам да. Йә өйләренә кагылып чыгарбыз, йә монда китертербез.

—Өйләренә керергә ярамый. Бирегә китертәбез. Шакир яклы кешеләрнең маңгаена бәрердәй чыгышлар булырга тиеш.

—Бергәләп әзерләрбез инде.

Батталов, томалап пешерелгән тавык шулпасы китереп, аны савытларга салды, тавыгын дүрт кенә кисәккә сындырып, уртага куйды. Алар, чәкештереп, тагын берәр бокал эчтеләр.

—Гадәти партия җыелышы түгел бу,—диде Нәҗмиев, кулына алган тавык ботын Батталовка таба селки-селки.—Коммунистлар сине гаепләмәсләр дип кем гарантия бирә ала? Ичмасам үзе сине гафу итеп чыгыш ясасын иде ул.

Алар сүзсез генә шактый вакыт мыш-мыш килеп, тавык ите кимерделәр. Бокалларны тутырганнан соң, башын Нәҗмиевкә таба иеп, Батталов болай диде:

—Кәрәм Нәҗмиевич, бәлки сез аның белән үзегез сөйләшеп карарсыз, ә?

Нәҗмиев, авызына умырып капкан итен чәйнәүдән туктап, каш астыннан Батталовка төбәлде. Аның аракы эчүдән һәм кайнар ризык ашаудан тирләгән йөзе хәтәр елтырый иде.

—Син нәрсә?! Бөтен райкомны под удар куярга телисеңмени?! Аның бит Нәҗмиев кереп, миңа шундый тәкъдим ясады, дигән бер сүзе җитәчәк.

—Әйе шул, сез хаклы,—диде Батталов.

Нәҗмиев, кара-каршы утырган җиреннән аның янына чыгып, колагына иелде:

—Дошман бирелмәсә, аны юк итәләр...

Батталов, анламыйча башын кыйгайтып, кырын күзе белән карады.

—Ничек инде... юк итәләр?

—Компромитировать итәргә кирәк аны. Җыелышта авыз ачып әйтерлек рәте калмасын.

—Ничек? Ничек?!—диде Батталов, өзгәләнеп.

Нәҗмиев аңа җавап бирмәде, акрын гына бер почмактан икенче почмакка йөри башлады.

—Минем бер план бар-барын,—диде ул.

Батталов, ашыга-кабалана аракы салып, аның кулына тоттырды, тәлинкә белән тавык ите алып килде.

—Беләсеңме нәрсә,—диде Нәҗмиев, тавык итен кабып йоткач.—Эчәме ул?

—Эчә,—диде Батталов.

—Әле хәзер больницадан кайтканнан соң да саламы?

—Шөперә. Булсын гына.

—Безгә хәзер аның шушы йомшаклыгын файдаланырга кирәк тә инде. Партҗыелышка кадәр аны ләх итеп исертергә кирәк. Шул хәлендә коммунистлар алдына бассын ул. Шушыны эшләрдәй ышанычлы кешең бармы синең?

—Бар, ник булмасын.


—Кем ул?

—Лесник Талыйп. Ул аннан как раз такталык нарат сорап йөри иде.

—Бу кандидатурага мин кушылам,—диде Нәҗмиев.—Үлгәндә дә беркемгә әйтәчәк түгел.

—Безгә җыелышны бик оператив оештыру шарт,—диде Нәҗмиев.

*Дәвамы киләсе санда*



## Рашат Низами

### КЕМ ШАКЫЙ ЗАМАНА ИШЕГЕН?

**Авырган чакта...**

**Галәмнән коела йолдызлар тузаны,
Сау чакта сизелми гомерләр узганы.**

**Чорналды тәнемә сырхаулык пәрдәсе,
Айларым, елларым—
Гарешкә очтылар һәммәсе.**

**Ерып, атлап барамын Вакыт урманын,
Типтем дә очырдым язмышым юрганын!**

**Тау чаклы гамәлләр башкарган дигәнем—
Очына да тормый икән ич энәнең.**

**Уйландым: дөньяда мин ниләр майтарган,
Үземме, әллә соң елларны картайган?**

**Күтелгән шатлыклар киләдер кичегеп...
Ни көчләр шакый соң замана ишеген?**

**Һич теләмим үземне кызгануларын,
Барлык чирдән хәтәр
Милләт өчен сызлануларым:**

**Халкым чирле—югалткан шанлы дәүләтен,
Ни көчләр белән кайтарыйк соң шәүкәтен?**

**Еллар һәм көннәрем артымнан ияргән.
Тезгенне тот, егет, егылма иярдән!**

---

Рашат НИЗАМИ *(1950)—шагыйрь, прозаик; шигырь китаплары («Йолдыз яңгыры», «Кызыл җәй» һ. б.), Фәрит Яруллин турында күләмле чәчмә әсәр, повестьлар, хикәяләр авторы. «Идел» журналының баш мөхәррире. Казанда яши.*

## Ай барыбер өстә!

Нинди өннәр килә
Туфрактан һәм таштан?
Чиркәү тәреләре
Аягүрә баскан.

Килмешәкләр килеп
Чиркәү салдырганнар.
Ватанымның күген
Айсыз калдырганнар.

«Тавык тәпиләре»
Күкне чукындырган.
Ялгызак бер болыт—
Чираттагы корбан.

Күңел бәргәләнә:
Чынмы, әллә ялган?
Ай сурәтен тәре
Аска егып салган.

Бәхәсләшә алам—
Юк, тутыкмый алмаз!
Ислам мәгыйшәте
Аста ятып калмас.

Иман нуры безгә
Кайта яңабаштан,—
Күпме манаралар
Зәңгәр күккә ашкан.

Син кизәнмә, кяфер,
Татар дигән көчкә...
Төнге күккә кара—
Ай барыбер өстә!

## Борчулы төн

Көлә-көлә,
Тәкъдир мине әзәрлекләп килә,
Тартып ега кайчак итәктән.
Шундый чакларымда ярый әле
Өмет бара мине җитәкләп.

Төн карасын ертып, мыштым гына
Әзәрлекли мине фаҗига.
Фал ачарга барыйм микән әллә
Күрәзәче Әхмәтхаҗига.

Өскә япса, тибеп очырмадым
Бу тормышның ертык юрганын.
Гамәл дәфтәренә язылгандыр
Кайчан, кайданиләр кылганым.

Гөнаһ-фәлән җыйганым юк болай,
Кызыкмадым кеше малына.
Тик нигә соң котылгысыз төстә
Салкын җилләр бәрә җаныма?

Син, кояшым, иң биектә чакта
Бигрәк иртә, иртә баедың.
Мин тормышны ныграк яраттым шул—
Шулдыр, ахры, бөтен гаебем.

Давылларда көймәм чәрдәкләнсә,
Яки сынса очар канатым,—
Минем кебек итеп җирне-күкне
Кем сөяр соң, кемнәр яратыр?

Тәкъдир мине әзәрлекләп килә,
Офыкларны тагын ут алды.
Кара атта кемдер үтеп киткәч,
Шомлы шәүлә күздән югалды...

## Зиратта килгән уй

Үлгәч тә адәмгә башлар иелә,
Яхшы кеше иде мәрхүм, диелә.
Сызлана җан, әрни-сыктый исәннәр
Күкләрдән агылган матәм көенә.

Баласынмы, әллә парын югалткан—
Бер кош аваз биреп куя таллыктан.
Кеше гомерләре булып зиратта
Күпме әнә каберташлар калыккан.

Кыска да соң адәмнәрнең гомере!
Дөрли, сүнә—гүя утын күмере.
Туган елы, үлгән елы—бер сызык,
Бар гомере сыйган шунда «чүкелеп».

Яши-яши талмасын күз карасы,
Безгә фәкать алга таба барасы.
Туган елың, үлгән елың язылыр,
Безнең гомер—шушы сызык арасы.

## Печәнче карт

Чалгы эленеп тора келәттә,
Дәрман посып ята йөрәктә.

Вакыт, ахры, шактый «каклаган»—
Чалгы сабын тузан каплаган.

Башакларга дип сөт төшсенгә,
Бии рәшә кырлар өстендә.

Урманнарда—алсу бөрлегән,
Болыннарда—печән өлгергән...

Чү, ни хикмәт булды соң бүген?
Өзде чалгы пәрәвез җебен!

Печәнчебез киерде түшен,
Кырын салды ак кәләпүшен.

Комлы кайрак тәмам очынган—
Сибелә йолдыз чалгы очыннан.

Гүя, скрипка кыллары—
Чеңли җирдә чалгы чыңнары.

Кояшны да хәтта тирләтеп,
Печән чаба бабай гөрләтеп...

## Иделдә көз

Икәү йөргән яр буйларын
Юксынып килгән идем.
Гаҗәпләнеп карап торам:
Күзләргә кергән Идел.

Каракучкыл дулкыннарда—
Арыганлык билгесе.
Үзгәрешсез калган бугай
Комнарның гына төсе.

Сыңар акчарлак талпына,
Канатларын уйната.
Ике канат асларында
Идел җәелеп ята.

Акчарлак та авырайган,
Каерып ишә җилне,—
Аның канат кагышлары
Элекке түгел инде.

Кояш белән су арасын
Җәй буена гизгән ул.
Акчарлакның төсе уңган—
Китеп барыр тиздән ул.

Ике канат асларында
Иделне тоеп кара!
Ямансу, гүя акчарлак
Мәңгегә китеп бара.

Күзнең бу югалтуларын
Син нигә кызганасың?
Китерер безгә Табигать
Язларның өр-яңасын!

Кошлар китә, яфрак китә—
Кем гаепле, эзләмик.
Китмәсен сөю! Аңарга
Сәҗдә кылып тезләник!

## Берәү генә

Күк гөмбәзе күпме йолдызларны
Кысып-кысып тоткан күкрәгенә.
Бу галәмнең төпсез коесында
Йолдызлар күп, Кояш берәү генә.

Сине күрдем, диванадай йөрдем—
Дөрләп утлар капты йөрәгемә.
Аллы-гөлле сөю бакчасында
Чибәрләр күп, ә Син берәү генә!

## Юлаучы

Тәгәри китте йомгагым,
Ул бит язмыш йомгагы.
Күңелемнән, кояш эзләп,
Карурман кичкән чагы.

Үлем бар дип сөйләнмәгез,
Ышанмыйм үләремә.
Җыр белән ялгыйм гомерне
Алдагы көннәремә.

Тәгәри китте йомгагым—
Өзелмәсен җепләре.
Идел кичәм... Чәчри биткә
Чал дулкын күбекләре.

Ярый әле Ышанычым
Сөеп калды аркамнан,
Ирек бирсәң, бу дулкыннар
Куячак бит арканлап!

Әле чорныйм, әле сүтәм
Язмышымның йомгагын.
Эндәшегез, минем кебек
Сәфәр чыкты кем тагы?

**Якуб
Зәнкиев**

# ӨТЕЛГӘН МӘХӘББӘТ

РОМАН

## 41

«Урак-чүкеч» колхозының ындыр табагы авылның читендәрәк, Иртеш буенда, кеше күзеннән кырыйдарак урнашкан иде. Ындырның көнчыгыш ягында атлы молотилка тора. Якында ашлык җилгәргеч машина да бар. Кибәгеннән аерылган бодай, солы көшелләре гәрәбәдәй булып өелеп ята. Ерак та түгел кырдан кайтарылган көлтә эскертләре өелгән. Боларны саклау вазыйфасы Локманга йөкләтелде. Кулына ау мылтыгын да, ашарга-эчәргә алырга да онытмый ул. Җилянгырдан ышыклану өчен бодай эскертен казып, өн дә әзерләп куйды. Менә төннәрнең берендә, эш юктан гына, азрак самогон салып, тамак туйдырып ятканда, аяк тавышлары ишеткәндәй булды. Шомлы тынлыкны бозып, постка куелган солдат кебек, урысчалатып:

—Стой, хто идет? Стрелять буду!—дип, янында яткан мылтыгын кулына алды.

—Бу мин, Локман дус. Молодец, бик шәп саклыйсың икән колхоз милкен. Мин шатмын,—дип мактап куйды рәис, янәсе ул аны тикшерергә килгән.

—Нишләп төнлә, ял итмичә, монда йөрисен? Берәр мәлгуне ашлык урларга киләме әллә, дип торам.—Локман мылтыгын эскерттәге куышына тыкты.—Ярый әле син икәнсең, Хәйрүш дус.

—Каравылчының үзен тикшереп карау да зыян итми кайчак. Теге сыңар күз, килгән саен, гырлап йоклап яткан була иде. Сине дә тикшереп карарга уйладым. Болай булса, бер карак та якын килә алмас ындыр табагына. Мондый эшең өчен сиңа премия дә бирмичә булмас. Тиздән план да тулырга тиеш. Колхозчыларга да өлеш тияр, дип уйлыйм.—Хәйрүш жайлап кына эскерт төбенә килеп утырды. Кесәсеннән яртысын да чыгарды.—Ышанычлы дуслар барында эшләр дә жайлы бара,—дигән булды ул.—Әйдә, бераз жылынып ал, зыян итмәс,—дип, Локманны да үз янына чакырды. Тегесе исә тезеп салынган көлтәләрне тартып чыгарып, куышын зурайтты да:

---

Ахыры. Башы 1, 2, 3 саннарда.

—Монда ышыграк та, җайлырак та булыр. Атлаганда беленмәсә дә, утыра торгач эчкә суык үтә,—диде.

—Һай, баш та үзендә, Локман дус. Бу нәкъ фронттагы землянкаларыбызга охшап китте. Җылы да икән, ашау-эчүгә дә җайлы. Бергәләп утырыйк әле бер, күптән утырганыбыз юк бит. Әйдә, минем сыйдан да авыз итик, тозлы акбалык алып килгән идем.

Алар «землянкага» җайлап кереп утырдылар, Локманның кружкасына салып, әче суны голт-голт йоттылар.

—Ах, шәп!—дип, фронттагыча, авызларын җиңнәре белән сөртеп куйдылар. Аннан Хәйрүш китергән закускага ябыштылар. Кайчандыр араларыннан җил үтмәслек иде бит, шуны искә алдылар. Беренче савыт бушагач, икенчесе чыкты. Локманның да теле чишелде, үзен күрсәтергә теләп, эскерт астына яшерелгән шешәсен эзли башлады. Янәсе, без дә төшеп калганнардан түгел. Хәйрүшнең дә башына бәрде самогон. «Дустының» аңа арты белән борылуыннан файдаланып, алдан әзерләп куелган парабеллумын алды. Локманның инсәсенә терәп үк, атып җибәрде. Тегесе тирән сулыш алгандагы кебек «эһ» итеп кенә куйды да тынды. Локман авыртуны да сизмәде, эшне аңларга да өлгермәде, һушын югалткан кеше кебек, каядыр тирәнгә агып киткәндәй тоелды аңа. Мылтык тавышын Хәйрүштән башка кеше ишетмәде дә, авыл ерак, тирә-якта кеше юк. Эскерттәге куыш тавышны үзенә йотты.

Байтак кына эчсә дә, Кәрбек гаять салкын кан белән башкарды эшне. Локманның җан биргәненә ышангач кына, бушап калган шешәләрне ындыр табагына таба тәгәрәтте. Атылган патронның гильзасын капшап табып алды, аны кесәсенә йөздерде. Шуннан соң гына «землянкасыннан» чыгып, саламга ут төртеп җибәрде. Ялкын телләре биешә башлагач ук, рәис авылга сыпыртты. Ут югарыга үрмәләп, эскертне ялмап йотканда, ул күптән өенә кайтып бикләнгән иде инде. Яшь-җилкенчәк кич утырудан кайтып килгәндә, кызыллык күккә ашардай булып күтәрелгән иде. Өйләреннән чиләкләр алып, алар ут сүндерергә йөгерделәр.

Милиция икенче көнне иртән килеп җитте. Янгын урыны җентекләп тикшерелде. Бер читтә самогон шешәләре табылды. Көл эчендә Локманның янып бетеп бөкәнгә әверелгән гәүдәсе бала-чаганың котын очырды. Табылган нәрсәләргә карап, каравылчының исерек килеш тәмәке тартып, шуннан кабынып киткән утта янып үлгәнлеген фараз кылдылар. Милиция вәкилләре дә, шундый фикерне язып, үз юлына китеп барды. Каравылчы мескеннең кара күмергә әверелгән сөякләрен җиргә иңдерделәр.

Локманның җидесен уздыргач, киңәйтелгән идарә утырышын җыйды башлык. Төсенә мөмкин булган кадәр кайгы билгеләре чыгарып, Хәйрүш сүзне башлады:

—Локман Хәбиров батыр солдат иде. Тыныч хезмәттә дә постта баскан солдат хәлендә вафат булды. Шул яшел елан—самогон аны дөньядан алып китте. Мәрхүмне аякка басып искә алыйк, иптәшләр,—диде дә, идәнгә караган хәлдә, үзе беренче булып урыныннан күтәрелде.

—Мәрхүм алай каты эчеп йөри торган кеше түгел иде ләса. Тәмәке кабызганда ничек андый саксызлык күрсәтте икән?—диде Алимбай әкә борчылган да, шиккә дә төшкән тавыш белән.

Бу бер атнада халык телендә шул сүз генә булганлыктан, тагын җавапсыз, тынып калдылар.

—Белмим, белмим,—дип кабатлады рәис тә әкрен генә тавыш белән,—инде янган ашлыкны нишләтәбез?

Тагын тынычлык. Сүзгә Кызылбаев кушылды:

—Аны нишләтәсе көн кебек ачык. Колхозчылар үзләренә бирелергә тиешле икмәкне саклый алмаганнар икән, үз инсәләре белән күтәрсеннәр инде менә. Дәүләткә тиеш булганын кырып-себереп бирәсез. Дәүләтне икмәксез калдырып булмый. Эшчеләр сыйныфына болай да икмәк җитешми. Янган игенне үзегезгә биреләсе урынга списать итәсез.

—Эшчеләрне, әлбәттә, икмәксез калдырырга ярамый, ә без нишләргә

тиеш соң? Шырчайлык та онебыз юк бит безнең,—диде Нәүбәһәр апа, ачынып.—Сугыш елларындагыча барыбызга да кырылып бетәргә каламы?

Мондый сүзләрне ишеткәч, вәкил кызарынып-бүртенеп чыкты:

—Син, кортка, сүзеңне үлчәп сөйлә. Күрәм, синең кулак психологиян һаман да баш күтәрә. Ачыктан-ачык колхоз ашлыгын әрәм-шәрәм итү турында агитация алып барасың!..—дип ябырылды.

—Сүземне үлчим дип, ачка үлгән Тәүкә әкәне туклыктан шешенеп үлде диярг әме әллә?

—Тәүкә әкәгез үзенең ялкаулыгыннан үлгән, колхозга тырышыбрак эшлисе калган.

—Ялган! Ул трудармиядән хәлсезләнеп кайткач, ашарына булмаганга шешенеп үлде. Менә минем 600 эш көнем бар. Һәр эш көненә нибары йөзәр грамм арыш, берәр тиен акча бирделәр. Көлке бит, валлаһи! Шуның белән мина кыш буена балакайларымны туендырырга, сугыш заемын да, налогын да түләргә кирәк. Ә бит барысы нибары бер капчык арыш та алты сум акча гына ул. Налогларны түләмәсәң, Тәтәк әнә костырып ала,—дип, бер кырыйдарак махмырдан интегеп утырган Тәтәккә төртеп күрсәтте.

Әлегә кадәр аларның сүзенә колак та салмаган Тәтәк сүзнең үзе турында баруын аңлап:

—Мин ни, мин партиябез кушканны гына үтим,—дип акланырга тотынды.

—Чыннан да, кайчанга кадәр бу хәлгә түзәргә була инде?—дип кушылып китте Мөжамал әбә дә.—Сугыш елларында фронтка кирәк дип түздек, хәзер сугыш та бетте бит инде.

—Хезмәт көннәребезгә бер грамм икмәк тә бүленмәсә, бу кышны ничек чыгарга соң? Хәер сорарга гына кала, капчык асып чыгып китикмени инде авылдан? Сез акыллы булгач, аңлатыгыз, ничек яшәргә соң безгә?—төрле яктан сораулы күз карашлары тагын вәкилгә калалды.

Ә тегесенең үз туксаны—туксан:

—Бик мескенләнмәгез әле. Барыгызның да хуҗалыгы бар, сөт, бәрәңге-фәлән дигәндәй... Эшчеләрнең сыерлары да, бәрәңгесе дә юк, алар нишләргә тиеш соң, сезнеңчә?

Мөжамал әбинең сүзе бетмәгән икән әле:

—Бәрәңге дип сөйләп утырган буласың тагы, күпчелегебезнең утыртырга бәрәңгесе дә булмады шул. Хәйрүш энем, шул ук Кызылбаев белән халыкны бакчаларыннан колхоз эшенә куган чакларыгызны оныттың дамы әллә? Алайса исенә төшерик. Кешеләрне хайван урынына күреп, көтү-көтү кудыгыз. Ач корсакка җир сөреп, иген үстерүчеләр дә без идек ләса. Чыра яктысында бәрәңге бакчасында казынган мескеннәр дә шул ук хатыннар иде. Хәлебез бетеп, җирдән күтәрелә алмаган солдаткаларны чыбык белән яручылар да шул сез икегез иде. Дөресен әйткән—туганына ярамаган, ди, Хәйрүш энем, икегезнең дә йөрәкләрегез таштыр сезнең. Нинди ана сезне шундый таш бәгырьле, җансыз итеп үстергәндер, Ходаем?!—тавышы калтыраса да, үзәкләргә үтәрлек итеп әйтә алды Мөжамал кортка.

Вәкил дилбегәне үз кулына алырга маташты:

—Тукта, җитәр диләр сиңа! Сине күптән Тубыл төрмәсендә көтәләр. Моннан соң да телеңне күп озайтсаң, ирен үлде дип тә җәлләп тормабыз, шунда илтеп тыгарбыз. Тукта яхшы чакта!—диде Кызылбай, буылып. Ачуын ничек басарга белмичә, күлмәк изүен чишәргә тырышты, төймә чишелмичә, өзелеп үк чыкты.—Без совет власте өчен көрәшәбез. Гитлерны җиңү өчен дә көчне кызганмадык. Сезнең икмәк мина кирәк мәллә? Армиягә кирәк ул, трактор, комбайн ясаучы эшчеләргә кирәк. Аңладыңмы шуны, аңгыра хатын? Кемгә каршы сөйләгәнеңне беләсеңме? Без власть кешесе. Тагын телеңне сузсаң, мин сине иртәгә үк лагерьга озатачакмын.

—Юк, бетмәде әле минем эчемне яндырган сүзләрем. Бетмәде. Оятың бөтенләй булмаса, лагерьга да, төрмәгә дә озатырсың. Барыбер

үләргә. Ләкин йөрәгемә кан булып төйнәлгән, таш булып укмашканны әйтмичә булдыра алмыйм. Әйе, бар сыерыбыз. Әмма ләкин бер кашык сөте үзебезгә тигәне юк. Барысы да дәүләткә, планга китә. Май йөзен күрмәгәнгә дә ни гомерләр үтте инде. Илле кило итне кайдан алып түлисе ди ул, йөз йомырканы хет үзең салып түлә?! Ике ярым сарык тиресен кайдан алып тапшырмак кирәк? Мин сарык та, тавык та асрамыйм, булганнарын шул налогларга биреп бетердем. Хөсничамал мама[1] танасын үстереп ике сыер иткән иде, колхозның уставы боермый дип, әнә ошы йоклап утырган Тәтәгегез берсен колхозга җитәкләп алып чыгып китте. Караган, үстергән хакы, суеп ашарга да рөхсәт итмәдегез бит. Авылыбыздагы унбиш хуҗалыкның сыерлары бөтенләй юк. Кияргә киеме, ашарга азыгы юк халыкның. Кайчанга кадәр болай була бу?—Мөҗамал әбә, кызып китеп, тузган чәчләрен яулык астына кымтыды.—Мескен кызым Сабирам да азык житешмәгәнлектән, чахоткага сабышып вафат булды. Сугышчылар сугышта, өйдәгеләр өйдә кырылды. Инде ике балам калды. Мине лагерьга җибәрсәң, аларны син карарсыңмы? Әллә әнә ошы колхозның нәсел үгезедәй солдаткаларның итәкләренә кадәр күтәреп, тикшереп йөри торган Тәтәгенме үстерер?

Бу юлы тегесе дә түзмәде:

—Мөҗамал енгә, син нимәгә дип гелән минем белән булышасың?—дип, сикереп торды.

—Син тик утыр, Тәтәк. Әгәр кылансаң, барлык кылмышларыңны бөтен авыл алдында әйтеп бирәм.

Әйтергә вәкил ирек бирмәде:

—Кем килсә аңа бәйләнәсең, әллә син тилебәрән орлыгын ашадыңмы, Мөҗамал кортка? Яхшы чакта яп алабай авызыңны! Инде мәсьәләнең аслына күчик, иптәшләр. Алайса, дәүләткә иген тапшырмыйбыз, дип карар чыгарыйк та, райкомга җибәрик. Йә, кемнәр шуңа кул куя?—диде дә каш астыннан сөзеп халыкка карады.

—Берәү дә, дәүләткә иген бирмибез, дип әйтми бит. Кеше куркытырга остаргансыз сез, иптәш Кызылбаев. Әлләни кадәр игенне дәүләтебезгә озатып та куйдык. Хәйрүш инде теге көннәрне үк планыбыз туксан процентны артты дигән иде. Без бит үз балаларыбызга ашатырга бер уч кына да оныбыз юклыгын исегезгә төшерәбез. Чукрак булмасагыз, ишеткәнсез шәт шул сүзне?—дип өстәде Нәүбәһәр апа. Эчтән үзе шүрләп тә куйды. «Сүз аңлый торган мәхлукларммы соң болар, шуларга сүз әрәм итеп торырга...»

Җыелыш буенча авызына су кабып утырган Хәйрүш сүз кыстырды:

—Планны тутыргач, артса, бүлешербез. Ашлык җилгәргәннән калган очыкны алырсыз. Мөмкин кадәр авыр хәллеләргә ярдәм итәргә тырышырбыз,—диде ул халыкны тынычландырырга тырышып.

—Кызылбайны ияртеп миңа кунакка кер әле, мин сезне әнә шул очыктан ясалган умач шырчае белән сыйлармын,—дип шаяртып куйды үткен телле Хәпчә әбә. Идарә утырышы шуның белән төгәлләнде.

Бу вакыйгалардан соң бер ай чамасы вакыт үткәч, көтмәгәндәуйламаганда авыл кибетенә ревизия килеп төште. Усалрак телләләр хат язып җибәргәндер, күрәсең. Тикшерүчеләр житешмәүчелекнең булуын алдан белгән кебек, эшкә керештеләр. Таңсылуның сигез мең сум акчасы житмәде. Кибетендә тикшерү башлангач ук, чибәр хатын йөгереп Хәйрүшкә китте, әҗәткә биргән акчасын кире кайтаруын үтенде. Тегесе күзен дә йоммыйча:

—Мин синнән кайчан акча алганым бар? Шулхәтле зур сумманы күргәнем дә юк минем. Юк белән минем башымны катырып йөрмә әле!—дип, алганыннан баш тартты.

Таңсылу моны көтмәгән иде, күзләрен зур итеп ачып карап торды да, бу сүзләр акылына барып ирешкәч, үкереп елап җибәрде.

[1]Мама—әби.

—Ул акча эченне тишеп чыксын!—дип каргады, үзенең алданганын аңлагач.

Ревизия нәтиҗәсен сельпога тапшыргач ук, Таңсылуны кулга алдылар. Авылда ук суд булды. Ана сигез мең акчаны үзләштергәне өчен биш елны чәпәделәр. Шулай итеп җиңел генә моннан да котылды Хәйрүш. Келәттәге ашлыкны себереп-сыдырып дәүләт планын тутырды. Ана тантаналы рәвештә райисполком һәм райкомның «Мактау грамотасын» тапшырдылар. Кулын кыстылар. Сессиядә почетлы президиумга чыгарып утырттылар.

Хәйрүшнең эшләре җайланды шикелле. Нурия ризалык бирмәсә, ана төкереп, Фәридәгә кармак салырга ниятләде. Анысы инде баш тартмас Хәйрүштән. «Иртә уңмаган, кич уңмас» ди бит, үзенә каршы төшәрлек кеше калмады дигәндә, сугышта өзелгән бер аягына чатанлап, Әхмәдүш авылга кайтып төште. Яралары бетәшкәнче хәрби госпитальдә яткан икән. Йортына кайтып керергә өлгерми дә калды ир, хатыны Таңсылу белән булган вакыйгаларны түкми-чәчми җиткерделәр. Кайсы кызганды хатынны, кайсы «шул кирәк» дигәндәйрәк мөнәсәбәт белдерде. Таңсылуны бик сагынып кайткан иде Әхмәдүш, өе ялгыз, шыксыз күренде. Тормыштагы апасы Рәсимә кереп өен рәтләде, аш-су пешереп йөрде. Әхмәдүш хатынын эзләп-юллап торага да барып карады. Ләкин һичбер эш чыгара алмыйча, нәүмизләнеп кире кайтты. Шыксыз өйдә ары-бире йөренде, берничек тә Таңсылуы турында начар уйлый алмый иде ул. «Ялгышкандыр, берәүләр алдаганнардыр. Белә торып сигез мең акчаны кая куйсын ди ул? Гомердә булмаганны...»

Хатынын исеннән чыгара алмады ир-ат. Шундый көннәрнең берендә Рәсимә әбәсе иплэп кенә мона сүз кушты:

—Әхмәдүш энем, син әле генә госпитальдән кайттың. Тынычлык, яхшы тәрбия кирәк сиңа. Безнең күршебездә генә яшәгән Мәүкәне беләсең бит. Байтак яшькә чыкса да, берәү белән дә буталып-чуалып йөрмәде, аш-суга осталыгы бар, эшмәгәр. Әллә шуңа өйләнеп куясыңмы, дим. Берүзең ничек яшисең инде?

—Әбә, минем үз бичәм бар гуй, Таңсылуымны әйтәм.

—Булса ни, армиядә биш ел йөреп кайттың. Инде әллә кайларга җибәрелгән Таңсылуыңны тагын биш ел көтеп утырасыңмы? Ул әнә шул растрата акчасына Хәйрүшне сыйлап әрәм-шәрәм итеп бетерде,—дип сөйләде Өннәш әбә.

Әхмәдүш әбәсенең Таңсылуны баштан ук сөймәгәнен белә иде.

—Бур үзенә тиңләр, уйнашчы артына тиңләр, ди халык. Өннәшнең сүзен тыңласаң, ярты авылны бур да ялганчы итеп бетерер. Мин хатыныма яратып өйләндем, әбә, көтәм мин аны. Нығрак тикшерсәләр, бәлки гаебе дә юктыр әле. Шул Хәйрүшләр генә алдаган булырлар үзен. Кеше сүзенә ышана торган беркатлы кеше иде шул ул, йөрәккенәм.

Көн арты көн үтте. Беренче суыклар белән авылга грипп авыруы килде. Авыл халкы белә: бу авыру йортка керсә, аннан бик сирәкләр генә котылып кала. Рәсимәне дә аяктан екты ул. Йортлары белән авырдылар. Бу көннәрдә Әхмәдүшкә аш-су әзерләүче дә булмады. Һәркемнең үз кайгысы, һәрбер йортта диярлек ут белән янгандай кызышып, авызлары кипшенеп, ярылыр дәрәҗәгә җитешкән авырулар ята. Рәсимә аякка басып, энесе янына кергәндә, тегесе дә сыңар аягына баса алмас дәрәҗәдә иде инде. Фронтовикка су бирүче кеше дә булмаган. Ашыгып-кабаланып алып кергән сөтен суган салып кайнатты әбәсе. Энесенең башын күтәреп, эчерде. Әлеге Мәүкәләргә кереп, елуыт та алып чыкты. Кызның үзен дә ярдәм итү сылтавы белән Әхмәдүшнең өенә чакырды. Тегесе, кергәч үк, фронтовикның өен ялт иттереп юып чыгарды. Тәрәзәләрен сөртте. Утынны да үзе ярып алып керде, мичен дөрләтеп ягып җибәрде. «Өйдә балаларым каралмаган, эшем дә күп, син инде, Мәүлиҗамал, минем энемне аякка бастырышырга ярдәм итеш, зинһар,—дип кызга ялварды Рәсимә әбәсе.

Мәүкә аз сүзле, кечкенәдән эшкә чыныгып үскән, нык бәдәнле,

кысык күзле, коймак битле, ирләрчә киң басып атлауны гадәткә алган утыз биш яшьләренә житкән кыз иде. Кереп-чыгып Әхмәдүшне тиз арада аякка бастырды. Ул грипптан арынгач та, кыз аңа кереп йорт эшләрен башкарып йөрде. Шул көннәрдә Рәсимә әбәсе Әхмәдүшне әкрен-әкренләп Мәүкәне алырга күндереп тә куйды. Алар икесе көн күрә, уртак ут яга башладылар. Мәүкә көннәр буе жимертеп эшли дә төнгә керсә изрәп йоклый. Түшәктә аның янында ир дигәнең булса ни дә, булмаса ни. Әхмәдүш Мәүкәнең кырыена гына барып, уятмаска тырышып ята да, кызу канлы Тансылуын исенә төшереп, сызлана. Үзе үк аны сөяр иде хатыны, кочагына кереп, эреп үк бетәр иде. Ә моны хатын димәсәң, хәтере калыр. Бүрәнә дә бер, бу да бер.

Берчак Рәсимә әбәсе хәл белергә кереп, сорап куйды:

—Йә, ничек яшәп ятасыз, яшьләр?

Мәүкә ишегалдында әвәрә килеп эшләп йөри иде. Өстенә иренең телогрейкасын кигән, билен буып куйган. Әхмәдүш хатынына йөзен чытып карап куйды да, дөресен әйтте:

—Ай-вай, Рәсимә әбәкәем, төннәрендә түшәктә минем белән суык бака ятадыр гуй. Белмисең хәлләремне.

—Түз инде, энем. Күнегеп китәрсең. Балагыз булыр. Кысыр Таңсылуың сиңа бала да бүләк итә алмады...

—Бала булса, ярыйсы булыр иде дә бит,—дип куйды ыңгырашкандай энесе. Калганы бар да аңлашылырлык иде...

Түзә алмады Әхмәдүш, врачка аягын күрсәтүне сәбәп итеп, Таңсылуын эзләп тагын торага юнәлде. Аларны тоткыннар эшли торган жирдә күрештерделәр. Таңсылуның өс-башы бик тузган. Аягында кыш көне ирләр кия торган дәү ботинка, башында өйдән киткән кара шәле, өстендә тоткыннар кия торган сырма. Әхмәдүшен күрүгә, хатын аның муенына барып сарылды. Күз яшьләре белән битен чылатты, үпте, сыйпады. Әхмәдүш аз-маз ризык алып барган иде, бергәләп авыз иттеләр. Азрак ис-осларын жыйгач, сугыш алдындагы тыныч, бәхетле көннәрен искә алдылар. Әхмәдүшкә хатын дөресен сөйләп бирде:

—Нахактан гына башымны ашадылар, йөрәк маем. Шул тончыгып үлгере Хәйрүш, колхозга кирәк дип, акча алып торган иде. Мин аңа ышанып биш мең сум акчаны кулына бирдем. Аннан алда да районнан вәкил килгән саен, соңыннан түләрбез дип, әллә никадәр аракы, азык-төлек алып тордылар. Ревизия килгәч, шулар алдында: «Мин аннан бер тиен дә алганым юк. Ялганлый», дип отказ бирде хайван. Әнә шул оятсыз мине бу хәлгә калдырды да. Ул бит үзенә дип түгел, колхозга дип сорады. Шулай булгач, каршы тора алмадым.

—Син аннан расписка-мазар алмадыңмы соң?

—Юк шул. Тик блокнотыма гына кайчан кемгә бурычка биреп торганымны язып барган идем. Ул блокнот өйдәге комод тартмасында саклана. Син шикләнмә, жаныем, минем бер генә дә кыек эшем булганы юк. Сине менә өйдә каршылаулар гына, һай, насыйп булмады. Чүкердәшеп кенә яшисе идек тә бит... Хәлеңнән килсә, мине, зинһар, моннан йолып ал! Күрәсең, мин нинди хәлгә калдым монда...—Хатынның күзләре тагын яшь белән тулды.

Әйтергә уйламаса да, түзә алмады Әхмәдүш:

—Тансылу, нәнәвем, миңа Мәүкәне кодалап куйдылар гуй инде...

Бу минутта хатын өчен мондагы жәһәннәмнән дә куркынычрак нәрсә юк иде, ахры. Иренең башкага өйләнгән булуы да ул кадәр начар хәбәр булып ишетелмәде. Яшьле күзләрен Әхмәдүшкә төбәп, ялынуын белде:

—Кичерәм мин сине, йөрәк маем. Нинди генә хәлендә дә кабул итәчәкмен. Миннән артыкны, күпме генә эзләсәң дә, күпме генә сайласаң да, барыбер таба алмыйсың. Бу жәһәннәмнән генә коткар, ялварып сорыйм синнән! Гомер буе бергә булырбыз, сөешеп яшәрбез...

Алар шулай саубуллаштылар. Артыннан тимер капкалар шыгырдап

ябылгач та, Әхмәдүш әллә ничә мәртәбә борылып карады. Таңсылуының жылысы, аның кызуы үзенә җитешмәгәнен тагын бер кат тойды.

## 42

Совет армиясе көне алдыннан мәктәпнең кырмыска оясыдай кайнап торган чагында көнбатыш юлыннан аркасына солдат капчыгы асып, култыгына кечкентик төргәк кыстырып, бер егет килеп чыкты. Һәркем үз шөгыле белән мавыкканлыктан, бу чандыр егеткә артык игътибар итүче дә булмады. Дежур укучылар коридорда чит кешенең булуын директорга житкерделәр. Гөлсинә апалары кунакны каршы чыгып алды һәм, әле мыек та төртмәгән егетнең үзен шулай кыю тотуына гаҗәпләнебрәк, өс-башын күздән кичерде. Телогрейка астыннан күренеп торган чигелгән күлмәк якасы, кыңгыр салынган кепкасыннан бүселеп чыккан житен төсле бөдрә чәче бу чандыр егетнең чаялыгын арттыргандай күренә иде. Гөлсинә аның кем булуы, кайларга юл тотуы белән кызыксынды. Егет, сүзне ничегрәк башлыйм икән, дигән кебек, азрак уйланып калды. Яшькелт күзләрендә моң-хәсрәт чагылып алды. Директор исә, егетнең хәбәре бик үк күңелле булмасын сизенеп, тынычсызлана ук башлады.

—Мин Айвар Мусин булам,—диде егет.—Киев шәһәреннән үзем. Зиннур абый Абдуллинның укучысы.

Гөлсинәнең күзләре зурайды. Аны иң гаҗәпкә калдырганы кунак егетнең соңгы сүзләре булды. «Кайда, ничек укыган бу бала Зиннур абыйсында? Берәр нәрсәне бутамыймы бу?»

Егет, аның гаҗәпкә калуын сизеп, эшне кыскача гына аңлатып чыкты. Фашистлар концлагерында балалар укытканлыгын ишеткәч, Гөлсинә тиз генә балалар белән бәйрәмгә әзерләнеп йөргән Нурияне, Фәриданә чакыртты. Яшьрәк фронтовиклар да шунда икән. Әхмәдүш, Мансурларны да чакырдылар. Айвар инде янадан бәйнә-бәйнә итеп Зиннур абыйсы белән ничек танышуларын, үзен ничек итеп үлемнән коткарып калуларын сөйләп бирде. Гөлсинә апасы үзен Нурия белән таныштыргач, аңа сынап карап торды да:

—Нурия апа, мин сезгә Зиннур абыйның кайнар сәламнәрен алып килдем,—диде.—Ул үзе кайтып житмәгән икән әле. Сез борчылмагыз, кайтыр ул. Безне дә туган илебезгә кайтырга, немецларның сүзенә ышанып, анда калмаска дип өйрәтте.—Егет абыйларын соңгы тапкыр ничек күрүен дә сөйләп бирде.—Абыйның иң соңгы сүзләре дә сезнең хакта булды, Нурия апа, ул сезне шулкадәр сагынган иде...

Аны чолгап алган кешеләр исләре китеп бу хәбәрне тыңладылар. «Менә бит кеше дигәненнен язмышлары, әллә кайда, әллә кемнәр белән очраштыра».

Айварның очрашу дулкынлануы бетмәгән иде әле. «Менә тагын ниләрем бар әле минем» дигән кыяфәт белән, ашыга-ашыга кулындагы төргәген чишә башлады. Аннан трубкага төреп куелган кәгазьләр күренде. Саклык белән генә ул кадерле кәгазьләрне өстәлгә җәеп салды. Тегеләр, нәрсә буласын көтеп, сабыр гына күзәттеләр. Беренче кәгазь битеннән аларга Зиннур карады. Әлегә кадәр егетнең сөйләгәннәренә ышанырга да, ышанмаска да белмәгән укытучылар рәсемгә карап каттылар. Әйе, бу ул, аларның Зиннурлары иде. Нурия үзе дә сизмәстән жанына сузылды, рәсемне кулына алып, күкрәгенә кысты. Сорау тулы күзләре белән Айварга карады.

—Мин боларны концлагерьда ясадым, өйгә кайткач, рәтләп алдым, зурайта төштем. Сугышка кадәр үк мин сәнгать мәктәбендә укыган идем,—дип аңлатты егет.

—Шулкадәр жир-суларны гизеп, безне ничек эзләп таптың соң син, Айвар энем?

—Безнең блокта Зиннур абый еш була башлагач, без аның белән

бик якынаеп киттек. Ул сезнең якларның матурлыгы, тайгалары турында сөйләде. Үзен Себер якларыннан дия иде. Соңгы тапкыр аны гестапочылар безнең блокта дәрес вакытында кулга алдылар. Ул безгә «Балалар, сезнең туган илегез бар, анда сезне сагынып көтәләр. Безнең гаскәрләр сезне азат итәчәк. Исән-сау кайтсагыз, минем әниләремә, Нуриямә сәламемне җиткерегез. Мин Себердән, Төмән...» дигәндә, аның авызын томаладылар. Туган илгә кайтып ирешүгә, мин аның адресын эзли башладым. Төмәнгә сорап яздым. Ниһаять, Тубыл военкоматы Абдуллиннарның бу авылда булуларын раслап хәбәр җибәрде. Сезне көчкә эзләп таптым. Анда ук үземә ант иткән идем: исән-сау кайтсам, барыбер сезне эзләп табам, абыйның соңгы сүзләрен җиткерәм дип. Ул бит мине дә, башка балаларны да үлемнән алып калды, бездә кайтуга өметләр уятты. Фашистлар көнтөн: «Сезнең илегез җинелде, сезнең илегез юк», дип торганда, Зиннур абыйның бер сүзе дә безне яшәтте, өметләребезне тергезде...

## 43

Зиннур Абдуллин Колыма лагерена килеп кергәнче барлык җәзаларны, кимсетүләрне егетләрчә үк булмаса да, тешләрен кысып кичерде. Өмет белән яшәде. Ләкин мондагы хәлләр аның соңгы өметләрен дә өзде, яшәрлеген калдырмады. Хайван кебек көтү-көтү мылтык астында эшкә йөрүдән, кыйналудан тоткыннарның кешелек сыйфаты бетә, күпләр акылдан да шашалар. Зиннур өчен иң курыкканы да үлем түгел, акылдан шашып, адәм типкесендә йөрү иде. Ул ничек булса да ирекккә, үз иленә, Нуриясенә хат кисәге язу чарасын күрә башлады. Бер баракта торып дуслашырга өлгергән Газиз исемле татар егетенең кайтыр, бу баздан ычкыныр көне якынлашты. Бу аның соңгы өмете иде. Ничек булса да моннан файдаланып калырга, мондый форсат тагын әллә була, әллә юк иде. Газиз дә тоткынлыкта калган дусты өчен хәленнән килгәнне эшләде: Нуриянең адресын ятлап алды. Кош теле кадәр генә цифрлар белән язган кәгазь кисәген тикшерүчеләрнең күзе төшмәслек җиргә текте. Хат ирекккә чыкты...

Көннәрнең берендә Нуриягә чит-ят кул белән язылган хат килеп төште. Конверт эчендә кечкенә генә кәгазь кисәге. Конвертны ачуга ук, күнеле «дерт» итеп китте кызның: хат аңардан иде! Цифрлар сүзләргә әверелгәч, түбәндәгеләр укылды: «Нуриям, җаныем, сине өзелеп сагындым. Мин хәзер Колыма лагерьларында. Мине гаепсездән озаттылар монда, гаепсезгә иза чигәм. Илебез алдында бер гөнаһым да юк. Син ышанырга тиеш миңа. Мәскәүдә яшәүче полковник Силинны эзләп табыгыз, ул мине белә, булышырга тиеш. Мине, җаныем, моннан йолып алырыңа өмет итәм. Әткәй-әнкәй алдында баш иям. Суырып үбәм, Зиннурың. Бу—Силинның Мәскәү адресы...»

Кыз бу хатны утта янган йөрәгенә басты. Сыйпады, күз яшьләренә чылатты. «Минә кайда икән аның сөйгәне. Кайларда иза чигә икән!» Хәзер аның исән-сау булуы гына да Нурия өчен зур бәхет, көтеп-көтеп тә ала алмаган өр-яңа хәбәр иде. Ул байтак исәнгерәп утырды, бер минутта башына әллә нинди уйлар килде. Бераздан фикерен туплап, Әхмәдүш абыйсына кузгалды. Мәктәптә дәресләр тәмамланып, балачага таралгач, янадан мәктәпкә җыелдылар. Зиннурның хатын кат-кат укып, аңларга тырыштылар. Хат бик кыска, җөмләләр өзек-төтек кенә булганга, күп нәрсә аңлашылмый иде. Димәк, аның иркенләп хат язарлыгы да булмаган. Уйлаша торгач, барысы да бер фикергә килделәр: ничек кенә булса да хатта күрсәтелгән полковникны табарга! Эш тагын Мәскәү кадәр Мәскәүгә бару өчен юллык акчаның да булмавына барып терәлде. Болайга киткәч, Нурия шатланып үзенең алтын алкаларын, әтиләре үзенә дип үстергән таналарын сатарга булды.

Әхмәдүш тә ярдәм итәргә булды.

—Мина «Кызыл йолдыз»га аена 5 сум, «Ватан сугышы» орденына

7 сум исәбеннән барысы дүрт йөз сум акча килде военкоматтан. Сугыш еллары өчен дә түләү карары чыккан,—диде.—Зиннурның эше барып чыкса, шуларның бер тиенен дә кызганмас идем. Тимер юл билетына да, ашау-эчүгә дә житәрлек ул.

Акча ягы шулай хәл дә ителде шикелле. Нурия, Әхмәдүш, Фәридә, Айвар берәр атнадан ерак юлга чыгар алайса, диебрәк эшне йомгаклый башладылар. Мәжлес шулай кызып барганда, кыюсыз гына атлап, Гөлсылу килеп керде. Локманы янып үлгәннән соң кеше арасында еш күренмәгән хатынның тиктомалга мәктәпкә килүенә бөтенесе дә гажәпсенде. Мәктәпнең директоры исә гажәпләнүен яшереп тә тормады:

—Исәнме, Гөлсылу, ни йомыш?—диде.

Тегесе сүзен нидән башларга белми аптырап торды. Шулай да тәвәккәлләп тотынды:

—Мин Локман белән Хәйрүшләр турында кергән идем... Локман үлгәнче безгә берничә тапкыр Хәйрүш керде. Сугышка кадәр Локман анардан курка, аның сүзеннән бер дә читкә чыкмый иде. Хәзер мина шунысы гажәп тоелды: сугыштан соң Хәйрүш Локманнан шикләнгәндәй күренә башлады. Локман ни сораса, ни әйтсә дә, тегесе үтәргә генә торды. Үләр алдыннан ирем өй салу турында сүз кузгатты. Нинди акчага, ничек салырга уйлавын мина чишмәде. Бер көнне Хәйрүш өйгә китереп, ана бер пачка акча тоттырды. Мин керешмәдем, артык төпченеп тормадым.Ирем үлгәченнән, Таңсылуны да алып киттеләр. Өч көн элек кенә ирем яшереп куйган урыныннан шушы акчаларны таптым. Инде ничәнче төнне йокысыз үткәрдем. Бәлки, минем Локманым белгәндер Хәйрүшнең хәлләрен, ярамаган кырын эшләрен?.. Тегесе шуна адым саен ярдәм итеп, бер дә каршы килмичә, минем мәхлукның көен көйләп, майлап торгандыр?.. Монда биш мең сум акча, мин андый акчаларны гомеремдә күргәнем юк. Локманның авызын томалар өчен китергәндер аларны Хәйрүш,акчалар Таңсылудан алынган түгелме икән әле? Әгәр шуның аркасында Таңсылу харап булган булса... Әхмәдүш, мә, ал әле шушы акчаларны. Җаным тынычлансын. Бәлки, сез аның очы-башына чыга алырсыз. Шул акчалар Локманның башына да житте ахрысы инде...

Бүлмәдәгеләр, исләре китеп, аны тыңладылар. Чыннан да Локманның үлеме, Таңсылуның төрмәгә эләгүе дә шул ук Хәйрүшкә барып тоташа түгелме соң?!

—Таңсылу үзе дә бу турыда әйтте дә бит, берәү дә аның сүзенә ышанмады ул вакытта, аны тыңлап та тормадылар,—диде Гөлсылу, кулга алу вакыйгасын искә төшереп.

—Ярый алайса, бу эшкә дә ачыклык керә башлады,—диде сабыр гына Әхмәдүш, маңгаен сыпырып.—Башта бу эшнең очына чыгарга кирәк, аннан соң Таңсылуыбызны да коткарырбыз, Аллам боерса. Рәхмәт сина, чибәркәй. Әгәр дә кирәк булса, судта бу сүзләреңне кабаттан сөйләрсең бит?

—Үзем белгәннәрне сөйләүдән баш тартмам. Ана ярдәмем тисә, бик шатланып эшләрмен. Минем мәхлугым белән ана «дус» булып йөргән юха елан аркасында гына төрмәгә эләккән булса, котылыр ул, котылмый калмас.

Гөлсылу чыгып киткәч, сүз тагын Хәйрүш, Локман, Таңсылулар тирәсендә барды.

—Менә бит эшләр ничек, үз гөнаһларын яшерү өчен үзенең иң якын дусты дип саналып йөргән кешегә дә кул күтәргән икән, димәк зур булган гөнаһлары, адәм башлары күтәрәлмәслек зур булган...

—Акчалар да житәрлек булды, мәсьәлә дә ачыклана төште. Тиз арада юлга чыгып, Силин дигән кешене эзләп карарга кирәк,—дип сүзне йомгаклап, кибән башын чыгарып куйды Әхмәдүш.

Гөлсылу белән Фәридә Зиннурны азат итәргә сорап язылган кәгазьгә өй борынча кереп, кул куйдырып йөрделәр. Бу эш шома гына бармады. Чын күңелләреннән авылдашлары өчен борчылганнар ышаныч белән

кулларын куйсалар да, ярты авыл, бәладән башаяк дип, бу эштән баш тартты. Аларны да гаепләп булмый шул. Сугыш алдыннан гына «халык дошманы» дип кулга алынган Мәмәтнең эшен юллап йөргән Корман, Барикә әкәләрнең язмышы онтылмаган иде әле. Тегесе дә кайтмады, болары да суга төшкән таштай юк булдылар. Бәлагә очрасаң гына, кемнең дус, кемнең түгел икәнен беләсең, диләр. Гөлсылу һәм Фәридә дә шул хакыйкать белән күзгә-күз очраштылар. Мона кадәр башлары тәкыя эчендә булган икән. Әле Алимбай әкә кул куя башлагач та, Өннәш аның өстенә әтәч булып кунды, кулындагы каләмен тартып алды. Фәридәнең корымнан ясаган карасы кулыннан төшеп, күлмәген буяды.

—Башыңны бәлагә тыкмакчы буласыңмы, ангыра?!—дип ябышты ул иренә.

Алимбае башта агарды, күзен кан басты. Аннан бар көченә хатынны этәреп җибәрде. Өннәш йөзтүбән барып капланды, ләкин монда да тыныч кына кала алмады.

—Асраган бозавыңның артка тибүе булды инде бу...—дип сукранды.

Алимбае исә гаризага үзенә бер горурлык белән кулын куйды. Моның белән ул үзен мыскыл иткән хатыннан да үч алды.

Серне сакларга кирәклеге ныклап әйтелсә дә, сүз чыга икән шул. Украина якларыннан авылга бер яшь егетнең килүе, аның Нуриягә ниндидер хәбәр китерүе дә, Нуриянең әле тагын Колымадан хат алуы да, Гөлсылуның мәктәпкә биш мең сум акча китерүе дә, ул акчаны Әхмәдүшкә тапшыруы да авыл буйлап бик тиз таралып өлгерде. Вакыйга бик зур итеп Өннәшкә дә житкерелде. Ул тиз генә Хәйрүшкә ишеттерү чарасын күрергә дип кенә торган арада—әле менә болары имза җыеп йөриләр булып чыкты...

Өннәш, куян артыннан чапкан эт кебек, телен салындырып, идарәгә килеп кергәндә, алгы бүлмәдә Чәмилә әбә нәрсәнедер исәпләп чат-чыт китереп, чутта сугып утыра иде. Ул Хәйрүшнең эчке бүлмәдә булуына баш бармагы белән генә ишарә ясап, үз шөгылен дәвам иттерде. Өннәш рәис янына сулышы кабып кергәнлектән, эчен тишеп чыгарлык булган хәбәрләрне әйтә алмыйча аптырады. Ишек төбендәге урындыкка артын төртеп, шәлен чиште.

Хәйрүш исә ана үз шатлыгын белдерергә ашыкты:

—Өннәш әбә, безнең колхоз урып-җыю буенча районыбызда беренче урынны алган бит! Менә шул унайдан мине өлкә авыл хуҗалыгы алдынгылары слетына җибәрәләр. Менә, ышанмасаң, кара!—дип, хатынга районнан килгән кәгазьне сузды.—Мәскәүгә барырга да путевка бирделәр...

Тегесе, алай исе китмичә генә:

—Котлыйм,—дип куйды. Инде үзенең хәбәрен житкерим дип кенә торганда, ишек ачылып китте. Бухгалтер Чәмилә әбә, гадәтенчә, ишекне шакып-нитеп тормыйча гына, килеп керде. Ул, кирә-керешли, командировка кәгазен Хәйрүшкә сузды:

—Менә, энем, сиңа хәерле юл телим, хәзер юлына акчаларны да әзерләп куям,—дип, ашыгып чыгып та китте.

Шул арада Өннәш, тыныч булырга ишарә ясап, бармагын иреннә-ренә тидерде дә пышылдап кына колагына үзенең ишеткәннәрен әйтте. Бер мизгелдә рәиснең төсе бөтенләй үзгәрде. Ул бер кызарды, бер агарды, теле бәйләнде. Әмма аның бу халәте озакка бармады: бер генә мизгелгә югалып калган рәис тиз арада үзен кулга алды.

—Өннәш әбә, сиңа Мәскәүдән нинди бүләк алып кайтыйм?—диде ул, күңелендәге үзгәрешләрне иң ышанычлы, якын кешесенә дә сиздермәскә тырышып.

Хатын барыбер әлеге үзгәрешне сизенде. Шуңа күрә ана туры карап:

—Син үзең миңа зур бүләк, исән-аман йөреп кайт, Хәйрүш,—диде.

—Рәхмәт яхшы сүзенә. Хәзергә сау булып тор. Бик ашыгам, документларны җайлыйсы бар. Үз урыныма вакытлыча гына Чәмиләәбәне калдырырга уйлыйм, аның белән дә сөйләшәсе сүзләр бар.

Өннәшнең хәбәрләре Хәйрүшкә аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте, алдан ук корып куйган планнарын чуалтып ташлады. Тансылуның «эш»ен янадан кузгаткан тәкъдирдә әллә ниләр казып чыгаруларын көт тә тор. Чүп өстенә чүмәлә өеләчәк. Халык үзе чагачак. Зинданга бер эләккәнче генә син очар коштай иркле. Бер эләксән ул зинданга, бар аннары инкарь итеп кара!.. Исән чакта башны алып кыякларга кирәк моннан!..

Колхоз рәисе шундук бухгалтерны үз янына чакырып алды.

—Кер әле бирегә, Чәмилә әбә. Мин уйлап тордым да, бер унайдан өлкә базаларына кагылып, колхозга яна молотилка да алып кайтырга булдым. Кассада булган бөтен акчаны әзерләп бир әле. Икмәк, ит тапшыру планнарын үтәгән өчен бирелгән акчаларның барысын да!—дип ачыклык та кертеп куйды хуҗа кеше.

—Үзен, ул акчалар колхозчыларның хезмәт көненә, дигән иден бит, мин ана ведомостьлар да төзеп куйдым инде,—дип карышты тегесе, рәиснен фикере тиз арада үзгәрүенә исе китеп.

—Кушканны эшлә син, Чәмилә әбә, халыкка сонрак бирербез. Күреп торасын бит, молотилкабыз бик искергән. Киләсе елга ул тузган машина белән ничек итеп иген суктырырбыз?—Рәиснен тавышында ризасызлык кына түгел, гайрәтләнү һәм ачу да чагыла башлаган иде инде. Ул кабат-кабат әйтеп тормаслык итеп:—Әйдә, барлык булганын санап бир, кәгазьләренә кул куярмын,—диде. Аннан сүзне беткәнгә санап, өстәп куйды:—Менә сина колхоз мөһере. Мин югында рәислекне вакытлыча син башкарырсын!—диде.

—Озакка дип китәсенме сон?

—Алдан әйтеп булмый, ин киме ун-унбиш көн үтәр, дип уйлыйм.

Икенче көн төшкә таба Әхмәдүш идарәгә кергәндә, Хәйрүш урынында Чәмилә әбә генә утыра иде. Хатын кергән-чыкканга рәиснен өлкәгә алдынгы колхоз рәисләре җыелышына китүен һәм берочтан, слет беткәч, Мәскәүгә дә путевка белән юл тотасын сайрап утыра бирде. Әхмәдүш сагаеп сорап куйды:

—Озак йөрерме сон ул анда?

—Ун-унбиш көнсез дә кайтып булмас, диде. Мәскәүдән кайтышлый юл унаеннан кереп, колхозга молотилка да сатып алырга тиеш әле ул. Әхмәдүш энем, синен йомышын ни иде сон? Бәлки, мин генә хәл итәрмен?..

—Юк, бик ашыгыч түгел, үзе белән сөйләшәсе сүз бар. Кайткач, күзайтынга керермен.

Чәмилә әбә, эш юклыкка эче пошкандай, кичә килгән газеталарны актара башлады. Делегатларның рәсеме төшерелгән икән, күзләрен кыса төшеп, шуларны карарга кереште. Әхмәдүш тә кызыксынып рәсемгә текәлде. Газетаны үзенә сорап торды:

—Иртәгә үк кертеп бирермен,—диде.

Колхозчыларның, бигрәк тә фронтовикларның, идарәдән укырга гәзитләр алып тору гадәте булганга, Чәмилә карышмады.

—Ярар, ярар, ал, кертергә генә онытма. Мин бит аларны җыеп тегә барам.—Гәзитләрне биргәндә идәнгә бер кәгазь кисәге дә төште. Әхмәдүш аны бөгелеп алды да, әйләндереп карады. Бу—Хәйрүш (Хәйретдин) Хәйбулловны слетка чакырып җибәргән хәбәр иде.

—И Аллам, бу кадәр дә ашыгу-кабалану булыр икән,—дип уфтанды хисапчы апа.—Кирәкле кәгазьләрен дә оныткан бит...

## 44

Көн артыннан көн, аннан атналар да үтеп китте. Кояшка карап яткан Кызлар Убасының бите кардан арынды, түбәдән тамчылар тама башлады. Әмма борчылып, түземсезлек белән көткән кеше кайтмады да кайтмады. Аны җир йоткандай булды.

Вакыт үтә торды, Хәйрүшне милиция дә эзләп таба алмады.

Көмешлесу авылы халкы арасында да имеш-мимешләр арта барды. Алар берсеннән-берсе артыграк, искитмәлерәк була башлады. Баштарак Хәйрүш турында «дезертирларга кушылып, тайгада йөри икән» дигән сүз таралды. Ана икенчеләре өстәлде. Имештер, Хәйрүшнең итек олтырагы астында яшереп салып куйган чит ил паспорты булган икән. Шуның белән ул Алмания якларына качкан, ди. Анда сугышта ире үлгән бер хатын белән никахсыз гына яшәп ята икән. Хәбәрләр, имеш-мимешләр торган саен арта-кабара барды. Кайберәүләр аны, әтисе вафат булгач, Кавказ ягыннан килеп чыккан сәүдәгәргә ияреп киткән әнкәсе янында, таулар арасында качып ята икән, дип тә сөйләделәр. Ни булса да булды, Кәрбек Хәйрүш кабат туган якларында күренмәде. Аның кайда булуын, кай якларга олагуын беркем дә төгәл генә әйтә алмады.

Районда алдынгылыкны алган «Урак-чүкеч» колхозының рәисе Хәйрүш Хәйбулловның тиктомалга юкка чыгуы һәм милициягә килгән шикле хәбәр район житәкчеләрендә генә түгел, хәтта өлкәдә дә ыгы-зыгы кубарды. Ашыгыч рәвештә Кузьмичев белән Кызылбаевны өлкә партия комитетына чакыртып алдылар һәм кинәйтелгән бюро утырышында карадылар. Анда инде Хәйрүш, ягъни Хәйретдин Хәйбуллов кылган явызлыкларны тикшереп белгәннәр иде. Кызылбаевны күп еллар аның белән арадашлык иткәне, район партия комитетының пропаганда бүлеге мөдире буларак, халык арасында аңлату-тәрбия эшен алып барасы урынга, мораль яктан череп таркалуы, юк авыруны сылтау итеп фронтка китмичә симулировать иткән, ягъни сугыштан качып яткан өчен партиядән чыгарырга, эштән куарга һәм шундук кулга алып, судка бирергә, дип карар чыгарылды. Аның урынына фронтовик Лосевны билгеләделәр. Райкомның беренче секретаре Кузьмичевка районда һәм үз аппаратында кадрлар белән эш алып бармавы, сәяси сукырлыгы, гамьсезлеге өчен каты шелтә чәпәделәр. «Мине дә Кызылбай белән бергә бәйләп, аның юлыннан озатмагайлары», дип, эченнән куяндай куркып утырган Кузьмичев каты шелтә белән котылуына чиксез куанды.

Бу хәбәрләрнең чын икәнен раслап Көмешлесуга язгы чәчүгә хәзерлекне жайга салырга әлеге Кызылбай урынына вәкил булып Илларион Лосев килеп житте. Колхоз жыелышын чакырып, райкомдагы үзгәрешләрне аңлатты, халыкны бердәм эшкә чакырды. Язгы чәчүгә орлык табып бирүне оештырды һәм бик өзлеккән гаиләләргә район фондыннан аз-маз булса да азык-төлек юнәтте...

Авыл умарта оясыдай гөжләп торды да, әкренләп тынды. Хәйрүш язмышы телләрдән төште. Бары тик Өннәш кенә иренә сиздермәстән, «Чынмы бу?»—дип Кызылбай турында иснәнеп, Хәйрүш өчен тирән кайгыга батып, торадан бушка йөреп кайтты. Әзенә-юлына төшә алмады. Авыл тынычланып, тынчык һавасы чистарып, күк йөзе калын болытлардан арынгандай булды. Әйтерсең күбәүләрнең күкрәкләрен кысып, сулышларын буып торган тимер кыршау шартлап өзелде. Сулыш юллары киңәйде...

Силиннан чакыру телеграммасы килеп төшүгә, Көмешлесудан бер төркем юлга чыкты.

Полковник Силин Себер кунакларын жылы сүз, ачык йөз белән каршылады. Килүчеләргә концлагерьдагы яшерен антифашистлар оешмасының эше турында бәян итте. Абдуллин белән ничек танышуы, нинди эшләр йөкләве хакында сөйләде. Аның фашистлар кулыннан котылып кайткач та, совет лагерена эләгүенә чын күнеленнән гажәпләнде.

—Әйе, бу сугыш елларында әллә нинди буталчыклар да булды шул. Аның һичбер гаебе юк икәнен белсәк тә, раславы жинел булмаячак...—диде ул, уйга батып. Күрәсең, үз тормышында мондый хәлләрне күреп, авызы житәрлек пешкән иде аның да.

Зиннур Абдуллин «эш»ен янадан башладылар. Килүчеләрнең һәрберсеннән жентекләп сорау алдылар. Зиннурның хатларын, Айварның рәсемнәрен, авыл халкының куллар куелган үтенечен теркәделәр. Полковник Силинның күрсәтмәләре аеруча зур әһәмияткә ия булды.

Эш җайлана башлагандай булды. Тик менә соңгы хәбәр юлчыларны тагын кайгыга салды.

— Абдуллинның авылда партиягә каршы агитация алып баруы хакындагы шикаятькә килеп төртелгәч, эш тагын тукталды,—диде Силин.

Бу хәбәр аеруча Нуриягә каты килеп бәрелде. Инде котыла, инде кайта, дигән өметләре уянгач кына, тагын юллары аерыла микәнни? Ана бу минутларда аңлатып бетергесез авыр иде.

—Елап кына эшкә ярдәм итеп булмый, сенелем, безгә Абдуллинның гаепсез булуын расларга, исбатларга кирәк. Шикаять үз вакытында тикшерелгән бит, шуның йомгак документлары кирәк,—диде полковник сабыр гына. Аның эшне белеп, чын күңеленнән ярдәм итәргә тырышуы, тагын да өзелергә торган өметләрне ялгарга ярдәм итте. Нуриянең күз аллары яктырып, аны чистарып киткәндәй булды:

—Ул шикаятьне мәгариф министрлыгыннан Шпитальник исемле олы кеше җитәкчелегендәге комиссия тикшерде бит. Ул иптәш Мәскәүдә генә яши. Шушы кешене табып, хәл итеп булмасмы икән бу мәсьәләне?

Мәгариф министрлыгына чылтыраттылар. Ләкин хәл ачыкланмады. Иптәш Шпитальник вафат, ә архивларның күбесе сугыш вакытларында күчереп йөрткәндә югалган. Документларны тиз генә табып булмасын хәбәр иттеләр.

—Тубыл шәһәре сугыштан ерак тылда булды бит. Бәлки, ул документ үзегездә табылыр?—дип сораулы карашын аларга төбәде Силин.—Хәзер кайтып, шуны эзләгез, бөтен өмет шул кәгазьләрдә. Тапсагыз, кичектермичә хәбәр итәрсез.

Эшне ярты юлга җиткереп, Көмешлесуга кайтты алар. Бу документны кайдан эзләргә мөмкин булуы хакында баш ваттылар. Шунда Нуриянең кылт итеп исенә төште: ул кәгазь бит Зиннурның үзендә үк саклана лабаса!

Фәтхулла абзыйларына йорт эшләрендә булышып йөргәндә, берчак Ниязбикә әби анардан сандыгындагы кәгазьләрне караштырып, тәртипкә китерешүен үтенде. Ул үзе русчаны укый белми, шуңлыктан улының кирәкле кәгазьләрен югалтып куймыйм дип курка иде. Нурия шунда мәктәп эшенең планнары, Зиннурның институтны тәмамлаган дипломы, көндәлекләр һәм шул документны да үз кулы белән җыеп куйган иде лабаса! Ничек әлегә кадәр исенә килмәгән соң ул? Кәгазь зур гына булып, анда комиссия әгъзаларының йомгак сүзләре, Зиннурның гаепсезлеге һәм яла ягучыларны судка бирергә хокукы булуы да күрсәтелгән иде.

Таң атканын Нурия түземсезлек белән көтеп алды. Айварны уятып, Фәтхулла абзыйларга атлап түгел, йөгереп килделәр. Боларның иртә таңнан ук кубарылып, сулышлары кабып, килеп керүенә картлар аптырап калдылар.

—Яхшымысыз.

—Исәнме, Нурия кызым, Айвар улым. Бер-бер хәл булдымы әллә? Бик ашыгыч йомышыгыз бармы?

—Йомышыбыз шул, Ниязбикә әби: Зиннур абыйның әлеге китап, кәгазьләрен салган сандыгы кайда хәзер?

—Өске йортта түгелме соң?

Анда хәзер берәү дә тормый. Утын күп китә дип, кышны аскы йортта гына үткәрде картлар. Ниязбикә әби дә каударланудан ачкычны таба алмыйча интекте. Нуриягә хәзер минуты ай иде. Кабалана торгач, корткаяк матча ярыгыннан ачкычны табып бирде. Тегеләр ике баскычны бер атлап, өскә очып менделәр. Гадәттәгечә кеше тормаган йортта дымлы, тынчык ис борынны ярып керде. Улларының язмышын хәл итәргә тиешле әлеге хикмәтле сандык почмакта моңаеп кына утыра иде.

—Инде кабаланмыйк, Айвар. Җентекләп карыйк.

Сандыкка төрле-төрле кәгазьләр, дәфтәрләр салынган. Документлар иң аста булырга тиеш. Үзе таслап, рәтләп куйган кәгазьләр барысы да үз урынында иде. Инде саргая төшкән кирәкле язуны тапкач, Нурия шатлыгыннан кычкырып җибәрде:

—Менә ул!—Икесе дә әлеге кәгазьгә төбәлделәр.—Шул инде, шул. Зиннурның бәхетенә сакланган булса иде.—Кыз аны тагын бер кат карап, күкрәгенә кысты. Эшнең нәрсәдә икәнен әлегә кадәр төшенмәгән карт белән карчык икесе берьюлы:

—Ул нинди гаҗәеп әйбер соң, балам?—дип Айварга мөрәҗәгать иттеләр.

Нурия бу минутларда бернәрсә дә аңлатырлык хәлдә түгел кебек күренде аларга, әнә бит кычкыра, үз-үзенә сөйләнә. Айвар да аннан артык түгел иде:

—Бу хикмәтле кәгазь сезнең улыгызны җәһәннәм төбеннән тартып алачак. Хәер-догада булыгыз. Хәзергә хушыгыз!—дип, ул Нурия апасы артыннан калмаска тырышты.

Нурия ун көннән соң Мәскәүдән җир-күкләргә сыймаслык шатлыклы хәбәр алып кайтты. Поездны төшеп этәрлек, янышнан йөгереп кайтырлык хәлдә иде ул. Булдырдылар бит! Йөргәннәре, тырышканнары бушка китмәде, өметләре өзелмәде болай булгач! Зиннур Абдуллин гаепсез дип табылган, реабилитацияләнгән. Гвардия капитаны исемен кире кайтарып, барлык орденнарын да яңадан бирергә карар чыгарылган икән. Алай гына да түгел, үзенең педагогик эшенә кайту хокукы бирелгән. Боларның барысы турындагы карар Колымага, лагерь башлыгына да җибәрелгән. Инде ул үзенең туган якларына әйләнеп кайтырга тиеш. Хәбәр Нуриянең эченә генә сыймый, аны йөзеннән, күзләреннән, иреннәреннән үк укырга мөмкин иде. Хәбәр бөтен авылны аякка бастырды, телләрдә аның исеме генә булды. Дуслары, якыннары түземсезлек белән кайту көнен көттеләр.

Нурияләргә шул көннәрдә генә бер кунак килеп төште. Ул Конда леспромхозы житәкчесе Сәлим Алкин иде. Алар барысы да Зиннур эше белән янып йөргәндә: «Нурия, мин сезгә килмәкче булам»,—дип язган хатларын алган иде алуын. Бу сүзләрнең нинди мәгънә белдерүен бик яхшы аңласа да, кыз хатларны җавапсыз калдырган иде. Кайгысы анарда түгел иде ул чагында. Менә хәзер ни әйтергә инде мона?

Алкин дигәне чем-кара күзле, уртача буй-сынлы, күрер күзгә мөлаем гына егет иде. Сугышның башыннан ахырынача тырышып эшләгән житәкче үз машинасына утырып килгән икән. Егет артык тартынып, сүзне озакка сузмыйча, кызның әти-әнисенә үз ниятен белдерде. Ул чая, үткер, әйткәнен үти торган кешегә охшаган иде. Бер уңайдан хуҗаларга бүләкләр, азык-төлек, хәтта затлы моксын, щекур[1] балыклары да салып килгән икән. Өч көн буе әнкәсе кызын күндерергә тырышты.

—Юньле адәм басмаган Колымаларда йөргән Зиннурны көтеп утырганчы, Ходай үзе юллаган егеткә чыксаң, ни була, кызым?—дип рәнжеп, күз яшьләрен дә сөртте.

Тик кызының җавабы бер иде:

—Менә-менә сөйгән егетем кайтырга торганда, мин ничек кияүгә чыга алыйм инде, әнкәй?—диде ул.—Үзем йолып алдым бит мин аны. Күпме көткәнем—күз алдында. Ташларлык булсам, болай көтмәгән дә булыр идем.

Сәлим дә риза булып кайтып китәргә ашыкмады. Сөйгән кызын ничек булса да алып кайтырга тиеш ул. Иптәшләре алдында да мактанып сөйләргә өлгерде бит. «Бәлки, урлап китәргәдер?»—дип уйлады ул, бер фикергә килеп. Шул ният белән, кызны машинасында авыл буйлап әйләндереп килергә күндермәкче булып та карады. Сәлимнең күзләре очкынланганны, уйларының чагылышы күзләрендә ялкынланганны абайлап, кыз баш тартты. Шулай булса да бирешергә теләмәде.

—Мин барыбер синсез кайта алмыйм, Нурия,—диде ул, ниятен яшереп тә тормыйча.

Вакыйгалар катлауланып кына барганда, рәхмәт төшкере күрше

[1]Моксын, щекур—Иртешкә Обь елгасыннан керә торган затлы балыклар.

малае Тимербай килеп керде. Малай ни өчендер бишмәте өстеннән чәчәкле-юлаклы күлмәк кигән иде. Ишек төбенә кереп басты да айнын унбишенче кичәсе кебек балкып тора башлады. Нурия апасынын үз хәле—хәл, күзенә ак-кара күренми иде. Әле дә ярый, Хәлимә апа эшне аңлап алды:

—Ай-һай, Тимербай баламның яңа күлмәге бар икән гуй, бигрәк матур инде!—диде ул, малайның күлмәген сыйпаштырып.—Кайдан алганнар икән мондый матур күлмәкне?

—Өннәм ыштаннан тегеп бирде,—диде тегесе, бөтен йөзе белән балкып.

Барысы да шаркылдап көлеп җибәрделәр.

—Бигрәк матур икән шул, байгасы[1] бирергә кирәк улыма.—Хәлимә апа бер йомырка алып, аңа тоттырды. Нурия апасы да малайга бер сум акча бирде. Тимербай, рәхмәтен әйтеп, ялт итеп чыгып та китте.

Өйдәге киеренкелек кими төшкән кебек булды. Тимербай япкан капкадан укытучы Фәридә килеп керде. Нурия әллә кайчан Сәлим турында әйтеп, кызның күңеленә бер уй салып куйган иде. Инде хәзер белмәмешкә салышып кына керде. Нурия, үзе чакырганны сиздермичә генә, кунакны укытучы кыз белән таныштырды. Сәлим бер дә сүзгә аптырап тормады, сөйкемле елмаеп:

—Белмәгәнмен, Көмешлесуда икән кызларның сылулары, унганнары,—дип, Фәриданең кулын кысты.

—Без дә белмәгәнбез, егетләрнең асыллары, байлары тайгада, баһадир кедрлар арасында, ышыкта үскәннәр икән,—диде Фәридә дә, егеткә туры карап.

Дус кызының егетне бер күрүдә үк ошатканын Нурия шундук сизде. Сәлим дә моны аңлады, игътибарын кырыс холыклы Нуриядән сабыр холыклы, чибәр булса да, тыйнаграк Фәридәгә борды. Хуҗабикә дә аларны ялгызларын калдырып кереп-чыгып йөрде.

Монда кереп чыгуына бер-ике сәгать тә үтмәгәндер, әлеге ташбаш Тимербай тагын чабып килеп керде һәм керә-керешли үк хәбәр дә салды:

—Сөенче, Зиннур абый кайтты!

—Ә-ә?!

—Торадан Зиннур абый кайтып төште!

Өстәл янында йөргән Нуриянең кулыннан агач табагы төшеп, идән буйлап тәгәрәп китте. Кунаклар икесе дә аңа төбәлде, тегесе кая барып, нәрсәгә тотынырга белмичә өй буйлап йөрде-йөрде дә, әле генә әйтелгән сүз акылына барып ирешкәч, ишектән чыгып йөгерде. Сәлим бөтенесен аңлап алды. Нурия артыннан кузгалган Фәриданең кулыннан тотып:

—Фәридә, акыллым, сабыр ит, кайтмый тор. Сине үзем озатып куярмын,—дип, кызның күзенә томырылып карады. Тегесе дә егетнең көче сизелеп торган кулыннан ычкынырга ашыкмады. Ягымлы гына елмаеп, ризалыгын белдерде.

Нурияләрдән алар бергә чыктылар. Сүзсез генә берсен-берсе аңлады алар. Икесе дә шушы минутны, шушы очрашуны көтеп яшәүләрен тойдылар. Шул кичтә Сәлим Фәридәгә тәкъдим ясарга да өлгерде. Фәридә Сәлимне үз итте, бер күрүдә үк яратты дисәк тә, хата булмас...

Нурия өйләреннән ничек чыгып китте, Фәтхулла әкәләренә шулай бәреп керде дә, сөрлегеп, туктап калды. Алдында басып торган ят та, үз дә булган кешедән күзен ала алмады. Кыз килеп кергәндә әти-әнисен күкрәгенә кысып торган егетнең йөзе балкып китте. Менә ул бер-ике адым Нуриягә таба атлады да, ике кулын сузып, сөеклесенең күзләренә туры карады:

—Гомерем буена сиңа бурычлымын, Нуриям. Миңа ышануын, мәхәббәтең, тугрылыгын, сабырлыгың гына мине ул җәһәннәмнән коткарды. Рәхмәт сиңа!

---

[1]Байгасы—яңа киемне котлап бирелә торган бүләк.

Бер мизгелгә катып калган кыз да, исенә килеп, сөйгәненә талпынды, аның күкрәгенә башын салды. Егетнең әткә-әнкәсе аларга туры карап оялтмаска тырыштылар, шул тирәдә бөтерелеп, ни эшләргә белмәделәр.

—Нурия, Нуриякәем, сине күрер көннәрем дә бар икән! Шушы минут өчен генә дә гомеремне бирергә әзер торган чакларым аз булмады. Ходаем, дөрестән дә бу төш кенә түгелме?

Алар исләренә килгәләгәнче, өйгә бер-бер артлы күрше-күлән, туган-тумача, укытучылар, укучылар кереп тулды. Барысы да Зиннур абыйларын күреп, шатлыкларын бүлешергә ашыктылар.

Зиннур олыгайган, күзгә күренерлек булып ябыккан, кулларының тамырлары да бүртеп, кабарып тора. Кырынмаган яңакларын төк баскан, кап-кара чәчләре чаларган, күзләре төпкә баткан. «Әйе, күрәселәрен күргән безнең мөгаллим,—дип уйлады авыл агайлары.—Күрәчәкләре күп булган икән бахырның».

Шау-гөр килеп торган өй бер минутка да бушап тормады. Берәүләр керде, икенчеләр чыкты. Алар арасында Айварны күрермен дип һич уйламаган иде Зиннур. Озын буйлы, чандыр гәүдәле егет абыйсына сабыр гына якынлашты, олыларча кулларын сузган иде, түзә алмыйча, үзе үк кочаклап та алды. Абыйсы егетне аркасыннан какты, гаҗәпләнеп, бер ана, бер Нуриясенә карады. Яңалыклар арты яңалыклар, аларның бүген очы да, кырые да булмас кебек иде...

Хәбәрләр төн буе сөйләшеп тә бетмәслек булды. Фронтовиклар, замандашлары кереп, төн буе сөйләшеп чыктылар. Кузайтынга керүчеләр үзләре белән алып килгән ризыкларын өстәлгә сала тордылар. Барысына да җитәрлек булды. Тирә-күршеләр, авылдашлары Зиннурның авызыннан күзләрен алмады. Күргәннәре дошманга язмасын икән. Исләре китеп тыңладылар. Үзләренең күз алдында үсеп кеше булган, укып белем алган, сугышның башыннан ахырына кадәр илне саклауда җанын да кызганмаган мөгаллимнәренең язмышына шулкадәр сынаулар төшәр дип кем уйлаган?! Бу төнне Зиннурның якыннарыннан берәү дә йокламады...

Нурия белән Зиннурның бер генә минутка да аерылышыр исәпләре юк иде. Әткә-әнкәсе, улларының уен сизеп, читкәрәк китеп, киңәшләшеп тә алдылар. Керүче-чыгучылар таң алдыннан гына таралышты. Азрак кына черем итеп алгач, өй эче янадан купты. Әнкәсенең мунчасы улы уянуга өлгергән иде, Зиннурны хуш исләр чыгып торган каен себеркесен тоттырып, бакча артына озаттылар. Мунча кереп, өйалдына чыгып утыргач, ул үзен янадан тугандай тойды. Шунда гына тормышның гүзәллеген, яшәүнең ләззәтен татыды. Инде кайчан керелгәнлеге дә онытылган мунча, өскә өелгән кат-кат керне генә түгел, бөтен күргәннәрне, кешелеген изгән концлагерь истәлекләрен юып алгандай булды. Җилкәләрен басып, җиргә индергән авырлыклар төшеп, иңнәренә канат үскәндәй тойды. Туган җирнең сулышы изге, шифалы, диләр. Чыннан да шулай, ахры. Әнә, өйгә бер кереп, бер чыгып әнкәсе йөри, сыер абзары тирәсендә әткәсе мәш килә, күршеләрендә генә Нуриясе кулларына ни алырга, үзен кая куярга белмичә, эченнән генә яраткан көен көйлидер. Күнелгә якын, газиз күренешләр. Шуны тою, аңлау өчен генә дә шулхәтле сынаулар үтәргә кирәк булды бит ана, шулхәтле сынаулар... Зиннур бермәлгә бугазына төелгән күз яшьләрен йота алмыйча азапланды, тагын бер кат тирән итеп сулыш алды да өйгә атлады.

—Кайтып та киләсенмени, балакаем? Пары әйбәт булдымы, эссесе житәрлекме?—дип элеккегечә үк каршы алды әнкәсе.

Зиннурга шундый рәхәт, җинел булып китте, гүя шушы биш ел гомер бөтенләй булмаган да. Әнкәсе, әткәсе дә шул ук, абзарда мөгрәгән сөтлебикәләре дә үзгәрмәгән кебек. Юк шул, барысы да башка, үзгә хәзер. Әнә әткәсенең төз генә чандыр гәүдәсе иелгән, беләзекләре тагын да нечкәргән, аяк атлаулары сабыр-салмакланган. Әнкәсенең башында бер бөртек тә кара чәче калмаган, күз тирәсендәге җыерчыклары тирәнәеп, маңгай сызыклары белән тоташкан. Тик күзләрендәге иман нуры гына

шул килеш, бер үзгәрешсез дә, куллары һаман тик торуны белми. Аннары... аннары үзенең тугры дусты—Актүше юк. Капка баганасы бөтенләй бер якка кыйшаеп, капка ачылганда һавага асылып куйгандай була. «Әзрәк хәл алсам, капкасын да, ихатаны да иплисе-сиплисе булыр»,—дип уйлады ул нәкъ теге вакытта, институт бетереп, печән эзләргә чыгып киткәндәгечә итеп.

Чәйне матчага кыстырып куелган чыра каскакны алып кабызган утта кайнаттылар. Авыл гадәтенчә, сугышка киткәндә Зиннурны озатып керешли әнкәсе үзе аны алып кереп, шунда кыстырып куйган иде. Юлга китүче булганда, һәр йортта, шундый гадәт монда. Каскак юлаучыны көтеп, еллар буе матчага кысылып тора. Беренче учакны, иясе ерак юлдан кайткач, шуның белән кабызалар. Чәй янында уллары көтелгән сүзне башлады:

—Әткәй-әнкәй, сез безнең теләкне беләсез инде. Нурия белән дә шулай килештек: озакка сузмыйча, өйләнешергә уйлыйбыз. Болай да күпме гомер әрәмгә узды. Сез каршы килмәсәгез, күршеләрегезгә кереп, Нуриямне сорап чыгуыгызны теләр идем мин. Калганын күз күрер.

Хәбәр шаккатарлык булмады. Картлар үзләре дә бу шатлыклы көнне ни гомер көтteләр бит.

—Ходайга тапшырып, барырга кирәк!—соңгы сүз шундый булды.

Никахны бердәнбер улларына Фәтхулла карт үзе укыды. Кычкырып әйтелмәсә дә, Көмешлесуда әле моңа кадәр тормышны никахсыз башлаган кеше юк иде. Нурия белән Зиннур да картлар теләгеннән өстен булмадылар.

Кичкырын ярлы гына туй табыны янына аларның дус-ишләре, якыннары җыйналды. Хуҗалар яшәреп киткән кебек, җинел-житез ике арада йөренеп тордылар. Ниязбикә әбинең дөньясы түгәрәкләнде. Бер көн эчендә өстенә яуган бәхет-куанычлардан җиде кат күктә йөзә иде ул. Үзе бертуктаусыз сөйләнә:

—Баламның кайтмасына, югалып калуына бер минут та ышанмадым, аның уттан-судан исән-аман чыгарына иманым камил иде. Алламнан көн саен, сәгать саен мәрхәмәт, шәфкать сорадым. Уклар яуганда да фәрештәләр үзләре канатларын җәеп саклаганнар улымны.—Узган саен улы белән киленен бер тин аркаларыннан кагып, иркәләп китә карчык. Шунда ашыгыч бер нәрсә исенә төшкәндәй, кече якка юллана. Үзенең бик кадерләп җыеп куйган нәрсәсен оныткан икән ич ул! Карчык калтыраган куллары белән кашлыктан кармалап, Зиннуры киткәндә каптырып, теш эзләрен алып калган ипи кисәген табып ала. Инде катып, сохарига әйләнеп беткән чәйнәмәне кадерләп табынга алып килә.

—Менә, балам, оныта да язганмын. Синең кайтуынны теләп өйдә көткән ризыгың. Бисмилла әйтеп кап, Ходаем тагын сәфәр китәргә, әлегә кадәр күргәннәрне күрергә язмасын. Ризыгың өзелмәгәнгә исән-сау кайта алгансың бит, балакаем.

Яшьләр бер кисәк сохарины да икесе бүлеп каптылар. Чаппар әкәләре әйтеп тә тормастан үзе белән бер мәжлестән дә калдырмый торган гармунын тартып, «Турчай» көен сузып та җибәрде.

Кечкенә турчай баласына
Сикереп лә менмән, биле аурыр.
Кыз бала сезгә, әй, кунактыр,
Авыр сүзләр әйтмән, яне аурыр.

Ак куян кача кыр белән,
Яна яуган йомшак кар белән.
Ахирәт күрке иман белән
Дөнья күрке сөйгән яр белән.

Туйның сые бик муллдан булмаса да, заманасына күрә уразасы, дигәндәй, һич гаепләүче булмады. Аштамыни эш башы?! Яшьләр өчен куанып, теләк теләп утыруларга ни житә? Аннан сон туй йолалары белән күркәм бит ул! Өстәл артыннан торуга, яшь кияү белән киленне сәке кырына алып килделәр. Фәтхулла абзый белән карчыгы яшьләр каршына басты. Кайнана сәкегә йөгенеч ястыгы салды, гадәт буенча яшь килен аңа тезләнеп ике тапкыр башын тидереп йөгенде. Ниязбикә

әби ястыкны янадан кулына алып, изге теләкләр теләде һәм килененә тапшырды. Яшьләр һәр Ходай бирмеш көн саен ул ястыкны баш асларына салырга һәм бүгенге көнге антларын исләренә кабат алырга, әчтән кабатларга тиешләр: «Олыларга һәрчак шәфкатьле, мәрхәмәтле, итәгатьле булырбыз. Бер-беребезне сәламәт чакта да, авырганда да, кайгыда да, шатлыкта да ташламабыз. Амин!»

Нуриянең янында гына бөтерелгән Фәридәнең дә бәхете йөзеннән күренеп тора иде. Дустының бәхетенә сөенде ул, аның аркасында үзе дә бәхете була алырлык кешене тапты. Гармун көенә төйдереп биеде укытучы кыз, идән уртасын тутырып тыпырдаучыларның берсен дә уздырмады. Гармунын йә баш очына күтәреп, йә күкрәгең киереп уйнаган Чаппар әкә дә аякларын тыпырдатырга өлгерә, кулларына күз иярми иде. Саубуллашыр алдыннан кунаклар яшьләр өчен чыбылдык корылган өске катка күтәрелделәр. Яшьләрдән алда, йола буенча, түшәктә авылдагы иң тату гаилә корып яшәүчеләрне аунатырга тиеш иделәр. Бу хөрмәт Чаппар әкә белән Апака әбәгә тиде. «Утау басу» дип аталган бу йоланы Нәбүбәһәр җиңгәләре үтәде. Яшьләргә тагын теләк теләнде: алар да шушы матур гаилә үрнәгендә тигез-тату гомер итсеннәр, балалар үстерсеннәр, бу кешеләрнең йөзенә кызыллык китерерлек булмасын! Алардан соң чыбылдык астына Нурия белән Зиннурны кертеп утырттылар. Икесенең башын бер шәл белән ябып, өсләренә эрбет чикләвеге сиптеләр. Сугышка кадәрге вакытларда аны борчак кәнфитләр белән аралаштыралар иде. Хәзергә бусы да бик шәп булды. Туй карарга җыелган бала-чаганы кияү чикләвеге җыярга керттеләр, өлеш тимәгәннәренә янадан өләштеләр.

Тал бөреле, тал бөреле
Тал бөреле була ул.
Җан яраткан, күңел тарткан
Яр бер генә була ул.

Яшьләрнең яңа тормышка аяк басулары шул рәвештә булды. Күңел ачып, сугыштан соңгы беренче туйны шулай үткәрде халык. «Менә инде чыннан да сугыш бетте, болай булгач»,—дип уйлады күпләр. Туй төн уртасында гына таралышты... Биш ел элек Нуриянең тормышына жилдавыл булып килеп кергән Зиннур бу олы шатлыктан исереп, бәхетенең олылыгына ышанмыйча, сөйгәненең ут-ялкын кабынган кочагына чумды. Алар чиксез бәхетле иделәр.

Бу тамашаларга иң куанган кешеләрнең берсе—Айвар иде. Йортта үз булып өлгергән егет мондагы уен-көлкене, йолаларны исе китеп карады, кирәк урында булышырга йөгереп йөрде. Бу гаиләдә ул янадан үзе югалткан күңел җылысын, гаилә бәхетен тапты. Зиннур абыйсы аңа туган абыйсыннан да якынрак иде. Аның өчен ут-суларны кичәргә әзер торган Нурия апасын да чын күңеленнән яратты. Әйе, Зиннур абыйсының юлдашы, сөйгәне нәкъ шундый булырга тиеш тә кебек иде аңа. Абыйсы нәкъ шундый мәхәббәткә, тугрылыкка лаек!

Туй узгач ул барысын да шаккатырды.

—Зиннур абыйны эзләп килгән идем, инде сезнең барыгызны да таптым. Сезнең бәхетегезне күреп, шат күңел белән китәмен. Кайтыр юлга әзерләнергә кирәк,—диде.

Инде бер айга якын үзләрендә яшәгән бу үз яшьләреннән күпкә олырак күренгән сабыр холыклы егеткә үз балаларыдай күнеккән картлар бу сүзләргә аптырап калдылар. «Китәргә? Шулай тиз генәме?» дигән сораулы карашларын уларына текәделәр. «Син нәрсә әйтерсең мона?» дип сорый иде аларның күзләре.

—Айвар, без синең белән бергә ут-суларны кичтек. Син булмасаң, бу кайту юлы күпкә озынрак булыр иде. Зур рәхмәт сиңа!—Зиннур абыйсы күзләрен тутырып аңа карады. Аның яшькелт күзләрендә аерылу моңы, яшенә туры килеп бетмәгән сагыш бар иде.—Айвар, син инде олы кеше, үз язмышыңны үзең хәл итәргә тиеш. Әтиең сугыштан

кайтмаган, әниен, сенелләрен фашист самолетлары шәһәрегезне бомбага тотканда вафат булганнар. Йортыгыз җимерелгән... Менә нәрсә әйтәсем килә сиңа, Айвар энем,—Зиннур кулын Айварның җилкәсенә салды,—менә нәрсә, кал бездә генә. Әти-әниләрем дә сиңа үз балалары кебек күнеккәннәр, Нурия апаң да каршы килмәс. Энем булып яшәрсең, укырсың, эшләрсең. Йә, ничек уйлыйсың?

—Чын, Айвар,—дип элеп алды Нурия дә,—без синең белән инде туганлаштык та, Мәскәүгә дә бергә барып килдек. Йә, ризалыгыңны бир инде.

Фәтхулла абзый белән Ниязбикә әби дә «э-э, э-э» дип башларын каккаладылар. Моны көтмәгән егет күзләрен тутырып аларның һәрберсенә тагын бер кат карап чыкты. Куанычыннан һәм күңеле тулудан бермәл ни әйтергә белмичә торды. Аның үзенең дә бу ягымлы, эчкерсез кешеләрне калдырып, билгесезлеккә чыгып китәсе килмәгән иде. Авыл кешеләре дә үзләреннән аерылып торган сап-сары чәчле, сөйкемле бу егетне чит итмәделәр. Барысы да якын күреп, «балам» дип кенә эндәшә. Айвар үзе дә монда Зиннур абыйсын, аның тәрәген эзләп килмәдемени? Аның эчке теләкләре абыйсының авызыннан сүзләр булып яңгырагач, барысы да аңлаешлы, шулкадәр гади булды да калды. Әйе, ул монда калачак!

Өстәлләр җыеп алынганны гына көтеп торгандай, ишектән үзе белән бер кочак мәрхәмәт, эчкерсезлек алып Әхмәдүш килеп керде.

—Чөкердәшеп чәй эчеп утыралар, димме боларны? Әйдәгез, атлар, яшьләр көтә сезне. Иң әүвәле авыл советына барып, язылышасыз, аннан күч күчерәбез,—диде ул, үзен хуҗаларча тотып.

Тиз генә җыенып, яшьләр чәнгелчек арбаның түренә балкып чыгып утырдылар. Айвар алардан да алда икенче аттагы яшьләр арасына чумган иде. Тагын гармун тавышы, тагын шау-шу, җыр, музыка бөтен авылны аякка бастырды. Совет йорты бу кадәр халыкка тар булып калды. Балдыз кыз булып Фәридә кул куйды, аның янында гына Сәлим елмаеп тора. Ул Нурия белән Зиннурны чын күңеленнән котлап, кулларын кысты.

—Нурия, рәхмәт сиңа, син булмасаң, мин үз бәхетемнең кайда адашып йөргәнен дә белмәс идем,—диде ул.

Нурия дә дусты өчен шат иде. Никадәр моңсу кичләрен бергә үткәрделәр, никадәр күз яшьләрен бергә түктеләр. Кайгылары уртак булган кызларның бәхет-шатлыклары да бергә булган икән. Эх, алданрак белеп торып булса икән моны! Икесенең бәхеткәйләре тулып-ташкан көнне дә кызлар бергә каршылады.

Ә күктә ундүртенче кичәсе тулган ай елмая. Ай аларга, җир кешеләренә өстән сөенеп карап, болытсыз күктә нур чәчеп йөзә дә йөзә. Көнчыгыштан сирпелә башлаган таң нурлары чал Иртеш өстен, эрбет ябалдашларын сихри бер төскә кертеп, җир өстенә яңа тыныч көн туып килүе хакында хәбәр сала...



# Әхмәт Рәшит

## УРТАК БУЛСЫН ГАМЬНӘР, БОРЧУЛАР

### И Ходаем, рәхмәтлебез Сиңа

Аллаһ әкбәр, дибез,—Алла бөек—
Ул бар һәм бер фәкать җиһанга;
Ул рәхимле, гадел, саф, шәфкатьле—
Һичбер нинди тиң зат юк Аңа.

Чөнки беркем Аны тудырмады,
Чөнки беркем Аннан тумады,
Ул гап-гади кеше заты сыман
Эзләп тапмады вә җуймады.

Фәрештәләр Аның әмерләрен
Армый-талмый йөри гел ташып,
Һәм Ул сеңгән безнең кальбебезгә,
Күкләр мөнбәреннән нур ашып.

Ул бар иткән барча җирне, күкне,
Утның, суның барын бар иткән;
Ул җәннәттә Адәм атабызга
Һава анабызны яр иткән.

Ул кодрәтле—һәм шул кодрәт белән
Шыта орлык, үсә үләннәр,
Һәм шул кодрәт белән ургып чыга
Салкын чишмә тирән-тирәннән.

---

ӘХМӘТ РӘШИТ *(1936)— шагыйрь, публицист; татар һәм рус телләрендә чыккан ун шигырь китабы, «Сөембикә», «Колшәриф», «Мөхәммәдъяр» поэмалары; «Беренче мәхәббәт», «Зәңгәр күлмәк» һ. б. популяр җырлар тексты авторы. Казанда яши.*

Һәм шул кодрәт белән күк йөзендә
Яшен яшьнәр, күкрәү яңгырар,
Һәм шул кодрәт белән исәр җилләр,
Төшәр карлар, явар яңгырлар.

Ул кодрәтле, әмма һәрчак гадел:
Кат-кат сынап адәм баласын,
Белеп тора булган нигъмәтләрдән
Кемнең ничек, күпме аласын.

Ул теләсә генә пәйда була
Җир йөзендә барча бәрәкәт,
Ул теләсә генә гәүдәбезгә
Тылсым булып иңә хәрәкәт.

Пәйгамбәрләр Җиргә җибәргән Ул,
Гыйбрәт итеп сиңа һәм миңа,
Һәм иңдергән изге китапларын
Камил булсын өчен бу дөнья.

Ислам дине безгә насыйп булган—
Рәсүлебез безнең Мөхәммәт—
Ирештергән өчен Аллаһ сүзен
Без укыйбыз аңа мең рәхмәт.

Бер гөнаһсыз яшәп булмыйдыр ла—
Без бит фәкать адәм баласы;
Намаз укып, тәүбә итеп кенә
Гөнаһларны йола аласың.

Сират күперләрен кичәсе бар,
Ахирәт бар—шуңа җыеныйк;
Гомерләрнең һәрбер мизгелендә,
И Ходаем, Сиңа сыеныйк.

* * *

Әй айкалды бу дөньялар—
Уңга, сулга чайкалды;
Әле ярый шул мәхшәрдә
Иман, рухым сау калды.

## Сeләү авылы бәетләре

Сeләү авылында сөлекле күл—
Бер коену анда ни тора;
Тәннәреңә кунса сөлекләре
Җилекләргә хәтле суыра.

Кешеләрне нужа дигән нәрсә
Пенза базарына китерә—
Сeләү халкы авыр заманнарда
Сөлек сатып кына көн күрә.

Кемгә дәва, кемгә шифадыр да,
Кызганыч бит кеше хәле дә—
Шул чорларны искә төшерептер,
Бәетләре елый әле дә.

## Китегез!

*Агыйделнең аръягында*
*Бер энәгә—бер сыер...*
(Шаян җырдан)

**Һәр чат саен кемдер разбой сала—**
**Суверенлык аңа ошамый;**
**Имеш, Мәскәү хәзер татарларга**
**Өстәл төеп өстән куша алмый.**
**Югыйсә бит әле тамагы тук**
**Һәм заманча тәти киемнән,**
**Эшләсә дә әпән-төпән генә**
**Калдым, ди ул, сукыр тиенгә.**
**Агыйделнең, имеш, арьягында**
**Бер инәгә сыер бирәләр,**
**Милләт диеп анда баш ватмыйлар,**
**Бәйнәлмиләл бөтен түрәләр.**
**Китегез соң, монда хөрти булгач,**
**Алтын ява торган төшләргә—**
**Адәм рәтле яшәр өчен ләкин**
**Анда да бит кирәк... эшләргә.**
**Китегез соң... урыс... яһүдме син,**
**Һәм иманын саткан татармы—**
**Аңларга бит кирәк ахыр чиктә**
**Илгә яный торган хәтәрне.**
**Сәрхүш Рәсәй һаман бәйрәм итә,**
**Матәм көне—атна аралаш;**
**Тернәкләнә алмас ахры инде—**
**Бар җиһанда аңа шул караш.**
**Бу бәхетсез илдә азмы-күпме**
**Татарстан—имин, нык—нигез;**
**Ошый икән—разбой кычкырмагыз,**
**Ә ошамый икән... китегез...**
**Китегез хет океан артларына—**
**Булсын җәннәт, булсын җәһәннәм,**
**Безнең эшкә генә тыкшынмагыз,**
**Юлыгызга сезнең ак җәймә.**
**Анда бәлки бәхетлерәк җирдер,**
**Рәхим итеп шунда китегез!**
**Китегез!**

## Төш күреп уянгач, төн уртасында язган шигырь

**И кара эт, кара эт,**
**Төшләремә кердең дә,**
**Бүлдең татлы йокымнан,**
**Һаулый-һаулый өрдең дә.**
**Ыржайткансың тешләрең—**
**Төштә тешләр идеңме?**
**Син ташлангач, мин әллә**
**Җебеп төшәр, дидеңме?**

**Мин тагын бер эт күрдем**
**Шул ук төштә—ак иде;**

Синдәй разбой салмады—
Колларымны ялады.

Бу дөньяның төсләре
Кара белән акмыни?!
Кара эт—кара язмыш,
Дигән сүзләр хакмыни?!

Без бу җирдә агын да,
Карасын да күтәрдек—
Язмышларны узарга
Әле гайрәт җитәрлек.

Ул кадәрле шашынма,
Шашынсаң үз башыңа;
Кара язмыш, читләп үт!—
Чәбә-чәбә, кара эт!

* * *

Кар-буранлы тар хәятта
Үтә көнем-төнем;
Җиргә төшкәнче боз була
Күз яшьләрем минем.

И сабый күңелле шагыйрь,
Шуңа китә исең!
Елаудан соң, йә, ни мәгънә—
Кем юатыр, дисең?

Дөнья салкын. Тирә-юньдә—
Боз бәгырьле җаннар;
Шигырь булып ак кәгазьгә
Тик ал каннар тамар.

## Гармунчы сөйгәнемә

Сызылып таңнар аткан чакта
Суза тальян гармуның.
Төннәр буе тыңлап ятам
Гармуныңның бар моңын.

Таң атканда кызлар күңеле
Нинди уйлар кичермәс?
Егет җырлар, сөям, дияр,
Кыз, сөйсә дә, сер бирмәс.

Өзмәсәнә үзәгемне—
Серне сизәр тын урам.
Болай да бит кочагыңа
Атылып чыгарга торам.

## Шигырь бәйрәме–2000

*Шагыйрь илне юатучы гына...*

Зөлфәт

Мин көткән идем бу көнне,
Бик көткән идем;
Исте җилләр, кичте көннәр...
Һәм хаклык җиңде.

Сөенер иде, мөгаен,
Тукай үзе дә;
Чөнки дөнья карый һаман
Шагыйрь күзенә.

Алданган чакта өметләр
Язмыш җилендә,
Бар гавамны юатыр зат
Тик шагыйрь генә.

Илгә хаким вә яугирләр
Ни бирә алды?
Табында гавам һәрвакыт
Өлешсез калды.

Дөньялар тулы зилзилә
Һәм илләр утта;
Ни генә булмыйдыр хәтта
Ошбу минутта?!

Кылыч күтәрсенме шагыйрь,
Җаннарны кыеп?
Шигырен кылыч итә ул,
Уйларын уеп.

Һәм изге антын яңартып
Йөрәге аша,
Мазлумнарның башын сыйпап
Яшәүгә дәшә.

Чын-чынлап аңласын өчен
Йөрәкне йөрәк,
Бу камил түгел дөньяга
Шагыйрьләр кирәк.



## Зиннур Хөснияр

# КЫШЛАГАН ҮГЕЗ

ХИКӘЯ

Көз керүгә аларның күп вакыты капка төбендә уза. Бер кат мал-туар карагач, авылда әллә ни эш юк. Көне салкын булса да, берәр сәгать вакытларын барыбер шунда уздыралар алар. Хәер, бу гадәт эшсезлектән түгел. Авыл кешесен эшсез дию дөреслеккә бик үк туры килеп бетми дә торгандыр. Үзен йортә алган пенсионерына хәтле күп итеп аяклы мал асрый бит аның. Көз житеп, жирләр туңдыруга, аны чалып, базарга алып чыга һәм шул рәвешле ел буе җан асрарлык запас туплый.

Капка төбендәге «җыелышта» әнә шул малларның һәрберсе телгә алына, кемнеке нәрсә һәм ничек ашый, суйганнан соң үгезнең арт боты күпме киләчәк—һәммәсе дә, үз җае белән, рәте-чираты белән, тәмләп кенә әйтелеп кителә. Анысыннан да бигрәк, суйганнан соң кем ни рәвешле һәм кайсы базарга илтеп сата—барысы энә күзеннән үткәрелә.

—Быел малай, үгезне үзем кайтып суярмын, диде.

Һәрвакыт каладагы малаен кыстырып сөйләүче Хәлил абзый башлап җибәрде. Малай—аның горурлыгы, мактанычы.

Ир-ат, Хәлил абзыйның каладагы малае турында сүз чыкса, тынып кала, дәшмичә тыңлап кына тора. Аның, минем малай, дип, авыз суы корытуына аз гына эчләре пошып, чак кына кытыклары да килә бугай. Имеш, анда гына малай, аның малае гына зур түрә янәмәсе!.. Әнә, Чәукә Шамиленең олы малае, район сабан туенда батыр калып, әр-яңа «Жигули»га утырып кайтты. Шамил абзаң да, берәр ай чамасы кәпрәеп йөргәннән соң, бүреген янә батырып киде, сүз саен «Жигули»ны кыстырмый башлады. Һәрнәрсәнең чамасы бар...

Хәер, Хәлил абзыйга да, аның түрә малаена да берәүнең дә үче юк,

---

Зиннур ХӨСНИЯР *(1961)—прозаик, «Таң ата да кич була», «Тәгәри китте язмышлар» һәм башка китаплар авторы. «Салават күпере» журналының һәм «Таһир+Зөһрә» газетасының чыга башлауларыннан (1989, 1997) баш мөхәррире. Казанда яши.*

ачулары да бик каты килми. Болай гына инде ул. Мактансын, горурлансын Хәлил абзый. Рәхмәт аның малаена, авыл башындагы җимерек күперне төзәттерде бит әле! Хәлил абзый үзе дә әйбәт кеше. Менә дигән мал врачы. Пенсиягә генә чыкты. Тирә-юньнең сарык тәкәләрен печүче дә ул иде. «Тәкә» дигән кушаматы да шуннан калды. Ә, гомумән, әйбәт кеше Хәлил абзый.

Капка төбендәгеләр сугымнар турында бик тәмләп сөйләшсәләр дә, бүтән елларда мал сатудан кергән акчаның нинди максатларда файдаланылачагы турында җентекләп сөйләшмиләр, бу хакта хәтта авыз да ачмыйлар, барысы да ләм-мим иде. Ә быел, быел авыл халкы мәчет салу эшенә керешмәкче. Быел сүзләр күп һәм аларның төрлесе булачак әле.

Хәлил абзыйның үгезе ике кыш чыккан. Узган кыш, февраль башында, яше тулды, хәзер бер яшь тә ун айлык үгез ул. Мунча бурасы хәтле. Атнага бер мәртәбә муенындагы тимер чылбырын өзмәсә, күнеле булмый ди. Тамакка да шәп, җиткер генә икән. Хәлил абзый үгезен бик хасиятли. Ул—аның мактанычы, горурлыгы, куанычы. Менә, малае кайтуга, бу атнада ук, муенына кызыл җеп салырга уйлап торалар әле. Быел ноябрь үтә дә салкын килде. Ураза кергәнче, үгезнең эшен тәмам кылу бик мәслихәт булачак, ди.

Хәлил абзый белән карчыгына ел әйләнәсе ашап торырга келәт хәтле үгезнең бер боты да җитеп ашкан. Калганын малаеның машинасына төяп җибәрергә исәп тота. «Базардан урыс суйган ит алганчы, мөселманныкы бит, натуральный». Шулай ди Хәлил абзый. Һәм бу аның җанын рәхәт кытыклап, күнелен җылытып тора. Үгез карау газаплары да, шул хәерсез хайван җәй көне очлы мөгезе белән төртеп сындырган кабыргалар авыртуы да онытылып тора.

Бүтәннәр мәчеткә дә өлеш чыгарырга уйлый. Хәлил абзый, Аллага да, муллага да ышанмаучы, дөньяви кеше буларак, андый исәпне күнеленә дә кертеп карамады. Малае да хупламас кебек иде аның бу эшен.

—Йөз процент минем геннар малайда!—дип мактанып алу да килешеп кенә тора иде Хәлил абзыйга.

Мал врачы буларак, әлбәттә, ген кебек сүзләр аңа күптән яхшы билгеле. Андый сүзләрне соңгы арада теленә аеруча еш кертә башлады. Карчыгы—элеккеге укытучы—мәхәббәт гәзите алдыра, «Таһир-Зөһрә» дигән. Элегрәк Хәлил абзый аны: «Мәхәббәт гәҗите укыр көнгә калдыңмыни, кортка!»—дип үчекләп тә йөргән иде. Карчыгы өйдә юкта өстәл өстендә яткан гәзитне караштыра, укыштыра башлагач, үзе дә кызыксынып китте. Бер мәкаләдәге: «Баланың холкын туксан процент ата-анадан килгән геннар формалаштыра»,—дигән фикер аеруча ошаган иде аңа. Шул рәвешле, мал врачы буларак, инде күптән белеп, хәзер теленнән төшеп калган «ген», «нәселдәнлек» сүзләре янә әйләнеп кайттылар. Бер яшьлектә, бер картлыкта, дигәндәй, мәхәббәте дә юк нәрсә түгелдер инде аның. Кичләрен карчыгы белән яшь чакларын исләренә төшереп утыралар бит әле. Хәлил абзый дингә ышанып ук бетми. Шулай да дин сабакларын укый. Әллә... Әллә инде картаймыш көнендә, кайчан булса да бу фани дөньядан китәселәре күнеленә кереп, акыл шәрифләре дин хакындагы фикерен үзгәртмәкче микән?

Бу җиһанда иртәгә тормышы өчен ныклы терәге булмаган адәмнәр генә, дин юлына басып, Аллаһы Тәгаләгә табына торганнардыр. Ә аның терәге бар бит. Каладагы малай—аның куанычы, ышанычы.

Хәлил абзыйның тормыш фәлсәфәсе элек әнә шундый иде. Соңгы елларда халыкның дингә ун як белән борылуы, күпләп мәчетләр салына башлау, өлкәненен-яшенең намаз иясе булып китүе аның күнелендә дә эзсез калмагандыр, әлбәттә.

Хәер, халык элек тә диннән йөз чөермәгән иде. Ничекләр генә итеп таптасалар, хурласалар да, ул динен ташламады. Дингә каршы котыртучы мокыт бәндәләр, үзләрен «пульно умныйга» санасалар да, шуны төшенмәделәр: һәр кеше үзенең кайчан да булса дөньялыктан китеп барасын белә, акылы белән оҗмах-тәмугларга бик үк ышанып бетмәсә дә, аннан кире кайтып: «Ышанмагыз, оҗмах та, тәмуг та юк икән ул!»—диюче булмагач,

«ә бәлки?» дигән гомерлек курку-икеләнү адәмнәрне һәрвакыт борчып торачак. Мәгълүм ич, кеше, олыгая барган саен, Ходайга ешрак мөрәҗәгать итә башлый.

... Әгәр дә кешенең хәлен аның тормыш дәрәҗәсе белән чагыштырып бәялисең килә икән, син аңардан шатлыгы турында түгел, кайгы-борчуы хакында сора. Соңгысы зур әһәмияткә ия булмаса, ул кеше—бәхетле кеше. Бәндәнең юк-төяккә дә игътибар итүчән булуы аның тормыш бөтенлеге хакында сөйли, чөнки бәхетсезлек барында ул аларга игътибар итә алмый.

Бүгенгесе көндә Хәлил абзый җыен вак-төяккә дә игътибар итеп яши торган кеше иде. Мәчет салуны исәпкә алмаганда, капка төбенә җыелышып сүз куерта торган мәсьәләләре дә гел юк-бардан гына тора бугай.

Мәчет салу турындагы сүз, моннан берничә атна элек, колхоз чөгендерен җыеп саткач та башланган иде. Капка төбендәге әңгәмәнең бер өлеше сугым турында булса, калганы мәчет салу эше иде. Агачтан салыргамы, таштанмы? Кеше яллап эшләтергәме әллә үзләре, авыл ирләре, җыелышып, керешергәме? Мулла кем булыр, кем азан әйтер, җомга намазларын кем укыр? Аксак Галимулла малае Габдулланың тавышы да матур, укуын да укый белә, гарәп хәрефләрен дә таный, диләр. Тик ул эчә. Егылып ятмаса да, туры килгәндә, мичкәсенә төшә торган малай.

Хәлил абзыйны, мәчет хакында сүз чыккач, беренче нәүбәттә әнә шул нәрсә борчый. Һәм ул мәчет мәсьәләсендә гел кирегә сукалый, бу эштә катнашырга атлыгып тормый; Ходайны танымаучы адәм буларак, әлеге гамәле аның холкына тач туры да килеп тора иде.

—Лучши картлар йортына ярдәм итәм мин,—ди.

Һәм ярдәм итә. Хәлил абзый, колхозда ветераннар советы рәисе буларак, картлар йортының тишек түбәсен алыштыру эшен кайгыртып, үз куллары белән җимерек мичен сүтеп, янасын чыгарды. Әле быел да, бәрәңге ала башлауга, ике капчыгын басу бакчасыннан ук шунда илтеп тапшырды.

Дөнья көн саен болганып, тулганып тора. Каладагы малай да, авылда мәчет салырга ярдәм итәм, дип атлыгып йөрүчеләрдән түгел. Бүген болай, иртәгә тегеләй ич хәзер дөньясы. Коммунистлар янадан килеп утырса, дип, ул партбилетын да ертып ташламады. Кем белә?..

Хәер, барыбер бу атнада, үгез суярга кайткач, Хәлил абзый малаена мәчет турында сүз катырга уйлап тора әле. Чыгарган ташы, меңгә якын кызыл кирпече дә әрәм ята. Халык купса, мәчетнең нигезенә, бәлкем, шуларны бирергә булыр, дип уйлап куя ул кайчакта. Малаеның ни әйтәсен алдан ук белә белүен. «Юк белән башыңны катырып йөрмә, артык булса, картлар йортына илт!»—диярме икән тагын? Мөгаен, бу хакта авыз ачмавын хәерлерәк булыр.

Юлдаш әби әйтүен әйтә ул, узган юлы барганда да әнә нәрсә диде әле, ирләр хатыннарны ярата, хатын-кыз балаларны, балалар песиләрне, ә песиләр беркемне яратмыйлар, дидеме? Юлдаш әби гомер йомгагын картлар йортында сүтеп ята. Чыгышы белән Байтимердән унҗиде чакрым ераклыктагы Юлдаш авылыннан. Гомере шәһәрдә узган. Фәннәр кандидаты. Ире белән бер малай тәрбияләп үстергән. Ире вафат булып, үзе дә, газ плитәсен кабызып чәй куярга да ярарлыгы калмагач, килене, карт кешенең балалар тәрбиясенә йогынтысы начар, дип аны Байтимердәге картлар йортына урнаштырган.

Хәер, әби, дигәч тә... Газ кабыза алмый, дигәч тә... Кызлар кебек әле ул. Сөйләшү, фикерләве генә түгел, хәтта гәүдә-сыны да бетәшмәгән, кем әйтмешли, тот та бүген үк берәр яшьрәк бабайга кияүгә биреп җибәр. Хәлил абый белеште: килене белән килешә алмаганнар алар, ә малаеның килен кулындагы дилбегәсе бик тә нык каештан ишелгән, ди, имеш.

Хәлил абзый һәр баруында әнә шул Юлдаш карчыгы белән гәпләшеп утыра, тегесе, килгән саен, гомереңнең бәхетле минутларын озынайтасың килсә, карчыгыңның сәламәтлеген кайгырт, ялгыш үлеп китә күрмәсен, дип акыл сата. Әлбәттә, Хәлил абзыйның карчыгы, кайчак ыңгыр-шыңгыр йөргәләсә дә, алай үлеп китәрлек түгел әле, тьфу, Аллам сакласын!

Хәер, соңлап булса да төшенде Хәлил абзый: Юлдаш карчыгы үз

малаена бик тә үпкәле, шуңа күрә ул Хәлилнен: «Малай, түрә малай!»—дип авыз суын корытуын бигүк өнәп бетерми бугай.

Нишлисең, балалар һәрвакыт акыл ягыннан аталарыннан өстенрәк инде, чөнки үз акыллары янына аталарыныкы да өстәлгән була бит.

Хәлил абзый каладагы малаен ярата гына түгел, ә кайчак аңардан шүрли дә булса кирәк. Шулай булмыйни! Ниндидер Байтимердән чыккан Хәлил малае Казан хәтле Казанда зур түрә булып эшләсен әле! Авылга бер мәртәбә вертолет белән дә кайтып төшкәне бар аның! Шуннан соң авыл халкы атна буе һушына килә алмыйча миңгерәп йөрде!

Юлдаш әби сөйләр ул. Тик малай—малай инде. Үгезне дә шуның өчен генә симертте Хәлил абзаң. Урыс суйган итне ашап ятмасыннар, дип. Мал врачы буларак, белә ич ул: Казан шәһәрендә юньле ит юк, белмичә алсаң, океан артыннан китерелгән «бракованные» ук булмаса да, барыбер Чернобыль үләнен ашап үскән сыерлар була инде ул. Ире шулай дигәч, хатыны Зөләйха:

—Ни сөйләп утырган буласың! Аның кем булып эшләгәнен белмисеңмени! Аларның ашаган ипиләренә тиклем ашлама белән үстерелмәгән. Үзең әйтмешли, натуральный!—дип каршы төшә.

Нишләрсең, карчыгы аның сүзләренә каршы киресен әйтергә ярата инде, шуннан тәм таба бугай кортка. Ә абзый аның белән килешми, үзе дә киресен сукалап ләззәтләнә. Дөресен генә әйткәндә, Хәлил абзый башта ук малаеның авыл хуҗалыгы институтына керүен, авылда яшәвен, торабара үз колхозларында рәис булып эшләвен теләгән иде. Зөләйха шул вакытта кырт кисте:

—Синең кебек тирес корты буласы юк!

Соңгы елларда гына, малай инде күптән юрист һөнәрен үзләштереп, зур урыннарга үрмәләп, дәрәҗәле түрә булгач кына бу хәл белән килеште Хәлил абзый. Белмәссең, аңламассың! Теге чакта, малай мәктәп тәмамлап, һөнәр сайлаганда, хатыны да хаталанмый, ул да хаклы иде кебек ич! Һәм хәзер дә... Чөнки Зөләйханың килен хезмәте күргәне юк. Ә Хәлил абзыйның бер рәхәтләнеп, авыз тутырып: «Киленкәем!»—дип, килене белән сөйләшә алганы, оныкларын үз туган телендә тәмле сүзләр әйтә-әйтә сөя алганы юк. Сынок, имеш, миленький, имеш! Марҗаның да ниндие диген әле: Нонна Иосифовна! Яһүди кода-кодагыйлары белән аралашканнары да юк, алар, кызлары кияүгә чыгуга, Израильгә күченеп киттеләр.

Шулай инде менә... Ул да хаклы, хатыны да хаталанмый...

Хат ташучы тартмага газеталар салып киткән. Район гәзите бар, бу калын журналны Зөләйха алдыра, мәхәббәт гәзитенең дә чираттагы саны килгән. Монысын да Зөләйха алдыра. Карчыгының, шушы яшенә житкәч, мәхәббәт жене кузгалганмы? «Таһир-Зөһрә», имеш. Әллә... әллә инде Юлдаш әбинең кем икәнлеген белгәнме? Хәер, юктыр, каян белсен, күрешкәннәре юк бит.

«Таһир-Зөһрә», имеш. Хәер, бер яшьлектә, бер картлыкта, диме әле? Хәлил абзый Зөләйхасын болай гына, шаяртып кына,—хәтта яратып та түгелме икән әле,—үрти, ирештерә иде.

—Мә, гәжитләрең килгән,—дип ул аларны өстәлгә таратып салды.— Берәрсендә үгезне ничек итеп симертү турында киңәш-табыш булмасмы икән. Булса, миңа да әйтерсең әле.

Тагын үрти Хәлил абзый Зөләйхасын. Зур гәүдәсе белән өй тутырып, идәнне шагыр-шыгыр китереп йөргән Зөләйхасы,—гомере буе балаларга әдәбият фәне укыткан хатыны, үртәлми, иренә ачуы килсә, юри мишәрчә акцент белән авызын томалап куя. Бу юлы да:

—Цукындың инде шул үгезең белән! Паетка[1] цыгар халь юк. Күрденме соң әле, тагын киртәсен жимергән бит, норсыз хайван!—диде дә өстәлдәге гәзит-журналларны жыеп, күзге алдына алып куйды.

Хәлил лапаска чыгып китте. Чынлап та, теге хәерсез мал муенындагы

[1]Паeт—лапас.

сибен тагын өзгән һәм лапастагы салкын оянын ике тактасын шартлатып сындырган. Хуҗасы килеп кергәндә, әле һаман дөбер-шатыр килә иде.

Хәлил абзый, кулына көрәк эләктереп, кызу-кызу үгез янына керде. Ә үзенен нинди ширлек эшләгәненен тойган хайван, сыртына көрәк сабы төшәсен алдан ук чамалап, арты белән почмакка чигенде. Хәлил абзый белә: үгезнең тынычлануы түгел әле бу, муенындагы авыр тимер баунын юклыгын сизү анын кытыгын китергән, ул әле тиз генә жимерү эшеннән тукталачак түгел, мондый гамәле исә кулына көрәк тоткан Хужа абзыйны хәйләләү өчен генә иде. Мөгезе белән төртеп алырга да күп сорап тормас.

Һи, ашыкма әле син, үгез дус. Гомере буе мал-туар арасында кайнашкан Хәлил абзаңны алай ансат кына хәйләләрмен димә! Иң әүвәл муенына сибенне кидерсен әле ул. Әһә, карышасынмы, бәйләтәсен килмиме! Алайса хәзер болай итәбез. Абзан шуннан эләктерсә, тыпырчына да, мөгезләрен белән айкана да алмассын—шым булырсын, хайванкаем. Берьюлы ике кабырганы сындырдың инде син теге чакта.

Хәлил абзый, үгезнең борынындагы бөжрасыннан тотып, гәүдәсе белән аны улак янынарак этте. Борыны авыртуга түзә алмаган үгез карусыз буйсынды, муенын бәйләгәндә дә тыпырчынмады. Кызганыч тавыш белән мөгерәп кенә куйды. Нәрсә ди, күрше сыерының тавышын ишеткәч кенә ычкындым, анын янына кунакка гына кереп чыкмакчы идем, диме? Ә-ә-әә, иртәгә син көтүгә чыгасынмы, дип сорамакчы идем, ди бугай. Вәйт, хәйләкәр. Көтү кергәнгә биш былтыр инде. Иртәгә син бүтән жиргә кунакка китәсен, Алла боерса. Хур сыерлары янына. Беләсен килсә, бер көтү хур сыерлары чәчәкле болында, сине көтеп, утлап йөри ди анда. Бер үзенә бер көтү булыр, яме. Иртәгә кадәр генә түз инде, жаныкаем.

Хәлил абзый, шулай сөйләнә-сөйләнә, үгезенә башак болгатып, анын муен асларын кашый-кашый иркәләде дә, тизәкләрен алгач, лапастан ишегалдына чыкты. «Һе,—дип көлемсерәде ул,—ожмахта хур кызлары бар, дип сөйләгән булалар бит әле. Үгезгә дә хур сыерлары буламы икән соң анда, ә? Юлдаш әбидән сорап карыйсы булыр әле. Ул Коръәнне су урынына эчә».

Үзенә әби түгел инде ул анын. Хәлил белән бер кормада алар. Картлар йортында яшәгәнгә күрә генә «Юлдаш әби» дип йөртәләр аны. Юкса... юкса теге чакта... Юлдаш авылы урманында чикләвек җыйганда очраткан кыз бит ул. Казанда студент булып институтта укып йөргән вакытта, Хәлил атлы гаярь егет, аны,—шомырт күзле, озын толымлы Таңгөлне,—кинотеатрга да чакырган иде. Бары бер мәртәбә барды Тангөл, икенчесендә кырт кисте: Хәлил, син авылга кайтып яшисе кеше, ә мин холкым белән дә, һөнәрем белән дә (ул университетның тарих бүлегендә укый иде) шәһәр кешесе булачакмын. Вакытынны бушка уздырып йөрмә. Үз тиненне тап!

Әйе шул, башкалар өчен генә Юлдаш әби ул. Чынлыкта Тангөл исемле. Тангөл әби. Хәлил өчен—Тангөл. Язмыш, диген... Язмыш кешене ярты гомеренә чаклы үз артыннан тартып, сөйрәп бара, аннан соң, туктап калмыйча атласын өчен, эткәләп, төрткәләп кенә тора, ди. Хәер, без бәхетсезлегебезне генә язмышка сылтыйбыз, уңышларны, бәхетле чакларны исәпкә кертмибез. Бәлки, эш монда язмышта гына да түгелдер... Алай дисәң, адәм баласының язмышы анын эшләпәсе астында гына, диләр бит. Кара, кара, ул, Хәлил абзый, нәкъ Тангөл кебек фикер йөртә түгелме соң? Юлдаш әби теленнән төшкән фәлсәфи сүзләр белән фикерли ич!..

Язмыш, дип инде, бәлкем, алай дип әйтерлеге дә юктыр. Бик гади һәм гадәти кебек кенә булды ич. Киногa чакырырга икенче, өченче көнне дә барды Хәлил. Бер килүендә Таңгөл, группадаш Казан егетенә ияреп, ресторанга китеп барды. Хәлил күз алдында. Казан малае бер бәйләм розалар күтәреп килгән иде. Хәлилнен хәтта ромашка да бүләк иткәне булмады, «Кино карарга яратмыйм мин!»—диде кыз һәм, бүлмәдәш кызы белән икесен генә калдырып, култыклашып чыгып та киттеләр.

Бүлмәдәш кыз Зөләйха, егетнең тирләгән учында бөгәрләнеп беткән кино билетларын үзенә сорап алды ул чакта, аннары тиз генә үтүген кыздырып, билетларны өстәлгә салды да, өсләреннән марля белән каплый-

каплый, үтүкләп тигезләде һәм яңагына куйды:—Кайнар, битне пешерә, киносы да шәп булырга охшаган,—дип, гади генә һәм бик тыныч тавыш белән әйтте дә салды.

Кинога ул көнне Зөләйха белән икәү киттеләр. Хәзер дә алар, олыгайган көннәрендә, кино карарга яраталар. Үз өйләрендә, икесе янәшә кәнәфигә утырып, телевизор экраныннан. Ияләнелгән, күнегелгән инде. Бергә яши-яши... гомер буе...

Теге чакта? Әйе, ул вакытлар, бигрәк тә беренче очрашу, тора-бара, еллар уза-уза, һаман саен ачыграк булып искә төшә, барлык нечкәлекләре белән күз алдына килә дә баса.

Кинодан соң («Кара каен» дип аталган бик әйбәт фильм иде) бик озак Казан урамнары буенча сөйләшеп йөрделәр. Кино тәэсиреннән егетнең теле аңкавына ябышкан, күп сөйләшми, тыңлый гына. Зөләйха, Чувашстанның Батыр районыннан Казан университетына укырга килгән мишәр кызы, сүли дә сүли. Әүвәл аңа кызның теле ничектер ят, сәер булып тоелган иде. Шунысы коткарды: аларның үз якларында да «ж», «ч», «һ» хәрефләрен нәкъ мишәрчә каты итеп әйтәләр һәм белмәгән кеше аны мишәр егете дия иде. Хәер, белмәгән кеше, дип, ерак бабалары кыпчак белән туганнардан бит. Аны мишәр диючеләр, үзләре дә белмичә, асылда дөресен әйтәләр булып чыга инде.

Күнеле һаман Казан егетенә ияреп киткән күрше Юлдаш авылы кызы Таңгөлдә булса да, Зөләйханың эчкерсезлеге, гадилеге егеткә бик ошый, кыскасы, аның белән күнелсез түгел иде.

Сәгать унберләр тирәсендә генә Зөләйханы тулай торагына озатып куйды ул. Кыз тулай торак ишегең ачкач, кермичә булдыра алмады: вахтада утыручы хатын, ярдәм эзләп, каравыл кычкыра иде. Баксаң, ике солдат, аны читкә кысрыклап, тулай торакка керергә маташалар икән. Вахтер хатын таныш егетне күрүгә:

—Әнә, БКД начальнигы үзе кайтты! Күрмәгәнегезне күрсәтә ул хәзер сезгә!—дип шәрран ярды.

—О-о! Боевая комсомольская дружина—меня бережет!—дип солдатларның берсе ыржая ук башлады.

Салмыш иде алар. Буе ике метрлы, таза бәдәнле көрәшче Хәлил, аларның якаларыннан гына эләктереп алды да ишектән чыгарып атты. «Хәзер мин сине урамга чыгарырга куркам инде!»—дип еламсырады Зөләйха. Вахтер хатын да: «Узыгыз, уз!»—дип кертеп җибәрергә әзерлеген әйтеп куйды. Бу фикер Хәлилнең үзенә дә ошады. Таңгөл дә кайткандыр. Хәлилне Зөләйха белән бергә күреп, шартласын әле: кино карарга яратмый, имеш...

Ләкин бүлмә бикле, Таңгөл кайтмаган иде.

Иртәгесен кояш икенче яктан чыкты...

Ә Таңгөл өчен ул бөтенләй сөенеп торды кебек. Чөнки Хәлилгә үзе дә битараф түгел, теленә шайтан төкерсен: авылга кайту, кайтмау турында ул болай гына әйтте. Дөресрәге, кызның иләс-миләс чагы иде, Хәлилнен күзләрендә мәхәббәт уты күреп, аны алай тиз сүнәр дип уйламый, һәм, көнләштереп, әлеге ут-ялкынның тагын да көчлерәк дөрләвен генә көтә иде. Таңгөлне пыскып торган мәхәббәт уты гына канәгатьләндерми, аны—чибәр, гүзәл кызны—шашып яратырга тиешләр.

Кыз-хатынны егет-ирләрнең холкы да, йөз-кыяфәте дә түгел, тасма теле һуштан яздыра. Ул вакытта янып торган шомырт кара күзле, сөлектәй сылу, тулган айдай гүзәл авыл кызы, бераз кирерәк тә, чак кына кыланчыграк та яшь кыз аның шулай икәнлеген каян төшенсен инде?..

Хәлил, беренче күрүгә, Юлдаш әбинең Таңгөл икәнлеген белмәде. Тегесе таныса да сиздермәскә тырышты бугай.

Картлар йортының дәү корсаклы миче ишелгән. Үз түбәсе астына ундүрт караучысыз җанны сыйдырган йортны, элеккеге клубны, көзгә кергәнче җылытырга кирәк иде. Хәлил, колхозның ветераннар советы рәисе, мич чыгаручы оста, эзләп йөреп тә таба алмагач, үзе тотынды. Кулы белә, балачактан өйрәнгән эше иде.

Картлар йортында, анын житәкчесенең сүзләре белән әйтсәк, тугыз әби һәм биш бабай тәрбияләнә. Күбесенең балалары исән-сау, бик сирәге генә япа-ялгыз.

Миччегә кирпеч биреп, балчык изеп тору эшенә барысы да дәррәү алынды. Мичнең хатын-кызлар ягындагысы ишелгән иде, шуна күрә төп кинәшчеләре дә алар һәм шулар ук аны өйрәтеп тә тордылар.

Мичнең яртысы өелеп беткән иде инде. Хәлилнең кулыннан калагы ычкынып китеп, идәнгә барып төште. Әбиләрнең берсе, җәһәт кенә иелеп калакны алды да миччегә сузды һәм... Хәлил абзый чак егылып төшмичә калды: Тангөл бит бу! Юлдаш авылыннан. Агач башында эләгеп калган кыз, Казанда бары бер генә мәртәбә булса да бергәләшеп киногa барган Тангөл! Ул егет чакта шашып сөйгән Тангөл ләбаса бу! Әллә охшаган гынамы? Туган тиешлесе булса?

Ул калакны Юлдаш әби кулыннан алды да ниндидер ят тавыш белән әйтеп куйды:

—Рәхмәт, Таңгөл!

Юлдаш әби дерт итеп китте. Анын сүрелә барган күз карашы гөлт итеп кабынды, аксыл йөзенең урталары кызарып чыкты, маңгаендагы җыерчыклары язылды, канәфер төсендәге юка иреннәренә кан йөгерде. Хәлилнең исә сап-салкын кирпеч кулын пешергәндәй булды.

—Мин сине күрүгә таныган идем, Хәлил.

—Мин танымадым, Юлдаш әби...

Ул көнне алар ике-өч сүз генә алышсалар да, Хәлил абзый, калган булышчыларын азат итеп, мичне икәүләп кенә диярлек чыгарып бетерделәр. Тангөл Хәлилгә кирпеч биреп торды. Шунысына шаккатты Хәлил: нинди кирпеч кирәген,—бөтенеме, яртылашымы,—булышчысына әйтеп тә торасы юк, ул үзе белеп сайлый, хатын-кыз башы белән каян белә, ничек чамалый, диген, һәр кирпече нәкъ туры килеп тора.

Мичләрне тиз чыгара торган иде Хәлил. Бу юлы нигәдер озаккарак сузылды. Әллә һәр кирпече күңел җылысына төреп салынды инде? Балчык, кирпеч һәм күңел җылысы... «Филәйсүф булып барасың түгелме, Хәлил туган»,—дип көлемсерәде мичче үзалдына.

Чикләвек урманында булган хәлне хәтерлисеңме, дип бик сорыйсы килсә дә, теле әйләнмәде. Онытандыр да, аннан бирле күпме сулар акты...

Чикләвек җыя-җыя урман эченә үк кереп киткән Хәлил кечерәк бер аланлыкка килеп чыкты. Ул кай тарафка китәргә белмичә таптанып торганда, аланлыкның икенче ягында: «Коткарыгыз!»—дигән ялварулы тавыш ишетте. Кыз бала тавышы. Егет, абына-сөртенә, тавыш килгән якка китте. Күңелендә курку да юк түгел иде—ерткыч мазар йөрсә! Тик шөбһәсе урынсыз булып чыкты, бер кыз агач башына менгән дә төшә алмыйча куркып утыра, дөресрәге, юан, кәкре нарат ботагы күлмәк итәгеннән эләктереп алган.

Хәлил, төбе чикләвек белән яшьнәгән бәләкәй ак капчыгын үлән өстенә куйды да, җитез генә агач башына үрмәләде, ботакка эләккән күлмәк итәген ычкындырды һәм, сикереп төшеп, кулларын югарыга таба сузды:

—Төш, төш, курыкма! Тотам мин сине!

Кыз, акрынлап, төшә башлады. Менгәндә ничек менгәндер, наратның аскы өлешендә ботаклары да юк, шоп-шома. Шул урынга житкәч, ул күзләрен чытырдатып йомды да егетнең кочагына сикерде. Анын гәүдәсе шулчаклы җиңел иде, күбәләккә әйләнеп, очып китәр кебек. Әле генә куркып агач башында елап утыра иде. Хәлилнең көчле кулларына килеп эләккәч, куркыныч узганга сөенеп, көлеп үк җибәрде.

—Ник миндән агач башына?

—Үзебезнең авылның өй түбәләрен карарга дип.

—Кайсы авылдан соң син?

—Юлдаштан.

—Күрдеңме соң өй түбәләрен?

—Менеп житеп булмады ич. Син нәрсә, прокурор кебек миннән сорау алып торасың әле! Ә?

—Мин прокурор түгел. Ә син минә—карга баласы. Агач башына каргалар гына куна, белдеңме!

—Син үзен—карга баласы, ә мин—Таңгөл!

—Таңгөл. Юлдаш кызы Таңгөл.

—Син үзен?

—Байтимердән мин. Чикләвеккә килдем.

—Безнең урман чикләвеген җыярга килгәнсең икән.

—Әгәр мин чикләвеккә килмәгән булсам, син агач башында елап утырган булыр идең әле.

—Харап икән! Нинди герой! Коткаручы табылган булыр иде әле, белдеңме!

—Белмәдем шул.

Шул рәвешле бер-берсенә урынлы-урынсыз сүзләр әйтешә-әйтешә беркавым чикләвек тә җыйдылар.

Ул елны чикләвек бик эре, бик ишле иде Юлдаш урманында. Ләкин, ул, кызганычка каршы, кыш көне сакларга яраклы булмады, эчләре кортлы яисә куыш иде.

... Хәлил абзый, үгезне бәйләп, өйгә кергәндә, Зөләйхасы, аны дәшәргә дип, үзе лапаска чыгарга җыенып тора иде. Төшке аш алдыннан алар икесе, кара-каршы утырып, өрек җимеше капкалыйлар һәм Зөләйха җәй көне үзе җыеп әзерләгән кырык төрле файдалы үлән төнәтмәсе эчеп куярга гадәтләнгәннәр иде. Дөрес, аш алдыннан ярты сәгать кала көндә эчелә торган үлән суы да, җимеше дә хатыны өчен түгел, нәкъ менә Хәлил абзый өчен генә әзерләнә иде. Чөнки аның ашказаны авырта. Әгәр аның белән бергә өстәл янына үзең утырмасаң, Хәлилнең җимешкә дә, үлән төнәтмәсенә дә орынып карамаячагын белә ул. Көйсез баланы юмалап ашаткан кебек әүвәл үзе үрнәк күрсәтә. Йөрәккә хәл кертә, дигәч, соңгы араларда ул ирен өрек җимешен сәгатьләп ашарга мәҗбүр итә башлады. Хәлил абзый тынламыйча булдыра алмый, аның өчен дип тырыша бит Зөләйхасы.

Шул арада гәпләшергә дә өлгерәләр үзләре.

—Гәҗиттән укыдым әле,—дип башлый сүзен Зөләйха түти.—Илле яшьлек берәү үзенең яшьтәшенә өйләнгән. Гомер буе күрше булып торганнар үзләре. Берсе өйләнмәгән, икенчесе кияүгә чыкмаган булган. Бар инде хәлләр дөньяда! Шаклар катарлык! Шуннан, болар өйләнешкәч, беләсеңме, игезәк балалары туган! Малай белән кыз ди. Хатыны кырык җиде яшьтә. Ничек батырлыгы җиткән. Ничек кавышканнар диген әле! Ул яшькә җиткәч тә мәхәббәт туар икән, ә?..

Хәлил абзый дәшми, Хәлил абзый ашыкмыйча гына авызындагы җимешен мүкелдәтә. Дәшмәсә дә, уйлый: «Мәхәббәттерме инде, юктырмы. Әмма нәрсәдер бар, карчык, бар...»

Монарчы, болай дип уйлау түгел,—бигрәк тә шушы яшенә җиткәч,—хис мәсьәләсенә кагылышлы хәлләр ике ятып бер мәртәбә төшенә дә кереп карамагандыр. Яшь чакта хәлләр булды инде анысы. Таңгөл өчен утка-суга керергә, теге Казан егетен телеграмм баганасына элеп куярга әзер иде. Ярый Зөләйха булды әле. Әнә, хәзер аның каршысында гәҗит хәлләрен сөйләп утыра ул корткa. «Нәрсә ди, иллегә җиткәч тә мәхәббәт буламы икәнни, диме? Причем монда мәхәббәт! Ир-атка әгәр кыен икән, ул өйләнә, рәхәт булса, шуның өстенә тагын берәр хатын-кыз эзләп чаба башлый диме? Тегеңә дә кыен була башлагандыр. Шуңа өйләнгән».

Хәлил абзый шул рәвешле үзалдына сөйләнә-сөйләнә янә бер кат лапасны урап килде. Үгезе тынычланган, тагарагындагы башагын чупырдата. Үгезләрнең язмышы очар кошлар язмышы түгел. Очар кошлар кебек аларның җаны гына оча, кире әйләнеп кайтмый, Ходай катында алар.

Адәм баласы үзе үк үз башын төрле әкият-фаразлар белән дыңгычлый да һәм аннары гомер буе шул ялганына үзе ышанып яши бирә.

... Теге кирпечләрне мәчеткә биреп әрәм иткәнче, лапас стеналарын өяргә тотасы булыр. Алайса үгез, тиктормас җан, ташкүмер калдыклары-шлактан коелган стенаны, мөгезләре белән төртә-кашый тишеп чыгара язган...

Хәлил абзый шундый киләчәк уйлар белән капка төбенә чыкты. Авыл тыныч, төшке аш вакыты булгангамы, урамда кеше-кара күренми. Беркавым капка баганасына сөялеп басып торганнан соң, ат карауччы Галимҗан узып китте—ферма складына онга барышы. «Атын дагалатмаган икән әле бу хәчтерүш малай»,—дип уйлап, Хәлил абзый аны күз карашы белән озатып калды. Фермадан ат абзарына кайтышлый ул бирәр капчык онын ярты литр аракыга алыштырачак, әлбәттә. Һәм фураж оны калдырган кешесен, башы авырткан саен, йөз грамм сорап кереп, ай буе изалаячак аннары.

Хәлил абзый капылт уйлады да янә лапаска таба юнәлде. Үгезгә башак биргәндә онын азрак салды бугай. Шуна өстәп ана он суы да эчерергә булды. Үпкәләп китмәсен хайван. Үгез он суы эчеп торганда, борынындагы бөжрасын да салдырырга ниятләгән иде, ләкин бура кадәрле бу хайванның башын, аякларын ничек кенә ныгытып бәйләсәң дә, чалыр алдыннан егулары җинел булмас, дип кире уйлады, чөнки шул бөжрадан тоткан очракта гына гаярь үгез кәҗә бәтиенә әйләнә дә кала иде. Бөжрасыннан каптырмасаң, аякларын да бәйләтмәячәк әле ул: хайван пычакны әллә кайдан сизә, диләр бит.

Малай иртәгә иртүк тан белән кайтып җитәргә тиеш иде. Бу юлы, ит алып китәсе булгач, вертолет белән кайтмастыр инде, шәт.

... Ходай Тәгалә кешегә тәхет биргәндә, шунын бәрабәренә, анын акылын да алып кала, диләр. Күрәсен, вакытын да ала бугай...

Иртәгесен Хәлил абзыйлар капка төбенә куе яшел төстәге япон джипы килеп туктады һәм аннан шофер белән тагын ике гулливер егет төштеләр. Хәлил абзыйның малае—машина хуҗасы—үзе күренмәде. Бәлкем, артта, икенче машинада кайта торгандыр, берәрсенә эше төшеп, тоткарланыбрак калгандыр? Хәлил абзый күн курткалы урыс егетләренең күзләренә өметләнеп карап, сорауларына җавап эзләде. Нәрсә, багана кебек торасыз, әйтегез инде, әйт, хәзер кайтып җитә, диегез. Малаенын үгез суярга кайтачагын бөтен авыл белә бит инде! Егетләрнең берсе машина артындагы әрҗәдән катыргы тартма алды да әле һаман Байтимер юлын күзәтеп торган хуҗа абзыйга таба атлады.

—Мясо здесь, мясо дикого кабана?

Хәлил абзый ана борылып та карамады, соңгы өмете итеп, монарчы инде күргәне булган шофер егеткә текәлде.

—Үзе кайда?

—О, Халил абы, ему некогда, сегодня, в субботу, у них день охоты. На кабана поехали.

—А быка, быка кто будет резать, дип сорыйм мин сездән?—дип ул яртылаш урысчага күчте.

—Мы, Халил абы. Не бойтесь, мы его сразу кых!

Хәлил абзыйның хәле китте, гәүдәсе калтырана башлады, тез асларына, әйтерсен, утын агачы белән китереп сукканнар иде.

Малай кайта, дип, сугымчы Галимуллага да әйтмәде. Югыйсә, кичә кичтән Галимулла үзе килде, башы авырта иде. Хәлил абзый аны, салкын су да бирмичә, куып чыгарды. Җитмәсә, артыннан: «Минем малай кайта!»—дип калды.

Бу кәттә урыс малайлары белән ничек итеп суймак кирәк инде ул кыш чыккан үгезне!

Хәлил абзый аптырап басып торды да, егетләргә үз артыннан барырга кушып, лапаска юнәлде. Сугым өчен кирәк булган бар нәрсәсе дә кичтән үк хәстәрләнеп куелган иде, таяклары да, баулары да. Утын пычкысыннан үзе ясаган пычагы да әллә кайчан кайралган, лапас шкафында гына тора.

Ул әүвәл, үгез янына үзе кереп, борынындагы бөжрасын алды. Якын килеп карагыз хәзер! Бу атнада кайтмаса, киләсендә кайтыр малае. Икәүләп тә бик шәп суярлар әле.

Ә бу әзмәверләрнең үгезгә көче җитсә, ә?

Ул егетләргә үгезне күрсәтте дә үзе җылы су белән чиста тастымал алып чыгарга дип өйгә кереп китте. Каны сиптермәсенгә каплап кую өчен

искерәк мунча себеркесе дә кирәк булыр әле.

Малай кайтмаганга ишегалдында дулап йөргән иренең күзенә артык чалынмас өчен, Зөләйха түти өйгә кереп, әллә кайчан җылы суын да, тастымалсөлгесен дә хәстәрләп куйган, шәһәр егетләренең өс-башын алыштырырга бишмәт-бушлатлар, киез итекләр әзерләү белән мәшгуль иде.

Хәлил абзый ачулы иде, хатынына сүз катмады. Авылга вертолет белән кайтканда, малай—атасының горурлыгы, берәр төрле ярамаган гамәл кылса— Зөләйха түти гаепле, малай аңа охшамаган булып чыга иде. Гомергә шулай. Иренең гадәтен яхшы белгән хатыны аңа күтәрелеп карарга да курыкты. Ул бары: «һай, малай актыгы, ичмаса, дуңгыз атарга киткәнлеген әйтеп җибәрмәсен ие, бүтән берәр сәбәп тапсын ие»,—дип кенә уйлап куйды.

Хуҗа, бер кулына сулы чиләген, икенчесенә бушлатлар тотып, өйалды баскычыннан төшеп барганда, ар якта, бәрәңге бакчасында, шарт та шорт аткан тавышлар ишетеп, каушавыннан, баскычта таеп китте һәм чиләгение белән бусага төбенә барып төште.

Ахырда беленде: урыс малайлары үгезне абзарыннан сөйрәп алып чыгып, лапас баганасына бәйләргә теләгәннәр. Үзенең үләсен сизеп, әүвәл юаш кебек күренгән үгез, чит кешеләрне өнәмичә, кинәт дулый башлаган һәм ачык лапас ишегеннән бәрәңге бакчасына чыгып киткән, шул җәһәттән яшьләрнең берсен төртеп егып, кабыргаларын сындырган, үлем исереклеге белән котыра-сикерә башлагач, урысларның берсе пистолетын чыгарган.

Иртән яуган ап-ак йомшак кар өстендә үлем белән тартышып, дерелдәп яткан мескен хайванның эч-башы тишкәләнеп беткән, алардан берөзлексез алсу кан саркый. Телен чыгарган, күзләре зур булып ачылып тора. «һай, хуҗа абый, дога-бисмилласыз кемнәр кулына тапшырдың син мине!—ди кебек иде зур күзләрендәге сүнеп бетергә өлгермәгән рәнҗүле карашы.— Хур сыерлары янына да кертмиләр ич инде хәзер мине!..»

Хәлил абзый дәшмәде, тешләрен чыкырдатып читкә карап бер төкерде дә хатынын Галимулланы чакырырга йөгертте.

Үгезнең итен Казанга җибәреп, бер ресторанга тапшырттылар да, акчасын, тиененә кадәр санап, мәчет салу эшендә башлап йөрүче төлке Хәкименә илттеләр. Хәким икенче көнне бөтен килеш акчаны кире кайтарды.

—Мондый акчаны, урыс атып үтергән хайван ите акчасын, изге эшкә, мәчет салуга тоту хәрәм булыр. Халык риза түгел, ачуланма, Хәлил кордаш,— диде ул, моңа үзен дә гаепле санады кебек.

... Иртәгесен иртүк Байтимергә китте Хәлил абзый. Йомыш-фәлән белән түгел, болай гына. Үзе чыгарган мичкә тунган аркасын терәп, байтак утырды ул. Иртәнге намазын укып тәмамлаганнан соң, аның янына Таңгөл-Юлдаш әби дә килеп утырды. Хәлил абзый, беренче мәртәбә күргәндәй, аңа озаклап, текәлеп карап торды да:

—Тангөл, әйт әле, син чикләвек җыйган чакларны хәтерлисеңме?— дип сүз катты.

—Нигә хәтерләмәскә?! Син миңа агач башыннан төшәргә булыштың.

—Тагын ниләр хәтерлисең?

—Синең белән кинога барганны.

—Нинди кино караганыбыз исеңдәме сун?

—Индийский иде бугай.

—Байтимер клубында да кино була икән бүген. Монда килешли белдерүен күрдем. Әйдә, бүген кино карарга барабыз, ә?

Юлдаш әби утырган урынында кыбырсынып куйды. Дәшмәде.

Мичкә терәлеп үк утырса да, Хәлил абзыйның аркасы һаман җылынып җитә алмый иде әле.

—Таңгөл, дим!


—Синнән тирес исе килә...

Хәлил абзый җавап кайтармады, янәшәдә генә таралып яткан черек усак утыннарын мич авызына томырды да тунган аркасын җылыга терәде...

*Декабрь, 2000 ел.*

# ҖАНЫНДА ДАВЫЛЛАР ИДЕ

1989 ел. Эреле-ваклы китаплары чыккаласа да, ул вакытта Рәшит Әхмәтҗановның учта сизелерлек калын китабы юк иде әле. Юка тышлы китап чыгарып зур шагыйрь саналып була димени! Рәшитнең максаты—иң яхшы әсәрләрен туплап «Шигырь китапханәсе» сериясендә томлык чыгару. «Шигырь китапханәсе»ндә чыгу—үзе зур дәрәҗә, шигърияттә үз урынын булуын билгеләүче бер күрсәткеч. Һәрхәлдә, бу сериядә басылу күпләрнең хыялы иде ул елларда. Өстәвенә, шагыйрьнең 50 еллыгы да якынлаша...



Китап чыгу мәсьәләсе нәшриятта тәгаенләнгәч, ул миннән шушы томлыкка кереш сүз язуымны үтенде. Хәзер уйлап куям: озак көтелгән кадерле китабына баш сүз язуны нигә миннән сораган? Холык-фигыль белән дә, язу-стиль ягыннан да шактый аерылабыз, ул вакытта мин ирекле иҗатчы, профессионал, түрә-мазар да түгел, дәрәҗәле пост та биләмим... Дөрес, аның әсәрләренә төрле елларда берничә эчке рецензия (нәшриятта элегрәк шундый тәртип: компетентлы саналган язучы яки шагыйрь, авторлардан кергән кульязмаларны укып, бәяләмә бирә иде) язганым бар иде. Бәлки, шуларны да истә тотып мөрәҗәгать иткәндер. Ризалык бирелде, «вәгъдә—иман» дигәндәй, 4-5 битлек мәкалә язылды һәм ул 1991 елда Рәшит Әхмәтҗановның «Монлану» исемле сайланма әсәрләр китабында «Күңел һәм җан сәфәре» исеме белән кереш сүз булып басылып та чыкты. Бүләк итеп биргән китабына болай дип язган: «Равил! Гомер шулай узды инде. Безнең бергә яшәүгә мин бер генә караңгылык та төшермәдем. Рәшит Әхмәтҗанов. 6 май 1991 ел.»

Бу хәлләрдән соң нәкъ ун ел гомер үткән. Әйтелгән, ташка басылган сүзләр әле ул арада гына искерергә тиеш түгелләрдер ласа! Шуңа күрә, әлеге кереш сүздән, озынрак булса да, кайбер өземтәләр китереп узам.

«Рәшит Әхмәтҗановның шагыйрь, һәм дә зур шагыйрь икәнен кешеләргә раслыйсы юк. Әмма аның шигъриятенең үзенчәлеген, нечкәлекләрен үзебезгә аңлыйсы, күпләребезгә төшендерәсе бар әле. Өч дистә елга якын шактый ук актив эшләп килсә дә, аның иҗаты турында әдәби җәмәгатьчелекнең аерым төпле фикере соңгы биш-алты ел эчендә генә ишетелә башлады. Бу хәлнең сәбәпләре нидә? Бәлки, тәнкыйтьчеләрнең исемлек кысасына үз вакытында керә алмый калуындадыр? Бәлки, шигъриятебездә берьюлы ике талантлы шагыйрь—ике Әхмәтҗанов (Роберт

һәм Рәшит) булуның «файдасыдыр»? Бәлки, иҗатының артык үзенчәлекле булуындадыр? Яшермим, укый-өйрәнә торгач, Рәшит Әхмәтҗанов дигән шагыйрь үзем өчен дә шактый ук «каты чикләвек» булып чыкты. Налим балыгы шикелле шома (яхшы мәгънәдә), тиз генә тоттырмый... аның шигъриятен «саңагыннан» әләктереп булмый... Шигырьләре техник яктан, Хәсән Сарьян «юнган агач» шикелле, бик нечкә зәвык белән эшләнгән; өстәвенә, образ, чагыштырулар, эпитетлар һ. б. калфак чигешендәге энҗеләр шикелле бик мул сибелгән. Шагыйрьлекне аерым юл-строфалардан, исемләнгән шигъри башламнардан да тоеп була («Яшь чагында авыр ташлар—тау астында», «Төшләремә кердең каен булып», «Акка кызыл ачык булып төшәр», «Сандугач керде күнелгә», «Минем өчен дөнья—нәкъ дүрт гамәл», «Кошлар бәйрәменә чакыру», «Салкын кышлар аккош булып кайтыр» һ. б.).

Яки менә бу дүртьюллыкны укып узыйк:

Муеныма аскан ташың—тау иде,
Мине тирән су төбенә салды ул.
Бүләк алып чыктым әле мин сиңа:
Сине сөйгәч—энҗе булып калды ул.

Рәшит Әхмәтҗанов—чын мәгънәсендәге татар милли шигъриятенең төп, дөрес юлында торучы шагыйребез. Ул—Р. Харис та түгел, Г. Рәхим яки Р. Мингалимов та түгел. Ихтимал, аны күпмедер дәрәҗәдә М. Әгъләмов белән параллель куеп буладыр. Икесе дә Хәсән Туфан шигъриятe тарафдарлары. Аларның төп эчкән чишмәләре—халык иҗаты, татар халкының эстетик традицияләре. Биредә сүз иҗатчының юнәлеше, кыйбласы турында бара. «Һәр сүз миннән бер матурлык сорый, мин фәкыйрьмен—алыйм кайлардан?..» дисә дә, шагыйрь, әйткәнемчә, сүзне, илһамны, җимне халык иҗатыннан, халык күнеленнән ала. Шуңа күрә дә аның шигырьләрендә безнең фольклорга хас бик күп традицион атрибутлар, образлар, тәгбирләр тулып ята. Беренче карашка гади күренгән шигъри сүзберәмлекләр, шагыйрь күнелендә үзгәртелеп, яңа төсмерләр ала, образ-фикергә әйләнә:

Урман эчләрендә урман шаулый,
Урын тапмый болан үзенә.
И болан...
Йә сугарлар балам күзенә дип,
Ачык аланнарда төлке уйный,
Урманнарга кача яшь болан.
Кил болан...
Урманнардан берни урламаган
Соңгы җан иясе—мин булам.

Кызганыч, безнең бүгенге яшьләребезнең күбесе халык иҗаты белән җимләнеп үсмәгәнгә, шагыйрь күнеле тудырган гаҗәеп бай һәм тылсымлы дөньяны тиешенчә тоеп, эстетик ләззәт ала алмый. Шәхес культы һәм торгынлык елларында бер-ике буын милли укучыларыбызны югалттык. Шулай да, үзебезне юатып, үзгәртеп коруларның нәтиҗәсе яңарышларга китерер дип өметләник.

Рәшит үзенең шигърият өчен яратылганын сизеп микән, бүтән жанрларга сибелмичә, фәкать поэзиядә генә эшләп килә. Ул бу яктан, күпмедер дәрәҗәдә, Х. Туфан, С. Хәким, Н. Арслановлар юлы белән китте. Бөтен җегәрен бер ноктага—бу очракта поэзиягә юнәлтү, табигый, аны бу өлкәнең чын остасы итә. Шуңа күрә дә Рәшит Әхмәтҗанов, гармуннарның теләсә нинди төрендә уйнаган Фәйзулла Туишев, Фәйзи Биккининнар шикелле, шигырь жанрының теләсә кайсы биләмәләрендә виртуозларча иркен эш итә: шигырьләрнең озынын яки кыскасын булсын, менә дигән итеп коеп куя, поэмаларны да оста үреп чыга, моңлы яки дәртле җыр текстларын да үзенчәлекле итеп яза. Әйтик, шагыйрьнең «Акчарлаклар»ы классик җырлардан саналырга хаклы дип уйлыйм. Балалар өчен дә җыйнак һәм тәрбияви әһәмиятле итеп яза белә. Бу китапта шагыйрь иҗатының тулы чагылышы: давылларын җанына яшергән ир-егет әдипнең дөньяга туккән күңел байлыгы,

кешеләргә әйткән фикер-хикмәтләре, хис-моңнары тупланган.

Әйткәнемчә, поэмалар өлкәсендә дә актив эшли Рәшитебез. Бу китапта алар берничә: «Язлар быел сонга калды», «Исәннәр моны», «Бишташ», «Аучылар кибетендә». Соңгы икесе, авторның гына түгел, гомумән, поэзиябезнең казанышы саналырлык поэмалар. Бер караганда, бу поэмаларның сюжет жепләре өзелеп-өзелеп киткәндәй тоела. Алай түгел икән шул. Ул жепләр үзәк өзгеч моң белән тоташтырылганнар икән. Моң сихеренә ия булган шагыйрьнең үзенчәлеге, ижади табышы итеп кабул итәргә кирәк моны.

Рәшит Әхмәтжанов—үзендә шагыйрьлек куәсе булган өчен генә ижат итә торган кеше түгел. Ул—ил тарихы, халык язмышы, аның бүгенгесе һәм киләчәге турында борчылып, әрнеп ижат итүче шагыйрь. Шигырьләрендә эчке моң саркып тора. Күңелдә бар булганны ачыктан-ачык әйтергә мөмкинлекләр житмәгән очракта (торгынлык елларында язылган шигырьләрен күздә тотып әйтәм), ижатчы бүтән юлны сайлый—кинаяләр, катлауландырылган образлар аша тасвир итә. Тик шунысы хак: Рәшит Әхмәтжанов нәрсә турында гына язмасын—авыр тойгылы уйлармы алар, якты-дәртле хисләрме—Шигърияттнең Матурлыкка һәм Гаделлеккә хезмәт иткәнен бер генә минутка да онытмый. Шагыйрь күңеле үз халкының бөтен тарихын хәтердә тотып ижат итә. Хәтерсезләрне уятыр өчен нәкъ менә шундый шагыйрь кирәк булгандыр да әдәбиятыбызга.

Югарыда әйтелгәннәр Шагыйрь турында бүгенге уй-тойгыларыма, инануларыма бер дә каршы килми икән. Моңа бик шөкермен. Әлбәттә, хәзер язылса, бераз бүтәнчәрәк, бәлки, тирәнрәк, анализлырак итеп язылыр иде. Әмма Шагыйрьгә төп караш, мөнәсәбәт элеккечә калыр иде, дип уйлыйм.

Табигый хәл, күбрәк яшәгән саен хатирәләргә ешрак биреләсең. Шагыйрь әйтмешли, «жир өстендә дуслар сирәгәйде, жир астында дуслар күбәйде». Еллар узган саен гомерең сәхифәләрен—инде дөнья кичкән танышларыңныкы, дусларыңныкы белән чагыштырасың да, әллә никадәр уртаклыкларга тап буласың. Рәшит—безнең буын шагыйре, бер-ике яшькә аерма булса да, минем буын шагыйре. Әдәбиятка бер чорда килдек. Беренче китаплар да бер үк елны—1965 елда чыкты. Төрле еллардарак булса да, бер үк шәһәрләрдә яшәдек—Әлмәт, Казан. Янә, еллары бергә туры килмәсә дә, бер үк шәһәрдә (Самара), бер үк частьта, бер үк казармаларда армия хезмәтен үткәнбез (солдаттан ул пеләшләнеп кайтты, минем дә чәчләр хисабына маңгай нык кына «үсә» төште ул елларда. Шунлыктан дип беләм, Рәшит күп чак баш киемендә йөрде: кышын—бүрек, жәен—берет, бүлмә-биналарда—түбәтәй. Күп фотоларда ул шулай сурәтләнеп калган да). Сонрак—бер үк редакциядә шактый еллар бергә эшләү... Әйе, хәтердә казынсаң, үткән гомердәге янәшәлекләрне тагын да санарга була. Болары—тәржемәи хәлгә караган фактлар. Ә максат берлеге? Ижаттагы уртаклыклар? Үзе әйтмешли, бергә-бергә үткәргән «Күңел бәйрәмнәре»? Исәпләп китсәң... Бу очракта әле бер кешене, бер шагыйрьне хәтерләп искә алганда туган уйлар. Ә андый затлар аз түгел бит! Дистәләгән, хәтта күп дистәләгән. Хәтерләр хәл-вакыйгалар күп, яшьрәк буыннарга әйтерлекләре дә житәрлек. Кыскасы, безнең буынга да мемуарлар язарга вакыт житкән икән!


Рәшитнең фанийлыктан бакый дөньяга күчүенә дә жиде ел үтеп китте. Хәтер офыгыннан китеп Онытылу рәшәсендә эреп югалыр өчен ярыйсы гына вакыт. Юк, бу шәхес онытыла торганнардан түгел. Еш искә төшә, юксындыра... Бездә кайчак киткән затлар турында, тәүбәгә килгәндәй булып, ярымрия, ярымриясыз сөйләнүчеләр табыла. Янәсе, вакытында кадерен белмәдек, бәяләмәдек (дәресрәге, белмәделәр, бәяләмәделәр)... Вакытында фәлән исем бирелмәде, төгән премия алмады... Гадәттә, андый соңарып «гаделлек урнаштыручылар» хаклы булмый. Һәр конкрет очрак-фактның—үз вакыты, үз сәбәбе, һәр төеннең—үз чишелеше. Тормыш логик юрауларга караганда күпкә катлаулырак... Әйе, чыннан да, соңарулар булгалый. Шулай да, премияләрдән, мактаулы исемнәрдән фетиш ясарга да ярамый. Тарихта Вакыттан кристаллашкан Исем генә кала. Тукай, Такташ, Жәлил... Премияләре юк шикелле. Бүгенге замангарак күчсәк, «Әни килде»нең авторы, драматург Шәриф Хөсәенов—Тукай премиясе лауреаты

Диас Вәлиевтән ким санала мыни? Яки Сажидә Сөләйманова шигърияте Гөлшат Зәйнашеваныкыннан түбән мени? Рәшит Әхмәтҗанов иҗаты да кайбер исемле лауреатларныкыннан бер дә ким түгел; хәтта өстенрәк тә әле.

Шагыйрь гомеренең байтак еллары «Казан утлары» журналы белән бәйле. 15 еллап эшләде ул бездә. 1991 елда аңа Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеме бирелде. Соңгы елларда редакция вазифаларын күбрәк өендә утырып эшләде. Бергә эшләгәндә кешене шактый ук яхшы беләсең. Төрле яктан. Юк, фәрештә түгел иде шагыйрь Рәшит. Кешегә хас бөтен сыйфатларга ия иде ул. Кирәк чакта кыю һәм усал, кирәк чакта «сабыйларча» хәйләкәр... Тар иңнәргә утыртылган бу «якты башка» Ходай кинаяле, гаҗәп сыгылмалы төртмә тел биргән... Әмма, башкалардан аермалы буларак, бер үзгә сыйфаты бар иде, ул—нечкәлек. Һәрнәрсәдә: шигърияттә дә, мәхәббәттә дә, җор-мәзәк сүздә дә... Ә суверенитет өчен кискен көрәш көннәрендә, Азатлык мәйданында ачлык тотучылар белән бер рәткә басып, халкыбыз киләчәге өчен җанын фида кылырга да әзер көрәшче, милләтпәрвәр икәнен раслады.

Рәшит Әхмәтҗановның рухи яшәве дәвам итә. Әсәрләре чыгып тора. Берничә ел элек «Рухият» нәшриятында затлы китап рәвешендә аның янә бер-томлыгы дөнья күрде. Иҗатын зурлаган мәкалә-очерклар басыла. Туган авылы мәктәбендә 1996 елда ачылган музей бүлмәсенә яңа буыннар аны яд итәргә килә. Казан зиратында Тукай белән янәшә үк диярлек күмелгән каберендә чәчәкләр өзелми...

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН,**
Татарстанның халык шагыйре




# Рәшит Әхмәтҗан

**«АЧЛЫК МӘЙДАНЫ» КИТАБЫННАН ШИГЫРЬЛӘР**

* * *

**Яшәргә! Яшәргә! Азатлык алмыйча**
**Кузгалып китү юк биелгы җәемнән.**
**Башкае киселгән нәселем Агачы**
**Тамырдан таралып, дөньяга җәелгән.**

Җәелгән җиремә—үлемсез агачым,
Иелмәс иңнәре биеккә үрелгән.
Яшәргә! Яшәргә! Яшәүләр—кешегә
Мең кабат газаплы булса да үлемнән.

Коллыкны яндырып каныбыз дөрләсен,
Дөрләсен, сүнмәсен—ант итик, Ватанчы:
Йә бозлы йортыма азатлык яуларбыз,
Йә янып бетәрбез—кол булып калганчы!

Илемә багышлап үземне, сүземне
Ачлыкта утырам шул газиз нигездә.
Яшәүне сөям мин!..
Сөягем белән, Ил,
Ирекккә илтүче юлларны тигезлә!

## Соңгы чолганыш

Җирнең быелгы Тәңредән иңгән
Азатлык дигән Бөек бүләге—
Бүген дә исән булганы өчен,
Татарларыма бирелер әле.
Аз калдык шулай—илбасарларга
Яуда тереләй бирелмәгәнгә.
Зурла, Җир, безне—без үлмәгәнгә!
Азатлык биреп зурлый алмасаң,
Хәбәр ит хәлне бөтен Галәмгә.

Хәлләребезне күреп торасың.
Ничек тә безгә чыгар юл табыш,—
Божрада тота! Йота да йота...
Чыгармый тора соңгы чолганыш,
Чыгармый тора!

* * *

Ялган булып су төбенә батасы бар,
Әгәр хаклык өскә калкып чыкмаса.
Дошман таптар каберләрдә ятасы бар—
Халкым болай бер-ике ел йокласа.

* * *

Ир-атны кем тыя ала соң
Яклаучы булудан үз халкын?
Беркем дә тыялмый, берни дә!—
Синең дә, шовинист, юк хакың.

Юк, боза алмыйсың бу канны—
Агулап маташма син аны.
Кояштай... миллион чакрымнан
Микробны үтерә—Иманы!

## Булмый ул!

*Рәшит Ягъфәровка*

Таныдым. Теге давыл бу.
Нигезгә бәрә! Димәк,
Ул тынсын өчен упкынга
Корбан бирергә кирәк...

Төн җитте. Чират—минеке.
Суырып алыр агым...
Һәм булыр упкыннан чыгып
Башны калкыткан чагым.

«Ай-һай, дөнья, туйдым синнән»,—
Дип әйтер өчен түгел.
Ымлаган иде йолдызлар:
«Ни булса—безгә үрел!»

Соңгы күренү булыр ул,
Соңгы үрелүләрем,—
Батармын туганнарымның
Озатып гомерләрен.

Кешедән туйган дөньяга—
Шул булыр минем бүләк.
(Салган бөтен ясакларын
Бетергән идем түләп.)

Мине кызганамы әллә,
Офыклар кызыл төстә.
Су астында да әйтермен:
Бу дөнья безнең өстә бит,
Бу дөнья безнең өстә.

Ә син, дус, кызганма мине,
Без—үлми торган халык!
Булмагач булмый икән ул,
Халыкның җанын алып!

## Сандугач

1

Без дә бит бер сандугачның
Таллары идек элек.
Ул кунса—тирбәлә идек
Сихри сиртмәләр кебек.

Хәзер инде санламыйча,
Һавада гына оча...
Сандугач кына үтерде,
Диярсез, сайрамыйча!

2

Яшәр генә чагым иде
Сандугач кебек сайрап.
Булмады! Бабамнар кебек
Утырам кылыч кайрап...

Минем кылычка—куркыныч
Булмастыр калганнары,—
Бары тик сандугач сайрап
Сындыра алыр Аны!

3

И сандугач, сандугач,
Анда түгел, монда кач...
Синең—илең, минем—өем,
Иелми торган Агач!

* * *

Кемдер монда ирек даулый,
Кулында—милләт байрагы.
Кемдер безгә коллык яулый—
Аның да бар үз байрагы...
Ә иртәгә,
кемнәр килеп,
Нинди байрак элэр тагы?

* * *

Көн буена яннарымнан китми,
Изгелегең белән издең мине:
Кыл өстендә торам—син мактыйсың.
Шуңа күрә синнән биздем инде.

Бу көрәшнең ни икәнен аңлау
Юк икән ул синдә—сиздем инде.
Кыл өстендә торам—сокланасың.
Өметемне шуңа өздем инде!

* * *

*Кеше барыбер кошлар нәселеннән!*

Сажидә Сөләйманова

Шагыйрәмә бер нур иңсен миннән!..
Күлмәгенә генә яшеренгән—
Кеше барыбер коллар нәселеннән.

«Кол» дигәндә—кылыч чыгармыйча,
Оясында ята чыгалмыйча.

Соңгы сулышкача чыдар, чыдар,—
Хурлык кочагында җаны чыгар!

Һәрбер бөҗәк азат, һәрбер үлән—
Кеше барыбер коллар нәселеннән.

Иле елый—йоклый төне буе,
Торса—җан асрау бөтен уе,

Алай түгел дисәң—бер сорау бар:
Уйсыз калган башны асраулар

Авырдыр ла... Җавап бир син, Кеше—
Ил коллыкта—бу соң кемнең эше?!

Батыршаның йөрәге ярылып үлгән,
Бәхтиярнең башын кылыч өзгән
Мизгелләрдә җаның ничек түзгән?!

Тамак туйса—сиңа такмак кирәк,—
Кайчан җуйдың, кайда синең йөрәк?

«Кол» дисәләр—кылыч чыгармыйсың;
Өеңнән дә хәтта чыгалмыйсың;
Очкан кошлардан да оялмыйсың,—
Шагыйрәмне минем ник алдыйсың?!!

* * *

Сәфәр ае—моңлы ай.
Сал салладым—сулар сай.

Сагыш салдым—сал авыр.
Сай сулардан ал, давыл!

Сагыш авыр—китәлмәм,
Сагыш ташы икән мин.

Ышаныч юк давылга—
Көтәм. Килми алырга.

Сөю, синдә бар өмет—
Ташны эзләп тап, эрет!

Калган гомер—шушы ай.
Сал кузгалмый—сулар сай...

* * *

... Дарга китерәләр. Сакчыларның
Кырыгында—кырык кылыч бар.
Ә кешеләр, мине соңгы кабат
Күрсәләр дә, барсы тынычлар.

Болай итеп хәтта Батыршаны
Озатмаганнардыр ләбаса!
Бар гаебем—яшәү. Әйтер идем,
Хөкемдарлар әгәр сораса.

Яши-яши дарга мендем. Үлдем.
Хәзер яклап беркем дәшмәсен.
Тавышыңнан мин уянып киттем:
—Үзем үләм, ә ул яшәсен!
Яшәсен!!.

Тавышыңның кайтавазы белән
Шигыремнең ахырын язгансың:
«Икебез дә һәр көн бер үләбез,
Кавышалмый калган яздан соң».

* * *

*Куйды илтеп аузын ачкан бүрәнәгә бармагын...*

Г. Тукай. «Шүрәле»

Казанында кычкыралар:
«Камыр булма—тимер бул!»
Шик-шөбһә бар: үз йөрәген
Халкынамы бирер ул?

Мәңге алданган халыкта
Икеләнү бар тагын:
Куймас микән аузын ачкан
Бүрәнәгә бармагын?

Мәскәүдән бит ыжгыралар:
«... булма камыр—бул тимер!»
Шүрәле хәлендә калса—
Коткарырга кем килер?

* * *

Пәйгамбәр була алмассың
Исемен генә алып,—
Мөхәммәт заманыннан ук
Җисемне сыный халык.

Тугры баласын пәйгамбәр
Итәргә әзер тора,
Ә угры булса—балаңнан
Үзеңә нәрсә сора?

Бел, әгәр алданса синнән
Тугрылык көткән халык,—
Дуңгыз көтүе көтәрсең
Халкың хәлендә калып!

* * *

Ура! Урыс башлы малай килде.
Бар Мәйданга «акыл» бөркелде.
Хәлне белде (көлде), алга китте
Күчмә Кызыл Байрак шикелле.

## Синме?

Өстә калганмы дөньяның вак-төяге,—
Тамырларның кочагында кем сөяге—
Беләсеңме?

Агачларның нигә соң ул асты икән,
Әллә үзе кискән агач басты микән—
Белмисеңме?

Бар кешегә бәхет даулап яшәгәнме,
Һәм бар кеше—бер кешегә таш бәргәнме—
Белмәдеңме?

Безнең дә бит чак-чак исән калды башлар,—
Таш бәрүдә—мәргән булды замандашлар—
Беләсеңме?

Кочар икән безне кайда, кайсы тамыр,
Безне яшел ярфаклардан кемнәр таныр—
Улым, синме?

* * *

Кешеләрне яклаганда кыйнадылар,
Кыядан ук ыргытырга кыймадылар.

Уйладылар: «Кыйнаганда безне ятлар—
Бәлки әле шушы адәм килеп яклар...»

Мин дә уйлыйм йөздән канны сөртә-сөртә:
Болар белән мине алда ниләр көтә?

Һәр терене яклап җирдә яшәдем мин,
Балкып тордым, юк-бар өчен дәшмәдем мин.

Хәзер инде әйтергә дә кыенсынам:
Гомер үткән даладагы кое сыман.

Сусаганга су биргәнмен... Үткән көннәр...
Көннәремне гомер иткән әнә кемнәр!

Затсызларны үз урнына кую кирәк,—
Уйларына хәнҗәр булып уел, йөрәк!

Каршы сук та—батмасыннар билдән генә,
Басарлык ит җәһәннәмнең идәненә!

* * *

Кайтып җиттем бу дөньяның
Бер яфраксыз ягыннан.
Таптым, кактым—сезнең өйнең
Капкалары ябылган.

Шакыйм, шакыйм,—юк, ачылмый,
Ник ачылмый капкагыз?
Иксез-чиксез бу дөньяга
Ялгызымны япмагыз!

Дуслар, сезгә ниләр булды?—
Капка кагам. Бикләнгән.

Мин кайттым, мин! Кайталмас дип,
Кайсыгыздыр шикләнгән.

Йөрде мине яклый-яклый,
Саклый-саклый Сөюем...
Кертмәсәгез, китәм инде,
Сөюем бар—үз Өем!

Минем Өем бу дөньяның
Бер яфраксыз ягында.
Сугылыгыз—сулышыгыз
Бик кысылган чагында.

* * *

Күңелемдә барны барлап яшим,
Саклап яшим—үлмәм!
Күңелемдә юкны мин барыбер
Беркайчан да күрмәм.

Күңелемдә юкны беркайда да
Мин барыбер тапмам.
Күңелдәге дөньям, китмә миннән—
Үлемнәрдән саклан!

Үлемнәрдән саклан, халкым, телем—
Сакла, туган илем!
Сау булсагыз, үзем... күзегезгә
Күренмәс тә идем.

* * *

Көрәшләрдә һәлак булган изге җаннар,
Кертәм сезне исәннәрнең исәбенә.
Кеше бары кеше булып кала җирдә,
Бу дөньяны сезнең кебек сөйсә генә.

* * *

Җирдән киткән изге җаннар—оҗмахта ла,
Җирдә калган изге җаннар—тәмугта.
Тәмуглардан кемнәр тартып алыр сезне,
Сез нишләрсез икән, дуслар, без юкта?..



**Миргазиян Юныс**

# «КӘРӘЗЛЕ ТЕЛЕФОН» КӘРӘЗЛЕМЕ?

ТЕЛЕМ кычытканга түгел, тел турында җаным әрнегәнгә тагын кулыма каләм алдым әле.

Кызганыч ки, мәкалә авторын язып куймаганмын: «сотовый телефон»ны ул менә шулай «кәрәзле телефон» дип тәрҗемә иткән. Урыс телендә «сотовый» сүзе геометрик фигураны, татар телендә исә, «кәрәз» балавыздагы бал саклана торган чокырларны аңлата. Шулкадәр килбәтсез, тупас, мәгънәсез килеп чыга «сотовый телефоны», «кесә телефоны», «юл телефоны»—телдә мөмкинлекләр җитәрлек—дип алу күпкә уңышлырак, иң әһәмиятлесе, дөресрәк булыр иде. Уйлап торырга иренү, фикерсезлек, гыйбарәнең асылына төшенеп җитмәү—менә нәрсә тизләтә «өлкән абзыкайлар» теленең туган телебезне кысрыклап юкка чыгарып торуын. Ә без моны өстән кушкан буенча түгел, татарлар үзебез эшлибез.

Мәгълүм нәрсә ич, тел нинди хәлдә булса, милләтнең иминлеге, аның вөҗгыяте дә нәкъ шул хәлдә була. Тел шундый сизгер индикатор-күрсәткеч ул, аны алдап булмый. Без бу турыда кайчак уйлап та карамыйбыз бугай! Әгәр күрше телдән бер сүзне алып, үз телеңә кушсаң, күрше телен бер бернәмлеккә баетып, үз телеңне шул ук бернәмлеккә ярлыландырдың дигән сүз. Чит, ят сүз (варваризм) туган йортына керү белән генә чикләнеп калмый, ул шул йортны өкренләп җимерә дә башлый. Һәркемгә аңлашылырга тиеш шикелле шушы хакыйкатьне һаман аңлап җиткермибез, тупас үҗәтлек белән телебезне җимерүне дәвам итәбез. Шулай дигәч, тагын күз алдымда булган бер хәл искә төште. Әлмәт троллейбуслары түр як пыяла

---

Миргазиян ЮНЫС *(1927)—прозаик, публицист. «Тозлы җил» (1973), «Теләп алган давыл» (1975), «Табу һәм югалту» (1979), «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» (1981), «Юлда уйланулар» (1983) һәм башка әсәрләр авторы. Әлмәттә яши.*

стеналарына менә нәрсә язганнар: «Эш вакытында йөртүчене сөйләм белән читкә юнәлдертмәскә!» Мин бик озак сүзнең нәрсә турында барганын аңлый алмыйча баш ватып утырып карап бардым. Нәрсәне аңлата икән соң ул сөйләм белән читкә юнәлдертү?» Әһә, янәшә язылган урысча текстны укыгач кына аңлый алдым: «Во время работы не отвлекайте водителя разговорами». Шушыңа охшаш тагын бер мисал китерми булмас, ахры. Бер кибетче кибетенә «Сәнәгый товарлар» дип язып элгән. Авылдан килгән карт белән карчык бик озак аңлый алмыйча бер-берсенә карашып тордылар. Карчык картыннан сорады:

—Нәрсә саталар икән соң бу магазинда?

—Әнә бит язылган,—диде акыллы карт.—Сәнәк сата торганнардыр инде.

«Сәнәгый товарлар»га артык бәйләнеп тормастан, шуны гына искәртәм, көндәлек тормышта телибезме без, юкмы, урыс теле туган телебездән аңлаешлырак, хәтта якынрак та тоела башлады. Психология бу. Акылга да, законга да буйсынмый торган эчке бер халәт.

Галимнәр раславынча, еллар, гасырлар дәвамында көн саен кабатланып торган чынбарлыкка адәм баласы, телиме-юкмы, өйрәнеп күнегә. Тоталитар чынбарлык безне гадәлсезлеккә күнектергән. Без колониаль шартларда яшәгәнлегебезгә дә төшенә алмыйбыз, чөнки күнегеп беткәнбез. Шушы күнегүләр, кызганычка каршы, тел ярдәмендә эшкә ашырылган. Уку, белем алу, көндәлек матбугат, аралашу тел ярдәмендә бара лабаса.

«... Сөйләм белән читкә юнәлдертмәскә!» дигәнне укыганнан соң мин, филолог буларак, беренче мизгелдә телебезне гаепләдем: «Бу белдерү туган телдә ничек килбәтсез яңгырый икән»—дип куйдым. Икенче кат укып чыккач аңладым ки, телебез түгел, аны куллана белмәүче татар кешесе гаепле икән. Троллейбустагы очракта да гади генә итеп: «Эш вакытында сөйләндереп, троллейбус йөртүченең игътибарын читкә юнәлдермәгез!»—дип кенә язып куярга иде дә бит, югыйсә, әнә, нинди сафсата килеп чыккан: «игътибар» урынына йөртүчене читкә юнәлдереп куюың бар...

Әле күптән түгел генә мәктәпләрдә татар телен өйрәтә башласак, телебез аякка басар, Мәрҗанилар, Тукайлар чорындагы бай, матур тел кухняда гына түгел, җәмгыятьтә, хәтта хакимият сарайларында да яңгырый башлар дип өметләнә идек. Мәктәпләрдә, чыннан да, татар телен өйрәнәләр. Хәтта урыс балалары да матур итеп татарча шигырь укыйлар. Рәхәтләнеп тыңлыйсың һәм куанасың. Мәктәп баскычыннан төшеп урамга чыктың исә, татар теле юкка чыга. Татарлар үзләре дә туган телдә сөйләшмиләр.

Әлмәттә яшәгән бер гаиләне мин якыннан беләм. Хуҗа үзе дә, хуҗабикә дә югары белемлеләр. Югары уку йортын тәмамлаганнан соң, икесе дә биш-алты ел авылда эшләгәннәр. Авылда туып-үскәнлектән, алар әле һаман да авыл белән элемтәләрен югалтмыйлар. Пенсиягә чыккач, авылга кайтып яшәү турында хыялланалар. Балалары татар мәктәбендә укыйлар. Гаиләдә балаларның урысча сөйләшә башлаганын ишетсәләр, шунда ук туктаталар, шелтәлиләр. Әмма, ни хәл итәсең, әти-әниләре артыннан ишек ябылу белән балалар урысча сөйләшә башлыйлар. Әти-әнисенә әйтмичә генә балалар белән үзем сөйләшеп карадым. Гаепләрен таныйлар, гафу үтенәләр. Урысчага күчүне болай аңлаталар: «Татарча сөйләшкәндә, фикереңне тулысынча аңлатырга сүз җитми, шуңа күрә әңгәмә өтек чыга. Әйтәсе сүзләрне әйтеп бетереп булмый... Урысча сөйләшү рәхәтрәк...»

Аңлашылдымы? Татар теле ягында—без, язучылар (татар телле язучылар), татар зыялыларының бер өлеше, татар теле укытучылары һәм әти-әниләрнең азчылыгы. Урыс теле ягында—татар авылыннан башлап, Мәскәү Кремлендә утыручыларга хәтле хакимият, «влач», һ. б.,

һ. б. Сан һәм күләм ягыннан кайсы як зуррак, кайсы як көчлерәк? Рәсәй—көчкә, күләмгә таянып эш итә торган дәүләт.

Телсезләнү—үз телеңне оныту гына түгел. Туган телдә сөйләшергә оялып, җиребезгә басып кергән колонизаторлар телендә сөйләшә башлау гына да түгел. Мәсьәлә күпкә катлаулырак. Бер төркем кеше җыелып торган җиргә якынлашу белән татар һәр очракта урысча исәнләшә һәм урысча сөйләшә башлый. Хәтта төркем йөз процентка диярлек татарлардан торган очракта да. Татарлар янына килгән урыс та нәкъ шулай эшли. Үз телендә исәнләшә һәм үз телендә сөйләшергә керешә. Кайчагында гаҗиз калып:

—Күреп торасың бит, барысы да татарлар, нигә урысча исәнләштең һәм өлкән абзыкайлар телендә сөйләшә башладың?—дип сорыйсың. Һәр очракта җавап бер:

—Кем белә, бәлки арада урыс та бардыр?

Шул ук урыс французлар җыелып торган җиргә килсә, урысча исәнләшми бит. Хәтта монголлар яисә Африкадагы иң артта калган халык—бушменнар белән дә үз телендә исәнләшеп, бары тик урысча гына сөйләшми. Моның сәбәбе нәрсәдә? Татарларның чиктән тыш әдәпле, өлкән абзыкайларның әдәпсез, тәкәббер булуларыннанмы? Юк, моның сәбәбе тирәндәрәк ята һәм безнең өчен чиктән тыш куркыныч симптом бу. Урыс үзен хуҗа итеп тойганга шулай кылана. Озак еллар татарларны мәктәпләрдә, югары уку йортларында Чыңгыз гаскәрләре белән көнчыгыштан килгән килмешәкләр дип өйрәндек. Озак еллар шушы риялы ялганга каршы чыгарга куркып яшәдек. Нәтиҗәдә, безнең психологиябезгә килмешәклек тойгысы кереп урнашты һәм тамыр җәйде. Халык җыелып торган җиргә якынлашканда урысча исәнләшеп, өлкән абзыкайлар телендә сөйләшә башлау—үз җиребезгә хуҗа түгел итеп тоемлаудан килә ул. Шушы гадәттән котыла алырбызмы соң без? Чынбарлык өметләндерерлек түгел...

Туксанынчы елларның башында мөстәкыйльлек көрәшендә шактый гына уңышларга ирешә алдык. Көгазьдә генә булса да, Мәскәү белән янәшә утырып, Шартнамә төзедек, үзлегебездән чит илләргә чыгып йөри башладык. Мәктәпләрдә туган телне өйрәнү, татар гимназияләре ачып җибәрү, ниһаять, милли югары уку йорты ачу турында хыялланулар, дисеңме. Аз тоелса да шактый гына булган икән кылган гамәлләребез. Ә хәзер күреп торасыз, Конституциябезне юкка чыгару эше бара. Идарә итү күзгә күренеп кулыбыздан ычкынырга тора. Шушы шартларда без милләтнең киләчәге өчен көрәшә алырбызмы? Татарның мөстәкыйльлеген юкка чыгару өчен мәйдан тотучылар кулында кораллы көчләр, милиция, ФСБ, безнең наданлыгыбыз, үшәнлек һәм иң гайрәтле, хәлиткеч көч—безнең аумакайлыгыбыз. Сатылырга әзер тору дип әйтергә теләгән идем, тартындым, йомшартыбырак әйттем. Вакытлы матбугатта Ринат Мөхәммәдиевнең сатылуын фаш итү ярышы бара. Әгәр бер ул гына милләт мәнфәгатен сатса икән... Иң куркынычы—бюрократлык һәм формализм. Бу сүзләргә татар телендә эквивалент та юк. Аңлашыла торгандыр дип уйлыйм. Тоталитар империя су сибеп, назлап үстергән шушы терминнар инде күптән интернациональ аңлатмага әверелеп беттеләр.

«Сотовый телефон»ны «кәрәзле» дип калькалаштыручы, һичшиксез, югары белемле кешедер. Ул йә журфакны, яисә Казан университетының татар бүлеген бетергән бәндәдер. Ә нишләп соң ул урыс телендә «сотовый» рәвешне аңлатса, татар телендә бары тик балавыздан хасил булган бал кәрәзен генә аңлатуы белән чутлашып тормаган? Кесәгә югары уку йорты дипломы тыгып йөрү генә адәм баласын бюрократлыктан коткара алмый. Бернинди чара коткара алмый бюрократлык куркынычыннан. Бәлки җитсә дә, үлемнең генә көче җитә торгандыр шушы бөек фаҗигагә? Бюрократ ул уйлый алмый.

Уйлый, фикер йөртә башласа, эшли алмый ул. Аның төп вазифасы югарыдан агылган боерыкларны аска таба үткәреп җибәрү. Өстәгеләргә тез чүгү, аскы яктагыларны баш идертү, тез чүктерү. Шушы эштә Аллаһы Тәгалә Атабыз Адәмне бар кылганда кулланган кызыл балчык кибеп ташка әверелә, хисләр, тойгылар юкка чыга һәм кеше буйсыну-буйсындыру машинасы—роботка әверелә. Роботка әверелеп беткәннән соң аның теле дә «... сөйләм белән читкә юнәлдертмә»гә әйләнә. Менә кем җимерә, беренче чиратта, мең еллар дәвамында дастаннар, мөнәҗәтләр, бишек җырлары, сугыш гыйлеменең затлы терминнарын тудырган бөек телне. Ул аны аяусыз, варварларча җимерә. Үз иркеннән түгел, билгеле, бюрократлыкның кануны шундый. Җимерү аның иминлегенә, аның югарыга күтәрелүенә бәйле. Югары уку йортларында диплом алу өчен көрәштә күпләр уйларга, фикер йөртергә өлгерә алмый калалар. Бирәүләр уйларга өйрәтмиләр, икенчеләр өйрәнергә теләмиләр. Башкача безнең наданлыгыбыз ничек шушы дәрәҗәдә камилләшә алыр иде? Дүрт йөз кырык сигез ел татар теленә каршы аяусыз һөҗүм бара. Кимсетү, мыскыллау, ваемсызлык аша. Нинди генә ысуллар кулланмаганнар Орхан-Енисей руник язмалар чорында ук теләсә кайсы классик тел белән мәйдан тотарга сәләтле бөек телне имгәтүдә, әкренләп аның умыртка сөяген сындыруда. Совет чорына кадәр әле баш бирмәгән татар теле вазифасын фидакярлек белән үти килгән. «Агыла да болыт агыла, туган-үскән илләр ягына. Тәрәзәмә чиртер дә яңгыр, нәрсә әйтер туганнарыма? Агыла да болыт агыла...» Музыкага тиң, өшкергәндә дәва бирерлек әлеге тылсымлы сүзләр, Хәсән Туфан күкрәгеннән бәреп чыгып, әле күптән түгел, совет чорында барлыкка килгәннәр. Ә инде бүгенге көндә без: «... йөртүчене сөйләм белән читкә юнәлдертмәгез» шикелле куркыныч өрәкне күрәбез, ишетәбез. Күргән чаралар телебезне үлемнән коткара алырмы соң?

* * *

КАЯН, нәрсәдән башлана күмәк, рәсми томаналык? Туган телкөебезне фикердән аерудан. Күптән күзәтеп йөрим, мәктәпләрдә һәм югары уку йортларында укучылар һәм студентлар сорауларга кәгазьдән укып җавап бирәләр. Алар гына түгел, укытучылар, фән докторлары үзләре дә шәкертләренә кәгазьдән укып аңлаталар. Бу очракта остаз бары тик магнитофон ролен генә уйный. Аудиториягә тапшырылган сүзләр дөрес бирүченең күңелендә фикер булып барлыкка килми. Күп очракта ул әле текстны юньләп аңлап та бетерми. Үзе аңламаганны ул ничек аңлата алсын? Надан остаз шәкертен наданлыкка өйрәтә. Көндәлек тормышта уйлау, мөстәкыйль фикер йөртү сирәк очрый башлады. Көнкүрештә генә түгел, вакытлы матбугатны, телевизион тапшыруларны әкренләп фикерсезлек, буш сүз баса бара. Бер генә мисал. «Тоташ философия, укырга авыр»,—дип, минем «Без—коллар» исемле әсәремне басмадылар. Бүгенге көндә татар язучысының төп бурычы—укучыны уйланырга, фикер йөртергә өйрәтү, күнектерү түгелмени? Без бит әле һаман туган телне югалту гамәлен милләтне югалтуга тигез икәнлеген аңлый алмый интегәбез. Татарның милли идеясе—милләтебезне саклап калу булырга тиеш. Телебезне саклап кала алмасак, милләтне берничек тә коткара алмаячакбыз. Дөрес, коллык шартларында, милексез, ялланып эшләп, татар үзенең телен дә, дәүләтчелеген дә коткара алмаячак. Исән калу өчен татар милекле булырга, милләтнең мөстәкыйль финанс системасы булырга тиеш. Фикер йөртә белмәгән бәндәгә шушы хакыйкатьне аңлату мөмкинме? Юк, билгеле. Без бит әле шушы көнгә кадәр Икенче бөтендөнья сугышында бары тик урыс дәүләтен генә коткарып калуыбызны аңлый алмыйбыз һәм аңларга теләмибез.

Татар шушы көнгә кадәр урыс мәнфәгатен үз мәнфәгате дип алданып йөри. Әнә, 1992 елның февралендә Татарстанда Референдум үткәрә башлагач, Урта урыс калкулыгы ягыннан кораллы көчләр чигебез янына килеп туктады. Ә без шул кораллы көчләрдә хезмәт итәбез, сугыш вакытында кан коябыз һәм коелган каннарыбыз белән горурланып йөрибез... Моны ничек аңламак кирәк: безнең үз армиябез үзебезне үтерергә килгән?.. Ялганга ышанырга өйрәнгәнгә шулай ул. Ялганны табигый дип кабул иткәннән соң, адәм баласы дөреслектән бизә һәм курка башлый...

Бөек немец философы Мартин Хайдеггер «Время иные» исемле китабында телне: «Язык есть вечно обновляющаяся работа духа, направленная на то, чтобы сделать артикулированный звук выражением мысли»,—*(262 б.)* дип аңлата. Икенче урында: «... мысль дает бытию слово. Язык есть дом бытия. В жилище языка обитает человек. Мыслители и поэты—хранители этого жилища»,—*(192 б.)* дип яза. Тәрҗемә итеп тормыйм. Бу сүзләрне без татарлар яши торган һәр йортның, һәр мәктәпнең, һәр югары уку йортының, һәр учреждениенең ишеге төбенә язып куярга тиешбез. Адәм баласы тел йортында яшәгәч, без, татарлар, кем йортында яшибез соң? Фатирда торучы белән үз йортында яшәүчене чагыштырып карагыз. Шушы чагыштыру безнең мескенлекне, үшәнлекне, томаналыкны аңларга ярдәм итәр иде. Җиребездән 3 миллиард тонна нефть суырып алып, «яшел акчага» сатканнар. Ә без ярым ач, ярым ялангач. Кая соң шул нефть сатудан кергән доллар кәшелләре? Әгәр без туган телебез йортында яшәсәк, туган туфрагыбыздан суырылган кара канның триллион долларлары Баренц диңгезенең төбендә, Вьетнам сазлыкларында, Чечня хәрабәләрендә күмелеп калуын аңлар идек шикелле...

Японнар җирендә йөргәндә, миңа бер нәрсә сеер тоелды. Икенче бөтендөнья сугышында японнарны АКШ гаскәрләре яулап алды. Алар әле дә шунда. Ләкин японнарның тәрҗемәчеләреннән һәм америкалылар белән эш итүчеләреннән тыш инглиз телен белүче японны очратмадым диярлек. Японнар безнең шикелле чит телдә сөйләшеп яшәсәләр, бүгенге уңышларына ирешә алырлар идеме икән?

Башкалабызда Салих Сәйдәшевкә һәйкәл куярга җыенабыз. Тик урын гына таба алмыйбыз. Җирле түрәләр: «Башта хуҗаларга (Шаляпинга), әби патшаның арбасына һәйкәл» куйыйк әле, әгәр хуҗалар рөхсәт итсә, үзебезнекеләргә дә куярбыз, дип уйлыйлар, ахры. Һәр эштә шулай. Һәр вакыйгада. Фатирда торган кеше ничек инде үз телендә сөйләшә алсын. Хуҗаның шикләнүе бар ич, «бу нәрсә сөйли, миңа каршы сөйләшмиме икән?»—дип уйлавы бар. Хуҗаның күңелен күрер өчен без, билгеле, аның телендә сөйләшәбез. Тел бит «яшәеш йорты», нинди телдә сөйләшсәң, шул телдә яшисең. Димәк, без инде Казан ханлыгын яулап алып, безне үзләренә буйсындыручыларча яшибез. Дөрес, үзебезчә яшисе килгән чаклар да еш була. Яшәргә тырышып карыйбыз, анда барып бәреләбез, монда килеп сугылабыз, әмма берни эшли алмыйбыз, чөнки йорт өлкән абзыкайларныкы, йорт хуҗасы нәрсә теләсә, шуны эшләргә мәҗбүрбез.

Укучының минем белән килешмәве бар. Урыс теле—бөек тел бит, урысча сөйләшеп без берни оттырмыйбыз, киресенчә, отабыз гына»,—дип дәлилләве бар хөрмәтле укучының. Урыс теле, чыннан да, бөек тел. «Прощай немытая Россия, страна господь, страна рабов»,—дигән урыс шагыйре Михаил Юрьевич Лермонтов. Һәм шушы бер җөмләгә тарихчылар Карамзин, Соловьев, Ключевскийның дистәләгән томнарына сыя алмаган империя тарихын сыйдырып бетергән. Лев Толстойның һәр җөмләсендә колач җитмәслек бөек фикерләр, Пушкинның һәр сүзендә музыкага төрелгән акыл һәм хакыйкать ята. Бәлки, чыннан да, татар теленнән тизрәк ваз кичеп, Лермонтов, Толстой, Пушкин телендә, бары тик шушы бөек телдә генә сөйләшә

башларга кирәктер? Нигә юкка өзгәләнергә? Инде баш биргәнбез, барыбер империянең корыч йодрыгына каршы тора алмаячакбыз?.. Шулай дип уйладым да, үз уемнан үзем куркып куйдым. Чөнки без «Рәсәйдә яшибез».

Халыкара ПЕН-клубның соңгы конгрессында мине бер нәрсә хәйран калдырды: Татарстанның яртысы зурлыгы Швейцариядә язучыларның мәнфәгатьләрен якларга тиешле өч Пен-үзәк яшәп килә икән. Җир йөзендәге иң тыныч, иң бай илдә. Швейцария студентлары аена 1000 доллар стипендия алып укыйлар. Укытучының тәҗрибәсенә һәм осталыгына карап, 3000 доллардан 5000 долларга кадәр эш хакы түгаенләнә. Инде ничә гасыр бу ил бер генә сугышта да катнашмый. Җир шарының бай кешеләре акчаларын Швейцария банкларында саклыйлар. Шул акчаларның процентлары, илнең данлыклы курортлары, тау үләне ашап үрчегән сыерларның тәмле сөтләре һәм ышанычлы тынычлык—менә каян агыла швейцариялеләрнең керемнәре. Бу илдә французча, немецчә һәм итальянча сөйләшеп яшиләр. Өч тел дә дәүләт теле санала. Мәктәпләрдә аларның өчесен дә өйрәнәләр. Телләр арасында бернинди кыерсыту юк. Аңлашыла ки, милләтләрнең үзара тигезлеген, татулыгын телләр тигезлегендә, телләр тигезлеген бары тик тынычлык шартларында гына саклап була. Гомер-гомергә зур, көчле армия тоткан, туктаусыз сугышып торган илдә нинди тигезлек, нинди хокук саклап булсын! Армия кайсы милләт кулында—шул милләт өстенлек итә һәм башка милләтләрне кыерсыта. Менә каян башлана икән Рәсәйдәге тигезсезлек, бу илдәге гасырларга сузылган колониаль буйсынуга дучар ителгән халыкларны урыслаштыру процессы... Ассимиляция астыртын рәвештә, яшертен юл белән эшләнә. Бер генә мисал. Узган елда Рәсәйдә яшәүче халыкларга Милли мәдәни мохтарият (Културно-национальная автономия) ачарга рөхсәт иттеләр. Кул чабып каршы алдык империя ыргыткан сөякне. Татарлар нәкь Алтын Урда чорындагыча Татар бугазы ярлыкларыннан алып, Карпат таулары итәкләренә кадәр таралып яшиләр. Димәк, татар яшәгән җирдә туган телебездә белем биргән мәктәпләр, театрлар, һ. б. ачу мөмкинлеге туды. Ләкин акчасыз рөхсәт, кысыр рәхмәт ул. Урыс телен, урыс культурасын, гореф-гадәтләрен саклау, үстерү өчен без, вак милләтләр, кесәбездән чыгарып салым түлибез. Урыс теле, урыс мәдәнияте бюджет акчасы белән тукланып симерә, шуңа күрә ул беркайчан да юкка чыкмаячак. Ә без телебезне, культурабызны саклау өчен акчаны каян алырга тиешбез? «Суверенитетны күпме йота аласыз, шул кадәр алыгыз»,—диде Президент Ельцин. Гасырлар буе урыс солдатлары аткан пуля, снарядлар астында яшәгән, туган туфракларыннан сөрелгән чеченнәр Ельцин тәкъдим иткән мөстәкыйльлекне йөз процентка алырга ниятләделәр. Нәтиҗәне күрәсез, Ичкериядә бер генә исән калган йорт, улын, ирен, әтисен, туганнарын югалтмаган бер генә гаилә дә юк бүгенге көндә. Татарстандагы телләр тигезлеге дә нәкъ шуңа охшашлы. Республикада ике дәүләт теле, шуларның теләсә кайсысын сайлагыз. Нишләптер, татар телен сайлаучы урысны, гомер буе эзләп йөрсәң дә, таба алмассың. Ә без, татарлар, телебезне югалтуның финалы ничек булачак, бу турыда уйларга теләмибез. Чара күрүче булмагач, уйланудан ни файда? Мин бик озак нигә без уйламыйбыз, дип аптырап йөрдем. Чынбарлыкның асылын аңлый алган бәндәнең язмышы фаҗигале шул.

* * *

ХАЛЫКАРА ПЕН-клуб конгрессы барганда озак еллар мине тынгысызлап торган тагын бер сорауга җавап таптым. Америка Кушма Штатларының аборигеннары—индианнар бары тик резервацияләрдә

генә сакланып калганнар, ә американнар шул кырылып беткән халык биргән тау, елга, күл һәм башка табигать исемнәрен үзгәртмичә саклап торалар: Кентукки, Арканзас, Огайо штатлары, Аппалач таулары... Энемнең дусты булган Америка язучысына мин шушы сорауны бирдем:

—Индианнар кушкан исемнәрне сез нигә үзгәртмичә саклыйсыз?

Ул миңа ничек җавап бирде:

—Алар бит шул исемне йөрткән җирләрнең җанына тиң. Гомумән, тарихи исемнәрне үзгәртү—искиткеч зур варварлык ул. Тарихка тияргә ярамый. Исем ул—шул ук археология. Казымыйча алырлык археология байлыгы.

Чыннан да, Америка экологлары индианнарның табигатьне саклау кануннарын җентекләп өйрәнәләр. «Тарихка тияргә ярамый». Тарих үзен-үзе ясый. Аны вакыйгалар агымы, шәхесләр майтарган гамәлләр тудыра. Бу инде күпләргә мәгълүм хакыйкать. Бәлки бу хакта урыс сәясәтчеләре, Рәсәй хакимияте генә белми торгандыр? Бәлки белергә теләмидер? Татарстаныбызда исән килеш сакланган исем бармы икән? Бар! Урыс исемнәре. Явыз Иван җиребезне басып алгач, шул ганимәт җирне саклар өчен урысларны куып китереп нығытмалар кора башлаганнар. Алар XVI гасырда, һичшиксез, үзләрен бүгенге көндә Чечнядагы урыс гаскәрләре шикелле сизгәннәр булса кирәк. Ят җирләр. Тирә-яктагы авылларда татарлар яши. Тоткан диннәре—ислам, гореф-гадәтләре—чит, телләре—аңлашылмый. Урысларга шундый шартларда яшәү чиктән тыш авыр булгандыр? Дөресен әйткәндә, кулыңнан коралны төшермичә, көне-төне куркып, сагаеп яшәүне яшәү дип тә булмый инде. Кирәк-ярак, азык-төлек белән тәэмин итү урыс армиясендә гомер-гомергә начар булды. Урыслар арасындагы урлашу, кеше өлешенә керү гадәте—ул бит бүгенге көндә генә барлыкка килмәгән. Димәк, яулап алынган җирләргә урнашкан гарнизоннарда яшәүчеләрнең җирле халык белән аралашырга теләве табигый гамәл. Әби патша заманында, ягъни колониализмның башлангыч чорында яндырылган, җимереп бетерелгән мәчетләрне торгызырга рөхсәт итүне, Казанда Шәрекъне өйрәнү эшләрен оештырып җибәрүне җирле халыкка урыс телен өйрәнү дип түгел, киресенчә, җирле халыкның телен өйрәнүне оештыру дип аңларга кирәк. Мәрҗанинең урыс телен өйрәнергә өндәве нәкъ шушы фикерне раслый. Бүгенге көндә бөек татар галимен урыс телен өйрәнергә чакырганы өчен гаепләүчеләр дә күренә башлады. Мәрҗани бит колонизаторларның телен өйрәнергә кирәк дип татарның зыялыларына мөрәҗәгать итә. Минемчә, Мәрҗани урыс телен өйрәнүне башлау белән татарларның үз телләреннән ваз кичүгә барып җитәчәген күз алдына да китерә алмагандыр. Әле бит бүген дә туган телебезне югалтуның фаҗигасен тулысынча аңлаучылар, хәтта галимнәребез арасында да, күп түгел. Чиновниклар арасында андыйлар бөтенләй юк диярлек. Ә инде хезмәт иясенә килгәндә, аларның уенда бары тик исән калу кайгысы гына.

Урысларның татар теленә җирәнеп караулары турында мин мунча кергәндә сөйләшергә яратам. Беренчедән, мунчада урыслык өлле кайдан күзгә ташланып тора. Икенчедән, юынганда адәм баласының феодаллык чорыннан бирле үзгәрмичә сакланган өстендәге киеме аша үзенең түрәлеген, байлыгын, элитага якын икәнлеген исбатлау юкка чыга. Адәм баласы мунчада ихласрак сөйләшә. Берчак шулай шәрә урыс белән шәрә татар әңгәмә куертабыз.

—Без урысларны яратуыбызны исбатлау өчен телләрен өйрәндек, культураларын үзләштердек. Ә урыслар безне яратмыйлар булса кирәк—телебезне өйрәнергә теләмиләр,—дим әңгәмәдәшемә.

—Сезгә җиңел, урыс телен өйрәндегез—шул җитә. Ә мин бит татарстанлылар телен: чуашныкын, мариныкын, мордваныкын, удмуртныкын

һәм, шуңа өстәп, татарныкын да өйрәнергә тиеш,—дип аңлата акыллы урыс.

«Татар» сүзе урынына сәясәтчеләребез дә «татарстанлы» гыйбарәсен куллана башладылар. Бу инде, үзенә күрә, «без милләтче түгел, республикабызда яшәгән барлык милләтләрне дә тигез күрәбез, хәтта үз милләтебезнең исемен дә кулланырга теләмибез» дигәнне аңлата булса кирәк. Сүзгә генә түгел, гамәлдә дә Татарстан Рәсәй империясендә иң интернациональ, иң толерант мөнәсәбәтле республика. Чынбарлыкта ул шулай, ә менә «татарстанлы» сүзен урыс шовинисты үзенчә аңлаган. Ул аны теге Брежнев чорындагы «историческая общность—советский народ» мәгънәсендә кабул иткән. Билгеле, «ул» үзен кертмәгән милләтсез бердәмлеккә. Без, милләт булудан туктап, «татарстанлы»га әверелгәнбез...

«Когда в душе воистину пробуждается чувство, что язык есть не просто разменное средтво для взаимопонимания, но подлинный мир, который дух внутренней работой своей силы призван воздвигнуть между собою и предметами»,—дип аңлата Мартин Хайдеггер һәм тагын менә нәрсә дип өсти: «Путь к языку обусловлен не столько языком как языком, сколько стремлением в единой картине представить совокупность духовно-исторического развития человечества в его цельности, но одновременно также и в его всегдашней индувидуальности» *(263 б.)*.

Әгәр Мартин Хайдеггерның «Телгә бару юлы» («Путь к языку» исемле фәнни эшенең эчтәлеге турында сөйли башласам, мәкаләм китапка әйләнер иде. Бәлки безнең галимнәребез тиздән Хайдеггерның бу әсәрен туган телгә тәрҗемә итәрләр? Телгә багышланган эшен тәрҗемә иткәндә аның «гуманизм турындагы язма» («Письмо о гуманизме») исемле фәнни эшендә татарчага әйләндерергә кирәк булачак, чөнки шушы ике язма үзара тыгыз бәйләнештә торалар. Бу хакта мин шуңа күрә озаклап сөйләп торам: әгәр без бөек немец философының телгә һәм тел аша рухияткә һәм, гомумән, галәмгә, яшәешкә тоташуны исбатлаган фәнни эшләре белән таныша алсак, туган телебезне югалтуның безгә нинди афәтләр китергәнлеген аңлый алыр идек.

Хәтерлисезме икән, Брежнев чорындагы торгынлыкта яшәгән совет кешесенең сәясәткә карата философиясе менә болайрак иде: «Тоталитарлыкмы, демократияме—нинди аерма, сугыш кына чыга күрмәсен». Ә сугыш дигән нәрсәнең туктаганы юк иде, совет кешесе тынычлыкта яшим дип алданганда, сугыш туктап тормады. Татар кешесе үзенең туган теле юкка чыгуга да шулайрак карый. Янәсе: «Әйбәт кеше нинди телдә сөйләшсә дә әйбәт кеше инде ул. Татарча сөйләшкәнгә карап кына начар кеше әйбәтләнә алмый бит. Татар экстримистлары «телебез бетә», дип шыңшып, кеше көлдереп йөриләр». Икенче зур дәлил болай яңгырый: «Гел татарча сөйләшеп йөргәнгә карап минем тамагым туярмыни?» Укучы, бәлки, бу сүзләрне мин үзем уйлап чыгарган дип хөкем чыгарыр? Мин аларны туган ягым Баулыда ишеттем. Тагын кабатлыйм: «Тамак тук, өс бөтен, дөньялар тыныч булганда, нинди телдә сөйләшсәң дә барыбер түгелмени?»—бу сүзләрне мин көн саен диярлек ишетеп торам.

Егерменче гасырның иң бөек философы Хайдеггер бөтенләй башкача уйлый. Телне ул болай аңлый: «Тәрәккыять юлында кешеләрнең тарихи һәм рухани омтылышларын үзара тел механизмы уртаклаштыра...» Урыс теленә күчү үзеннән-үзе безнең мөстәкыйльлеккә, иреккә, үз җиребезгә үзебез хуҗа булып яшәүне мәңгегә юкка чыгарып, «единая недилимая Россия» өчен көрәшүчеләргә әверелүебезне немец философы шул кадәр ачык һәм төгәл исбатлый алган.

* * *

БҮГЕНГЕ көндә татар халкы ике юл чатында кая барырга белмичә аптырап карап тора. Сулга китсәң, йөз процентка урыслашасың. Бу очракта без тарихтагы иң кыргый, иң аяусыз империянең барлык әшәкелекләре өчен өлкән абзыкайларыбыз белән тигез җавап бирәчәкбез. Җир шарының иң бай, иң уңдырышлы җирендә халкын ачлы-туклы яшәтеп тотканы өчен дә, туктаусыз сугышып торып, хатын-кызны тол, балаларны ятим, ирләрне гарип яшәткәне өчен дә без җавап бирергә тиеш булачакбыз. Гасырларга сузыла Рәсәй оештырган сугыш. Чит дәүләт белән сугышудан туктап торган чакларда Явыз Иванның опричнинасы, революция, гражданнар сугышы, 37 еллардагы геноцидтагыча үз халкын юкка чыгара Рәсәй. Без, урыслашкан татарлар, бу җинаятьләр өчен тарих хөкеме каршында тулысынча җавап бирәчәкбез. Ә инде бүгенге көн җинаятьләре, чечен халкын тулысынча юкка чыгарып, Ичкерия җирен «Град», «Ураган» снарядлары артыннан калган вулкан көленә әйләндергәнебез өчен тарих хөкеме алдында, һичшиксез, җавап бирәчәкбез, чөнки без ул җинаятьләрне бергәләп эшләдек.

Чатлыктагы юлның икенчесе—татарның телен торгызуга һәм, Мартин Хайдеггер әйткәнчә, «туган тел йортында яшәүгә» алып бара. Бу чиктән тыш авыр, сикәлтәле юл. Көрәш юлы беркайчан да җиңел булмый, без бу хакыйкатьне белеп торырга тиешбез. Бүгенге көндә без: «Туган телне мәктәпләрдә өйрәнәләр, Аллага шөкер»,—дип тынычланып яшибез. Бер генә мисал: марксизм-ленинизмны без беренче класстан ук диярлек башлап, вузны бетергәнче укып өйрәндек һәм шуннан соң атна саен политдәресләрдә тукран шикелле тукып тордык. Бүгенге көндә шул тәгълиматны белгән кешене таба аласызмы сез? Юк, билгеле. Татар теле дәресләрендә инде менә дүрт ел даими катнашып, тыңлап утырам. Нәкъ марксизм-ленинизмны өйрәнгәндәгечә, тоташ формализм ысулында бара туган телне өйрәнү дәресләре. Туган телдә язылган китапларның күпчелеге социалистик ярышка, социализм төзүгә багышланган. Татар язучылары арасында бер төркем урыс һәм дөнья әдәбиятыннан сюжет-коллизия урлап тамак туйдыра. Татар китабының сатылмавы, мәктәпләрдә татар әдәбиятының абруйсызлыгы, бәлки, татар китабында милләтнең язмышы чагылмавы, өсәр эчтәлегенең безгә чит, ят булуыннан киләдер?

Ә инде туган тел коралы белән тамак туйдыручы журналистларның «кәрәзле телефон», «сөйләм белән читкә юнәлдертмәскә» шикелле шедеврлар тудыруы хакында баш ватып торуның кирәге дә юк. Бу мисалда тәрҗемәченең мәктәп елларында туган телнең шифалы сулышын, аның җанын тоя алудан мәхрүм калуы ярылып ята, лабаса.

* * *

МӘКТӘПЛӘРДӘ туган тел дәресләре кертү генә телкәебезне коткара алмаячагын аңладык шикелле. Телне һәм шуның аша үзебезне коткару өчен нинди чаралар күрергә тиеш икәнбез соң? Телебезнең язмышы бүгенге көндә хакимият сарайларында, дәүләт структураларында хәл ителә. Идарә итүдә ике дәүләт теленең бары тик берсе генә өстенлек тотуын кабатлап торуның кирәге дә юктыр? Бу турыда тукып тору туйдырып бетерде инде. Туктаусыз кабатлап торуга карап, бу мәсьәлә барыбер халкыбызның, бигрәк тә җитәкчеләребезнең аңына барып җитә алмаячак. Әнә, Латвиядә мөстәкыйльлек яулаганнан соң икътисади һәм сәяси проблемаларны тулысынча диярлек хәл итә алдылар, ә урыс теле мәсьәләсен бернәрсә эшләтә алмыйча интегәләр.

Ике дәүләт теле үзара тигез булсын өчен, беренче чиратта, һәр дәүләт чиновнигы ике телне дә белергә тиеш. Ә инде югары

звенога килгәндә, әгәр без Президент итеп Татарстанның титуллы телен белмәүчене сайлап куйсак, бу инде мәсьәләсе көн тәртибеннән алып ыргытыла дигән сүз. Минемчә, һәр депутат та ике дәүләт телен белергә тиеш. Әгәр депутатлыкка дәгъва кылган урыс депутаты икенче дәүләт телен, ягъни татар телен белми икән, аның мондый үз кимчелеген рәсми рәвештә күтәреп чыгарга батырлыгы җиткән кеше Татарстанда бармы соң? Совет чоры безне милләтчелектән куркырга, шовинистлык белән горурланырга өйрәтте. Без әле һаман совет чоры күзаллавын дәвам итәбез. Депутатларның ике дәүләт телен дә белергә тиеш булуын тормышка ашырасыбыз килсә, без әшне туган телен белмәгән татар депутатларыннан башларга тиешбез. Бу мәсьәләне тормышка ашырырга безнең көчебез җитәргә тиештер.

Май аенда Мәскәүдә узган 67 Бөтендөнья ПЕН-клубы конгрессында кыерсытылган телләргә багышланган фикер алышуда мин Татарстандагы вәзгыятьне болай аңлаттым. Тел—аралашу күпере. Тел өйрәнү, телсезлек елгасы өстенә салынган күпергә тиң. Татарлар, урыс белән толерантлыкта яшәү теләгенә буйсынып, үз ярларыннан урыслар ягына таба күпер салдылар. Мин үземнең милләтем белән горурлана алам. Татарлар арасында урысча белмәгән кешене ни кадәр эзләсәгез дә очрата алмассыз. Ә урыслар күпернең икенче яртысын—татарлар ягына юнәлдерелгәнен салдыlargeмы соң? Алар күпер саласы ярга пушкалар, танклар китереп урнаштырдылар да, «күпернең саласы өлешен салып бетереп», безнең тулысынча урыслашып бетүне көтеп тора башладылар.

* * *

ТУГАН телнең фаҗигале язмышына җаным сыкрау хакында яза башласам, зарларымның очына чыга алмыйм. Менә хәзер дә нокта куяр алдыннан уйга калдым. Кем укыр бу мәкаләмне? Авылда яшәүчеме? Аларның үз зарлары муеннан. Производствода эшләүче слесарь, металл кыручымы? Алар арасында «Казан утлары»н алучы чиктән тыш аз. Татар галимнәреме? Белмим, бәлки миңа гына шулай тоела торгандыр, фән докторлары, академиклар саны күбәйгән саен, милләт язмышына бәйләнешле мәсьәләләр белән кызыксынучылар саны азая бара шикелле. Бәлки минем каләмдәшләрем укыр бу мәкаләмне һәм минем ялгышлыкларымны табып, тәнкыйтьләп чыгарлар? Әйтмим бу турыда, үземдә калдырам. Болай да зарым чиктән ашты. Көлеп-елмаеп, бер-беребезгә комплиментлар гына әйтешеп яшәр чак килерме икән безгә?

*Декабрь, 2000 ел.*

*Әдәбият тарихы*

**Тәлгат Галиуллин**

# ТУКАЙНЫ ЯҢАДАН УКЫЙБЫЗ...

Тукай шигърияте жиһанга ямь, яктылык бөркеп торучы, тун катлауларны эретеп, жиргә, күңелләргә жылылык бирүче кояш кебек үзенә бер илаһи көчкә ия. Аның иҗаты тар кысаларга гына сыймый, ул халкыбызның «хәсрәт көен көйләп», авыр үткәне белән саубуллашып, киләчәк өчен көрәшергә өйрәтә, шуңа чакыра.

Әдәбият күгендә нибары 7-8 ел ялтырап, үз йолдызлыгын—шигъри мәктәбен—тудырган шагыйрьнең мирасы күп тармаклы, киң кырлы. Аның үткен телле публицистикасы, камчылы сатирасы, кинаяле юморы, тәнкыйть эшчәнлеге—һәркайсы игътибар үзәгендә торырга тиеш. Тукай шигърияте турында сүз чыкканда исә фән белгечләре, тәнкыйтьчеләр күбрәк Тукайның сәяси юнәлеше алга чыгып торган «Государственная Думага», «Китмибез», «Көзге җилләр», «Сорыкортларга», «Сафия» кебек әсәрләрен үзәккә алалар. Чөнки аларның мәсләге, юнәлеше, максаты ачык ярылып ята, юл араларыннан кичереш төсмерләрен дә эзлисе юк.

Ә укучыга тәкъдим ителгән бу парчаларда исә сүз Тукайның «онытылыбрак» торган, мәктәп дәреслекләренең түрендә урын алмаган, кайчагында «пейзаж лирикасы» дип аталган шигырьләр турында бара. Табигать матурлыгын сурәтләүдән башланган ул шигырьләргә әдәп-әхлак, милләт язмышы мәсьәләләре килеп керә. Лирик затның уй-кичерешләре гаҗәеп бай, каршылыклы. Бередә тирә-якның хозурлыгы күңел шигърияткн тудыра, тормыш, язмыш турында уйландыра.

**«Көз»** (1906)—халык, милләт язмышы турында ачынып, уйланып язылган әсәрләр шәлкеменнән. Бер караганда, табигать күренешләрен эзлекле рәвештә тасвирый алым белән күз алдына бастырган шигырьләргә тартым, җавап та таләп ителми торган риторик эндәш («Күрәмсез, дусларым, көз килде...») белән башланып киткән тезмә күңелдә авыр, басынкы хисләр уята. Игеннәр урылган, җыелган, тургай пыр-пыр килеп ризык эзли, кошлар җылы якларга очып китәргә әзерләнә, урманнар саргаеп, зәгъфран түсенә кергән, мәрхәмәтле кояш та яктысын киметкән.

Лирик затның күңелен ниндидер үкенечле, хәтта кайгылы, сагышлы хисләр ташкыны били. Шигъри сурәткә көзгә нәфрәт уятырдай усал, төртмәле, кue төсләр килеп керә. Әйтерсең лә, ел фасылы аның шәхси дошманы: «Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез» кырларны ул мазарстан-каберлеккә тиңли, табигатьнең бу чорын кабул итмәвен кат-кат тәкърарлый («Ничәйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез»). Укучы күңелендә үз рухына кулай кичереш, хисси якынлык уяткач, көзге табигатьне әле читкәрәк китеп сурәтләгән шагыйрь үз шәхесенә кискен сикереш ясый:

Үлеп торсам иде мин алты айдай,
Эреп бер йокласам мин сары майдай...

Димәк, лирик зат көзне, аның артыннан килгән кышны бөтенләй кабул итми, берише җан ияләре шикелле (әйтик, аюлар, ташбакалар) тирән йокыга талу турында хыяллана. Шул йокысыннан аның яз җиткәч, җиһанны яшеллек каплагач кына, «бәхетле һәм тәхетле» шаһ булып уянасы килә. Тукай шигырен шунда тәмамлап, нокта куярга да мөмкин иде, чөнки тәгәлләнгән фикер

әйтелгән, кичереш эзлекле рәвештә үстерелгән. Тик иҗатчының күзне бөтенләй кабул итмәве, ямьсез буяулар, ачулы, әрнүле сурәтләве генә аңлашылып бетми. Кайбер шагыйрьләрне көз үзенең туклыгы, туйлары, төрледән төрле буяу-төсләре белән сокландырган ич, аларның илһамнарын уяткан. Тукайның остазы Пушкин—шуның ачык мисалы.

Татар шагыйре көзге нәкышьләр белән хозурланып, дөньясын онытып, мәхәббәт сагышларына бирелеп кенә утыра алмый шул. Аның җанын дәүләтчелекне һәм хаким көчен югалтып, мәрткә киткән халкының ачы язмышы телгәли. Ләкин шагыйрь чит көчләрне гаепләү, дәүләтне, патшаны битәрләү юлына басмый (бу хакта шул ук елда язылган «Государственная Дума» шигырендә үз сүзен әйтер), озак еллар дәвамында көз халәтендә калып, якты язына, матур аяз көненә килә алмаган өчен ул халкының үзен генә гаепли. Дөрес, алдарак ул кыр «Такыр калды татар башы кеби» дип, татарның артка калуына, иске йолаларга ябышып ятуына төрттереп узган иде, хәзер аны «И фәкыйрь милләт» дип атый һәм шигырен кискен сорау белән тәмамлый: синең язың мин «кабергә сөрелгәч, кыямәт көндә мин үлеп терелгәч» кенә килерме икән?

Шул рәвешле, табигатьнең бер фасылын сурәтләүдән башланып киткән шигырь халык язмышы, киләчәге, бигрәк тә үзаңы уяну кебек катлаулы җәмгыяви, хәтта сәяси мәсьәләләрне калкытып куя. Үзәктә кискен тәнгәллек, янәшәлек алымы ята: ямьсез көз—шулай ук сүнүгә, инкыйразына йөз тоткан милләт. Үзәктә лирик затның бер нәрсәне дә тиз генә үзгәртеп булмауны аңлавы тудырган ачынышлы, авыр кичереш. Үз халкының язын (бәһарын), якты көнен (нәһарын) күрү өчен шагыйрь үлеп, кыямәт көнендә уянуга да риза.

Тукай авыр хисләренә тиң, халкы язмышының чарасызлыгын күпертеп күрсәтердәй сынландырулар тапкан: «басты золмәт, китте якты». Шигъриятенең үзәк традицион образларыннан—җил сурәте дә читтә калмаган. Ул—афәт илчесе, явызлык хәбәрчесе: әүвәл ул суык җил колакны шаулата, аннан «Тулып әчкә өрә, мисле куык...» Суык җил белән куыкның рифмалашуы да хис-тойгыларны куерта. Унберле-унберле ижеге белән, бернәчә гарәп, фарсы алынмаларыннан башка саф татар әдәби телендә иҗат ителгән «Көз» шигыре табигать фасылы аша катлаулы иҗтимагый гамәлләр мәгънәсен белдерә белүнең ачык үрнәге.

**«Җәйге таң хатирәсе»** (1910). «Федоровтан мокътәбәс» дип куйган бу шигырендә Тукай табигатьнең матурлыгын, кабатланмас гүзәллеген, тыйнак нәфислеген ачып бирүгә омтыла. Иҗатының әлеге чорында шагыйрь, гомумән, әйләнә-тирә мохиткә, мәңгелеккә игътибарлы, ул күбрәк табигать фасылындагы илаһи, саф күренеш-манзараларны үзәккә ала, сурәтләү чараларын кызганмыйча, саранлык күрсәтмичә, мул, иркен куллана. «Урынын» таң өчен бушатырга мәҗбүр булган күктәге айга нисбәтән бер-берсен кысырыклап вә тулыландырып өч эпитет килә: моңлы, хәсрәтле, ялкау. Шагыйрьнең хөр күңеле иртәнге яктылыкны да гади генә кабул итә алмый: ал таң галибанә (җиңүче рәвешендә) нурланып җиһанга җәелә, шул арада йолдызлар сүнә, йөрәкләрне иләсләндереп йомшак, иркә, назлы саба җиле исеп куя.

Кыскасы, төнге караңгылык пәрдәсен алып ташлап, кешеләр көтеп алган мәрхәмәтле таңның җиңүен шагыйрь искиткеч маһирлык белән тасвирлый, аны мөселман кешесенең күзаллавына якын, әмма ифрат яңача янгырашлы образлар ярдәмендә күз алдына бастыра:

> Пәрдәдән чыкты, ачылды ямь-яшел кыр һәм ялан,
> Китте инде кап-кара каплап ята торган чапан.

Шул мизгелдә дин әһелләре кия торган кара чапан һәм куе яшеллеге белән сафландыргыч кыр-басулар күз алдында пәйда була. Мондый хөрриятне, иртәнге азатлыкны сихерле көзге күк серле күлләр, елмаеп көлмәкче чәчәкләр, лаләләр, үләннәр, ягъни барча тереклек зарыгып көткән икән. Ә рәхмәтне исә шагыйрь сайрар кошлардан әйттерә: «Сандугачлардан ява, янгыр кеби, мәдхияләр».

Иртәнге ямьле, сихәтләндергеч гүзәллеккә вәйран калган «аккошлардай ак күчмә болытлар төркеме» дә мәңгелек хәрәкәтен туктатып тора. Ләкин табигатьнең хәтердә калырлык бу матур манзарасын тасвирлау шагыйрь өчен үзмаксат түгел икән. Соңгы ике юлда иҗатчының асыл нияте, шигъри максаты тәгаенләнә: синең алдыңда җәйге таңның иң гүзәл, иң саф чагы, әфәндем, син дә йоклап ятма—«Шул вакытта уйла, шагыйрь: килде илһам, уйласаң». Бердән, табигый

матурлык, туган жирнең газиз якынлыгы, йокысы туйган сабый бала кебек, елмаеп, балкып уянуы хисси жанлы адәм баласын битараф калдыра алмый. Икенчедән, шагыйрь илһам күктән иңәр дип көтеп утыра алмый; ул туктаусыз эзләнә, табигать күркен сиземли, аны жанына үткәрә белергә тиеш. Бары тик уйлы сүз остасы гына тирәлек, мохит ямен аңлый һәм укучысына ирештерә ала.

Тукай үзе дә иртәнге табигый гүзәллекне ачып салуга буяуларны кызганмаган. Таң, ай, йолдыз, чәчәк, аккош, ак болытлар кебек халык фикерләвендә туган сурәтләр һәркайсы үзенчә, янача (ак болытларны күктәге аккошлар белән чагыштыруга гына игътибар итегез) яңгыраш алганнар. Әмма табигать кабалануны, кирәкмәгән ашыгуны сөйми. Биредә таң жиле иплəп кенә исеп куя, «яфраклар аз-аз селкенә». Мохиттәге тыныч талгынлык, күренешләрнең табигый, тәртипле алышынуы (берсе дә чиратсыз керми) үзе үк унбишле ижекне, таң ата—ай бата, лаләләр—мәдхияләр, күркене—төркеме кебек иркен, ятышлы рифмаларны сорап тора. «Жәйге таң хатирәсе» татар шигъриятендә пейзаж лирикасы үсүгә уңай йогынты ясаган әсәрләрнең берсе булды.

**«Иссез чәчәк»** (1910) шигыренә өлгене Тукай XIX йөз башы шагыйре И. Дмитриев парчасыннан алган, ләкин ул әлеге әсәрне (шигырь «Полевой цветок» дип атала) кабатлау юлына басмыйча, фикерне тирәнәйткән, үстергән. Әсәр күчерелмә мәгънәгә, кинәйтелгән метафорага корыла. Болынлыкта үсеп утырган гади, «иссез чәчәк янлыш» хуш исле чәчәкләр белән бер бәйләмгә эләгә. Бик гадәти гамәл. Шуннан нәрсә булган? Аз гына вакыт узуга, кыргый чәчәккә хуш, гүзәл исләр сеңгән, ул да затлы чәчәкләр рәтенә кергән.

Әлеге үзгәрешне бәян итү соңгы ике юлда ясалачак әхлакый нәтиҗә, йомгак өчен кирәк. Мәгърифәтнең файдасына, киңәш бирүнең уңай йогынтысына инанган Тукай биредә форсатны ычкындырмый, табигать күренешен кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә күчерә. Адәм баласы да, кыргый чәчәк үрнәгендә, яңа, уңай мохиткә эләксә, «тәүфикъле дус-ишләр һәм белешләр» белән аралашып яшәсә, «гүзәл гадәткә һәм дә изге эшләргә» өйрәнер, янача яши башлар.

Саф татар әдәби телендә язылган бу шигырь табигать күренешләре белән кешелек җәмгыяте арасындагы якынлыкны, күчешне, дәвамлылыкны раслаучы шигырьләрнең берсе.

**«Пушкиннән»** (1906)—Тукайның «Шүрәле» имзасы белән нәшер ителгән, башлангыч чор иҗатына караган шигырьләреннән. Әсәрнең «Тәрҗемә вә тәшрих» дигән үзгә исеме дә мәгълүм. Ошбу шигырьне укучысына тәкъдим иткән «Уклар» журналы Пушкинның 1824 елда язып башлап, төгәлләнми калган исемсез тезмәсен китерә һәм чибәр бер кызның рәсемен дә бирә.

Тукай нигез-өлге итеп алган шигырен Пушкин гаремга килеп эләккән чибәр кызга мөрәҗәгать-киңәш рәвешендә язган. Ирең үзенне алты хатыны янына кертеп бикләгәнче, азатлыкның кадрен белеп кал, каберлек янындагы фонтанга бар, салкын чишмә суын чумырып алып, шуңа карап, яшь гомернең дә шулай ялтырап, чәчрәп эзсез югалуы, үзеннең дә хәрәмнән кире яшьлегенә әйләнеп кайта алмавын турында уйлан, ди шагыйрь.

Тукай әлеге шигырьнең үзәк фикерен, яшь кызга юнәлтелгән, кинәйтелгән риторик эндәш алымын саклаcа да, эзмә-эз, сүзгә-сүз тәрҗемә юлына басмый. Исемгә чыгарылган «тәшрих» сүзе исә ачыклау, шәрехләү дигән мәгънәне бирә. Сибгат Хәким бик дөрес язганча: «Тукай иҗади тәрҗемә иткән; үз рухына туры килгән әсәрләрне генә тәрҗемә иткән. Артык намуслы шагыйрь булганга күрә, ул әз генә иярсә дә, һәр шигырьнең башына кемнән файдалануын язып барган» *(Тукай Г. Әсәрләр. Дүрт томда. 1 т.—Казан, 1975. 12 б.).*

«Пушкиннән» шигыре—иҗади тәрҗемәнең ачык үрнәге. Төп нөсхәдә сүз үткән заманда булып узган хәлләр турында барса (ир хәрәмендә инде алты хатын бар), Тукай, нәкъ шулай буласына шик-шөбһә белдермичә, вакыйганы киләчәккә күчерә: «Тагы алты хатын алыр, тагын да алыр,—туймас, алыр жан бар чагында». Ул залим ир синең кадереңне белеп, синең генә тәменне татып яши торган адәм түгел. Аны үзгәртеп булмаячак, язмыштан узмыш юк. Яшь кызга киңәшен Тукай, Пушкин үрнәгендә, әмма тагын да кискенрәк төстә, боерык фигыль ярдәмендә ирештерә: «хәл начар, кыз!, «йөгер фонтанга», «чишмә суын түк, сип тә, уйна», мөмкинлек булганда, иркәләнеп, шаярып кал, ди.

Автор чибәр, яшь бичара кыз язмышына битараф булмавын яшерми. Тукай әсәрендә кыз баланың үкенечле киләчәге, фаҗигасе көчлерәк сурәтләнә.

Бу хәлнең мәгълүм иҗтимагый-сәяси сәбәпләре бар.

Урыс шагыйренең телгә алынган әсәрен «Уклар» журналы «Пушкин—ислам хатыннары хакында» дигән гомуми баш астында бирә. Бөек шагыйрь иҗатында Коръән, көнчыгыш мотивлары, мөселман динендәге хатын-кызларның язмышы мәгълүм урын алып торса да, төп юнәлеш түгел. Аны күбрәк урыс җәмгыяте, андагы вәзгыять борчый. Шуңа күрә, ул хәрәмгә эләккән кыз турындагы, тулаем алганда, ифрат көчле чыгачак шигырен тәмамламый, ярты юлда калдыра, исем эзләп тә баш ватмый.

Өлкән яшьтәге байларга һәм дин әһелләренә хатыннары өстенә кияүгә бирелгән, сатылган яшь кызлар язмышы Тукайның исә йөрәгендә, бәгырендә утыра. Чынлыкта «Пушкиннән» әсәре татар җәмгыятендә кол хәленә төшерелгән хатын-кызның хокукларын яклау, аның авыр, аянычлы язмышына игътибар юнәлтү максаты белән язылган. Исеме әйтеп тормаса, Тукайның иң яраткан унберле иҗек белән, төгәл һәм яңа кафияләр ярдәмендә язылган ошбу шигырьнең кем әсәренәдер нәзирә буларак язылган икәнлегенә төшенмәскә дә мөмкин. Чөнки үзәктә—татар теле ярдәмендә ачылган татар дөньясы. Тукай, Пушкин шигыренең табышын үстереп, аккан су белән кеше гомере, хатын-кыз язмышы арасындагы якынлыкны тасвирлауга зур әһәмият бирә. Су үз юлындагы барча чүп-чарны читкә атып, «көмеш төсле агадыр» һәм каядыр кереп югаладыр. Агым суның тавышы, өне калмый, гомер дә шулай бик тиз үтеп китә, дөньяда вакытны туктата алырлык көч юк. Тукай үкенечле, фаҗигале, йөрәкне әрнеткеч сүзләрне кызның үзеннән әйттерә:

Бетәмен, гаиб булам, калмый эзем дә;
Бәхил бул, и кичем һәм көндезем дә!

Татар һәм гомумән көнчыгыш хатын-кызлары тормышы, язмышы белән китаплар яисә икенчел чыганаклар аша гына таныш Пушкин фаҗигане тетрәндергеч яссылыкка күтәрә алмый. Тукай шигыренең мөстәкыйльлеге исә күләм үзгәрешендә дә күренә. Пушкинга фикерен әйтү өчен тугыз юл җитсә, Тукайга кичерешне ачып, җәеп салуга егерме юл кирәк була.

**Пушкин вә мин** (1912) иҗат юлының башында Тукай күренекле урыс шагыйрьләре Пушкин белән Лермонтовны остазлары дип атый, алар мирасыннан өлге алуын, әдәби осталыкка өйрәнүен яшерми. Ләкин үзе әйтмешли, югарыга үрли барган саен, үз-үзен, мөстәкыйльлеген раслау рухы көчәя бара. Ярым шаян, чынында, җитди мәсьәләләр күтәргән «Пушкин вә мин» шигыре шуның ачык үрнәге.

Тезмә кискен чагыштыру, капма-каршы куя алымы белән башланып китә:

Хәзрәти Пушкин авылда язды үз «Евгениен»,
Мин исә җырлыйм фәкать бәрәнгенең көен.

Сарай һәм шәһәр шагыйре Пушкин, соңрак тәнкыйтьче В. Белинский тарафыннан «урыс тормышының энциклопедиясе» дип бәяләнгән «Евгений Онегин» исемле атаклы шигъри романын вакытлыча авылда яшәп иҗат итә. Мәгълүм булганча, үзләрен, вакытларын кая куярга белмичә интеккән өстен сыйныф вәкилләре тормышын сурәтләү аша әсәрдә чорның катлаулы әхлакый, фәлсәфи мәсьәләләре күтәрелә. Романның төп каһарманнары—бай, зыялы катлау кешеләре.

Тукай исә, үзе кат-кат искәрткәнчә, фәкать «бәрәнге көен» җырлау белән мәшгуль. Әлбәттә, «бәрәнге көе»—шартлы алым, метафора, аны туры мәгънәсендә кабул итәргә ярамый. Монда тел төбеннән гади халык тормышына, аның мон-зарына, шатлык кайгысына якынлык сизелә. Тукай үз остазының тук тормышлы, нәзберек зәвыклы, сәнгать белән генә яшәгән югары катлау кешеләре, генераллар, Татьяна кебек чибәр кызлар турында гына язуын хупламавын яшерми дә. Әнә шулай итеп шигърият үсешендәге ике юнәлешне капма-каршы куя-куя укучыны әзерләгәч, Тукай төп фикерен әйтә:

Шунда күрмим үземне һич тә Пушкиннан түбән;
Тугъры күз салсан эшенә—ул үзе миннән түбән.

Гаҗәеп үткен фикер! Шагыйрь алдагы юлларда, шулай ук күпертү алымына таянып үзенең ни өчен бөек Пушкиннан өстен торуын исбатлауга ирешә. Җиһан бервакыт Пушкинны һәм аның романын онытыр, ә Тукайның

«Бәрәңгесе», анын дәртләнеп, илһамланып сурәтләгән, гадәти, ямьсез, әмма чын тормышны үзәккә алган шигырьләре «яуме мәхшәрсез» (кыямәт көне житкәнче), дөнья юкка чыкканчы яшәячәкләр. Шагыйрьнең үз-үзенә, ижатының мәңгелегенә ышанычы пәйгамбәрләр-чә алдан күрүчән булды.

Ләкин әле бу урында шигырь төгәлләнмәгән, ана ниндидер хисси-фикри дәлил житеп бетмәгән кебек тәэсир кала. Шуна күрә шагыйрь үз ижат юнәлеше—реализм файдасына янә бер исбатламыш өсти.

Язганың булса бәкалы, ул бәкага тартыла:
Мин дә булдым һич тә онтылмас кеше шул аркада.

«Бәкалы» (дәвамлы), «бәкага» (дәвамга, мәңгелеккә) сүзләре исә шигырьнең мәгънәви-фикри офыгын киңәйтеп жибәрәләр. Иманына, намусына, сайлаган юлына тугрылыклы, туган халкы мәнфәгатьләреннән читкә тайпылмаган шагыйрь беркайчан да оныттылмас, каләме чүпчарга уралмас, тутыкмас дигән фикер алга сөрелә. Бераз мактанып куюдан да тартынып тормый Тукай.

Ләкин үзен Пушкин белән янәшә, хәтта халыкчанлык нисбәтеннән аңардан өстенрәк тә куеп, ул һич кенә дә остазының рухын рәнжетми—аңа «Хәзрәти Пушкин», дип олылап эндәшә. Димәк шунда да ул үзенен «бәрәңге көен»—пакъ, чиста сүзен, ялган белән пычранмый торган ижади юнәлешен, мәсләген—фидакарьләрчә яклап, раслап чыга.

«Пушкин вә мин» шигырендә чит телләрдән алынган берничә сүз («яуме», «бәкалы») татар теленен фонетик һәм морфологик таләпләренә буйсынган. Әсәрнең өслүбе Тукай өчен гадәти (15-19 ижекле) булса да, рифмалары ифрат үзенчәлекле. Пушкин романынын һәм каһарманының исеменә татар теленнән ике аваздаш сүз-кафия табылган: Евгением—көен, Евгенией—минем. «Көен» белән «минем» алдыннан «бәрәңгенең», «бәрәңгемне» сүзләре килү исә Пушкин әсәренә хас югары өслүбне тормыш-көнкүреш дәрәҗәсенә төшерә.

«Пушкин вә мин»—Тукайның әдәбият тарихында үз урынын билгеләгән, ижат юнәлешен элгәрләре белән бәхәстә раслаган әсәрләреннән берсе.

**«Гомер хакында»** (1909) шигыре «Яшен» журналында басылып чыга. Ул нибары ике юлдан тора:

Бик күңелсез бу начар журнал—гомер,
Анда, әлбәт, баш мәкалә мал ирер.

Шагыйрь шул чорда яшәгән кешенең гомерен (үзен дә әлеге рәткә кертеп) сай эчтәлекле, буш, начар журналга тиңли. Бер яктан, Тукай ул елларда яшәп килгән кайбер басмаларның түбән сыйфатына төрттерсә, икенчедән, мәгънәсез, күңелсез узган гомерне күчерелмә сурәт аша тәнкыйтьли. Әмма иң начар дәрәжәле журналның да баш мәкаләсе кемгәдер файда китерә. Димәк ки, берише кешенең гомере дә «мал ирер»гә багышлана, күнелсез журнал дәрәжәсенә төшә. Турыдан-туры әйтмәсә дә, Тукай мондый тук тормышны хупламый, басмага сылтаган булып, астыртын рәвештә замандашларыннан көлә. «Гомер—(мал) ирер» рифмасы кешенең бәясе төшүгә, асыл кыйммәте югалуга ишарә кебек яңгырый.

**«Гомер юлына керүчеләргә»** (1910). Әдәбият галимнәре, тәнкыйтьчеләр Позняковтан файдаланып язылган бу әсәрнең соңгы юлларын еш кабатлыйлар («Нигә мин кечкенә Апуш түгел, зур-зур Тукай булдым?») һәм аны шагыйрьнең үзен житлеккән шәхес, әдип буларак танылуына ишарә, мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализмга күчүенә дәлил итеп китерәләр. Бу гоманда, бәлки, дөреслек бардыр. Әмма ижатчы үзе гомер юлына керүче сабыйларга булган бу мөрәжәгатендә ниндидер олы, нәзари мәсьәләләр калкытуны, йә чишүне максат итеп куймый. Ул үзе үткән тормыш ызаннарын барлый, кайбер нәтиҗәләр ясый (аңа әле бу вакытта нибары 24 яшь!), шәхси тәҗрибәсеннән чыгып, мәктәп балаларына сүз ката, аларны ихластан аңлап, хәлләренә кергәндәй, яклагандай, теләктәшлек иткәндәй була. Шигырьнең жавап таләп ителми торган, гади, риясыз беренче юллары да шул хакта сөйли: «Беләм инде, сабыйлар, сезгә мәктәптә күңелсездер. Аның тоткынлыгыннан сез бигүк түгелсездер». Мәгълүм микъдарда балалар халәтенә якынлык белдергәннән соң, күчеш ясап, шагыйрь үзенең сабый чагын искә төшерә. Ул да хыялында «анда да монда очып йөреп», «азатлык» эзләгән, аның күңеле дә мәжбүриятне, тар кысаларны кабул итмичә, гел иреккә, киңлеккә, мөстәкыйльлеккә омтылган.

Газаплы, авыр күренгән бу «мәхбүс» шәкерт еллары үтеп киткән, лирик зат богау-чикләүләрдән азат хәят юлына баскан. Ул «дәү кеше» булып киткән һәм «хәзер тормыш белән уйныйм» дип, тоташ уен-көлкедән, кайгы-хәсрәтсез бәйрәмнәрдән торган киләчәгенә юл ала. Мәктәп тәртибеннән, анда хөкем сөргән әдәп-әхлак богауларыннан арынса да, ни хикмәттер, лирик зат үзенең соңгы чор тормышында артык шатлыкны да күрми, тулы азатлыгы да аңа сөенеч-ләззәт китерми. Киресенчә, сабый чакта күрелмәгән житди сынаулар, күңел сызлаулары килә һәм ул, ниһаять, «гомер итмәк» дигән ата-бабадан калган гыйбарәнең асыл мәгънәсенә төшенә башлый. Күбәләк төсле чәчәктән чәчәккә очып йөрү генә түгел икән гомер итү. Борчу, кайгылары, бихисап мәшәкатьләре дә күп икән аның.

Үз ачы тормыш тәҗрибәсеннән, ижтимагый дөньяны яңача, тирәнрәк анлавыннан чыгып, шагыйрь гомер юлына керүчеләргә киңәшен бирергә, аксакаллар мисле өйрәтеп алуны, әдәп-әхлак кагыйдәләрен искә төшерүне кирәк дип таба: «Гомер итмәк»—тырышмактыр ялыкмый, һич тә ял итми», ялкаулыгыңны жинә алсаң гына халкыңа һәм тәңренә бурычларыңны кайтара алырсың. «Гомер сахраларын» гизгәндә арыган, талчыккан, тукталып тору турында хыялланган, төшенкелеккә бирелгән авыр мизгелләрендә ул нурлы мәдрәсә елларын искә ала, шул чор истәлекләрендә үз күңеленә юаныч, таяныч таба, «тоткынлык» елларын ихластан сагынып куя. «Зуп-зур Тукай»ның хәтта сабыйчак елларына әйләнеп кайтасы килә. Шуңа күрә талгын, салмак кына үсеп килгән әлеге кичереш киеренке халәт, тирән үкенеч төсмере ала.

Әсәрнең мантыйкый үсеш юнәлеше буенча шагыйрь гомер юлына керүчеләргә нисбәтән шигырь башындагы мөрәҗәгатен кабатларга яисә искә төшерергә тиеш иде кебек. Әмма ул чакта шигырь үгет-нәсихәт, дидактик әсәр булып китәчәк. Тукай мондый жиңел юлга басмыйча, үз шәхси тойгысын, үз хәсрәт-үкенечен алга чыгару белән чикләнә: «Нигә, дим, изге мәктәптән, сабый чаклардан айрылдым?» Нәтиҗәне һәркем үзе ясасын.

Уналтылы ижек белән язылган «Гомер юлына керүчеләргә» шигырендә Тукай, максатына яраклы рәвештә, катлаулы метафоралар, сынландырулар эзләп баш ватмый, фикерен, киңәшен ачыктан-ачык әйтеп бирү алымын сайлый. Дөньяга ике төрле караш (сабый чак һәм житлеккән чор), ике төрле әхлакый мөнәсәбәт (мин һәм алар—сабыйлар) кичерешнең каршылыклы, шул ук вакытта эзлекле үсешен тәэмин итә.

**«Шигърият һәм нәсер»** (1911) Тукайның эчтәлеге, сәнгатьчәлеге ягыннан иң катлаулы, шул чор яшәешенең ижтимагый каршылыкларын калкытып куйган, хәтта әдәбият белән сәнгатьнең төрле якларын инләгән әсәрләреннән берсе. Күренекле галим И. Нуруллин бу шигырьдә «саф сәнгать» тарафдарларының поэзиясе белән тормыш прозасын каршы куеп» сурәтләү күрә *(Нуруллин И. З. XX йөз башы татар әдәбияты.—Казан, 1982, 120 б.).*

Чыннан да, әсәрнең исеме үк табышмактай сәер, бәхәсле һәм төрлечә анлатуларга урын калдыра. Аны тар кысаларга, әзер калыпларга сыйдыруы кыен. «Шигърият» сүзе жанрны, әдәби төрне билгеләүме, әллә табигать күренешләрен, анда кичереш үсеше белән бәйле хәрәкәтне (шигырьдә без ямьле кичтән алып таң атканчы, кояш чыкканчы барган үзгәрешләрнең шаһиты булабыз) тасвирлаумы? Тирәлекне, мөхитне үзәккә алган юлларның куш тырнаклар эченә алынуы да тикмәгә түгелдер.

Ә «нәсер» билгемәсе нәрсәне анлата? Шагыйрь аны түбәнрәк, талымсызрак төргә санап, һәр куплетның соңгы ике юлында төрле яклап фашлана килгән «шәһәр серләрен» төртмәле бәяләү өчен кулайрак күргәнме? Һәрхәлдә, бер шигырьдә ике дөнья, матурлык белән оятсызлык, хозурый иркәлек белән женси азгынлык, көн белән төн, су белән ут кебек янәшә киләләр. Алар бетемнәрендә рифмалаша, әмма аерым-аерым яши.

Һәр куплетның беренче ике юлын укыганда, өченче, дүртенче юлларда сүзнең ни хакында барасы, ниндирәк фикер әйтеләсе турында фараз кылуы да кыен, чөнки алар арасында мантыйкый, мәгънәви яисә хисси бәйләнеш, дәвамлылык юк диярлек. Тукай үз дәверенең игътисадый-сәяси хәлләреннән, жил-давылларыннан читтә кала алмаган шикелле, аның каһарманы да ямьле күл буенда, кичке ямь белән хозурланып, дөнья мәшәкатьләренә, кешене мыскыл итүгә, изүгә, кысуга кул селтәп карый алмый. Ваемсызлык битлеге

астында яралы, рәнҗүле, игътибарлы жан яши. Жае чыккан саен, ул башкалар исәбенә рәхәттә гизүче затларга үпкәсен, үчен сездерә тора, кемнәрдәндер көнләшеп куюын да яшерми. Ул да бит—адәм баласы.

Җәмгыятьнең кеше күзеннән читтәрәк булган, яшеренгән күренешләрен, мажараларын күзәтү өчен урыны да бик мәгънәле сайланган: балкып чыккан ай нурында иркәләнеп, ялтырап яткан «тын күл» буенда ук җиңгәчинең яшерен фәхешханәсе дөрләп эшли, чибәр жарияләр байның күңелен «төрлечә» күрәләр. Шунда ук «Бай абый! Бирче хәер! Бик ач торам», дип иңри, шыңшый торган бер тишек акчага лаек булган теләнче малай хуҗаның саруын кайнатып аяк астында бутала. Байга да тынычлык юк, ул да, йөзен сытып, зарлана: «-Бәдбәхетләр! Сез талап, дөньям минем Гүр кебек».

Шул рәвешле, шигырьнең үзәгендә төрле мәгънәви яссылыкларда яткан төшенчәләрне янәшә, дөресрәге, капма-каршы кую, фәнчә әйткәндә, антитеза алымы ята. Бер якта шигъри гүзәллеклеге, кабатланмас яме белән үзенә тартып торган табигать, икенче очта түбән өслүб белән тасвирланган бозыклык, азгынлык, тотнаксызлык. Нурлы йолдызлар белән бизәлгән күк астында берәүләр кәеф-сафа кора, типтерә, хәтта йолкыш Гыймуш та акчага «хур кочмак була», ә ярлылар ачлыктан тилмерә, хәер эсти.

Шул арада әле генә күкне бизәп торган нурлы йолдызлар берәмләп сүнә башлый, сандугач сайравына башка кошлар да кушылып, җиһан таңны каршылый. Тиздән күл белән кояш нурлары кушылыр.

Аңа карап кына җирдәге тигезсезлек, явызлык, оятсызлык бетәрме? Бу сорауга җавап шигырьнең «нәсер» өлешендә, өченче-дүртенче юлларында эзләнә. Әле һаман да «иске корсактан» әшәке өн килә, тәрәкъкыйче, ягъни алдынгы карашлы булуга дәгъва итүче берәү «сугыш булса», «Ишмиләр юкка түнәр», дип сөйләнсә, Ишми исә мактануын, шапырынуын белә: «Күп җәдитне мин җибәрдем кабренә». Икенче бер көч: «Аклыкны ватам!» Бәндәләр «төнгә» ахырда күнделәр», дип җикеренә. Беренче ике юлда әкрен генә таң ата, Ә Ишминең фикердәше, аркадашы, гомумән, аклыкка, киләчәккә кизәнә.

Шул рәвешле, шагыйрь эзлекле рәвештә чорның катлаулы иҗтимагый вәзгыятен ача. Шигырь һәм эчтәлеге, һәм бирелеш рәвеше буенча тәгәлләнгән бөтенлек дәрәҗәсенә җиткерелә. Шунда нокта куелыр дип уйларга мөмкин. Әмма үзен татар дөньясында барган һәр нәрсә өчен җаваплы санаган Тукай әдәбият вә сәнгать мәсьәләләрен һич кенә дә әйләнеп үтә алмый. Ул үз фикерен, бәясен әйтеп калырга ашыга.

Бу очракта аны татар мәдәни үзәкләренең берсе булган Әстерханда көтмәгәндә җырчы булып киткән Камил Мотыйгый-Төхфәтуллинның талымсыз, зәвыксыз («агач») репертуары, Сәйяр артистларының «корсак кайрап» йөрүләре пошаманга сала. 1905-1911 елларда нәшер ителгән «Казан мөхбире» битләрендә, гомумән шигырьдә, шау-шу чыгарып, һәртөрле шәхси эзләнүләр белән мавыгуы өчен шагыйрь Сәгыйть Рәмиевкә дә шактый көчле тәнкыйть чыбыгы эләгә.

Шул чорда «Йолдыз» газетасы битләрендә, Г. Ибраһимов белән Тукай арасында шигырьнең тормыштагы урыны, мәгънәсе, эчтәлеге турында кызу бәхәсләр бара. Романтик рухлы Г. Ибраһимов хиссият вә хыял дөньясына йөз тоткан шигъриятне яклап, Тукайны тормыш ваклыкларына артык игътибарлы булуда гаепли, С. Рәмиев белән Дәрдмәнд поэзияләрен күтәрә. Тукай чынбарлыкны бөтен ялангыч дөреслеге белән тасвирлаган поэзиянең дә яшәргә хакы барлыгын яклап, чыга. «Шигърият һәм нәсер» шигырендә ул әлеге бәхәсләргә дә җавап бирә кебек. Беренче юлларда ул идеал тормышны, романтик манзараларны, илаһи матурлыкны үзәккә алса, өченче-дүртенче юлларда реалистик сурәтләү алымнарына өстенлек биреп, тормышның түбән, әшәке якларын сурәтли. Шигырь белән назым (тезмә), романтизм белән реализм бер шигырьгә, хәтта бер куплетка, үнберле иҗеккә сыеша.

Шул рәвешле, «Шигърият һәм нәсер» әзерлекле, Тукай яшәгән, иҗат иткән чорны яхшы белгән укучыга йөз тотып язылган полемик әсәр. Ул гасыр башында ук иҗат ителгән булса да, заманча яңгырашын, шигъри нәфислеген югалтмаган әсәрләрнең берсе. Азгынлыкны, бозыклыкны фашлавы, ачы тәнкыйди рухы белән ул безнең катлаулы икътисадый-сәяси чорыбызга да якын, аһәңдәш.

## Ədəbi tənqit
## Әдәби тәнкыйть

# МИЛЛӘТ КАҺАРМАНЫ

Фәнис Яруллин... Кем генә белми икән бу исемне, кем генә яратып укымый икән аның тирән мәгънәле, матур телле шигырь-поэмаларын, хикәя-повестьларын! Әйе, ул күптән инде милләтебезнең горурлыгына әйләнгән олы әдип!

Быел «Яралы язмышлар» исеме белән татар, рус һәм инглиз телләрендә дөнья күргән, үтә дә гыйбрәтле әсәре аша Фәнис Яруллин Америка халкына да танылды. Чөнки бу әсәрнең персонажлары—Казан ятимнәре—хәзер Америкада гаилә җылысы, ата-ана назы, кыскасы, бездә төшләренә дә кермәгән бәхет тапты.

«Бу китапның язылышы үзе бер китаплык булса, аның инглизчәгә тәрҗемә ителүе үзе бер гыйбрәт»,—дип сөйләгән иде Фәнис бер очрашуда. Китапның татарчасы басылып чыгып, укучыларда уңай тәэсир алгач, әсәрдәге кайбер ятимнәрне Америка ата-аналары үзләренә уллыкка-кызлыкка алалар. Америкага киткән балалар, билгеле, мондагы тәрбиячеләрен сагынып яши.Һәм алар үзләренә аеруча якын булган Миңлегөл апаны эзләп Мәгариф министрлыкларына, төрле оешмаларга хат арты хат яудыралар. Ниһаять, бер хатлары Миңлегөл апага килеп җитә. Миңлегөл апаның да андагы балалар белән ешрак хат алышасы, аларның тормышларын тирәнтенрәк беләсе килә. Һәм Фәнис Яруллин Миңлегөл апаны Казан шәһәренең 2 нче татар гимназиясенә җибәрә. Бу гимназиядә компьютерлаштырылган класслар бар. Интернет белән тоташкан электрон почта һәм инглиз телен яхшы белүче татар укытучылары укыта. Ул укытучылар Миңлегөл апаның татарча язган хатларын турыдан-туры инглизчәгә тәрҗемә итеп Америкага җибәреп торалар. Ә соңыннан, бу хатлар нигезендә Фәнис Яруллин «Йөртә безне язмышлар» дигән повесть язгач, 2 нче гимназиянең инглиз теле укытучылары аны да татарчадан инглизчәгә тәрҗемә итә. Бу әле татар әдәбиятында турыдан-туры инглизчәгә тәрҗемә ителүче беренче әсәр булгандыр. Дөрес, соңыннан редактор Н. Савухина әсәрнең әдәби эшләнешен карап чыга.

Шунысы кызык, бу әсәр үзебездә китап булып чыкканчы ук Интернет аша Америкага җибәрелә. Анда әсәр бик ошый. Һәм китап булып басылып чыккач, бу ятимнәрне тәрбияләүче ата-аналарга гына түгел, Америкадагы мәктәп балаларына да көчле тәэсир ясый. Аны мәктәпләргә алып барып укыйлар. Шулай итеп бездәге ятимнәр язмышы зур яңгыраш ала. Китапның ике кисәге берләштерелеп «Яралы язмышлар» исеме белән басыла.

Баулы районы, Кызылъяр авылында туган ачы язмышлы, гаҗәеп көчле рухлы бу егет минем өчен аерата якын...

Казанның иң зур мәктәпләреннән саналган, рус һәм татар яшьләренә белем бирүче 18 нче эшче-яшьләр урта мәктәбендә директор булып эшләгән чагым. Бервакыт, шигъри җанлы укучыбыз Арсланова Рушания аркылы, солдат хезмәтендә фаҗигага очрап, сөлек кебек бер татар егетенең хастаханәдә ятуын ишетәбез. Алтмышынчы еллар башында республика газета-

журналларында аның күп кенә шигырьләрен укысак та урта белеме булмавы башыбызга килмәде.

Мәктәпнең уку-укыту эшләре мөдире, физика укытучысы, искиткеч кешелекле Наилә Гатауллина хастаханәгә барып, бу егет белән танышып кайтты. Табиблар белән сөйләшкәч, аның киләчәктә аякларына баса алмаячагы беленде. Ничек кенә булмасын, егеткә урта белем кирәк.'Сөйләшү вакытында Фәнис үзенең укырга теләвен белдерде.

Педсовет. Сөйләшәбез... Киңәшәбез... Аерым расписание төзеп, хастаханәгә йөреп егетне укытырга, дигән карарга киләбез. Бу изге, әмма түләүсез эшкә беренчеләрдән булып татар теле һәм әдәбияты укытучысы Вәли ага Хаҗиев бик теләп алынды. Калган укытучылар да ризалык бирделәр. Шулай итеп, тар гына палатада, бик тә кыен шартларда, авырту-сызлануларын чыраена да чыгармыйча (аның кечкенә генә хәрәкәте дә коточкыч авырту бирә, диләр иде табиблары), искиткеч зур тырышлык белән дәресләр ала башлады Фәнис.

Көн арты көн, ай арты айлар үтте, имтиханнар вакыты да килеп җитте. Үзен кызгануларын кичерә алмаганын белсәк тә, табиблар белешмәсенә таянып, без аны имтиханнардан азат итәргә уйладык. Ә ул:

—Юк, университетка керү имтиханнарын бирү өчен мин үземнең көчемне сынарга тиеш!—дип безне гаҗәпләндерде.

Күрәсең, белем алу юлында беренче сынауны җиңеп чыга алу тормышта үзен исбатлар өчен кирәк булгандыр аңа. Кашыкны кулларына бәйләп үзе ашарга өйрәнгән егет (чөнки бармаклары йөрми) каләмне дә ике кул арасына кыстырып, вак кына итеп язарга өйрәнде. Тик ул вакытларда маңгаеннан бәреп чыккан эре тир бөртекләре аның каты авыртудан нинди газаплар кичергәнен ачык сөйли иде. Бу халәтен сиздермәс өчен нинди дә булса шаян сүзләр табып әле безне көлдерергә көч табар иде ул.

Ниһаять, зур комиссия алдында, яңадан барыбызны да сокландырып, барлык фәннәрдән дә имтиханнарны уңышлы тотты ул.



*Фәнис Яруллин тормыш иптәше Нурсөя ханым белән. Рәссам Зөфәр Гыймаев рәсеме.*

Мәктәптән соң да җанын саклау өчен көрәш белән узган һәр көне шигъри иҗат белән үрелеп барды. 1964 елда «Мин тормышка гашыйк» дип аталган

беренче шигырь китабы дөнья күрде. Газета-журналларда Фәнис турында матур-матур мәкаләләр чыга башлады. Шигырь сөюче укучы кызларыбыз аның шигырьләренә, дәртле очкыннар тулы күзләренә, сөйләшүендәге шаянлыкларына гашыйк иделәр. Хастаханә палатасын чәчәкләрдән өзмәделәр. Шул кызлар арасында шигърияткә мөкиббән, гомумән, әдәбиятка гашыйк җан, төскә-биткә бик чибәр, төпле акыллы укучыбыз Нурсөя дә бар иде. Һәм ул күп тә үтми, туып килүче яшь шагыйрьне үз йөрәгенә бәйләп тә куйды. Бу хакта шагыйрь үзе болай ди: «Язмыш миңа тазалыкны (үз якларында сабантуй батыры булган), максатка омтылучанлыкны, көчне, сәләтне, ярыйсы гына буй-сынны, коңгырт-кара маңгай күзләре өстенә тирәнгә карый белүче күңел күзләре биргән дә: «Туктале, бер кешегә күпкәрәк китте бугай бу»,—дип кайберләрен кире тартып алган, һәм: «Болардан башка нишләр икән бу»,—дип читтән генә күзәтеп тора башлаган. Иң зур байлык—саулыгымны югалтып та башка сыйфатларымны саклап кала алгач, өрьяңадан юмартланып олы бүләк ясарга уйлаган, ягъни-Нурсөяне яныма китергән. Әйе, Нурсөя миңа чын-чынлап язмыш бүләге». Шигъри юллар белән болай дип тә өстәп куя:

Әллә нинди бер ашкыну белән,
Сиңа бара җаным тартылып,

Сөю турындагы һәр шигырьгә,
Төшә бары синең яктылык.

Тәне авыру булса да, җаны сәламәт, йөрәге тулы хыял, күңеле тулы өмет белән Фәнис һаман белемгә, яктылыкка омтылды. Яңадан барыбызны да таң калдырып, Казан дәүләт университетын уңышлы тәмамлады. Ул инде шигырьләр, поэмалар белән генә әйтеп бетерә алмаган сүзләрен, фикерләрен проза, драматургия һәм әкиятләре аркылы да бирә башлады. Шулай итеп, Фәнис Яруллинның иҗаты торган саен киңәя һәм тирәнәя барды. Аерым әсәрләре рус, казах, украин, венгер, болгар һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп газета-журналларда, төрле альманахларда дөнья күрде һәм дәреслекләргә кертелә башлады. Аңа аеруча танылу китергән әсәрләре «Җилкәннәр җилдә сынала», «Кыйгак-кыйгак каз кычкыра», «Чәчәкләр моңы» булса, поэтик әсәрләрдән «Җан авазы», «Нәсел агачы» кебек поэмалары иде.

Бервакыт Фәнис миңа мондый хәл сөйләгән иде. Мөхәммәт Мәһдиев (Фәнисләрнең бакча күршесе) аңа болай ди: «Әгәр син Дагстанда торсаң—Рәсүл Гамзат, Кыргызстанда яшәсәң—Чыңгыз Айтматов дәрәҗәсенә күтәрелә алыр идең. Нигә башкортта Мостай Кәримне күтәрделәр, ә Сибгат Хәкимне юк... Чөнки без татар токымыннан. Ә татар борыны белән боз тишсә дә аны күрмәскә тырышачаклар. Әнә русларның Николай Островские бер әсәр белән дөньяга танылды. Бу әсәр шедевр булган өченме? Юк, язучысы рус булган өчен. Безнең әсәрләребез чит телдә басылып чыккан очракта да башта русча имгәтелә, аннары башка телләрдә җаны алына. Әгәр әсәр ике-өч телгә тәрҗемә ителә икән—аның җансыз, рухсыз гәүдәсе генә кала».

Фәнис Яруллин чорыбызның халыкка иң якын—күп укыла торган һәм үзе дә иң күп укый торган әдибенә әйләнде. Ул үз халкының йөз аклыгы, аның вөҗданы, иманы. 1978 елда «Сулыш» һәм «Аерылмас дус» дигән шигъри китаплары өчен ул Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты булды. 1984 елда «Татарстан республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән исем алды. Ә 1988 елда «Халыклар дуслыгы» ордены белән бүләкләнде. 1995 елда «Җан авазы китабы өчен аңа Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелде. Театрларда да аның пьесалары буенча спектакльләр куелып тора. Бүгенге көндә дә утыз дүрт китап авторы булуга ирешкән бәхетле язучы. Фәниснең әйтүенә караганда, хәзерге көндә профессиональ театрларда гына да аның 13 пьесасы куела. Ә халык театрлары куйганнарын да исәпләсәң бу сан күпкә артачак.

Әсәрләре җанлы, бай, матур тел белән язылганнар. Җиңел укылалар, күңелне тиз җәлеп итәләр. Фәнис Яруллин бөтен иҗаты белән тормышны, кешеләрне яратырга, яктылыкка омтылырга, зарланмый-сукранмый гына кыенлыкларны җиңә белергә өйрәтә.

Ул халык күңелендә берсеннән-берсе гыйбрәтле, яшәешебезнең барлык

проблемаларын күрсәткән һәм киләчәкне алдан кузаллап язган публицистик мәкаләләре белән дә тирән хөрмәт казанды. Соңгы вакытларда гына да «Вакыт уза безнең йөрәк аша» *(«Заман гәзите, декабрь, 2000 ел)*, «Таркалу» *(«Мәдәни җомга» гәзите, 19. 01. 2001.)* дигән саллы мәкаләләре күпләрнең күзен ачып уйланырга мәҗбүр иткәндер. «Моннан 10 ел элек демократия уенын башлап җибәргән Үзәк өчен иң кулай вакыт житте... Законнарны Русиянекенә яраклаштыру—ул буйсындыру дигән сүз... Халыкның соңгы сынык икмәген тартып алу... Таянырга җирең, байлыгың, шул байлыгыңнан файдаланырга хокукың булса гына—син хөр, син көчле»,—ди ул.

«Таркалу» дигән публицистик мәкаләсендә ул милләтебезнең рухи яктан таркалышын, аның сәбәпләрен күрсәтә. Милләтне милләт итеп тотып торган тел, әмма шушы нигез ташыбызның төрле төбәкләрдән килгән күп милләт вәкилләре тарафыннан сыекландырылуын, ягъни ассимиляцияләшүен үз төбәкләрендә барган мисалларга таянып укучының күңеленә ярып сала. Без күпвакыт мәйданнарга чыгып демонстрацияләр, митинглар ясаучыларны, күбрәк кычкыручыларны көрәшчеләр, дибез. Ләкин, тәптәнрәк уйлап карасаң, үз өендә тыныч кына язып ятучы талантлы каләм иясенең аудиториясе зуррак икән. Ташка басылган сүз, урамда кычкырылган лозунглардан аермалы буларак, тирәнтен уйланылып, фикерне калкуландырып, образлар белән көчәйтелеп бирелүе һәм аның кабат-кабат укылуы белән көчле.

Фәниснең тагын бер күркәм сыйфаты—каләмдәшләренең, иҗатына игътибарлы, хөрмәтле булуы, аларны һәрвакыт кулына каләм алып укып баруы. Кайчакларда ул: «Яңа китаплар чыга тора, тавышсыз-тынсыз гына тарала тора. Яңа китаплар турында вакытлы матбугат бер сүз дә дәшми»,—дип борчылуын белдерә. Илдус Алмаз төзегән «Ак вә кара» китабына «Изге хисне милли тел сөйләр «дигән мәкаләсендә югары бәя бирә. «Шагыйрьләрнең йөрәгеннән кайнар кан булып тамган шигырьләрне бер җыентык рәвешендә укучы кулына тоттыруы белән автор нык игелекле эш эшләгән»,—дип яза ул. Җыентыкны халык язучысы Нурихан Фәттах мәкаләсе тәмамлый. Фәнис бу олы әдипнең васыять кебек әйтелгән кайбер фикерләрен үз мәкаләсе аркылы укучыга ирештерә. «Милләтне савыктыру өчен халыкның милли аңын уятырга, милли рухын нығытырга, милли телен көчәйтергә кирәк. Бу эштә тарих безгә таяныч була ала. Бу авыр, тотрыксыз көннәрдә милләтнең күзе сезгә төбәлгән, татар яшьләре! Киләчәк сезнеке. Милләтне бәхетле итү язмыш тарафыннан сезгә йөкләтелгән. Кыюлык, уяулык, аңлылык юлдашыгыз булсын, энеләрем-сеңелләрем!»

Олы җанлы Фәнис Яруллинның үтә дә игелекле каләме аша бик күп язучыларыбыз үзләренең иҗатлары турында җылы сүзләр ишеттеләр. Мәсәлән, Айдар Хәлим, Тәбриз Мөбәрәков, Мәхмүт Әхмәтҗанов, Гакыйл Сәгыйров, Илдар Юзеев, Шәүкәт Гали, Шамил Маннапов, Туфан Миңнуллин, Кәүсәрия Шәфикова—болары әле минем хәтеремдә калганнары гына.

Ә менә шагыйрь Илгиз Кәлимуллинның һәм репрессия елларында төрмә газапларын күргән шагыйрь Мәҗит Рафиковның рус телендәге шигырьләрен татарчага тәрҗемә итеп кенә калмаган, иҗатларына матур рецензияләр дә язган Фәнис.

Без инде күп еллар буена гадилектән матурлык тудыручы сәләт иясе Фәнис белән аралашып яшибез. Очрашкан саен, бу гел изге җаннардан гына торган гаиләнең күңел байлыгына сокланабыз.

Күптән түгел, бер очрашу вакытында, Фәниснең тагын бер матур сыйфаты, юк сыйфаты гына түгел, таланты ачылды.

Ул көнне радиодан аның моң тулы җырларын яңгыратканнар иде. Мин ул җырларның туу тарихлары белән кызыксынып сораштыра башладым.

—Мин аларны язган чакта ук җырлап язам. Һәр шигырьнең үз көе була. Тик мин ул көйләрне вакытында хәтерем сандыгына гына салып куя алмыйм. Шигырь язылып бетүгә, аның көе дә, сиздермичә генә, каядыр китеп югала бара. Магнитофонга язып баруларны булдыра алмадым шул... Менә инде җырламый башлаганыма да ике еллап вакыт узды, тыным җитми кебек...—дип сөйләп китте ул.

Безнең тәмам гаҗәпкә калып утырганны күргән Нурсөя: «И-и-и,

Гөлчәчәк апа, һәр гаиләдә була торган үпкәләп алулар, яшьрәк вакытларда, бездә дә булгалый иде. Андый чакларда мин кечкенә бүлмәгә чыгып китә идем дә сөйләшми идем. Ә Фәнис көннәр буе җырлап ята. Ул озын, моңлы көйләрне ярата. Әнә шулай үзәк өзгеч җырлары белән күңелемдәге үпкәләрне юа да ала иде»,—дип өстәп куйды.

Без кыяр-кыймас кына Фәниснең җырлавын үтенә башладык.

—Алайса, сезнең яраткан «Гөлҗамал»ны сузып карыйм, тыным җитмичә туктап калсам, үзегез дәвам итәрсез,—дип әкрен генә, җырдагы моңлы борылышларда башкортларча (моңны тагы да тирәнәйтеп) җырлап җибәрмәсенме! Аннан Хәсән Туфан сүзләренә язылган «Әйткән идең» һәм башкортның «Янбикә» җырын сузды.

Гаҗәп... Ә иң гаҗәбе—кырык елдан артык аралашып шушы моңнан мәхрүм яшәгәнбез. Ни өчен? Нигә дип ул бу талантын кешеләрдән яшергән? Хәтта үзенә бераз үпкәләп тә алдык. Ә ул, безнең сүзләргә җавап итеп булса кирәк, әкрен генә «Сибелә чәчәк» җырын башлап җибәрде. Аннан Әхмәтнең гармунда уйнавына кушылып, барыбыз бергә җырны дәвам иттек.

Көнен дә, төнен дә ятакка беркетелгән олы язучы, кечкенә генә ике бүлмәле фатирын гамьле дә, серле дә дөньяга әйләндереп яши. Ул аны болай сурәтли:

Өем кысан минем, күңел шуңа
Рәнҗеп куя.
Ярый әле кысан өемә дә
Кояш сыя.
Ай-йолдызлар да өемне
Итә якын.
Тирбәлә күктә бишектәй
Караватым.

Ай-кояшлар гына сыямы соң?.. Анда әле төрле районнардан, автобусларга төяләп килгән, 20-30 ар укучы да сыя һәм алар бу өйдә шигъри матур кичәләр уздыралар.

Бу изге почмак бик күпләрнең яралы күңелләренә шифа була алырлык, өметсезләрдә өмет уятырлык изге урынга әйләнә. Укытучы, йә булмаса журналист булырга хәзерләнүче студентлар һәм татар әдәбияты укытучылары үзләренә төрле консультация, киңәшләр алу өчен дә шушы өйгә киләләр.

Һәр елны Казан дәүләт университеты, педуниверситет һәм төрле көллият студентлары Фәниснең әсәрләре буенча курс эшләре һәм дипломнар яклап торалар. Инде кайбер аспирантларның аның иҗатын өйрәнүгә алына башлаулары да яңалык түгел.

Республиканың күп кенә район үзәкләре һәм Казанның аерым мәктәпләре, гимназияләр Яруллиннарның үзләрен чакыртып та төрле конференцияләр, ачык дәресләр уздыралар. Билгеле, Фәнискә болар берсе дә җиңел генә бирелми. Әмма авыр вакытларда ул үзенең йөрәгенә дәшә:

Син дә хәлсезләндең йөрәк,
Арыдыңмы әллә?
Хәлсезлегең кичереп булыр,
Ләкин дәртсезләнмә.
........................
Ләкин гамьсезләнмә.

Гадәттә, сәламәт тәндә генә сәламәт рух, дигән әйтем яши. Ә гомерлек бәлага дучар булган Фәнис, гадәти булмаган куәтле омтылыш һәм ихтыяр көче белән үзенә бер могҗиза тудыра. Үзенең аянычлы хәл-әхвәле, язмышы белән көрәшә-көрәшә иҗат офыкларын һаман киңәйтә бара.

Яши-яши икесе бер җанга әйләнгән Фәнис белән Нурсөянең тагын бер искиткеч сыйфатларын—шәфкатьле, мәрхәмәтле, ярдәмгә мохтаҗларга игътибарлы булуларын дә әйтми калу мөмкин түгел.

Шагыйрьнең «Сәүия нигә елаган» дигән шигыре бар. Шуннан бер өзек:

Сәүия дигән кыз туган,
Ул кыз бик елак булган.

Көне-төне елаган,
Өзмәгән дә куймаган.
.....................
Әйтә генә алмаган
Аягым авырта, дип,
Мине шул елата, дип.

Нурсөянең бер туган сеңлесенең кызы Сәүиянең туган вакытта җайсыз килеп бер аягы зәгыйфьләнә. Казаннан читтә, Мари республикасында, ерак бер авылда Сәүия бик чибәр кыз булып үсә, тик аягының зәгыйфьлеге генә шул көе кала бирә. Чөнки әле ул вакытта медицина мондый очракларда ярдәм итә алмый иде. Бу кыз баланың киләчәк язмышы өчен Фәнис белән Нурсөя нык борчыла. Уйланалар. Бер-бер артлы Сәүиянең әти-әнисе үлеп, кыз бөтенләй терәксез дә кала. «Нурсөянең бер иңендә мин, икенче иңендә минем авыруым. Сәүияне алда күп операцияләр көтә. Аны дәваларга, тәрбияләргә Нурсөянең өченче иңнәре юк бит... Әгәр ул сынып китсә, мин нишләрмен?.. Сәүия дә кыз бала, укымыйча калса, нишләр?..» Кайтып таянырга әти-әниләре дә булмагач, авылда яши алмаячагы да ачыклана. Соңгы фикер җиңә һәм кызны үзләре янына алдыралар.

Горький урамындагы хастаханә белән ике арада йөрү, өйгә кайткач дәвалануны дәвам итү мәшәкатьләре бары да Нурсөядә булса, Фәнис баланың өйдәге укытучысына әйләнә. Аны унберенче сыйныфка укырга урнаштыралар.

Сәүия хәзер Казан дәүләт педагогика университетында математика-информатика факультетының 5 нче курсын тәмамлап килә. Дүртенче курстан бирле Лобачевский степендиаты. Өстәвенә, җиңел машина йөртергә өйрәнү курсларын укып, машина йөртү хокукын да алды.

Фәнис белән Нурсөя бу кыз өчен сәламәт ата-аналарның да күбесе булдыра алмаслыкны башкарып киләләр. Инде хәзердән үк алар Сәүия киләчәктә аспирантурага кереп укысын өчен бөтен көчләрен куялар. Мин ышанам, аларның бу теләкләре тормышка ашар. Чөнки Сәүия үзе дә аларның йөзенә кызыллык китерми. Гел отличнога уку өстенә мәкаләләр, нәсерләр, бәяләмәләр язып газеталарда бастыра. Кем белә, бәлки әле Фәнис талантының «йогышлы» ягы да бардыр. Бирсен Ходай!

Без, укытучылар, Яруллиннарны җир кешеләре итеп түгел, Ходай тарафыннан кешеләргә үрнәк һәм гыйбрәт итеп, җир йөзенә махсус иңдерелгән җаннардыр дип күрә башладык инде.

Бервакыт, Сәүиянең әле Казанга килгән генә еллары, Язучылар берлегендә эшләүче бер бәндә, һич тә тайчынмыйча: «Ул кызны китереп, Фәнис фатирын зурайтырмын, дип уйлыйдыр. Юкка тырыша, ул бит аның гаилә әгъзасы түгел»,—дигән иде. Ни аяныч, бездә әле изге ният, игелекле эшләрне дә кире якка борырга маташучылар җитәрлек шул!

Фәнис хатыны турындагы, аның батырлыгы, фидакарьлеге хакындагы язмасы, моңарчы әле беркем тарафыннан да язылмаган искиткеч матур поэмага тиң. *(«Сөембикә» журналы, 11 сан, 2000 ел).*

Үз гомерләрендә бер мәртәбә генә булса да зур батырлык күрсәтүчеләрне, гадәттә, герой дип бәялиләр. Ә Фәнис Яруллинның, үз халкына намус белән хезмәт итәр өчен узган 42 ел гомеренең һәр көне, һәр төне—батырлык! Җитмәсә, кайчакларда кызганган булып Нурсөянең күңеленә яра салучылар да очрап тора. Фәнис андыйларга:

Күпләр сине аңлап җиткермиләр,
Бу соң, диләр, нинди җүләр йөрәк?
Сине аңлап җитү өчен дә бит
Синең биеклеккә менү кирәк,

—дип җавап бирә. «Нурсөя минем мәхәббәткә, яшәүгә, эшкә сусаган җанымны бер караштан аңлап ала һәм сүнеп баручы тормыш учагымны тергезеп тора белде. Ул минем өчен яшәү чыганагы. Уңышсызлыкларыма үземнән ныграк көенде, җиңүләремә миннән күбрәк сөенде»,—ди ул.

Фәнис Яруллинның, олы әдип буларак үткән гасырга горур караш ташларга тулы хокукы бар. Ул халкыбызның мактанычы, куанычы булды.

Күренмәгән батырлык—батырлык түгел, әйтелмәгән хакыйкать—хакыйкать түгел, диләр. Шушы гыйбарәне истә тотыпмы, Фәнис Яруллинның туган авылы мәктәбендә музее ачыла. Белүемчә, башка күп кенә район китапханәләрендә дә Ф. Яруллинның иҗатын яктыртучы музей почмаклары эшли. Балтач белән Баулының бер урамы, менә ничә еллар инде, Фәнис Яруллин исемен йөртә.

Балтач район җитәкчеләре урамга исем биреләсе көнне, Яруллиннарның икесен дә алып килеп, бөтен халык катнашында, зур тантана белән Урам бәйрәме уздыралар. Җәйләрен яши торган Баулыдагы йортына Ф. Яруллинның башкорт рәссаме Дәнис Йосыпов тарафыннан бронзадан ясалган барельеф белән мемориаль такта урнаштыралар. Әйе, халкыбыз бу каһарман талант иясен гомерлеккә үз итте.

Ә шулай да, кайбер очрашулар вакытында мондыйрак сораулар да ишетергә туры килә аңа:

—Фәнис абый, сезнең нәрсәгәдер үкенгән чакларыгыз булмыймы?

—Гомерләре заяга үткән мескеннәргә генә хастыр ул үкену. Минем көннәрем мәхәббәт белән, эш-хезмәт белән тулы, кешеләр арасында уза. Яратып һәм яратылып яшим. Тормышка ашмаган хыялларым бар, билгеле. Нурсөяне кочагыма кысып йөгерәсем килгән чакларым, йә алдына тезләнеп, үзем өзгән чәчәкләр кочтәсен аның аяк астына җәясе килгән чакларым була... Ул бит минем гомеремне озынайтучы әбелхәят суым...

Алтмыш яше тулыр алдыннан, үз үлеменә бары ярты сәгать кала, язучы-галим Тәбриз Мөбәрәков аның рухи көченә, сәнаигы нәфисә талантына соклануын белдереп:

Сиңа, Фәнис дускай, теләгем бер:
Җиткәч тә яшьләрең алтмышка,
Иҗат ашың белән тондыра бир
Таш ыргыткан явыз Язмышка!—

дип юкка гына язып калдырмагандыр.

Мин бу язмамны тәнкыйтьче Рифат Сверигинның «Казан утлары» журналының 1999 елгы 6 санында чыккан «Туксанынчы еллар әдәбияты» дигән мәкаләсендәге Фәнис Яруллинга карата әйтелгән сүзләре белән тәмамларга телим:

«Кайсы әсәрне әдәбиятыбыз казанышы дип саныйсыз?» дигән сорау «Кемнәрнең әсәрләрен» дип бирелгән очракта, мәсәлән, проза өлкәсендә берничә исемне атар идем. Бу исемлекнең иң өстенә башкалардан үзгәрәк әдип—Фәнис Яруллинны куяр идем. Ни өчен үзгәрәк? Аның прозасын шигърияте белән бәйләнештә генә аңлап була. Шулай булгач, бу әдип турында сөйләгәндә жанр мәсьәләләрен түгел, ә шәхес мәсьәләсен куярга кирәк. Әдип һәрвакыт үзе булып—халык, милләт, җәмгыятьне борчыган заман, тормыш проблемаларын йөрәгә аша үткәрүче, кичерүче һәм сынмас, бүйсынмас рухлы шәхес булып кала. Аның 1994—98 елларда дөнья күргән өч томлык сайланма әсәрләренең, «Серле дөнья», «Җан авазы», «Көн сулышы», «Яз гөлләре» «Күзге моң» исемле җыентыкларының әле бөтенләй өйрәнелмәгән, тикшерелмәгән гаять бай эстетик дөнья икәнлеген әдәби җәмәгатьчелек белми диярлек. Күпләр, кызганычка каршы, бүген дә Фәнис Яруллинны шәхси фаҗигага юлыккан һәм шул турыда үзенең «Җилкәннәр җилдә сынала» повестын язып чыккан кеше дип кенә күз алдына китерәләр. Ә мин аны заманыбызның актуаль иҗтимагый эстетик мәсьәләләрен кыю күтәрүче буларак, Лев Толстойларга тиң олы зат дияр идем. Әмма җәмәгатьчелеккә, укучыларыбызга моны исбатлап бирәсе бар әле».

Чынлап та, иҗатны шәхес белән бергә бәйләп караганда гына аның тирәнлеген, киңлеген, гуманистик сыйфатларның кайдан килгәнлеген ачык белергә, аның тамырларына төшенергә мөмкин.

Мин бу олы шәхеснең, үзенең мәхәббәт алиһәсе Нурсөя белән, дусты Тәбриз теләгәнчә, үзе тудырган сихри дөньясында озак еллар тулы иҗат белән яшәвен телим!

**Гөлчәчәк ГАЛИЕВА**

Мансур
Вәли-Барҗылы

# АЛМАГАЧЛАР ЧӘЧӘКТӘ

ЯШЬ ПРОЗАИКЛАР ИЖАТЫ ТУРЫНДА УЙЛАНУ

## Чорлар чигендә

Кайсыдыр пәйгамбәребезнең сүзсез генә ике бармак күрсәтүенә карап «2000 нче елда ахырзаман житәчәк!» дигән яман фараз кылучылар һәм шуның белән бөтен кешелек дөньясын зур хафага салучылар бар иде... Бүген инде Аллага шөкер диик: әлегә ахырзаман килеп житмәде кебек—Жир дигән гүзәл планетабызда исән-сау гына яшәп ятабыз.

Ләкин... Ләкин, шулай булса да, соңгы дистә елларның кешелек тормышына зур һәм кискен үзгәрешләр китерүен беркем дә инкарь итә алмас, мөгаен.

Әйе, егерменче гасырның урталарыннан алып халыкның иң зур күпчелеге шәһәрләрдә: димәк үзенең тудыручысы булган жирдән һәм табигатьтән аерылып, димәк тоташтан таш белән тимер һәм ясалма материаллар арасында, димәк бөтенләй бүтәнчә көн итә башлады. Хәзерге кеше яшәешендә төрле техника, автомат җайланмалар, компьютер һәм телевидение үтә зур урын били.

Аннары, СССР дигән империя таралып ил чикләре ачылгандай булгач, халыкның зур дөнья белән аралашуы нык артты, активлашты. Бу күренеш, нигездә, уңай бәяләнергә тиеш булса да, аның тискәре якларын да күрми калу мөмкин түгел: куркыныч авырулар күбәйде, наркомания һәм жинаятьчелек үсә, кеше үтерүләр саны үтә нык артты.

Шулай—хәзер татар милләте дә бик кызу ритмда яшәүче дөнья агымына кереп бара. Татарстаныбызга атна саен диярлек чит илләрдән делегацияләр килә, күпләгән килешүләр төзелә, безнекеләр дә ерак-ерак илләргә еш йөреп тора.

Жир дигән уртак планетада яшәгәч бүтәннәргә хас күп нәрсәдән читтә калырга да мөмкин түгелдер... Ләкин шунысы торган саен ныграк борчый бара: мондый актив хәрәкәт, кызу агым эчендә яши башлагачтын безнең милләтнең үз йөзе югалмасмы? Милли холык-психология, бүген дә һәм киләчәктә дә безнең өчен һәм дөньяның үзе өчен дә бик кадерле булырга тиешле гореф-гадәтләр нишләр?

Әлеге сорауларга уңай жавап табарга теләп эзләнә башласак без ирексездән диярлек рухи дөньяга—әдәбият һәм сәнгать дөньясына—килеп чыгабыз.

## Мәңгелек маяклар

Гасыр башына, яңа меңьеллык башына Хәсән Туфан, Салих Сәйдәшев, Һади Такташ, Гомәр Бәширов кебек олуг затларның 100 еллык юбилейлары туры килү зур символик мәгънәгә ия. Алар, бер яктан карaганда, менә кадәр яшәгән мең еллык гомерле татар мәдәниятенең яктысын һәм жылысын үзләренә туплаганнар, үзләрендә әнә шул олы рухи хәзинәне чагылдырып балкыйлар... Ә инде икенче яктан күз салсак, алар яңа чорга, яңа заманга кереп баручы яңа юлларга да яктылык сирпеп, безгә юл күрсәтеп торалар.

Әйе, үтеп киткән егерменче гасыр зур-зур вакыйгаларга һәм кискен борылышларга гаять бай булса да (әллә ничә зур сугыш, аларда миллионлаган халык кырылу, шулар өстенә тагын әллә ничә революция һәм тормышның асты-өскә килү, атом һәм химия аварияләре аркасында зур зыян күрүләр һ. б.)

гасыр афәтләре барыбер, әдәбиятны төп юлдан—гасырлар буена уңышлы рәвештә атлап килгән олы юлдан—яздыра алмады. Татар әдәбияты барыбер кешенең күңел юлдашы булып, аның иң изге һәм иң мөкатдәс хис-кичерешләрен җырлаучы булып калды.

Әлбәттә, әдәбият-сәнгатьнең кешелек тормышында тоткан урыны хакында төрле һәм кайнар-кайнар бәхәсләр дә тумады түгел ул гасыр дәвамында. Биг-рәк тә фән-техника революциясе көчәеп барган илләрда әкияттәгечә гүя әле генә чүлмәктән чыккан бу яңа «пәри»гә артык зур өмет баглаулар булды. Фи-зиклар белән лирикларның кайнарланып бәхәсләшүләре дә тарих хәтеренә язып куелды... Еллар үтте, тулаем гасыр үзе дә узып китте... Ләкин физиклар да үз урыннарында калды, лириклар да алыштыргысыз миссияләрен үтәп киләләр.

Инде хәзер, әлеге парә-парә килүләр басылгач һәм еллар тузанына күмелә төшкәч, кайбер сөземтәләр дә чыгара алабыз сыман. Аерым алганда, менә мондый нәтиҗә. Кешенең күңел дөньясын, аның йөрәген, хис-кичерешләрен бер генә нәрсә белән дә алыштырып булмый икән! Хәтта әле соңгы вакытта галимнәр шуны да ачыклап килә: безнең гасырлар буена «җан» диеп сөйләшә торган хикмәтебез үзе дә кешенең йөрәге тирәсенә тупланып яши икән. Бер кешенең йөрәген алып икенче кешегә куйсаң—аның бөтен холык-фигыле, хис-кичерешләре үзгәрә икән! Димәк, кешелек дөньясы бер дә юкка гына «йөрәк» дигән нәрсәгә гасырлар буена аерым бер игътибар биреп килмәгән икән!

Үзебезнең татар әдәбиятын алсак, анда хисси башлангыч бигрәк тә көчле. Аның бүтән телләргә үтә авыр тәрҗемә ителүе, күп очракларда хәтта тәрҗемә кылына алмавы да әнә шундый асыл һәм нечкә хасияте белән аңлатыла. Халык бәгыренә аеруча якын иҗатчы затлар гомере дә моны тагын бер мәртәбә раслый. Әйе, әдәбиятыбызда мәңгелек маяклар булу—барыбыз өчен дә бик зур бәхет.

## Яшьләр килә...

Республика матбугаты битләрендә яңа исемнәр еш кына күренә. Сүзне зуррак күләмле әсәрләрдән башлыйк. Тәвәккәлләп «роман» яисә «повесть» дигән житди һәм зур җаваплылык сорый торган жанрга тотынучы яшь автор булдымы икән соңгы елларда? Яшерен-батырын түгел: андый тәвәккәллек өчен элеккерәк елларда яшьләргә байтак кына тәнкыйть таягы да эләккәләде. Дөресрәге тәвәккәллекнең үзе өчен түгел, ә житәрлек микъдарда тәҗрибә тупламаган килеш зур күләмле жанрга кереп киткән һәм уңышсызлыкка очраган өчен сүктеләр күп кенә яшь прозаикларны. Әлбәттә, житмешенче-сиксәненче елларда тәүге повесте белән ук игътибар казанган Әхәт Гаффар да булды. Ләкин аның уңышы да, нигездә, классик әсәрләргә таянуда яисә караган нәфис фильмнарга ияреп язуда иде. Эпигонлык дигән бу күренеш күп чагында плагиатка якын тора һәм яшь язучылар аннан бик хаклы рәвештә куркалар да. Һәрхәлдә, минем үземә бу юл бик тайгак, ышанычсыз тоела һәм бүгенге яшьләргә дә иҗатның башын аннан алып китәргә киңәш бирәсе килми. Саф күңелле, изге ниятле, зур максатлы иҗатчы юлы түгел ул!

Әлеге хакыйкатьне бүгенге яшь иҗатчылар бик яхшы аңлый, күрәсең, соңгы елларда әдәбиятыбызда андый күренешләр күзәтелми башлады. Бу унай-дан, бер яшь язучыга адресланган һәм «Казан утлары» журналында элегрәк басылып чыккан ачык хатның тәэсире булгандыр диеп әйтәсе килми билгеле, ләкин, шулай да, ул елларда—әле прозабыз нык көчле булган чорда—эпигон әдәбият тудыруның зыянлы икәнен күрсәтү кирәк иде, сорала иде. Ул чагында без игътибар иткән әлеге яшь язучының зур иҗат юлына чыгып сокланып укырдай чын әдәбият әсәрләре тудыра алмавы гына эчне пошыра пошыруын... Ә бит ул—шактый ук талантлы, бигрәк тә үткен тел куәсенә ия автор.

Биредә яшьләр өчен мөһим тагын бер нәтиҗә килеп чыга шикелле: әйе, әсәр язу өчен әйбәт, матур, сыгылмалы, образлы тел бик тә кирәк, бик тә мөһим—ләкин, әнә шул хәзинә белән янәшә үк, изге ниятләр белән рухланган, канатланган чиста, матур, керсез күңел дә кирәк. Дөньяга, кешеләргә бирергә, бүләк итәргә теләгән югары омтылышлар, кешелек өчен кадерле һәм мөһим булган яңа, саф кичерешләр бик тә сорала әдәби иҗатта.Менә шушы соңгысы

булмаган тәкъдирдә яшь иҗатчыны кризис, рухи ачлык, тупик дигән яман нәрсә көтә. Икенче төрле итеп әйткәндә, моны: яшь язучының актив һәм тирән рухи дөнья белән яшәргә тиешлеге диеп тә билгеләргә була.

Әнә шундый эчке «мотор»ың синең күкрәк читлегендә даими рәвештә эшләп тормаса, син—яшь автор—иҗат юлыннан бик әллә ни ерак китә алмыйсыңдыр...

Ләкин, шулай да, бүгенге яшьләрне кыюсызлыкта гаепли алмыйбыз икән: соңгы ике еллык басмаларны укыганда мин ике яшь автор язган ике повестька юлыктым. Аларның беренчесе Рәдиф Сәгъдинең «Алло, хәлләр ничек?» повесте *(«Идел» журналы, 11 сан, 1999 ел)*, икенчесе Ләлә Сөләйманның «Гасыр ахырында» повесте *(«Ватаным Татарстан» газетасының 2000 елгы 12-14 июль саннары)*.

«—Алло, алло! Кем бу? Дамир синме? Сәлам, туган! Хәлләр ничек? Яхшы инде алайса. Бик әйбәт! Малайлар ничек? Ну, әйбәт булгач, бик яхшы! Сәлам әйт егетләрнең барчасына да! Без иртәгә Казанга очабыз, әй! Шул сәгать унберләрдә саунада көрешә алырбыз диеп уйлыйм... Билетын өч бәягә алдык инде, Касан белән. Ну, Мәскәү хәлләрен үзең беләсең бит инде, монда һәрбер җирдә ыштаныңны салдырырга торалар!»

Рәдиф Сәгъди повестеның иң беренче бите үк әнә шулай башланып китә. Укучы күреп өлгергәндер, әсәр башында китерелгән шушы берничә җөмләдән генә дә әлеге сүзләрне әйткән кеше хакында күпме мәгълүмат алабыз: ул Мәскәүдә яши, аның дус егетләре күп, алар бай яши (билетны өч бәягә алырлык булгач!), самолет белән кайтырга уйлагач аларның вакыт ягы да кысан, күрәсең... Шулай ук боларның Казанда да эшнәләре байтак: әнә бит «малайлар ничек?» диеп кенә хәл белешә. Мәскәү шәһәрендәге тормыш белән Казандагы яшәү аермасы да сизелеп ала әлеге җөмләләрдән—Казанның эшләп яшәргә өйрәнгәнлеге, ә Мәскәүнең кеше таларга күнегүе дә күренә.

Әлбәттә, әсәр дәвамында күренәчәк геройлар турында башта ук шуның кадәр хәбәр җиткерә алу һәм ул мәгълүматның укучы хәтеренә сеңүе—болары яшь авторның уңышлы ягы, казанышы. Шушындый кызу темпны, тыгыз динамиканы автор алга таба да югалтмаска тырыша: маҗаралы кино карагандагы сыман безнең күз алдына бер-бер артлы замана хикмәтләре килеп баса... Бирелә Мәскәүдән килгән егетләр белән Казан кызларының барысы бергә һәм эчә-эчә сауна керүләре дә, мускул кабарткан егетләрнең үзара тыныша алмыйча кан коюлары да—һәммәсе дә бар... Ләкин повестьның эчке битләренә үткән саен күңелне бер тойгы били бара: «бу хәтле актив хәрәкәтнең, күп вакыйгаларның үзәгендә нәрсә ята соң—автор безгә нинди фикер аңлатырга тели соң?» дип уйлана башлыйсың. Һәм, ни кызганыч, ул сорауга ачык җавапны табып ала алмыйбыз. Билгеле, повестьлар белән бергә сәхнә әсәрләре дә язучы Рәдиф Сәгъдинең каләме талантлы, югарыда әйтеп узуыбызча, ул вакыйгаларны бер-берсенә оста үреп бара. Катнашучыларның холык-фигыльләре дә укучы күз алдына килеп баса. Ләкин... Ләкин менә «эчтәлекнең җитдилеге, тирәнлеге» дигән хикмәт житенкерәми әле аңа. Бу повесть Янарышның беренче елларында язылганмы әллә дигән тәэсир кала. Ул чагында иҗат дөньясына ирек килгәч «болай да язып була!» диеп—язгы болынга чыккан яшь маллар сыман—күккә ашардай булып сикереп, чабышып йөрүләр бар иде бит... Әмма ирек үзе генә әле ул төп хәзинә түгел икән, аңа ирешкәч тә «эш» һәм «хезмәт» дигән бәхет алга килеп баса икән. Һәм ул «эш» дигән бәхет белән «иҗат» дигән бәхет бертөслерәк була икән—аларның һәр икесенә дә җитди карау, аларның иң нечкә серләренә ия булу, тырышлык, җитдилек, басылып эшләү сорала икән... «Иҗат» дигән дөнья ул эшнең дә иң авыры—ял белән дә, вакыт белән дә, сәламәтлек белән дә санашмый, санлашмый торганы, үзенә бөтен көчеңне, бар җегәреңне суыра торганы икән...

Ерак Мөслим төбәгенең кечкенә генә бер авылында яшәп ятучы яшь автор Ләлә Сөләйман исә үзенең үткән җәйне «Ватаным Татарстан» газетасы битләрендә басылган «Гасыр ахырында» повестен без югарыда телгә алып үткән «Алло, хәлләр ничек?» әсәренә юри капма-каршы рухта башлап китә кебек:

«Ашыкмый гына намазын тәмам иткәч, Шәмсекамал карчык бисмилласын әйтеп «Аятел көрси»не укый башлады:—Әгүзе билләһи... Бисмиллаһи...

Шул арада шыгырдап урам капкасы ачылды, дисбесен тарткан карчык тәрәзәгә күз салды. Керүче кеше йөгереп үтте—таный алмый калды.

—Шәмсекамал апакай гынам!

Шакымый-нитми генә өйгә бер хатын килеп керде. Чәчләре тузгыган, куллары калтырый—үзе әле ап-ак итеп акшарланган мич артына, әле дәү сандыкка күз сала. Аңлашыла, качар урын эзли хатын...»

Күрәсез булыр: бу әсәрнең тәүге юллары ук намазга игътибарны юнәлтә, әнә шул мәңгелек канун буенча яшәүче Шәмсекамал карчыкны үзәккә куя... Ә инде бераздан күрше хатыны Гөлзирә йөгереп керә. Әсәрнең менә шушы өлеше дә бик мәгънәле. Әнә, өлкән кеше—сабыр, тыныч, аның кулында Коръән... Ә менә яшь хатын ни кыяфәттә: ул йөгерә, аның чәчләре тузгыган, куллары калтырый, үзе качарга (!) урын эзли...

Хәтта менә шушы бер эпизод үзе генә дә өлкән буын һәм яшь буын турында бик күп нәрсәне әйтеп, сөйләп тора.

Әйе, гап-гади бер татар авылында яшәп ятучы яшь килен Гөлзирәнең тормышы мәхшәрдәге сыман: ире Идрис көн саен эчә һәм көн саен аңа бәйләнә. Шулай дөньясын онытып эчә торгач Идрис көннәрдән бер көнне хастаханәгә килеп эләгә, анда байтак кына ята. Әнә шул чагында инде Идрисне кара магия әгъзасы Васил үзенең мәкерле җәтмәләре белән чолгый, аның күңелен, рухын богаулый. Ахырда Идрис куркыныч һәм кешелек тормышын җимерүгә юнәлтелгән көчкә әверелә. Безнең көннәрдә татар авылында яшәп ятучы гап-гади бер ир явыз секта йогынтысына килеп эләгә.

Юк, безнең максат бу ике повестьның эчтәлеген сөйләп бирү түгел, анысын укучының үзенә калдырыйк та—шушы ике әсәрдә чагылган уртак якларны барлыйк, күзәтик.

Иң элек шунысын сөенеч белән билгеләп үтәргә кирәк: яшь авторлар зур бер тәвәккәллек табып прозаның күләмле һәм күп көч сорый торган тармагында—повесть жанрында—әсәр иҗат итү эшенә алынганнар. Димәк, бу инде үзендә күпмедер көч, илһам ташкыны тою дигән сүздер. Үз-үзенә шактый ук нык ышанудыр. Әлбәттә, кайсыбер вакытларда графоманнар да зур-зур күләмле әйберләр язып ата, аларны мондый «эч киту»дән дәвалап та булмый. Ләкин без инде бу очракта андый иң түбән дәрәҗәне искә алмаска тырышыйк. Чөнки инде анысы өлкән яшьтәге кешеләрдә күбрәк була һәм, турысын гына әйткән чагында, ул күренеш еш кына очракта медицинаның шизофрения дигән авыруы белән бик якыннан килеп тоташа.

Икенче уңай як: яшь авторлар курыкмыйча заман темасына мөрәҗәгать иткәннәр! Югыйсә, элеккерәк елларда яшь авторларның әбиләр һәм бабайлар тормышы турында әдәби әсәр язулары үзенчә бер норма сыман кабул ителә башлаган иде. Моның сәбәбе, күрәсең, чынбарлыкны яхшылап белмәүдә, күбрәк китап тормышы белән яшәүдәдер. Яшь авторларның нинди дә булса әсәр укып яисә кино карап хикәя язарга утыруларын һәм редакцияләргә юллауларын без инде байтак очраттык. Бу очракта исә Рәдиф тә, Ләлә дә үз күзләре белән күргән, үзләре янәшәсендә агып яткан реаль яшәешкә чумганнар. Шуны үз йөрәкләре, үз күңелләре аша үткәреп әдәби әсәр тудырганнар.

Ике авторга да хас булган тагын бер сыйфат: аларның җөмләләре күп бизәкле, чуклы-чуклы түгел—сокландыргыч чагыштырулар, сынландырулар һәм бүтән төрле телбизәкләр дә сирәк күзгә ташлана. Һәм шунысы кызык—менә шушындый, бер караганда корырак тоелырга тиешле стиль, әсәрләрне укыган чагында бик үк борчымый да. Шулай булырга тиешле нәрсә сыман кабул ителә. Ни өчен шулай? Югыйсә бит безгә: «Матур әдәбият ул матур булырга тиеш, бизәкле һәм матур җөмләләрдән торырга тиеш!»—дигән иҗади лозунг сыман сүзләрне дә еш кына ишетергә һәм шуны чынга ашырган әсәрләрне дә күрергә туры килгәли... Ә биредә, менә бу яшь авторлар иҗаты уңаеннан, ни өчен соң җөмләләрнең күп бизәкле булмавы сизелми, бу хәл күңелне борчымый?

Мәсьәлә шактый ук җитди, шуңа күрә, әйдәгез, аңа бераз гына озаккарак тукталып алыйк. Башта тегे: «җөмләләр дә матур һәм бизәкле булырга тиеш—шуның өчен матур әдәбият бит ул!» дигән сүзне ачыклап китик.

Минем уйлавымча, «матур әдәбият» диеп әйткән чагында без һич кенә дә җөмлә матурлыгын гына күз алдында тотмыйбыз. Бирелә «матур» дигән сүзгә: югары максатлар һәм идеяләр белән рухланган матур эчке яшәеш тә, үзе матур рухи дөньяга ия булган һәм рухланган яшәеше белән укучыны да тәэсирләндерә алырдай, чын мәгънәсендәге матур геройлар да керә. Әсәрнең үзе сыман—геройлар да тыштан гына чибәр түгел, ә эчке яктан да матур булсалар

гына безнең күңелне яулый ала бит! Менә шуның шикелле: «матур әдәбият» дигәндә без бу сүзнең киң, тулы мәгънәсендә кулланабыз диеп уйлыйм. Ә тар, түбәнрәк мәгънәсендә генә түгел. Шулай булгач инде авторларның иҗат җимеше үзләре дә һәр яктан, шул исәптән, җөмлә һәм стиль җәһәтеннән дә, матур һәм төзек булырга тиеш—бусы уңаеннан һич кенә дә ике төрле фикер юк. Димәк, сүзебезнең әлеге өлешен йомгаклый төшеп шуны гына искәртик: матур һәм бизәкле-чуклы җөмлә төзү, шундый стильгә ия булу үзе генә—һич кенә дә төп һәм бердәнбер максат түгел!

Ярый, янадан яшь авторларның әле генә без күздән кичергән повестьларына әйләнеп кайтыйк. Чыннан да, алар өчен иң мөһиме—вакыйгалар, геройлар һәм аларның эш-хәрәкәтләре. Әсәрләрне укыганда без нигездә вакыйгага ияреп барабыз, шуларны күрәбез һәм күңелгә кабул итәбез, шуларга үзебезнең төрлечә реакциябезне булдырабыз. Кыскасы, без әсәрдәге геройлар тормышы, аларның язмышы белән яшибез. Минемчә, менә бу факт, менә шуңа ирешү—яшь прозаиклар өчен төп уңышларның берсе.

Хәзер инде әлеге повестьларда күзгә ташланган кайбер җитешсезлекләргә тукталыйк. Аларның да уртак булганнары шактый.

Иң элек яшь авторларның сюжет төзүдә осталыклары җитмәү нык ук сизелә. Ләлә Сөләйман повестенда, мисал өчен, берничә сюжет сызыгы күренеп тора һәм аларның һәр кайсысы үзе бер әсәр сорый сыман тәэсир кала. Билгеле, югарыда әйтеп узганыбызча, автор повестьның баш өлешен бик динамикалы алып китә, әмма уртага җитәрәк вакыйгалар күп тармакларга аерыла һәм күпмедер дәрәҗәдә буталчыклык туа, укучы адаша. Ул бераздан төп юлга килеп чыга чыгуын, ләкин ул чагында инде күңелдә: «ә теге әйләнмә юлны үтү бик кирәк идеме соң әле?» дигән сорау туа.

Рәдиф Сәгъди исә катнашучыларны артык күбәйтеп, үз укучысын шулар арасында адаштыра. Бусы да сюжет коруда осталык, тәҗрибә җитенкерәмәү билгесе.

Менә шушы беренче кимчелек икенче уртак җитешсезлекне дә китереп чыгара—повестьларның икесе дә күләм ягыннан шактый ук сузылганнар. Аларда артык өлешләрнең байтак булуы «гади күзгә» дә күренеп тора.

Әсәрдәге геройның эчке дөньясы... Безнең яшь авторлар бу өлкәгә ни дәрәҗәдә игътибарлы соң? Ләлә Сөләйманны әлеге мәсьәләдә гаепләве кыен—ул әсәрдәге һәрбер хәрәкәт белән бергә үк кешенең психологик халәтен дә үреп бара. Шулай итеп тышкы тормыш белән эчке дөнья гармоник дип әйтерлек дәрәҗәдә тоташып китә, органик рәвештә тоташкан чынбарлык күз алдына килә. Ә менә Рәдиф Сәгъди тышкы тормышны кинодагыча төгәл һәм образлы итеп тасвирлый, күрсәтә—кешенең эчке яшәешенә исә аның игътибары җитеп бетми. Ләкин, гаделлек хакына шунысын да искәртергә кирәк: икенче бер яктан алсаң, «автор әнә шул ысул аша үз геройларының эчләре буш икәнне күрсәтә бит», дип уйларга да мөмкин. Хәзерге яшьләрнең рухи дөньялары бик ярлы икәнне күрсәтә ич ул дияргә дә ярый кебек... Ләкин, әдәбиятта, бигрәк тә безнең чорда әнә шул эчке «бушлык»ны образлы итеп ачып бирү, аны укучының исендә калырлык итеп күрсәтү дә кирәктер. Ягъни, әлеге бушлык ул—вакуум булмаска тиеш, ә укучыга тәэсир итә торган, аны дулкынландыра, тетрәндерә торган, йокысыннан уята торган халәт булырга тиеш. Ә битараф, тын бушлык түгел!

Дөнья әдәбияты әсәрләрен күздән кичерсәң, еш кына шундый бер хәл күзәтелә: яшь автор күренсә, ул гадәттә үзе белән яңа герой да, өр-яңа карашлар да алып килә һәм ул карашлар, ул холык-характерлар гадәттә моңа кадәр яшәп килгән тәртипләр белән каршылыкка керә. Шундый конфликтны үзәккә куеп урыс әдәбияты классикасында хәтта «Аталар һәм балалар» дигән роман да язылды. Ә бездә ничек соң?

Рәдиф Сәгъди әсәрендә яшьләрнең яшәү рәвеше бик тә үзләренчә булса да алар артык зурга дәгъва итмиләр. Үз өерләре куйган тәртип буенча яши бирәләр... Әмма шунысы бар: безнең бүген «яшьләр» дигәнебез берничә елдан инде олыгаеп, урта буын булачак! Алар дөнья дилбегәсен үз кулларында тотачак. Димәк, тормышта үзләре теләгән яшәү рәвеше урнаштырачаклар... Повесть ахыр чиктә әнә шундый пошамангa төшерә.

Ләлә Сөләйман әсәрендәге яшь кешеләр шулай ук мактана алмый. Аларның мәхәббәтләре дә, гаиләләре дә юк һәм, кыз белән егет өйләнешеп

бергә яшәсәләр дә, бала табарга, бала багарга ашыкмыйлар. Менә бу хәл үзе үк инде бик тә шомлы фал...

## Ә хикәядә ничек?

Хикәя жанрында яңа исемнәр дигәндә иң элек «Казан утлары» журналында үткән ел бик әйбәт хикәяләр бастырган Айгөл Әхмәтгалиева һәм Сөмбел Гаффарова, «Идел»дә ике мәртәбә чыгыш ясаган Рәмзия Габделхакова, шулай ук күп кенә газета-журналларда кечкенә хикәяләр белән күренгән Илфак Шиһапов исемнәре телгә килә. Сүз уңаеннан тагын шунысын да искәртеп үтү кирәктер: бүгенге проза үсешенә Мөслим төбәгеннән чыккан иҗат әһелләре бигрәк тә күп көч кертә. Менә берничә исемне генә карагыз. Хәзерге прозадагы иң саллы иҗатчы Фоат Садриев дисенме, ел саен диярлек кызыклы һәм тирән эчтәлекле роман-повестьлар белән куандыручы Флүс Латыйфины аласынмы, укучы хәтерендә калган «Соңгы көз», «Гөлҗиһан», «Биек таунын башларында» һ. б. повестьлар авторы Факил Әмәкне әйтәсенме—болар барысы да әлеге районда туып-үскән прозаиклар. Беренче повесте һәм хикәяләре белән безнең игътибарны яулаган һәм без югарыда сүз алып барган Ләлә Сөләйман да шуннан. Инде менә «Соңгы өмет» дигән уңышлы хикәя *(«Казан утлары», 2 сан, 2000 ел)* авторы Айгөл Әхмәтгалиеваны да әлеге төбәк үстергән. Моны бик кызык бер феномен димичә ни дисең инде! Шундый шатлыклы күренешләр тагын да булсын иде дә бит, әмма әдәбиятның үз кануннары шул!

Ләкин шулай да, бүген яшь иҗатчылар үстерү дигәндә, без иң зур игътибарны мәктәпләргә һәм алардагы әдәбият укытучыларына юнәлтергә тиешбездер. Әгәр дә бала укыган мәктәптә матурлыкка һәм әдәби сүзгә сизгер, нечкә күңелле һәм кайгыртучан җанлы укытучы эшләсә, әдәби түгәрәкләр яшәсә һәм стена газеталары чыгарылса—андый җирдә инде үзенә табигать тарафыннан иҗади орлык салынган баланың күңеле үсеп китә, аңа тәүге канатлар чыга, анда иҗади дәрт-илһам туа... Укытучы кеше бит әле ул иҗатчы баланың беренче укучысы да була... Әнә шул чагында ул җылы сүз әйтә алса, бала күңелендәге матурлыкны үсендереп җибәрә алса—аннары китә инде иҗат буасы ерылып! Ягъни, мәктәп баласы үзе акрынлап-акрынлап матбугат белән, чын иҗатчылар дөньясы белән тоташып китә. Чын мәгънәсендә: инешләр Иделгә кушылгандай була инде шуннан соң!

Үзенең хикәясен:

> Баш куям тезләренә лә
> Яшь коям эзләренә...

дигән үзәк өзгеч халык җырыннан башлап киткән Айгөл Әхмәтгалиева да, һичшиксез, әнә шундыйрак баскычларны узгандыр. Хикәянең керешендә халык җырының җанны өтә торган юллары белән укучы игътибарын җәлеп иткәч, автор бүгенге авыл тормышының гыйбрәтле күренешләрен нечкә психологик алымнар һәм төгәл тотып алынган детальләр ярдәмендә тасвир кылырга тотына. Шунысы мөһим—Айгөлнең хикәясендә дә яшь буын вәкиле Фагыйлә чорсыз һәм теле-телгә йокмас бер хатын итеп бирелә. Ә өлкән яшьтәге Шәмсенурттәй әнә хискә-моңга бирелеп утыра, аның күңелендә кадерле хисләр, изге уйлар һәм хәзерге хәлләргә аптырау, борчылу. Тормышның ярлы булса да чистарак, матуррак, ышанычлырак, кешеләрнең әйбәтрәк һәм бер-берсенә карата шәфкатьлерәк булган чагын сагыну... Әсәрне укыганда бу изге уйларның автор күңеленнән чыгуына, шуннан—йөрәк түреннән—агылуына чын-чыннан ышанып барасың.

«—Син гаепле, барысына да син гаепле, эт баласы! Бет, дөмек!

Бала елый, ярсый-ярсый елый. Ә хатынның йөзендә җиңү тантанасы, үч алу ләззәте. Барысы да ул уйлаганча, уңышлы килеп чыкты...»

Үзенең «Югалту» исемле хикәясен *(«Идел» журналы, 7 сан, 1999 ел)* яшь автор Рәмзия Габделхакова әнә шулай бик тә югары драматизм дулкыннарында башлап китә. Бирелә яшь гаилә тирәсендәге хәлләр үзәккә куела: хатын, бәләкәй бала һәм сөяркә. Кечкенә чагында балалар йортында үскән Илгизә үзенә Фәндәснең мәхәббәте сүрелә башлаганын сизгәч, аннан һәм аның хатыны Энҗедән үч алу юлына баса: аларның бәләкәй арбадагы балаларын урлый һәм урманга алып барып терелләй җиргә күммәкче була...

Шул ук журналның 9 санында басылган «Мин гаепле түгел» хикәясендә

(1999 ел) бу автор андый ук зур фажигәне алмый, ә икенче төрлерәк вакыйгага мөрәҗәгать итә.

«Нургали бүген дә кибет төбендә басып тора иде. Зөлфия алымнарын акрынайтты. Бу диванаины күрмәс өчен генә дә әлләниләр бирер иде! Әйтерсең лә, бар дөнья яктысын шушы егет каплап тора.

—Нигә мин, нигә башка берәү түгел?—дип уйлый Зөлфия. Ул үзен чынлап та, бу жүләрнең корбаны итеп сизә».

Әйе, Нургали—акылга таманрак егет. Ләкин менә аның яшь кибетче Зөлфиягә күзе төшкән. Егетнең әнисе Кәүсәрия апа да менә бик газаплана: «Бәхете булмады шул балкайның. Язмыштыр инде... Алай гел жүләр дә түгел бит үзе, әйткәнемне аңлый, кушканны эшли. Бар нәрсәсе дә урынында аның. Ир буларак, дим...»

Кәүсәрия апа үзләренең акчалары күплеген дә әйтә—«мин сезгә машина да, фатир да алып бирә алам» ди... Кыскасы, Зөлфиянең үз улына кияүгә чыгуын тели бәхетсез ана. Ә яшь кыз моны ничек кабул итә соң?

«Икенче көнне эшенә килгәч, ишек төбендә таптанып торучы Нургалине күрде. Хурланды, ярсыды Зөлфия:

—Нәрсә кирәк сиңа, ә? Нәрсә карачкы кебек тагы монда килеп бастың?! Бар, өеңә кайт. Ычкын моннан! Күземә күренмә бүтән! Гарык мин синнән, гарык! Менә моннан гарык! Мунча пәрие! Бар, кайт, өеңдә утыр!»

Әлбәттә, жүләр саналса да, үзе яратып йөрегән Зөлфиядән мондый утлы сүзләрне ишеткәч Нургали инде түзә алмый—асылына.

Яшь хикәяче безне бүгенге көннең әнә шундый фажигале хәлләре эченә алып керә. Ул әсәрендә озынга сузмыйча тасвир кыла, психологик яктан да төгәл эш итә, драматизмны да югалтмый. «Ә мондый әсәрнең язылу максаты нидә соң?» диеп сорасак: «Бүгенге кешегә гыйбрәт бирү, аның күңел күзен ачарга теләү, фажигаләрне алдан кисәтергә тырышу»—дигән җавап алырбыз, мөгаен.

Соңгы елларда бик актив иҗат иткән, китаплар чыгарган һәм хәтта Татарстан Язучылар берлегенә дә кабул ителгән Сөмбел Гаффарова турында без инде «яңа исемнәр» диеп сөйләшергә тиешме икән? Әйе, бу сорауга җавап нинди генә булса да без, барыбер мондый яшь каләмебез булуга сөенү хисен яшерә алмыйбыз. Сөмбел иҗаттагы кыюлыгы, иҗади хыялының көче һәм теленең матур-сыгылмалы булуы белән җәлеп итә. Үткән ел «Казан утлары»нда (1 сан) аның өч кенә хикәясе басылган, әмма алардан да үзенчәлекле автор, тормыш күренешләренә һәм кеше язмышларына сизгер йөрәк яшәве күренеп тора. Ә бәлки хәзер Сөмбелгә үзен повесть жанрында сынап карау чоры да житкәндер? Әлеге хикәяләрдәге иҗади яктан киң сулыш сизелү, кыюлык һәм житдилек күренү әнә шундый уйга да этәрә.

Безнең юмористик хикәя өлкәсенә дә менә дигән яшь сәләт килүен шатланып билгеләп үтәргә кирәк. Сүз «Татарстан яшьләре»нең үткән елгы 9 декабрь санында «Карар» исемле, «Казан утлары»ның 1999 елгы 7 санында «Комган белән самавыр» дигән чын юмор әсәрләре бастырган Илфак Шиһапов турында бара.

«—Их, комган туган,—диде самавыр, ямьшәйгән борынын турыларга маташып.—Бар иде безнең дә адәм балаларына кирәк чаклар. Утыра идем бит мин табын түрендә. Көн саен юып, чистартып торалар иде үземне...» Менә шушындый кызыктыргыч сүзләр, үзенчә аһәң, күңел күтәргеч елмаю дулкыны белән башлап киткән бәләкәй генә хикәя укучыда матур тойгы калдыра, автор каләменең уңышы юмордагы уңышы дип кабул ителә. Ә «Карар» дигән әсәрендә исә Илфак татарның хәзер яңадан актуальләшкән ике хатын алу идеясен үзәккә куеп, шулай ук үткен генә шаяру хисе китереп чыгара. Ахырдан хатын кешенең: «Сания белән Әминәне генә алып кайтма, башкасына мин риза...»—диюе дә һич көтелмәгән яктан уйнатуы белән ситуацияне тагын да көлкерәккә әйләндерә. Кыскасы, Гамил Афзал, Фәнзаман Баттал, Камил Кәримов янына тагын бер яшь авторның килеп кушылуы—бәхәссез сөенеч.

Соңгы елларда безнең прозада Алмаз Гыймадиев дигән яшь язучыбыз да матур гына эшләп килә. Узган 2000 елда Татарстан китап нәшрияты аның «Хуш, Тамчыгөл!» исемле икенче җыентыгын бастырып чыгарды. Газета-журнал битләрендә еш кына күренеп сөендереп торган автор үзенең китабында да иҗади юнәлешенә хыянәт итмәгән: бүгенге мәктәп балалары, яшүсмерләр дөньясы бик

мавыктыргыч итеп, кызыклы ситуацияләр, күренешләр аша тасвир кылына.

Үз хикәяләрен үгезне шундук мөгезеннән алып башлый Алмаз. «Мине мәктәптә «Дезодорант Рәсим» дип йөртәләр. Бигрәк ямьсез кушамат инде, иеме?» Әсәрнең иң тәүге җөмләсе итеп куелган менә шушы сүзләрдә хикәя эченә чакырып торган тылсымлы тарту көче дә, бүтән язучыларны кабатламаган үзенчәлекле язу стиле дә һәм баштан ук көләсене китергән кызыклы кушамат та бар. Китапта бары тик ике бит күләм биләгән менә шушы бик бәләкәй хикәядә 8 Март бәйрәме тәэсире дә, малайларның кызларга бүләк эзләп Казанга килүе дә һәм андагы маҗаралары да, нәрсә икәнен аңлап бетермичә бүләккә дип коңгызларга сиптерә торган сасы дару алып кайтулары һәм бөтен мәктәпкә көлкегә калулары да сыйган.

«Ата-аналар» җыелышы дигән хикәя дә шуннан зур түгел, әмма бусында инде кайсыбер әтиләрдән көлә Алмаз Гыймадиев. Әнә берсенең малае мәктәптә инша язганда өйләрендә ни күрсә шуны язган, хәтта өйдә кәрт сугуларны да. Ә әтиләре исә җыелышта:

«—Дөрес түгел!—дип кабатлады ул.—Кая ул әкәм-төкәмнәргә мине оту! Язган икән, дөресен язсын. Кичә пеналына хәтле оттырып бетерде бит ул чебеш!»

Шушы кыска гына өзектә дә яшь авторның кеше холкын, тормыш вакыйгасын оста эләктереп ала белүе, шуны үз әсәрендә матур, тәэсирле итеп җанландыра алуы күзгә бәрелеп тора.

Чаллы шәһәрендә яшәүче Айгөл Нуретдинованың «Хикмәтле тартма» дип исемләнгән беренче китабы әллә ни калын да түгел—аңа нибарысы дүрт әкият сыйган, әмма аларның һәрберсе истә кала торган. «Көннәрдән бер көнне, гомере буе балта остасы булып эшләгән Бәдретдин бабайның келәтендә булган ди бу вакыйга...» Әнә шундый ымсындыргыч сүзләрдән башлап китә яшь автор әлеге китаптагы тәүге әкиятен. Айгөл биредә сүзне беренче карашка эш кораллары турында гына алып бара кебек, анда балта:

—Мин гайрәтле,
Мин сәләтле,
Каршы алыгыз түрәне.
Минем аркада салалар
Келәтләрне, өйләрне,—

дип мактана. Янәшәсендә яткан чүкеч тә аннан калышмый, бераздан пычкы да сүзгә кушыла... кыскасы, тартмада яткан һәркайсы үзен генә мактый башлый.

Ләкин әкиятне укыганда без инде биредә эш коралларын гына күрмибез, безнең алга үзләренең әнә шундый мактанчык холыклары белән бергә төрле-төрле кешеләр килеп баса. Алар арасында килеп чыга торган хикмәтле хәлләр искә төшә.

Ә инде яшь язучының китаптагы «Кирәмәт» дигән икенче бер әкияте фаҗигале мәхәббәт хакындагы моңсу бер легенда, поэма сыман кабул ителә. Бу әсәрдә Таңсылу исемле яшь гүзәлне сөйгәне Кирәмәттән аералар, башка әкиятләрдән үзгә буларак алар ахырда да кавыша алмыйча кала. «Сагыштан, кайгыдан нәрсә эшләргә белмәгән Кирәмәт кая киткәндер, бу якларда аны башка күрүчеләр булмаган. Тик сагыштан саргайган, өметен өзгән Таңсылу гына һәр таңны Зәңгәр күл буенда каршы ала ди...»

Китаптагы әкиятләр теленең ягымлы, йомшак, тәэсирле, хисчән булуы, хикәяләүнең мавыктыргыч алып барылуы белән дә күңелгә ошый.

## Егетләр кайда?

Соңгы елларда татар прозасында күренгән яңа авторларны күзәткәндә алар арасында егетләрнең аз булуы нык борчуга сала торган күренеш. Моның сәбәбе нәрсәдә икән?

Минемчә, әлеге күңелсез күренешнең иң беренче сәбәбе шул: хәзерге яшьләрдә ничектер рухи тормыш—җитди күренеш, җитди нәрсә диеп саналмый башлады шикелле. Тирә-юнебездә төрледән төрле техниканың бихисап күбәюе һәм аларның үзенә зур игътибар таләп итүе, безнең чынлыгыбызда зур урын биләве, телевидение белән компьютерларның кешене төрле яктан чолгап алуы,

бизнес мөнәсәбәтләренең соңгы елларда шулай ук нык активлашуы, сервис тармагына байтак яшьләр соралу, тамашалар-шоулар күбәю һ. б.лар—менә болар барысы да хәзер тормышыбызда чамасыз зур урын били башлады һәм нәтиҗәдә, рухи яшәеш нык ук кысрыкланды.

Аннары, икенче зур сәбәп, минемчә, мондый: әдәбият ул—зур рухи көч, рухи батырлык сорый, иҗатчының әнә шундый көчкә ия һәм үзенчәлекле шәхес булуын таләп итә. Ә безнең соңгы дистә елларда үскән егетләребез андыймы соң? Моңа хәтле тормышта ир-ат билән торган гаять җаваплы вазифаны үз өсләренә алырга әзерме алар? Гаилә өчен, балалар өчен һәм, ахыр чиктә, тулаем җәмгыять өчен җаваплылыкны үз өсләренә алырдай хәлдәме алар? Соңгы еллар тормышының шактый иркә шартларында үсеп калыплашкан күп кенә егетләрне күздә тоткан чагында әлеге сорауларга уңай җавап бирүе шактый ук кыен. Ягъни, бик тә гадиләштереп әйткән чагында: бүген үз сүзләрен әйтергә дә куркып яшиме әллә безнең егетләребез? Әллә инде аларның халыкка әйтердәй мәгънәле, мөһим эчтәлекле сүзләре дә юкмы?

Тагын бер мөһим момент бар. Белүебезчә, әдәбият, бигрәк тә аның проза тармагы, автордан язу өстәле янында озаклап һәм басылып утыруны, язган әйберенне кат-кат укуны һәм җентекләп төзәтүне, аннары тагын әллә ничә мәртәбә күчереп язуны таләп итә. Менә шушындый зур сабырлык, түземлек һәм үҗәтлек сорый торган эшкә хәзерге бик актив хәрәкәт чорында үскән егетләрнең чыдамлыгы җитми кебек. Мондый зур психологик һәм хәтта физик хезмәткә алар әзер түгел, бу—аларның кулыннан килми торган бик авыр вазифа.

Дүртенче бер сәбәп: соңгы еллардагы актив хәрәкәт шаукымы, объектив рәвештә дип әйтерлек дәрәҗәдә, яшьләрнең, бигрәк тә егетләрнең, эчке яшәешен үтә гадиләштерде, примитивлаштырды, аны ярлыландырды. Аларның күбесе «яңа урыс»ка һәм «яңа татар»га әверелде—ә болары хакындагы мәзәкләрне инде хәзер бик тә күп беләбез. Аларның кем икәнлеге хакында озаклап сөйләп торасы да юк... Үзләрендә иҗат өчен иң кирәк булган җан олылыгы, күңел нечкәлеге җитмәгәч—алар нишләп әсәр язарга утырсын соң инде?! Алар машина куа, дөнья куа һәм кай чакларда сирәк-мирәк кенә әйбәт эшләр дә эшләп ташлыйлар...

Менә без югарыда берничә сәбәпне күрсәтеп үттек. Егетләрнең әдәбиятка соңгы елларда ни өчен аз килүен аңларга тырыштык. Әмма бу хәл берәр вакыт үзгәрер микән соң? Югыйсә, әдәбиятта ир-ат акылы бик тә кирәк бит! Бу: зур социаль проблемалар күтәрү дигән сүз, тирән фәлсәфилеккә ирешү дигән сүз, монументаль әдәби образлар иҗат итү дигән сүз, бүгенге чынлыктагы кин масштаблы һәм үткен әхлакый-рухи конфликтларны әдәби әсәргә уңышлы рәвештә алып керә алу дигән сүз.

**Минем ышануымча, безнең егетләр яши-яши үзләренең хәзерге яшүсмер чакларын, яшүсмер акылларын узарлар, дөньяның фән һәм техника беләнгенә алга бара алмаганлыгын аңларлар. Үз яшәешләрендә, үз язмышларында, җәмгыятебез яшәешендә әнә шул ачы хакыйкатьне бөтен акыллары белән һәм үз бәгырьләре аша уздыра-уздыра төшенгәч—әнә шул чагында инде алар үз йөрәкләренә тынычлану һәм ышанычлы бердәнбер сердәш эзләп әдәбиятка киләчәкләр.**

**Ә моңа кеше бары тик үз язмышы аша гына ирешә ала. Кеше моңа бары тик үз зиһене, үз акылы һәм үз язмышыннан килеп чыккан рухи әхлакый сабаклары, тәҗрибәсе җирлегендә генә ирешә ала. Әнә шул чагында гына кеше җаны, кеше акылы чынлыкта әдәбиятның нәрсә икәнен чынлап торып аңлый, төшенә ала. Һәм әнә шундый чакларда инде уйлап кына чыгарылмаган, ә чын тормыштан алынган чып-чын әдәбият әсәрләре туа. Кеше язмышларына тоташкан әсәрләр барлыкка килә.**

**Бирсен Ходай, көтик әнә шундый бәхетле елларны!**

...Татар халкының иң яраткан агачларыннан берсе булган алмагачлар язларын яшь киленнәр сымак ак чәчәккә күмелеп утыра... Дөньяның иң матур, иң күңелле көннәре була ул. Җаннар, йөрәкләр өмет, ышаныч, яктылык белән тулы була андый ямьле көннәрдә...

Безнең прозадагы бүгенге яшьләр дә әнә шул ак чәчәккә күмелгән алмагачларны хәтерләтә. Озакламый чын һәм тәмле җимешләр бирәчәк алар! Алма ашар көннәребез алда әле... Бирсен Ходай!





## 8—ӘНФАЛ (ТАБЫШ МАЛЫ) СҮРӘСЕ

***(Әнфал сүрәсе 75 аятьтән тора. Мәдинә-и Мөнәүвәрәдә иңгән. Әнфал—сугышта кулга төшерелгән байлык, ганимәт дигән сүз.)***

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Сугышта алынган ганимәт турында синнән сорыйлар, әйт син аларга:

—Ганимәт Аллаһ белән Пәйгамбәр карамагында,—диген.—Шуңа күрә, әгәр дә сез мөэмин булсагыз, үзара тату булыгыз, Аллаһтан куркыгыз вә Рәсүленә итагать итегез.

*(«Бәдер сугышында мөселманнар җиңеп, кяферләр кача башлагач, мөселманнарның бер өлеше кяферләрне куа китә, икенче төркем Рәсүлне саклап кала, өченчесе исә табыш җыю белән мәшгуль була. Соңра барысы да бер урынга җыелгач, мал хакында низаг чыга. Бу аять шул хакта».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**2.** Аллаһны зикер иткәндә аларның йөрәкләре тетрәр, аятьләр укыганда аларның иманы арта, алар бары тик Аллаһ хөкемнәренә генә таянып эш итәләр. Менә шулар була инде чын мөэминнәр. **(3)** Алар намазларын дөп-дөрес укыйлар вә үзләренә иңдерелгән нигъмәтләрне *(Аллаһ юлында)* сарыф итәләр. **(4)** Менә шулар була инде чын мөселманнар. Алар өчен Аллаһ катында нинди дәрәҗәләр, ярлыкаулар вә бихисап ризык бар.

**5.** *(Бәдер сугышында кулга төшкән ганимәтне бүлешкәндә, кайбер мөселманнар: мал дөрес бүленмәде, дип ризасызлык белдерделәр.)* Раббың *(дошманнарга каршы сугышыр өчен)* сине хаклык белән өеңнән чыгарды, ләкин кайбер мөселманнар *(сугышка барырга)* һич теләмәде. **(6)** Дөреслек уртага чыкканнан соң да алар синең белән бәхәсләшә, әйтерсең лә, аларны күренеп торган үлемнең күзенә өстерәп алып баралар.

*(«Һиҗрәтнең икенче елында Мәккә кяферләренең сәүдә кәрванын Әбү Суфьян Шамга алып китә. Болар элегрәк мөселманнарның малын талап, ватаннарыннан куган кураешлар иде. Кәрванның юлга чыкканлыгы турында хәбәр алгач, Мөхәммәде Рәсүлулла (с.г.с.) бу кәрванны кулга төшермәк өчен, өч йөздән артык сугышчысы белән юлга чыга. Бу турыда хәбәр алгач, Әбү Суфьян куркыныч турында Кураешка хәбәр юллый һәм кәрванны башка юлдан алып китә. Шулай итеп, ул кәрванны коткара. Мөшрикләр мең кешелек гаскәр белән юлга чыга. Мөселманнар кәрван белән түгел, мөшрик гаскәре белән очрашу мәҗбүрендә кала. Арадан берсе:*

*—Без сугышыр өчен әзер түгел, без бары тик кәрванны талар өчен чыктык,—диде һәм бәгъзеләре сугышмаска теләп, чигенә башлады.*

*Тора-бара бөтенесе бергә сугышырга булды һәм сугышта мөселманнар җиңү казанды».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**Журнал өчен Рабит Батулла әзерләде.**

**7.** Исегездәме, Аллаһ, табыш буларак, сезгә ике төркемнең берсен вәгъдә иткән иде, сез коралсыз кәрванны алырга теләдегез. Аллаһ үз сүзләре белән Хакыйкатьне өскә чыгарырга теләп, кораллы *(Кураеш гаскәрен)* кяферләрне кырып бетерергә кушты. **(8)** Кяферләр моны ярамас эш дип санасалар да, Аллаһ Хакыйкатьне өскә чыгарыр өчен, яманны бетерер өчен шулай мәгъкуль күрде. **(9)** *(Сугышка керер алдыннан)* сез Аллаһтан ярдәм сорап, дога кылдыгыз, Аллаһ догагызны кабул итте һәм әйтте:

—Сезгә ярдәм итәр өчен мин сезгә бер-бер артлы мең фәрештә җибәрәм,—диде.

*(Мөселманнар өч йөз кеше булып, мөшрикләр мең кеше иде. Шуңа да карамастан, мөселманнар җиңү яулады.)*

**10.** Аллаһ моны сезнең күңелләрне куандырыр өчен, тынычландырыр өчен эшләде. Чөнки ярдәм бары тик Аллаһтан гынадыр. Аллаһ—мотлак җинүчедер, кодрәт вә хикмәт ияседер. **(11)** Шул вакытта *(сугыш алдыннан)* үз тарафыннан миһербанлык илә сезне *(ял итеп алсыннар, куәт җыйсыннар өчен)* йокыга талдырды; сезне сафландырмак-пакьләндермәк өчен, шайтанның вәсвәсә юшкыныннан тазартыр өчен, күңелләрегезне бер-берсенә якынайтмак өчен, аяк баскан җирегезне *(тез буыннарыгызны)* ныгытыр өчен, Күктән яңгыр яудырды.

*(«Кураеш гаскәре алданрак килеп, Бәдер коесы янында урнаша. Ислам мөҗәһитләре исә сусыз кала. Комлы җирдә йөрү кыенлаша, иркенләп хәрәкәт итәргә мөмкинлек булмый. Шайтан мөселманнар күңеленә вәсвәсә сала: үзегез Аллаһның сөекле бәндәсебез, дип әйтәсез, үзегез сулы урынга да җирләшә алмагансыз, ди. Яңгыр яугач, мөселманнар суга туеналар, шайтанның вәсвәсәсе юкка чыга. Яңгырдан соң ком тыгызлана, сугышыр өчен, йөрер өчен уңай була. Мөселманнарның күңеле күтәрелә».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**12.** Менә Раббы фәрештәләренә боерык күндерде:

—Ышаныгыз, мин сезнең белән бергә булырмын; барыгыз, иман китергән-нәргә ярдәмче булыгыз; Мин кяферләрнең йөрәгенә куркы салачакмын; аларның муен тамырларына орыгыз; аларның бөтен бармакларына чабыгыз,—диде. **(13)** Моның сәбәбе шулдыр ки: алар Аллаһка һәм аның Рәсүленә каршы төштеләр. Кем Аллаһка вә Рәсүленә каршы төшә, аларга Аллаһның хәтәр җәзасы иңәчәк. **(14)** Менә, бу җәзаны күргәнсездер бит, хәзер шул газапларны татып багыгыз. Кяферләргә *(җәһәннәм)* ут әзерләнгән. **(15)** Әй, мөэминнәр, кяферләр гаскәре белән йөзгә-йөз очрашкан чакларда куркып качмагыз. **(16)** Яңадан сугышыр өчен чигенү яки уңай урын алмак өчен, вакытлыча сугыш кырыннан китү ярый. Әмма башка шартларда чигенү—Аллаһның җәзасына дучар булу, дигән сүз. Андыйларның урыны—җәһәннәмдер. Ул бик тә хәтәр җәза урыны.

*(Бәдер сугышы вакытында Мөхәммәд (галәйһиссәлләм) мөшрикләргә каршы бер уч туфрак атты, шуның белән дошманнарның күзе томанланды, гайрәтләре шиңде, мөселманнар хәтәр орышып, җитмеш дошманны үтерде, җитмешен әсир итте. Мин фәлән кадәр дошманны үтердем, мин төгән кадәресен ордым, дип масайганнарга Аллаһ әйтте):*

**17.** —Аларны сез үтермәдегез, фәкать Аллаһ үтерде; *(туфрак)* атуны да син атмадың, Аллаһ аттырды; бу эшләрне Аллаһ мөэминнәрне сынар өчен башкарды. Шик юк ки, Аллаһ барысын да ишетеп торучы, белеп торучы. **(18)** Барысы да нәкъ шулай. Шик юк ки, Аллаһ кяферләр корган тозакларны вата тора.

**19.** *(Әй, кяферләр)* сез җиңү теләгән идегез, *(мөселманнарга)* җиңү килде. Әгәр дә сез *(Аллаһны инкарь итүдән)* ваз кичсәгез *(яки мөселманнарга каршы сугыштан баш тартсагыз)* үзегез өчен хәерле булыр. Әгәренки янә сугыш башласагыз *(Пәйгамбәргә дошманлыкны дәвам итсәгез)*, Без дә ана ярдәмгә килербез. Гаскәрегез никадәр күп булса да, файда булмас. Аллаһ мөэминнәр белән бергә.

**20.** Әй, мөэминнәр, Аллаһка вә аның Рәсүленә буйсыныгыз; *(вәгазьләрен,*

*Коръән сүрәләрен)* ишеткән хәлдә, Аннан йөз чөермәгез. **(21)** Ишетмәгән көе дә: ишеттек, дигәннәр кебек булма. **(22)** Шөбһәсез, Җир йөзендәге җан ияләренең Аллаһ каршында иң әшәкесе—фикерли белмәгән телсез-чукраклар кебек бәндәләр. *(Ишетсәләр дә—саңгырау, сөйләшсәләр дә—телсез мәхлуклар.)* **(23)** Аллаһ алар күңелендә берәр төрле игелек күрсә иде, шиксез, аларны ишетерлек, сөйләшерлек итәр иде. Ләкин ишетсәләр дә алар барыбер йөз чөерәчәк.

*(«Бу аятьләр Аллаһ илчесенең сүзен, вәгазьләрен ишетеп тә, ишетмәгәнгә салышканнарга ишарәдер. Ишеткәннәрен дөрес мәгънәдә аңламаганнарына күрә, сүз аңламаучы, саңгырау, телсез-чукрак хайваннарга охшатыла. Андыйларда игелек сәләте юк».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**24.** Әй, иманлы кешеләр, ул сезне тереклек чыганагына *(Коръәнгә)* чакырса, Аллаһка вә аның Рәсуленә буйсыныгыз. Һәм белеп торыгыз: Аллаһ кеше белән аның күңеле арасында торыр вә сез, һичшиксез, Аның янына тупланачаксыз.

***(«Аллаһ кеше белән аның күңеле арасында торыр»*** *җөмләсен шәрехләүне тәфсирчеләр үз өсләренә алмыйлар. Ләкин аңлатырга тырышучылар бар. Башка бер аятьтә: Без инсанга шаһ тамырыннан (аортадан) да якын торабыз, диелгән. Аллаһ кешенең кабилиятенә (мөмкинлегенә, сәләтенә) күрә, аның күңелен теләгән тарафка юнәлтә. Пәйгамбәребез болай дога кылды: Әй, күңелләрне юнәлтүче Аллаһ, минем күңелемне Үзеңнең динең тарафында ныгыт. Исемнәре телгә алынган тәфсирчеләр язуы буенча ул җөмләне болайрак аңлап булыр иде. Аллаһ кешенең матди бәдәни теләкләре белән аның рухи омтылышлары арасында. Кеше ике юл чатында тора. Бәдәни, физиологик теләкләр һәм рухият ихтыяҗлары. Кайсы теләк җиңсә, кеше шул юлдан китә. Аллаһ кешегә ирек куеп, шул юл чатында кешенең кылмышларын күзәтә.)*

**25.** Сез шундый фетнәләрдән куркыгыз, ул фетнәләр бары тик залимнәргә генә кагылмас *(барыгызны да тар-мар итәр)*, белегез ки, Аллаһның газабы дәһшәтледер.

*(**«Фетнә»** сүзенең төрле мәгънәләре бар: чуалыш, гауга, башбаштаклык, бозыклыкка өндәү, ара бозу, котырту. Юк-барга кызыгып, туры юлдан язу, Җиһадта катнашудан баш тарту, Ватанга хыянәт, милләтнең бербөтенлеген таркатырлык гамәлләр кылу... Әйтик, бер шәхес, үз тормышын баету өчен, халкының мәнфәгатьләрен сатса, бөтен халык, гөнаһсызлар зыян күрә. Бу аятьнең тәрҗемәләрендә дә, тәфсирләрендә дә аерма шактый. Шуңа күрә, берничәсен мисалга китерү мәҗбүрендәбез.*

*—**И. Крачковскийда:** «Бойтесь испытания, которое постигнет не только тех из вас, которые несправедливы»: гаделләргә дә кагыла торган яман сынаулардан куркыгыз, ягъни Аллаһның сынауларыннан гаделләр дә куркырга тиеш.*

*—**В. Пороховада:** «И бойтесь мятежей и смут, что (появившись) вовлекают не только тех из вас, что нечестивы».*

*—**Ш. Ногманида:** «Зарары фетнәне булдыручыга гына булмыйча, бәлки зарары барыгызга да була торган фетнәне булдырудан сакланыгыз». Нәтиҗә: кеше урлаша, үзе генә гөнаһлы була; икәү зина кылса, икәвесе гөнаһлы була. Ләкин аңлы рәвештә дә, абайламастан да кылынган шундый ялгышлар, хаталар, гөнаһлар була, мондый гамәлләрне кылган кеше үзе генә Аллаһ каршысында гөнаһлы булып калмый, берничә кешегә, күп кешегә, бөтен халыкка, хәтта барча кешелеккә зыян салучы хаин, Иблискә тиң гөнаһкяр була.)*

**26.** Җир йөзендә сез аз санлы, гаҗиз идегез, хәтерлисезме? Башкалар сезне килеп басар, *(талар, әсир итәр)* йортыбыздан сөреп чыгарыр, дип котыгыз оча иде. Аллаһ сезгә сыеныр урын бирде. Ярдәме белән сезне куәтләндерде, сезгә саф, татлы ризыклар бирде. Шаять, шөкер итәрсез. **(27)** Әй, иман китерүче халык, Аллаһка вә аның пәйгамбәренә хыянәт итмәгез. Белгәнегез көенчә, *(аларга хыянәт итсәгез)*, үзегездәге әманәткә дә хыянәт иткән булырсыз. **(28)** Белеп торыгыз, малларыгыз вә балаларыгыз сезне сынау өчен генә бирелә вә бөек әҗер Аллаһ янындадыр. **(29)** Ий, иманлы халык, әгәр Аллаһтан курыксагыз, Ул сезгә яманнан яхшылыкны аерырлык зиһен бирер, хаталарыгызны кичерер, сезне ярлыкар. Аллаһ—бөек миһербан иясе.

**30.** Кяферләр сине үтерергә ниятләп, аяк-кулыңны богаулап, өеңнән алып чыгар өчен, тозак корганнарын исенә төшер. Алар тозак кора икән, Аллаһ та аларга тозак корыр. Тозак коручыларның иң остасы—Аллаһ Тәгалә!

**31.** Аятьләребезне тыңлагач, әйттеләр:

—Ишеттек, әгәр телибез икән, без дә шулай сөйли алабыз. Бу борынгылар сөйләгән әкияттән башка нәрсә түгел,—диделәр. **(32)** Янә исенә төшер әле, алар ни диде?

—Йа, Аллаһым, әгәр бу китап Синең катыңнан килгән бер Хакыйкать икән, *(дәлил өчен)* Күктән таш яудыр яки безгә хәтәр җәза бир,—диделәр. **(33)** Син алар арасында чакта Аллаһ аларга җәза бирмәс. Алар арасында ярлыкау сораганнар булганда да җәза бирмәс. **(34)** Харам мәчетенең сакчылары булмаганнары көенчә, алар мөселманнарны мәчеткә кертми. Ни өчен соң Аллаһ аларны җәзага тартмый?

—Анда бары тик тәкъва кешеләр генә сакчы булып тора ала. Ләкин аларның күпчелеге моны белми. **(35)** Аларның Бәйтулла янындагы догалары да сызгыру яки кул чәбәкләүдән башка нәрсә түгел. *(Әй, кяферләр)* инкарь итүегезгә күрә, хәзер инде газабын да татыгыз.

***(Риваятьләргә күрә, мөшрикләрнең кайбер ирләре, хатыннары Бәйтулла тирәли ялангач килеш әйләнеп йөри, тәваф итә. Тәваф вакытында алар бармакларын авызларына кабып сызгыралар, кул чабалар. Баксаң, бу аларның дога кылуы икән.)***

**36.** Шик юк ки, инкарь итүчеләр малларын кешеләрне Аллаһ юлыннан яздырыр өчен сарыф итәләр. Алга таба да шулай сарыф итәчәкләр. Әмма соңыннан бу аларның үз башларына йөрәк ачысы булып, иң ахырда җиңелү газабы булып төшәчәк. Имансызлар исә җәһәннәмдә тупланачак.

***(«Бәдер сугышында, аннан соң булган сугышларда да мөшрикләр бөтен байлыкларын уртага салып, Исламны җиңәргә маташып карадылар, ләкин ахырда бөтенесе дә тар-мар ителде».***

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**37.** Аллаһ мордарны тазадан *(кяферне мөселманнан)* аерды; бөтенесен берьюлы җәһәннәмгә атмак өчен, мордарларның бер өерен икенчесенә кушты. Менә, зыян күрәчәкләрнең үзләре шулар була инде. **(38)** Инкарь иткәннәргә сөйлә: *(сиңа дошман булудан)* ваз кичсәләр, кылганнарын *(гөнаһларын)* кичерәчәкмен. Киресенчә булса, андыйлар белән үткәндә ни булганын алар күреп тора. **(39)** Фетнәләр беткәнчегә чаклы, Аллаһның дине тулысы белән урнашканга чаклы алар белән орыш. Инкарь итүдән туктасалар *(Аллаһка иман китерсәләр)*, Аллаһ аларның гамәлен хуп күрер. **(40)** Әгәр *(иманнан)* баш тартсалар, белеп торыгыз ки, Аллаһ сезнең яклаучыгыз. Ул нинди кодрәтле яклаучы вә Ул мөкәммәл ярдәмче! **(41)** Әгәр дә Аллаһка *(иман китергән булсагыз)*, нәҗес белән пакьлекне аерган Көнне, ике гаскәрнең *(Бәдер сугышында)* бер-берсенә каршы килгән көнне, колыбызга *(Мөхәммәдкә)* иңдергәнебезгә *(аятьләргә)* инанган булсагыз, белеп торыгыз ки, ганимәт *(җиңелгән дошманның малы)* сыйфатында алган һәр нәрсәнең төгәл биштән бере Аллаһныкы, Рәсүлнеке, аның якын кардәшләренеке, ятимнәрнеке, мохтаҗларныкы, юлчыларныкы. Аллаһ һәрнәрсәгә кодрәтле, хактыр ки. **(42)** Исегездәме? *(Бәдер сугышы вакытында)* Сез үзәннең бу ягында *(Мәдинә тарафында)* идегез, тегеләр ерак тарафта *(Мәккә ягында)* иде. Кәрван исә сездән аскы якта *(диңгез буенда)* иде. Әгәр сез бу урында очрашырга алдан ук сүз куешкан булсагыз, аймыл булып шөбһәгә төшкән булыр идегез. Ләкин Аллаһ кирәкле боерыгын җиренә житкезде; һәлак булачак кешенең *(мөшрикләрнең тар-мар ителүе)* үлеме күренсен өчен, исән калганның *(җиңүче мөселманнарның)* исән икәне ап-ачык дәлил булсын өчен, Аллаһ шулай кылды. Аллаһ ишетеп-белеп торучы. **(43)** Исенә төшер әле, Аллаһ синең төшеңдә аларны аз итеп күрсәтте. Әгәр аларны күп итеп күрсәткән булса, сез каушап калыр идегез, *(сугышыргамы, сугышмаскамы, дип)* талаша башлар идегез. Ләкин Аллаһ *(сезне үзара дошманлашудан)* коткарды. Шик юк ки, Ул кешеләрнең күңелендәгеләрне белеп тора. **(44)** Башкарылачак эшне җиренә житкезер өчен, Аллаһ *(сугыш кырында)* кара-каршы килгәч, аларны аз санлы итеп күрсәтте, аларга да сезне аз итеп күрсәтте. Бөтен эшләр Аллаһ карамагындадыр. **(45)** Әй,

мөселманнар, *(дошмани)* гаскәр белән йөзгә-йөз очрашкан чагыгызда *(каушамагыз)* каты торыгыз вә туктаусыз Аллаһ исемен телгә алыгыз, уңышларга ирешерсез.

**46.** Аллаһка вә аның Рәсүленә буйсыныгыз, үзара гаугалашмагыз, юкса, куркуга төшәрсез, гайрәтегез кимер. Түзегез! Аллаһ түземлеләр ягында.

*(Кардәшләр, мөселманнар арасындагы ызгыш, талаш, гауга, иске чабата бәясенә дә тормаган мал өчен дошманлашу кебек нәрсәләр гаиләне дә, халыкны да, дәүләтне дә, Исламиятне дә зәгыйфьләндерә. Дошманнарның куәтен арттыра. Андый гаиләләр, андый дәүләтләр, андый мөселман өммәте җиңелергә мәҗбүр була, коллыкта яшәргә дучар ителә. Бу да Аллаһның фани дөньяда шундый гөнаһларыбыз өчен бирелгән газабыдыр.)*

**47.** Күкрәк кагып, *(урынсызга кәпрәеп)*, халыкны Аллаһ юлыннан яздырырга дип, өйләреннән чыкканнар *(кяферләр)* кебек була күрмәгез. Алар кылганнарның барысын да Аллаһ чорнап алды.

*(«Кураеш кяферләре: халык арасында шөһрәтебез артсын дип, сугышка рыя белән тәкәбберләнеп чыктылар».*

Шәех Ногмани тәфсиреннән.)

*(Мөшрикләрнең кәрваны куркынычсыз урынга килеп җиткәч, Әбү Суфьянның илчесе килеп: барыгыз, кәрваныгыз сау-сәламәт килеп иреште, диде. Әбү Җаһил әйтте: Бәдергә барып, анда шәрабларыбызны эчмичә, җарияләр каршыбызда саз чиертеп, бәетләр җырламыйча торып, янызыбыздагы гарәпләрне (кыйнау белән) туендырмыйча, мотлак, бармабыз, диде. Ләкин алар җиңү шәрабы урынына тустаганнардан үлем әчесен эчтеләр. Вә аларга җиңү бәетләре урынына матәм һәм зар елаган хатыннарның фөрьядлары (егълаулары) булды».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**48.** Шайтан алар кылганнарны *(масайганнарын)* яхшы эш итеп күрсәтте.

—Бүген сезне җиңә ала торган һичбер куәт юк, мин сезгә ярдәм итәрмен,—диде.

Ләкин ике гаскәр кара-каршы килеп баскач, ул артына әйләнеп карамыйча, качып китте.

—Мин сездән ерак, мин сез күрмәгәннәрне *(фәрештәләрне)* күрәмен, мин Аллаһтан куркамын, Аллаһның газабы бик тә хәтәр,—диде.

**49.** Монафикълар белән күңелләрендә *(хөсетлек)* чире булган кешеләр *(чын мөселманнарга карап)* әйтте:

—Боларны диннәре алдады,—диделәр.

Хәлбуки, кем Аллаһка сыена, белеп торсын, Аллаһ—мотлак җиңүчедер, хикмәт ияседер.

*(«Күңелләрендә чир булганнар»ның мәгънәсе будыр ки. Кураештагыларның бер өлеше Исламны кабул итеп тә, мөселманлыкларын ныгытмадылар. Кураеш Бәдер сугышына чыкканда болар теләр-теләмәс кенә, ирексездән генә сугышка китте. Алар мөселманнарның азлыгын күреп, куркуга төштеләр. Мөселманнар, һичшиксез, җиңеләчәк, дип хоткы тараттылар. Чыннан да, ул чакта мөселманнарның саны өч йөз унөч булып, кяферләр бер мең сугышчы иде. Ләкин Аллаһ ярдәме илә мөселманнар җиңү казанды».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**50.** Фәрештәләр:

—Мәгез, татыгыз җәһәннәм газапларын,—дип, аларның чырайларына, аркаларына китереп органда, кяферләрнең җаннарын алганда карап торсаң икән! **(51)** Менә бу *(җәза)* кылган золымыгыз өчен. Аллаһ *(гөнаһсыз)* колларына җәза бирүче түгел. **(52)** Аларның гамәле тач фиргавен токымыныкы кебек вә алардан элек яшәгәннәрнеке шикелледер. Алар да Аллаһның аятьләрен инкарь иткәннәр иде. Шул гөнаһлары аркасында аларны Аллаһның газабы тоты. Аллаһ көчледер. Аның җәзасы хәтәр. **(53)** Ни өчен Аллаһ шулай гамәл кылды? Чөнки Аллаһ бер кавемгә биргән нигъмәтен *(карарын)* үзгәртми, үзләре үзгәрмәсә генә инде. Хакыйкатән, Аллаһ ишетеп-белеп

торучы. **(54)** Аларның гамәле нәкъ фиргавен токымыныкы кебек вә алардан элек яшәгәннәрнеке шикелледер. Алар Раббының аятьләрен ялганга чыгарырга маташтылар. Без дә аларны гөнаһлары аркасында һәлак иткән идек вә Фиргавен нәселен *(диңгезгә)* батырдык. Аларның барчасы да залим иде.

**55.** Жир йөзендә яши торган жанлыларның Аллаһ каршысында ин яманы—кяферләр. Чөнки алар имансыз.

*(Күп тәфсирләрдә «җанлылар» сүзе урынына «хайваннар» сүзен кулланганнар. Без Садретдин Гүмүш тәрҗемәсен алдык.)*

**56.** Алар үзләре белән килешү төзегәннән соң, Аллаһтан тартынмыйча, һәрвакыт ант боза торган халык. **(57)** Шуңа күрә, әгәр сугышта аларны жинсәң, аларга шундый жәза бир, *(ант бозганнары өчен алар артындагыларга)* башкаларга да сабак булсын.

**(58)** Әгәр берәр халык *(ант бозып)* хыянәт итәр дип, шикләнсәң, дөреслек вә гаделлек белән алдан кисәтеп, арагыздагы килешүне *(антны)* боз. Аллаһ хаиннәрне сөйми. **(59)** Имансызлар: без жиңдек, дип куанмасыннар. *(Мөселманнарны)* жинә алмаслар.

*(**Ш. Ногманида:** кяферләр, Рәсүлдән алда чыкты, дип хисаб итмәсеннәр! Тәхкыйк, алар Аллаһ Тәгаләне гаҗиз кыла алмаслар, диелгән.*

***В. Пороховада:** и пусть неверные не думают, что взяли верх,—им не ослабить (верных).*

***Х. Чантайда:** ул көфер итүчеләр, котылдык вә гаҗиз калдырачакбыз, дип фараз итмәсеннәр.*

***И. Крачковскийда:** и пусть не думают те, которые не уверовали, что они опередили; они ведь не ослабят.)*

**60.** Аларга каршы, көчегездән килгәнчә, куәт туплагыз, Жиһад өчен яхшы атлар хәзерләгез, шулай итеп, Аллаһның дошманнарын, үзегезнең дошманнарыгызны вә үзегез белмәгән, әмма Аллаһка мәгълүм дошманнарыгызны куркытыгыз. Аллаһ юлында сарыф иткәннәрегез кимчелексез үзегезгә кайтыр, сез гаделсезлеккә дучар булмассыз.

**61.** Алар солых теләсә, син дә риза бул вә Аллаһка тәвәккәл ит. Ул ишетеп-белеп тора. **(62)** Әгәр алар сиңа хәйлә кора башласа, Аллаһның яклавы сиңа житәр. Ул сине мөэминнәр аша килгән ярдәме белән саклар. **(63)** Ул аларның күңелләрен берләштерде. Син Жир йөзендәге бөтен нәрсәне сарыф итеп бетергән булсаң да, аларны берләштерә алмаган булыр идең. Аллаһ аларның арасын татулаштырып, берләштерде. Ул—мотлак жиңүче, хикмәт иясе.

*(«Мәдинәле Әвес белән Хазрәҗ кабиләләре арасында бетмәс-төкәнмәс дәһшәтле бер дошманлык бар иде. Араларында канлы сугышлар булып, һәр тарафның алдынгыларыннан байтагы үлде. Озак заманнар бер-берләреннән кан үче алу белән мәшгуль булдылар. Аллаһ аларны Ислам белән шәрәфләндереп, үч алу максатын юкка чыгарды, алар берләшеп, дуслаштылар».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**64.** Ий, Пәйгамбәр, *(ярдәмче буларак)* сиңа ияргәннәргә бер Аллаһ житәр. **(65)** Ий, Пәйгамбәр, мөэминнәрне *(азатлык өчен)* сугышка өндә, әгәр сезнең арада сабыр-чыдам холыклы егерме кеше булса, ике йөз *(имансызны)* жиңәчәксез. Әгәр сез йөз кеше булсагыз, мең дошманны жиңә алырсыз. Чөнки алар—бернәрсә дә аңлаумаучы өер. **(66)** Инде Аллаһ йөгегезне жиңеләйтте. Сезнең зәгыйфьләнгәнегезне белде. Шулай да, арагызда чыдам-нык йөз кеше булса, ике йөз дошманны жиңәр. Сез мең кеше булсагыз, Аллаһ ярдәме белән, ике мең дошманны жиңәрсез. Аллаһ чыдамнар янында.

*(«Элек заманнарда мөселманнарның саны бик аз иде. Бер кеше ун кешегә каршы сугышырга мәҗбүр иде. Саннарын арттырып, Аллаһ Тәгалә мөселманнарның йөген җиңеләйтте. Бер мөселманның ике кяфергә каршы сугышуы әмер ителде. Бәдер сугышында мөселманнар җитмеш кяферне әсир алды. Рәсүлулла (с.г.с.) бу әсирләрнең язмышын хәл итү хакында аркадашлары белән киңәшләште.*

*Хәзрәти Әбү Бәкер Ситдыйк: йолым бәрабәренә, ирекка җибәрергә кирәк, диде. Сагд бине Муагаз исә: үтерергә кирәк, диде. Әсхабе Кирам (Пәйгамбәрнең якыннары) беренче тәкъдимне якладылар. Нәтиҗәдә, йолым түләтү бәрабәренә әсирләрне ирекка чыгарырга кирәк, диелде. Шул мәсьәлә турында түбәндәге аять иңдерелде».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**67.** Җир йөзендәге барлык дошманнарын җиңгәнчегә кадәр, һичбер пәйгамбәр *(кяферләрне)* әсир алырга тиеш түгел. *(Әсирләрне түләү хакына азат итеп)* сез дөнья малы казанмак буламсыз? Гәрчә, Аллаһ Ахирәтне тели. Аллаһ—көчледер, хикмәтләр ияседер. **(68)** Аллаһ тарафыннан баштук әмер килгән булмаса, алган йолымнарыгыз аркасында, сез хәтәр җәзага тартылган булыр идегез. **(69)** Хәзер инде кулыгызга төшкән ганимәттән хәләл вә пакь булганнарын ашагыз. Аллаһның җәзасыннан куркыгыз. Шик юк ки, Аллаһ ярлыкаучы һәм мәрхәмәт итүче. **(70)** Ий, Пәйгамбәр, кулыгызга төшкән әсирләргә әйт:

—Әгәр Аллаһ күңелләрегездә яхшы ният булса, сездән алынган *(йолым)*нан да хәерлесен сезгә бирер вә сезне ярлыкар,—диген. Аллаһ ярлыкаучы, кичерүче. **(71)** Әгәр сиңа хыянәт итәселәрен алдан белсәң *(аптырама)*, моннан алда да Аллаһка хыянәт иттеләр. Аллаһ аларга каршы сугышыр өчен сиңа мөмкинлек вә кодрәт бирде. Аллаһ—белеп торучы, хикмәтләр ияседер.


**72.** Иман китереп, һиҗрәт иткәннәр *(ватаннарын, йортын-җирен, малларын ташлап киткәннәр)*, Аллаһ юлында игелекле гамәл кылган, җаннары *(маллары)* белән Җиһадта катнашкан мөһаҗирләрне сыендырып, аларга ярдәм иткәннәр бер-берсе белән *(мирас бүлешерлек дәрәҗәдә)* якын булырлар. Иман китереп тә, һиҗрәт итмәгәннәр исә, һиҗрәт иткәннәренә чаклы *(мирас бүлешерлек)* якын була алмый. Алар өчен җавап тотылмый. Әгәр дә алар *(көченмәгән мөселманнар)* дин өчен *(кяферләргә каршы сугышта)* ярдәм сорасалар, аларга ярдәм итү сезнең бурычыгыз. Ләкин сезнең белән солых төзегән *(кяфер)* халыкка каршы сез гаскәр бирмисез. Аллаһ сезнең ни кылачагыгызны алдан ук күреп тора.

**73.** Кяферләр үзара ярдәмләшеп, бер-берсе белән тату яши. Әгәр сез дә шулай *(тату)* булмасагыз, Җир йөзендә фетнә *(иман зәгыйфьлеге, көферлек)* вә *(дин мәйданында)* чуалышлар, азгынлыклар булачак.

**74.** Иман китереп тә, Аллаһ юлында һиҗрәт вә Җиһад итүчеләр, үз яннарына сыендырып, аларга ярдәм итүчеләр—менә чын мөэминнәр шулар була инде. Ярлыкауны да, бетмәс-төкәнмәс ризык алучылар да шулар булыр.

**75.** Иман китереп, соңыннан һиҗрәт итеп, сезнең белән бергә Җиһадта катнашканнарның барысы да сезнең кавем булыр *(ягъни, сез бер-берегезнең малына варис була аласыз)*. Аллаһның Китабына күрә, якын туганнар бигрәк тә бер-берсенә мирасчы *(варис)* була. Аллаһ барысын да тәгәл белеп тора.

*(Бу аять иңгәнгә кадәр мираска варислык бары тик кан кардәшләр арасында гына иде).*



Гыйлем
Фән

# "ИДЕГӘЙ" ДАСТАНЫНДА ИЛ ТОТУ ҺӘМ ТӘРБИЯ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

## Ил һәм гаилә

Мәгълүм ки, Алтын Урда цивилизациясе катлаулы үсеш юлы үткән, Евразия киңлекләрендә яшәүче халыклар тормышына зур үзгәрешләр керткән көчле бергәлек булган. "Идегәй" дастанында бу бөек цивилизациянең дөньяны күзаллауга бәйле бик күп үзенчәлекле карашлары шигъри юлларга үрелеп бирелгәнен без инде тикшереп узган идек (*"Казан утлары", 1999, №2)*. Чыңгыз хан Ясасы ил белән идарә итүдә, гаилә мөнәсәбәтләрендә төп таяныч канун булган. Ясада Чыңгыз ханның гаилә тотуга һәм бала тәрбиясенә бәйле шәхси карашлары чагылыш тапкан булуы әһәмиятле. Яса шул карашларны канунлаштырган. Бөек хан үз гаиләсендә тәртип урнаштырып, тәрбияле балалар үстерүгә ирешә алган шәхес кенә ил белән идарә итәргә хокуклы дип санаган. Яса нигезендә идарә ителгән Алтын Урда дәүләтендә гаилә коруда, аны тотуда һәм бала тәрбияләүдә әзлекле гореф-гадәт, тәртип яшәп, буыннан-буынга тапшырылып килгән.

Дәүләт җимерелү нәтиҗәсендә, әлеге карашларны үсештә яшәтеп килгән идарә итү тәртибе юкка чыккан. Шуңа күрә аларның күбесе дастаннарда, мәкаль-әйтемнәрдә, тел хәзинәсендә генә сакланып калган. Ләкин җентекләп тикшергәндә, "Идегәй" дастаны югалган карашларның энциклопедиясе булып хезмәт итә ала. Дастанны өйрәнү барышында кат-кат бер үк фикергә киләсең: биредә һәр сүзнең тирән эчке мәгънәсе, кинаясе бар. Сүзнең беренче йөрәк тибешенә, бәреп чыккан авазлар яңгырашына тоташтыра кебек безне дастан юллары.

Инде килеп, безне кызыксындырган "ил" һәм "гаилә" мәгънәсенең дастанда биләгән урынын карап китик. "Ил" сүзе әсәрдә күп тапкырлар кабатлана. Чөнки дастанда төп бәхәс—илне тота белү, аны саклау, илгә лаеклы үрнәк-өлге булу турында бара. Без илне бүгенге көндә күбрәк ватан, дәүләт буларак аңлыйбыз. Дастанда исә, "ил" әлеге мәгънәдән тыш һәркемгә зарур уртак эш өчен җыелу, гадел һәм уртак гамәлләр өчен берләшү, уртак иминлек урнашкан урын мәгънәсендә дә кулланыла. Пир Галәттин гаскәр белән килгән Идегәйне, кайчандыр үз шәкертен, Туктамыш хан ягына кучәргә өнди. Пир : "Илләштермәк— илчедән",—дип, бу киңәшенең хаклы, ихлас, артында мәкер ятмаганына шәкертен ышандырырга тырыша. Идегәй Галәттиннең сүзләрен кабул итә алмый. Туктамыш хан Идегәйнең атасын үтерткән. Үлем хөкеменнән аның үзен Җантимер генә коткарып калган. Идегәй туган туфрагыннан аерылып, газиз улыннан аерылып читтә гомер сөрергә мәҗбүр. Ул гына да җитмәгән, мәкерле хан күз нуры Норадынын ялгызы чүлдә үлемгә чыгарып җибәрүне оештырган. Җәбернең артык зур булуын, боларның барысын да өлкән пирнең белгәнлеген исенә төшереп:

> Илләштермәк илчедән...—
> Илләшер көн булганда,
> Пирем, анда кайда иден?—

дип илләшү, илгә берегүнең төп шарты үтәлмәгәнне рәнҗеп остазына белгертә. Әйе, әгәр хәлиткеч тәвәккәллек, кыюлык сораган авыр чакларда Галәттин аңа ярдәм кулын сузган булса, Идегәй тәкъдимне, һичшиксез, кабул итәр иде. Хәзер соң инде. Вакытында пир Туктамышның гаделсезлекләрен сүзсез,

каршылыксыз үткәреп җибәрә. Нәкъ шуңа күрә остазы белән илләшеп, аның киңәшенә ияреп уй-ниятен үзгәртә алмый Идегәй. Илләшү—дастанда хакыйкать эзләүгә, аны табуга тиң кабул ителсә, "ил атасы", "ил бие", "ил" булу—ир-егет өчен иң зур дәрәҗә һәм танылу икәнлеге исбатлана. Исемең "ил" белән янәшә куелсын өчен ил сүзен тотарга, ил-халык белән бергә булырга кирәклеге дастанда даими яңгырап, кабатланып тора.

Идел йорт ике булганда,
Ил берекми торганда,
Идегәй белән Норадын
Ике яры булганда,
Ир Норадын ил-йорттан
Үз атасын куганда,—

гаилә эчендәге ызгышның илне таркатуга китереп җиткерүче сәбәпләрнең иң зурысы, тәэсирлесе икәнлеген дастан тыңлаучысына аңлата һәм катгый рәвештә искәртә.

"Гаилә" сүзен җентекләп тикшергәндә, "гаилә"нең турыдан-туры "ил"гә бәйләнгәнен күрү, аңлау катлаулы түгел. Чынлап та, башта килгән "га" иҗеге "ил"не барлыкка китерә, саклый, азаккы "ә" авазы өстәлү "ил"не җәелдереп, киңәйтеп җибәрә. "Гаиләтүн"—гарәпчәдән тәрҗемә иткәндә, "кече җәмгыять" дигәнне аңлата. Гаилә, ир белән хатын төзегән кече җәмгыять—илнең нигезен, умырткасын тәшкил итәләр. Дастанда ил тамырына бәйле сүзләр : "гаилә", "Идел" -"әти иле", "илләштерү", "илсенү", "илче", "дәүләт"—"дәү ил". Бу сүзләрнең барысы да илдән үсеп чыга, илгә тоташа, аңа таяна, илнең үсүен, ныгуын, яшәвен белгертеп, аңлатып тора. "Ил", "гаилә", "дәүләт", "илче", "Идел", "илләштерү" сүзләренең уртак тамырлары булуы бу сүзләрнең уртак багланыш-омтылышлар, уртак гамәлләр тәэсирендә һәм нәтиҗәсендә барлыкка килгәнлеге турында белгертә.

Әсәрдә сөйләнгән ата-бабаларыбыз тормышы белән безнең бүгенге тормышны чагыштырганда бер зур аерма күзгә ташлана: ил тоту алар яшәешен күпкә мәгънәле, максатлы һәм эчтәлекле иткән. Бигрәк тә ирләр тормышын. (Чынлап та, үз әниемнен) кайчакларда: "Дөнья көтәрдәй ирләр бетте",—дип зарлануының төп сәбәбен соңынан аңладым.) Ил-терәк булырдай, хатын-кызны, балаларны, ярдәмгә мохтаҗ ятимнәрне, гарип-горабаны тормыш авырлыгыннан саклардай дәүләт ирләрен Рәсәйнең рәхимсез сәясәте, аның туктаусыз сугышлары юкка чыгаруына уфтанып әйткән икән инәки бу ачы хакыйкать сүзләрен. Гаилә илнең нигезен тәшкил итә дип без әле дә еш әйткәләштергәлибез. Әмма безнең хәзерге кулланышыбызда бу сүз-тезмә үзенең борынгы киңлеген, тирәнлеген, элеккедән килгән эчке мәгънәсен тулысынча диярлек җуеп бетергән. Бүген гаилә авыр хәлдә, хәтсезе җимерелә. Әти-әниләре исән балалар да шактый еш ятимнәр йортларында, чит-ят кешеләр карамагында гаилә җылысы күрми интегеп үсәләр. Авылда ил тотуның югалуына, бастырылуга ияреп килгән эчкечелек, шәһәрдә эчкечелеккә өстәп, тарихи тамырларның корып юкка чыгуы тоташтан диярлек гаиләнең нигезен какшаткан. Хәзер яшьләр арасында хәтта гаиләдән баш тартып, вакытлыча гына никахсыз яшәп карау һәм баласызлык алга сөрелә.

Алтын Урда чорына кайтыйк. Илне тотучы ирләр һәр очракта гаиләдә үсеп ныгыганнар, рухи җегәр туплаганнар, тәрбия алганнар. Буыннар бәйләнеше гаиләдә барлыкка килгән һәм гаилә шартларында сакланган. Өлкән буынның тәҗрибәсе, яшь буынның кайнап торган көче, гайрәте гаиләдә бергә үрелгән. Ул чор тәрбиясе берничә сыналган юлны истә тотып башкарылган. Беренчесе, затлы нәселләрне барлау, аларны саклау, шулардан үрнәк алу һәм үрнәкне дәвам иттерү. Икенчесе, балага гаилә шартларында күңел җылысы, наз, ярату хисе, уй көче, уңай үрнәк белән йогынты ясау. Өченчесе, баланың сәләтенә карап һөнәргә, гыйлемгә, эшкә өйрәтү һәм тормышта аңа үз урынын табарга булышу.

## Нәсел саклау. Ил һәм җир

Дөньялыкта кешеләр күп төрле була. Бер-берсенә бөтен яктан да охшаш, нәкъ үзара тәңгәл сыйфатларга ия ике кешене табу мөмкин дә түгелдер. Ләкин нәселнең ниндидер үзенә генә хас үзенчәлекле уртак

сыйфатлары буыннан-буынга күчеп югалмыйча нәсел дәвамында саклана килә. Фәндә мондый уртаклыкны **геннар** теориясенә таянып аңлаталар. Нәселгә хас уртаклыкның саклануына бик борынгыдан игътибар иткәннәр. Хаким катламнар гына түгел, гади халык та баласы гаилә корганда аның нинди нәселгә бәйләнәсен, ул бәйләнешнең киләчәк унай яисә кире нәтиҗәсен, бәйләнеш тудырган яна буынның булачак сыйфатларын алдан ачыкларга һәм гореф-гадәткә таянып мәсьәләне хәл итәргә омтылган. "Нәселленең сүзе өскә чыгар", "Атасына карап улын коч, анасына карап кызын коч", "Оясында ни булса, очканында шул булыр", "Алма агачыннан ерак төшми" һәм башка шуның кебек тирән мәгънәле, тормыш тәҗрибәсеннән туган мәкальләр нәсел тәэсирен сынамыш рәвешендә һәркемнең күнеленә салып куярга мөмкинлек биргән. Нәселнең яхшы сыйфатларын саклау, аны киләчәк буынга тапшырылырга тиешле иң зур, иң ышанычлы байлык дип карау, ата-бабаңның кем икәнен белү, шуның өчен нәсел агачына язып, теркәп кую халкыбызда күркәм бер гадәт булган. Телебездә туганнар авызыннан әйтелгән иң каты яманлау сүзе булып "нәселсез бәндә", "нәсел корыткыч", "нәсел череткеч" икәнен дә искәртеп китәргә кирәктер.

Дастанда нәсел саклауга, нәселне дәвам иттерүгә мөнәсәбәт шул чор җәмгыятендә яшәп килгән карашка, кабул ителгән тәртипкә таянып сурәтләнгән. Ул чорның дәүләт төзелешен үсеп утырган агач белән чагыштырырга була. Хан - агачның төбе һәм төп буе, биләре, бәкләре—юан ботаклары, ул ботаклардан тагын нечкәрәк ботаклар—морзалар үсеп чыга; халык исә—агачның яфраклары. Тамырлар монда—нәсел җепләре, шәҗәрә. Агачның бөтен күзәнәкләре ата-бабадан килгән гореф-гадәт, тәңречелек, Яса кануннары белән сугарылып, шулардан яшәргә көч ала.

Алтын Урдада гаскәр тоту, салым җыю, акча сугу, юл йөрү, хәбәрләшү, халык санын исәпкә алу кебек көчле дәүләткә хас мөһим эшләр төгәл үтәлешле итеп җайга салынган булуын хәтерлибез булыр.

—Алты айлык йортымны
Бер каләмнән үткәргән
Диван бием Байназар,—

дип дәшә үзенең бер яранына Туктамыш хан. "Бер каләмнән үткәрү"нең халыкны теркәү икәнлеге аңлашыла. Теркәү вакытында һәр кешенең кем нәселеннән булуы, нинди һөнәре барлыгы, көче-җегәре ачыкланган. Кешенең сәләтенә, көченә соклану, камил кешене үрнәк итеп алу ул заман өчен бер дә ят күренеш булмаган. Туктамыш ханның Идегәйне беренче тапкыр очратканнан соңгы халәтен искә төшерик. Олы хан егетнең үз-үзен тотышын, кыюлыгын, тапкырлыгын, җегәрлеген күреп шундый әсәрләнә, өч көн, өч төн шул халәтеннән чыга алмый. Идегәйнең Урман бигә чыгарган кырыс хөкеме Туктамыш ханның аңа ышанычын тагын да арттыра. һәм олы хан Кобыгыл исемендә йөргән Идегәйне үзенә хезмәткә алырга дигән фикергә килә, аны гаскәр башлыгы итеп билгели.

Хан хакимлегендә булган дәүләт агачы һәм нәсел бәйләнешләренең хәрәкәткә килүе Идегәйнең кемлеген ачыклаганда яхшы күренә. Туктамыш хан, гадәт буенча, мәгълүмат алырга теләгән һәр батырга исеменә өстәп кем баласы, нинди нәселдән булуы, нинди эшләр башкарганын тулысынча атап дәшә: "инсәнә суксам—инкәймәс, искемне бирсәм—иләмәс Исәнтәй улы Ходайбирде батырым", "эчсә канга туймаган, илгә аз да яуга күп Акбалтыр улы Уагым белән Монҗыр улы Чуагым", "карангыда юл тапкан, хәфия җирдә сүз тапкан... Туктар улы Тугача".

Хан дәүләт житәкчесе буларак, вазифасын истә тотып, югары катламны барлап торса, ил ирләре илнең иминлеген, көчен саклар өчен, авыр чакта бер-берсенә ярдәм итү йөзеннән үзара ант эчкәннәр. Идегәйнең исән калуы да антка бәйләнгән икәнен тагын бер кат искә төшерик. Дастан каһарманы Җантимер заманында Идегәйнең әтисе белән ант эчкән була. Җантимер антына тугрылык саклап, газиз баласын корбан итә һәм антташы Котлыкыяның улын коткара. Ни өчен алай эшли ул? Әгәр Җантимер белгән килеш Идегәйне корбан иттерсә, ул бары тик үз гаиләсенең, үз нәселенең иминлеген генә саклап калыр иде. Алтын Урда дәүләте күләмендә иң затлы аксөяк токымын саклап калу ил өчен, дәүләтнең иминлеге, аның көчле булуы өчен кирәк. Үз мәнфәгате белән дәүләт мәнфәгате капма-каршы очрашканда ил бие Җантимер үз мәнфәгатен һич өстен куя алмый. Ул бу шартларда үз баласын корбан итүгә бара. Безнең бабаларыбыз тормышында әйткән сүзне, бигрәк тә антны тота

белү—кешенең шәхеслек дәрәҗәсен билгеләүче, аның кемлеген күрсәтеп торучы асыл сыйфат дип кабул ителгән булган.

Шулай итеп, җәмгыятьтә ике төрле бик тыгыз туплану, якынаю юлы барлыкка килгән: туганлык, нәсел җепләре буенча һәм ант аша. Ул чорда ил белән идарә итүдә нәселгә таяну, нәсел хокукы канун рәвешендә кабул ителгән булган. Хан тәхетенә фәкать Чыңгыз нәселеннән булганнар гына утырган. Автор Идегәйне чыңгызлардан бик күп өстен сыйфатларга ия итеп күрсәтә. Хәтта "Ир Идегәй органда аннан (ир Чыңгыздан) өстен орышы" дип әйтелә. Өстенлеген Идегәй үзе дә белә. Әтисенең өстенлеген Нурадын да күрә. Көче, акылы, җегәре, халык өчен кылганнары ни зур булмасын, Идегәйнең тәхеткә турыдан-туры дәгъва кылмавы ата белән ул арасында кискен каршылык китереп чыгара. Норадын тәхеткә бары тик Чыңгыз нәселе генә лаек дигән караш белән килешми. Нәсел хокукына караганда табигый сәләт, җыйган белем һәм затлы тәрбия күчмәлек чоры хорафатыннан өстенрәк дип бара ул. Бу турыда Норадын әтисе белән дә, башка югары катлам кешеләре белән дә бәхәсләшеп, үз фикерен кат-кат дәлилләп тора. Чыннан да, тәхеткә Чыңгыз нәселеннән булмаган, ил уен тоеп, ил-халык турында тирән кайгыртып, илне илләштерергә сәләтле кешене утырту, бәлки таралып барган дәүләтне саклап калуга, торгызуга китерер иде? Әмма мондый борылышка—гасырлар буе яшәп килгән кануннан тайпылырга мөмкинлек бирелми. Алтын Урданың таралып, таркалып баруын тәхет өчен ызгышлар көчәйтеп һәм тизләтеп җибәрәләр. Иң өске катламга үзгәреш кертерлек көч җәмгыятьтә оеша алмый кала.

Кардәшлек җепләре, антташлык хисләре белән тыгыз бәйләнеп оешкан халык ИЛ төзегәндә шушы хәрәкәткә яшәгән җир үзе дә кушылып киткән. Туган җир, аның табигате төсмерләре безнең ата-бабаларыбыз өчен кардәш, антташ кебек үк якын, кадерле, газиз булган. Шунадыр "җир" һәм "ир" дастанда рәттән, янәшә куеп сурәтләнә. Җантимер гаиләсендә алпамыштай ир булып өлгергән Идегәй үзен тәрбияләгән ата-анасына рәхмәтен белдереп "Ир булган соң җир булыйм",—ди. Норадын Алтын Урдадан куылып, чүл газаплары кичеп әтисе янына исән-имин килеп җиткәч, аны түбәндәгечә сәламли:

Идел белән Җаектан,
Сарай белән Болгардан,
Норадын кара комыннан,
Уел белән Кыелдан,
Каргалы, Эләк буеннан,
Татарның тулы йортыннан
Сина килдем, атаем!

Шәһәрләре, елгалары гына түгел, Норадын сәлам алып килгән тауда йөргән китмән койрык куйлары, симез өркәчле дөяләре —болары да туган җирнең күнелне сулкылдатып ала торган төсмерләре, атасы өчен бик кадерле, аның гомерлек истәлек-юлдашлары бит. Яшьлегендә тауда ятып куй баккан Идегәй Норадынның сүзләрен-нән тәмам җирсеп, улының илен күргән күзләрен үбеп тетрәнә. Дастан юлларында китерелгән күренештә бернинди дә арттыру, йә булмаса купшы ясалмалылык юк. Безнең халыкка хас табигый, күнелне сагышлы да, моңлы да итә торган бер хис инде ул илне-җирне сагыну. Шунадыр яна тормыш башлап киткән җирләрдә авыл булсын, елга булсын калдырып киткән туган җирне искә төшерә алырлык, аңа аваздаш исемнәр кую даими бер гадәт булган. Кырым-Сарай, Уел, Чаллы, Минзәлә, Болгар—болар бит авыл исемнәре дә, ерак бабаларыбызның туган җиренә бәйләнешле истәлек тә. Үзебезнең авылыбызга кагылышлы атамалар: "Балтач урамы", "Казан кешесе урамы", "Аккош күле", "Ур урамы"—исемнәре белән сагыну-хатирә кебек моңлы яңгырыйлар. Безнең авылдан ерак түгел Ык елгасы ага. Ык елгасы бездә генә түгел элекке Алтын Урда җире булган Көнчыгыш Себердә дә ага икән. "Ык"—мәгънәсе буенча хәрәкәт, агу дигәнне аңлата. "Ык"—фигыльнен вакытын күрсәтү максатында кулланганда, күмәк хәрәкәткә өндәү, йә үткән күмәк хәрәкәтне белдереп кую буларак яңгырый. ЫК— шул ук агу була түгелме соң? Хәтта бу сүзнең яңгыравында да агымсу тавышы ишетелеп киткәндәй тоела.

И газизем, и атам,
Каерылып атны тартаек (тартайЫК),
Ана Иделгә кайтаек (кайтайЫК),
Идел багында ятаек (ятайЫК).
...
Угыбызны анда атаек (атайЫК),
Ата-ата ятаек (ятайЫК)!

Нәсел-нәсәбәне, туган-тумачаны җыеп берләштерүнең, аларны бер-беренә якынайтуның үзенең буыннан-буынга тотылып, сакланып, тапшырылып килгән гореф-гадәткә әйләнгән тәртибе булган. Дастанда бала туугa, төрле тантаналарга багышлап үткәрелгән зур туйлар турында сөйләнә. Бала туу—нәсел агачының үсенте җибәреп ныгыганын, зурайганын күрсәтеп тора. Бу—бик әһәмиятле вакыйга. Зур туйлар белән билгеләнә торган вакыйга. Хәтердә гомергә сакланырлык сый-хөрмәтләр, бүләкләр тарату белән үткәрелә торган мәҗлес. Мондый туйларны югары катламга кергән кешеләр үзара ярышып, берсеннән-берсе уздырырга омтылып, бай һәм мул итеп кора белгәннәр. Норадын тугач бәхетле ата бу хөрмәткә хан туеннан да олы итеп туй оештыра:

Барын-югын җыйдырды,
Ялгызыма алкыш тисен дип
Өлкән бер туй кылдырды ,—

диелә дастанда.

Ул чорларда туйларны, мәҗлесләрне, бергә сөйләшеп утыруларны четерекле сорауларга җавап эзләгәндә яисә кемне дә булса сынап белергә кирәк булганда, йә булмаса хан тирәсендә туплану максатыннан чыгып та даими җыйганнар. Идегәйнең кемлеген туйда ачыклаганнарын искә төшерик. Сүз уңаеннан шуны әйтергә кирәк, хәлиткеч мөһим хәлләр турында табын корып, ачылып сөйләшү—җитәкчеләр, эшмәкәрләр өчен бүген дә канун сыман бер гадәт. Гавам каршына чыгып сөйлисе сүзләрдә ышаныч чамалырак. Андый сүзләр күп очракта сәясәт өчен, гади халыкның башына томан, күзенә төтен җибәрү максатыннан гына сөйләнелә. Кабул ителәсе җитди карарлар тар даирәдә, табын янында күзгә-күз карашып хәл ителә. Нәкъ дастандагыча дисәк тә ялгыш булмас: бүгенге көндә дә мәҗлес өчен кирәкле кешесе барлана, табыла, чакырыла. Ашап-эчеп, кәеф-сафа корып утырганда кирәкле җавабы әзерләнә, карары кабул ителә. Шул эшне оештыра белмәгән кеше хәзер дә хакимлеккә ирешә алмый.

## Нәсел башы сайлау. Җыен

Дастанда ир егетнең нәсел башы булып танылуы Идегәйгә кагылышлы сурәтләнгән. Бала чактан ук аның кешеләргә тәэсир итә алу, туплау сәләте барлыгы беленә: "Җантимернең биш угыл—бишенә дә баш булды",—диелә. Инде Идегәй кискен адым ясап, Сәмәрканд әмире Шаһтимергә качып китәргә мәҗбүр булгач, агалары берсүзсез ана килеп кушылалар. Юлда аларга уникe кеше өстәлә һәм юлдашлар саны унҗидегә җитә. Унҗиде — оешу өчен ниндидер тылсымлы мәгънә салынган чик сан ахыры. Һәм бу санга басым ясалып, аерым шигъри юллар багышланган.

Әй унҗиде, унҗиде!
Өчләп салсан, өч булмас,
Кушлап салсан, куш булмас,
Бишкә бүлсәң, бүленмәс;
Ялгызга яндаш булмасам,
Беренә берең иш булмас.

Юл йөрү, элек бигрәк тә, җыенып, көтелмәгән хәлләргә әзер булып чыгып киткәндә дә, мәшәкатьле һәм авыр булган. "Юл газабы—гүр газабы",—дип юкка телгә кермәгән инде ул. Идегәй әзерлексез, кинәт кенә качып чыгып китәргә мәҗбүр була. Юлдашлары да шул ук хәлдә. Шушы кыен вакытта Идегәй иптәшләренең иминлеге өчен җавап тотачагын, аларга терәк булачагын, азакка кадәр алар турында кайгыртачагын белдерә. Үзенең ир булырга өндәгән

сүзләре белән юлдашлары күңелендә авырлыкларны җиңүгә ышаныч уята, аларны җилкендерә, ныграк туплый:

Ирмен дигән ир егет,
Арысланга тиң егет,
Утка салсаң, янмыйдыр,
Суга салсаң, батмыйдыр,
Барган җирне җитмичә,
Юлда үлеп ятмыйдыр.
Ярен әйтмә, борын әйт,
Мин исәндә үлмәссең!
Үлмәссең дә бөлмәссең,
Авырлыклар күрмәссең!

Бу әйткәннәр сүздә генә калмыйча, Идегәйнең кылган гамәлләрендә чагылып тора. Шуңа күрә аның җыен башы, юлбашчы булып танылуы табигый. Ул иң авыр шартларда җаваплылыкны үз өстенә алудан курыкмый. Иптәшләре аның ихлас күңелле, сүзендә торучан, кыю, акыллы, батыр икәнлеген тагын бер кат сыныйлар. Мондый кеше һәр очракта башкаларны үзенә тарта, аның белән утка да, суга да керергә була.

"Бу җыенның эчендә кемнәр бар да кемнәр юк",—дип "җыен" сүзе дастанда беренче тапкыр Туктамыш хан авызыннан яңгырый. Беренчелектә яшерен эчке мәгънә бар. Хан җыены—ул иң югары, рәсми җыен. Шул ук вакытта хан бу сүзләрне илдәге барлык җыеннар турында кайгыртучы, алар өчен өлге булган хаким буларак та әйтә. Җыеннарны оештыру, үткәрү тәртибе, җыен башы сайлау дәүләт агачы төзелешен кабатлаган. Хан җыены, морзалар җыены, халык җыены—һәммәсенең дәүләт кәүсәсендә тоткан урыны, үз хокуклары булган. Туктамыш ханның үз җыенын ничек оста файдаланганы Идегәйнең кем икәнен ачуда һәм Нурадынны чүлдә үлемгә чыгарып җибәрү күренешләрендә җентекләп сурәтләнгән.

Аксак Тимер янына качкан кешенең малае буларак, Нурадынны ни эшләтергә дигән сорау белән хан мәкерле гамәлләр остасы Җанбайны үз катына чакырта. Туктамыш хан Җанбай белән бөтен шик-шөбһәсен белгертеп, ачыктан-ачык сөйләшә. Ул Идегәйнең дә, Нурадынның да үзеннән көчле булуларын таный. Атасы ерак, Нурадын янда гына, аны астыртын үтертсә, Тәңре хөкеменнән куркуын әйтә. Бөек Тәңре ятимнәрне, гарип-горәбәне, толларны, ярдәмчесез карт-корыны үз канаты астына ала һәм ул бичараларның рәнҗеше җавапсыз калмый бит. Шундый зур дәүләтне җыю һәм түрәлек итү Тәңре ярдәменнән, аның кодрәтеннән, ризалыгыннан башка мөмкин түгел. Иксез-чиксез җирләр, сансыз коллар хуҗасы Туктамыш хан үз хакимлегенең илаһи көч белән чикләнгәнлеген белә. Шуңа ул Җанбайның киңәшен тотып, Нурадынны әтисе янына чыгарып җибәрергә карар кабул итә. Бу эшне дә хан ялгызы гына башкармый, ә үнике бидән торган җыенын җыеп, ятим балага кем нинди юл кирәге бирәсен билгели. Кем—кием, кем—корал, кем—ат китерергә тиеш була. Уйласаң, мал-мөлкәт ханның үзендә дә җитәрлек. Өстәвенә ул яраннарына : "начарын бирегез",—дип кисәтми, киресенчә, "качса котылып китәрдәй ат бирегез",—ди. Һәм менә хан җыены Нурадынга юл хәстәре тапшыру тамашасына җыела. Китергәннәре—ертык тун, сапсыз чукмар, киндер аел, бау камчы, иң мәсхәрәлесе—"кабактай эче өрелгән, таяктай муены сузылган" ат. Шулай итеп җыен үзенең хан мәкере белән теләктәш икәнлеген, аны сүзсез аңлавын һәм сүзсез буйсынуын исбатлый. Әлеге манзарада җыен үзенең асыл мәгънәсеннән—нәселне саклаучы, илләштерүче, ярдәм кулы сузучы булуыннан ваз кичеп, мыскыллаучы, эзәрлекләүче, таркатучы рәвешенә кергәнлеген күрсәтә. Илнең ни сәбәптән таралганын аңлар өчен бу юллар үтә әһәмиятле.

## Җыеннарның халыкны оештыруда тоткан урыны

Халкыбыз тормышының күп ягы тирәнтен өйрәнелмәгән. Моңа кадәр уй-фикернең артык бастырылган булуы үткәннәргә дөрес бәя бирергә комачаулаcа, бүген без фикердә булса да үзебезнең иркле икәнлегебезне тоя, аңлый алмыйбыз кебек. "Җыен" сүзенә кабат әйләнеп кайтыйк. Телдә

тормыштагы теге яки бу күренешне (ни-нәрсәне) аңлаткан, шуны атаган сүз табу—чын-чынлап зур вакыйга. Сүз булу, беренчедән, бу күренешнең кабатланып торуын, гадәти чынбарлык икәнлеген күрсәтсә, икенчедән күренешкә уйда-фикердә безнеңчә мәгънә салынганын, безнең дөньяны аңлау-күзаллауларда үз карашыбыз барлыгын белгертә. Ниндидер ясалма "фәннилек"кә һәм сәясәткә таянып үткән мирасыбызның юкка чыкканы шушы бер сүз язмышында ачык күренә. Тикшереп карыйк. Дастанда без ата-бабаларыбызның дәүләт төзегәндә гасырлар буе сыналган кануннарга таянып һәм гореф-гадәттән килгән тәртипне саклап эш иткәннәрен күрдек. Дәүләтнең нигезен гаилә ныклыгы, нәсел-ыруын бердәмлеге һәм халыкның җәмгыять булып оеша алуы барлыкка китергән. Халыкны оештыруда, идарә итү эшен халыкка таянып башкаруда җыеннар хәлиткеч бер чара, чорына күрә шактый камил демократик алым булып торган. Җыен, нәсел-ыру, гаилә илнең һәр кешесен өч катлы канат астына кертеп, адәм баласының иминлеген саклаган, аңа бәла-казадан, гаделсезлекләрдән, дәүләт(хан, түрә) бастыруыннан котылырга мөмкинлек биргән. Идегәйнең Җантимер гаиләсенә сыенып, алпамыштай ир булып өлгерүе—канатларның ышанычлы булуын дәлилли. Мондый мисалларны ерак булмаган тарихыбыздан да табарга була. Әлмәт—Бөгелмә юлы буена урнашкан Тайсуган авылы XV111 гасыр башларыннан ук үзенең мәдрәсәсе белән тирә-якта дан тоткан. Бу авылда берничә буын Байтугановлар мулла булып торган. 1929 елда башланып киткән террор иң беренчеләрдән булып мөселман руханиларын юк итә. Шул террор башланган елны Тайсуган авылы мулласы Байтуганов Мөхәммәттаһирны Себергә сөргенгә озатырга дигән карарга килә. Байтугановның авылдашлары мулланың язмышына битараф калмыйлар. Тайсуганлылар муллага яшертен генә хәбәр биреп торалар һәм Мөхәммәттаһирны кулга алырга бер көн кала кемнеңдер ярдәме белән мулла юкка чыга. Мәрхәмәтле кешеләр бераздан аның гаиләсенә дә Сталин сатрапларыннан котылырга юл ачалар. Бу тарих бик гыйбрәтле. "Идегәй"дә сурәтләнгән бердәмлек, туганлык хисләренең даими яңартылуы гына адәм балаларына авыр чакларда бер-берсенә ярдәм кулы сузарга, тоталитар дәүләт тудырган аяусызлыкны йомшартырга мөмкинлек бирә. Мөхәммәттаһир мулла, дин кешесе буларак, авылдашларын дөрес тәрбияләгән, шуңа күрә Ходай аңа һәм гаиләсенә бәладән исән-имин котылырга иманлы кешеләр җибәргән дип фикер йөртеп нәтиҗә ясарга була. Кеше күңеленә көне-төне дошманлык уты салып торсаң, ул утның ялкыны ут кабызучының үзен дә ялмаячак. Әшәкелек, дошманлык—йогышлы чир кебек. Әфган, Чечен жиреннән "дошманны" тар-мар итеп кайткан бичара җиңүчеләрнең күбесе, "җиңү" ялкынында үзләре янып юкка чыкканнын да шаһитлары бит без бүген.

Халыкны дин ярдәмендә һәм дин белән күп очракта уртак тел тапкан гореф-гадәткә таянып үз-үзен якларга, сакларга өйрәтү—дәүләтнең үзенең иминлеге өчен ук кирәк мөһим эш. Күрәсең, бу хакыйкать артык авырдыр, артык зурдыр, югыйсә Рәсәй патшалары үз халкын юкка чыгарып бетерү өчен шулай тырышмаслар иде. Әллә бу үзара аңлашуны югалту—Алтын Урда чорындагы шикелле таркала башлау тудырган йогышлы бер чирме?

"Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә "җыен" сүзенең өч мәгънәсе бирелгән. Беренче итеп "искергән" тамгасы белән җыен—"нинди дә булса мәсьәләне хәл итү өчен җыйналган җәмәгать җыелышы" дип аңлатыла. Сүзлек 1981 елда чыккан. 1999 елда чыккан "Татар энциклопедик сүзлеге"ндә "җыен—казан татарларының язгы чәчү белән урып-җыю арасында үткәрелә торган календарь бәйрәме" дип бирелә. Әйе, бәйрәм—җыенның шатлык йөзе, кешеләрнең борчуларын читкә куеп очраша, күңел ача, бушана торган урыны. Ләкин җыенның иң әһәмиятле ягы—шул төбәк(авыл) халкының үзара сөйләшү, киңәшләшү, аңлашып килешү максатында оеша алуын тәэмин итүдә. Җир, көтүлек, тормыш-көнкүрештәге тәртип турында соңгы мәгълүматларны алышу, уртак карарга килү өчен җыелган авыл халкы. Җыеннар бәйрәм аша да, киңәшләшү юлы белән дә халыкны берләштергәннәр, бергә туплаганнар, бергәлек хисе уятканнар—бусы бигрәк тә әһәмиятле. Авыл җыенына һәр нәсел аерым бер бәләкәй җыен булып килеп кушылган. Нәсел җыены шул нәселнең иң ихтирамлы, җаваплылыкны үз өстенә ала белгән ир кешенең исеме яки атамасы белән йөртелгән. "Тәкә җыены", "Уба җыены"—безнең Баулы якларында нәсел җыеннарының атама мисаллары. Җыеннарда күңел ачып, бәйрәм ясап кына вакыт үткәрмәгәннәр, ә нәселнең хәлен барлаганнар, кемгә нинди ярдәм кирәклеген дә ачыклаганнар. Ятим

калган, ярлыланып киткән туганнарына булышлык итү мөмкинлекләрен эзләгәннәр. Әнинең әтисе үлеп, әбиебез өч бала белән ятим калгач, әбигә ярдәм йөзеннән әниләрне туганнары килешеп-киңәшеп үзләрендә тота торган булган. "Баштанаяк киендереп, тәрбияләп җибәрәләр иде",—дип сөйли иде инәки. Шулай итеп җыеннар үткәрү гадәте авыл кешеләренә бик борынгыдан килгән дәүләт булып берләшеп яшәү рухын сакларга мөмкинлек биреп торган.

Югарыда телгә алынган ике сүзлек чыккан 1981 һәм 1999 еллар арасында Рәсәй җирлегендә бик зур тышкы үзгәрешләр булды. Иң мөһимнәре—безнең бугазга басып торган, дөньяда бердәнбер хакыйкатькә дәгъва кылган коммунистлар хакимлеге бетерелде һәм империя үзенең чикләрен кечерәйтергә мәҗбүр булды. Бу үзгәрешләр тагын да тирән хурлыклы җимерелү упкынынннан котылу, югары хакимият катламын милек хуҗасы итеп (капиталистик өлгедә) үзгәртеп кору максатыннан чыгып эшләнде. Безнең милләт бу үзгәрешләргә әзер түгел иде. Сәгыйт Рәмиевнең егерменче гасыр башында милләт зыялыларына ташлаган "тамыры ерак ... атадан калган хата" дигән соравымы, бәясеме җавапсыз калды. Хата табылмады. Күп уй-фикерләр "искелек" дигән тамга белән галим-голәмә күзеннән дә яшерелгән булып чыга түгелме?

Авыл җәмгыятен борынгы грекларның гражданнар җәмгыяте—полислар белән чагыштырып булыр иде. Тарихны кыскача гына искә төшереп китик. Безнең эрага кадәр VIII—VII гасырларда Аттика ярымутравында һәм Борынгы Грециянең башка төбәкләрендә зур милек хуҗалары һәм ирекле милексезләр арасында каты көрәш бара. Бу көрәштә милексезләр сан ягыннан күпчелекне тәшкил итә. Шуңа өстәп әйтик, вак милек хуҗалары эре җирбиләүчеләргә әҗәткә кереп күпләп бөләләр. Аларга түли алмаган бурыч бәрабәренә үзләрен сатып колга әйләнүдән башка юл калмый. Ризасызлык көннән-көн ныграк көчәя. Җәмгыятьтә шушы ике катлам арасында барган канлы көрәшне туктату өчен радикаль реформа ясаудан башка чара калмаганлыгын аңлау барлыкка килә. Реформа үткәрүне затлы нәселдән чыккан, гаделлеге белән танылган шагыйрь Солонга тапшыралар. Солон милексез катламның иске бурычларын сызып ташлый, кешене бурыч өчен колга әйләндерүне закон белән тыя, тумыштан бирелгән өстенлекләрне бетерә. Ул Борынгы Греция җәмгыятен милегенә карап дүрт сыйныфка бүлә һәм дәүләт белән идарә итүдә иң зур чыгымнарны иң бай сыйныф җилкәсенә сала. Дүртенче—иң түбән сыйныф гражданнары налоглардан тулысынча азат ителәләр һәм аларны сирәк очракларда гына сугышка алалар. Налог түләү, мобилизацияләнү—югары сыйныф вазыйфасы санала. Солон грек җәмгыятенә тагын бер бик әһәмиятле сәяси-иҗтимагый үзгәреш тә кертә. Солон конституциясе буенча, бөтен сыйныф вәкилләренең дә җыенда катнашу, сүз сөйләү һәм тавыш бирү хокукы тигез таныла. Ярлы катламның һәрвакыт күпчелек тәшкил иткәнен истә тотсак, бу җыеннарда карарлар кем файдасына кабул ителгәнен аңлау кыен түгел. "Халык—сайлауның чын хуҗасы булганда, ул дәүләтнең дә хуҗасы була",—дип әйткән бөек фикер иясе Аристотель . Солон законнары нигезендә, Греция җирлегендә әкренләп демократиягә үсәргә мөмкинлек туа. Ләкин полислар ирекле кешеләрне генә берләштергәннәр. Күпсанлы коллар полиска кермәгән. Коллык—Борынгы Греция цивилизациясен юкка чыгарган сәбәпләрнең иң зурысы.

Әйтелгәнчә, авыл җәмгыятенең оешуы да полисларны хәтерләтә. Милекне тану, җыенга таянып идарә итәргә омтылу—юнәлешләр бер үк. "Җыенда ят кеше булмас"—дигән мәкаль җыеннар үткәрү тәртибенең мәгънәсен ачып бирә. Җыенда катнашкан һәр кешенең ят булмыйча, үз булуы авыл җәмгыятенең нинди идеалга омтылганын күрсәтә. Җыелып сөйләшү, киңәшү юлы белән аерым шәхеснең хокукларын тану кече җәмгыятьтә, тернәкләнеп, үз урынын булдырган. Борынгы Греция—Алтын Урда—авыл җәмгыяте арасындагы охшашлыклар сүзнең җәмгыятьтә тоткан урынын билгеләүдә дә шактый тәңгәл килә. Борынгы греклар да, алтынурдалылар да(соңыннан авыл җәмгыяте) идарә итүдә сүз сөйләп ышандыруга, сүз белән тәэсир итүгә, хак сүзгә зур урын биргәннәр. Ягъни, сүз тәэсирен, аның көчен кануннар нигезендә таныганнар. Алтын Урда һәм ханлыклар җимерелгәч татар кешесе дәүләт яклавын тәмам югалткан. Исән калу һәм берләшү өчен гореф-гадәткә салынган нәсел-ыруга, кече җәмгыятькә (авыл җәмгыятенә, шәһәрдә—мәхәлләләргә) таяну октябрь инкыйлабына кадәр дәвам иткән.

Егерменче гасырның 20—30 елларында җыеннар бетерелә. Ерак чорлардан сакланып килгән Сабан туйлар да халыкның туганлашуын ныгыткан, беркеткән

йола бәйрәме буларак түгел, ә хакимият җыелышыннан соң күнел ачу тамашасы кебегрәк оештырылып, хәзер Республикабызның бөтен авылларында да бер көндә үткәрелә.

## Ил ирләренең балачак тәрбиясе

Бер яшендә бер икән,
Баскан җире шил икән.
Ике яшьтә ил булды.
Әйткән сүзе им булды.

Әлеге юлларны укыгач Идегәйне ирексездән антик чорның иң көчле мифик баһадиры Геракл белән чагыштыра башлыйсың. Грекның мифик герое бишектә чакта үзен чагарга җибәрелгән ике еланны буып үтергән булса, Идегәйнең көченнән җир инеп, селкенеп тора. Һәр ике герой да башка сәләтләре, зирәклекләре белән гавамнан аерылып торалар. Әмма алга таба Идегәй сизелмичә диярлек мифик герой төсмерләреннән арына да, гади бер авыл малаена әверелә. Шуңа аның үсмер чактагы тормышы гадәти авыл малайларыныкын хәтерләтә—ул көтү көтә, атта чаба, ук тарта, төрле уеннарда катнашып баш оештыручы була. Шул уеннарда Котлыкыя улы үзенең үсмерләр арасында барсыннан да иң көчле, иң зирәк икәнен исбатлый. Дала балалары аның тапкырлыгын, кыюлыгын, көчен танып, үзләренә баш итәләр. Һәм Идегәй Туктамыш ханны күргәч тә югалып калмый, ә очраклы очрашуда олы ханның күнелен ауларлык уен кора.

Мондый тайпылыш ничек барлыкка килгәнен аңлар өчен дастанның төрле чорлардагы һәм төрле төбәкләрдәге вариантларын чагыштырып карау кызыклы һәм әһәмиятле булыр иде. Дастанның борынгырак вариантларында мифик элементлар көчлерәк, калкурак булырга мөмкин. Ә буыннан-буынга телдән тапшырылып, аның мифик элементлары тормыштагы күзәтүләр, чагыштырулар, фәлсәфи нәтиҗәләр белән алыштырылган булуы бар. Татар халкының бер үзенчәлекле ягы—дөньяны акыл белән, үткәннәр тәҗрибәсенә таянып үлчәргә тырышу. Мәкаль дә шуны раслап: "Татар тотып карамыйча ышанмый",—ди бит. Кулы белән булмаса, күзе белән, акылы белән үзе тотып-капшап, күнел тәҗрибәсе аша үткәреп карамыйча татарны ышандыру шактый авыр. Тәрбия турындагы юллар да мондый гомумиләштерүнең урынлы икәнлеген күрсәтәләр.

Дастанны җентекләп укыганда шул аңлашыла: Алтын Урда чоры тәрбиясенең үзенә хас эчке эзлеклелеге, тәртибе, гасырлар буе камилләшкән алымнары булган. Мәсәлән, биш яшькә кадәр баланы иркәләгәннәр, назлаганнар, яратканнар, аның холкын күзәткәннәр, табигый мөмкинлекләрен кинәйтү, сәләтен үстерү максатында бала белән махсус шөгыльләнгәннәр. "Өч яшендә аталык остаздан китап башлатты",—диелә Идегәйнең Җантимер гаиләсендә нинди тәрбия алуы турында сөйләгәндә. Һөнәргә махсус өйрәтү алты яшьтән башлана торган булган. Һәм биш яшендә сәләтләре тәмам ачылган Идегәйне—"Җантимернең биш угыл—бишенә дә баш булды"— сугышчы итеп тәрбияли башлыйлар. Ул алты яшендә ат менә, җиде яшендә ук тартырга өйрәнә, ә сигез-тугыз тулганда бүгенге "у-шу"ны хәтерләткән кул сугышында үзен чыныктырып, "сигез тукмак сындырып, туң тимергә кул ора". Кыска гына итеп бирелгән тәрбия турындагы юллардан күренә—баланың киләчәге, аның җәмгыятьтәге булачак урыны өчен иң әһәмиятле чор—биш яшькә кадәр яшәгән чоры. Халык телендә баланың нигә сәләтле икәнлеген билгели алмаганда "ачылып китә алмады әле",—дип әйтү гадәте бар. Бу тәгъбир үткән тәҗрибәнең телдә саклануы кебек янгырый түгелме? Балачак тәрбиясенең гомерлек икәнен белдергән "алтыныкы—алтмышта",—әйтеме шулай ук телебездә даими кулланышта.

Алтын Урдада бала фәкать гаиләдә генә тәрбияләнергә тиеш дигән катгый фикер өстенлек иткән. Бу фикерне безгә халыкның баш тәрбиячесе сыйфатында сурәтләнгән пир Галәттин җиткерә. "Ни яман?",—дигән сорауга ул болай дип җавап бирә: "Төркене юк кыз яман. Бишектәгеләр елашып, атасыз калса—ул яман. Атадан янгыз туган—ул яман." "Төркене" сүзе—нәсел-нәсәбәсе дигәнне аңлата. "Атадан янгыз туган" дигәннең мәгънәсе хәзер дә үзгәрмәгән—"атасыз" "җилдән" дигәнгә туры килә. Аңлашылганча, нәсел ныклыгы, ятимнәрнең булмавы—ул чорда бала тормышы өчен дә, дәүләт иминлеге өчен дә иң

ышанычлы, зарур шартларның берсе саналган. Бу бик гади, ышанычлы хакыйкать. Моның дөреслеген исбатлап тору кирәк тә түгелдер.

Әсәрдә тәрбиясе тагын да җентекләбрәк, эзлеклерәк, тирәнрәк сөйләнгән кеше—Норадын. Идегәй һәм Норадын тәрбиясен тулаем бергә алып гомумиләштергәндә Алтын Урдада аксөякләр, хәрби юлбашчылар катламы ничек тәрбияләнгәнен, ул вакытта балага карата нинди йола—сынамышлар үтәлгәнен тулысынча диярлек күз алдына китерергә була.

Норадын Идегәй кебек затлы атаның көтеп алынган, яратылуга сугарылачак баласы буларак дөньяга килә. Әти кеше өчен ир бала туу— күңелдәге татлы хыялларны кузгатып җибәрә. Бу хәлне автор дастан чоры кешеләренә хас чагыштыру аша —"ат башыдай ул туды",—дип аңлата. Идегәйнең Норадынга булган өмет-ышанычлары ни дәрәҗәдә икәнне бала тугач үткәрелә торган зурлаулар, сый-хөрмәтләрнең муллыгы күрсәтә. Ул Туктамыш хан бичәсе Йәникәнең көнчелеген дөрләтеп кабызып җибәргән "хан сыена тиң кылып" туйлар үткәрә. Колларын җыеп баланың бәхетенә багышлап теләкләр теләтә. Галимнәрне чакырып "гарәби китап" уку тантаналары оештыра. Һәм Идегәй боларны бер максат белән башкара — баланың күңел кырында кылганнарының барсының да шифалы эзе калачак. Идегәй улының киләчәктә сугышчан юлбашчы булуын тели. Бәлки Норадын тәхеткә дә ирешә алыр? Ата кеше бала күңеленә бу уйларны да салырлык гамәлләр кыла: "Яуда явыр булсын дип, яуны бергә кыдырды". Тәрбиядә вак нәрсәләр юклыгын искәртеп, бала тирә-юнендәге әйберләр дә алдан уйлап сайлана. Яхшы аргамак, затлы кием — Норадынга бала чактан югары катлам вәкиле булуын тоеп үссен өчен бирелсә, садак—сугышчы язмышына алдан күнектерү өчен биленә тагыла. Кадергә, кайнар яратуга сугарылып, өстенлек аша гына бирелә торган мөмкинлекләрне тоеп һәм табигатенә сеңдереп үсә Идегәй малае. Аның нинди ир-егет булып үсеп житкәнен, нинди биеклекләргә күтәрелергә мөмкин икәнлеген инде күпләр күреп тора.

Токымы Чыңгыз угланнар
Норадынны күргәндә,
Буйларын басып буй үскән
Ир буласын белгәндә, —

тәхет тирәсендәгеләр күңелендә егеткә карата көнчелек хисләре тумый калмый, билгеле. Әтисенең Аксак Тимер янына качып китүе көнчелекне дошманлыкка әверелдерә. Дошманлык белән туенып яшәүче сарай ялагайлары киләчәктә Норадынны Идегәйгә каршы да котыртачак, үлемгә дә этәрәчәк—болары бәхәссез. Сату-сатылу, мәкер-гайбәт, бер-берсен уздырып куштанлану — хакимият тирәсендә даими кайнап торучы гадәти күренеш.

Идегәй һәм Норадынга бирелгән һәр ике тәрбия дә куелган максатына ирешә. Җантимер гаиләсендә алган тәрбия Идегәйгә иркле, затлы, хакимнәр белән үзен тигез куеп сөйләшә белә торган батыр ир булып өлгерергә мөмкинлек бирә. Бу кешенең көче, үз-үзен тотышы шул кадәр камил була, автор үзенең соклануын аның турында язган һәр юлга диярлек салган. Кыяфәте нинди, ничек атлый, ничек сөйләшә—сурәтләү мөкиббән күзләр күрүендә бирелгән. Кемнәр белән генә чагыштырмый ул Идегәйне—Чыңгыз хан белән дә, "Румдан купкан Эскәндәр" белән дә ( Искәндәр Зөлкарнәйн—Александр Македонский), "Дарап улы Өрестәм" белән дә (Фирдәүсинең "Шаһнәмә"се герое Рөстәм)—һәм барсыннан да өстен куя. Автор фикеренчә, бала сабый чакта алган тәрбия җимешләрен тормышта җәмгыятькә тулысынча кайтарып бирә. Тәрбиядә балага нинди уй—хис—гамәл максатлары юрасаң, көченне куйсаң бала шул теләкләрне акларлык булып үсә. Шуңа күрә дә Идегәй:

Аты юкка—ат булды,
Чүлләгәнгә—су булды,
Адашканга—юл булды.

Икенче җирдә:

Иркле кеше ул булып,
Илне тоткан ир икән.

Идегәй гади халык арасында иректә үсә. Аны идарә итү эшенә, хакимлеккә махсус өйрәтмиләр. Норадынны, киресенчә, алдан түрәлеккә әзерләп үстерәләр.

Хакимлеккә, кешеләрнең язмышлары белән идарә итәргә әзерләү Норадынның үзен иректә яшәүдән, гади тормыш белән ләззәтләнә белүдән мәхрүм итә. Яшәү максатын алдан артык катгый билгеләү, тормышның табигый агымына юл калдырмый. Мондый очракта кеше үзен үзе уйлап чыгарган максат, яки тәрбия нәтиҗәсендә уена, күңеленә сеңдерелгән үзенә бирелгән бәя (роль) белән тулысынча тәңгәлләштерә башлый. "Мин генә хаклы", "мин һичшиксез иң өстә, бөтен кеше соклана торган урында булырга тиеш", "бу дөнья минем өчен генә" һәм башка "мин"не үзсендереп торган уйлар кеше күңеленә тулысынча хуҗа булалар. Тора-бара бу хәл шәхес өчен фаҗигага әйләнергә мөмкин. "Тәхет тоткынлыгы" югары катлам кешеләре өчен гадәти булса, бу хастаның "максат тоткынлыгы" рәвешендә тәэсир итүе дә бар бит әле. Балачактан күңелендә түрәлек дәгъвасы тоткан Норадын әтисенә шушы дәгъваны таләп итеп белдерүне хак гамәлгә саный. Шуңа күрә куелган таләбе үтәлми калган очракта Идегәйне илдән куачагын ачыктан-ачык әйтә. Идегәйнең улына баглаган өметләре, тәрбиягә түккән көчләре шул хәлләрдән соң әрнеткеч бер төергә әверелеп, ата йөрәген тырнавы аңлашыла торгандыр.

Картайган да көнемдә
Үз башыма көч иттем,—

ди Идегәй тәрбиядә артык максатчан булуының үзенә үк китереп сукканын аңлагач.

## Тәрбиядә тәэсир мәсьәләсе

Борынгылар фикерләвенчә, яшәү, тормыш — уйны, тәэсир көчен, вакытны һәм мәңгелекне үзендә саклаучы, чынбарлыкка әвереллерүче илаһи бер хәрәкәт. Бу турыда без уй, кыр, вакыт һәм мәңгелеккә багышланган бүлекләрдә бераз тукталып киткән идек. Дөньяны тоташ бер хәрәкәт челтәре агымнары итеп аңлауның ул чорда ничек кулланылганын безгә Субра ерау үзенең сирәк очрый торган сәләте аша күрсәтте. Ерау мәгълүмат кырына тоташып Идегәйнең яшерен серен ачты. Әсәрдә безнең күзаллауларга сыеп бетмәгән тагын бер очрак сурәтләнгән. Ул Норадын белән бәйләнешле. Алтын Урдада Хан булу турында хыялланган Норадын әтисе белән дә, башка югары катлам кешеләре белән дә даими бәхәсләшә. Үзенең тәрбия һәм гыйлем өстенлеген һәрчак исбатларга тырыша. Аның максаты—Туктамыш ханны һәм башка югары катлам кешеләрен идарәдә нәсел өстенлегенә генә таянмыйча, тәрбия, гыйлем өстенлегенә юл бирергә ризалаштыру, шуны танытуга ирешү.

Ялан кылыч кулга алып,
Яу кайтарган мырзамын;
Борак сынлы ат менеп,
Билек сөргән мырзамын,

Шаh Норадын миндермен,
Шушы йөргән Чыңгызның
Кайсы улыннан кимдермен?

Норадын үзенең гыйлем өстенлеген күрсәтү өчен: "Укымыйча белдем",— дип тәкърарлый. Әлеге сүзләрдән укымыйча белүнең укып белүгә караганда өстенрәк бәяләнеп йөрүе дә аңлашыла. "Укымыйча белү" мөмкинме соң? Ул ничек була? Бәлки әтисенең ул тугач та галимнәрне бишек янына җыеп, шунда китап укытуы, изге китап сүзләре турында мәгънә соратуы аның акылына-уена турыдан-туры сеңеп калгандыр? Өстән генә карап үткәндә бу әкияти аңлатуга ошаган. Шул ук вакытта Норадынның дәлилендә тирән мистик мәгънә дә бар.

Адәм баласы тормыш юлында очраган бер генә тәэсир шаукымын да югалтмыйча, онытмыйча яши. Дөньяны ул өзлексез үзенә сеңдерә. Һәр тәэсир кешенең күзәнәкләрендәме сакланып вакыт-вакыт аның аңына, акылына, күңеленә, хәтеренә саркып чыга. Кеше күңелендә күп уй-хыяллар, омтылышлар яшеренеп яшиләр. Аларның күңелгә каян кереп оялаганын тәгаен генә билгеләү дә кыен. Нәселдән дә алар, балачактан да, тирә-як кешеләр күңеленнән дә, тормышның үзеннән дә. Кешегә иң нык тәэсир, әлбәттә, ата-анадан, гаиләдән килә.

"Оясында ни булса, очканында шул булыр",—ди мәкаль бу күзәтүнең дөреслеген раслап. Һәркем үз тәҗрибәсеннән чыгып та әйтә ала, гаилә йогынтысы —гомер буена җуелмас йогынты. Тормыштагы төрле очрак-сынау-сорауларга безнең гаиләдән алып чыккан әзер җавапларыбыз бар. Гаиләнең яшәү тәртибе балага тулысынча сеңеп кала. Бишектәге бишкә төрләнә— шулай итеп, бала табигать, нәсел, гаилә, мохит тараткан тәэсирләрнең барысын сеңдереп, без теләгәнне-теләмәгәнне дә хәтерләп, үзләштереп, үзенең холкы, киләчәге итеп үсә бирә. Җентекләп тикшергәндә "укымыйча белү" алай әкияти үк тә түгел икән. Матбугатта йоклаганда кеше хәтеренә чит телдәге сүзләр, башка мәгълүмат салу турында хәбәрләр күзгә чалына. "Укымыйча белү" шул була түгелме соң инде? Борынгылар безнең яңа ачкан ысулны күптән белгәннәр һәм чынбарлыкта кулланганнар, димәк.

Тәэсир турында сөйләгәндә ярату тәэсирен беренче итеп куярга кирәктер. Ярату—әсәрнең аһәңе булып янгырый. Илне-җирне ярату, ата-ананы, баланы ярату, дөрес сүзне ярату, атны ярату—дастан геройларының яшәү мәгънәсен, яшәү асылын тәшкил итә. Адәм баласын аңлар өчен аны дөньяга нинди уй-хисләр китерүен белү кирәк. Көтелгән, кадерле, яратулы бала булганмы ул, әллә артык кашык булып, какканнар да сукканнармы аны? Яратудан мәхрүмнәр, ятим үскәннәр, бала чактан кагылып йөргәннәр бу дөньяга башка күз белән карый. Рәнҗетелгән кешенең язмышы да башка. Баланы рәнҗетүгә юл куймау, баланы ярату, аның киләчәге өчен кулдан килгәнне эшләү һәм ир бала турында ата, кыз бала турында ана кайгыртуы—дастан туган чорда җәмгыятьтә шундый тәртип яшәгән.

Беренче карашка каршылыклы итеп күрсәтелгән Идегәй белән Норадын мөнәсәбәтләренең асылында ата белән улның бер-берсен тирән яратуы, терәк булырга омтылуы ята. Җантимер гаиләсе җылылыгында ирек, иркенлек тоеп үскән Идегәй улына карата да шундый мөнәсәбәтне саклый һәм ике арада туган каршылыкларны йомшарту теләге белән беренче адымны һәрчак үзе ясый. Аның Норадынга булган яратуы көчле, сүнмәс, сүрелмәс итеп сурәтләнгән. Батыр, кыю, әмма артык ышанучан һәм ярсу холыклы Норадын сарай куштаннары корган тозакка бик тиз эләгә. Ул Туктамыш хан кызы Ханәкәне Идегәйдән көнләп, атасының күзен бәреп чыгара. Әтисе аның кылган җинаятен гафу итә —читкә чыгып киткән улының илгә кайтып үз янында булуын үтенә. Норадын илгә кайтып күпмедер яшәгәч ара янадан бозыла. Сәбәбе шул ук—Норадын һаман хан тәхетен дәгъвалый. Әтисе риза булмагач аны илдән куа. Идегәй улына хәлне аңлатырга тырыша, аннан баш тартмый, аның теләген үтәп, казак булып чыгып китә.

Каулаганың мин булсам,  
Мин качаем, син каула,  
Һәрбер көндә дошманың  
Миндәй качсын,мырза углым!

Идегәй бу адымы белән дә улын ихлас ратканын, сүзләренә колак салганын күрсәтә. Ул бит олыгаеп барса да Норадыннан көчлерәк.

Көрәшсәм, сине егармын,  
Йөгерсәм, сине узармын;  
...  
Каргышым кара таштан үтәдер,  
Аһым җирне-күкне тотадыр,  
Күтәрә алмассың, Норадын!

Идегәйнең казак булып чыгып китүе, чагыштырып караганда, король Лирның үз кызлары тарафыннан куылып йөрүеннән бермә-бер аерыла. Көч беләнме, тылсымы беләнме улын буйсындыру аның өчен үтәп булмаслык эш түгел. Идегәйнең адымында корбанга бару, улына хәлнең нинди икәнлеген үз тәҗрибәсендә аңларга мөмкинлек бирү, киләчәктә килешүгә юл калдыру да бар. Ул үз өстенлеген белеп эш итә, өстенлеген күрсәтеп тә улын кимсетәсе килми.

Норадын әтисен аңлаудан узган. Тәхеткә ирешү теләге—иң аяусыз сукыр теләк Норадынның күңел күзен тәмам каплаган. Нәтиҗәдә, артык көчле теләк аны кабат тозакка, бу юлы үлем тозагына китереп каптыра. Норадынны коткара алмаячагын аңлаган Идегәй улын чиксез яратуын, аның белән горурлануын

белдерә. Мәңгегә аерылышу мизгелендә алар шулай бәхилләшәләр. Бу тетрәндергеч матәмле манзара ата һәм улның ихтыяр көчләре, рухи гайрәтләре, нинди дәрәҗәдә тәңгәл икәнлеген исбатлый:

Ташкын тирән дәрьяны
Болыттай уткән мырза углым!
Кола саргыл баласын
Куга чөйгән мырза углым!
Ку канатын сал итеп,
Идел кичкән мырза углым!

Бу юлларда Идегәйнең күңел тирәнлеге, шәхес бөеклеге чагыла.

Күңел турында бәлки җентекләп язарга кирәктер. Без бит күңел сүзенә бик тирән мәгънә салабыз. Күңел безнең өчен хәтер дә, күз дә, уй-хис туплана торган урын да, эчке сизгерлек тә, дөнья белән тоташтырып торучы күренмәс кыллар да. "Эго", "супер эго", "подсознание", "третий глаз"—шушы эчке сиземләүгә кагылышлы сүзләрнең мәгънәсен телебездәге "күңел" сүзенә сыйдырып була. Уйны тыеп туктату, күңелне уйлардан арындырып тынычландыра белү—бу инде катлаулы күңел (фәлсәфи) эзләнүләре аша гына ирешелә торган халәт. Тән, җан, акыл, күңел һәм уйлар дөньясы—кеше тормышында бер-берсеннән аерылмыйча үзара тоташып яшиләр. Яшәү максаты һәм сәләт үзара тәңгәллектә булганда гына адәм баласы бу дөньяда үз урынын таба ала, күрәсең. "Үз урыны" дигән сүзне дә биеклек, дәрәҗә, байлык дип кенә аңлау дөрес булмастыр. Кешенең тормышта үз урынын табуы күбрәк күңел канәгатьлегенә бәйле. "Күңелен шунда тындырды",—ди дастан Идегәйнең бала тәрбияләүдәге омтылышларының максатын. Кеше һаман әз өйрәнелгән, даими сораулар тудырып торучы катлаулы бер зат. Ата-бабаң нинди тормыш белән яшәгән, әти-әниеннең язмышы нинди булган, синең бишегеңне нинди уй-теләкләр белән тирбәткәннәр—боларның берсе дә югалмыйча синдә саклана.

Бу юлларны язгач бүгенге көндә яшь буынга карата алып барыла торган тәэсир турында әйтмичә калып булмый. Тәэсир бит ул гаилә белән генә чикләнми. Адәм баласы дөньяда яши. Дөнья ничек тәэсир итә, нинди яшәү үрнәге бирә—бу да әһәмиятле. Тирә—якка игътибар белән карагыз әле— әшәке сүз, эчкечелек, фахишәлек, үтереш һәр адымда безнең балаларны сагалап, котыртып тора түгелме? Рекламалар, кибет витриналары, телеэкраннар эчәргә, кәеф-сафа корып рәхәт яшәргә өндиләр. Гәзит киоскларына килсәң шәрә хатыннар бөтен "байлыкларын" күрсәтеп, "син дә шулай эшлә, чишен, ят, рәхәтлән",—дип вәсвәсәләп торалар. Телевизор экраннарындагы кабәхәтлек турында язмый да башладык, күндек инде. Ә җимешләре нинди? Хәзер кешене мәсхәрәләп гомерен өзү чебен үтерүгә тиң кабул ителә түгелме? Әнә, кичә Әлмәттә унсигез яшьлек кызны көчләп, үтереп гаражлар арасына ыргытып киткәннәр. Бүген шундыйрак мәет бакчадан табылган. Лаешта жиденче сыйныф малайлары беренче класста укучы кызны башта мәсхәрәләгәннәр, аннан муенына таш бәйләп шакшы суга салганнар. Кем сискәнеп, нәфрәтләнеп, үз кылганнарыбыздан коты алынып, кая баруыбызны белергә теләп шушы мәхшәрнең авторларына эндәште? Мондый хәлләр бит үзеннән-үзе тумый. Бу—халыкка карата алып барылган җинаятьчел тәэсирнең беренчел җимешләре. Әмма шуны да онытмасак иде—тормыш тукымасы шундый итеп тукылган—анда яхшылык та, начарлык та оештыручының үзенә дә житәрлек өлеш чыгара. Тормышта һәр әшәкелекнең, һәр аздыруның, гаделсезлекнең кайтаваз үче, үзенең җавабы бар. Аздыручы кеше үзенең агуын башта үз күңелендә үстерә, аннан гына аны дөньяга чәчә.

Без бит кеше тәрбиясен хезмәт белән чикләп, шуна кайтарып калдырабыз. Әмма эшкә өйрәнгәнче адәм баласы үзен чолгаган дөньядан бик күп нәрсәне сеңдереп, үзләштереп өлгерә. Һәм нәкъ шул хезмәткә керешкәнче җыйганы аның алдагы тормыш юлында иң әһәмиятле чыганак булып тора түгелме? Һәрхәлдә, "Идегәй" дастанында сурәтләнгән тәрбия алымнары ул заман кешеләренең баланың сабыйлык чорына күп игътибар биргәннәр дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Дастан ата-ананың, тәрбиячененң балага күңел халәте, акыл көче, яратуы белән иткән тәэсире, гаиләдәге (илдәге) тәртипнең балада саклануы, нәселдән килгән хәтер кырының югалмыйча буыннан-буынга тапшырылуы турында сөйли.

**Зәрия ХӘБИПОВА**

**Вил Ганиев**

# XX ЙӨЗ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

ТАРИХИ-БИБЛИОГРАФИК КҮЗӘТҮ

XX йөздәге татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышы дәвере игътибарга аеруча лаек бер дәвердер. Искиткеч зур патриотлык хисе белән яшәгәндә әдәбиятның халыкка хезмәт итү идеясе иң биек ноктага җитә. Авыр сугыш шартларында әдәбият зур кыенлыкларны җиңәргә ярдәм итә, кешене канатландыра, аның рухын күтәрә. «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналы нинди генә авыр шартларда да чыгудан туктамый. Аның битләрендә иң әүвәл фронтовик язучыларның алгы сызыктан, госпитальдән яки фронт газеталары редакцияләреннән җибәргән әсәрләре басыла, шуларны укып тылдагы кешеләр үзләренә иң кирәкле мәгълүматны, рухи азыкны алалар. Журналның һәр яңа санын укучылар түземсезлек белән көтеп ала, журнал кулдан кулга йөри.

Сугыш елларында татар шагыйрьләре, прозаиклары, драматурглары иҗат иткән күренекле әсәрләр XX йөз татар әдәбиятының алтын фондына керә. Менә алар: М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре», Ф.Кәрим, Г.Кутуй, С.Хәким, Ә.Фәйзи, Ә.Ерикәй, Г.Хуҗи, Ш.Мөдәррисләрнең лирикасы, Ф.Хөснинең «Йөзек кашы» (1945), Ф.Кәримнең «Разведчик язмалары» (1943), И.Газиның «Алар өчәү иде» (1944) повестьлары, Ш.Камалның «Марат» (1949), Ә.Еникинең «Бер генә сәгатькә» (1944) хикәяләре, М.Әмирнең «Миңлекамал» (1944), Р.Ишморатның «Кайту» пьесалары һ.б.

Татар язучыларының кулына корал алырдае барчасы да сугышка китә. Җөмһүрияттә Язучылар союзын карт драматургыбыз Таҗи Гыйззәт җитәкли. Безнең әдәбият ул елларда зур югалтулар кичерә. Ф.Кәрим, Нур Баян, Р.Ильяс (1908—43), М.Әблиев (1900—41), Д.Фәтхи (1906—43), М.Вәдүт (1915—42), М.Гаяз (1917—43), Г.Рахман (1914—42), Әгъзам Камал (1918—43), шулай ук әдәбият мәйданында әле күренә генә башлаган А.Аитов (1908—41), Габдулла Гали (1920—41), К.Вахит (1916—42), Ә.Әминев (1918—42), А.Гимад (1915—43), М.Гатау (1913—43), М.Әхмәтгалиев (1920—43), И.Закир (1911—44), С.Мөлеков (1920—41) һ.б. сугыш кырында ятып кала. Польшада госпитальдә Г.Кутуй вафат була. Шагыйрь һәм подполковник Хәйретдин Мөҗәйне (1901—44) Каршылык күрсәтү хәрәкәтенә катнашкан өчен фашистлар Дахауда атып үтерәләр. Фашистлар төрмәсендә М.Җәлил белән А.Алишны (1908—44) һәм аларның көрәштәшләрен гильотинада һәлак итәләр. Яшь шагыйрь Рәхим Саттар (1912—43) шулай ук антифашистларның яшерен оешмасында эшләп, лагерьдан качкач та, юкка чыга (мөгаен, һәлакәткә дучар булгандыр).

Сугыш елларындагы әсәрләр еш кына ут эчендә, һич югы окоп шартларында, землянкадагы сукыр лампа яктысында, редакция машинасында языла. Фронт газеталарында кайсы мөхәррир, кайсы хәрби хәбәрче һ.б. сыйфатында М.Җәлил, Г.Кутуй, А.Шамов, М.Максуд, Р.Ишморат, И.Гази, Г.Галиев, Ә.Исхак, Ә.Фәйзи, Ә.Ерикәй, Г.Насрый М.Садри, Г.Хуҗи, Г.Әпсәләмов, М.Мазунов һ.б. эшли.

Мәскәүдә яшәп, 1940 елда Әдәбият институтын тәмамлаган яшь язучы Г.Әпсәләмов (1911—79) өчен сугыш дөньяны танып белү, чыныгу мәктәбенә әйләнә. Карелия муентыгында сугыш шартларында ул бер-бер артлы матур гына хикәяләр яза башлый. Аның тормышчан язмалары әледән-әле «Совет әдәбияты» журналы битләрендә күренә, 1944 елда исә «Төньяк балкышы» исеме белән җыентык булып чыга. Шул вакыттан Бөек Ватан сугышы темасы аның иҗатында төп тема буларак яши: «Алтын йолдыз» (1948) белән «Газинур» (1951) романнары авторга 50 елларда ук дан һәм шөһрәт китерә.

30 елларда буразнага төшеп кенә килгән шагыйрьләр Ватан сугышы елларында ныгып-чыныгып өлгерәләр. Бу сыйфат иң әүвәл С.Хәким, С.Баттал, М.Садри, Ш.Мөдәррис, З.Мансурларга хас.

Зур күләмле эпик әсәрләр сугыш елларында язылмый, бәлки бераз соңрак, сугыш беткәч күренә башлый.

Төркиядә һәм кайсыбер бүтән илләрдә яшәгән татар эмигрантларының күбесе, кызганыч ки, СССР халыкларының Ватан сугышында туган илне саклавын да, патриотик хисен дә аңлап җиткерми, большевикларның җиңелүен тели, фашистлар белән бугазга-бугаз килгән ватандашларына, рус эмигрантлары шикелле, ачыктан-ачык теләктәшлек күрсәтми. Моның сәбәбе, мөгаен, Төркия хакимияте алып барган сәясәткә бәйледер: гәрчә фашистлар ягында сугышмаса да, Германиягә һичбер тел-теш тидертми.

Татар әдәбияты сынатмый, укучыларга окоп хәлләрен дөп-дөрес иттереп җиткерә тора, каһәрле сугышның бөтен авырлыгы солдат җилкәсенә төшкәнен сурәтли, аның рухи дөньясын ачып сала.

Сугыштан соңгы унъеллыкта чынбарлыкны киң колач белән тасвирлаган зур күләмле әсәрләр дөнья күрә. Әдипләребез, әле сугыш тәэсиреннән тулаем арына алмаган хәлдә, үткәнне дә, бүгенгене дә шул күзлектән карап бәялиләр.

1948 елда «Совет әдәбияты» журналында да, шул ук вакытта аерым китап булып та Г.Бәширевнең «Намус» романы дөнья күрә. Укучылар аның вакытлы матбугат битләрендә чыккан аерым бүлекләрен элегрәк тә укып өлгергән булса да, роман тулаем килеш һәркемнең күңеленә хуш килә. Бигрәк тә аларга милли характерның гаять асыл сыйфатларын үзенә туплаган Нәфисә образы ошый. 1948 елда тагын К.Нәҗми үзенең озак еллар буе иҗат иткән һәм өлешчә генә вакытлы матбугат битләрендә чыгаргалаган «Язгы җилләр» романын укучылар игътибарына тәкъдим итә. 1951 елда «Намус» романы да, «Язгы җилләр» романы да Сталин премиясенә лаек табыла. Мәгәр мактаулы хәлләре әлләни озакка сузылмый: Хрущев заманында хәлләр үзгәреп китә, рухи байлыкка мөнәсәбәт тә яңачарак була, бәя дә тәнкыйть күзлегеннән чыгып бирелә башлый...

1951 елда М.Әмир «Ялантау кешеләре» дигән романын чыгара. Анда ул сугыш вакытындагы авыл тормышын бераз шомартыбрак узса да, бик тәфсилләп сурәтли. «Саф күңел»дә (1960) шул ук теманы дәвам иттерә, нәтиҗәдә дилогия килеп чыга. И.Гази да шундыйрак язмышка юлыга: 1949 елда ул «Онытылмас еллар» дигән повестен чыгара, ә инде 1964 һәм 1971дә янә ике повестьта шул сюжеттан алдарак булган хәлләрне (ретроспектива) тасвирлап бирә һәм трилогия китереп чыгара. Тәнкыйтьчеләр бу трилогияне бик хуплап кабул итәләр һәм тарихи-революцион эпопея дип бәялиләр.

Ф.Хөснинең «Авыл өстендә йолдызлар» (1955) повесте дә гаять зур мактау сүзләренә лаек табыла. Автор авыл кешеләренең мәхәббәтен романтик рухта, хискә бирелеп тасвирлый, ә инде аларның сөйләшүен әдәби телебезнең гүзәл үрнәге дәрәҗәсенә җиткерә.

Әдәбият авылдагы тормыш-көнкүрешкә үзенең катгый бәһасен бирмичә кала алмый иде. Тик инде моның өчен иҗтимагый атмосфераның үзгәрүе зарур иде. Ниһаять, шундый кискен юнәлешкә юл ачыла. Әдәбиятыбызда әлеге юнәлешне Ә.Еники башлап җибәрә: 1954 елда «Рәхмәт, иптәшләр!» повестен, 1956 елда «Саз чәчәге» повестен һәм «Рәшә» (1962) повестен иҗат итә. Аңардан соң А.Гыйләҗев «Өч аршын җир» (1962) повестен, М.Мәһдиев «Фронтовиклар» (1973) романын чыгара. Аларга башка прозаиклар да иярә.

1954 елның 22 июлендә Төркиянең Анкарә каласында 76 яшендә Гаяз Исхакый вафат була. Әдипне, васыятен үтәп, Истанбулдагы Әдернекапы зиратына җирлиләр. Даһиның вафатын ул чагында әле туган илендә берәү дә белми...

50 елларның икенче яртысы һәм 60 елларда татар әдәбияты бик нык үсеп китә. Аның язмышына, мөгаен, 1957 елда Мәскәүдә үткән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы да, репрессияләнгән язучыларның аклануы һәм әдәбият дисбесенең тулылануы да, шулай ук элеккеге кырыслыкның бетерелүе дә тәэсир иткәндер.

Мәскәүдә декаданы әүвәл 1941 елда үткәрмәкче булалар. Сугыш кына комачаулап кала. Шуннан инде илленче елларның икенче яртысында шуңа атап Казан, Мәскәү, Ленинград нәшриятләрендә китап чыгара башлыйлар. Тәрҗемә эшендә нәкъ менә урак өсте булып ала. Декада алдыннан күп кенә авторларыбызның китаплары рус телендә чыга; шагыйрьләрдән: М.Җәлил,

С.Хәким, С.Баттал, Ә.Исхак, Ә.Ерикәй, Ә.Давыдов, Ш.Мөдәррис, З.Нури, М.Хөсәен китаплары, прозаиклардан: Ә.Еники, И.Гази, Ф.Хөсни һ.б. авторларның, драматурглардан: Р.Ишморат, М.Әмир пьесалары, әдәбият галимнәреннән Р.Бикмөхәммәтевнең «М.Җәлил» дигән китабы дөнья күрә.

1956 елда зур күләмле «Татар поэзиясе антологиясе» әзерләнә. Ул XII йөз шагыйре Кол Галидән башлап бүгенгәчә сигез гасыр шигъриятен эченә ала. Моңарчы фәкать галимнәр генә өйрәнгән бик күп борынгы шагыйрьләребезнең иҗаты белән укучыларны таныштыру мөмкинлеге ачыла. Әйтик, Мәүла Колый, Утыз Имәни, Һибәтулла Салихов кебек суфый шагыйрьләр иҗаты мәгълүм була. Ш.Бабич, Х.Туфан кебек әдәбиятка яңадан «әйләнеп кайткан» шагыйрьләребез иҗатына зур урын бирелә. Антологиянең фәнни аппараты СССР ФАнең Казан филиалы һәм Казан дәүләт университеты галимнәре тарафыннан башкарыла. Нәкъ бер елдан шул ук антология Казанда рус телендә дә чыга. Бу эшкә 82 тәрҗемәченең катнашуы татар әдәбиятының рус әдәбияты белән үзара бәйләнешләре нык булуын исбатлый.

Мәскәүдә 24 майда ачылган декада тантаналар белән генә чикләнми, әлбәттә. СССР Язучылар союзында булган утырышларда татар әдәбияты әсәрләре турында фикер алышулар зур кызыксыну уята. Кайсыбер әсәрләр яки аларның тәрҗемәләре нәкъ менә дискуссия китереп чыгара. Андый фикер алышулар, әдипләребез һәм шагыйрьләребез иҗатына бирелгән югары бәя тиздән бөтен җәмһүрияткә мәгълүм була: барлык дискуссия, фикер алышуларның стенограммасы «Совет әдәбияты» журналында басылып чыга. Декада безнең заман татар әдәбияты тарихында зур вакыйга буларак янә дистә елларга аның үсешенә турыдан-туры стимул ролен уйный, рус язучылары һәм тәрҗемәчеләре белән дустанә мөнәсәбәтләрне ныгыта.

Партия Үзәк Комитеты 1956 елның 2 июлендә «Шәхес культы һәм аның нәтиҗәләрен җиңеп чыгу турында» чыгарган карары игълан ителгәннән соң бинахак хөкем ителгән шактый гына язучыларыбыз вафатларыннан соң аклана. Шулар арасында XX йөздә иң зур фаҗига кичергән даһи әдип һәм җәмәгать эшлеклесе, 1937 елгы репрессия корбаны Г.Ибраһимов та була.

Репрессияләнгән авторларыбызның әдәби мирасын халыкка яңадан кайтарып бирү иң изге бурычка әйләнә. 1956—57 елларда Г.Ибраһимовның 3 томлык «Сайланма әсәрләре» дөнья күрә. 1956 елда драматургия классигы К.Тинчуринның да «Сайланма әсәрләре» чыга; театрларда аның «Зәңгәр шәл» белән «Казан сөлгесе» драмалары сәхнәгә куела. 1959 елда М.Галәүнең «Болганчык еллар» белән «Мөһаҗирләр» дилогиясе рус телендә басылып чыга: вакытында бу әсәрләр тәрҗемә ителеп, Мәскәүдә чыккан, оригиналлары исә әдипне кулга алганда вәйран ителгән була. 1961 елда шагыйрь М.Крыймовның 1 томлыгы, 1959 елда Г.Толымбайның «Хикәяләр, повестьлар» җыентыгы чыга. Бераз соңрак Ш.Усмановның төрле жанрдагы мирасы да өйрәнелә: 1960 елда татарча, 1970, 1975 елларда русча китаплары укучылар кулына керә.

Әле генә М.Галәүнең кульъязмалары юкка чыкканы телгә алынган иде. Кызганыч ки, андый хәлләр шактый булганы соңрак ачыклана: Г.Ибраһимовны кулга алганда «Безнең көннәр» трилогиясенең икенче һәм өченче кисәкләре, Ф.Кәримнең көндәлекләре, каралама кульъязмалары һ.б. авторларның да иҗат җимешләре юкка чыкканы мәгълүм була.

Сәяси репрессия корбаннарына әверелгән язучыларның иҗади мирасы халыкка яңадан кайтарылганнан соң татар әдәбиятындагы бушап калган урыннар акрынлап тула башлый. Әмма шуннан соң да әле Г.Исхакый, З.Вәлиди, С.Максуди, Й.Акчура, Г.Баттал-Таймас кебек эмигрант әдип вә галимнәребезнең иҗаты озак вакытлар халыктан яшерелгән хәлендә кала килә. 1937 елда атылган Фатих Кәриминең әсәрләре дә фәкать 1995 елда гына кабат дөнья күрә.

Тоткынлыктан кайткан язучыларның кайсыберләре (Г.Гали, 1900—54; Г.Шәрәф, 1896—1950 һ.б.) төрмә газапларын кичергәннән соң сафтан чыгып, иҗади эштән ваз кичәргә мәҗбүр була. Тик инде төрле михнәтләрдән соң иҗатларын уңышлы дәвам иттерүчеләр дә юк түгел: Х.Туфан (1900—81), И.Салахов (1911—98), С.Рафиков (1913—71), Мин Шабай (1913—63) һәм студент чакларында кулга алынып, соңыннан акланган әдипләр: Г.Тавлин (1925—98), М.Рафиков (1925—86), А.Гыйләҗев (1928).

Сәяси хәлләрнең йомшаруын (оттепель) тарихчылар, 1953 елда башланып, 11 ел дәвам итә, дип билгеләп үтәләр. Әнә шул вакыт эчендә татар әдәбиятында атмосфера шактый үзгәреп өлгерә. Күптән түгел макталган әсәрләрнең шактые чынбарлыкны дөрес күрсәтмәгән, бизәп-матурлап тасвирлаган, дип бәяләнә.

Х.Туфанның тоткынлыкта язган «Сүз кушасы килә талларга» һәм «Кайсыгызның кулы җылы?» кебек шигырьләре нәкъ әнә шул заманда дөнья күрә, гәрчә үзенең кара язмышын чагылдырмаса да, искиткеч зур бәя ала.

Татар әдәбиятында ул дәвердә лагерь темасы ныклап тамыр җибәрми, бу хәл бераз соңрак, 80 нче еллар азагындагы роман һәм повесть, яки шигырьләр көлтәсе буларак калкып чыга.

Хәер, сугыш темасы да бик үк суынып өлгерми әле, тик инде язучылар аның бөтен катлаулылыгын, каршылыкларын ачып салырга тырышалар. Фашист әсире буларак зур газапларны үз җилкәсендә татыган, соңрак әсирлектән качып котылган шагыйрь Н.Дәүли «Яшәү белән үлем арасында» дигән гаять кырыс чәчмә әсәр иҗат итә. Булган хәлләрне зур осталык белән, ышандырырлык итеп сурәтләгән әлеге китап 2-3 тапкыр басылып чыга; 1960 елдан башлап әсәрнең русчасы кабат-кабат чыгып, яңадан-яңа укучыларның күңелләрен яулап ала.

М.Әмирнең «Җан көеге» (1969) повестенда сугыштагы батырлык түгел, бәлки ул афәтнең күрексез ягы тасвирлана. Әсәрнең үзәгендә сугыш кырыннан качып кайткан һәм әнисе белән хатыны өчен хурлыклы җан көегенә әверелгән дезертир образы. Бу әсәр В.Распутинның «Онытма гомергә» повестенә аваздаш.

Шул ук дәвердә Г.Әпсәләмов эшчеләр сыйныфына багышланган зур күләмле әсәрен («Сүнмәс утлар» романын 1958) иҗат итә.

Декада елында Р.Төхфәтуллинның (1924—1940) «Авылдашым Нәби» (1957) повесте дөнья күрә. Фронтларда булып кайткан, авылдагы тормышны яхшы белгән яшь прозаик авыл җирендә иген игеп яшәүче зур акыл иясенең гаҗәеп үзенчәлекле һәм кызыклы образын гәүдәләндерә. Бу авторның «Йолдызым» (1962), «Җиләкле аланнар» (1969) һ.б. повестьларында да авыл кешесе, аның көнкүреше искиткеч бай тел белән, гыйбрәт алырлык итеп сурәтләнә.

А.Гыйләҗев исә «Өч аршын җир» (1962) һәм «Урталыкта» (1969) повестьларында авылны икенче яктан күрсәтә: авторны иҗтимагый каршылыклар ныграк кызыксындыра.

Димәк ки, әле каралган дәвердә безнең әдәбият тематик яктан да, тормыш-көнкүрешкә мөнәсәбәт-караш ягыннан да гаять күптөрле иҗади күренеш буларак балкып ала.

Алтмышынчы еллар өлкән буын язучыларының аеруча активлашып китүе белән үзенчәлекле. Әдипләрдән: И.Гази, Ф.Хөсни, Г.Галиев, Г.Бәширов, А.Расих, Ә.Еники, И.Туктаровларны, шагыйрьләрдән: Х.Туфан, С.Хәким, М.Садри, Ә.Исхак Ә.Давыдов, Г.Хуҗи, Н.Арслан, Ә.Ерикәй, Г.Латыйп, Н.Гайсиннарны, драматурглардан: Н.Исәнбәт, Р. Ишморатларны әйтеп китү зарур.

Шул ук вакытта милли әдәбиятның үсүендә урта буынның роле искиткеч зур, хәтта әле яшь буын вәкилләре дә үзләреннән өлеш кертәләр. Проза өлкәсендә Г.Ахуновның (1925—2000) «Хәзинә» (1963) романын, Э.Касыймовның (1930—86) «Гомер ике килми» (1964) романын, Н.Фәттахның (1928) «Бала күңеле далада» (1966) романын, М.Хәсәновның (1927—1990) «Саф җилләр»(1961—1963) романын, М.Рәфыйковның (1925—1986) «Илһам авазы» (1966) хикәяләр җыентыгын, Ш.Рәкыйповның (1929) «Чәчәкләр сөйли белә» (1967) повестен, Р.Батулланың (1938) «Исемем минем Дүрткүз» (1966) повестен, Б.Камаловның (1930) «Сыналыр чак» (1965) повестен, М.Хуҗинның (1930) «Хикәяләр» (1966) җыентыгын, Ш.Бикчуринның (1928—91) «Ташлы тауда» (1959) хикәя һәм очеркларын, Г.Сабитовның (1931—95) «Туган җир туфрагы» (1963) хикәяләр китабын, А.Хәсәновның (1937) «Озын аяк» (1966) хикәяләр җыентыгын, Х.Сарьянның (1930—78) «Әткәм һөнәре» (1966) повестен, М.Маликованың (1935) «Казан каласы — таш кала» (журналда — 1967) повестен, Г.Мөхәммәтшинның (1932—72) «Сер итеп кенә» (1960) хикәяләр җыентыгын, Р.Фәизовның (1931) «Яшьлек юллары» (1964) повестен,

К.Тимбикованың (1937) «Зәңгәр күлмәк» (1969) хикәяләрен, А.Тимергалинның (1931) «Пәһлеван кабере» (1960) мажаралы һәм фантастик хикәяләрен, «Ерак планетада» (1967) фантастик хикәяләрен, Р.Хафизованың (1929) «Кыңгыраулар җыры» (1967) хикәяләр җыентыгын, М.Юнысның (1927) «Тимер фил» (1968) диңгезче язмаларын, «Занзибар зәңгәр болытлар артында» (1970) хикәяләр җыентыгын, Р.Кәраминең (1942) «Дүрт кешелек каюта» (1969) повестен әйтеп үтү урынлы булыр.

Алтмышынчы елларда поэзиябезгә талантлы шагыйрьләр дә килә. Дебютантлар арасында: Р.Фәйзуллин (1943) беренче китабы «Рәсем ясыйм» (1965), Р.Гатауллин (1941)—«Гөлләр су сорый» (1966), М.Шабаев (1933)—«Яңа җыр» (1962), Р.Харис (1941)—«Кайтаваз» (1969), Роберт Әхмәтҗанов (1935)—«Беренче яз» (1958), Рәшит Әхмәтҗанов (1941—95)—«Хыялларым үзем белән» (1965), Р.Мингалим (1937)—«Әйт, кояшым!» (1966), К.Мостафин (1932)—«Җыр сафка чакыра» (1966), Г.Рәхим (1941) — «Вәгъдә» (1967), Н.Мадъяров (1928)—«Чык бөртекләре» (1960). К.Латыйп (1927) — «Солдат эзләре» (1960), Т.Камалиев (1940—80)—«Ромашкалар эзлим» (1967), Ш.Маннапов (1938)—«Яшьтәшләрем» (1967), М.Әгъләмов (1946)—«Кыңгырау» (1970).

Шул ук вакытта драматургиягә Туфан Миңнуллин (1935) белән Шамил Шаһгали (1920—86) һ.б. талантлар килә. Туфанның пьесалары 1967—69 елларда куела башлый һәм елдан-ел ныграк активлаша бара; Шамилнең «Таң атканда» драмасы 1960 елда куела.

Татар әдәбиятына аңарчы да, аннан соң да шулчаклы яңа көчләрнең килгәне булмый. Барлык жанрларга яшь талантларның килүенә, мөгаен, иҗтимагый үзгәрешләр, милли үзаңыбызның дөрләп кабынуы сәбәпче булгандыр. Муса Җәлил татар әдәбиятының байрагына әверелә. Җөмһүриятебезнең яшь иҗатчылары әлеге үзгәрешләрне иң беренче булып сизәләр. Алтмышынчы елларда яшьләр әдәбиятка зур кыюлык һәм фикер хөрлеге алып киләләр, моңарчы тыелган хакыйкатьне ачарга, элек хөкем сөргән ялганны һәм күз буяуны фаш итәргә дәртләнеп керешәләр.

Шулчаклы зур исемлекне китерүемнең сәбәбе менә нидә: исемлектәге кешеләрнең берсе дә (үлем-җитем килмәгән очракта) әдәбияттан читләшмәде, иҗат эшен ташламады. Нәкъ әнә шулардан тора-бара мәшһүр каләм осталары, яңа классиклар үсеп чыкты. Алтмышынчы елларда әдәбиятка килгән шагыйрьләр һәм әдипләр бүгенге көндә милли әдәбиятыбызның умыртка сөяген тәшкил итәләр.

Алтмышынчы еллар әдәбиятында Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» (1965) повесте аерым урын алып тора. Дөресен генә әйткәндә, бу әсәр татар халкының милли тормышында хәлләрнең мөшкел икәнен аермачык билгеләп чаң сугу ук булмаса да, кыңгырау чыңлату вазифасын үти. Авылда гомер кичергән Акъәби шәһәрдә яшәүче оныкларына килә һәм... ник килгәненә үкенерлек хәлгә төшә. Чөнки аның оныклары милли гореф-гадәтләрне дә, ана телен дә белмиләр, ата-баба йортына да, милли мәдәниятккә дә юк аларда мәхәббәт хисе, әбиләре гомер буе сандыгында күз карасыдай саклаган әйберләрнең кадерен-кыйммәтен, гомумән, белмиләр — театр сәхнәсен бизәргә генә яраклы бутафория дип карыйлар. Сабый чактан алган тәрбияләре өлкәннәргә хөрмәт күрсәтүдән ерак тора. Картлар белән яшьләр арасына күпер салынмаган, һәм төп фаҗига әнә шуннан килеп тә чыккан: әбекәй үзенең газизләре белән сөйләшүдән генә дә мәхрүм ләбаса! Чөнки балалар татар мәктәбендә белем алмаганнар, ана телен өйрәнү мөмкинлегеннән мәхрүм ителгәннәр... Әнә шул сәбәпле Акъәби оныкларына үзенең күңел төпкелендә шушы көнгәчә саклап килгән уй-фикерләрен сөйләп бирү-аңлатудан да, гомере өзелер алдыннан, үлем түшәгендә ятканда актык сүзләрен әйтеп аңлатудан да гаҗиз...

«Әйтелмәгән васыять» повестенда Ә.Еники сабыр гына кузгаткан фаҗига бит, чынлап уйлап карасаң, гасыр башында ук калкып чыга, татар җәмәгатьчелеге рус теленең үтеп керүенә, киң колач җәюенә юлларны тутырып ачкач ук, баш калкыта. Дөрес, ул чагында әле буржуаз мөнәсәбәтләрнең җайга салына гына башлаган чагы була, милләт алдына иҗтимагый һәм икътисади

үсешкә ирешү өчен рус һәм аурупа мәдәнияте, фәне, техникасы белән ныклы бәйләнешләр булдыру зарурияте килеп баса—бу якынаю цивилизация таләбеннән чыгып башкарыла. Әмма үзара бәйләнешләр канатларын барча тармакка җәя башлаган бер дәвердә үк Г.Исхакый «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) дигән антиутопик повестенда һәм Г.Ибраһимов «Татар мәдәнияте нинди юлдан китәр?» (1916) дигән мәкаләсендә ана теленең, милли мәдәниятебезнең киләчәге өчен борчылуларын белдергәннәр, күңелсез хәлләрнең килеп чыгу ихтималы барлыгын әйтеп кисәтү ясаганнар иде. Мондый хәлгә төшкәнебез өчен алар кемне дә булса гаепләсәләр, фәкать үз телебезнең кадерен белмәүче, мәдәниятебезнең кыйммәтен санга сукмаучы, кайсы милләт вәкилләре булуларын да оныткан үзебезнең милләттәшләребезне гаеплиләр, көчле тәнкыйть уты белән көйдерәләр. Чөнки Октябрьгә хәтле үк үз халкыбызны әйдәп барырга тиешле татар морзалары ансат кына урыслашып китәләр — төп вазифаларыннан ваз кичәләр. Менә ни сәбәпле Г.Исхакый белән Г.Ибраһимов «морза» сүзен нәфрәтләнеп телгә алалар. Эмиграциядә, 1923 елда язылып, Берлинда 1938 елны, туган илендә 60—70 елдан соң, 1992дә генә дөнья күргән «Көз» исемле повестенда Г.Исхакый нәкъ әнә шундый, милли гореф-гадәтләребезгә ваемсыз морзалар гаиләсен күрсәтә. Гаиләдә милли гореф-гадәтләрне онытып җибәргән, алардан ятсынып борын чөйгән өчен морза кызы Гөлсем шәхес буларак ачылып җитүдән дә мәхрүм кала, гаилә тормышында да әлләни бәхеткә ирешә алмый. Милләт язмышы XX йөз татар әдәбиятында төп тема буларак яшәп килә. Безнең әдипләребез һәм шагыйрьләребез милләттәшләрдән татар җанлы татар булуны таләп итәләр. Хәер, рус язучысы В.Распутин да бит үз милләттәшләре алдына шундый ук тугрылык таләбен куя; аермасы шунда гына: рус теленең бетү куркынычы юк.

Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыятенә» яңадан әйләнеп кайтыйк әле. Бу әсәр писхологик прозаның өлгесе булырлык дәрәҗәгә җиткереп язылган: бүгенге чынбарлыкның иң-иң четерекле ягы укучы хөкеменә шулхәтле ышандырырлык детальләр белән сурәтләп бирелгән ки, әлеге мәсьәләгә авторның мөнәсәбәте хакында авыз ачарга да урын калмаган.

«Әйтелмәгән васыять»не мин үзем Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» һәм «Көз» повестьларына, шулай ук Г.Ибраһимовның «Татар мәдәнияте нинди юлдан китәр?» дигән публицистик мәкаләсенә тиңләр идем.

Олуг әдибебез Г.Бәширов милли мәсьәләгә бөтенләй икенче яктан килә һәм «Туган ягым — яшел бишек» (журналда 1967 елны дөнья күрә, 1973 тә исә аерым китап булып чыга) повестенда татар халкының борын-борыннан килгән гореф-гадәтләрен, әдәп-инсафын, рухани байлыгын, аның үзенчәлекле бизәкләрен гаҗәеп зур осталык белән тасвирлап бирә. Авылдан йөз чөергән яшьләребезгә киная беләнрәк милли нигезебезнең төп йортта икәнлеген искәртә.

Алтмышынчы елларда әдәбиятыбызның горизонты киң булуы, тормышның төрле якларын күрә белү осталыгы, тематик һәм стилистик яктан күпкырлы икәнлеге ачыла. Әйтик, медицина хезмәткәрләренә багышлап Г.Әпсәләмов «Ак чәчәкләр» (1965) романын, Н.Фәттах чирәм җир сөрүчеләргә «Бала күңеле далада» (1966) романын, космос яулаучы Андриан Николаевка багышлап К.Латыйп «Йолдыз тапкан егет» (1964) документаль повестен иҗат итә. В.И.Ленин темасын татар язучылары даһи якташыбызның Казанга бәйле биографик мәгълүматларда ачып бирәләр: С.Хәким—«Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты» (1961), М.Ногман—«Кокушкино таңнары» (1964) поэмаларын иҗат итә, Р.Ишморат—«Давылга каршы» (1963) пьесасын яза.

Производство темасы һәрвакыт актуаль саналганга бу өлкәдә әледән-әле яңа әсәрләр иҗат ителә: Г.Ахунов «Хәзинә» (1963) романы белән нефтьчеләргә багышланган сериягә нигез сала. «Дружба» газүткәргечендә эшләүчеләр тормышы С.Хәкимнең «Үрләр аша» (1967) поэмасында һәм Ә.Маликовның «Дуслык юлы» (1960) балладасында чагыла.

Балалар дөньясы Ә.Бикчәнтәеваның (1913—86) «Яз бүләкләре» (1962) шигырь китабында, «Мин аңлыйм сине» (1966) повестенда, Л.Ихсанованың (1923) «Ана күңеле» (1968) повестенда, З.Вәлинең (1924) «Балан бәлеше» (1963) һәм «Җирдәге йолдызлар» (1965) хикәя җыентыкларында күренә.

*Дәвамы киләсе санда*

# «МИН ЧИГЕНӘ АЛМЫЙМ...»

## ХИСАМ КАМАЛОВКА 75 ЯШЬ



Үзенең күп санлы шигырь китаплары белән дә саллы-саллы проза әсәрләре белән дә укучыларга яхшы таныш булган күренекле әдип, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Хисам ага Камалов иҗаты турында уйлан-ган саен күңелдә шундый сорау баш калкыта: күргәнне һәм кичергәнне рәттән сөйләп барумы бу, әллә күңел көндәлегеме?

Шигъриятен алсак—борчылудан һәм юатудан, сагыштан һәм шатлыктан тора аның лирикасы. Шагыйрьнең үз укучысы белән күзгә күз калып эч серен уртаклашуы мөгаен, шулай буладыр.

Бу шигъри дөньяда вакыт күчешен, тормыш үзгәрешләрен ачык тоясың, аның бөтенлегенә һәм чынлыгына ышанасың. Шагыйрьнең лирик герое иң авыр сынаулар кичкәндә дә сынмаган, көрәш сукмагыннан тайпылмаган. Беренче шигырьләрендә үк ачык билгеләнгән шушы кыйблага Х. Камалов һәрвакыт тугрылыклы кала. Бөтен иҗаты белән. Бөтен яшәеше белән. Шуңа күрә аның хис-тойгылары саф һәм тыйнак, үзәк өзгеч дәрәҗәдә чын.

Белсәң, әнкәй, дошман тылларына
Разведкага барган чакларым,
Мин куркудан доган гел укыдым,
Җаным саклап кеше сатмадым.

Кабат-кабат канатлары каерылган сабыр холыклы һәм нечкә күңелле кеше күзләре белән дөньяга карау җиңел түгел. Аның бик тирәндә яткан көчле рухын тиз генә абайлап өлгермисең. Әнисе кебек үк: «Үзе юаш, үзе тәҗрибәсез, ничек калсын шушы мәхшәрдә?..»—дип чын күңелдән борчыласың. Сыкранулары күбрәк төсле.

Шулай да гаҗәп бит: шигырьдән шигырьгә күңелдәге образ ачыклана, зурая, куәтлерәк була бара. Аның сагышы да, шатлыгы да,сафландыргыч һәм рухландыргыч ташкынга әйләнеп, безне бөтереп ала. «Сөенмәсен», «Җилләр иса..» кебек шигырьләренең һәм «Әнкәй истәлеге» поэмасының да тәэсир итү көче әнә шунда. Шагыйрьнең тавышы тонык, хатирәләре авыр, үкенече зур. Хәлбуки, әсәрне укып чыгасың—күңелдә хәсрәтле тойгы түгел, яктылык, бары яктылык кына кала.

Сугыштан соң утыз-кырык ел үткәч, Х. Камалов сугыш турында зур күләмле әсәрләр иҗат итте. Сүз барыбызга да яхшы таныш булган «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» һәм «Үлгәннән соң яздым» исемле өч роман хакында бара. («Безне өйдә көтәләр» романы мисалында Х. Камалов иҗаты 1986 елда Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.)

Әлеге трилогия—язучының бөтен гомере белән əзерләнгән, шул өч роман да—тормышының аерылгысыз бер кисәге. Шуңа күрә ул, Җиңүдән соңгы дәвердә сугыш темасына күпме генә китаплар язылган булмасын, кабатланудан курыкмый: һәркемнең гомере бер генә.

Әйе, унсигез яшендә күргәнен Хисам Камалов бүгенге аяз һәм борчулы күк

астында күз алдыннан кичерә. Ул тарих китабына кергән исемнәр белән, шаккатыргыч вакыйгалар белән мавыкмый. Көнделәнә язылып калган дәһшәтле чынбарлыкны—кешеләрнең үз-үзен тотышын, вакыйгалар сурәтен мөмкин кадәр конкрет-төгәл итеп искә төшерергә омтыла, һәр детальнең үзәгенә үтеп сурәтли, һәр күренешне тәфсилли. Кайчакта шул траншеяларда адашып калырсың кебек... Ләкин, алгы сызыктан бүгенге көнгә кадәр сузылган телефон җебе буйлап баргандай, бер деталь икенчесенә килеп ялгана, бер герой язмышы башкаларныкы белән үрелә башлый. Ул—зур Җиңүгә өлеш керткән сугышчыларның берсе икән; аның үзгәлекләреннән бигрәк, типик, уртак сыйфатлары истә кала, меңнәр белән берләштергән язмышы калкып чыга. Бу геройлар, бу бәрелешләр, бәлки, олы сугыш стратегиясе күзлегеннән караганда, әллә ни зур игътибарга да лаек түгелдер. Әмма алар, халык батырлыгы—Бөек Ватан сугышының катлаулы чынбарлыгыннан аерылгысыз, дип дәлиллиләр, кешенең авыр сынаулардан җиңеп чыгуы турында безнең белгәннәребезне тулыландыралар.

Без монда сугыш дигән зур дөнья, сугыш дигән гаять катлаулы образ белән очрашабыз. Ил өстенә килгән афәт һәм аерым бер кеше драмасын, теләк һәм мәҗбүрилек нисбәтен бөтен тирәнлеге белән аңлау, аңлату искиткеч авыр. Сугыш, теләсә нинди авыр сынау астында калгандагы кебек, кешенең соңгы рухи көчләрен эшкә җигә, күңел төпкелендә яткан иң яшерен хәзинәләрен яктыга чыгара. Канлы көрәш һәм тормыш кырыслыгыннан, дошманга нәфрәттән тупаслана башлаган җан җылыга, яхшылыкка тартыла. Үлем ачысын тоеп яткан Айкилдиевның әле дә булса мәхәббәт утына үрелүе, майор Мостафин белән латыш кызы арасындагы мөнәсәбәтләр әнә шундый. Окоп читендәге чәчәк кебек табигый, гүзәл һәм фаҗигале.

Сугышның кырыс холкына буйсынмаучы мондый геройлар һәр әсәрдә бар. Һәр очракта алар үзенчә ачыла.

Г. Әпсәләмовның җете романтик төсләргә бай булган «Алтын Йолдыз», «Газинур» романнарында, мәсәлән, аларның рухи көче тау елгасы кебек бөтереп алып китә. Х. Камалов хикәяләвендә исә укучының игътибары К. Симоновчарак—сугыш күренешләренә күбрәк юнәлтелә, кискен, хәлиткеч мәлдә төрле характерлар, йөзләр чагылып үтә, кешенең фаҗигасе һәм ныклыгы ачыла. Биредә тыныч, эшлекле тон өстенлек итә, җәелебрәк, ашыкмыйчарак акканлыктан, вакыт-вакыт ярлар абайланмый башлый, хәрәкәт-агым тукталып калгандай тоела, характер үсешен абайлау кыенлаша. Ләкин шушы сабырлык, басынкылык белән язучы сугыш хәлләренең драматик-катлаулылыгын, тирәнлеген искәртергә теләми төсле. Әсәрнең эчке агымы, гомумән, укучыны ияртүдән битәр, бөтен юнәлеше белән аңа таба борылган кебек, өерелеп-өерелеп килүче дулкыннарга каршы ишеп барырга мәҗбүрсең. Әмма бу—ясалма катлауландыру түгел. Тормыш сөземтәсенең бик тирән катламнардан саркып чыгуын тояр өчен, чын фаҗиганең һәм чын бәхетнең янә бер чыганагын аңлый башлар өчен кирәк ул каршылык.

Әлегәчә иҗатында прозаизмнарга нык таянып килгән шагыйрьнең «авыр артиллерия» жанрында үз-үзен болай тотышы әллә ни гаҗәпләндерми. Шагыйрьлек анда иң гади язмышлы кешеләрнең күңел байлыгын, кешелеклелек матурлыгын тасвирлаганда гына танылып-сизелеп китәдер шикелле... Әмма сораулар туа тора, аларга җавап табуы да кыенлаша бара. Капма-каршы кебек тоелган ике сыйфатны—тәфсилләп, нечкәләп тасвирлау белән сүзгә саранлыкны ничек бергә куша алды икән язучы? Сугышта разведкага йөргәндә, дошман уты астында элемтә урнаштырганда канына сеңеп калганмы бу сыйфатлар? Ә төрле кешеләрнең фронтта табышу-очрашуы һәм һәлакәте бер-берсен хәтерләтеп куйган чаклар—аларны ничек аңлатырга?

Геройларның хәрәкәт активлыгын сурәтләү дә язучының иҗат һәм тормыш принциплары белән бәйләнгән. Х. Камалов, мәсәлән, геройның үлеме дә һәрвакыт батырлык булырга, нинди дә файда китереп калдырырга тиеш дигән схемага буйсынмый. Алексей Баранов снаряд кыйпылчыгыннан һәлак була. Бөтен фронт буенча соңгы хәлиткеч һөҗүмгә күтәрелгән вакытта. Сугыш бетәргә дә озак калмаганда. Майор Мостафин, ут эченнән исән чыгып, ял вакытында снайпер пулясыннан һәлак була. Очраклы үлем бигрәк тә үкенечле. Әмма ул көчле характерның тормыш бәясен очсызландырмый, ә яшәү мәгънәсе турындагы сорауны тагын да катлауландыра, киеренкеләндерә.

«Аны өйдә көтәләр!»—Менә ни өчен ут эченә керә солдат, ул үз өен, нәселен

дошманнан яклау өчен изге яуга чыгуын яхшы белә Романнардагы һәр геройның «баләкәй» тылы күз алдына килә Алар үзеннән-үзе ничектер зур тыл төшенчәсе белән бәйләнә Сугышчының ил алдындагы бурычын аңлавы һәм аны гомер бәрабәренә булса да үтәве шушы тыл белән бәйләнгән.

Фронт чынбарлыгы якты төсләрдән генә тормаган. Иңгә төшкән авыр йөк, билгеле, үзәкләре нык булмаганнарны тиз сафтан чыгаргандыр. Хисам Камалов әлеге мәсьәләләрне дә тыл белән, өй белән, сугышка кадәрге тормыш мөнәсәбәтләре белән тыгыз бәйләнештә ала. Аның беренче романында майор Мостафин кайчандыр үз йортына зур бәла-каза китергән берәүнең язмышын уңай якка хәл итә Үч алмый. Уйлап карасаң, теге адәм әле икеләтә гаепле—гаделсезлекне чор исеменнән, власть исеменнән эшләп килгән. Язучы, әнә шул рәвешле каршылыклар эченә чумырып, геройларның характерындагы, үз-үзен тотышындагы эчке механизмны ачарга җай эзли.

Сугыш чынбарлыгы аша кеше табигатен, халык язмышын аңларга омтылу, замандашларыбызны рухи һәм әхлакый мәсьәләләр турында уйлануга җәлеп итү. Бу әсәрләрнең иҗтимагый-фәлсәфи колачы, заманчалыгы менә шунда. Даут Мостафин, Мирхас Зәйнуллин кебек асыл егетләрнең, Фәимә кебек мәхәббәттә тугрылыклы, кыю кызларның гөнаһсыз яшьлеген, үлемсез уй-хыялларын, өзелеп калган җырларын язучы безнең чорга мирас итеп тапшыра.

Сугыш авазы ераклашкан саен, аңа аек мөнәсәбәт тә артканнан-арта һәм көчле дошманны тар-мар итү өчен нинди зур ныклык кирәклеге турында әдәбият та кыюрак һәм ачыграк сөйли бара. Бик вакытлы сөйли. Чын шаһитлар кими барганда... Әле алар исән чакта... Минемчә, «Һәркемнең гомере бер генә», «Безне өйдә көтәләр» кебек китапларның язылуы, аларда чынбарлыкның, кеше язмышының тирәнрәк чагыла баруы—турыдан-туры бүгенге көнебез, хәзерге чынбарлыгыбыз белән бәйле: димәк, тулырак, мәгънәлерәк итеп яшәргә өйрәнәбез, димәк, хакыйкатьне яңадан торгызу теләгебез көчле!

Аның җанын аңлап, якын күреп, Сибгат Хәким болай дип язган иде: «Хисамның тормышында, дөньяга карашының ныгуында Бөек Ватан сугышының роле искиткеч зур... Хисамны мин, ул икенче фронтта сугышып йөрсә дә, үз взводымдагы солдат кебек хис итәм...»

Хисам Камаловның үз язмышын күздә тотып язган «Яраланган пулеметчы» турындагы шигыре дә шул фикерне раслый:

Калдырыгыз пулемет төбендә,
Мин чигенә алмыйм барыбер!

Әдәбиятта, кешелеклелек өчен көрәштә үзен гади солдат итеп саный әдип һәм шушы юлда бер адым да артка чигенергә уйламый.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**

# ĞASIR YƏŞTƏŞE

SƏRWƏR ƏDHƏMOVANIN TUUINA 100 YIL

Monnan şaqtıy yıllar elek Sərwər xanım Ədhəmova, Gəlşat Zəynaşeva, Marzia Fəyzullina həm min Çallının M. Waxitov isemendəge urta məktəbenə uquçılar belən oçraşuğa barğan idek. Ul waqıtta əle KamAZ digən gigantnıŋ telgə də kerməgən çağı. Çallı da ber qatlı ağaç yortlardan torğan ğədəti awıl rayonı ğına. Qunaq yortları da keçkenə ikən. Bezne, suıqtan küşegep kilgən yulçılarnı, xucabikə açıq yəz belən qarşılamadı.

—Urın yuq. Qazannan bik olı keşelər kilə dip əyttelər. Şularga saqlap toram,—dide.

—İ, seŋlem, Qazanda bezdən də olı keşene tapmassıŋ,—dip, Sərwər apa matur itep yılmayıp cibərde.

Anıŋ tapqırlığı oşadımı, əllə olı keşelər bolay da urınsız qalmas dip uyladımı, xuca xanım qulın seltəp:

—Aldan kilgən urın eçen, uzığız əydə—dip, tıynaq ber bülmənen işegen açtı. Sorağannı da kətmiçə çəy də kiterep birde.

Bez təmam cılınıp, tellərebez çişelep, ozaq səyləşep utırdıq estəl yanında. Aq cəymələ yomşaq urınnarğa yatqaç ta küzgə yoqı kermədе.

Sərwər apanı belep betermə̈gənmen ikən əle min. Anı yazuçılar cıyılışlarında, balalar ədəbiatı seksiələrendə kürep yərim, qulyazmalar tikşergəndə səyləgən süzləren, bigrək tə ədəbi tel turındağı fikerləren küŋelgə seŋderergə tırışam, xalıq səyləmenə qolaq salırğa, süzleklərdən faydalanırğa digən kiŋəşləren yazıp ta quyğanım bar. Küpne kürgən, dərəcəle keşelər



*Tatarstan yazuçılarınıŋ VII qorıltayında (suldan uŋğa): tərceməçe Sərwər Ədhəmova, ədəbiat ğalime Gəlsem Məxəmmədova həm yazuçı Ləbibə İxsanova. 1968 yıl.*

belən aralaşqan, tatar ədəbiatı klassigı Qawi Nəcminen xatını bulğan, üze də tanılğan yazuçı, osta tərceməçe minem øçen buy citməs ber keşe kebek toyıla ide. Bu kiçtə min anın kin künelle, bik ğadi, uyın-kølke yarata torğan zat ikənen beldem. Xətta yəş ayırımlığı da onıtıldı. Ul bezgə üzenen yəş çağın, ədəbiat belən mawığa başlağan yıllarn søyləde.

Troisk şəhərenen møğəllimnər ğailəsendə tuğan Sərwər sabıy çaqtan uq tıyu-qısularnı kürmiçə, xør tabiğətle, şayan qız bulıp üsə. Anın yəşlege Oktəbrnen dawıllı kønnərenə turı kilə. İrek cillərе yanalıqqa sizger künelle Sərwərne də bøterep ala. Bu anın uqıtuçılar əzerli torğan «Dərelmøğəllimət»tə belem alğan waqıtı bula. Nərsə də bulsa ber yanalıq uylap tabarğa ğına torğan uquçılar «Yəş køç» digən jurnal çığarırğa bulalar. Üzlərе gektograf yasıylar, niçek kirək alay qəğəz yünətələr. Øç yøz danə basılğan bu jurnalda Sərwər Ədhəmovanın «Millətemə» digən berençe şiğere basıla.

Tomsk universitetının meditsina fakul'tetında uqığan waqıtında da, üze øçen genə, køndəlek dəftərenə şiğerlər yazıp quya torğan bula.

Bik awır yıllar bula ul. Suğış waqıtında bølgenlekkə təşkən ilne 1921 yılğı açlıq cəfalıy. İdel buyı ølkələrendə xalıq küpləp qırıla. Bu afəttən balalarnı saqlap qalu øçen ikməkle ølkələrdə yøzlərçə balalar yortları buldırıla. Tomsk şəhərendə də qırıqlap balalar yortı açıla. Sərwər Ədhəmova şularnın bersendə tərbiəçe-uqıtuçı bulıp eşli başlıy.

—Ul sabıylarnın sağışlı küz qaraşların onıtırlıq tügel ide,—dip søyləde Sərwər apa şul kiçtə.—Aşarğa-eçərgə citərlek anısı. Ləkin balalarnın sağınularına çıdar xəl yuq. Øygə qaytasım kilə dip cılıylar, əti-ənilərеn tellərennən təşermilər. Alarğa ber yuanıç bulsın dip, spektakl' quyarğa buldıq. Üzebeznen balalar yortındağı ber waqiğadan «Awıl tormışınnan ber küreneş» digən piesa yazdım. Mawığıp kittelər balaqaylar. Spektakl'ne qat-qat uynadılar.

Ozaqlamıy tormış caylana başlıy. İgen unışı da əybət bula. Balalarnı tuğan-üskən cirlərenə qaytaru mømkinlege tua. Sərwər Ədhəmova da, İdel buyınnan kilgən yøzləp balanı alıp, Qazanğa yul tota.

Biredə ul, berençe kønnən dip əyterlek, şawlap-gørləp torğan ədəbiat məydanına kilep kerə. Ədəbi oçraşularğa, şiğer kiçələrenə yøri başlıy. Hadi Taqtaş, Ğalimcan Niğməti, Ğədel Qutuy, Qawi Nəcmilər belən tanışa. Üzenen də bala çağı qazaq dalalarında ütkən Qawi Nəcmi belən duslığı ike yəş yørəknen qaynar məxəbbətenə əylənə, bəxetle ğailə tormışı başlana.

Kürenekle yazuçı Qawi Nəcminen Sərwər apa icatına yoğıntısı bulmıy qalmağandır. Ber ğailədə ike yazuçı yəşəgəndə tabiği xəl ul. Ədhəmova da şul yıllarda başlap, balalar øçen küp yaza. «Pioner qələme» (xəzer «Yalqın») jurnalı həm «Yəş lenınçı» (xəzer «Sabantuy») gəzitendə yana şiğerlərе basılıp tora. Yəşüsmerlərnen xolıq-ğədətlərеn, uy-toyğıların, izgelekkə-maturlıqqa sizger künellərеn yaqınnan belgən yazuçığa balalar belən obrazlar telendə søyləşü qıyın bulmıy. Anın şiğerlərе uqırğa cinel, otıp alırğa caylı, balalar tormışınnan künelle ber waqiğanı søyli torğan bula.

Üz ğomerendə Sərwər Ədhəmova keçe yəştəge balalar øçen unlap kitap bastırıp çığara.

Şulay da ul üzenen ədəbi sələten, køçen, waqıtın tərcemə eşenə birə. Kønbatış xalıqları ədəbiatın, klassikasın, Sovet yazuçılarının in yaxşı ürnəklərеn tatar uquçısı Sərwər Ədhəmova tərceməsendə də uqıy. Puşkin, Tolstoy, Gor'kiy, Prişvin h. b. ədiplərne tatarçalaştıra. Original əsər yazğan kebek ük tormışnı tirənten øyrənü, küp ezlənü sorıy torğan awır eş dip qarıy ul anar. V. Belinskiynın «əsərne uqığanda bez tərceməçene tügel, ə anın avtorın kürergə telibez», digən fikeren üzenə qanun kebek qabul itə. Tel baylığın øyrənü øçen tatar ədəbiatının in yaxşı əsərlərеn kübrək uqırğa kirək dip, bez yəşlərgə də sabaq birə ide ul.

Sərwər xanım Maksim Gor'kiy əsərlərеn ayıruça ilhamlanıp tərcemə itə. Anın altı tomlıq tərcemə əsərlərеn ike tapqır bastırıp çığara. 1934 yılda Bøtensoyuz yazuçılarının berençe siezdına barğaç, Aleksey Maksimoviç belən yaqınnan tanışa. Utırışlar arasındağı ber tənəfestə søyləşep torğanda:

—Minem əsərlərne tərcemə itü awırmı?—dip sorıy ədip.

—Cinel tügel,—di Sərwər xanım, dөresen əytə.

Ədip ana qayber kinəşlər birep əlgerə. Sonınnan, eş waqıtında qıyın xəlgə qalsa Sərwər xanım xat aşa Gor'kiy belən kinəşkələp tə ala.

Sərwər Ədhəmova Məxtər Auezovnın Lenin premiəse alğan «Abay» romanın tərcemə itkəndə ayıruça zur dulqınlanu kiçerə. Qazaq telen yaxşı belü genə tügel, kin cəyləwlərdə yanğırağan qazaq cırların, dumbra tawışların



*Sərwər Ədhəmova (suldan ikençe), Ləbibə İxsanova (suldan dürtençe), Marzia Fəyzullina (suldan bişençe) həm Gəlşat Zəynaşeva (suldan altınçı) uqıtuçılar belən oçrašu waqıtında.*

işetep üsü, qazaqlarnın tormış-kənküreşe, ğөref-ğədətləre belən tanış bulu romannı nəq originaldağıça tatarçalaştırırğa mөmkinlek birə. Bu zur xezmət өçen Məxtər Auezov Sərwər xanımğa çın küneldən rəxmət əytep xat yaza.

Məxtərəm tərceməçenen: «Bez hərqaysıbız üze ezləgən, üze dөres dip tapqan yul belən eşləp kildek həm kiləbez. Xəzer inde tərcemə əlkəsendə yıllar buyı tuplanğan azmı küpme təcribəbez bar,—dip əytkən süze istə qalğan. Tabiğəte belən tıynaq keşenen şapırınmıyça əytkən süzləre ul. Ə bit Sərwər xanımnın üzen, tanılğan yazuçılardan Məxmüt Maqsud belən Afzal Şamovnı tatar ədəbiatında tərcemə məktəben buldırğan ğali zatlar dip əytergə bula. Sonğı kənnərgə qədər eşləp kilgən Rəis Dautov, Yaxya Xalitov, Qıyam Minlebayev, Fəniə Ğaynanova, Sania Sibğatullinalarnı şuşı məktəpnen sələtle şəkertləre dip sanıybız.

İzge eş cirdə yatmıy, dilər. Sərwər xanım Ədhəmovanın tərcemə kitapları küp buın uquçılarnın künelen cılıttı, kin dөnya belən tanıştırdı, sənğətçə uylarğa өyrətte. Tuuına yөz yıl tulğan kөnne də anın ruxı, səykemle obrazı beznen künellərdə. Bez anı sağınıp iskə alabız.

**Ləbibə İXSANOVA**

# МАТУРЛЫГЫН МАКТАП ТАҢНАРНЫҢ...

РӘШИТ ГӘРӘЙНЕҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Тәкъдиренә язылганын сизенә идеме ул—шуңа ашыктымы, әллә картаймыш көнендә гаилә-көнкүреш шартлары жайланып, тормышы бер эзгә төшкәч, ниһаять, күнеле тынгы таптымы, Рәшит бик үк түгәрәк булмаган 65 еллыгын уздырды. Түбән Камадагы, Минзәләдәге, Актаныштагы дуслары һәм туганнары аңа күптән көтелгән жылы сүзләрен әйттеләр, иҗат сөенечләре теләделәр. Шагыйрь—шат, шагыйрь—дулкынланган, шагыйрь—бәхетле, әмма йөзенә күпмедер дәрәҗәдә монсулык билгеләре дә кунган иде. Җитмеш яшькә кадәр әллә барып житәм, әллә юк дию булгандыр инде...

Менә хәзер, югалту ачылары азмы-күпме басыла төшкәч, аның үзе һәм шигъри сүзе турында уйланып утырам әле.

Язмыш безне шактый иртә очраштырды. Минем Буа шәһәренең Мулланур Вахитов исемендәге урта мәктәбен тәмамларга йөргән чагым. 1954 елның яңа өметләр белән килгән якты язы. Мәктәпкә комсомол райкомыннан шалтыратканнар. «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре» ул вакытта шулай атала иде) газетасыннан шагыйрь Рәшит Гәрәй бирегә икән—аның әдәбият белән мавыгучы укучыларны күрәсе килә икән. Мин инде өйрәнчеклек чиркануын үтеп, Казан хәтле Казанда берничә шигырь бастырган автор ул чагында! Киттек без сабакташым Ленар Җамалетдинов белән (хәзер ул атак-лы фольклор галиме, Тукай бүләге лауреаты), күрдек ул тере шагыйрьне. Гади генә, тыйнак кына икән. Яшь булса да, ике китап чыгарырга өлгергән. Ә Буага кукуруз игүче яшьләр турында материаллар тупларга килгән.

«Чәкән» дигән сәер сүзне дә (Хрущев заманы бит бу!) иң беренче тапкыр без аның авызыннан ишеттек. Рәшит Гәрәй без күтәреп килгән шигырьләр белән танышты, киңәшләрен бирде. Үз шигырьләрен дә укыды. Безгә иң ошаганы «Заставалар аша» дигәне булды. Ул әле генә әдәбиятыбызга яңадан кайтарылган Муса Җәлилгә багышланган иде. Хикмәте Хода, без шул



*Укучылар белән очрашу вакытында (сулдан уңга) шагыйрьләр Рәшит Әхмәтҗанов, Рәшит Гәрәй һәм Әхмәт Рәшитов. 1982 ел.*

елны университетка керү имтиханнары тапшырганда, инша темалары арасында каһарман шагыйребезнең «Моабит дәфтәрләре» турындагысы да бар иде. Без инде, икебез ике жирдә утырган булсак та, әле күптән түгел генә танышкан Рәшит Гәрәй атлы шагыйрьнең әлеге әсәрен читләтеп үтмәгәнбез булып чыкты. Әлбәттә, иншабызга «бишле» куелган иде.

Казанда укый башлагач, Рәшит Гәрәй белән мөнәсәбәтләр чын кешеләрчә дуслыкка әверелде. Хәер, аның дөньяда бер генә дошманы да булмагандыр дип уйлыйм. Ул каләмдәшләренең уңышларыннан көнләшми, киресенчә, сөенә генә иде. Зур дәрәжәләргә, мәртәбәле исемнәргә кызыкмады. Аның өчен әйбәт шигырь язып, кешеләрне сөендерә алу үзе мәртәбә иде.

Мина Рәшит Гәрәй белән озак еллар дәвамында якыннан аралашырга туры килде: республикабыз авылларында үткәрелгән бик күп кичәләрдә бергәләп катнаштык. Туган-үскән якларга да икәүләп кайткан чаклар булды. Тәгаен генә фатиры булмаганлыктан, еш кына минем кысан бүлмәмдә кунып та калгалый иде. Ниһаять, ахыр чиктә Язучылар берлегенең ул вакыттагы житәкчесе Зәки Нури егетлек күрсәтте: документлары да рәтле-юньле тутырылмаган килеш (үзе турында кайгырта белми иде Рәшит!), фатир юллап бирде.

Төрле истәлекләргә бирелеп, аның бар гамәлләрен хәтердән кичерәм. Бик еш кына авылдан-авылга шигъри очрашулар үткәреп йөрибез. Гадәттә ул йокысыннан таң әтәчләре белән бергә тора. Башкалар әле йокы симертә. Рәшит Гәрәй шыпырт кына киенә дә урамнарга чыгып китә. Очраган һәр кеше белән әңгәмә корып тора. Теләсә кайсы авылның су буйларыннан урап йөри, чишмәләр чылтыравын, кошлар сайравын тыңлый, терлек-туарның, каз-үрдәкнең чыр-чуына колак сала. Шулардан шигъри моң таба. Аның белән бергә әдәби сәяхәткә чыккан каләмдәшләре йокыдан торганчы, ул инде бөтен авыл белән танышкан, хәтеренә гаять үзенчәлекле, гүзәл бер аһәң чыңлап торган шигырь беркеткән булыр. Аннан ул уендагы шул шигырен кәгазь битенә төшерер, иптәшләренә укып күрсәтер.

Саф күңелдән чыккан, алдашусыз, риясыз шигырьләр. Авыл халкында гына була торган сафлык Рәшит Гәрәйнең төп сыйфатын билгели иде бугай. Ул якын күргән Минзәләсе тарафына китеп, Малтабар авылындагы туганнары янына кайтып, Казаннан берничә айлар буена югалып тора иде. Шәһәр шау-шуын ничектер өнәп бетерми идеме ул, күңеле аны һаман авыл жиренә тартып торды. Минзәләсенә чын-чынлап гашыйк иде ул.

Туган жирнең газизлеге Рәшит Гәрәй күңеленә авыр сугыш елларында атлар көтеп, сабан сөреп, өйдән-өйгә почта таратып йөргән чакларда сеңгәндер. Ә иҗади иманы 17 яшендә үк «Совет әдәбияты» журналында, «Үсү юлы» альманахында, көндәлек матбугат битләрендә беренче шигырьләрен бастырганда, 18е тулып, Минзәлә педагогия училищесен тәмамлагач, Иске Мәлкән һәм Чебенле авылларында балалар укытканда, 19 яшьтән «Яшь сталинчы» газетасының үз хәбәрчесе булып эшләгәндә ныгыгандыр. Аннан солдат хезмәте—совет гаскәрләренең Германиядәге группасында кече лейтенант. Талантлы егетнең иң беренче китабын өлкән каләмдәшләре аннан башка гына—ул армиядә чакта бастырып чыгаралар. Иртә балигъ булу, иртә өлгерү—бу чор иҗатчылар өчен бик табигый күренеш. Мәскәүдәге әдәбият институтын да ул татар язучылары арасыннан беренчеләрдән булып тәмамлады. Шуңа күрә әзерлек, теоретик белем өстенә, татар халык иҗатын да әйбәт үзләштергән бу шагыйрьнең әсәрләре һәркемне җәлеп итеп тора иде. Алар җырларыбызга хас эчке моң белән өртелгән, ачык һәм аңлаешлы иде. Кызганыч, композиторларыбыз аның иҗатына сирәгрәк мөрәҗәгать иттеләр.

Рәшит Гәрәй бүген безнең арада юк шул инде. Татар авылы ихлас бер җырчысын югалтты... Соңгы елларда ул буыннары сызлаудан зарлана иде. Гомер буе авырлыклар күрә-күрә дөнья ку да, кайдан килсен инде ул пәһлеван сәламәтлекләре?! Шулай да ул шыңшымады—бәләкәй генә уңышына да сөенеп, дусларының кадерен белеп яшәде.

Минем архивымда Рәшит Гәрәйнең егермеләп хаты саклана. Аларда шагыйрьнең шәхси тойгылары, көндәлек борчу-мәшәкатьләре генә түгел, бүгенге әдәбиятыбызның бизәлмәгән хакыйкате дә чагыла. Әйдәгез, аның кайбер хатларын бергәләп укып карыйк әле.

**Әхмәт РӘШИТ**

Рәшит!

Сәлам барсын сиңа! Озак вакытлар буе хат яза алмый тордым. Җыентыгыңның кайсы якка хәл ителүен белми торып, язасы итмәгән идем. 1967 елда чыгачак «Беренче карлыгачлар»га бик күп авторлар (14 кеше!) кергән. Әзерләп бетергәч, кыскарта-кыскарта изаланабыз). Синең җыентыкны 1968 елга калдырырга диделәр. 1968 дә дә нәкъ шундый ук җыентык чыгару планлаштырыла. Бу хатны алу белән Шамил Рәкыйпов белән элемтәгә кер, җыентыгыңа өстәр өчен үзеңдәге барлык яңа шигырьләреңне җибәр. План инде төзелеп бетү алдында тора. Былтыргы кебек соңга калырга тырышма!

Андагы танышларның һәркайсына сәлам әйт! Әйбәт кенә эшләвеңне теләп— Рәшит.

*24. XI. 66. Казан.*

Әхмәт!

Сиңа һәм Казандагы барлык дусларга Минзәлә сәламе барсын! Иҗатыңда уңышлар теләп калам.

24 мартта язган хатыңны байтактан алган идем. Җавапны бүген генә язам. Сәбәбе—Казанга әллә үзем дә кайтып җитәрменме дип торган идем. Күрүенчә, мин әле һаман Минзәләдә. 14 апрельдә әнинең үлүенә бер ел тула. Шуны үткәрмичә китеп булмый (Менә шушы җөмләне язып бетерүем булды, синең «Беренче мәхәббәт»еңне җырлый башладылар. Чүпрәлеләр концерт биреп яталар. Син үзең дә, Чүпрәледә йөргән чаклар да искә төште).

Шул менә шул... Казанга инде 14 апрельдән соң кайтырмын дип торганда, Минзәлә редакторы шалтырата: «—Рәшит абый, кешеләребез җитми, берничә ай бездә утырып тор»,—ди. Үзебезнең егетләр бит, бер айга ризалык биреп, кичә дөрестән дә килеп утырдым. Гостиницада менә дигән ялгыз бүлмә бирделәр. Бу хатымны әнә шул бүлмәдә чуарлап утырам.

Минзәләдән авылга юл салына башлады. Димәк, җомга, шимбә, якшәмбе көннәрен Малтабарда уздырачакмын. Беренче кайтыш—11 апрельдә. Ә икенче атнада Казанга кайтып килермен кебек: 21 апрельдә соңгы тапкыр райвоенкоматка барасы бар. Чәенне куеп, 19 апрельдә (бәлки бер көн алда, яки соң) кетә торсаң да бер дә гөнаһ булмас.

Телефоннан кичә Эльс белән дә, Сәгыйдә белән дә сөйләштем. Акча җибәрәбез диделәр. Анарчы да бер тапкыр алган идем инде (Алексеевск өчен).

Минем хәлләр менә шул. Әхәтнең әйберен эшләп бетереп җибәрдем. Хәзер үземнекe белән утырам.

Үзеңдә ни хәлләр бар? Кәефләрең әйбәтме? Егетләр нишләп йөриләр? Габделхәй симермәдеме әле? Барлас нишләп йөри? Үзең турында да, Казан хәлләре турында да әйтеп, тиз генә хат яз әле (менә Гали абыйның «Идел поэмасы»н русча тапшыра башладылар).

Әхмәт! Иренмичә генә теге карточкаларны эшләп җибәрә алмассыңмы? Безнекеләр көтә. Уларына бик-бик җибәрәселәре килә инде.

Бер 15 көн чамасы, өйне җылытып, шунда эшләп утырдым. Мичкә бәрәңге тәгәрәттем. «Агымсулар...»ны укып чыктым. «Ни әйтергә? Ничек әйтергә»не шулай ук укып бетердем. Хәзер гәҗит укыйм.

Хат көтәм. Редакция исеменә яз. Сәлам белән—Рәшит.

*8. IV. 75. Минзәлә.*

Әхмәт дус!

Сиңа һәм Казандагы барлык иптәшләргә бик күп сәлам булсын! Иҗатыңда уңышлар, үзеңә исәнлек-саулык теләп калам. Менә мин бер-ике айга дип кайткан җиремнән Минзәләдә нәкъ биш ай чамасы юандым. Инде Казанга кайтырга дип, самолетка билетлар алгач, ревматизм тагын кинәт аяктан екты, менә бер атна инде больницада ятам. Белмим, азрак кузгалырга кайчан ирек бирер тагын... Мин бит монда җәп-җәйге киемнән кайткан кеше, салкыннары, яңгырлары сиздерми генә китереп бәрде, ахры. Торып утырырга да әмәл юк.

Бик сорагач, кайткан көннән бирле диярлек редакциягә булышып утырдым. Кешеләре җитми, эшкә килүчеләр юк, килә-нитә калсалар, торыр урын юк, дип табан ялтыраталар. Минем өчен бер ягы әйбәт булды: районның барлык хуҗалыкларында диярлек булып чыктым. Һәркайсы машинкада 9-10 биттән дә ким булмаган 26 мәкалә яздым. Аз-маз гына шигырьләр дә язылгалады шикелле. Кайберләрен «Социалистик Татарстан»да биргән иде. Мин редакциядә вакытта Минзәләгә Мидхәт, Нәфыйкъ,

Зөлфәт һәм Гамбәров килеп киттеләр. Фаилнын үлемен район үзәгеннән ерактагы бер авылда ишеттем. Көнелдә һаман әле борчу, әллә нинди бер читенлек.

Әхмәт! Матбугат йорты астындагы кибеттә минем «Синдә калам» бар иде бугай. Тагын бер бишне тәреп жибәрә алсаң, бик сөенер идем. Үзем белән алып кайтканы бетте. Ә больницада яңа танышлар арта тора. Аннан соң әйтеп яз: «Сәяхәтнамә»н Казан кибетләрендә бармы? Минзәләдә бар ул. Кирәк дисәң, бер 20не алып кайтырмын. Башка җыентыкларын күренми.

Хәзер менә шулар иде. Барлас һәм Габделхәйләр нишләп йөри? Кәрамиләр өйдәме? Жәйне кайда уздырдың? «Казан утлары» ның 10 саны күренмиме әле?

Хат көтеп, сәлам белән Рәшит.

*25. X. 82. Күзкәй.*

Хөрмәтле Әхмәт дус!

Үзеңә, Мәдинәгә һәм Казандагы барлык башка дусларга бик күп сәлам! Тормышыңда, эшеңдә, ижатыңда уңышлар, үзеңә саулык-сәламәтлек телим.

Хатыңны алып бик сөендем. Үзеңдәге, әдәбият дөньясындагы һәм, гомумән, Казандагы яңалыклар белән таныштыруың өчен зур рәхмәт. Минзәлә педучилищесынын 50 еллык бәйрәменә килгән әдипләр аша да Казан хәлләре белән азмы-күпме танышкан идем. Бер үк вакытта җанга рәхәт тә, шул ук вакытта шактый ямансу да булып китте. Казанга тизрәк кайтасы килә башлады. Һәм ул көн, ниһаять, якынлаша бугай инде.

Бүгенге-иртәгәле больницадан чыгып, 20ләре тирәсенә юлга кузгалырга исәп. 22 декабрьга самолетка билетка заказ биреп куйган идем, Бигеш аэродромыннан очарга туры киләчәк. Шуңа күрә бер көн алдан Түбән Камага барып кунарга кирәк. Анда минем апаларның, син белгән апаларның кызлары һәм кияүләре яши. Алар да бик ныклап чакырып киткәннәр иде.

Педучилище юбилее бик матур үтте. Хәер, ул хакта Мәдинә сөйләгәндер инде. Мин синең 25 данә җыентыгыңны алып куйган идем. Аларны Мәдинә артыннан җибәрдем. Авыр була, әйберем күп, дисә, үзем кайтырга да күп калмаган иде анысы. Юл кешесенә янчык та авыр, дигәндәй, юлда ана болай да шактый кыен булгандыр.

Бу хатымда сине сораулар белән борчып тормыйм инде, Әхмәт. Ни өчен, дисәң, миңа хәзер синең хатың килеп өлгермәячәк. Дөнья хәлләрен Казанда очрашкач сөйләшербез. Баштарак, байтак нәрсә язгандай иткән идем, соңгы айда кулга ни эләксә, шуны укудан бушап булмады. Мин бит хәтта мәкаләне дә акрын гына йөри-йөри язарга яратам. Тагын җәйне көтә башладым бугай инде. Үз гомеренне үзең куа-куа бар инде, инәенне... Газиз мәрхүм әйтмешли. Сәлам белән Рәшит.

*13. XII. 82.*

Хөрмәтле Әхмәт дус!

Сәлам сиңа Актаныш якларыннан! Әнә шундый ерак җирләрдән Рәшит абзаң Гәрәй яза әле бу хатны сиңа. Нишләп әле шундый җир читенә барып чыктың, дип аптырыйсыңдыр бәлки. Хәләл җефетең син фараз кылган җир читеннән булгач, берни дә эшләр хәлең юк, җанкисәгем. Әллә кайларга барып чыгасың икән ул. Ләкин син шуны да онытма: Актаныш бит әле ул мин туып-үскән Минзәлә ягы да. Башта анда кунак булдык, сиңа да аз-маз таныш булган Малтабар, Күзкәй, Калмия авылларында сабантуйлар карадык. Инде менә көннәрне әбиләрдә һәм бажайларда уздырып ятабыз, бакчада чүп утыйбыз, бәрәңге төбе өябез, колорадо кортына агу сиптерәбез һәм... лимонад эчәбез. Мондагысын эчеп бетергәч, тагын бер атнадан Түбән Камага кияүләргә китәчәкбез. Иптәш хатынның ялы әле август башларында гына бетә. Шунарчы башлар бетмәсә, июль ахырларында, мөгаен, Казанга да әйләнеп кайтачакбыз. Ә шунарчы әле сезгә шигырьләр җибәрә торырга булдым. Үз кулың белән кертеп биргә караганда, язган әйберләрне хат белән юллау җинелрәк бит ул. Берәр җаен табып бәлки радио аша кычкырта алырсыз. Алтмыш еллыгымны уздырганнан соң бер ел эчендә язган бөтен әйберем шушылардан гыйбарәт. Ничек бәяләсәң дә бәяләрсең, анысын үзеңә тапшырам. Ә шулай да укып чыгу белән өстәлең кырындагы чүп савытына ташламавыңны теләр идем.

Казанга кайткач күрешербез дип уйлыйм. Сиңа әле тагын бик зур гозерем кала. Анысын күрешкәч әйтермен. Хәзергә сау булып тор.

Үзеңә, гаиләңә, янындагы һәм Казандагы барлык дус-ишләргә күп сәламнәр юллап, иҗатыңда уңышлар теләп—Рәшит Гәрәй.

*6. VII. 92. Актаныш.*

# ЯЗЫЛУ БАШЛАНДЫ

Хөрмәтле укучыларыбыз! 2001 елның икенче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. Ул июнь ахырына кадәр дәвам итәчәк. «Казан утлары»ның индексы—73210.

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар игътибарына: «Казан утлары»на «Горпечать» киоскларында язылырга мөмкин. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була.

Яраткан журналыгыз—«Казан утлары»на язылырга онытмагыз! Яңа гасырда да бергә булыйк!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

Количество комплектов:

на 2001 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | ли-тер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал 73210 (индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | ______ руб.______ коп. | Количество комплек-тов |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ______ руб.______ коп. | |

на 2001 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)



# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ЕЛЛЫК ҖЫЕНЫ

2 мартта Татарстан язучыларының әдәби ел йомгакларына багышланган җыены булып узды. Анда җиде доклад тыңланды: **Рифат Сверигин** (проза), **Нәҗибә Сафина** (поэзия), **Рәдиф Сәгъди** (драматургия), **Равил Рахмани** (балалар әдәбияты), **Ркаил Зәйдулла** (публицистика), **Әлфәт Закирҗанов** (тәнкыйть), **Владимир Корчагин** (рус әдәбияты). Җыелышта, шулай ук, Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе рәисе **Равил Фәйзуллин** XXIII корылтайдан соң башкарылган эшләр турында исәп-хисап чыгышы ясады.

Тыңланган докладлар һәм чыгышлар буенча фикер алышуларда Чаллы язучылар оешмасы җитәкчесе Вахит Имамов, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Флүс Латыйфи, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе Рәзим Вәлиуллин, язучылар Миргазиян Юныс, Айдар Хәлим, Кыям Миңлебаев, Резеда Әхтәмова, Нияз Акмал, Лена Шагыйрьҗан, Бөтентатар «Мәгариф» оешмасы вәкиле Гөлфәния Җәләлова, «Мәгариф» һәм Татарстан китап нәшриятлары директорлары Мөдәррис Вәлиев белән Дамир Шакиров катнашты. Алар әдәби жанрлар буенча ясалган докладларда әйтелгән фикерләрне тулыландырдылар, гомумэшне яхшыртуга юнәлтелгән эшлекле тәкъдимнәрен әйттеләр.

Җыелышны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин алып барды.

## НӘҖИП ҖИҺАНОВ ХӨРМӘТЕНӘ

2 мартта М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында күренекле татар композиторы, җәмәгать эшлеклесе, СССР халык артисты, СССР һәм Татарстанның Дәүләт премияләре лауреаты Нәҗип Җиһановка 90 яшь тулуга багышланган юбилей кичәсе булды.

«Нәҗип ага бер кеше тормышында мөмкин булмаган эшне башкара алуга ирешә,—диде кичәдәге чыгышында Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев—Милли традицияләрне файдаланып, ул татар халкы музыкасын яңа баскычка күтәрде—аны югары сәнгать дөньясына алып керде.

Ул Татарстан Композиторлар берлегенә 30 елдан артык җитәкчелек итте. Аның мирасы гаять зур—8 опера, 3 балет, 17 симфония, романслар, җырлар һәм сюиталарны үз эченә ала. Шушы барлык әсәрләр буыннан-буынга тапшырылачак, аларның кыйммәте елдан-ел үсә барачак.»

Юбилей кичәсендә Татарстан вице-премьеры И. Хәйруллин, мәдәният министры И. Тарханов, Россия Композиторлар берлеге рәисе, Россия халык артисты В. Казенин катнашты.

* * *

Күренекле композитор истәлеген мәңгеләштерү максатында, аның татар профессиональ музыка сәнгатенә һәм милли мәдәнияте хәзинәләренә, республикада музыкаль белем бирү системасын үстерүгә гаять зур өлеш кертүен билгеләп, җәмгыять һәм дәүләт алдындагы хезмәтләрен искә алып, Татарстан Президенты М. Ш. Шәймиев Казан дәүләт консерваториясенә Нәҗип Җиһанов исемен бирү турында Указ чыгарды.

## ӘДИПНЕҢ ЙӨЗ ЕЛЛЫГЫ

Халык язучысы Гомәр Бәшировның тууына 100 ел тулуны җәмәгатьчелек зурлап билгеләп үтте. 27 февраль көнне Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасында классик әдипкә багышланган тантаналы кичә булды. «Җидегән чишмә» дип аталган бу кичәдә Татарстан Дәүләт Советы рәисе Ф. Мөхәммәтшин катнашты һәм чыгыш ясады. Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ф. Галимуллин язучы таланты һәм иҗатының зурлыгы турында сөйләде.

## БАКЫЙ УРМАНЧЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Татарстан Рәссамнәр берлегенең күргәзмәләр залында Бакый Урманче исемендәге бүләккә кандидатлар эшеннән торган күргәзмә-конкурс ачылган иде.

23 февральдә Казанның Б. Урманче музеенда шушы күргәзмә-конкурска йомгак ясалды һәм җиңүчеләргә аның исемендәге премияләр тапшырылды.

Бакый Урманче исемендәге премияләр дүрт номинация—рәсем сәнгате, сынлы сәнгать, графика һәм декоратив-гамәли сәнгать буенча билгеләнде. Рәсем сәнгате буенча рәссам **Илдар Зарипов** («Күчтәнәч»), графика буенча **Григорий Эйдинов** («Булгаковча төшләр») һәм **Нияз Хаҗиәхмәтов**

(«Чыңгыз хан»). Декоратив-гамәли сәнгать буенча **Софья Кузминых** лауреат исеменә лаек булдылар. Ә сынлы сәнгать номинациясе буенча бүләк бирерлек эш табылмады.

### ТӨРКИЯДӘ ОЧРАШУЛАР

Февраль ахырында Төркиянең Истанбул шәһәрендә төрки дөньяның хәзерге әдәбияты мәсьәләләренә багышланган конференция булды. Аның эшендә Татарстаннан да делегатлар катнашты. Делегация составында Фоат Галимуллин, Мөсәгыйт Хәбибуллин һәм Харрас Әюпов бар иде.

Төрки илләрдән килгән язучылар әдәбиятның хәзерге торышы, аны үстерү һәм үзара мөнәсәбәтләрне җайга салу мәсьәләләре хакында сөйләштеләр. Татарстан делегациясе Казакъстан, Төркия, Кыргызстан һәм башка илләр вәкилләре белән очрашты, үзара хезмәттәшлек итү юллары турында фикер алышты. Форумда Фоат Галимуллин чыгыш ясады.

### ТӘНКЫЙТЬ ҖАНЛАНМАСМЫ ДИП

14 февральдә әдәби тәнкыйть остаханәсенең күчмә утырышы «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясендә уздырылды. «Вакытлы матбугат һәм әдәби тәнкыйть» дигән темага багышланган «Түгәрәк өстәл» сөйләшүендә А. Әхмәдуллин, К. Тимбикова, Рифә Рахман, Н. Сафина, М. Хуҗин, Ә. Рәшитов, Ә. Закирҗанов, Н. Гамбәр, Г. Гомәр һ. б. лар кызыклы һәм эчтәлекле чыгышлар ясадылар. «Түгәрәк өстәл» сөйләшүен остаханә житәкчесе Мансур Вәли алып барды.

### КЫЮ ОЧ, «АКЧАРЛАК»!

Башкортстанда яшәүче татар язучыларының Башкортстан «Китап» нәшриятында «Акчарлак» исемле татарча альманахы басылып чыкты.

Җыентыкка җәмгысе 42 авторның иң яхшы әсәрләре сайлап алынган.

### ИЛҺАМЛЫ ҖЫР

15 февраль көнне «Җыен» фонды һәм Татар дәүләт филармониясе Г. Камал театрының кече залында халык җырчысы **Илһам Шакировның** 66 яшьлегенә багышлап «Илһамлы җыр» дигән кичә үткәрде. Җырчы иҗат юлындагы истәлекле вакыйгаларны искә төшерде һәм, тамашачыларны ялыктырмыйча, армый-талмый җырлады. Ижатташлары-дуслары җырчыны һәм тамашачыларны җанга якын җырлар белән сәламләделәр.

### ГАЛИМ ЮБИЛЕЕ

Язучы һәм әдәби тәнкыйтьче, профессор, Татарстан Язучылар берлеге рәисе, ТР халык депутаты **Фоат Галимуллинга** 60 яшь тулды.

Юбилей уңаеннан котлаулар юбилярның Язучылар берлегендәге бүлмәсендә яңгырады.

Юбилярга Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев исеменнән котлауларны ТР Президенты Аппараты житәкчесе Әгъзам Гобәйдуллин житкерде. Ул Фоат Галимуллинга Татарстан Республикасының Мактау Грамотасын тапшырды. Юбилярны котларга ТР Премьер-министр урынбасары Илгиз Хәйруллин, министрлыклар вәкилләре, республиканың иҗади берлекләре житәкчеләре, хезмәттәшләре килде.

### БҮЛӘК ИТЕЛГӘН БҮЛӘК

Бөгелмә татар җәмәгатьчелеге быел үзенең Һади Атласи исемендәге премиясен танылган язучы, җәмәгать эшлеклесе, техник фәннәр докторы **Зәки Зәйнуллинга** тапшырды. Әлеге бүләк аңа милли мәдәниятне һәм татар халкының үзаңын үстерүдә күрсәткән фидакарьлеге өчен бирелде. Язучы исә премия акчасын районның Карабаш бистәсендәге татар мәктәбенә тапшырды. Ул акча мәктәптә яхшы укыган, татар әдәбиятын житди үзләштергән укучыларга махсус премия итеп биреп барылачак.

### НӘҖИП НӘКЪКАШ ДӨНЬЯСЫ

1 мартта Казанның Халыклар дуслыгы йортында танылган рәссам-хаттат, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Нәҗип Нәкъкаш әсәрләреннән торган күргәзмә ачылды. Бу күргәзмәнең үзенчәлеге шунда: автор соңгы 80 ел эчендә онытылган борынгы сәнгатебезнең аерым бер төре булган гарәби каллиграфияне, шәмаил, ләүхә, туграны тергезеп, яңартып җибәрүче.

Күргәзмәдә 100 гә якын хезмәт урын алган. Биредә традицион шәмаилләр, шәхесләргә багышланган тугралар, шәмаил-миниатюралар һәм китап бизәлеше үрнәкләре куелган.

---


## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** «Яз»—фотоэтюд.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Әдәбият галиме Вил Ганиев.

# ЯҢА КИТАПЛАР

Мөсәгыйт ХӘБИБУЛЛИН. **Аллаһы бүләге.**—Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2000.—304 бит. Тиражы—3000 данә.




Мөсәгыйт Хәбибуллин—«Кубрат хан», «Илчегә үлем юк», «Шайтан каласы», «Хан оныгы Хансөяр» кебек тарихи романнары белән укучыларга киң билгеле язучы. Бу яңа романда Урта Иделдә яшәүче төрки-болгарларның XIII гасыр башында кичергән фаҗигале хәл-әхвәлләре бәян ителә. Мәгълүм булганча, борынгы болгар бабаларыбыз монгол яуларын байтак еллар буена Русь җирләренә, гомумән, Европага җибәрми тоткарлап тора. Аяусыз сугышлардан соң, чамасыз зур югалтуларга дучар булгач кына, 1236 елда монголлар болгарларның ил-калаларын яулауга ирешәләр. Идел буе Бөек Болгар дәүләте үзенең мөстәкыйльлеген югалта...

Әсәр киң катлам укучылар җиңел аңларлык йөгерек телдә язылган, заманча полиграфик югарылыкта нәшер ителгән. Китапның мөхәррире—Н. Вәлитова, рәссамы—В. Булатов.

Нур ӘХМӘДИЕВ. **Чакматаш.**—Казан. «Рухият» нәшрияты. 2000.—512 бит. Тиражы—3000 данә.




Шигырьләр, поэмалар, балладалар, риваятьләр... Бу җыентыкка нефть төбәгендә яшәүче танылган шагыйрь Нур Әхмәдиевнең утыз елдан артык иҗат гомереңең иң яхшы үрнәкләре тупланган.

Эчтәлекләренә һәм язылу вакытларына нисбәтән автор әсәрләрен алты бүлек итеп төзегән: «Чакматаш», «Мәҗүсилек», «Мәҗнүни-ана», «Татарлыктан оялмыйм мин», «Чит җирләрдә йөреп гыйбрәт ал», «Поэмалар, балладалар...»

Китапны «Татнефть» карамагындагы «Рухи янарыш фонды» нәшер иткән (Бу Фонд соңгы берничә ел эчендә унга якын шагыйрьнең сайланма әсәрләрен чыгарган иде инде: Г. Афзал, С. Сөләйманова, Рәшит Әхмәтҗанов, Ф. Яруллин, Зөлфәт, К. Булатова, Ф. Гыйззәтуллина...). Кереш сүзне бу китапны төзүче-мөхәррир Наис Гамбәр язган. Рәссамы—Д. Җәлалетдинов.

Индекс 73210



**Вил Ганиев**

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)